
ISSN 0206—418

# КАЗАН УТЛАРЫ

7. 1992



## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Мөхтәрәм милләттәшләр!

Журналыбызның узган саннарында без, хәлебезнең мөшкел-леген белдереп, сезгә мөрәҗәгать иткән идек. Анда әле журналга икенче яртыеллыкка язылу бәясе тәгаен генә билгеле түгел иде. Бишенче санда без сезгә икенче яртыеллыкка язылу бәясен күрсәтеп (60 сум), бланк тәкъдим иттек. Шул бланкны тутырып, элемтә бүлекләренә барырга кирәклеген искәрттек. Әмма, шуңа да карамастан, редакция адресына юллап акча җибәрүчеләр дә (48 сум яки 60 сум) бар.

Кабатлап искәртәбез: журналга язылу өчен акчаларыгызны редакциягә җибәрмәгез, ә элемтә бүлекләренә барыгыз. Редакция подписка эшләре белән шөгыльләнми, чөнки бу аның вәкаләтләренә керми.

Күп кенә газета-журналлар, матди ярдәм алу өчен, редакция фонды оештырдылар. Бүген без дә шундый фонд оештыруыбызны белдерәбез һәм Татарстанда, Россиядә, БДБ дәүләтләрендә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә мөрәҗәгать итәбез. Безгә ярдәм итәргә теләүчеләр булса, хәл кадәри акчаларын түбәндәге адрес белән күчерә алалар:

420066, г. Казань, ул. Декабристов, 1. Волжско-Камский акционерный банк РКЦ ГЦБ. Р/счет № 700161998/2345114 МФО 265005.

Яңадан искәртеп үтәбез: бу иганә акчалары журналны яздырып алу өчен түгел, ә бәлки аның матди хәлен җиңеләйтү максатларыннан чыгып кына җыелачак. Әйткәнебезчә, редакция үзе журналга яздыру эшләре белән шөгыльләнми.

Журналыбызның 70 еллык бәйрәме көннәрендә редакция исеменә бик күп истәлекле бүләкләр тапшырылды, шул исәптән, акчалата иганәлек (спонсорлык) итүчеләр дә булды. Шулардан Үзбәкстан Республикасы мелиорация министрлыгы (министры Р. А. Гыйниятуллин) — 200 мең, «Татнефть» берләшмәсе (генераль директоры Р. Г. Галиев) — 200 мең, Казан компрессмаш производство берләшмәсе (генераль директоры Ә. М. Галиев) 20 мең сум күләмендә иганә акчалары күчерделәр. Бу оешмаларның барлык хезмәт коллективларына һәм җитәкчеләренә аерым рәхмәтебезне белдерәбез.

Сезнең ярдәм белән «Казан утлары»ның нурлары тагын да балкыбрак торыр, дип өметләнәбез, кадерле укучыларыбыз, мөхтәрәм милләттәшләребез!

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

7

(837)

1992

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Р. ХАРИС. Бөек хәбәр. *Шигырьләр* ..... 3
С. АЛИШЕВ. Татар халкының батыр улы ..... 9
Җ. РӘХИМОВ. Батырша. *Роман* ..... 11
Л. ШАГЫЙРЬҖАН. Өченче микрофон. *Шигырьләр* ..... 83
А. ХӘЛИМ. Өч аяклы ат. *Повесть* ..... 88
Ф. ЯРУЛЛИН. Һаман да бер ук кыйблам. *Шигырьләр* ..... 130
И. ГЫЙЛАҖЕВ. Йолдызлардан эзлим үземне. *Шигырьләр* ..... 135

ПУБЛИЦИСТИКА

М. Рәхимкулова, Л. Хәмидуллин. Университетлар үрнәгендә ..... 138

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

С. Хафизов. Яңача караш кирәк ..... 157
Л. Кәшфиева. Яңарыш һәм сатира ..... 164

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫННАН

М. Гайнетдинов. XVII йөздә татар яңарыш хәрәкәте ..... 170

Г. Ахунов. Аналар бәхете өчен көрәшүче (*Язучы Рәисә Ишморатовага 75 яшь*) ..... 187

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 191

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**

**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**

**Тәлгат Галиуллин**

**Аяз Гыйләҗев**

**Салих Маннапов**

**Зиннур Мансуров**

**Ростәм Мингалимов**

**Фәрвәз Миңнуллин**

**Минтаһир Минһаҗев**

**Мөхәммәт Мәһдиев**

**Ринат Мөхәммәдиев**

**Рашат Низамиев**

***(баш мөхәррир урынбасары)***

**Индус Таһиров**

**Марс Шабаев**

***(җаваплы сәркатип)***

**Тәүфикъ Әйди**

**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Поэзия и проза»: начало романа ДЖ. РАХИМОВА «Батырша», окончание повести А. ХАЛИМА «Трехногий конь», стихи Р. ХАРИСА, Л. ШАКИРЗЯНОВОЙ, Ф. ЯРУЛЛИНА, И. ГИЛЯЗОВА.
«Публицистика»: статья М. РАХИМКУЛОВОЙ и Л. ХАМИДУЛЛИНА «На примере университетов».
«Литературная критика»: статья С. ХАФИЗОВА «Новый взгляд», статья Л. КАШФИЕВОЙ «Возрождение и сатира».
«Из истории татарского народа»: статья М. ГАЙНУТДИНОВА «Движение национального возрождения в XVII веке». Статья С. АЛИШЕВА «Храбрый сын татарского народа».
Статья Г. АХУНОВА «Борец за счастье матерей» (К 75-летию писательницы Раисы Ишмуратовой).
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: картина уфимского художника М. Вафина «Батырша»; известный поэт, драматург Р. Мингалим.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Кояш Тимбикова, Тәүфикъ Әйди, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.

Производствога бирелде 2.04.92 ел. Басарга кул куелды 7.06.92 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70\times108\ ^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 23720. Заказ В-254. Бәясе 1 сум 80 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1992 ел.

# ШИГЪРИЯТ

## Ренат Харис

### Бөек хәбәр

I

*«Бер-береннән ни турында сораша алар?*
*Бөек хәбәр турында...»*

Коръән. «Хәбәр» сүрәсе.

Алда ни буласын белми күзен йомып баручылар,
шуның өчен адым саен көтмәгәнгә таручылар,
безне анда ни көтә дип уйлый-уйлый аручылар,
тиздән бәя төшә диеп ихлас өмет итүчеләр,
акча алыштыруларга аждаһа кебек үчлеләр,
йә Аллаһдан, йә Иблистән бөек хәбәр көтүчеләр,—
кайсы күбрәк вәгъдә итсә, шуның белән китүчеләр, —
ул хәбәрне бүген сезгә әйтәчәкмен үзем, кыеп:
кояш чыкты,
һава иссез,
юл тотрыклы,
ә су сыек —
сөенә белегез!

2

*«...Һәм без сезне җөп итеп яраттык,*
*һәм тынычлану вакыты дип сезгә төнне билгеләдек,*
*һәм яшәү вакыты дип сезгә көнне билгеләдек...*

Коръән. «Хәбәр» сүрәсе.

Таңнан торып, киеп камыт, тартып арба,
әй эшлибез — янәсе лә бәхет арта...
Әйе, арта! Маңгайдагы җыерчыклар...
Ярь-яшь килеш күбебезгә бөкре чыккан.
Шаяртабыз: — Яшьләр житкәчтен кырыкка,
ние гаҗәп, эшләр дә китә шырыкка...
Ныклап баксаң — әле гомернең уртасы,
ә күбебез инде яшәүнең туртасы.
Маңгай белән җир сөрәбез көннән көнгә —
без Вакытның беләбез бит көнен генә.

---

Ренат ХАРИС (1941) — *шагыйрь, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән күпсанлы шигырь китаплары авторы. Ул — М. Җәлил исемендәге премия лауреаты. Казанда яши.*

Төне дә бар! Ул бит йомшак зәңгәр юрган,
ә Җир өсте ятак итеп яратылган.
Көндез эшлик! Һәм ул шулай тиештер дә...
Ә төннәре, алла кушып,— сөешергә!

3

*«...котылу урыны бар —*
*баглар һәм йөзем бакчалары,*
*вә тулы түшле яшьтәш хатыннар,*
*вә тулы саба.»*

Коръән. «Хәбәр» сүрәсе.

Аллы-гөлле чәчәк тулы баглар,
тулы түшле яшь-яшь хатыннар,
тулы саба... һәр ир-затның моңа
мөмкинлеге, хәтта хакы бар.

Тыныч өйләр, урман аланнары,
алып ирләр йөри көлешеп.
Тулы саба... һәр хатынга болар
күпме кирәк, шулай тиешле...

Кул җитмәслек йолдыз мени болар?!
Һәм җитә дә — әйтсәк дөресен.
Канатлылар болытларны коча,
аяклылар йөри йөрисен...

Хәмер елгалары, еллар агып,
тутыралмый безнең бугазны,
түшле хатыннарга бурычлыдыр
ирләрнең дә Җирдә бик азы,

кайгылардан ләкин котылу юк...
Безгә бу Җир никтер бүген ят...
Аңлы килеш онытылып булса,
җәннәт булыр иде бу дөнья.

* * *

Күкләр тетрәп, баш түбәмә
коелган мәлдә йолдыз,
һич көтмәгәндә калганда
ни маяксыз, ни юлсыз,
«Яшәргәме, чикләргәме?»
дигән уйлар җәтмәсен
өзәргәме, әллә... ме дип,
икеләнгән чакта —
Син,
Син
җанның елдырымына
өстисең тере ялкын,
канда батмас, туңда катмас,
ут алмас татар халкым...

# Бакый Урманче

Исендәдер, исендәдер, Бакый ага,
кыш көне дә кайткан идек без Казмага,
болай гына, иснәргә авыл һавасы —
калада авылдан килгән кем табалсын
сулагач та җан исерә, акыл айный
торган һава!.. Хәзер моны мин дә аңлыйм.

Син ул чакта бик яшь идең — җитмешеңә
бер чакырым иде әле... Чит кешегә
сөйләсәң дә ышанмастыр — җегәреңнең
утыз яшьлек ун хатынга җитәрлеген
син яшерми идең миннән, якын күреп:
сокланып яши белүдә,— диеп,— сере...

...Иртәгесен җил котырды, китте буран —
көн яктысын ак кар сибеп урлый торган...
Күк белән Җир тоташтылар, ходай кушып.
«Минем күккә аша торган чагым шушы,
тулпар кирәк, тулпар,— дидең,— артлы чана —
буран саен никтер йөрәк канатлана...»

Дилбегәне үзең тоттың. Айгыр оча
киртләч кырлар буйлап... Юк, юк, бозваткычтай
ерып бара әллә карны, әллә күкне...
Ахры, Киек каз юлына менеп җиттек
дисәм, дөнья әйләнәсен бер уратып,
каршыбызда калыкты Черкен зираты.

Син чанадан карга чумдың, чумдың билдән...
«Әткәй, әнкәй! Ишетәсезме — сезгә килдем»,—
дип кычкырдың... Беравыкка буран тынды,
әйтерсең, карга өере, арып, кунды
каберләрне саклап торган тирәкләргә...
Мөмкинме соң моны сүздә сурәтләргә —

зиратларда агач түгел, җаннар шавы
ега икән кешеләрне, өскә авып.
Бакый ага, син булып син дә түзмәдең...
толыбыңны көрткә яптың да тезләндең...
Балбал кебек... Дога кылдың онытылып...
Яңа өйгән көрт астында калды толып...

Торып бастың... Син — Кол Гали, тере «Сагыш»...
Мин сорадым: «Шушы мени күккә ашу?»
Һәм син әйттең: «Хәтереңә бикләп берүк:
күккә ашу — ул асылда җиргә керү,
аннан чыгу... һәм мин чыктым. Басып торам...
Күңелемдә күк тынлыгы, монда буран

фәрештәләрен тузгыта — сыный мине...
Ишетегез! Мин буранга сыймыйм инде»—
дип кычкырдың... Айгыр, өркеп, чапты дулап
ак мәрмәргә әверелгән кырлар буйлап...
Ә син калдың... Килсәм янына әйләнеп,
урыныңда бары пәйгамбәр һәйкәле...

* * *

Безнең барлык кылганнарны
тарих торадыр барлап...
Каеннар санын арттырдык
имәннәрне акшарлап —
алардан, диеп, Җиргә ямь,
илебезгә яктылык...
Башка агачлар яныннан
уздык без күзне йомып...
һәм бер заман яңгыр яуды,
юды барлык буяуны...
Иван булып йөргән татар
Имам булып уянды.

## Гомәр Бәширов

Исәндәдер, шәп хәтерле Гомәр ага,
иске журналлардан тузан кага-кага,
язучылар китапханәсендә генә
«урыс башлы татар» белән бер әңгәмә
үткәрүең, Җир шары күк эчтән көеп,
тәре юкмы йөрәгендә моның, диеп.

Йөрәгемә кертә алдың син кулыңны.
Капшап таптың аркылыны-торкылыны!..
Күзләреңдә тантана итте шулчакны
Мефистофель күзендәге зәһәр чаткы.
Ышанычың сынды синең, өметең дә
күзне кисте, әйләнеп ачы төтенгә.

«Йә, нәрсә бу» дияр өчен бәреп йөзгә,
бәгырьдәге кылларымны өзә-өзә,
аркылыны-торкылыны кырыс кына
суырып алдың күкрәктәге кынысыннан.
Алтын түгел, ялтырап торган корыч ласа!
Идегәйләр кулындагы кылыч ласа!

Әйе, бер чир бар татарда, Гомәр ага —
бер-берсенә ул кушамат, ярлык тага,
җайлый белә чыпчык, чумар һәм песиен,
шаяруга корылганын, сәясиен.
Үзең әйттең: — Безнең татар бик тиз кыза,
кушаматлар шаярудан шуңа уза...

Исәндәдер, шәп хәтерле Гомәр ага,
көндәй балкып, иңнәремнән кага-кага,
алып керден бөек эзләр ишле кырга.
«Кылычың бар... Каләм ит тә җырлар тырна!» —
диеп әйттең... Аннан куйдың бераз мактап,
араладың мине шулай кушаматтан.

һәм мин, менә — яхшыдырмы, ямандырмы —
ак кәгазьгә үз хәлемчә җырлар тырныйм.

Миндәйләр күп татарның олы кырында,
аларга да син кылыч-каләм турында
сөйләгәнсең... Һәр халыкка, сирәк-мирәк,
үз туксаны туксан булган намус кирәк.

* * *

Җил исеп куйды да кисеп,
һавада йалт-йолт алтын...
Иренеп кенә сузылып,
мин берсен тотып алдым,
каен яфрагы кебеген...
Баксам — алтыны тутык.
Без алтын да тутыгырлык
нинди заманда тудык? —
дигән фикер — салкын ялкын —
бер кабынды, бер сүнде...
Китегезче, сары уйлар,
шөбһәләнү, көрсенү —
Һаваларда йалт-йолт алтын,
кояшның юмарт чагы.
Сүнү алдыннан кабыну...
Күңелдә көз чуагы.

## Сибгат Хәким

Исеңдәме, Сибгат ага (шулай дисәм,
үпкәләмә — миңа бит син һаман исән),
судан чак-чак юешрәктер — коры шәраб
йота-йота бер утырган идек сайрап,
сорау-җавап, җавап-сорау алыштырып,
һич чагышмас нәрсәләрне чагыштырып.

Ул заманда шәраб арзан, татлы иде.
Аны эчкәч туган сүзләр затлы иде,
кыйммәт иде тарих битләре өчен дә,
кыйммәт иде кантур бетләре өчен дә,
чөнки кайчак шундый әңгәмә бетүгә,
чакырттылар обкомга йә кегебегә.

Белдең... Белдек... Ә исеңә төшерүгә,
әйтә идең: «Әбиләрен өшкерим лә...»
Муса кайтты, Туфан кайтты... Дәрдемәнд тә...
Ә «Идегәй», ә Гаязлар бары мәрттә —
алар исән... Уяныплар... ышаныгыз!
Ышансагыз — коры булыр ыштаныгыз...»

Башкаларның белмим ничек, Сибгат ага,
минем — коры, чөнки яла яга-яга
чыныктырып бетерделәр — бу да файда —
дәва алып йөрисе юк әллә кайдан.
Күптән түгел янә бер дус, шактый азып,
хәтта халык дошманы дип атый язды...

Исендәдер, Сибгат ага, шәп бер кичтә,
судай коры затлы шәраб эчә-эчә,
сиңа сорау биргән идем туры ярып:
«Бүген татарда ничә зур шагыйрь барын
әйтегезче, кемнәр алар? Без дә белик...»
Йа хода, син шешә тотып, шәраб бүлеп

бирдең безгә, беравыкка калдың тынып,
күзең түшәмне капшады. Аннан тонык
аккорд алды өстәлемдә бармакларың,
рояльгә баскан шикелле тармакланып.
Әкрен генә әйттең аннан: «Алар... өчәү —
берсе Туфан, берсе — Маннурдыр, минемчә,

ә тагын берсе, егетләр...» Син тукталдың,
иң аз шәраблы стакан сорап алдың,
аннан әйттең елмайдың да әллә ничек:
«Тагын берсе... Тагын берсе... Әйдә эчик
салып куйган шәрабларны, айнымасын...»
Һәм без эчтек... Эчтек никтер торып басып.

Һәм без моны күп сөйләдек мәзәк итеп,
янәсе син бу сораудан шома киттең,
«без үзебез дип торабыз» дип әйтмичә...
Һәм төшендек уйлагачтын әллә ничә:
калдыргансың син безгә, чын хәким кебек,
тагын берсе мин булырмын дигән өмет.

* * *

Начар мыни патша булу?!.
Начармы түрә булсаң?!.
Дөньяда бик күп яхшылык
шулардан, күрә белсәң!..

Шагыйрь патша булмый, имеш...
Бик буласы... Бик тели...
Алла буласы килгәнгә,
патша буласы килми...

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ БАТЫР УЛЫ

«Казан утлары»ның 1986 елгы 2 санында «Батырша батырлыгы» исемендә тарихи очерк урнаштырылган иде. Журналда тарихи роман басыла башлау уңаеннан мин әлеге очерктан фикерләрне кабатламыйча, аңа кайбер өстәмәләр кертеп, халкыбызның батыр улы турында тагын искә алырга уйладым.

Билгеле булганча, Габдулла Гали углы Мәзгыйльдин (Батырша) хәзерге Башкортстан республикасының Балтач районы Карыш авылында игенче Гали ага гаиләсендә 1715 елда дөньяга килә. Гали ага, гаиләсе Карыш авылының барлык кешеләре кебек үк, мишәр-татар токымыннан булган. Кайбер тел галимнәре мишәрләрдә фамилияләр күбесенчә баба исеменнән, ә казан татарларында ата исеменнән ясала, диләр. Мин үзем бу фикер белән килешмәсәм дә, Габдулланың фамилиясе Галиев түгел, ә Мәзгыйльдин булган дип уйлыйм (Мәзгыйльдин — гыйлем иясе дигән кушамат дип әйтүчеләр дә бар). Физик яктан куәтле, фикере көчле, бәхәсләрдә җиңү яулавы өчен Габдуллага Батыршаһ дип яхшы гына кушамат биргәннәр.

Батырша туган Карыш авылы тарихы исә Рус патшалыгының яулап алу сәясәте, башкортлар җирен колонизацияләү белән бәйле. 1552 елда Казан дәүләтен яулагач, Рус дәүләтенә көнчыгыштагы күчмә халыкларның җирләрен үзләштерү кирәк дип саналган. Башкорт күчмә, далаларының уртасында Уфа елгасының Агыйделгә койган җирендә 1580 елларда Уфа шәһәре-крепосте төзелә. Ул шул өлкәнең хәрби, сәяси һәм идарә үзәге булырга тиеш була. Аны башкорт халкыннан нык сакларга кирәк дип тә уйланыла. Шуның өчен крепостьта нык хәрби көчләр тоту гына түгел, ә аның тирә-юнендә дә ышанычлы хәрби көчләр урнаштырыла. XVI гасырда йомышлы мишәрләрне («служилые мещеряки») Россиянең көньяк чикләрен ныгытуда — оборона сызыгын (валлар, кальга — крепостьлар) төзүдә киң файдалансалар, XVII гасырда аларны көнчыгышка күчереп утыртып, шул ук максатта файдаланганнар. XVII гасырда күпләгән мишәр авыллары Уфадан төньякта да, көньякта да барлыкка киләләр. Бер документ хәбәр иткәнчә, Башкортстанның төньяк-көнбатышында бу вакытта башкортлар бик аз булалар («Археология и этнография Башкирии» Уфа, 1971 ел. 22 б.) Тагын бер факт: XVII гасырда 35 йортлы Карыш авылы XVIII йөздә зураеп киткән һәм үзеннән хәзерге Чишмә районына, ягъни Уфаның көньягына Салихова дигән авылны төзергә кешеләр бүлеп чыгара алган. Бу авылда да мишәрчә-татарча сөйләшкәннәр.

Татар халкының мишәр этнографик төркеме Идел һәм Ока елгалары ярында монда күптәннән утырган кыпчак кабиләләренең берләшүеннән һәм аларга болгарларның кушылуыннан оешкан. Казан татарлары дигән төркем исә Идел-Кама болгарлары һәм аларга бераз шул ук кыпчак кабиләләренең кушылуыннан төзелгән. Бу ике этнографик төркемнең бер халыкны тәшкил итүе фәндә нык исбат ителгән. Батырша үзе дә: «Безнең болгар бабаларыбыз...» — дип язып калдырган. Аның милли чыгышын тикшергәндә, патшага язган хатларына игътибар итсәк, анда да үзен башкортлардан аерып язганын күрербез. XVIII гасыр галиме, Батыршаның замандашы П. И. Рычков та шул ук фикердә: «Мишәрләр — шул ук татарлар алар, бары тик исемнәре белән генә аерылалар», — ди ул.

Менә документлар тагын ни сөйли: «Деревни служилых мещеряков Кульбарисово (Сабаево тож), Янагушево, Сюнеево, Байбако (или Бибаков), Кемеево, Бабаево, Мрясимово, Умкеево (Турнико тож), Башелап, Арбаш (Багильдино тож), Деуш, Урюш (или Ургуш), Утеш, Акбердино (Подлубово тож), Коши,

Тимкино, Богданова, Карыш, Иштиряково... Они выходцы из Алатырского, Курмышского, Арзамасского уездов (ЦГАДА, 1173 ф., I алынма, 1119 — саклау берәмлеге (Бу архив документларын бирүе өчен Д. Б. Рамазановага зур рәхмәт.) Икенче берсендә болай язылган: «дер. Карыш является одной из самых ранних мишарских деревень, возникших в Осенской дороги».

Мишәр диалектының гомумтатар телендә бер тармак икәнен фән күптән инде исбат иткән. Батыршаның хатларын тел җәһәтеннән тикшерү дә шул ук нәтиҗәгә китерә. Үз вакыты өчен шул кадәр матур һәм оста итеп язу куәтен Батырша татар мәдрәсәләрендә тирән белем алу, татар халкы тарихын яхшы үзләштерү һәм тирәк-як тормышын үткен күзәтү нигезендә булдырган. Зирәк акыллы яшь егет мәдрәсәләрнең иң алдынгыларын сайлый алган.

Тайсуган авылы мәдрәсә җитәкчесе Абдрахман Тайсугани үз заманы өчен галим булган. Батырша аңа барган. Сүз уңаеннан әйтәсе килә, 1980 елда бугай, Тайсуган урта мәктәбенең 250 еллык юбилеен зурлап үткәрергә уйлаганнар иде. Иж-Буби мәдрәсәсенеке кебек. Барып чыкмады, ахры. Мәктәпләрнең юбилейларын уздыру бик зур тәрбияви һәм сәяси әһәмияткә ия юкса. Иж-Буби мәдрәсәсе һәм мөдәррисләренең юбилее 1990 елда бөтен халыкның горурлык хисе астында үтте. Инде, Ташкичү авылы мәдрәсәсенең мөдәррисе Абдессәлам Ураев — ахун үз вакытының атаклы эшлеклесе, Батырша аңа да килгән. Ташкичү мәдрәсәсен Батыршадан соң йөз ел үткәч атаклы галим һәм мәгърифәтче Ш. Мәрҗани тәмамлаган. Бу фактлар үзләре генә дә бик күп нәрсә аңлатсалар кирәк. Мондый югарылыктагы мәдрәсәләр Башкортстан җирендә XVIII гасырда булмыйлар әле. Монда авыл мәктәпләре булган, ә күп җирдә «балаларга татар грамотасы укыту» (Урысча документлардан алынган сүзләр) буенча шәкертләр эшләп йөргәннәр. Батырша, югарыда телгә алынган мәдрәсәләрдә гыйлем алганнан соң, халыкка хезмәт итә башлый. Бу мөхтәрәм юлда ул байтак уңышларга ирешә. «Гайнә татарларының Илеш мулла авылында ел ярым гыйлемендә тордым»,— дип яза ул үзе. Ягъни шул авылда имам-мөдәррис булып, халыкны мәгърифәткә өндәп, начарлыктан качарга, яхшылык кылырга өндәп тәрбия иткән. Бу авыл шулай, Илеш мулла авылы дип аталган булса кирәк. Анда татарлар яшәгәнлеге шик астына алынмый, чөнки башкортлар булса, Батырша аны искәртеп үткән булыр иде. Аннан соң 4 ел буе Исет төбәгендә Мөслим старшина авылында шул ук хезмәттә эшләгән. Бу инде мишәр авылы булган.

Инде Батыршаның төп фикере, восстаниенең дә төп максаты булган идея турында әйтик. Ул Батыршаның халыкка язган өндәмәсендә чагыла: «Без (патша) хөкүмәтен бетереп, үзебезнең укымышлы голәмәләребездән торган милләт мәҗлесе төзергә һәм аның идарәчелегендә булырга тиешбез!» Патша хөкүмәте, кулына корал тотып сугышучыдан да бигрәк, әнә шул бәйсезлек, халык азатлыгы идеясе җәелүдән коты очып курыккан. Батыршаның патшага язган хатында «ак патша»га ышану да, ул үткәргән сәясәттән шикләнү дә бар. Ләкин бу хатларның төрмәдә язылган булуларын да истән чыгармаска кирәк... Ә өндәмә иректә, халык массаларын көрәшкә күтәрү өчен язылган.

Батырша җитәкчелегендәге азатлык хәрәкәтенең татар һәм башкорт халыклары тарихында тоткан урыны, әһәмияте бик зур. Ул бу халыкларның социаль һәм милли-азатлык көрәшендәге бер эпизод яки күренеш кенә түгел. Ул — милли-азатлык хәрәкәтендә, мөстәкыйль үз дәүләтеңне булдыру өчен көрәштә алга киткән бер адым, яңа баскыч. Батыршага кадәр баш күтәрүче татар-башкортлар үз дәүләтләрен булдыру юлында «хан күтәрергә», хан сайлап куярга омтылалар. Батырша исә беренче мәртәбә голәмалардан торган «Милләт мәҗлесе» сайлап куюны, аның кулына бөтен хакимиятне бирү мәсьәләсен күтәрде. Бу инде мөстәкыйль дәүләт өчен гасырлар буена үсә барган фикер юнәлешендә бер баскычны икенче баскыч белән бәйли торган чылбыр иде. Батыршадан соң Мулла Морат: «Болгарны торгызырга вакыт җитәдер»,— дип оран салды. Озак та үтми, Пугачев восстаниесендә катнашкан татарлар үзидарә гамәлен тормышка ашыра башладылар. XIX йөз үзенең тагын да яңа фикер юнәлешләрен, мәгърифәтчелекне алып килде. Ләкин бәйсез дәүләт төзү фикере бервакытта да сүнмәде...

**Сәлам АЛИШЕВ,**
Тарих фәннәре докторы, Тел, әдәбият һәм тарих Институтының тарих бүлеге мөдире, Җирдә тормыш һәм гаделлек өчен көрәшүче рыцарьлар конфедерациясенең Югары Совет әгъзасы.

Җәмит Рәхимов

# БАТЫРША

**РОМАН**

## Таш ләхеттә

Диварның тупас ташлары арасына кыстырылган нарат чырасы чыртлап атты да ялкыны сүрелеп калды. Болай да шомлы хибесханә эче караңгылыкка чумды. Кайдалыгын һәм гамәлен онытып, миендә кайнаган уйларын кәгазьгә төшереп утырган Батырша җитү чәчле чал башын күтәрде, каршындагы яктылык чыганагына беравык карап торды, кулындагы кауры́й каләме гарәпчә нәкыш белән чуарланган юллар өстенә тавышсыз гына төште. Аннан куш куллап каршындагы чырага үрелгән иде — беләзегендәге богау чылбыры зыңлап куйды. Чыраның инде каралып кәкрәергә өлгергән күмерле кисәген сындырып таш идәнгә төшереп җибәрде — ярыйсы гына яктырып китте. Батырша кабат урынына — шомарып беткән чыршы бүкәненә чүкте дә әле генә үз куллары белән сырланган юлларга текәлде: «Вә һәр нәрсә кем кадерле вә газиздер. Аның чурасында[1] сакчылары бардыр. Гөлләр шаһының сакчысы чәнечкедер, мөгарәдәге хәзинәнең сакчысы — аждаһадыр. Шуның шикелле падишаһлар да зиннәтле сарайларында читятлардан саклана булыр. Зөбәрҗәт диңгез төбендә әбелхәят[2] зольмәттә[3] икән, соңгысының гыйззәт вә шәрәфәт баһасы бөтен дөнья хәзинәсенең мең бәясенә тиң. Падишаһлар әбелхәят мисалыдыр. Хакыйкать тереклек чишмәсе икән, падишаһлар — тереклек чишмәседәй хакыйкать иясе. Ә мәрхәмәтле вәзирләре һәм наибләре[4] әбелхәяткә кояр вак чишмәләр бәрабәрендә, ягъни хакыйкать чишмәсен куәтләндерер затлар, ә залимнәр шул чишмәгә үткәрмәс зольмәт мисалыдыр. Падишаһлар, бәлкем, тагы да шәрәфәтле вә мәрхәмәтлерәктер. Шуңа аңарга ирешер юлда манигъ-киртәләр дә биегрәк һәм ныграктыр. Аларны искиткеч ныклык вә гайрәт белән генә ерып йә аша атлап булуы ихтимал. Ә мин горбәтлектә[5] йөргән бер бәндә, залимнәр зольмәтен, манигъ-киртәләрне үтә кичеп, ул хакыйкать-мәрхәмәт чишмәләренә җитешеп, сусавымны бастыра алармынмы? Бер әмәлен табып, гөнаһ корабыма утырып, диңгезләр кичеп, манигъләр җимереп, олуг падишаһыма ирешсәм икән, дию фикерләдем».

Кинәт Батыршаның тәне буйлап яшен ташы узгандай булды, сары суккан йөзе башта агарды, аннан бүртенеп кызарды. Аһ, нәрсә бу?! Чыннан да, аның берәүгә дә баш бирмәс гыйсьянчы куллары белән язылган юллармы соң болар?! Берәү алдында да мескенләнмәс, төрле бәйгеләрдә, бәхәсләрдә җиңелүне белмәс мәгърур Баһидиршаһныкы-

---

Җәмит РӘХИМОВ (1935) — *публицист һәм прозаик, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Девон хәбәрчесе», «Тәвәккәл таш яра», «Кыядагы чәчәкләр» һ. б. китаплар авторы. Җөмһүриятебезнең Лениногорск шәһәрендә яши.*

Журнал варианты

[1] Чурасында — иясе янында.
[2] Әбелхәят — тереклек суы.
[3] Зольмәт — караңгылык.
[4] Наиб — урынбасар.
[5] Горбәтлек — мосафирлык.

мы бу сүзләр?! Кисәктән хәлсезләнеп калганын тойды, бер-беренә богау чылбыры белән тагылган куллары, аңа буйсынмастан, алдындагы тимер өстәлгә төште — корыч чыңлап куйды. Ишек катындагы тәбәнәк утыргычта йокымсырап утырган сакчы күзләрен ачты, каударланып билендәге кылыч сабына ябышты, куркынган карашын тоткынга төбәде. Ләкин шикләнерлек берни дә юк иде. Шәрә ияген богаулы куллары өстенә куйган Батырша каршындагы тәбәнәк диварның иләмсез тупас ташларына карап каткан. Солдат кулын кылычыннан алып, ипләбрәк утырды һәм кабат күзләрен йомды.

Аҗаган балкышы булып әле генә башына килгән фикердән тетрәнеп куйды Батырша. «Гөлләр шаһы. Әбелхәят мисалы. Тереклек чишмәседәй хакыйкать иясе»,— дип мыскыллы пышылдады аның иреннәре. Шулай да булсын, әлеге сүзләрдә ихласлык бар. Ни генә димә, ул гомере буе падишаһка чын күңеленнән инанды, падишаһ гаделдер, шәрәфәтле вә мәрхәмәтледер, дип тәкрарлады. Бу аның рияләнуы булмыйча, йөрәгендә егет чагында ул тамырланып, даулы гомере юлында ныгыган иманы иде. Бүген, әле менә шушы мизгелдә, әнә шул иманы чатнады түгелме соң?!

Хуш, патша хәзрәтләренә әйтелсен дә ди купшы мәдхияләр. «Мәрхәмәтле вәзирләре дә наибләре әбелхәяткә кояр вак чишмәләр бәрабәрендә» дигәне каян килеп кергән диген? Улмы белми аның наибләрен, улмы күрмәде аның түрәләренең залимлеген?! Оренбур җиренә гөбернатор итеп җибәрелгән баш наибе Ниплүй янаралны гына ал. Аның тугрылыгы, намуслылыгы хакында халык арасында риваятьләр йөри. Ә чынында никадәр мәкерлелек, икейөзлелек ул бәндәдә! Башкортлар белән кыргыз-кайсакларны бер-беренә кылыч-ук күтәртүче шул, Казан татарлары белән башкортларны дошманлаштыручы да шул ук эт җан. Оренбур җирендә яшәүче халаекларны, төрле болаларда катнашканнары өчен үз куллары белән асып-кисмәсә дә, аларны меңәрләп-меңәрләп кырдыручы, гомер сөргән, ата-бабалары рухын саклаган бихисап авылларын яндырып вәйран иттерүче, колак-борыннарын кистереп, төмәне-төмәне белән сөргенгә олактыручы, бер гөнаһсыз нарасыйларны, шул сабыйларны назлаудан башканы белмәгән аналарны чукындырып, көтүе-көтүе белән коллыкка саттыручы да шул ук Ниплүй гөбернатор ләбаса! Батыршаның халыкны үгетләве һәм кыздыруы буенча яу купкач, Оренбур ахуны Ибраһим исеменнән ялган кәгазь яздырып татар-башкортлар арасына таратгыруына, өлкән дин әһеле исеме белән аларны күндәмлеккә өндәвенә генә бак син. Шайтанның да башы җитмәс моңа. Аныкы җиткән.

Ярый, гөбернаторы шундый булсын да, ди. Анысы ни әйтсәң дә үз мөселманың түгел, чыкылдап торган урыс, кара йөрәк, кяфер. Шул залимнең уң кулы булып йөрүче алдакчы карт дуңгыз Котлымәт морзага бак тагы. Татар-башкортларга золым-зольмәт, җәбер-җәфа, бәлаказа китерүдә һич чик белмәде. Килмәк абыз, Акай һәм Карасакал яуларын бастыруда миһербансызлыгы, кансызлыгы хәттин ашты: халыкны асты-кисте, сөргенгә куды, кол итеп сатты, авылларын яндырды, иләүләрне вәйран кылды, кыз-хатыннарны хур итте, балаларны ятим калдырды. Халык аны юкка гына «Шайтан морза», «Котырган Тәфтиләү» дип атамады шул. Аның ерткычлыгы, каһәрләре, җәзалары һәм кансызлыгы хакында җыру бер дә юктан туган дисеңме? Ничек әле?

Тәфтиләүнең менгән, ай, атлары
Чаптар да гына белән тимеркүк.
Тәфтиләүдәй кансыз булыр микән,
Шушы илдә кыргый җәнлек күк.

Мөнәҗәт әйткәндәй авызы эченнән генә көйләп утырган Батыршаның тоныкк тавышыннан сискәнеп сакчы кабат башын күтәрде. «Алласына сыгына шәрә баш, намаз укый»,— дип уйлап алды ул, гадәтенчә

аның хакында, гәрчә тоткынның чәчләренә инде күп айлар буе пәкекайчы тимәсә дә.— Укы өйдә, укы, табын, барыбер, шушы юеш таш ләхеттә чериячәксең! Солдат, уңгарак авып, ойый башлаган сул ботын угалап алды, тәмләп бер иснәде һәм кабат күзләрен йомды. Батырша исә аның кымшангалавын сизмәде дә, дымы саркып торган таш диварга карап каткан хәлдә, ярсып-ярсып уйланды.

Шулай, халык ерткыч Тәфтиләүне ләгънәтләде, ташларны чокып аңа каргыш язды. Ә падишаһ нишләде диген? Патша хәзрәтләре исә шул явызны алтынлады — палкауник дәрәҗәсе бирде. Ә Батыршаныкылар күтәрелгәч, ихтилалчыларга[1] башлап кылыч селтәүче дә шул ук Котлымөхәммәт морза Тәвкилев булмады мыни? Батырша яуның ни белән бетүен үзе күрмәсә дә, чамалады, таш ләхеттә ятып та ишетте: аның белән көрәшкә чыккан татар-башкортларны явызларча бастыруда, Килмәк абыз, Акай, Карасакал яулары чорындагыча ук, асу-кисүдә шул ук кан коючы Тәфтиләү танылган. Тагы шунысы да килеп иреште Батыршага: шул ләгънәтләнгән Оренбур каласын салу һәм аннан соңгы елларда дулкын-дулкын булып калыккан татар-башкорт яуларын тар-мар иткәндәге катылыгы, кансызлыгы өчен патшабикә аңа иң зур гаскәри чин — янарал дәрәҗәсе биргән. Бәс шулай икән, наибләре белән яраннары да, падишаһ дип, алланың җирдәге шәүләсе дип ат алганы да бер чыбыктан сөрелгәннәр булып чыга түгелме соң?!

Тәвкилеве Тәфтиләү, динен-иманын саткан бәндәдән тагы ни көтәсең. Әләкчәй Иваныч, имеш. Тфү! Чын мөселман диген үз мишәрең булганы да эттән туган бит аның. Бакчы, бу Яныш ыстаршинаны. Батыршага гына да түгел, бар халаеккка золымлык кылды. Һичбер вакыт тәһарәтләнеп, ходайга сәҗдә кылмыш булмаган ул имансыздан кемнәр генә зар еламады?! Ә бит янаралларга, түрәләргә ярады Яныш, гомергә вернай ыстаршина булды. Гаҗәп тә түгел, кайда бола, кайда чуалыш, кораллы егетләрен ияртеп, халык өстенә ул чапты. Хәтерендә, халык күтәрелгәч, Яныш белән серләшмәк булып, аның катына барды Батырша, ыстаршинаны ихтилалчылар ягына аудармакта иде исәбе. Җавабы бер булды Янышның: «Бу хәлдә сабыр итәек, аннан инде кем өскә чыкса, шуңа кушылырбыз.» Үзе исә сабыр итмәде. Бөрҗән башкортлары кузгалу белән, камандасыннан әтрәт туплап, алар өстенә китте. Батыршаны тотарга дип, Карыш-башка егетләр җибәрүче дә шул явыз иде.

Соң боларны белми иде мени Батырша? Түрәләрнең урысы-башкорты-татары — бары да залим, дип күпме текрарлады. Падишаһка язган тәкъризнамәсендә дә шул хакта ачынып сөйләде ләбаса: «Мондагы түрәләр кирәк залим, кирәк гадел улсыннар, аларның хөкеме бозылмыйдыр. Угрыны тугры дисәләр, тугры буладыр, угры дисәләр, угры буладыр... Түрәләр аннан акчалар алдылар. Байларның малы төкәнде, ярлылар бурычлар булдылар. Көндә бетәр эшне айга суздылар. Халаекларга җәфалар күргәзделәр, кыйнамак, сукмак, алым алмак берлә, малларын угырламак берлә вә һәм кешеләрне үлтермәк берлә. Яныш камандасында Туктар авылының Туктарны, указдан артыкны бирмәгән өчен, бер башлык агулы шәрап эчереп үлтерде. Сөләйман командасында Субай авылының бер кешесен олау озата барганда юлда драгуннар кыйнап үлтергәннәр». Шушы юлларны алдарак үз куллары белән язды ла Батырша. Уфадан Оренбурга барышлый юлда үз күзе белән күргәннәре тагы. Сотниклар бер башкортның үзен камчылап, атын имгәтеп киттеләр. Каргалы янында бер татарга тора салып бәйләнделәр... Ә ул... «мәрхәмәтле вәзирләре вә наибләре әбелхәяткә кояр вак чишмәләр», имеш. Тфү!

---

[1]Ихтилалчы — баш күтәрүче, фетнә, бунт ясаучы.

Батырша, ярым караңгыда кармаланып, алдындагы кәгазен ике куллап күтәреп алды да авызына капты, язганын кыргыйларча тешләре белән өзгәләргә тотынды. Кәгазь кыштырдауга, ишек катыннан әфисәрләр Хомутов дип йөрткән әлеге сакчының йокылы тавышы ишетелде:

— Ят инде, такырбаш!

Тоткын шунда гына бүгенге хәленә әйләнеп кайтты, сасы зинданның сөремле диварын әле генә күргәндәй, бераз текәлеп торды да, ишеккә таба борылып, эчкә баткан күзләрен солдатка төбәде:

— Тышта төнме, көнме?

— Дәшмәскә! — дип бар көченә чыелдап җибәрде Хомутов. Монысы инде ишекнең теге ягындагы сакчыларга да ишетелсен өчен иде. Аннары ярым шыпыртлап өстәп куйды: — Төн узып бара инде, ят!

Батырша ут яңартмады — чакма чагып чиләнәсе килми иде, шулай ук ятагына аварга да ашыкмады. Башына бүген генә килгән вәсвәсәле фикерен чарлап, ачыклабрак куясы килә иде аның. Хуш, ул инде менә алты ел буе «гыйззәтле дәүләтле падишаһымыз газими хәзрәтләренә» гарызнамә яза. Оренбур җирендә яши торган бик күп халаекларның аяныч хәлен бәян итә, үзенең ихтилал башлыгы булу мәҗбүриятен, гыйсьянчылык сәбәпләрен аңлатмакчы була. Үткән төндә генә башына килде: гарызнамәне урысчага аударачаклар лабаса. Тылмачларның әлеге юлларны тәрҗемәли алмый интегүләре бар. Аларны, гарәп-фарсыны катыштырмыйча, үзебезчә — төрки белән язарга дигән фикергә килде. Бүгенге көне шуның белән юанып үтте. Инде ятарга дигәндә, кабат укып бакса, «аһ» итте, гыйсьянчы җанның шундый купшы, төче сүзләр яза алуына гасабилана башлады. Кирәкме соң ул төче сүзләр? Тулаем алганда, бу үтенеч хатының хаҗәте бармы?! Хәер, аның кайбер данәләре галиҗәнапка дип тапшырылды инде. Шәрәфәтле вә мәрхәмәтле падишаһтан исә ләм-мим: ни телдән, ни язма рәвештә. Гарызнамә аңа барып ирешкәнме? Укыганмы ул асыл патшабикә Батыршаның йөрәк канына манып язган зарлы сүзләрен? Юктыр, укыса, бер-бер намә кылмый калмас, тугры хөкемен җиткерер иде. Вә әй хәсрәт, бая гынак яшен ташы булып башына килгәннең чынлыгы хак, күрәмсең. Падишаһы да үзенең күп санлы наибләре вә яраннары, түрәләре күк залим икән!

Ачышы каты төен булып бугазына утырды Батыршаның, тәмам нәүмизләнеп, башын куллары өстенә салды — тимер салкыны тумыштан пәке-кайчы күрмәгән шәрә ияген чиркандырды. Шул хәлендә күпме утыргандыр, күңелендә бер якты уй калкып, кәефләнеп киткәндәй булды. Сакчы Гришканың башына солдатлардан курка-өркә генә сүләгәне хактыр, шаять. Аның өзек-төтек хәбәрләренә караганда, Батырша егет чагыннан ук ишетеп белгән әби патша үлгән, имеш. Аның урынына тәхеткә ир-ат падишаһ утырган, ди. Димәк ки, пайтәхетнең үзендә ыгы-зыгы. Шундый чакта гарызнамәнең укылмый ятуы гаҗәпме булыр?

Өр-яңа ачышы Батыршаны дәртләндереп җибәрде, богауларын шалтыратып, торып ук басты. Шулайдыр, тәхетнең үз тирәсендә дә болгавырдыр. Менә яшь патша аягына басар, ныгып алып, ил-дәүләт хакында эш-сүз йөртә башлар, ниһаять, Батыршаның гарызнамәсенә дә чират җитәр вә...мәрхәмәтле падишаһның гадел хөкеме аяк-куллардагы богауларны гаип итәр. Йа раббым, мәрхәмәтеңнән ташлама, шулай булсын, амин! Кем белә, бәлкем, ул хат-үтенеч инде хөкемдарның рәхмәтле кулындадыр...

Т а р и х б и т л ә р е н н ә н. Россиядә тәүге милли-азатлык хәрәкәтенең идеологы һәм җитәкчесе Батырша — Абдулла Гали улы Мәзгытдин держаВаның иң чирканыч, әшәке төрмәләреннән берсе булган Шлиссельбург крепостенда утырган бу еллар — XVIII гасырның 50 еллары ахры — алтмышынчы еллары башы, чыннан да, империя тәхете тирәсендә гаять болгавыр чор. Патшалар, өсләрендәге күлмәкләре сыман, алмашынып кына тора — гасырның тулар-тулмас алты дистә

елы эчендә тәхеткә сигез хаким утыра. Россиянең тәүге императоры бөек Петр Беренче үлгән 1725 елдан башлап, аның Елизавета Петровна тәхеткә ия булган 1741 елга кадәр узган уналты ел гомер эчендә генә дә ил белән идарә итү кулдан-кулга алты тапкыр күчә. Тагы да гаҗәбе — Петр Икенчене исәпкә алмаганда, калганнарының властька килүләре очраклы хәл, башбаштаклык һәм законсызлык була.

1761 елның декабрь азагында Елизавета Петровна да үлеп китә. Сарай тирәсендә чуалучы дворян аристократлары, гвардия офицерлары башына тагын патша эзләү хафасы төшә. Дөрес, тәхет дәгъвалаучыларга мохтаҗлык юк. Тик кайсыннан уңасың бит әле? Менә Петр Беренченең өлкән кызы Анна Петровна белән голштейн-готтерпский герцогы Карл Фридрих улы, русларда Петр Өченче дип йөртелә торган Карл Петр Ульрих.

Аксөякләрнең күбесе, бигрәк тә гвардия офицерларынан дүрт бертуган Орловлар, тәхеткә аның акыллы һәм чибәр хатыны Екатеринаны күтәрү ягында. Унбиш яшеннән бирле Россиядә яшәүче, православие дине буенча чукынганнан соң Екатерина исеме алган ярлы немец принцессасы Софья Фредерика Августа 1745 елда Петр Өченчегә кияүгә чыга. Үзе тырышса, тәхетне дә элэктерә алыр иде, мөгаен. Алай да законлы варис булган ире барында бу эш кыенрак. Дөрес, Екатеринаның граф Сергей Салтыковтан тапкан улы — булачак император Павел бар тагы. Тәхеткә аны утыртып, ил белән идарә итүне анасы Екатеринага биргәндә дә ярар иде яравын. Тик Петр Өченче исән булганда...

Әнә шул шартларда властька Петр Өченче килүе гаделлек булып тоела аксөякләргә. Әлеге исерекбаш исә тәхеттә үткәргән ярты ел гомерендә үзенең кем икәнен тулысынча күрсәтә. Бу кадәр дә өшеке, өхлаксыз, рус рухына ят патшаның кыланышларына чыдавы шул хәлләрне күреп торучыларга бик кыен була. Россиянең бәхетсез тәхете өстендә янә болытлар куера һәм 1762 елның 28 июне төнендә гарасат башлана. Шул төннән Екатерина Икенче дип — тарихка, әби патша Екатерина-Сания дип — төрки халыклар теленә кереп киткән яңа императрица «сөекле» ире Петр Өченчене кулга алдыра һәм тагы берничә көннән аны бөтенләй юк иттерә — Россия тәхете озак елларга шушы икейөзле, хәйләкәр һәм чибәр хатын кулына күчә...

Зиндан тып-тын. Гадәти тынлык кына да түгел, ниндидер шөбһәле, чит-ят галәм тынлыгы иде бу. Әйтерсең, дөньяда бернинди хәят-тереклек калмаган, тик Батыршаның гөнаһлы җаны гына, үзенә урын тапмый, гаять зур каберстанга әверелгән ил-җир арасында адашып йөри. Алай да бөтенләй үк үлеп-туңып бетмәгән икән әле тормыш. Кайдадыр, таш диварлар артында, чак ишетелерлек булып су чупылдады — Батырша елмайгандай итте.

Гүя ул татар җырларыдай моңлы, башкорт далаларыдай иркен Агыйдел ярында, бөдрә таллар арасында, мондагы хозурлыкка һәм хөрлеккә кинәнеп утыра. Аягы астында гына наян вак дулкыннар чупылдаша, баш очында гына оҗмах кошлары сайрый. Ә су буеннан, йөгерек дулкыннар гел иркәләп-назлап торган дымлы тыгыз комнан атлап Зөлхәбирәсе килә. Һәрвакыттагыча, гәүдәсе, килеш-килбәте үзенеке, чырайы — Тутыяныкы. Ни гаҗәп, хатыны белән ничәмә еллар гомер сөреп, өч бала үстереп, әнә шул күренештән арына алмады Батырша. Зөлхәбирәсе исенә төштеме, күз алдына Тутыя йөзле таныш сын килеп баса. Каршында берсеннән-берсе сөйкемле улы Таҗик белән кызы Зөләйха пәйда була. Алардан арттарак яңа туып калган баланың да чыраен шәйли сыман. Ярый әле, улының җиде яшендә дөньядан китүен, ягымлы кызларының, аналары белән бергә, урыс алпавытына сатылуларын белми иде ата кеше. Белсә, чыдамас, йөрәге шартлап ярылыр иде, мөгаен.

Дулкыннар чупылдавы кинәт юкка чыкты — ишек төбендәге зиндан «фәрештәсе» хәрәкәткә килде:

— Син, такырбаш, тыныч ят. Колак төбең кычытмаса, мине бимазалама!

Батырша дәшмәде. Иләмсез шыгырдап ишек ачылды — кояш чыккандай булды — мөгәрәгә шәм яктысы кереп тулды. Тик бу сөенечле мизгел шунда ук юкка чыкты. Ишек артында сакчының шалтыр-шолтыр йозаклар белән маташуы ишетелде, идән такталары чыелдады, аннан кабат бар да тынды. Сакчыларның төннәрен үзләре «коридор» дип йөрткән озын аралыкның аргы башына җыелып ниндидер комарлы уен уйнап мәж килә торган гадәтләре бар. Шунда ашыга иде бугай хибесханә «фәрештәсе».

Ул, бар дикъкатен туплап, баягыча су чупылдавын ишетергә теләп ятты. Әмма, ни гаҗәп, күңелле мизгел кабатланмады. Каяндыр, еракътан, кызмача солдатларның ат сыман кешнәп-кешнәп алулары гына ишетелеп куя. Батырша күзләрен йомды, уе белән моннан бик ерактa калган иркен далаларга кайтып китте.

... Шушы ыгы-зыгылы дөньяда яшәгән кырык алты ел гомере, хәер, зур мәдрәсәгә килгәнче узган унсигез елын санамаса да ярый, бер хыял-омтылыш, бер ният белән узды Батыршаның. Исәбе — ничек кенә булса да ак падишаһ каршына җитү, Идел-Урал төбәгендәге кырыкмаса кырык телдә аңлашып тереклек итүче халаекларның гаять тә авыр хәлләрен бәян итү иде. Шул теләгенә ирешсә, кан еглап гомер сөрүче кешеләрнең моң-зарларын түкми-чәчми әбелхәят бәһасы патшабикәгә җиткерсә, шәфкатьле әби патша үз колларының аяныч хәлләрен ишетер һәм, шөбһәсез, гаделлек кылычын селтәр — залим янаралларны вә түрәләрне китап хөкеменә тартыр, дип өметләнде.

Тукта, гомер бакый башыннан китмәгән, бөтен тормыш юлында якты өмет, ихлас ышаныч булып балкыган әлеге изге ният аның күңелендә кайчан вә кайда бөреләнеп, шытып китте соң? Үзе туып-үскән Карышбаш мишәрләре арасында андый гөнаһлы уйларга урын юк сыман иде ләбаса. Алайса каян килеп керде соң ул тәшвишле уй Батырша башына? Ә, әйе, Зәй буенда Казан татарлары белән аралаша башлагач, шунда гомер ишетмәгән-күрмәгән зольмәтнең шаһиты булгач, миенә калка башлады ул вәсвәсәле фикерләр. Яраткан имамы вә мөдәррисе Гәбделрахман исә шул коткылы уйларына әбелхәят суы сипте.

Падишаһка әйтәсе сүзләрен гомере буе барлады, гыйбарәләрен чарлады, шомартты. Вә әй хәсрәт, шәфкатьлеләрнең шәфкатьлесе дип йөрткән падишасы каршына үз аягы белән килеп егыла алмады. Инде кул-аяклары богаулы хәлдә, зөбаниларның көтү-көтү сагы астында пайтәхеткә килеп җиткәч тә ак падишаһның нурлы йөзен күрү, агулы дуен булып күңеленә утырган зар-моңнарны сөйләп бирү насыйп булмады. Галиҗәнапның вакыты юк дип, кулына кауры́й каләм тоттырдылар, төргәге белән ак кәгазь, чыра бирделәр, патшага җиткерәсе сүзләреңне тез, диделәр. Ул язды, көннәрен дә, төннәрен дә язды. Айлар буе язды, еллар буе. Тик белмәде: падишаһка барып җитә алдыларммы аның йөрәгендәге ялкынга манып язган сүзләре? Юктыр. Батырша кырыкмаса кырык тапкыр кәгазьгә төшергән золымлыклар, әшәкелекләр, халаекларның сукбай этнекеннән дә кайтыш тормышта тереклек итүләре хакында укыса, мәрхәмәтле патша түгел, таш та телгә килер, бар дөньяга оран салыр иде.

Батырша, богауларын шалтыратып, кулларын күчерде, аларны кайнар маңгаена куып берни уйламый ятарга, йоклап китәргә тырышты. Әмма бер кузгалган уй ташкынын тыеп торырга куәте җитмәде. Тоткын ыңгырашып куйды, тешләрен кысты, күзләре утлы күмер булып көйрәде. Башында тагы да шыксызрак, иләмсезрәк, куркынычрак уйлар биешергә тотынды. Тукта! Аны гомере буе эзәрлекләгән Каракош шәүләсе шул — шул үзе микәнни?! Йа хода! Әле теге чакта, Зәй буенда ук аның күңелен ниндидер тәшвиш, коточкыч бәла, яманлык, хәтта һәла-

кәт көтү хисе кереп урнашкан иде. Гүя коточкыч зур хәшәрәт бер кош, киң канатлары белән кояшны каплап, көн баешы яклап Батырша өстенә, Идел-Урал буйларында яшәүче халаеклар өстенә очып-очып килә. Ерткыч кош үзе бик еракта булып, исеме падишаһ дип атала мәллә?! Юк, юк, падишаһ кына да түгел, патшалык!

Бәс шулай икән, ул кара көчтән котылмак юк. Дансыз-шансыз салкын үлем көтә аны. Бу өнсез-шыксыз утрау аның падишаһка барыр юлында иң соңгы ям ыстаны түгелме соң? Әлбәттә, шулай. Әлеге ямнан чыгу юк, алда — мае бетеп, сүнеп бара торган шәм сыман, акрынлап бетү генә.

А, юк, тиз генә биреше торганнардан түгел Баһадиршаһ! Ул әле, теге Каракош, аның күкрәгенә килеп кунгач та, тарткалашыр, көрәшер, сугышыр. Тик ничек? Бу үлем базыннан качып, билгеле.

Батыршаның бер-беренә тагылган куллары ихтыярсыз аска төштеләр, аягына үрелделәр. Ул, караңгыда кармаланып, богау бәҗрасы ышкылудан каешланып, нечкәреп калган чолтәрен капшады, шомарып беткән тимер бәҗраны әләктереп алды. Аннан аягының йөзен бик нык турайтып бәҗраны аска шуытты. Еллар буе күнектерелгән аяк та, бәҗра да җайга килеп тора — тимер кыршау, ансат кына шуып, чыгып ук китте. Елмаеп куйды Батырша — аяктагы богаудан бик тиз котылырга була анысы. Тик кулдагылары. Һай, ирекке чыксамы?! Ничек тә кисәчәк, бәреп ватачак аларын. Ә дәрьяның бер як яры якынрак бугай. Сирәк-мирәк кенә йөрергә чыккан көннәрендә шул тарафтан өтәч кычкырганын ишеткәне бар. Димәк ки, богаулы куллары белән дә йөзеп чыгачак. Тик бу таш ләхеттән ничек котылырга да, шыксыз әҗәл базының җиде сажинлы диварына ничек менәргә? Хәер, зәбанилар кулыннан ычкына алса, баскычын табар анысы. Ә нишләп ычкынмаска? Йөрергә чыккач, янәшәсендәге бердәнбер сакчыны богавы белән сугып үтерүе берни түгел. Аулаграк чак икән, диварлар өстенә менү дә кыен булмас. Тик ничек төшәргә теге якка? Су кальга кырыенда ук түгел бугай. Килгәндә үз күзләре белән күрде лә: диварлар төбендә ком-таш өеп ясалган тар утраулар. «Аларга тирән чокырлар казылып, су тутырылган» — ди Гриша. Сикерү мөмкин түгел дигән сүз. Их, бау булса! Юк, ялгызың гына качу турында уйлыйсы да юк. Бердәнбер өмет — Гришкада, миһербанлы бәндәдә. Ул дилбегәләр табып бирсә...

Батырша тынычлап калгандай булды. Салкын богау бәҗрасын кабат аягына кидереп куйды да күзләрен йомды. Миендәге ашкынулы уй соңгы кат яктырып сүнде: качарга, качарга!

Бераздан ул ябылган кысан сасы баздан баһадирларча гырылдау ишетелә башлады. Ә җирдә 1762 елның 28 июнь кояшы чыгып килә иде.

## Абдулла

### Беренче бүлек

Унтугызын тутырган Абдулланың Уфа якларында алган мәшһүр Тайсуган мәдрәсәсенә икенче кышын укырга килгән елы иде. Тәгаен шул: бу якларда тәүге тапкыр Оренбург дигән сүз таралып, Уфага таба олы яу узган 1147 елның, ягъни милади белән 1734 елның кара көзе иде ул. Олы атна көнне, җомга намазыннан соң, шушы шанлы мәдрәсәнә тотучы имам һәм мөдәррис Гәбделрахман өенә чакыртты аны.

— Килдеңме, менла Баһадиршаһ?!

Абдулла кызарып, күзләрен җиргә төбәде — бу дөньяда аңа әле Гәбделрахман мулла гына Баһадиршаһ дип эндәшә иде. Әллә шаяртуы, әллә үз итеп дәшүе.

Шәкертенең уңайсызлануын сизеп алган остаз, борылып, агачтан буралган келәткә кереп китте, эчтә нирләрдер шалтырата торгач, кулына әдернә җәя белән бер садак ук һәм кыска саплы сөңге тотып килеп чыкты.

— Йөреп кайтаек бер!

Егет сүзсез ризалашты. Остазының гадәтен күптән белә ул. Яз-җәй дими, көз дими, еш кына сунарга чыга Гәбделрахман. Быел да кар төшкәнне көтәргә сабырлыгы җитмәгән әнә. Хәер, кәҗәсе түгел, мәзәге дигәндәй, киек-җәнлек аулауга әллә ни исе китми мулланың, урман-әрәмәләр, болын-кырлар урап, сәйран кылып кайтса, шуңа күңеле була сыман. Әлхасыйль, татарлар, исемен бозып, Габдрахман дип йөртә торган бу кеше Абдулланың моңа кадәр белгән муллаларына һич охшамаган. Килеш-килбәте мәһабәт, кием-салымы пөхтә — кала байларыныкына тартым. Мәчеткә барганда башына фәс киеп, аның өстеннән чалма урап йөрсә дә, мәдрәсәдә ул рәвешендә күренми диярлек. Сүзгә үткен, белмәгәне юктыр. Дәрестә еш кына дин сабагыннан дөньяви хәлләргә күчеп китә, шәкертләренә гомер ишетмәгән әллә кайдагы илләр-җирләр, диңгез-дәрьялар хакында сөйли, әллә кайсы хан заманнарын, борынгы бабаларыбыз яшәгән болгар илен искә төшерә, шәрекъ мәмләкәтләрен вә аларның хакимнәрен телгә ала, бигрәк тә гарәп-фарсы галимнәре һәм шагыйрьләре турында оныталып бәян итә. Гарәп һәм фарсы телләрен су урынына эчә, күп кенә хәкимнәрнең акыллы сүзләрен үз телләрендә мисал итә, робагыйларын укып күрсәтә. Аның йорты тирәсендә чуалгач, сизенә Абдулла: остазы өендәге хатын-кызларның йөзләрен ир-аттан яшерү-яшермәү хакында да ничектер битараф кебек. Юк, аны хак динебез исламга тел тидерә, дип әйтә алмый Абдулла. Киресенчә, дин кануннарын да, шәригать өйрәтүләрен дә бик төгәл белә Гәбделрахман мулла, аларны җиренә җиткереп үти, шәкертләренә дә тәфсилләп аңлата. Алай да һәр вәгазен:

— Томаналыктан качыгыз, наданнардан читләшегез, телләр өйрәнегез, төрле фәннәр белән шөгыльләнегез, — дип тәмамлый...

Җыену озакка сузылмады, шул җиңелчә кулдан кузгалдылар. Абдулла хәтта башындагы киез эшләпәсе белән аягындагы кәвешен алыштырырга, җиләнен салып, бишмәт киярге дә өлгермәде.

Авылны чыгуга ук куе әрәмәлек башланды. Көз инде аны вәйран иткән: шомыртларның бурлаттай яфракларын талап, җиргә түшәгән, моңа кадәр ямь-яшел утырган таллары, кайнар су белән пешекләгәндәй, лөшперәйткән. Алай да җәй әле бөтенләй китмәгән кебек. Әнә ул кипкән сарут, бөтерелгән сары яфраклы әрекмән төпләрендә посып ята сыман.

Инде шактый юл үттеләр. Ләкин Гәбделрахман ешлыкка борылмады, иңбашына эленгән җәясен кулына алмады, тирә-якка карана-карана, хозурланып, Зөйгә төшә торган такыр сукмактан атлый бирде. Сөңгесен таяк итеп уң кулына тоткан Абдулла аны ашыктырмады. Икәүләп сунарга беренче чыгулары түгел, шәкерте остазының гадәтен белеп бетерде инде: киек-җәнлек тотарга чын-чынлап ниятләгән булса, болай ук еракка китмәс, әрәмә эченә борылыр иде Гәбделрахман.

— Безнең Иске авыл да нәкъ шушылай урман-әрәмәләр эчендә утырыр иде, — дип сөйләп китте алдан атлаучы Гәбделрахман. — Инде җиденче кыш бит, ә күңел һаман утырмый, — ди ул сыкранып. — Урыны бай, ямьле югыйсә. Хәзергә бик тыныч та. Йөрәккә исә һаман нидер кирәк, һаман Казан ягына тарта. Ярый әле юанычка мәдрәсә бар. Юкса, сагыштан саргаерсың, кем менла Баһадиршаһ!

Абдулла тагы уңайсызланып куйды. Кайдан уйлап чыгарды соң әле Гәбделрахман хәзрәт әлеге кушаматны? Ә, әйе, быелгы яздан, кечкенә генә Тайсуган авылын «гөж» китергән вакыйгадан соң шулай дип атап йөртә башлады аны мулла.

Сәрвәр йолдызының[1] соңгы көннәре иде. Урыс атнасы көнне, сабактан соң, Гәбделрахман аларны — Абдулланы һәм тагы ике шәкертне урманга алып китте. Урман дип авыз тутырып әйтү генә инде. Авыл кырыендагы юкәлектә иде имамның чолыклыгы. Агачлар әле яфрак ярып бетермәгән, хәтта яткыл җирләрдә урыны-урыны белән кар ята. Юкәлек исә кап-кара, тик бөреләр генә уңган бавырсак булып бүрткән. Алай да бөтен тирә-якта яз исе, чәчәкләр исе, бал исе. Куыш агачларга ясалган чолыкларда кышлаган бал кортлары инде чын-чынлап эшкә керешкән. Килеп җитүгә, мулла үзе дә җиңнәрен сызганды, тиз арада дүрт-биш дистә умартаны урман аланына чыгарып тезделәр.

Әмма эшләре хәерсез булып чыкты. Икенче көнне таң белән Гәбделрахман мәдрәсәгә үзе кереп уятты аларны. Төнен аю умарталарны вәйран иткән.

— Болай булгач, тынгы бирми инде ул хәерсез,— дип сукранды Гәбделрахман, яңа борынлап килгән үлән өстендә күч булып үлеп яткан кортларны куш учына алып.— Ничек тә өркетергә кирәк бу явызны. Шуңа йөрәгегез җитәрме, егетләр?

Абдулла дәшмәде. Ике иптәше исә, берсен-берсе уздырып, шаулашырга тотындылар:

— Һәй, аны өркетүе,— дип җилкенде Иштирәк дигәне.

— Утлы кисәү белән куабыз аны,— дип әтәчләнде Юлтимер.

— Алай,— дип куйды мулла, бик үк ышанып җитмәвен яшереп тормыйча.— Шулай да без башта кулдан килгәнен эшлик әле.

Көн кичкә авышканда алан агачлары чатлы-ботлы яткан ур белән уратып алынган иде. Алай да умарталарны саклап кунасы иттеләр. Билгеле инде, бу эш яшьләргә тапшырылды, мулла үзе авылга кайтып китте. Шәкертләр исә, чакма чагып, мөшкәгә ут көйрәттеләр, келәт алдына ук диярлек учак ягып җибәрделәр. Келәттә сыекланып беткән җәя белән дүрт ук бар икән. Шуларны алып, читкәрәк китте Абдулла һәм тиз арада бер көртлек белән боҗыр атып алды. Кошларның бик ябык, начар вакыты иде бу апрель ае. Алай да көлгә күмеп пешерергә ярарлыклар.

Чолыклыкка көек исе таралырга өлгермәде, Гәбделрахман кабат килеп җитте. Үзе генә дә түгел, унике-унөч яшьләрдәге кызы Тутыя белән. Мулла үзе олы бер төен итеп иске чикмән, торыпша ише нәрсәләр күтәргән, кызның исә ике кулында ике чүлмәк: берсендә аш, икенчесендә әйрән булса кирәк. Тутыя бала итәкле озын ситсы күлмәктән. Чигүле алъяпкычын бәйләп куйгангамы, биле өзелердәй булып тора. Шуңамы сыны Зәй буе камышы сыман. Балигъ булып җитмәгәнгәме, башка сәбәп беләнме, яулыгын артка чөеп бәйләгән. Аның ахактай ап-ак саф йөзен күргәч, әллә нишләп китте Абдулла. Тутыяның күмер сыман чем-кара күзләре, карлыгач канатыдай корым кара кашлары, матур песи борыны һәм иреннәре дулкынланып торган җыйнак авызы исертеп җибәргәндәй булды егетне. Ярый әле, остазы Гәбделрахман вакытында телгә килде:

— Ник аптырап калдың әле, менла Абдулла? Кайнар килеш борай боткасы ашап алырга кирәк! Иртәнге якта салкын булса дип, киемсалым, урын-җир алып килдем менә. Тик йокы белән мавыгып, аю корбаны булмагыз тагы!

Гәбделрахман белән Тутыя төмам күз бәйләнгәч кенә киттеләр. Ул арада караңгылык иңде, күзгә төртсәләр дә күренмәслек булды. Җитмәсә, урның тегә ягында кемдер дапы-дөпе йөренгән кебек. Шикләнүләрен бер-беренә сиздермәс өчен, егетләр юри кычкырып сөйләштеләр, учакны әр-яңадан дөрләтеп җибәрделәр дә, янәшәдәге имән төпләренә утырып, утка текәлделәр.

[1] Сәрвәр йолдызы — сәфәр ае.

— Әкият сүлә әле, Абдулла! — дип ялынды Иштирәк.

Сүз дә юк, әкиятләрне дә, төрле риваятьләрне дә күп белә Абдулла. Өлкәннәрдән ишеткәннәре дә җитәрлек, китаплардан укыганнары да буа буарлык. Өстәвенә, аларны кеше җанына ятарлык итеп сөйли дә белә. Тик әкият сатарга кәефе юк иде аның бүген.

Күз алдында һаман — Тутыя сыны...

... Нидер дөпелдәгәнгә сискәнеп, башын күтәрде Абдулла. Караса, учакта ут сүнел бара, бүкәннәрдә утырган егетләрдән җиллэр искән, кайнар күлдән арттарак кара бер шәүлә басып тора. «Чыдамаган, тагы килгән», — дип уйлап алды егет остазы турында хөрмәт белән. Тик әлегә карачкы ягыннан «шак-шок» иткән авазлар ишетелгәч кенә, аның аю икәнен аңышып алды. Кабаланып аягына басты, тик борылып келәткә таба йөгерергә дә, бер тарафта яткан балтаны алырга да өлгермәде — аю аңа таба атлады. Абдулла, елан чаккандай өтәләнеп, төп өстенә менеп басты һәм урман хуҗасын каршыларга әзерләнде. Тегесе исә озак көттермәде, ал аякларын егеткә таба сузды. Менә-менә ботарлап ук ташлаячак. Абдулла исә аюның килеп басканын көтмәде, үзе алга томырылып, бар көченә кизәнде, йодрыгы белән аюның ике күзе арасына сукты. Нидер чыртлагандай булды, ул да түгел кулында кайнар сыеклык тойды егет. Ләкин ни дә булса уйларга өлгермәде — сул кулбашы оеп китте, аннан, утлы күмергә пешкәндәй, чәнчешеп сызларга тотынды. Бераздан исә бар да эрегәндәй юкка чыкты — Абдулла, чайкала-чайкала, төп өстенә авып төште.

Ул иртәнге салкында остазы Гәбделрахман тавышына күзләрен ачты: «Йа алла, исән икәнсең! — дип шөкрана кылды Гәбделрахман, аннан малайларча шатланып, очынып сөйләргә тотынды. — Юк, син Абдулла түгел, менла кем, син — Баһадиршаһ! Белдеңме шуны. Машалла, аю кадәр аюны сугып үтергәнсең ләбаса!»

Мулла аны иплэп кенә күтәрде, имән төбенә утыртты. Шунда гына күрде Абдулла: учак көле янында ук зур көрән аю ята. Аның бар җире дә исән, тик маңгае гына чәрдәкләнгән иде...

Бу вакыйга һич онытылмады. Остазы Абдуллага исә: «Баһадиршаһ», — диеп кенә эндәшә, аны улы кебек якын итә, шәкерте белән теләсә нәрсә хакында ачыктан-ачык гәпләшә иде...

Зәй буена да килеп җиттеләр. Абдулла тәмам аптырады — болай ук еракка киткәннәре юк иде ләбаса. Инде менә ям чаба торган олы юлга да килеп чыктылар. Гәбделрахман, юл катысына туктап, соңгы елларда тәмам такыраеп, киңәеп киткән трактның әле бер ягына, әле икенче ягына карап, нидер уйланып торды да:

— Дөньялар имин түгел, Баһадиршаһ, — дип куйды. Аннан үзалдына сөйләнгәндәй тезәргә тотынды: — Заманалар ипләнеп, менә шунда, олы юл буенда авыл нигезләсәң, шәп булыр иде дә... Габдрахман авылы, ә?!

Абдулла ни дип тә җавап кайтарырга өлгермәде, кояш баешындагы Кичү кальгасы яклап дөңгер сукканнары ишетелде, атлар пошкырган тавышлар килгәндәй булды. Гәбделрахман бер мизгелгә югалып калды, аннан, кисәк аңына килеп, шәкертенең беләгеннән алды:

— Әйдә, тиз бул!

Алар юл аръягындагы урманга таба йөгерделәр. Чикләвеклектә Гәбделрахман җиргә чүкте, юлдашының чабуыннан тартты:

— Чүк! Карап калаек: ниткән затлар икән?

Юлда атлар пошкырганы, ниндидер әмер авазлары аермачык ишетелә башлады, ул да түгел, өчерләп рәт-рәт тезелгән атлы драгуннар күренде. Өсләрендә кызыл якалы мундир, башларында өчпочмаклы эшләпә, шулар астыннан бөселеп үрелгән чәчләре чыгып тора. Аркаларындагы озын мылтыклары талгын гына чайкала. Яуның исәбенә чыгарлык түгел иде. Җайдак гаскәриләрдән бераз гына артка калып,

алты ат җигелгән фәйтун бара. Ул бизәкле тула белән тышланган — эчендә утырган түрәнең бик зур бәндә булуы шөбһәсез.

— Сарбазлар,— дип пышылдады Гәбделрахман, шыпырт кына.— Ашыгалар. Богелмә суына җитеп кунаргадыр исәпләре. Йа аллам, тагы җан кыярга барулары микәнни Уфа ягына. Үзең шул яктан булгач, ишеткәнсеңдер, Баһадиршаһ, Алдар-Күчемнәр баш күтәргәч тә бик күп халыкны кырган бит ул имансызлар!

Атасы сөйләгәне бар Абдуллага: әле ул туганчы, моннан чирек гасыр булыр элек, Агыйдел буйларында яшәүче татар-башкортлар, башларында Алдар белән Күчем ыстаршиналар торган хәлдә, кансыз түрәләргә, патшаның йомышлы кешеләренә каршы кузгалгач та, шушылай драгуннар килгәннәр бу якларга. Казан юлында орыш каты булган, кан дәрья булып аккан. Алай да болачылар нык торганнар, өсләренә меңләгән калмык җайдаклары ябырылгач кына җиңелгәннәр. «Тагы ни булды икән? — дип уйлады Абдулла.— атай-анайларга, йортка хәвеф килмәсме?». Шикле уйларыннан остазы коткарды:

— Ярый, хәерле булсын,— диде Гәбделрахман, бүреген салып. Аның башыннан җиңелчә бу күтәрелә иде.— Әйдә. Бүре чокырына барып, су эчик булмаса!

Бүген аларга тынычлап сәйран кылу насыйп булмаган икән. Карый торгач, күрделәр: чишмә буенда ниндидер бер сәләмә бәндә, суга иелеп, корымлы чиләк юып маташа. Кабат җиргә чүктеләр, тегене күздән яздырмый гына, тынып калдылар. Шикле кеше исә аны-моны сизмәде, чиләген тутырып су алды да, янәшә сукмакларның берсеннән яр өстенә атлады.

— Тып-тыныч Зәй буйлары да бимазалыга әйләнде,— дип пышылдады Гәбделрахман шәкертенең колагына ук диярлек.— Без күчеп килгән елларны гына да кеше аягы басмаган җирләр иде югыйсә.

Сүзен әйтеп бетермәде, әлеге бәндә киткән якта ачыргаланып бала елаганы ишетелде.

— Качаклар! — Гәбделрахман аягына басты.— Бала-чагалары да бар икән. Әйдә, яннарына бараек әле, киңәшкә мохтаҗлардыр.

Бәләкәй генә урман аланы. Урталыкта учак дөрли, аның тирәсендә ике дистә чамасы кеше кайнаша. Чишмәдән менүчесе учак янына җиткәч, андагылар җанланып, җиңелчә шаулашып алдылар. Көн шактый чиратып җибәрүгә карамастан, житү чәчле башын берни белән дә капламаган таза буынлы ир-ат, тегенең каршына чыгып, су тулы чиләкне кулына алды. Сәләмә хатыннарның берсе бер түтәрәм итне чиләккә чумырды. Качаклар тын калдылар, тик әлеге дә баягы, бер чырыйлап, бер үксеп, әнисе кочагына сыенган бала гына өзгәләнде:

-- Инәй дим, ашарга!

— Өрекмәгез, өрекмә! — диде Гәбделрахман, учакка якынаеп.— Юлбасар түгелбез, шулай ук патша йомышлылары белән уртагыбыз юк. Әссәламегаләйкем! Шушы төбәктәге Тайсуган карьясының имамы Гәбделрахман булам,— дип, учак янындагы муртайган төпкә утырды мулла.— Бу исә минем шәкертем. Кай илләрдән буласыз вә кая таба юл тотасыз?

Барысы өчен дә җавапны чал сакал-мыеклы, эчкә баткан кыпкызыл күзеннән яшь килеп торган аксакал бирде:

— Без инде, мөнла кем Габдрахман, төрле иләү халаеклары җыелдык монда. Бәгъзебез Олы идел буеннан, бәгъзебез Зәядән үк. Чулман иделеннән дә бар...

— Кая дип бару соң?

— Ниятләвен Урал-тау ягына дип ниятләгәниек тә...

— Соңгарак калгансыз,— Гәбделрахман мескеннәрнең хәлләрен уртаклаша башлады.— Уралга җитә алмассыз, кыш басар. Җәй башында ук кузгаласыгыз калган.

— Үзебезнең дә шулай мәслихәтләшү, ошбу чишмә буена нигезләнү уе ие дә,— дип сүзнең җаен үз кулына алды аксакал,— анау сарбазлар котны алды бит әле. Чак чыгып өлгердек юлдан...

— Алайса, тыңла! — Гәбделрахман тагы да дәртләнеп китте.— Шушыннан кыйблага таба китсәгез, Сагышлы суына барып чыгарсыз. Ул Шушма елгасына алып төшәр. Сагышлы тамагынд Нәдер дигән бер авыл булып. Нәдергә җиткәч, Ураз намлы мулланы сорагыз, ярдәмнәреннән ташламаслар.— Сез мөһаҗирләрнең ризык ягы да чамалы бит әле.— Мулла Аблуллага борылды.— Менә Бәһидиршаһ бер капчык борай китереп китәр үзегезгә...

Икәүләп Тайсуганга таба атлаганда, остазының шунда әйткән бер сүзе бөгыренә мәңгелеккә сеңеп калды Абдулланың.

— Җитәсие ак патшаның үзенә! Сүлисие халаекларның яман хәлен!...

## Икенче бүлек

Туган авылына кайтырга дип, чана юлы өзелгәнче үк кузгалды Абдулла. Шуның белән отты да. Боз көпшәкләнгәнче Ыкны үтеп калды, аннан соң да шактый юл алырга өлгерде. Апрель башында исә юллар иртәнге якта да атлап булмас хәлгә килде. Юлда очраган беренче авылга тукталудан башка чара калмады. Бик үк зур булмаган ярлы гына типтәр авылы иде бу Әҗем дигәннәре. Аның әле күптән түгел генә төпләнгәне күренеп тора. Йортлары яңа, тик бик кечкенәләр, өйаллары читәннән, барысы да кабык түбәле — кыскасы, хәерчелекләре урамга үк чыккан.

Алай да хәлле генә кешегә тап булды Абдулла. Өйлә вакыты иде. Хуҗа аны ачык чырай белән каршылады:

— Бәрәкалла, мактап йөрисең икән, пешкән ашка килеп кердең,— дип кунакчылланды ул мосафирга, үзе күрешергә дип, кәкерәеп каткан кулларын сузды.— Шушы Әҗем карьясының Гарифҗан булам мин.

Абдулла үзенең шәкерт икәнен әйтте. Җәйгелеккә атасы Гали янына, Карышбашка кайтып баруын сөйләп бирде. Уфадан ары дигәч, чамалады хуҗа.

— Сәфәрең ерак икән, олан,— дип куйды ул.— Юллар исә тәмам өзелде, берәр атна сабыр итми булдыра алмассыңдыр. Рәхим ит соң: өебез кысан булса да, күңелебез иркен.

Хуҗаның моңа кадәр почмак якта савыт-саба шалтыратып йөргән хатыны, шәүлә сыман тын гына чыгып, сәкедәге киндер ашъяулыкка буы чыгып торган агач табак куйды.

— Шәкерт кеше — галим кеше инде ул.— Гарифҗан тезенә җитеп торган киндер күлмәгенең җиңнәрен сызганды, кунагы алдына зур гына чаган кашык куйды.— Ил-җирдә ни хәбәрләр бар?

— Шөкер бездә! Зәй буйларында әлегә иминлек. Иген игеп, мал асрап, тереклек итеп ятулары.

— Ай-һай, имин үк микән? Мәгәр көзен Уфага таба яу узган, дип сүлиләр бездә.

— Анысы узды да, тынды бугай ул. Уфа ягыннан бернинди дә ыгы-зыгы ишетелми сыман.

— Ишетелер төсле шул, кем Абдулла. «Оренбур пахуты» дип аталган бу яу безнең тарафларда яшәүче халаекларга тагы да тарлыклар, авырлыклар, яңадан-яңа җыемнар алып киләчәк, дип әйтәләр.

— Әлеге чирүнең уе яманлыкта дисеңме сән? Кала салу бит әле өшәкелек дигән сүз түгел.

— Мин әйтмим, тиле, халык әйтә.— Гарифҗан тагы да ярсый төште, кашыгын куеп, өйрән уртлап алды.— Кирилыф дигәне узган көз,

Уфага килү белән, типтәрләрнең санын алдырган. Юкка гына эшләткән дисеңме син аны? Көт, булыр тиккә! Биремнәр артачак дигән сүз бу, кем Абдулла. Өстәвенә, чукындыручыларга өзер исемлек. Янә дә килеп, алпаут балаларыннан ике драгун рутысы төзеткән ди Кирилыф. Мишәрләрне чирү хезмәтенә, типтәрләрне казна эшенә кушкан.

— Бу хәлләргә халаеклар ни ди икән соң?

— Хафага калган аксакаллар Кирилыф җәнапләренә хат язганнар, үзе берлә сүзләшү өчен йәрекчеләр җибәргәннәр. Мәгәр түрә аларны тыңлап та тормаган, куалап чыгарган. Шуннан инде Килмәк абыз үзе чарасына керешкән: Бәпәнәй мулла, Сәетбай, Рисәнбай ыстаршиналарны, Кучәнбай батырны, Казан өязе качкыны Әминне вә башкаларны җыеп сүләшкән. Хәл катмарланган: йә ил, йә яу дигән мәсьәлә килеп баскан.

— Шулай ук мыни?

— Алай гына да түгел шул, шәкерт.— Әле күптән түгел Кимәк абыз, Бәпәнәй мулла, Акай белән Көчек батыр вә башкалар изге Газый мәчетенә җыелганнар. Намаздан соң Тәфтиләү морзага илчеләр җибәргәннәр болар, патша йомышлыларының Оренбур каласын салудан ваз кичүләрен таләп иткәннәр. Илчеләрне кулга алдырган Тәфтиләү, җыенда катнашучыларны тотып бирүчеләргә кафтанлык тукыма вәгъдә иткән. Ярый, бер дога! Әлхәмделиллаһи...

Егет хуҗаның йорт эшләренә булышты, абзардан тирес тә чыгарышты, чоланның череп беткән түбәсен яңа кабык белән ябышты. Шулай итеп, биш-алты көн үтеп тә китте.

Арба юлы төшмәгән иде әле төшүен. Барыбер юллар кипкәнне көтмәде Абдулла. Җәяүлегә аларның кирәге шул кадәр генә. Юл буендагы чирәмлекләр исә инде төмам җилләп, яшәреп киләләр иде. Аягына күн итеген киеп, җиләне белән тиреле бүреген биштәренә салды да юлын дәвам итте.

Көймәче яллап, Агыйделне кичүгә, колагына чаң тавышы килеп керде Абдулланың. Текә үрне күтәрелүгә, тавыш тагы да гайрәтләнде, ниндидер хәвеф-шом булып йөрәкне сыкратты. Кала үзәгенә якынлашкан саен халык төркеме куерды, атлар ишәйде, мондагы ыгы-зыгыга һич исләре китми «сагыз чәйнәп» торган дөяләр күренде. Ул да түгел бөтен тирә-юнь гаскәриләргә күмелеп калды. Йөзләрчә җайдаклар һәм кызыл якалы мундир кигән драгуннар арасында мишәр яугирләрен танып алды Абдулла. «Оренбур пахуты»ның кузгалуыдыр, мөгаен, дип уйлап алды ул һәм бер читтәрәк аты сыртындагы иярен рәтләп маташкан мишәр янына тукталды.

— Ни бар, кая куптыгыз болай?

— Кирилыф җәнапләре пахут чыга — кала салырга барабыз!

Бу — 1735 елның унберенче апреле иде.

Байлыгы белән мактанырлыгы булмаса да, тормышыннан зарланмый иде Мөзгытдин углы Гали. Хәләл җефете Бибинур белән икәүдән-икәү генә тереклек итүләренә карамастан, шөкер, яшәүләре кешенекеннән ким түгел. Ата-бабадан калган җире җитәрлек, аты да икәү. Абдуллалары Тайсуганга киткәч, сыерның берсен бетерделәр бетерүен. Аның каравы, кәҗә-сарык, кош-корт ишек алды тулы. Ирле-хатынлы тырыша торгач, нәкъ Карыш елгасы буенда кара-каршы ике өй җиткерделәр.

Мәгәр бер хафасы бар Бәләкәй Галинең. Ни хикмәттер, туганнан бирле кулы арасында йөртеп тә, бердәнбер углы Абдулла йөрәгендә игенче һөнәренә дөрт уята алмады. Әйтми-дәшми тордыңмы, китабына кадала да доньясын оныта. Сүз катучы булмаса, көннәр буе шул китаплары белән җенләнеп утыра. Әх, үзе ялгышты шул Гали. Укымаган кеше — сукыр кеше дип, үзе белгәнне углына өйрәтте. Бик яшьли хәреф танып, хәтта яза башлады Абдулласы. Мәчет каршындагы мәктәпкә йөри башлагач исә, төмам «галим» булды.

Шул рәвешле үзен-үзе, улы Абдулланы битәрли-битәрли җир сукалап маташкан Гали озын буйлы, киң җилкәле егетнең җир башына килеп туктавын абайламады да.

— Алла куәт бирсен, атай!

— Исән-аман гына кайттыңмы, углым?!

Абдулланың җәйге тәнәфесе шул сәгатьтә үк башланды. Буразнага күңеле ятып бетмәсә дә, көч куеп эшли торган эшне сагынган иде егет. Кинәнеп пар ат белән җир сукаларга тотынды. Әмма икенче кат әйләнергә өлгермәде, бер кочак ботак-сатак күтәреп, урманнан анасы килеп чыкты. Ул имән ботакларын җир башындагы туйра янына ташлады да, күлмәгенең итәкләрен җыя төшеп, улы катына йөгерде.

— Улым, Апушым минем!..

Мунчаны кайткан көнне үк ягып керделәр. Иртәгесен исә улының исән-имин кайтуы хөрмәтенә авылдашларын ашка җыярга булды Гали. Сабан өстенә дип симертелгән тәкә кояш чыкканчы ук, чалынды, өйдә таң белән таба чыжлый башлады, тирә-якка май исе таралды.

Өйләдән соң кунаклар җыелды. Карышбашның барлык могтәбәр ирләре дә, мулласы белән мәзине дә бар иде монда. Гали, токмачтан соң ук, егетнең кулына Коръән китереп тоттырды.

Уку иң яраткан һәм күнеккән гамәле Абдулланың — кыстатып тормады, китапның урта бер җирен ачты да, Мисыр мәкаме белән көйләп, укырга кереште. Табындагылар сокланып, гаҗәпсенеп утырдылар.

— Инде, углым, без наданнарга төркичәгә тәфсирләп тә бирсәң икән,— дип куйды Гали, сүрә укылып беткәч. Улының гыйлемлеген зурдан күрсәтәсе килә иде аның.

Һәм Абдулла атасының йөзен кызартмады, сүрәнең һәр сүзен дөрес тәфсирләп, табындагыларга аңлата башлады. Шулчак моңа кадәр тын гына утырган Мостафа мулла телгә килде:

— Бакчы, кем менла Абдулла,— дип башлады ул сүзен.— Бүген гает тә, җомга да түгел. Яңа туганга ат кушмыйбыз, мәет җирләмибез. Бәс шулай икән, изге китап сүзләрен калдырып торыйк. Менә монысын укып бак булмаса...

Абдуллага тире тышлы калын гына бер китап тоттырды мулла. Аның беренче битен ачуга ук «Йосыф китабы»н танып алды шәкерт. «Монысы үзебезчә, төркичә»,— дип куйды һәм көйли төшеп укып китте:

> Гөзиз Йусеф төмам ун бер йөшәр ирди,
> Йагкуб сөүчи уйлукында уйур иди,
> уйуркән бер гөҗәб дүш Йусеф күрди...

Шул көннән соң инде авылда әр-яңа таралды: «Бәләкәй Галинең Абдулласы галим булып кайткан икән».Монысына күңеле булды Галинең. Крәстиән эшенә күңел куймый дип лыгырдаганчы, галим булган дип сөйләсеннәр, әйдә!

Шундый көннәрнең берендә Карышбашка яңа хәбәр килеп ирешә. Теге чакны «пахут чыккан» Кирилыф, Уфадан ун чакрым китүгә, Чесновка елгасы буена тукталган икән. Вологда драгун пулкының биш рутасы килеп җитүен көтәргә ният иткәннәр, ди. Шунда торганда Кирилыф янына ике кеше килеп, аңа татар-башкорт халәекларының теләген җиткергәннәр: янарал ниятеннән кайтсын, югыйсә каршылык күрсәтеләчәк, дигәннәр. Кирилыф тегеләрнең һәр икәвен кулга алдырган һәм җәзага тарттырган — берсе үлеп үк киткән. Ниткәндер кара татар-башкортларның таләбеннән ярсыган Кирилыф Вологда драгун пулкларын көтеп тормаска булган. Ул янындагы унбиш рута мүнтәзим чиру[1], өч йөз илле казак, алты йөз мишәр, шактый гына йомышлы татар һәм чукынган калмык яугирләре, шулай ук егерме өч бакыр тубы белән булачак Оренбурга пахут чыккан. Ул кузгалып, дүрт көн узганнан соң,

[1]Мүнтәзим чиру — регуляр армия.

Чесновка елгасына, башында палкауник Чириков торган Вологда пулкы да килеп җиткән. Уфадан йөз алтмыш чакрымдагы Мәләвез суы буена җиткәч, Вологда пулкына Килмәк абыз җитәкчелегендәге өч мең болачы һөҗүм иткән һәм патша гаскәрләрен тәмам туздырып ташлаган. Бу хәлләрне белгәч, Кирилыф, ярдәмгә дип, отрәт җибәргән. Тик анысы, болачыларны очрата алмыйча, кире әйләнеп кайткан.

Аулак Карышбашка әледән-әле килеп ишетелгән әнә шундый сүзләр Абдулланы уятып җибәргәндәй булды. Ул, тагы да дәртләнеп, яуга әзерләнә башлады. Әмма аның ни аты, ни коралы юк иде. Атасы белән киңәшү дә урынсыз. Атасы да, анасы да аңа чат ябышканнар — андамонда җибәрү хакында ишетәселәре дә килми.

Абдулла качып китәргә, дигән карарга килде. Атасы өйдә юк вакытны чамалап, келәттән кәкшеәп беткән җөя белән күгәргән сөңге, иске ияр алып чыкты, аларны тәртипкә китерде. Актарына торгач, Мәзгытдин бабасыннан калган көбә күлмәк тә тапты. Ата-анасыннан яшереп кенә ризык әзерләде. Ут-үлән күтәрелеп, җәйге эшләр беразга тынып торган арада, атлар да көрәеп, матурланып киткәннәр иде.

Кичен Абдулла атларын ындыр артыннан ерак булмаган түбәгә генә тышаулады, үзе исә бөтенләй йокламады бу төндә. Яктыра башлау белән, акрын гына торып, өйдән чыкты, яуда кирәгәчәк коралларын һәм йөгәнен яшергән урыныннан алды да атлары янына йөгерде. Туры алаша йөгәнгә башын үзе сузып тора иде. Алай да юлы уңмады Абдулланың. Атын җитәкләп, әйберләре янына килгәндә, анда атасы килеп баскан иде.

— Болай кая җыендың инде, Абдуллаҗан? — диде ул, тыныч кына.

Инде яшереп торуда мәгънә юк иде, егет дөресен әйтеп бирде:

— Килмәк абыз катына, атай.

— Туктале, олан,— диде Гали.— Син безнең бердәнбер углыбыз. Ять-яшь башыңны харап итмә, атаң белән анаңны хәсрәткә салма. Аннан килеп... Сыңар ат белән нишләрбез без?!

— Соң, атай...

— Өйгә кайтыйк, балам!

Атасының соңгы сүзе керде Абдуллага. Ул йомшап төште, күндәм малай сыман югалып калды. Гали исә туры алашаны тышаулады, ат башыннан йөгәнен салдырып алды, иярне кулына алды да өенә таба атлады. Абдуллага аңа иярүдән башка чара калмады.

Күп тә үтми арыш урагына төштеләр. Абдулланың кайнар йөрәге тагы суынгандай булды, уйлары имин тормыш юлына кереп китте. Алай да ерак басуга ук килеп җиткән хәбәрләр аны әледән-әле алгысытып куя, ә вакыты-вакыты белән якты өметләрен томалый иде:

— Августның алтысында Кирилыф Ур тамагына барып җиткән...

— Унбишендә кальга сала башлаганнар...

— Утызында кальгага гаскәриләр кертелгән.

— Утыз берендә, Оренбур каласын нигезләүне хәбәр итеп, чаң сугылган, чиркәүдә гыйбадәт кылынган, туплардан атылган!

— Болачыларны бастыруда бигрәк тә Ниплүй янаралның наибе Тәфтиләү морза узына икән...

Берсеннән-берсе шомлы хәбәрләр бу яклардагы татар-башкорт халаекларының җиңелүен, патша ягындагыларның өстен чыгуын сөйлиләр иде. Әмма тарлыкка, ким-хурлыкка каршы көрәш тукталмаган иде әле...

* * *

Укуын дәвам итәргә дип, кабат Тайсуганга килгән Абдулла бола хәлләрен тәгаен белми, алай да берсеннән-берсе шөкәтсез хәбәрләр Зәй буена посып утырган тын авылга да килеп-килеп җитә һәм яшь

егетнең ярсулы йөрәген телгәли иде. Ә беркөнне ....Ә беркөнне бу аулак төбәккә халыкның йөрәгеннән тамган канга манчып чыгаралган җыр килеп җитте:

Астындагы ияр атка тияр,
Ияре лә белмәс, ат белә.
Тәфтиләүнең кылган каһәрләрен
Үзе белмәсә дә, ил белә...

Кара ла гына урман, кыя бите,
Шаулыйдыр ла кичен җил чакта.
Ташкайларга чокып каргыш яздым,
Оныкларым укыр бер чакта.

Кинәт Абдулланың күз алдына явызлык үзе килеп баскандай булды. Аждаһадай шөкәтсез вә әзмәвер, биниһая зур авызлы, кара канга баткан томшыклы әшәке бер каракош, имеш, ул. Әнә кояш баешы ягыннан офыкны каплап шул хәшәрәт килә, юлында очраган бар халаекларны ботарлап ташлый, һәлак итә. Тик ни-нәрсә соң ул?

Кул бармакларының чатнап сызлавыннан айнып киткәндәй булды егет. Бакса, ике йодрыгын да чытырдатып кыскан икән. Ул, йөрәгенең януына чыдый алмый, сикереп торды һәм, чарасызлыктан аптырап, тау астындагы чишмәгә таба китеп барды. Әйтерсең лә, анда күз яшедәй саф салкын су гына түгел, аның эчендәге ялкынны басардай шифалы зәмзәм суы да ага иде.

## Өченче бүлек

Урысча санаганда, 1740 ел. Димәк ки, Абдулланың Тайсуганга килеп гыйлем эстәп йөрүенә дә җиде ел тулды. Бу кадәр сузмаса да ярый иде яравын. Ул инде бишенче кышында ук, мөдәррисе Гәбделрахманны узып ук киткән иде. Гомерне заяга үткәрмим дип, остазына ярдәмләште — хаттатлык кылып, берсеннән-берсе калын китаплар күчереште, сабагының бишенче елында ук яңа шәкертләргә сабак тыңлатыр булды. Вә ләкин асыл максаты — Гәбделрахман белгәннәрне күңеленә сеңдереп калу, гыйлемгә булган сусынын бастыру иде. Шулай дип үзен-үзе юата-юата, янә ике ел үтеп китте. Быелгысының да әнә җәүза — сабан ае узып бара. Башка шәкертләр инде байтактан туган оясларына — авылларына таралып бетте. Аның исә шушы Тайсуганнан, аны урап алган урман-әрәмәләрдән арынып чыга алганы юк. Китәр дә иде, алдагы юлы, мәсләге ачыкланмаган. Кая алып китәр аны даладагы тынгысыз юллар?

Карашын аръякка күчергән иде — имәнеп китте Абдулла: каршыда, нәни генә култыкта, акка саргылт бизәкләр төшерелгән күлмәк итәген күтәреп, тезеннән суда Тутыя басып тора. Егет тәмам һушсыз калды, хачка табынган кяфер сыман, каршындагы манзарага карап катты. Шул рәвешле мизгел үттеме, әллә мәңгелекме, берзаман исенә килде егет. Күңел күзе беләнрәк бакса, култыкта Тутыя түгел, былтырдан калып корып кипкән бер оя камыш утыра, имеш. Абдулланың йөрәге чәнчеп, сыкрап алды. Тутыя! Аны һаман да Тайсуганнан җибәрми, Зәй буена тышаулап куючы асыл зат — озын торыклы шул сөрмә күз ләбаса!

Тора-бара Тутыя аның һич саекмас сагышына әверелде. Алай да үтәр дип көтте Абдулла, әлегә җиткән кыз булып пешеп өлгермәгән бу чандыр затны вакыты җиткәннән соң уйларга тырышты. Шулай булмыйни, Тутыя әле сабыйлыктан чыгып җитмәгән, ул исә — инде өченче дистәне куучы сазаган шәкерт.

Вә әй хәсрәт, Тутыя аты йөрткән шул изгелек фәрештәсен күңеленнән йолкып ата алмады Абдулла. Аткан да булыр иде, өченче елгы печән өсте ачык зиһенен бөтенләй чуалтты, тәмам иләсләндерде егетне.

Җәй аеның иң хуш вә иң хозур чагы иде. Атасы белән чалгылар чүкеп, тырма-сәнәк ише кораллар көйләшеп йөргән Абдулла, кисәк сүз әйтеп, Бәләкәй Галине шаккатырды:

— Атай, бәңа атна-ун көнгә Тайсуганга бару кирәк!

— Бик тәҗел йомышмы соң, углым?

— Тәҗел, атай.

Абдулла һич кенә дә алдашмый иде. Остазы Гәбделрахман, печән өстендә булмасын, игеннәрен урып-җыюда булмасын, ялчы ялламый, авыл кешесенең җәйгә чыккач бетмәс-төкәнмәс әйләнеп киткән мәшәкатьләрен үз гаиләсе белән генә ерып чиләнә иде. Мөлкәте җитмәүдән түгел, утыз-кырык кына йортлы Тайсуганда буш куллар табуы үзе бер бәла. Шәкерте җәйге тәнәфескә китәргә дип җыенгач та зарын сөйләп алды Гәбделрахман. Имамның тел төбен шунда ук төшенеп алды егет — чиллә тирәсендә килеп чыгып, бераз булса да булышмассыңмы, дию иде мулланың. Абдулла аның кинаясен аңламаганга сабышты. Нигә дисәң, атакае белән киңәш-табыш итми торып, кистереп кенә дә булса әйтүдән кыенсына иде. Карышбашка кайтып, чәчү чәчкән, йорт тирәсендә алай-болай иткәндә инанды егет: атакае белән анакае хәзер инде аның ярдәменнән башка да теләсә нинди мәшәкатьне ерып чыгачаклар иде. Ник дигәндә, бу якларга — Агыйдел, Карыш, Әй буйларына кырыкмаса кырык телдә сөйләшүче халаек килеп тулган. Башкортлардан җир сатып алганда килешүләре махсус дәфтәргә язылганда «типтәр» дип аталган бу адәмнәр тормышларының очын-очка ялгау өчен теләсә нинди эшкә ялланырга әзерләр. «Бабуллар» дип ат алган йортсыз-җирсез, нәсел-нәсәпсез сукбайлар исә тамак хакына тавыңны күчереп куялар.

Карышбашка кайтканнан бирле йөрәгенә һич тынгы бирмәгән ашкынуын шулай дип акларга тырышты Абдулла. Чынында исә күңелендә күбәләк булып талпынган Тутыяны гаять сагынган иде егет. Шушы көннәрдә барып, әлеге сөйкемле затны күрмәсә, һич төзәтеп булмый торган нидер туар, хәтта кояш тотылыр сыман.

— Анакаең ни әйтер икән соң? — диде атасы, байтак кына дәшми торгач. — Хәер... Барып кайт соң...

Тайсуганга ул иртә таң белән барып төште. Шәкертен күрүгә шатланса да, куанычын тышка чыгармады Гәбделрахман, аны әле кичә генә күргәндәй әйтеп куйды:

— Килдеңме, кем, Баһадиршаһ?

Абдулла теге чаклардагыча кызармады. Ул инде монда үзенә «Батыршаһ» дип, күпчелекнең исә анысын да печеп «Батырша» дип эндәшүләренә күнегеп бара. Анысына әһәмият итеп тормады, остазы белән ике куллап исәнләште дә, як-ягына каранып алды. Печәнченең станы бөдрә өянке төбендә, аты туарылып куелган арба янында иде. Егет шунда таба китте һәм килә-килешкә тирәк ботагына элеп куелган чалгыны күреп алды. Янавычы тоткасына элеп куелган. Чалгыны алып, янап җибәрде, алан башына узды, остазы артыннан пакуска төште.

— Кая шулай ашкынасың, әй, Баһадиршаһ? — диде Гәбделрахман.

— Чалгысы көйле...

— Ай-һай, чалгыда гына микән хикмәт?!

Җорлана-көлешә көн үзәгенә кадәр чаптылар.

— Җитәр, сулу алаек, Баһадиршаһ!

Сүзен әйтте дә, эре-эре атлап, станга таба китте имам. Абдулла исә, аның артыннан карап-карап торды да, чалгысын ястыктай кабарып торган пакуска куеп, Зәйгә атлады. Бу турыда оеп кына, тымызык кына ага елга. Димәк ки, тирән. Егет як-ягына каранып алды да, анадан тума чишенеп, суга сикерде.

Ул төмам сафланып-хушланып калган хәлдә станга якынлашып килә иде, чайкалып алды. Аннан исен җыеп, кабат алдына карады. Ялгышмаган: бөдрә тирәк янындагы учак кырыенда, төнге ут тирәсендә

күбәләк сыман Тутыя бөтерелеп йөри. Корымлы калай чиләккә бер тотам мәтрүшкә салып маташкан кызга текәлде егет. Шул мизгелдә аларның күзләре очрашты.

— Ай! — дип җиңелчә кычкырып җибәрде Тутыя, читкә борылды, шул арада яулыгын башына шуытып менгерде, битен каплагандай итте. — Шулай сөзеп карамасаңчы, Апуш абый?!

— Сагындырдың, Тутыя!

— Әйем, оялтасың...

— Оялма, Тутыя, багалмасы булып җиткәнсең!..

Кыз, кыенсынып, тирәк төбенә китеп барды. Шундагы кием-салым, капчык-торыпша ише нәрсәләр арасыннан кижүле ашъяулыкка төргән зур төенне алды, табын әзерләргә тотынды. Әй, бәхет! Үзе кочагын җәя түгелме соң Абдуллага?! Нигә аңа ничә еллар йөрәге түрендә йөрткән кадерле сүзләрен аулакта Тутыяның үзенә әйтеп калдырмаска?..

Аяк тавышлары ишетеп, артына борылды Абдулла һәм әрәмәдән чыгып килүче остазын күреп алды.

— Менә җиләк тә булды, — диде Гәбделрахман, изрәп пешкән җимеш тулы эшләпәсен үлән өстенә куеп. — Табын әзерләдеңме, кызым?

— Ипи кисмәгән, әткәй.

— Анысын гына кисәрбез!

Төенчекне чишеп, ике касә, бер бәләкәй чүлмәк алды, аларны тастымал белән сөрткәләде дә, савытларга мәтрүшкә чәе койды мулла. Аннары пешкән йомырка, бәләкәй ләнгәч белән май, уч-уч шишара чыгарды, күпереп пешкән арыш ипие кисәргә тотынды.

— Үзең дә утыр, кызым, — диде ул, читтәрәк торган Тутыяга.

— Әйем. Мин... сез киткәч...

— Ярый соң. Аннары пакусларны әйләндерерсең, кызым!..

Эш белән мавыгып сизмәгән дә: көннең кызуы җиткән, чалгы пәке белән кырылган баш түбәсе кызып, эрер чиккә җиткән ләбаса. Егет эшләпәсен эзләп китте. Учактан бер тарафта, тузгыган пакус өстендә яткан тула эшләпәсен күтәреп алыйм дисә, аның астында тәлгәшләп җыелган кып-кызыл җиләк учмасы күреп алды. Кинәт үзенең дә янып пешкән җиләк сыман кызарганын тойды, әллә нишләп китте. Менә-менә йөрәге атылып чыгар да, төшеп печән арасына тәгәрәр сыман. Ул аланлыкка торып йөгерде, остазын көтеп-нитеп тормастан, киерелеп-киерелеп печән чабарга тотынды...

Нидер дөбердәгәндәй булды. Абдулла башын күтәреп офыкка, аннан күк йөзенә бакты. Һава чалт аяз иде. Дөбердәү исә кабатланып-мы-кабатлана. Егет аның Зәй аръягындагы олы юлдан килгән арба тавышлары икәнен абайлап алды. Качаклар! Инде ничә еллар көн вә төн Урал-тауга таба агылалар. Ерак юлның ахырына җитмичә, шушы төбәктәге нигезләнеп калучылары да байтак. Соңгы елларда гына да, Абдулланың күз алдында диярлек, Әлмөхәммәтнең Әлмәт, Килмәмәтнең Мәмәт, Сөләйманның Сөләй авыллары, Зәйнең үрге агымында елганың ике ярына тезелеп киткән башка күп карьялар барлыкка килде.

Бу якларда татар авылларының ишәюе хөкүмәтнең дә эчен пошыра бугай. Әнә бит, ашыга-кабалана яңадан-яңа урыс авыллары, кальга-калалар салалар. Моннан алты ел элек Бөгелмә суы буенда Кече Бөгелмә калыккан иде. Янә дүрт елдан Олы Бөгелмә барлыкка килде. Өченче ел исә Печмән вә Куак бистәләре нигезләнде. Бер дә юкка түгел болар!

Җилкәсенә кемдер кагылудан тетрәнеп куйды Абдулла. Борылып карарга өлгермәде, колагы төбендә үк остазы Гәбделрахманның көр тавышы ишетелде:

— Моңаясыңмы, Баһадиршаһ?

— Моңаерга туры килә, хәзрәт. Егерме биш тулды: юл сайланмаган, мөслек ачыкланмаган.

— Ачыкларга бик вакыт, югыйсә,— мулла эшләпәсен салып, аны нәзек бармаклары белән сыпыргаларга тотынды.— Сайлаган — сазга, очыраган — тазга, диләр. Сиңа Гәбделсәлам ахун мәдрәсәсенә, Ташкичүгә бару мәслихәт булыр шаять.

— Әллә соң Бохарага юл чыгып карарга кирәгмы, хәзрәт?

— Анысына фатиха бирә алмыйм, кем, Баһадиршаһ! — дип кычкырып җибәрде остаз тып-тын су буен ярып.— Бохара — шәрекъ ул. Безнең юл исә, Баһадиршаһ, телибезме-теләмибезме, урыслар белән бергә хәзер. Сизәсең булыр: алар ләгатен, урысчаны да үрәнергә кирәк.

— Нишләргә дә белгән юк инде, хәзрәт. Атай белән анай да карталар. Башлы-күзле булырга да вакыт.

— Анысын сизәм, кем, Баһадиршаһ,— дип мулла янә урынына утырды, кулын егетнең иңенә салды.— Кызым Тутыя белән бер-берегезне яратуыгызны да беләм. Шәкли яктан өйләнешүегезгә дә каршылыгым юк. Сәндәй кияү — бер диган таяныч булыр иде бәңа. Тик, бигайбә, анысына да фатихам юк, мелла Баһадиршаһ! Милләт сәнең төсле ачык зиһенле затларга мохтаҗ. Тагын вә тагын гыйлем эстәргә кирәк сәңа, углым!..

## Дүртенче бүлек

Карышбаш белән Ташкичү арасын дүртенче ел таптавына карамастан, шул мәшәкатькә һич кенә дә күнегә алмады Абдулла. Монысында ялыктыргыч булды юлы. Туган авылыннан Ык суына җиткәнче генә дә ике тәүлек үтте. Алай ук узмаган да булыр иде, шәт: Агыйдел буенда куныл, иртәгесен кояш күтәрелгәнне, көн җылытканны көтәргә туры килде. Ат койрыгына ябышып, иманыңны качырырлык салкын сулы Агыйделне кичү үзе күпме гомерне алды тагы. Аннан инде, бераз җылынмабызмы дип, атта шашып чабу. Ыкка тиз җиттеләр җитүен. Әмма Минзәләдә тукталыш кылу үзе фарыз иде.

Монда тукталулары дөньядагы һәр нәрсә белән кызыксынучан аның кебек бәндәгә бигрәк тә ярап куйды. Шушы гомергә кадәр башкорт җирләренең капкасы саналган Минзәләдә сәүдәгәрләр дә, гаскәриләр дә кайнап тора, юлаучылар белән бергә тәбәктәге хәбәрләрнең яңадан-яңасы агыла гына. Анысы моңа кадәр дә, өч кыш рәткә Ташкичү мәдрәсәсендә дәрес тыңлаганда да, җәйләрен атасы белән җигелеп җир эшләрен тартканда да, бөтенләй гафил булып ятмады егет. Алай да ерактагы Карышбашка яисә Ташкичүгә килеп ирешкәнче, сүзләрнең күбесе имеш-мимешкә әйләнә, аларга ышануы кыенлаша бара иде. Биредә исә элек колагына кергәннәрнең күбесе расланды.

Абдулла өч ел буе Казан өязенең Ташкичү карьясында гыйлем җыеп йөргән арада, бу якларда әллә ни хәлләр булып алды. 1740 елгы яу шундый ук рәхимсезлек белән бастырылды, аның башлыгы Карасакал яралы хәлендә далага качып эреде. Шуннан инде тәбәк бераз тынычланып, түрәләргә дә, кара халыкка да тормыш-көнкүреш хәлләре белән шөгыльләнү мөмкинлеге туды. Әмма иксез-чиксез Казан губернасында шаккатыргыч вакыйгалар булгалап кына торды.

Шуларны уйлап атларын атлата торгач, тагы бер көнлек юл үтелде. Чулман Иделенә килеп җиттеләр. Монда инде Абдулла, үзен озата килүче типтәр Колчурага атын биреп, калган юлны ялгызы узарга тиеш.

Көймә табып Чулманны кичүе — үзе зур мәшәкать. Шөкер, анысы да үтте. Инде елганың бу ягыннан да дүртенче тәүлеген тәпили Абдулла. Ярый әле көннәре әйбәт тә, юлы такыр. Төннәрен салкын салкынын. Аның каравы, көндез кояш карый, яңгырларның да байтактан яуганы юк.

Табигатьнең күзге хозурлыгы аякларына көч-куәт, йөрәгенә гайрәт бирә Абдулланың. Шуңа кәефләнеп атлый да атлый егет. Тик менә ялгызлык кына... Олы юл булмагач ни, юлаучылар юк диярлек, сирәк-мирәк очраганнары да бер авылдан икенчесенә баручылар гына. Ялгыз башы булгангамы, аны сагыш баса. Шәрәләнеп калган урманнар, буш кырлар моңсулыгы күчәме соң күңеленә? Ни-нәрсе хакында гына уйламасын, фикеренең очы Зәй буена барып төртелә. Күз алдына ястыктай кабарып яткан печән пакуслары, тамып торган җиләк төлгешләре, шул җиләкләр кебек пешеп җиткән сылуның Идел камышыдай зифа буе килеп баскандай була, колагына кызның: «Әем, оялтасың, Апуш абый!» — дигән сүзләре ишетелгәндәй тоела.

Йөрәгенең «Тутыя-Тутыя» дип рәхәт сулкылдавын тоеп, кайнарланып-ашкынып атлавында егет. Шул ләззәтле сагышы беразга булса да онытылмасмы дип, юлын кисеп чыгучы куяннарны куып карый, үзе белән шаяргандай, бер алдына, бер артына төшеп уйнаган төлкеләр артыннан чаба. Тик сары сагышы аны ташлап китми, һаман да йөрәген талый, миен кайната. Ниһаять, уфтануы ут-җыр булып тышка бәреп чыкты:

Төштем Агыйделгә кер юарга,
Балтасыз бәкеләр уярга.
Бер ходаем насыйп итмәгәндер
Бер ястыкка башлар куярга...

Төштем Агыйделгә су буена,
Балтасыз бәкеләр уярга.
Еладым-еладым, юктыр файда,
Әүвәл сүгән ярым, син кайда?!

«Әүвәл сүгән ярым, син кайда?!» — дип кабатлап сузды да туктап калды егет, аннан шаркылдап көлеп җибәрде. Тукта, кайда да булса берәрсеннән ишетелгән сүзләрме болар, әллә сагышның күңелендә шытып чыгышымы? Үз башында бөреләнгән җыру булса, бик шәптән түгел бит, әй! Шулай дип уйлавы булды — теленә мәшһүр «Йосыф китабы»ның юллары килде:

Яңа туган айга охшаш кашларың бар,
Энҗеләргә охшаш синең тешләрең бар...

Абдулла бая үзе җырлаган җыруны асыл зат Кол Галинең сүзләре белән янәшә куеп карады — күгәреп беткән бакыр тиен янында зөбәрҗәт ялтырап киткәндәй булды. Габделсәлам ахун да сүзләрен сәйләп урынына тезә бит әнә. Җыру чыгаруын башкаларга сиздермәскә тырыша мәгәр. Алай да күңеленә килгәннәрне кулындагы теләсә нинди кәгазь кисәгенә төртеп кую гадәте булганга, җырулары якыннарына, алар аша бүтәннәргә ирешә тора. Үткән кыш мулланың Абдулла кулына килеп кергән бер китабы эчендә менә мондый юллар бар иде:

Су акар гөлдүр-гөлдүр,
Сөүгәнем кызыл гөлдүр.
Сәндин үзгәне дуст тотсам,
Пычак ал, бәни үлдүр...

Тутыяга хат итеп салырмын дип, аларны дәфтәренә күчереп алды Абдулла. Вә әй хәсрәт, Зәй буе әрәмәләренә кереп югалган аулак Тайсуганга нинди генә хәбәр барып ирешсен, ди?!

Фикеренең янә Зәй буйларына салулавын сизеп, уен кабат остазына күчерде ул. Рахман рәхим, бер биргәнгә бирә бит хак тәгалә: абруйлы ахун да, атаклы вә гүзәл гыйлемле дәмелла да, халаеклар икърар иткән шагыйрь дә. Ие, Идел-Урал төбәгендә генә түгел, Рәсәйдәге бөтен мөселман дөньясына «Габдессәлам Урай углы» дип аты таралган Габделсәлам бине Уразмөхәммәт бине Колмөхәммәт бине Колчура — аның остазы, кара төндәге камәре.

Әйтмәгәне булсын, мөдәррисләреннән уңды Абдулла. Тайсугандагы Гәбделрахман да, дөньяга шуның өчен генә килгәндәй, мәгърифәт эшенә кулы ятып тора. Гәбделсәламнең исә дөньясы киңрәк, күге иркенрәк. Аның җиһанына борынгы Юнан вә Рум да, Аурупаның башка мәмләкәтләре дә, Искәндәр Зөлкәрнәен, Субудай кебек яу башлыклары да, Әбугалисина, Олугбәк сыман галим-голәмә дә, һун вә Чыңгыз яулары да, Әфләтун, Локман төсле хөкимнәр дә, тагы әллә ниләр сыя. Шунысы бар: дәресен каян һәм кемнән генә башламасын, сүзенең ахырында Идел буйларына, Бөек Болгар мәмләкәтенә кайтып төшә. Гарәп вә фарсы, чыгтай вә госманлы телләрен ана теледәй белүенә карамастан, саф төрки белән сөйли Гәбделсәлам, аның башка телләрдән ким түгеллегенә ишарә ясый.

Ислам динендәге төрле мәзһәпләрне, калям шәрифне һәм шәригать кануннарын тирәнтен аңласа да, ахун күпчелек дәресләрен шәкертләрне дөнья вә дөньяви хәлләр белән таныштыруга багышлый. Бигрәк тә пәйгамбәрләргә хәтлеге Юнан вә Рум мәмләкәтләре тормышын, алардагы коллар язмышын, шул бичараларның хакимнәргә каршы яуларын сөйләргә ярата, халаеклар хөрлеген ялкынланып бәян итә. Изелгән-тапталган татар-башкортларның да бу дөньяда үз өлешләре, хакы барын дәлилли. Менә шуңа да Гәбделсәлам мәдрәсәсен үз итте Абдулла, менә шуңа да Ташкичүгә ашкынып барышы. Чү, нәрсә бу? Мәчетле авылы урнашкан үзәннән ургылып төтен күтәрелә. Янгын! Кешеләргә ярдәм кирәктер, мөгаен. Ул, талчыгуын да онытып, йөгереп китте. Авылга килеп керүгә гаҗәпсенүе артты гына. Кабык түбәле бәләкәй генә кырый өйнең ишеге каерып ташланган, тәрәзәләренең карындыклары ерткаланган, яңаклары җимерелгән, миче ишелгән. «Ниткән дә булса яу купкан мәллә?» — дип уйларга өлгермәде, каршысына ике драгун килеп чыкты. Кулларында балта-пычкы, үзләре кызмача. Алар егетне читән буена тибәрделәр дә янәшәдәге хуҗалыкка таба атладылар.

— Фанатиклар бу татарлар. Йортсыз-җирсез калса калалар, барыбер чукынмыйлар,— дип сөйләнде драгуннарның берсе.

Казанга Лука Канаш дигән ерткыч бер әрхәрәй килүен, әтрәт белән авылларга чыгып, халыкны көчләп чукындырып йөрүләрен ишеткән иде инде ул. Авылны урап яккан учакларның ни икәнен шунда гына төшенде Абдулла. Халаекны куркытырга дип, билгеле. Уйланып бара торгач, мәчет янындагы мәйданга килеп чыкты.

— Әй, мөсафир, аракы эчәсеңме?

— Тун кирәкме, әллә танамы?

Бер тарафта басып торучы баштанаяк карага төренгән ике каратунны күреп алды. Алларында ачык мичкә, чүмече өстендә.

— Айда, бушка сыйлыйбыз! — дип кычкырды аларның озыны. Менә шушы «тавык төпие»н муеныңа так та, чүмече белән чөмер! Тун киеп ал! Сыерлы бул! Өч ел рәткә салым түләмәссең!

Абдулла инде мондагы мәхшәрнең ни-нәрсә икәненә тәмам төшенгән иде. Шулчак колагына икенче бер өн ишетелде:

— Әйа, мөсафир! Мөселманмы син? Мөселман булсаң, йөгер — кач бу җирдән! Монда чукындыралар!

Тавыш килгән якка борылса, чәче-башы тузгыган бер бәндә. Кул-аяклары богаулы, үзе мәчет каршындагы баганага бәйләп куелган. Авылның имамы яисә Лука Канаш кешеләренә каршы чыгучыларның берсе бугай. Абдулла шунда ташланды. Исәбе — богауны ватып, тегене коткару иде. Тик багана янына барып җитә алмады, каршына һай-һаулап, алын арбага җигелгән атларын кыйнап, бер төркем драгун килеп чыкты. Иплә брәк бакса, калтырап-тетрәп китте: кучәргә тагылган калын арканда гарәп хәрефләре белән язылган кабер ташлары сөйрәлеп килә. Драгуннар аларны зираттан йолкытып алганнар. Яңа салыначак чиркәү нигезенә, имеш.

— Вәхшиләр! Нишлисез сез?! — дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды Абдулла.

Аңа җавап итеп, берсе арттан җилкәсенә сөңге белән күтәреп сукты — егет җиргә капланды. Ул да түгел колагына тәкъбир тавышы ишетелде:

— Аллаһе әкбәр, аллаһе әкбәр. Ля иллаһы...

Шунда ук кыска-кыска фәрман авазлары яңгырады:

— Залпом... пли!

Дистәләрчә мылтык берьюлы гөрселдәде. Тәкъбир әйтүчеләрнең берничәсе урам тузанында аунап калды...

Абдулла исен җыеп аягына басканда, мондагылар бар да мәчет башына карап торалар иде. Әлеге кара япанлы каратуннарның берсе мәчет кыегына ялтырап торган хач беркетеп маташа, җирдәгеләр исә акырышып, аңа куәт биреп тора:

— Уңгарак, уңгарак! Нәкъ маңгаена када!

— Булды бу. Моны хәзер православный мәчет дисәң дә ярый.

— Ха-ха-ха!

Көлешеп бетермәделәр, мәчет башында тагын берәү пәйда булды. Ак киндер күлмәген җилгә җибәргән яланбашлы бу зат, һичшиксез, Мәчетле кешесе иде. Ул кыекның сырт тактасы буйлап килә-килешкә туза башлаган чабатасы белән каратунга китереп типте — тегесе чыркылдап җиргә килеп төште. Авыл агае исә, берни булмагандай, кулындагы чалгысы белән селтәнде — хачны чабып атты.

Кинәт мылтык шартлады. Чалгылы бәндә, ни булды дигәндәй, җирдәгеләргә сөер карап, бераз чайкалып торды да, гөрселдәп мәчет алдында яткан каратун өстенә килеп төште.

Төтенгә уралган мылтыгын тоткан драгун Абдулладан дүрт-биш адымда гына иде. Егет җәһәт кенә биштәрен салып атты, ике сикерүдә тегенең янына барып җитте, килә-килешкә күтәрелгән тимердәй нык йодрыгы белән мылтыклының башына сукты. Драгун «эһ» тә итми җиргә чүкте. Калганнары бер мизгелгә генә югалып калдылар да, кисәк Абдуллага ташландылар.

Ул аларның беренчесен тибеп екты, икенчесен баш аркылы томырды. Сөлектәй килеп ябышкан өченчесен сугып миңрәтте дә инешкә таба ыргылды. Чапкан уңаена аръяктагы тыкрыкны абайлап алды. Тыкрык тулы халык, төркем-төркем булып, янәшәдәге урманга таба йөгерә иде.

Шулар артына төште Абдулла. Әмма авылны чыгарга өлгермәде, артында тояк тавышлары ишетелде. Борылып караса, ат менгән ике драгун, кылычларын уйнатып, аңа якынлашып киләләр. Аны-моны уйлап торыр ара калмаган иде инде. Абдулла тыкрык буендагы имән киртәнең иң өстәгесен суырып алды, артына борылды һәм өстенә килеп баса язган җайдакларга кизәнде. Ярсудан күзләре акаеп чыккан атлар өркеп, арт аякларына бастылар. Солдатларның берсе егылып төште. Ул да түгел, егет аны күсәге белән җиргә сылады — тирә-юньгә болыт булып кан чәчрәде. Икенчесенә кизәнәм дип, киртәсен күтәргәндә, тегесе борылып мәчеткә таба чаба иде инде.

Чит-ят урманда урала торгач, Абдулланың бите-кулы тырналып бетте, аяклары талып, тәмам агачка әйләнде. Мәгәр шушы ук яшел диңгезгә кереп югалган Мәчетле кешеләренең эзенә төшмәде, кая да булса илтә торган юл очратмады. Бәхетенә, урманы зурдан түгел икән — инде егылам, инде бер-бер куак төбенә ятып йоклыйм дигәндә, ачыклыкка килеп чыкты һәм Ташкичү юлына тап булды.

Ул Ташкичүгә килеп кергәндә, төн уртасы җиткән иде инде. Уртаклыктагы мәдрәсә йортына кагылганчы, туктап-туктап тыңлады. Тирәюньдә шикле авазлар юк, әлегә әтәч тавышлары да ишетелми, тик йокылы этләрнең анда-санда өргәләп алулары гына колакка чалынгалап куя. Ташкичүдә шөбһәләнерлек нәрсә сизелми.

Абдулла тәмам тынычлады. Шул арада күзенә бу мәлдә авылдагы бердәнбер утлы тәрәзә чалынды. Остазы, гадәтенчә, төнката китаплары белән әвәрә килеп утыра булса кирәк. Сак кына шакыды. Аксылланып торган пыялада шәүлә уйнап алды, хуҗаның такыр башы, пөхтә түгәрәк сакалы күренде. Эчке ишек ачылды, өйалдында аяк тавышлары чаштырдады. Ул да түгел, Габделсәламнең көр тавышы яңгырады:

— Кем йөри кара төндә?

— Мин әле бу, хәзрәт, Абдулла.

— Бәракалла, Батыршаһ! Сиңа соң көн беткәнме?

Караңгыда капшана-капшана өйгә уздылар.

— Бүре кумагандыр бит, Батыршаһ?!

Абдулла күзләрен ачты һәм үзенең шактый аяныч хәлдә икәнен абайлап алды: бишмәтенең җиңнәре өзелеп чыга язган, алача ыштаны ерткаланып беткән, башындагы мескен бүреге юкка чыккан. Баш исән! Баш! Шуңа да җавабында сагышлы күңел күтәренкелеге сизелде:

— Бүредән хәтәррәкләр дә бар икән, хәзрәт, дөньяда.

Ахун аның тәмам агарып калган йөзен, талчыккан кыяфәтен хәзер генә күреп алгандай булды һәм, шәкертенең хәвеф-хафага таруын сизенеп, егетнең бишмәтенә үрелде:

— Өстеңне сал да иплэп кенә сөйлә: ни булды?

— Анда... Мәчетледә...

— Ишеттем,— диде Габделсәлам, кайгылы тавыш белән.— Син шунда тап булдыңмы, Батыршаһ?

— Тап булу гынамы соң, хәзрәт, эчендә кайнадым. Аннан да битәр кан түктем, теге кара йөрәкләрнең икесенең башына җиттем.

— Ай-ай.— Габделсәлам, кабартма иреннәрен кыймылдатып, авызы эченнән генә нидер укынып алды, кызгылт чырае агарып китте, байтак кына дәшми утырды. Аннан ярым көйләп җыру әйтте:

Карчыга ла диген, ай, асыл кош
Кош кундырмас агач башына.
Батыр егет кенә, ай, шул булыр—
Хас дошманның җитәр башына.

— Син ашап ал,— диде ул, янә утыргычына урнашып. Ипи белән сөтне егетнең алдынарак этте дә янә сөйләп китте.— Димәк ки, түзмәдең?! Анысы шәп булмаган. Ялгыз башың гына берни кыра алмассың, Батыршаһ. Халык дәррәү кузгалса гына...

— Кузгалмыйлар шул, хәзрәт!

— Сүзең хак, качалар. Тик ак патшаның вә әрхәрәйләрнең кулы анда да җитмәс димә. Ул чакта нишләрләр?

Абдулла ашауга ябырылды. Хуҗа исә Канаш өскаф кешеләренең бөтен Казан артында мәхшәр кубарулары хакында сөйләп китте:

— Ярый, аллаһе тәгалә мәрхәмәтеннән ташламаса, артыгын кылана алмаслар,— дип сүзен түгәрәкләргә ашыкты Габделсәлам.— Нә генә булып бетмәсен, аларны туктату синең белән минем кулдан гына килмәс, Батыршаһ. Үзең хакында уйлан син. Нишләргә ниятлисең? Минем фикеремчә, Казан төбәгендә калырга ярамый сиңа. Кит син моннан!

Шәкерте ни әйтер икән дип, күтәрелеп караса, тегесе тәрәзә янагына сөялгән килеш йоклап киткән, имеш. Габделсәлам сәкегә тун җәеп, зур яктан мендәр алып чыкты.

Иртәнге чәй янында сүз төнлә өзелгән җиреннән башланды:

— Атаң-анаң нигезенә кайт, Батыршаһ. Ул якларда мондый ук галәмәтләр юктыр әле. Тик сак бул, зинһар, олы юлларга чыкма!

Өч елга беренче мәртәбә бугай, остазына каршы килде Абдулла. Сүз белән түгел, гамәле белән. Арчаны үтүгә, килгән эзенә — Минзәлә юлына борылмады, турыдан Чулман иделенә таба атлады. Тизрәк олы юлга — Казан-Оренбур трактына чыгарга да, йөтрәк Тайсуганга кайтып

җитәргә. Элеккеге остазы Гәбделрахман бер-бер киңәш бирми калмас. Һай, киңәштә мени соң хикмәт! Тутыя дигән фәрештәне күрү кирәк аңа!

Аның ям атларына утырудан башка чарасы юк иде. Бердән юлы ерак, аннан килеп, төн уздырырга барыбер өмәткә керергә кала. Алары исә ям стансаларында гына. Ярый әле остазы аңа юлга дип акча биргән иде. Рәхмәтләр генә яусын инде үзенә. Җай белән бер кайтарыр, боерган булса.

Икенче кичне төнгә Яланкыр авылындагы өмәткә туктадылар. Абдулланың юлга чыкканнан бирле беренче мәртәбә адәмче йокларга җыенуы иде бу.

Ашар-ашамас чүлмәк савыттагы итләрне эткәләп-төрткәләп утырганда, авыр урыс капка шагырдап ачылып китте һәм анда атын җитәкләп керүче ыспай киемле юлаучы күренде. Караңгылык куерып килсә дә, ялгышмады Абдулла — өмәткә төшүче Гәбделрахман мулла иде. Кашыгын ташлап, егет атыла-бәрелә тышка йөгерде.

— Әссәламегаләйкем, хәзрәт! — дип кычкырды.

— Баһадиршаһ, димме?! Каян болай? — Гәбделрахман атын лапас астына алып китте, Абдулла аңа иярде.

— Сүләсәң озак, хәзрәт. Үзең соң кая юл тоттың әле?

— Мәшәкать чыкты бит, кем, Баһадиршаһ. — Тутыям Әлмәтнең яшь мулласы белән никахлашты. Бирнәгә дә, туйга да нәрсәләр кирәк — Казанга барыш.

— Тутыя?!. Тутыя кияүгә чыктымы?!

— Алманың вакытында җыеп алынуы әйбәт, Баһадиршаһ...

Өмәттән беренче кузгалган ям атына утырып кабат юлга чыкты Абдулла, йөрәге исә: «Уфага, Уфага!» — дип ярсып типте. Әйе, аның өчен Тайсуган дигән карья юк иде инде дөньяда...

## Бишенче бүлек

Күтәрелә барган саен җелекләрне суыра, буыннарны калтырата, сулыш алуны буа торган Ирәндек сырты да, исемнәре мәгълүм булмаган тагы байтак кына кыя-ташлар да артта калды, ут-үлән баскан беленер-беленмәс сукмак түбәнгә авышты. Абдулла үзе дә, тычкан сыртлы җирән аты да җиңел сулыш алдылар. Ул арада киң күкрәкле, куе яллы елдам алаша адымын арттырды, ярсып диярлек алга атлады. Тик аның болай худлы баруы озакка сузылмады, каршыда, инде сыегая башлаган томан эчендә, тагы бер шәрә кыя пәйда булды. Инде икенче көне юлда, як-якта исә һаман да шул күккә ашкан мәгърур таулар да, алардан калышмаска тырышып кояшка тартылган нарат-карагайлар. Юлына әледән-әле ярсу-йөгерек елгалар, мәкерле тарлавыклар, мәшәкатьле тау үткелләре дә юлыга юлыгуын. Әмма алары да даладагы сыман иркенлек хиссияте бирмиләр, шушы бихисап кыя-сөңгеләрнең, карагай урманнарының дәһшәтле мәһабәтлеген купайталар гына. Шуңа карамастан, монда үзеңне ничектер хөр, иркен итеп тоясың. Булса да булыр икән ыгы-зыгысыз, шау-шусыз илаһи бер төяк! Өстәвенә сул тарафка сузылган ике тау арасындагы үзәнлектән, шушы төбәк баласы — башкорт егетенең киң күкрәктән сузып-сузып җырлаганы ишетелде:

Уралкайзан бөйек ай тау булмас,
Уралкайзы һөймәс тө йөн булмас.
Үз илкәе өсен корбан булган
Ир-егеткәйнең гүмере йөл булмас...

Абдулла тезгенен җибәрде, күн итеге үкчәсе белән атының корсагын сыдырып узды, алаша елдам гына алдырып китте. Егет, тезгенен

ияр кашына элеп, янө уйга батты. Барча халаеклар Каракош канаты астында диген. Ә ул, ахмак, өнө шул җиһанны томалап килгән пырдымсыз көчтән Урал аръягына китеп котылмакчы булды. Дөресрәге, качты. Посарга түгел, кылычка ябышырга кирәк булгандыр, бәлки?!

Ие, Ташкичүдән кайткач, аңа үзләренең Карышбаш авылында шөгыль табылмады. Ничарадан бичара дигәндәй, үзләреннән ике көнлек юлда гына булган Гәйнә иләүендәге Илеш мулла авылына барып урнашырга, малайларга сабак тыңлатырга насыйп булды аңа.

Төпләнгән җирендә сүз килерлек түгел иде анысы. Ни дисәң дә, халкы үз каның — татарлар. Илеш үзе — янып торган ир уртасы кеше, бик бирелеп имамлык итә, мәчеттән башкасына катнашмый. Абдулланың мәдрәсәсенә кереп тә карамый диярлек. Җаны-тәне белән хөкемдарларга бирелгән. Түрәләрнең урысы булмасын, үз мөселманыңнныкы булмасын — аңа барыбер, гел шулар тирәсендә чуала. Ахры, шуңа мулланы яратып бетермиләр авылда.

Абдулла да аның өлеге гадәтен башта ук өнәмәде, мәгәр дәшмәде. Мәдрәсәдә үз иркендә булуыннан үтә канәгать иде ул. Тик бервакыт Унаш углы Илешнең ишегалдына килеп керсә, мондагы хәлгә шаккатып калды Абдулла. Мулланың куштаннарыннан берәү, Алпамыш Хафиз, җиргә сузып салынган ялчы Гапсаттарның шәрә артын камчы белән каезлый. Бер мизгелгә генә катып калган Абдулла, исенә килеп, җәлладның өстенә атылды, аның имән күсәгедәй нык кулын тотып алды. Кызарып-бүртенгән, тирләп чыккан Хафиз гәүдәсенә ятышмаган нәзек тавыш белән чыелдап җибәрде:

— Чау, нишләвең, мөгаллим?!

Тавышка өйдән Илеш мулла килеп чыкты, ишегалдында бөхәс, тавыш купты. Байтак тарткалашкач, шул ачыкланды: елга якын Җаек буенда яңа кальга кору эшләрендә булып кайткан бабул Гапсаттар хезмәт хакы турында сүз кузгаткан иде. Илеш аңа: «Анысын падишаһтан сора»,— дигән. «Падишаһ бик еракта шул, безнең моң-зарларны ишетми»,— дип җаваплаган тегесе. Патша хәзрәтләре хәтле патша хәзрәтләренә тел тидерүе өчен суктыруы икән аны хәзрәтнең.

Ничек итсә итте, барыбер ялчыны аралап алды Абдулла. Әмма бу изгелеге аңа явызлык булып кайтты. Илеш яшь мөгаллимгә кырын карый башлады, җай чыккан саен иләү ыстаршинасына аны яманлап сөйли торган булды.

Баш исән-сау чакта моннан китеп котылырга мәллә дип йөргәндә, Абдулланы Уфа провинсә кәнсәсенә чакырттылар. Хәбәрне ишетүгә, йөрәге чымырдап китте. Вә әй хәзрәт, ахыр чаккан икән Илеш. Хибесханә сасысын исниселәре бар икән әле.

Әйа, кодрәтлесең икән, хак тәгалә — Илеш мулла шикаять язарга өлгермәгән булып чыкты. Аны Уса юлындагы Гәрәй вә Иректе иләүләрен алынган гарызнамәләрне тикшерү, өлеге дә баягы туганнар арасында мирас малы хакында чыккан низагны хөкем итү өчен чакырткаңнар икән. Шатлыгын йөзенә чыгармады Абдулла, мәгәр бу эшкә биш куллап алынды — төп нигезгә дә, Карышбаштагы фатирына да кереп тормастан, Уса юлына китеп барды.

Батыршаһ мөгаллимгә олуг түрәләрнең йомышы төшү хәбәре аның үзеннән алда кайтып җиткән, ул гынамы, бөтен Агыйдел, Караидел, Әй буйларына таралып өлгергән иде. Илеш мулла аны зурлап каршы алды, гөбернатор көткәннән ким кыланмады. Алай да бу аның чираттагы мәкере генә икәне йөзенә чыккан. Чыннан да, чырае якты булса да, эшне итәге астыннан йөртте Илеш, мөгаллимне кысуның яңадан-яңа юлларын уйлап тапты. Шуннан инде китәргә дигән фикерен тәмам ныгытты Абдулла. Җитмәсә, җае да чыгып тора. Уфада ул очраклы гына Урал аръягыннан килгән Мөслим ыстаршина белән танышып китте. Үзләренең мишәр кешесе икән. Авылларындагы мулла дөнья куйгач, мөселманнар имамсыз, малайлар мөгаллимсез калган. Шуңа кулай

кеше эзләп килүе икән. Абдулланың кемлеген белеп алгач, чат ябышты, Мөслимгә кодаларга тотынды.

Ул чакта анык кына җавап бирмәгән иде Абдулла. Хәзер исә шул сөйләшүне исенә төшерде, озын-озакка сузмый Урал аръягына чыгып китте. Әлхасыйль, качты ул Илеш авылыннан. Бәлки, бу аның чираттагы хатасы булгандыр. Барысы да шулай посып котыла торган булса, кем теш күрсәтер Каракошка?!

Мөслимдә ул эшне зурдан кубып, үзенчә башлап җибәрде. Җитмәсә, Мөслим ыстаршина «мөгаллим» дип өзелеп тора, кирәк мәдрәсә хаҗәтеннән, кирәк шәхси йомышларыннан ярдәменнән ташламый. Өстәвенә, авыл халкы да аны үз итте. Аны янә авылдан-авылга, вулыстан-вулыска да чакыра башладылар, агай-эне арасында туып кына торган бәхәсле мәсьәләләрне китапча хәл итүен үтенделәр. Әле атна элек кенә Уса юлындагы Уран иләүеннән бер татар килеп төште. Атасы үлеп, мирас бүлешә-бүлешә өч агай-эне зык килеп беткәннәр икән.

Кешенең гозерен аяк астына салу гадәте юк Абдулланың. Чулман буендагы Уран иләүенә ашкынып кузгалды — шунда дип китеп барышы яшь мулланың. Кыяга барып төртелгәндәй, аты кисәк туктап калды. Абдулла, үзе дә сизмәстән, билбавына кыстырылган чукмарын алды, ияренә бәйләгән җәясенә ябышты. Үзе ялтын-йолтын каранды. Мөгаен, аю-мазар. Юк, тирә-юнь тыныч-имин иде. Егет атын алга әйдәде. Тегесе исә урыныннан да кузгалмый, башын чайкап-чайкап ала, туктаусыз пошкыра. Абдулла иярennән төште, атны тезгененнән алды. Тик алашаның җитәкләгән килеш тә кузгаласы килми, алгы аякларын терәп карыша.

Бу хәл Абдулланы пошамаңга салды. Ат бер дә юкка тынычсызланмас, янәшәдә хәвеф-хәтәр булмаса, болай кыланмас. Ул тирә-юньне урап киләсе итте. Коралларын тотып, аланга төшәлгән кылган келәмен иңли-буйлый башлады. Ләкин бу бәләкәй яткылда шикләнерлек берни дә юк иде. Атына һәм үзенә ачуы чыгып, инеш буйлап учагына таба кайтып килгәндә, яр буенда яртылаш җиргә иңгән мунча кадәрле мүкле ташка тап булды. Бакса, төбендә бер сәләмә ята. Сәләмә генә дә түгел, шул кулга алгысыз чүпрәк-чапрак арасында адәми зат гәүдәсе дә ауный бугай.

— Әй!

Җавап бирүче түгел, кыймылдаучы да булмады. Абдулла алгарак иелде, сәер нәрсәне җентекләбрәк карарга тотынды. Җиргә капланып яткан ялан аяклы бәләкәй гәүдә.

— Ляхаулә, вәлакуате...

Абдулла җилән чабуы белән чебеннәрне куып таратты, чиркана-чиркана малайның битен, муенын капшады. Юк, үлгәнгә охшамаган, тәнендә җылы бар.

Көтелмәгән табышын инеш ярына алып килде Абдулла. Аны мүк сыман тыгызланып торган кылган өстенә салды да кесәсеннән киҗеле киндер тастымал чыгарды, аны мул итеп чылатты һәм малайның битен сөрткәләргә тотынды. Тегесе су салкынын сизде бугай, хәлсез генә иреннәрен кыймылдатып куйды, кибеп-коргаксыган теле белән ялмангандай итте.

Абдулла тастымалын җыеп тоткан хәлдә инештән су алды, аны малайның авызына агызды. Тегесе исә эчте дә эчте. Соңы начар буласын чамалап, чүпрәген үлән өстенә ташлады, малайны учак янынарак алып килде, җиләнен салып башы астына кыстырды. Тегесе исә: «Су!», «Су!» — дип ыңгыраша иде.

— Сабыр ит, олан, сабыр ит, өзлегерсең,— дип юатты аны Абдулла һәм янәшәдәге атына карап алды. Анысы берни булмагандай тыныч кына утлый иде.

Мескен сабыйга тагын бер кат су эчергәч, Абдулла биштәреннән зур түгәрәк арыш ипие, пешкән тавык, йомырка һәм корт чыгарды.

Тавыкның бер ботын сындырып алды да малайга суздь. Тегесе хәлсез кулы белән калҗаны эләктереп алды, комсызланып аңа ябырылды, күз ачып йомганчы ялмап йотты. Түзмәде, тавыкның икенче ботын да бирде Абдулла, аннан кисәк кенә азык-төлеген җыештыра башлады.

— Берьюлы ярамас, олан. Түз, алладан сабырлык сора! Ни атлы буласың?

— Яхъя,— дип мыгырданды малай.

— Алай. Ничәдә инде?

— Белмим.

— Баруыңмы, кайтуыңмы? Кайсы карьядан?

— Карьядан түгел, завуттан мин. Тимашевкадан.— Яхъя инде адәм рәтле сүз сөйләр хәлгә килгән иде. Алай да аның җавапларыннан башта берни аңламады Абдулла, сорашты да сорашты.

Ул аңлаган кадәресе шул: малайның атасы татарлардан сирәк һөнәр иясе — мәгъдән танучылардан булса кирәк. Гаиләсе белән Тимашевка дигән завутта балчык өйдә гомер сөрсә дә, җәйләр буе таулар арасыннан кайтып керми икән. Былтыр да иртә яздан, җирнең туңы бетәр-бетмәс чыгып киткән кола-яланга. Аның кайдалыгын вә шөгылен бер кеше — Яхъяның анасы гына белә, имеш. Хатын ире янына өледән-өле барып йөри, тамагына кабарга ризык ташый булган. Ата кешенең эш урыны завуттан бик еракта булмаган, күрәмсең. Җәйге матур көннәрнең берсендә улы Яхъяны да иярткән ана. Кыргый таулар, калын урманнар арасындагы сизелер-сизелмәс сукмактан шактый озак барганнар болар. Малай барын тәфсилләп сөйли белми. Хәтерендә шул гына калган: әрлән оясыдай тирән чокырга төшеп-менеп йөри атасы. Агач чиләккә салып, шуннан ниндидер ташлар алып чыга да аларны зур чүмечкә сала, учак утында эретеп карый. Шунысын бер дә онытмаган малай: «Бу тау гел бакырдан тора»,— диген, имеш, атасы.

Шул көннән бирле атна үткәндерме, аймы, бервакыт кичен бик соң кайта анасы. Чәчләре тузган, елый-елый шешенеп беткән, бармакларында тырнаклары кубып, куллары канга баткан. Анасының сулкылдый-сулкылдый сөйләгәненнән шуны төшенә малай: теге бәләкәй тирән баз ишелеп, атасы күмелеп калган.

Шуннан соң Яхъяларның болай да хәерче йортлары коточкыч мохтаҗлыкка төшә. Икесе дә ярым шәрә, ач. Ана тапканын-табынганын улына ашата, үзе ачлыктан шешенеп, танып булмас хәлгә килә. Аннан ялгыша-саташа башлый. Беркөнне аның үле гәүдәсен завут буасыннан табып алалар. Ачка үлеп яткан Яхъяны бер урыс крестьяны үзләренә алып китә.

Монысын ишеткәч, Абдулланың колагы торды, ярыйсы гына тернәкләнеп киткән малайга нәүбәттәге соален бирде:

— Урыслар да бар алайса?

— Анда гел урыс диярлек?

— Соң, соң?

— Аларның үзләрендә дә такы-токы шул.

Бусы инде Абдулла өчен көтелмәгән яңалык иде. Ул бит моңа хәтле урысларны гел түрә-мазардыр, каратун-путтыр, атлы казактыр, кораллы гаскәридер дип кенә күз алдына китерә иде.

— Ачлар дисең алайса?

— Ач кына да түгел, ярым шәрәләр. Өйләре агачтан булса да, эчләре чат безнеке сыман. Шыр сәке дә чүлмәк-табак.

— Түрәләр бераү генә димсең?

— Анысы бераү дә бит... Янында камчылы-кылычлы казаклары бар.

Инде төмам төн булды: ай калыкты — аланны сихри нурга күмде. Абдулла, соңара башлаган ахшам намазын укып алмакчы булып, урыныннан кузгалды. Борылып инешкә таба китәм дигәндә, тагын туктап калды — малайның язмышы ачыкланып бетмәде ләбаса.

— Соң сән нишләп йөрисең дә, кая барасың болай?
— Үзем дә белмим.
Шулай дип җавапласа да, төпчөнә торгач, әйтеп бетерде Яхъя. Аны үзләренә алып кайткан Игнат дәдәйнең тормышы да очын-очка ялгап кына бара икән. Алай да гаиләсенә сыендырган малайны, Яхъя кышны аларда чыккан. Тик тегенең марҗасы Анна түтәй малайның артык кашык икәнен еш кына телгә алып тора, ди. Җәй җитүгә, турыдан ук ярып салган:
— Син инде үз ягыңа, үз халкың арасына авыш, сынок! — дигән.
Атасы белән анасының Ык буендагы бер авылдан күчеп килүләрен белә икән малай. Авылның исемен генә хәтерләми. Кулына Анна түтәй биргән ипи катылары төенләнгән киҗеле ашъяулык тотып, туган ягына дип юлга чыга Яхъя. Тау-урманнар арасында буталып йөри торгач, юлдан яза. Монда ничек килеп егылганын да хәтерләми.
Таһәрәт яңартып, ашык-пошык кына намазын укып алгач, янә табын кормакчы булып, учак янына килде. Яхъя инде кылган-келәмгә авып йоклап киткән иде. Абдулла аннан-моннан гына капкалап алды да, иярен баш астына куеп, күккә карап ятты. Күк йөзе эреле-ваклы, якты вә сүрән йолдызлар белән тулы иде. Һай, санап очына чыга алучы бар микән бу йолдызларның?! Баксаң, җирдәге халаеклар саныннан да күбрәктер әле алар. Ә сыйганнар бит, сыйганнар күк гөмбәзенә! Халаеклар исә сыймый, сыярга да теләми. Берсен-берсе кимсетә, җәберли, суя. Син начар, син вак-төяк, янәсе. Бигрәк тә урыс түрәләре котырына, ике йөз ел буе җәберлиләр бит инде мөселманны, көн яктысы күрсәткәннәре юк! Вә әй хәсрәт, патша әгъзәм хәзрәтләре, ягъни шәрәфәтле мәликәбез белми микәнни шул хәлләрне? Юктыр. Белсә, халаекларның үзара низагына юл куймас, һәркайсына туры юлны күрсәтер иде.
Шулчак Яхъя саташып кычкырып җибәрде. Абдулла җылыткан урыныннан торып, малай янына килде, бисмилласын әйтеп, аның маңгаеннан, битеннән сыпыргалады, догасын укып, битен өшкерде.
Яхъя тынычлап оеп киткәч кенә, янә барып ятты. Инде бөтен барлыгын шушы малай язмышы биләп алды. Малай тере күренә. Ашатып-эчертеп, аягына бастырсаң, сабак тыңлатып, гыйлем-гыйрфан бирсәң, хәйран гына ир чыгып куюы бар үзеннән. Әллә соң атай белән анайга алып кайтыргамы? Миннән игелек күрмәделәр, бахырлар, карт көннәрендә бер юанычлары булыр Яхъя.
Абдулла малай язмышы хакында уйланып яткан арада, таң сызылды, үләнгә чык төште, аланга куе томан ятты — чиркандырып җибәрде. Ул, урыныннан кузгалып, учакка ботак-сатак өстәде, янәшәләрендә генә аягында килеш черем итеп торган атына карап алды. Аннан, кире каккысыз нияткә килеп, бөгәрләнеп яткан Яхъяга эндәште:
— Тор, олан, кузгалабыз!
Абдулланың Урал алды буйлап уралып йөрүе бушка китмәде. Язмыш аны Җомагыл атлы киң күңелле бер башкорт җәйләвенә алып килде. Хуҗа үзе дә, аның кыр казакларыннан булган ике көтүчесе дә гаҗәеп юмарт, кешелекле булып чыктылар. Ашау-эчү байларча ук булмаса да, шактый мулдан иде, хәтта ки көн саен калҗа, кымыз кебек нигъмәтләрдән авыз итәргә туры килде. Анысыннан да бигрәк, тәмам бетешкән Яхъяга сөте мулдан. Тустыганлап та, агач чиләккә капланып та эчте малай — күзгә күренеп хәлләнде.
Өч көнлек сөйләшүләренең сөземтәсеннән шул мәгълүм булды Абдуллага: ил-җирдә әлегә иминлек иминлеген. Мәгәр далада көне-ае белән ишәя барган типтәр-бабуллар арасында ризасызлык, канәгатьсезлек көйри, тымызык ыгы-зыгы кайный, имеш. Булыр да, типтәрләр вә бабуллар тәякнең иң хаксыз-хокуксыз, изелгән-тапталган бәндәләре. Туган-үскән җирләреннән кубарылулары гына җитмәгән, монда күченеп килүләренә, җир дия-дия, башкорт асабаларына коллыкка төшкәннәр. Ул мескеннәр зарланмый кем зарлансын тагын.

Бу кадәресен шулай тиеш дип кабул итте мулла. Тик менә Җомагыл агайның икенче бер сүзеннән сискәнеп куйды: зар-моң, хәтта янау авазлары кайсыбер мишәр иләүләрендә дә ишетелгәли, имеш. Мишәрләр гомер бакый салым-алым дигәнне белмәделәр. Ак патшага ихластан хезмәт итеп килде алар. Шуңа да уртак кушаматлары — вирнайлар. Мишәрләр ыңгырашырлык, алар зарланырлык сәбәпләр юк бугай ла...

Ярый, ни булса да булыр, туасы көннәр барын да аныклар. Хәзергә ил-җир хәлләрендә гаме юк әле Абдулланың, нияте — тизрәк Карышбашка кайтып, Яхъя дигән ошбу йон йомгагын атасына калдыру. Аннан инде иркенләп Уран иләүендәге, теге ыгы-зыгылы гаиләне иминләп кайту.

Ятим малай белән сөйләшә-сөйләшә бәләкәй генә инеш ярында тән уздырганнан соңгы көнендә юлы җанлана төште Абдулланың. Берәмләп тә, төркем-төркем дә бер якка таба атлаучы җәяүлеләрне узып китте, ат менгәннәре исә аны басып җитте. Барысы да бер тарафка ашыгалар. Сорашмаса да сизенде Абдулла: типтәр-бабуллар. Араларында татарлар гына түгел, чирмеш-чувашлар, мукшы-арлар да бар. Азмаз гына ябай башкортлар да, хәтта берән-сәрән урыслар да күренгәли. Түзмәде Абдулла, янәшәсенә туры килгән шадра битле, түгәрәк кара сакаллы татар җайдагына сәаль бирде:

— Кая барыш болай, кардәш?

Шадра аңа ачулы гына карап алды:

— Мәләкәскә,— дип ысылдады.

— Нәстә бар соң, ау-яу юктыр бит?

— Бәй, белмәйсең мени? Яңа указ чыккан бит. Шуны Мәләкәстә кычкырып укыйсылар икән...

Сөйләшә-сөйләшә ябай гына бер авылга барып керделәр. Монда инде халык өйләр санынннан бик күпкә артып киткән, урамнар кысырыкланып калган. Абдулла якындагы тыкрыктан ындырлар артына чыкты. Яхъяны култыгына кыстырган хәлдә атыннан төште, малайны былтырдан калган салам күбәсенә утыртты, атын киртәгә бәйләде:

— Сән шунда тын тартмый ултыр, олан. Мин — хәзер...

Абдулла килеп басканда, писыр Рахманкул дигәннәре нәзек кәҗә тавышы белән, көчәнә-көчәнә, нидер укып маташа иде. Аның тавышы арткы рәттәгеләргә килеп ирешми диярлек. Алай да вакыт-вакыт: «ясак», «җан башыннан түләнә торган салым», «имана» дигән сүзләре яңгырап-яңгырап китә — һәрхәлдә, сүзнең ни хакында барганын чамаларга мөмкин. Рахманкул укып бетергәндерме, юктырмы, мәйдан кисәк кенә бер авыздан үкереп җибәрде:

— Сик-сән ти-ен!!!

Аннан инде ата кызны, ана улны аңламастай тавыш купты:

— Кирәкми-и-и!!

— Түләми-и-ибез!!

— Да-лу-уй!!!

Сотник Бахмәтов дигәннәре беләгенә камчы элмәге эленгән кулын югары күтәрде — мәйдан сагаеп калды. Халык тына төшкәч:

— Акылың алтын икән — үзең түлә! — дип кычкырып җибәрде Абдулла эргәсенә туры килгән теге шадра.

— Хак, түрәләр үзләре бирсен!

— Сукыр бер тиен дә түләмибез!!

Халык төркеме кызганнан-кыза барып, мәйданны тоташ гүләү күмеп китте. Ул да түгел, баш очларында таяк-күсәкләр болганды, җанлы бокра кысылганнан-кысыла барып, түрәләрне урап алды. Сотник Бахмәтов кылычын кынысыннан тартып чыгарды, казак Порошин да, коралын башы өстендә болгый-болгый, түрәләр алдына чыгып басты. Әмма халыкның сабырлыгы нибары мизгелгә сузылды, мәйдан өстендә янә берсеннән-берсе усал, янаулы тавышлар яңгырады:

— Сөйрәп төшер!
— Тап-та!!
Ярсудан шашынган бәндәләр утынлыкка ыргылды, шул тарафка таяклар, ташлар очты. Тегеләр дә кан исе чыкканны сизделәр бугай, җанлы бөҗраның сыеграк җирендә торучыларны бәрә-ега каравыл өенә кереп бикләнделәр.
Гаярьрәкләр каравыл өенә ябырылды.
— Ват-җимер!
— Ут салыгыз, ут!
Шушы тамашага хәйран калып торган Абдулла, үзе дә сизмәстән, куәтле беләкләре белән халыкны як-якка ишеп, утын өеме янына килде, арада иң озын һәм иң калын имән баганасының юан башыннан күтәреп алды. Аның ни кырырга ниятләвен бик тиз төшенеп алдылар. Баганага берьюлы дистәгә якын егет килеп ябышты. Җитез генә күтәрделәр дә каравыл өенә ябырылдылар. Егетләр йөгереп килгән шәпкә имән баганаaның нәзек очы ишеккә китереп бәрде — имән такталар чәрдәкләнде, ишек капланып төште. Казак Порошин ишек төбендә ук торган икән, кылычы артыннан ук үзе бөгелеп куырылды:
— Кулны, кулны харап иттегез, ворлар!
Ул сынык уң кулын сулы белән күкрәгенә кысып, үкереп елап җибәрде. Егетләр исә аңа карап кына суынмадылар, түрәләрне эләктереп алдылар. Сотник Бахмәтовның кулларын үз камчысы белән артка каерып бәйләделәр. Вахмистр Моисеевка да бау табылды. Кайсыдыр сотникны сугып екты, анысы өстенә вахмистр барып төште, камчылар чыжлады, һавада күсәкләр уйнады. Шашынган кешеләр тегеләрне таптап-изеп, үч алу ләззәтеннән кинәнгән мәлдә, мәйданда куәтле бер аваз яңгырады:
— Туктагыз! Кан коясыз лабаса!
Иләү ыстаршинасы Сөеш Әбҗәков икән.
— Туктагыз дип әйтәм! — Сөеш кара тиргә баткан типтәрләр каршына килде: алдарак торган егеткә акайды:
— Әһә, морза Карабаш углы? Көтергә!
Аннан янәшәдәгеләргә ябырылды:
— Исмәгыйль Исхак углы?! Дарга!..
— Аһ, хәсис чирмеш! Кинҗәбай, сән дә монда?!
Старшина кисәк тәртелеп калды — күзләре Абдулланың сакал-мыексыз чыраена текәлгән иде.
— Монысы ниткән бур тагы? Ас...
Сүзен әйтеп бетерә алмады. Абдулланың тимердәй нык йодрыгы маңгаена килеп төште — Сөеш гөрселдәп җиргә ауды, телдән язды. Шуны гына көткәндәй, күсәкләр гөпелдәде, камчылар чыжлады.
Вулыс ыстаршинасын эт итеп кыйнап ташладылар. Аннан инде, һәркайсын ботыннан сөйрәп, каравыл өенә кертеп аттылар, өсләреннән бикләп алдылар.
Күнекмәгән эштән тирләп, тәмам суга баткан егетләр утын агачлары өстенә утырыштылар. Тамашадагы халык аларны урап алды. Сүз үзеннән-үзе каравыл өендәгеләрне нишләтү хакында киңәшкә күчте. Абдулла бәндәләрнең җан ачуы белән әйтелгән сүзләрен тыңлап-тыңлап торды да телгә килде:
— Ашыкмагыз әле, җәмәгать?! Боларны тәмуг кисәве итүе ансат ла ул. Исәннәрендә бер-бер файдага ярамасдармы? Алып чыгыгыз әле теге әфисәрне?!
Егетләрнең икесе җилтерәп каравыл өенә кереп китте. Ә дигәнче Моисеевны сөйрәп чыктылар да төркем уртасына китереп бастырдылар.
— Ат бирегез! — дип боерды Абдулла.
Йөгәнле ат житәкләп килделәр. Мулла Моисеевка эндәште:
— Сән үз аңындамы, вахмистр?

Моисеев дөшми генә ияген какты.

— Аңласаң, вәйт шул,— дип дәвам итте Абдулла.— Хәзер үк Уфага кайт та, полковник Люткинга әйт: типтәрләр вә бабуллар бернинди салым-алым да түләмәячәкләр, диң!

Төркем, аның сүзен хуплап, гөрләп алды:

— Хак! Дөрес!

Ярым үлек хәлендәге вахмистрны күтәреп алдылар да атка атландырып куйдылар. Ирексездән илчене озата барырга дип, татарлардан Уразмәт Олыкаев алынды.

Кешеләр кыр капкадан чыгып барган ике җайдакны сүзсез генә карашлары белән озатып калдылар да кайсы-кая тарала башладылар. Инде Абдулла да тынычлап, аек уй йөртер хәлгә килгән иде. Салам күбәсендә утырып калган Яхъя белән киртәгә бәйләгән аты исенә төште, ашыкмый-кабаланмый гына ындырлар ягына китеп барды.

Гыйсьянчы авылны чыгып, байтак җир үткәч кенә тәмам суынып, тынычланып калды Абдулла. Йокымсырап барган малайны кулына кыса төшеп, узган юлына борылып карады. Дала тын вә хәвефсез иде. Тирә-юньдәге иминлек шөбһәле уйларын куып тараткандай булды. Тезгенен ияре кашына ташлап, атына чөңгереп алды, хәбәрсез иркенләп бармакчы иде. Әмма каршына куаклык артындагы борылмадан дүрт-биш җайдак килеп чыкты. Казаклар. Алдан килгәне атын Абдулла алашасына аркылы куйды, башлык икәнен сиздереп, вәкарь белән сөаль бирде:

— Кем син? Кайдан вә кая барыш?

— Урал аръягыннан, Мөслим ыстаршина камандасыннанмын. Имән калага углымны алып барам.

Башкорт җирләрендә яшәүче халаекларның балаларын сатып тамак туйдырулары гадәти хәл. Ышандылар, шаркылдашып көлешә башладылар:

— Сине генә көтәләр ди Уфада. Кала гаскәриләр белән тулы.

— Ахмак. Бала базары Оренбурда инде, анда хакы да әйбәтрәк...

Шул рәвешле көлешеп-шаулашып алдылар да, казаклар үз юлларына китеп бардылар. Абдулла тир бәреп чыккан маңгаен сөртеп алды. Шөкер, алла саклады.

Урау һәм мәшәкатьле булса да, ыгы-зыгылы Уфаны читләтеп үтте Абдулла.

Кабат эзгә төшеп, ике-өч ук атар ара үтәргә өлгермәделәр, каршыдагы үрдә тузан болыты күтәрелде — ишле генә атлылар төркеме болай таба төшеп килә иде. Абдулла тезгенен тартты, бер мизгел генә уйланып торды да алашасын янәшәдәге өрәмәлеккә таба борды.

Әтрәт юыртып узып та китте. Атлар тоягыннан күтәрелгән тузан белән бергә Абдулла күңеленә яңа шөбһә ятты. Димәк ки, аларның мишәрләре түрәләрне яклап яу чаба. Өметләр киселде, типтәрләрнең авызлыкланасылары шиксез. Ие, хәвеф-хәтәрдән читтәрәк булу хәерле. Яхъяны Карышбашка кертеп кенә чыгарга да аулак Урал иләүенә таба юл алырга кирәк.

Акылы белән шулай беркетсә дә, күңеле түреннән боз булып икенче бер хафасы калыкты мулланың. «Тагын качасыңмы? — диеп битәрли башлады ул янә юлына төшкән Абдулланы.— Батыршаһ тәхәллүсе йөрткән буласың тагы. Юк, ошбу олуг исем харам сиңа, харам!»

## Алтынчы бүлек

Зыңгылдап нидер төшеп ватылды. Бөләкәй адашының вата-җимерә гарәп сүзләрен тәкърарлавын тыңлап мич буенда басып торган Абдулла башын күтәрде, мәдрәсәнең бәләкәй тәрәзәсенә карады. Шөкер, күз

карасыдай саклаган пыяласы исән икән. Алайса, нәрсә чылтырады соң? Карашы каршыдагы мәчет кыегына, тырпаеп торган юкә кабыклардан «үсеп чыккан» боз сөңгеләренә тукталды. Үтә күренмәле имчәкләрдән ашыга-йөгерә тамчылар тәгәрәшә. Авыр боз сөңгеләрнең берсе, йөгерек тамчылардан көнләште бугай, үзен бар иткән кабыктан ычкынып китте дә, чылтырап, малай-шалай таптап такырайткан сукмакка барып төште. Мөгаллим үзе дә сизмәстән көрсенеп куйды — тагы язлар җитә! Шәкертләренә беравык кызганулы-сагышлы карап торды да янә телгә килде мөдәррис:

— Китапларыгызны ябып, букчаларыгызга салыгыз да, өйләрегезгә кайтыгыз. Быелга сабаклар тәмам.

Пырхылдап күгәрчен көтүе күтәрелдемени — мәдрәсә гөр итеп алды, ул да түгел, малайлар, тишек кисмәктән аккан су кебек, күзгә күренеп кими башладылар. Хәтта чит авыллардан килеп укый торганнары да әллә кай арада юкка чыктылар...

Кабат яз җитте, дигән уй янә кытыклады Абдулланың миен. Тик баягыча сагыш юк иде инде күңелендә мулланың. Киресенчә, ниндидер куанычлы дәрт. Юкка шәкертләренә сылтап маташкан икән, алардан битәр ашкынулы язны үзе сагынган лабаса! Кыш буе мәдрәсәдә бикләнеп яту тәмам ялыктырган. Озын кыш йөремсәк күңеленә богау булып ята Абдулланың. Урал тавының аръяк итәгендә бу авыл кар көртләре эчендә югалып кала. Баштарак — каз өмәләре, туй-төшем, сугым чорында әллә ни сизелми әле. Раштуа якынлашуга, күңелне генә түгел, бөтен тәнне сагыш баса, мәдрәсәдәге аулак хөҗрә мөгарәгә охшап кала. Бар юанычы — шәкертләр дә җомга намазы мулланың. Ярый әле, шушы кар баскан авылда Мөслим ыстаршина бар. Хәлне аңлагандай, әледән-әле ашка чакырып ала, табын янында ил-җир хәбәрләрен ишеттерә. Гәбделсәламнең Оренбурга, дөресрәге Сәгыйть бистәсенә урнашуын да Мөслимнән ишетте Абдулла. Шуннан бирле остазы янына барып кайту дәртендә ымсынып яши.

Хәбәрләр дигәннән... Оренбурда типтәрләр явын бастыруда башлап йөргән мишәр вә башкорт ыстаршиналарыннан Салих, Сөләйман, Әхмәр, Якуп вә башкаларга падишаһ исеменнән бүләк итеп затлы кылычлар биргәннәр, имеш. Башкаларын белеп бетерми Абдулла, мәгәр бүләкләнүчеләр арасында үзе туып-үскән каманда ыстаршинасы Янышисемен ишетү — яралы йөрәгенә тоз салу белән бер булды. Янышның үз авылларындагы халаекларга әшәкелектән башка өч тиенлек тә игелек күрсәтмәвен атасы сөйләгәннәрдән дә, авылдашларыннан ишетеп тә белә бит ул.

Хәерсез хәбәр кешене Урал аръягыннан да эзләп таба. Хут февраль бураннары котырынган көннәрнең берендә авылга Себергә узгынчы сәүдәгәрләр кәрваны тукталды. Араларында Карышбаш ягыныкылар да бар икән. Зур толыпка кереп чумган Гәйнә татары китерде аңа яман сүзне: атасы — Гали Мәзгытдин углы вафат! Шул көнне үк ерак юлга чыгып китәргә дип талпынды Абдулла. Һаман да шул Мөслим ыстаршина кайтарды күңелен. Баксаң, хаклык, чыннан да, аңарда икән. Атна буе тилергән буранда Уфа ягына түгел, күрше авылга дип кузгалу да ахмаклык. Җитмәсә, атасының вафатына ике атна үткән бит инде — бердәнбер углы кайтмады дип, җирләми тормаслар. Мөселманда мәетне озак тоту гадәте юк лабаса...

Абдулла шулай тирән уйга батып утырган мәлдә, шыгырдап мәдрәсәнең авыр ишеге ачылды, бусагада җәйгечә күлмәк-ыштаннан вә түбәтәйдән, алай да аякларына киез каталар кигән Апуш күренде. Мөдәрриснең иреннәренә елмаю кунды — унике яшьләр чамасындагы бу чос малайны ярата иде мулла. Ыстаршина углы булганы өчен генә дә түгел, зиһенлеге хакына. Остазының мөнәсәбәтен малай үзе дә белеп сизеп тора, шуңа да мулла үзен иркен тота. Әле дә ишектән үк шәрран ярды:

— Адаш абзый, атай сөне безгә кайтсын дип әйтте. Токмач салган, бөлеш пешкән, дип әйтергә кушты...

Ир уртасына җитүенә карамастан, бөтен кыяфәтеннән егетлек бөркелеп торган старшина аны, гадәтенчә, бик ачык каршылады. Ишекләрне үзе ачып, болдырга ук чыкты, мулланы култыклап, киң иркен өенә алып керде, җиләне белән эшләпәсен салдырып, зур агач чөйгә элеп куйды. Үзе үк җиз комган белән су, кызыл башлы сөлге алып килде, үз куллары белән юындырды. Аннан инде, гомергә бер килгән кунагын күргәндәй яктырып, ак өйгә алып керде, өстәл янындагы артсыз урындыкка көрпә салды:

— Утыр әле, хәзрәт,— диде ул урынга ымлап, шул арада алдагы яктагыларга кычкырырга да өлгерде:— Сезнең нихәл анда?

Урта ишек өче итеп чыелдап куйды: икесе дә шул якка карадылар. Ишек ярыгында чүлмәк кувшин һәм аны сабыннан тоткан нәфис кул күренде. Өй хуҗасы урыныннан күтәрелде, барып кувшинны алды, сак кына өстәлгә китереп куйды. Аннан билгесез оста куллары белән ясалган шкафтан ике данә бохар касәсе алып килде.

— Имеш-мимеш белән дөнья тулы. Тик хәерлесе генә юк, гел моң-зар да гел күз яше. Тәяктәге халаеклар күзгә күренеп хәерчеләнә бара. Ачлык та ялангачлык, кара үлем сагалый халаекларны!

— Шулай ук мыни соң, Мөслим абзый?

— Алай гына да түгел шул, Батыршаһ! Оренбур, Уфа базарлары сатлык бала-чага белән тулы...— Старшинаның тавышы чатнап киткәндәй булды, «Батыршаһ»ка күчкәнен сизми дә калды. Бу исә сүзнең ихласлыгы хакында сөйли иде. Шуны расларга теләгәндәй, Мөслим җиңел генә өстәл янына күчеп утырды, чүлмәк-кувшиннан пиалаларга бал койды.— Токмачка хәтле берәрне тотаек әле, Батыршаһ?!

Сүзен урта ишек артыннан ишетелгән хатын-кыз тавышы бүлде:

— Сиңайтәм, токмачны алсаңчы?!

Мөслим, бөтергечтәй хәрәкәтләнеп, урыныннан купты, сыза ачык ишеккә барып, алдагы яктан сузылган агач коштабакны ике куллап тотып алды, кайнар бу бөркеп торган шулпаны өстәлгә китереп куйды. Шул ук тәртиптә табынга түбәләмә ит тулы тагын бер коштабак, яргыч ташы хәтле арыш ипие, чалгы пычак, чаган кашыклар килде. Бер уңайдан мич арасындагы чөйдән озын алача тастымал алып, анысын мулланың итәгенә салды хуҗа. Аннан инде, кулларын пешерә-пешерә, ит турарга тотынды.

Абдулла, өзелеп калган сүзне ялгыйсы итте:

— Калада халаек, дисең алайса?

— Һай, Батыршаһ!— Старшина туралган итне токмач өстенә аудар-ды, кашыгын кулына алды.— Бисмилләһи... Әйдә, аштан үрел, хәзрәт... Ие, яңа салымнан миңрәп калган бөтен типтәр-бабул купкан анда. Теге Сембер куписы Тәүердәшефкә язылалар. Сабанга тешкәнче, завут салуда эшләп алмакчылар, имеш. Әле юлда, өч авыл арасы җир булыр, бер татар типтәре белән кайтырга туры килде. Шул завут дигәннәренең янындагы урманнар тулы халык, ди. Кыш дип тормыйлар, җир казыйлар, агач кисәләр, икешәр-өчәр ат белән тарттырып, бүрәнә ташыйлар икән. Халаеклар анда чебен урынына кырыла, ди. Заманаҗның ахыры җитүдер бу, Батыршаһ. Карап сүләгәнчә, кара җирне исраф итеп килә ләбаса афәт!

— Ахырзаманга ерак әле, Мөслим абзый. Каракош азына шулай.

— Урыс түрәләрен әтүеңме?

— Аның кем вә ни икәнен төгәен әтә алмыйм. Питырбур Мәскәү вә Казан якларыннан килә безгә ул явызлык. Чарасын күрмәгәндә, бар халаекларны ялмап йотуы бар ул хәшәрәтнең.

— Чарасы ни, Батыршаһ?

— Кылыч-сөңге кайрау, атларга менү дип беләм, Мөслим абзый.

Старшина коңгырт-кара күзләрен зур ачып, муллага текәлеп калды, аннан ашавын да онытып, канатланып сөйли башлады:

— Һай, Батыршаһ! Атка менәрлекләр мени соң адәм балалары?! Былтыргы карат әтрәтләреннән котлары алынып, бөтенләй хәчтерүшкә калганнар. Әтәм ич, байтагы балаларын сатып, ач үлемнән котылмакчы. Урыс түрәләре дистәләп җыялар.

Абдулла, авызына китергән кашыгын капмыйча, үткер карашын старшинага кадады:

— Сатылган угланнар чукындырылачак алайса?! Вә әй хәсрәт! Лука Канаш кулы монда да килеп җиткән икән. Ля хәүлә валя куәте! Сән әллә ниткән хәвефләр сүлисең әле, Мөслим абзый.

— Булганын сүлим, Батыршаһ.— Старшина, кисәк кузгалып, чүлмәк-кувшинын алды, чокырларга бал салды.— Шыңа йөрәк әрни дә.

— Сизенгән ием бән аны, Мөслим абзый, сизенгән ием!

— Нәрсәне, Батыршаһ?

— Теге Каракошның мәкерен. Ул хәшәрәт халаекларның җиренә-малына гына түгел, калебенә кадала. Илеңә-кенеңә ия булу гына да җитми аңа, кешенең җанына богау сала, рухын минекли!

— Уемдагын тартып алып әттең, Батыршаһ!

Алдагы яктан ишетелгән ягымлы тавыш аларны айнытып җибәрде:

— Сиңайтәм, тавышланмасагызчы?! Узган-барганның әллә ни уйлавы бар... Бәлешне биримме?

Коштабакларны алып, өстәлгә таба белән бәлеш утырткан арада, икесе дә суына төштеләр. Абдулла, бәлеш кисү белән мавыккан хуҗага карап, аек фикер йөртә башлады. Тукта, төбәктәге хәерсез хәлләрне сөйләү өчен генә чакыртмагандыр ла аны илөү агасы?!

Мөслим дә артыграк комарланып китүеннән канәгать түгел иде. Ул, урынына иплэп утырды да, кунагына эндәште:

— Ярый, дөньясының башына төкер, Батыршаһ. Утыр. Бән бит боларны сүләп, сәне шаккатырырга чакырмадым... Сүзнең асылына күчик.

Төмен белеп, сөзеп кенә бал эчеп алдылар да бәлешкә ябырылдылар. Алай да хуҗа ашау белән мавыкмады, кашыгын өстәлгә куйды:

— Күптән әтәсем килеп йөри, хәзрәт... Ие, бәнем авылда өченче кышыңны чыктың, ике җәй җәйләдең дисәк тә хаталанмыйбыздыр. Шөкер, телгә килмәдек, араны бозмадык. Сер түгел, сәңа хәтле безем мишәрләр аллаһ йортына теләр-теләмәс, элкән-селкенрәк йөри торганнарые. Хәзер, ана, җомга кеннәрдә мәчеткә сыймый халаек. Әллә кай тау араларындагы башкортларга кадәр киләләр...

— Бәнем вәгазьне тыңларга яраталар алар, Мөслим абзый.

— Хикмәт нидә дип сорамыйм. Имам буларак та, мөдәррис буларак та ярата сәне каманда. Әлхасыйл, бөтенләйгә кал сән бездә! Бер дигән йорт салып бирәм, бергә-бергә малын-туарын тергезеп җибәрербез.

— Анай карт шул, Мөслим абзый. Янә дә килеп, теге Яхъя атлы углан да бар бит әле бәнем.

— Аларын да уйладым, хәзрәт. Атка түибез дә апкиләбез үзләрен. Үләнеп җибәрерсең. Сәңа дип атап йөрткән, күз төбәп торган чәчби дә бар. Йомышлы мишәр Хәсән кызы Зөлхәбирә. Кыз түгел — эш аты. Уйлап та торма — үлән! — Мәсьәләне шулай ансат кына хәл ителүгә санады бугай, ашыгып кувшинга үрелде старшина, янә чокырларга бал бүлде.— Йә, хәерле никах хакына!

Абдулла моңа хәтле дөньяда ике генә хатын-кыз — Гөбделрахман мулла кызы Тутыя белән анасы гына бар дип белә иде. Тутыя Әлмәтнең яшь мулласына хатынлыкка бирелгәч, аның өчен бу җиһанда бер генә хатын-кыз җенесе яшәп калды — анасы. Баксаң, кыз-кыркын дигәннәре тагы да бар икән!.

Зөлхәбирә сөйләп бетергәсез йорт җанлы булып чыкты. Килен булып төшүенә атна да үтмәде, Мөслим старшина салдырып куйган

шәрә өйне җәннәт итте дә куйды. Тәрәзә башларына чүпләмле сөлгеләр, алардан өскәрәк түр буе эленде. Старшина арттырган киң агач караватка бирнә малы — ястык-түшәкләр, юрганнар өелде, алар чыбылдык белән капланды, сынык аяклы өстәлгә киҗеле ашъяулык җәелде — өй эче чүпрәк-чапрак белән тулды. Әллә кай арада гына ашаяк бүлмәсе чүмеч-коштабаклар, комган-тагараклар белән күмелде, тәрәзә төпләрендә гөлләр пәйда булды.

Абдулланың анасы Бибинур да гомер бакый тик тору дигәнне белмәде бит. Килен кайнана туфрагыннан диюләре хак икән. Килгәннән бирле арты утыргычка тими Зөлхәбирәнең. Күз дип тормады, дистәгә якын тавык, аталы-аналы каз асрый башлады. Көннәрнең берендә исә буаз тана җитәкләп кайтып керде. Яшь остазбикәнең тынгысызлыгы мулланы да мәшәкать белән күмде. Сыеры булгач, анысына абзары, печәне, каз-тавыкка кетәге кирәк бит әле. Хак, үзе балта чапмады, чөй какмады Абдулла, мәгәр әлеге эшләрнең һәркайсы артыннан йөрү дә байтак кына вакытны ала иде. Келәү ае (октябрь) керүгә карамастан, мәдрәсәдә сабакларны башламый торды имам-мөдәррис, һаман да хуҗалык кирәк-яраклары артыннан йөрде. Хәер, алары сыныкка сылтау гына иде бугай. Хагын әйткәндә, гел генә дә яшь бикәче янында ураласы килә иде мулланың.

Рамазан җитәргә дүрт-биш көн кала исә, Абдулла җанындагы яшь кияү дәрте артка чигенеп, мөдәррислек комарлыгы уянды. Ул мәдрәсәгә кереп, андагы хезмәтче аша Апушны һәм Мөслимдәге биш-алты малайны чакыртты, тирә-яктагы мишәр вә башкорт авылларына барып, шәкертләргә хәбәр салырга кушты.

Ул арада кырпак кар төште, дәресханәләр ягып җылытылды, чит авылныкылар үзләре күтәрә алган кадәр ризыкларын алып мәдрәсәгә җыелдылар. Иртәгә дәресләр башланмакчы.

Шул көнне кечкә буйда мәдрәсә ихатасына уйламаган-көтмәгән юлаучы — Карышбаш бабулы Колчура килеп керде. Атының төмам талчыгып, бөтенләй эштән чыгуына караганда, йомышы җитди вә ашыгыч иде чапкынның. Шулай булып чыкты да. Бернинди хафасыз, ваемсыз гына мәдрәсәдән чыгып килүче Абдулла, аны күрүдән элек, тавышыннан танып алды.

— Хәзрәт, анаң вафат! — дип кычкырды Колчура, сәлам бирергә дә онытып.

## Җиденче бүлек

Батырша мулланың Карышбашка кайтып төпләнүе хакындагы хәбәр, кона-сәгате белән дигәндәй, барлык дүрт юлга: Казан, Уфа, Себер вә Нугай юлларына таралып өлгерде.

Әйә хәсрәт, Батыршаның бөтенләйгә күчеп кайту хәбәре мөселманнар яши торган һәр аймакка ирешкәндә, имеш-мимешләрнең башкасы — хәвефлесе шытып чыкты. Утсыз төтен булмый. Имеш-мимеш таралган икән, димәк, аның нигезе бар. Һәм, әйтергә кирәк, хәзрәт «ычкынган», дип фикер йөртүчеләр хаклы иде. Хикмәт шунда, авылга күченеп кайтуының икенче атнасында ук, яшь мулла адәм әйтеп, адәм ышанмас мәрәкә кузгатты: үткән ел гына дөнья куйган ятимә Хәнифә карчыкның мунча хәтле генә бер тәрәзәле өен сорап сотник Ясәвигә гарызнамә язды, шунда күчәргә теләге барын белдерде.

— Сән нәрсә, мулла, читтә йөри торгач, ычкына башладың мәллә? — дип көлде Ясәви, әлеге сөер язуны кая куярга да белмичә.

— Ыланнарга мәдрәсә юк, Ясәви, — дип тыныч кына аңлатуында булды Абдулла, — атайдан калган кара-каршы гүрничәне дәресханә итәргә дим.

— Мәчет эргәсендә мәптәгебез бар лабаса, хәзрәт.

— Анысында кыз балалар укытырбыз.

Сотник артыгын бәхәсләшәсе итмәде, икенче көнне старшинага китте. Яныш старшина гаризнамәне укып та тормаган, кул гына селтәгән, имеш. «Авыл үзегезнеке, җыенда хәл итегез»,— дигән. Аңа ни, Карышбаш әллә бар, әллә юк дөньяда, үз түяге Чуртанлыкүл генә имин булсын.

Ясәви мулланың әлеге гамәлен дивана бер бәндәнең җүләрлеге дип караса да, гавам мәсьәләнең асылына тиз төшенде, яшь имамның ниятен күтәреп алды, җыен башланып китүгә, һәр тарафтан хуплау авазлары ишетелде:

— Бәрәкалла! Бик мәгкуль, хәзрәт.

— Аллаһе тәгалә саулыгыңны бирсен.

— Хәнифә кортканың йортын сүз итеп сүләп торасы да юк, бушка бирергә кирәк!

Авылдашларының теләктәшлеге Абдулланы канатландырып җибәрде.

— Рәхмәт, аксакаллар,— диде.— Быелга шылай ярап та куяр, шәят. Вәләкин бәнем гүрничә генә сыйдырмас шул барын да...

Аны берьюлы ике-өч тавыш бүлде:

— Сүзеңне ачык итеп әт, хәзрәт!

— Ачыгы шул: зур итеп мәдрәсә гыймарәт кыласые, картлар.

— Бүрәнәсен генә сүләш, хәзрәт!..

— Барыбер эш юк ла кышын...

Җыеннан ул дәртләнеп, канатланып кайтты, иртәгәдән калмый тирә-күрше карьяларга хәбәр саласы итте. Вәләкин җыенның карары өенә аңардан алдарак кайтып җиткән иткән — Зөлхәбирә аны караңгы чырай белән каршылады:

— Бу ни инде, мулла, үз йортыңнан үзең баш тарт, имеш!

— Бер кичкә куян тиресе дә чыдый диләр, остазбикә. Кышны ничек тә чыгарбыз шунда, боерган булса.

Зөлхәбирәнең турсаюы уен-муен гына түгел икән:

— Бән ул йортны барып карадым, мулла. Анда кышлау түгел, төн кунуы да имәнгеч. Үзе кысан, үзе караңгы...

— Кысан булуы безнең өчен әйбәтрәк тә булмагае, остазбикә,— дип көлеп җибәрде Абдулла. Ул әле һаман да шаяруга исәп тота иде.— Бер-беребезне эзләп мәшәкатьләнәсе юк.

Хатыны исә уенга кушылырга уйламады да:

— Бәне ләхеттә черетергә дип үләнгәнсең икән.

Монысы инде артыгы иде. Абдулла җилтерәп мич арасына узды, борылышта тукталды һәм җикеренеп диярлек әйтеп салды:

— Гүрничә кирәксә, атаң йортына кайтырсың, остазбикә!

Бу хәтлесен көтмәгән иде Зөлхәбирә. Гаҗизләнеп калды, әмма үзен бик тиз кулга алды:

— Бәнем көмәнем бар, мулла,— диде.

Абдулла аны, таза беләкләре белән кысып, күтәреп алды, җилтерәтеп түргә алып чыкты, сабыйны уйнаткандай әйләндерде дә, китереп сәкегә утыртты.

— Менә монысы сүз ичмасам,— диде ул, еш-еш сулап.— Ә сән, кысырык та, караңгы, имеш. Уйлап баксаң, ни бары ярты кыш бит, канатым. Малларны исә Колчура белән Яхъяга тапшырырбыз.

— Яхъяга да сабак тыңлатмакчы буласың бугай ла,— дип иркәләнде хатын.

— Ие, ул яшь, зиһенле малай. Аңа әле укыйсы да укыйсы.

Бергә яши башлауларына өсләренә килгән беренче яшен яшьнәми калды. Хатынының күндәмлеген аның гакыллылыгыннан дип тапты мулла, монысын яхшы фалга санады. Әнә бит, һич кенә өнәмәсә дә, Хәнифә карчык өенә күчүне үзе башлап йөрде, утынын китертте, яктыҗылытты, юды-җыештырды. Кыскасы, әлеге үпкәләшү вакыйгасыннан

соң өченче көн дигәндә, алар инде ятимә карчыкның җир идәнле тавык кетәклеге хәтле генә өендә иделәр. Кысанлыгына да, бердәнбер тәрәзәдәге карындык аша төшкән саран яктылыкка да исләре китмәде. Эчләрен иң нык пошырганы — мичнең морҗасыз булуы, ягъни кара мунча мисалында ягылуы иде. Алай да борчуларын бер-беренә сиздермәделәр.

Абдулланың мәдрәсәгә барырга дип, тунын төймәләп торган чагы иде. Иртәнге тәтен саркып бетмәгән өйнең калҗайган ишеген ачты, эчкә атларга да, атламаска да белми торган старшинаны күреп, зиһене таркалып китте.

— Бак, Яныш абзый, сән түгелме соң? — диде ул, үзен кулга алып.— Уз өйдә, уз!

— Үзең чык, Батырша. Сәнең бу тәмугта тын алырлык түгел икән.

Мулла тире кырыйлы колакчынсыз бүреген башына чәпәде дә, чакырылмаган кунагы каршына атлады.

— Сәне ычкынган дип ишеткәнием — хак икән,— дип каршы алды аны Яныш һәм, минем арттан атла дигәндәй, тышка ук чыгып китте. Читән өйалдында, аның әле генә монда булуын раслап, сасы хәмер исе генә калды. «Сәрхушлыгын ташламаган икән әле бу»,— дип уйлап алды мулла һәм, тупас сүзгә ничегрәк җавап кайтарасын чамалый-чамалый, ишегалдына атлады.

— Мондыен ук диваналыкка житү өчен шул гомер гыйлемлектә йөрү кирәгиеме, өйа, менла Батырша?! — дип һаман да тупаслануында булды старшина, тирә-ягы тулы кеше булуга карамастан.

Хәер, аның үзе сыман ук котырган сыер сөтеннән авыз иткән җан сакчылары Янышның моннан күп гайре гамәлләренә дә күнегеп беткәннәр, түрәнең шәригатькә дә, гореф-гадәткә дә сыешмый торган кыланышларын хуплаудан башканы белмиләр иде. Бу юлы да ат кебек кешнәшеп, хуҗаларының «акыллы» сүзен җөпләп куйдылар.

Абдулланың эчендә кату төшкәндәй ачу оеп, тамагына калыкты, мөгәр сабырлыгын җыйды, тыныч кына әйтеп куйды:

— Ыланнарга мәдрәсә кирәк, Яныш абзый. Шул хакта үзем Чуртанлыкүлгә барырга дип торам әле. Мәдрәсә гыймарәт итәргә бүрәнә кирәк булачак. Юллашмассың микән дигәнием...

— Өйа хәзрәт, дурак, вакыйган, дурак икәнсең! Бетле мишәр вә башкорт малайларына мәдрәсә кайгыртып йөрергә кем дип беләсең сән бәне?!

Түрәнең кызмача чагында, житмәсә исерек егетләре алдында, мәдрәсә хакында сүз кузгатуына үкенеп куйды Абдулла. Авызына шайтан төкергән старшина белән сүз көрәштерү урынсыз иде. Синең бер сүзеңә аңарда унау:

— Безнең өтек халаекларга заман һаман да бер инде ул, Батырша. Ил чакта — буразна, яу чакта — ияр. Әлхасыйл, мәдрәсә дигәнеңне ишетмим бүтән. Имам икәнсең,мәчетеңне бак ана... Ие! Ә бәнем янга килү ниятең — бик мәслихәт ният. Үземнең дә сәне чакырырга дип сугылуым. Килгәләп йөр — әмерләрем бар!..

Ул көннәрдә теләндә сабак сүзләре булса да, башында бүтән нәрсә иде имамның — бүрәнә, ничек тә булса урман бүлемтеге юнәйтү. Үзе шәкертләрнең сабакларын тыңлаган була, күңеленнән исә Уфадагы таныш-белешләрен барлап утыра. Шөкер, ишләре күп калада, араларында дуст диярлекләре дә байтак. Шунысы аяныч, берсе дә зур урында түгел. Менә син өй, моңа хәтле ничек хәтеренә килмәгән диген. Ураков дигән морза бар бит әле дөньяда. Ата-бабасы Казан ягыннан, диләр. Димәк ки, үз кеше. Ничек кинәт яктырган булса, шулай ук тиз караңгыланды йөзе —Ураковның чукынганлыгы исенә төште. Шулай булмыйни, муенына тавык тәпие такмаса, провинсә кәнсәсендә утырыр иде мени?! Йөрер иде шунда Дәүләкәннәр сыман «чабаталы морза» булып.

Икенче көнне ул шәкертләрен иртәрәк таратты. Үзе исә өйлә намазыннан соң юкка чыкты. Аның кая китеп олагуын авыл халкы түгел, остазбикә дә белмәде. Кара бияне юлга әзерләшеп йөргән Яхъя гына остазының ниятен бераз чамалагандай булды.

Морзага булган өмете акланды бит мулланың. Ходаның рәхмәте төшкәндерме, җае шулай ансат килеп чыккандырмы, ай да үтмәде, урман кисәргә рөхсәт язуы Абдулланың кесәсенә килеп керде.

Рөхсәт язуы Карышбаш кешеләрен дәртләндереп җибәрде. Моңа хәтле бернигә ышанмый, мулланы да диванага санап йөргән Ясәви булып Ясәви гел үзгәреп, эшне үзе башлап чабасы итте. Каян ишетеп, каян белеп бетергәннәр, диген, урман эшенә бөтен иләү авыллары купты.

Инде бар да көйләнде, инде иркенләп дәресләр бирергә, тынычлап яшәргә дә була дип йөргәндә, Яныш старшинадан чапкын — өлгә сәрхуш егетләрнең берсе килеп:

— Ыстаршина агай чакыра,— диде.

Старшина аны сәке сыман киң зур өстәл башына утыртты, шул арада ишеген ачып, хатын-кыз таифәсенә кычкырды:

— Кайсыгыз анда? Ит чыгарыгыз!

Күз ачып йомганчы дигәндәй, өстәлгә олы гына агач коштабак белән салкын ит, зур гына ипи түгәрәге һәм бу як халкы өчен бөтенләй ят ризык — тозлы кәбестә килеп утырды. Яныш исә, хатыннар җенесенең чыгып бетүен көтеп, идән уртасында басып торды да өстәл янына килде.

— Афәрин, үз сүзле, хәтта кем кире беткән бәндә икәнсең, Батырша.— Ул өстәлдәге чүлмәк-комганга үрелде, кытай чынаякларына нидер салды да, кунагы каршына утырды.— Тәки бурatасың мәдрәсәңне, ә?! Вәләкин сән ни... вурлар үрчетмә инде ул нәмәстәңдә.

— Мәдрәсә гел инсафлыкка гына үрәтә, Яныш абзый.

— Йә, йә, чәпчемә. Әйдәле, шуның өчен тотып куйыйк бер.

Әллә кайдагы чуашмы, мукшымы авылында ясатып алган бу эчемлекнең әшәке исе баядан бирле борынына кереп, күңелен болгатып тора иде Абдулланың. Үзенә таба сузылган чынаякны кулына алды да, гөберле бака тоткандай чирканып, бер читкә куйды:

— Бигайбә, Җиһанша абзый, бал вә кымыздан башка нәрсәне авызыма алганым юк.

— Алайса байлар сые белән сыйлыйм әле үзеңне,— дип, Яныш урыныннан кузгалды һәм хатын-кыз таифәсенә эндәште.— Әй, чәй бирегез!

Чәйне Мөслим старшинада эчкәләде Абдулла. Бак, Янышка да килеп җиткән. Ярый соң, аны бик тансыклаган иде мулла.

Старшина өен тутырып шаркылдап көлеп җибәрде:

— Бу доньяда яши белсәң, бар да булыр, Батырша. Чамаң да, нәфесең дә... Сән әле иблис токымыннан авыз итмәгәнгә охшыйсың. Уразаң бер ачылсамы?! Әле кичә Ядәч авылында... Чатырыма бер хур кызы китерделәр егетләрем. Чибәр чукынган — бер кашык суга сал да йот үзен. Вәләкин артыгын яшь, ун-унике тирәсендә булыр. Кызгандым бит, дурак, кайтарып җибәрдем. Тәңгә анасын алып килергә куштым...

— Йә, ярый, шаярдык,— дигән булды ул, салганын эчеп куйгач.— Тәк, нидә туктадык соң әле? Ә, ие, Мостафа хәзрәт белән тату яшәдек без. Авыр туфрагы җиңел булсын, сүземнән һич чыкмады, мәрхүм хөкемнәрен бән әйткәнчә ясый иде.

Сүзнең болай кисәк һәм көтелмәгән якка борылып китүе Абдулланы аптыраштa калдырды. Ул, чынаягындагы чәйне эчеп бетерде дә, старшинаның күзенә чекрәеп карады:

— Хөкем бит ул, Яныш абзый, кемдер кушканча чыгарылмый,— диде, балаларча беркатлылык белән.— Хөкем китапча гына була, шәригатьчә.

Яныш тагы көлеп җибәрде:

— Сән гел бала-чага икәнсең, Батырша,— диде ул, күз төбенә килгән яшен җиңе белән сөртеп.

Абдулла сискәнеп китте, уйчанланып калды. Әллә инде борчаклары пешмәсен төшенде, әллә исерүе җитте, старшина, чайкала төшеп, урыныннан кузгалды, ишеккә килде һәм үкереп җибәрде:

— Әй, кайсыгыз?! Муллага урын салырга кирәк.

Моны ишеткәч, Абдулла кабаланып аягына басты, ишек катындагы чөй янына килеп, киемнәренә үрелде:

— Юк, бән кайтам, Яныш абзый!— диде ул, тунын кия-кия.— Хуш, сау булып тор!

Ничек чыккандыр да, ничек этләр тимәгәндер аңа? Абдулла аларын хәтерләми. Чуртанлыкүлне атлый-йөгерә чыгып, кар көртендә чокыраеп торган кышкы юлга баскач кына, тукталды, иркенләп тын алды. Сән, шәрәфәтле падишаһ, ничекләр түзеп торасың биредәге түрәләрнең башбаштаклыгына?!

* * *

Һиҗринең 1163 елдагы (1750 ел) язы Карышбаш имам-мөдәррисе гаиләсенә берьюлы ике шатлык алып килде. Дәреслә төмамланып, шәкертләр авылларына таралдылар — Абдулла белән Зөлхәбирә дә, ниһаять, үз нигезләренә кайттылар. Кар эреп, җир кипшенүгә, авылда моңа хәтле һич күренгәне булмаган олы өмә узды: су буен тутырып, төрле якка таралып яткан мәдрәсә бурасы таш нигезгә күтәрелде, түбәсе дранча белән ябылды. Инде бераз тын алып, гаиләнең үз мәнфәгатен кайгырту җае чыкты.

Кая ул?! Җәй башы мәшәкатьләрнең тагы да зурракларын, катлаулыракларын өстәп куйды. Ишек-тәрәзә яңаклары, рамнар ясатасы бар. Такталар да идән-түбәгә җитешле түгел. Мичләрне дә җәйдән чыгартасы иде. Кирпече сукмаган. Пыяла табу — үзе олы хәсрәт.

Күрше авылларда юлы уңмагач, ул арырак төбәкләргә, әллә кайлардагы волостьларга барып чыга торган булды. Теләсә кем катына түгел, билгеле. Халык арасында яхшы исеме чыккан, үзе ишетеп кенә булса да белгән мәрхәмәтле, мәрәвәтле адәмнәр янына инде. Шундыйларның берсе — Уса юлындагы мишәр камандасының старшинасы Сөләйман Диваев иде.

Кулына балта тотып ишегалдында нидер майтарып йөргән Сөләйман аны үзе каршы алды. Старшина инде тәмам чаларган, чын мәгънәсендә аксакал булып җиткән. Алай да йөреш-хәрәкәтләре җиңел, җиргә нык баса. Кыяфәтенә карап кына сигезенче дистәне куучы карт димәссең.

— Әссәләмегаләйкем, старшина,— диде Абдулла, күрешергә ике кулын да сузып, камандада моннан ике ел элек булып узган хәлләргә ишарәләп, өстәп куйды:— Ил-җирдә иминлекме?

Ихатасына килеп керүченең кем икәнен белмәсә дә, Сөләйманның йөзенә дустанә елмаю чыкты, балтасын җиргә ташлап, сәламне алды. Аннан инде кыюсыз гына сорап куйды:

— Танып бетермим, кем диеп беләек?

— Карышбаштан Гали углы Абдулламын.

Карт кисәк кабынып китте, кулларын җәеп җибәрде:

— Әйа, Батырша хәзрәт! Беләм, беләм. Бик күп ишеттем синең хакта. Кая, атыңны кертик әле.

Алар юынып, ак өйгә узган арада күз бәйләнде. Хатын-кыз тайфәсе, өнсез шәүлә булып кына, киҗеле ашъяулык җәелгән өстәлгә ялгыз шәм яндыган шәмдәл кертеп куйды, шулай ук тавыш-тынсыз гына табын әзерләде.

Абдулланың күзе исә — өйнең караңгы як стенасы буйлап сузылган киштәләрдә. Түзмәде, рөхсәт-фәлән сорамый гына килеп, зәвык белән тышланган калын китапларның берсен кулына алды. Бу исә Абдуллага йомышын әйтеп бирү өчен бер дигән җай иде. Ул Карышбашта мәдрәсә гыймарәт итү хәлләрен сөйләп бирде.

— Синең катка килү дә, Сөләйман абзый, шул хактае: өч-дүрт булса да оста табып бирмәссең микән дигәнием.

— Ашыкма, Батыршаһ. Икене-өчне генә кунасың әле, насыйп итсә. Әйдә, табынга утыр әле!

Алар китаплар белән әвәрә килгән арада, табын әзерләп өлгергәннәр икән. Бераз капкалап алуга, хуҗа сүзнең очын үз кулына алды:

— Саф мөселманнарның бер-беренә ярдәме — саваплы эш инде ул, Батыршаһ,— дип башлады Сөләйман, маңгаен сөлге белән сөртеп.— Кулдан килгәнен булышырбыз, боерган булса. Вәләкин эш бит... Ие... Яныш барыбер кадерен белмәс аның.

— Түрәләр бар да бер чыбыктан куылганнардыр инде алар.

— Әйа, юк, хәзрәт! — Сөләйман кашыгын куеп, кызып ук китте.— Һәр җан иясе үзенә бер дөнья ул... Әйтик, бән Уфа кәнсәсенә дә, губернаторга да — әлхасыйл, үземнән өстен бөтен түрәләргә вирный хезмәт итәм. Берүк вакытта камандамдагы халаекларга да зыян-зәхмәт салмаем, алым алмаем, үз эшемне кешедән эшләтмәем. Мәсләгем — бүре дә тук, сарык та исән булсын.

— Афәрин, Сөләйман абзый, афәрин!

— Кайбер иләү агалары алай итми инде,— дип ярсуында булды старшина, гүя кунагының сүзен ишетмәде дә.— Салым-алымнарны халаеклардан тияреннән артыграк җыеп, байтагын үзләренә чөлдереп калалар. Алым алу хакына кайсыбер бәндәләрне чирү хезмәтеннән коткарып, алар урынына башкаларын озаталар. Һай, намусыңны жуйсаң, баю юллары күп инде ул, хәзрәт! Әйтик, шул ук Яныш... ул кадерең белмәс синең. Әдә, үземә күчеп кил! Бер җәйдә мәдрәсә салып бирәм, үзеңә өй җиткерәм.

— Булмас, Сөләйман абзый. Алай итсәм, авылдашлар күзенә ничек карармын?! Башлаган эшем кала лабаса...

— Хак әйтәсең, хәзрәт. Эшне ярты юлда ташлау егетлек түгел— дип килеште старшина.— Ярый сүземне кире алам. Шәп кенә бер шәкертеңне җибәрерсең, боерган булса.

— Анысың эшлибез, Сөләйман абзый. Яхъя атлы бик тә зиһенле шәкертем бар. Шуны бирермен Әҗиккә.

Серләре килеште, ястү намазыннан соң да озак гәпләштеләр. Мәгәр хуҗа кәтелмәгән кунагыннан һич ялыкмады. Мунчалар яктырып, зур сый мәҗлесе җыеп ике тәүлек миһман итте ул Абдулланы. Тәмам дуслашып, өченче көнне генә хушлаштылар.

Тагы ике көннән Карышбашка килеп төшкән балта осталары шул дуслыкның ныклыгы билгесе иде.

Уттай кызу көннәрнең берендә, Абдулла мәдрәсә ишеге төбендә кирпеч бушаттырып торганда, яннарына, атын кара тиргә батырып, Яхъя килеп чыкты. Күк биясен туктатып өлгермәде, шәрран ярып кычкырып җибәрде:

— Мулла абзый! Остазбикә ни... анда.

Шунда ук төшенде Абдулла. Парлап чаптырып киттеләр.

Алар яңа басудагы арыш җиренә килеп җиткәндә, Зөлхәбирә белән Колчура саз буендагы зирек күләгәсендә тын гына утыралар иде. Хатынының йөзе тартылып, агарып киткән, итәгендә — ниткәндер чүпрәккә төрелгән җанлы йомгак. Зөлхәбирә дәшмәде, хәленнән кыенсынып, башын аска иде. Аның өчен җавапны Колчура бирде:

— Баланың кендеген кискән, бәйләгән. Угыл! — диде.

— Хәерле булсын! Атын Таҗик дип куярбыз.— Абдулла күптәнге карарын тышка сыгып чыгарды.

Карышбашта яңа мәдрәсә ачылу хакындагы хәбәр Агыйдел, Караидел буйларына гына сыешмыйча, бөтен Оренбург далаларына, Казан якларына, хәтта Урал аръягына барып ирешкән. Көз җитүгә, Карышбашка мишәр, типтәр вә башкорт малайлары килеп тулды. Алар арасында провинциянең дүрт юлыннан гына түгел, һич уйламаган җирләрдән — хәтта Көнгер, Казан, Тубыл якларыннан килүчеләр дә шактый иде. Шәкертләрнең күплеге бер яктан зур куаныч булса, икенче яктан дәмеллага зур мәшәкать. Ул инде үзе генә сабак биреп өлгерә алмый, ярдәмгә хәлфәләр табасы бар.

Никадәр генә чыгымлы, мәшәкатьле булмасын, Карышбашта мәдрәсә ихъя ителүе, мулланың дәмелла булып китүе, Абдулланың үзе өчен генә түгел, камандадагы бар халаекларга шатлык вә горурлык иде. Бу хәлгә сөенмәүче бер генә бәндә бар иде монда. Батыршаның дәмелла буларак та, мөдәррис буларак та танылуы, даны-шөһрәтенең бөтен иләүләргә таралуы ифрат көнчел старшинаның кытыгына тиде. Хәзер куркыту-янау белән генә берни майтара алмыйсың монда. Халаеклар арасында дәрәҗәсе ифрат зур муллага кизәнгән йодрыкның үз башыңа төшүе мөмкин. Алдырсаң, хәйлә вә әтлек белән генә алдырырга була.

Үзе биниһая гадәләтле Абдулланың исә башында кемнән дә булса үч-ачу алу, кинә куу кебек исәп бөтенләй юк иде. Дәмелла, бөтен дөньясын онытып, мөдәррислек шөгыленә чумды. Тышта инде төмам кыш булып, барча җирнең ак япан ябынуын да сизмәгәндәй булды.

Шул рәвешле бар да эзгә төшеп, дәресләр җай гына барган салкын көннәрнең берендә мәдрәсә ишеге төбендә ниндидер тавыш, ыгы-зыгы купты, эт өргән авазлар ишетелде. Абдулланың Бөек Болгар, анда гыймарәт ителгән зур-зур сарай-тирмәләр, мәдрәсә-китапханәләр турында, Идел буендагы шул борынгы дәүләттә ерак бабаларыбызның хөррә улуы хакында сөйләп торган чагы иде. Сүзен яртысында өзеп, тышка колак салды. Мәгәр ни дә булса кылырга өлгермәде, дәресханәнең зур ишеге ачылып китте, бусагада өстенә төлке тун, башына сусар бүрек кигән Яныш күренде.

— Әйа мулла, белдек! Син монда бу бетлеләргә шайтан сабагы тыңлатып ятасың икән,— диде ул, үтә дорфа кычкырып, һәм, сүзенең хаклыгын раслагандай, кулына бөкләп тоткан камчысын болгап алды.— Мәдрәсәне без пәйгамбәр сүзләрен тыңлау өчен ихъя кылдык, дип беләм.

Абдулла аның гадәттән тыш кызмача икәнен абайлап алса да, ярсып китмәде, тыныч калды. Старшинаның каршына килеп, әйтәсен басынкы гына әйтте:

— Әй, ыстаршина, монда дәресләр бара. Сүзең булса, хәлфәләрнең ял бүлмәсенә рәхим итең!

Шулай диде дә үзе аралыкка чыкты, аптырашта калган Яныш исә аның артыннан атлады. Аллы-артлы аулак бүлмәгә барып керделәр. Карыш як диварда дәмелланың үз куллары белән зур бозау тиресенә ясап куйган хариталы (картаны) күргәч, йортавайның күзләре акаеп чыкты:

— Әйттем бит, шайтан сабагы диеп! Малай-шалайларны юкка котыртырга ничек оялмыйсың, мелла?!

— Оланнарга гыйлем бирүнең ояты юк, Яныш агай.— Абдулла әле тыштан һаман тыныч күренсә дә, эчендә инде ризасызлык куерып, ачулы сүзләре тамагына килеп боялгән иде. Чыдамады, күңелендә сакланырга тиешлесе авызыннан ычкынды.— Әйтсәм әйтим инде, ыстаршина: мөселман кешегә, түрәгә исә бигрәк тә, һаман саен сәрхуш-

ләнеп, халаекларга күренеп йөрү — рисвайлык ул! Җитмәсә, таң чыгыдай саф күңелле шәкертләр катына килеп керәсең.

— Бән? Бәнме сәрхуш?! — дип җикереп җибәрде Яныш, тар бүлмәне тутырып әрле-бирле йөри-йөри. — Авызыңны чамалап ач, мелла! Шул маңкалар алдында бәнем абруемны төшермәкчеме сән, йә?!

Муллага сабырлыгын саклавы кыен иде. Алай да кызып китмәде, мәгәр тавышы ныгыды, анда тимер чыңы яңгырап киткәндәй булды:

— Бән сәнең абруеңа кагылмаем, ыстаршина. Вәләкин болаен йөреп... Туктар карьясыннан халаеклар шикаять белән килделәр вана. Биктимер атлы бәндәнең җәмаллы катынын куркытып, зинага күндермәк булгансың. Ире вә туганнары катынны сәнең кулдан йолып алгач, аларны камчы белән суктыргансың.

Абдулла түзмәде, җәнҗал ишетелми микән дип, ишекне ачты, аралыкка карады. Янәшәдәге дәресханә ишеге ярыгындагы дүрт-биш баш шунда ук юкка чыкты. Дәмелла, чыраена аны-моны чыгармыйгына, дәресханәгә узды, шәкертләрне мәдрәсәдән чыгарып җибәрде дә янә хәлфәләр бүлмәсенә әйләнеп кайтты. Ул килеп кергәндә Яныш, тәрәзәдән тышка карап, нидер уйланып тора иде. Дәресханәдән урап килү бик вакытлы булды — Абдулла шактый суынып, сүзне салкын акыл белән дәвам итәр хәлгә килгән иде. Шулай да тавышында кырыслык дәмелланың:

— Сән куркытма, ыстаршина! — диде ул, ныклы итеп. — Бәнем шүрләрлек эшем, гөнаһым юк. Инде белү-белмәүгә килгәндә, әйтәем: халаеклар бөтен аh-зарлары белән бәңа киләләр. Янә дә килеп, авызым бер ачылганда, шунысын да әйтәем: алым алуыңны туктат сән, ыстаршина!.. Күгәрчен карьясыннан Исмайны өченче ел, нәүбәте җитмәгән килеш, чирү хезмәтенә язгансың. Ике сум акча биргәч кенә, аның урынына башканы олактыргансың. Нәүбәтләре җитмәенчә пахутка язылып, алым бирмәк исәбенә торып калучылар бер Исмәгыйль генә түгел бит, Яныш агай. Андыйлар карья саен вә күпләр...

Абдулла җае чыккан саен, ләкин үзләре икәүдән-икәү генә булганда, Янышның бөтен әшәкелекләрен чыраена бәреп әйтү, аны оялту, вәгазьләү белән тугры юлга түндерергә ниятли. Мәгәр эшне зурга җибәрү, губернага шикаять язу юк аның уенда.

Хәер, Яныш та аны бөтәнчәләй борчымады. Әллә тәүфикъка килде, әллә кара эшләрен майтаруның башка юлларын тапты — ничек кенә булмасын, үзе дә килеп чыкмады, чакыртып та йөдәтмәде. Абдуллага исә шул гына кирәк тә. Ул башы-аягы белән мәгърифәт вә гыйлем дөньясына чумды, мәхәллә эшләре белән мавыкты — гаилә коручы яшьләргә никах укыды, яңа туган сабыйларга ат куйды, бу фани дөньядан киткәннәргә ясин укып, аларны дәфен кылды.

Кояш язга авышкан шундый көннәрнең берендә, Абдулла инде бүгенге дәресләрен бетереп, өенә кайтырга дип торганда, мәдрәсәгә башында Яхъя торган бер төркем шәкерт килеп керде. Дәмелла беравык тын торды, аннан инде Яхъяга карап:

— Ни хәл вә ни хәбәр? — диде.

— Бүген дә ашап киткәннәр, — диде Яхъя, күптәнге сүзен дәвам иткәндәй.

— Барыбызны да ач калдыралар болай булса, — дип аның сүзен күтәреп алды икенчесе — Казан өязеннән үк килеп укучы колга буйлы Исмәгыйль Алкин.

Дилбегәнең очын Кәнгер өязе татары — бүлтерек Дәүләтбай Кәҗәголыв үз кулына алды:

— Һаман да шул Яныш старшина этләре инде, мулла абзый. Кәтүләре белән киләләр дә, бөтен чоланны айкап ташлыйлар.

— Бәнем елкы итен ялмап йотканнар, — дип еламсырап зарланды башкорт Чурагол.

Анысының сүзен дәррәү күтәреп алдылар:

— Бөнем каз түшкәсеннән җиләр искән!

— Бөнем ак май тутәрәмен...

Ниһаять, мәсьәлә ачыкланды — сүз Яныш этләренең мәдрәсә чоланына чираттагы һөҗүмнәре турында бара икән.

— Карап-карап торам да, аптырыйм бән сезгә,— дип башлады Абдулла, салмак кына.— Үгез тик егетләр үзегез, вәләкин зарланышып йөрүдән бушамыйсыз. Таяктыр, камчыдыр алып, ярып җибәрегез үзләрен — бөтәнчәләй килмәслек итеп.

Әйтәсен әйтте дә өенә ашыкты дәмелла. Хәләл җефете Зөлхәбирәнең икенче балага авыраеп йөргән көннәре. Бикәче янына кайтмаенча эт куып йөрсенме инде, әә?!

Ул инде әлеге сөйләшүне дә, Яныш этләрен дә оныткан иде. Мәгәр этләр мәрәкәсе тынмаган икән әле. Ике-өч көн үтте микән, мәдрәсәгә, хәтта дәресханәгә үк, бер өер егетләре белән старшина килеп керде. Яныш гадәттәгедән дә кызмачарак һәм кызылрак иде. Ишектән керәкерешкә дәресханәне ярып кычкырып җибәрде:

— Әйа мулла! Сән бунда юлбасарлар симертеп ятасың икән!

Бу хәлгә ни дияргә белмичә, бер мәл аптырап торды Абдулла. Янышны хәлфәләр бүлмәсенә чакырырга, шунда аңлашырга дип, авызын ачкан иде, старшина аңардан өлгерерәк булып чыкты:

— Башкисәрләрең бөнем иң яхшы, иң акыллы этемне — Дүрткүземне харап иткәннәр. Өстенә кайнар су сибеп. Тәүлек буе шыңшып ятты да җан тәслим кылды бахыр. Кем буны эшләсә, шул алга чыксын!

Дәресханәдә мазар тынлыгы урнашты, берәү дә утырган урыныннан кузгалмады. Шәкертләр башларын игәннәр дә тын калганнар. Аларның хәлен аңлый иде мөдәррис:

— Этләрең шәкертләрнең ризыкларын ашап йөдәтәләр, Яныш агай. Өсләренә кайнар су коегыз дип бән куштым,— диде.

Дәресханә «аһ» итеп куйды. Шәкертләрнең җәзадан котылуларына куанулары идеме бу, мөдәррисләренең кыюлыгына сокланулары идеме — белмәссең. Янышның күзләре акаеп чыкты, сигезәрләп үргән каеш камчы тоткан кулы өскә күтәрелде:

— Һа! Төп башкисәр үзең икәнсең алайса. Ярый, калганын башка җирдә сүләшербез!

Сүзенең җитдилеген белдергәндәй, камчысы белән кизәнде дә, кисәк борылып, чыгып китте старшина. Өере, шау-гөр итеп, аның артыннан ташланды.

Тагын ике көннән дәмелланың өенә иртә таңнан мылтыклы ике гун килеп керде. Алар кичә үк килеп, старшинада кунганнар, тән ката сыйланганнар бугай, күзләре-башлары тонган, үзләрен гаять дорфа тоталар. Абдулланы акырып-җикереп киендерделәр дә, өеннән алып чыгып киттеләр. Корсагы борынына җиткән Зөлхәбирә, бәләкәй Таҗикны кочаклаган хәлдә, кычкырып елап калды.

Аны провинция канцеляриясе астындагы төрмәгә аерым камерага кертеп яптылар да, гүя оныттылар.

Мондый шартларда кешегә бер иптәш кала — уй, аны бер шөгыль юандыра — уйлану. Абдулла да туктаусыз баш ватты. Ләкин фикерләве эзлекле булмыйча, чуалчык бер саташу сыман иде. Әлбәттә инде, күбрәк үзенең билгесез язмышы хакында уй йөртте. Шул уңайдан, билгеле, мәкерле вә кара эчле Янышны да искә алмый калмады. Менә-менә дип, бәби көткән Зөлхәбирәсе күз алдына килгәч исә, үзе дә, бурлат чырайлы Яныш та каядыр чигенеп, юкка чыктылар. Ярым караңгы бүлмәдә чарасыз вә ярдәмчесез Зөлхәбирә генә торып калды.

Шул рәвешле ярым уйланып, ярым төшләнеп ята торгач, ярты ай чамасы вакыт үтеп тә китте. Беркөнне иртәнгә якта күзен ачса, гаҗәеп бер нәрсәгә игътибар итте Абдулла — камера ниткәндер бер сасы ис белән тулган. Ул аны башта инде унбиш көннәр мунча күрмәгән тәненнән килә дип уйлады. Аннан инде теге аш дип атала торган юынтык су

исенә нисбәтләде. Соңрак исә үзенең беркатлылыгыннан көлеп үк җибәрде — ишек катындагы агач чиләктән килә торган бәдрәф исе ләбаса бу!

Алай да тагы берничә көннән соң үзенең нык ялгышканын төшенде Абдулла. Юк, әлеге күңел болгаткыч ис... үзенә бер аерым ис — хибесханә исе! Аңардан өметсезлек, чарасызлык, курку вә өркү, сагыш, кайгы-хәсрәт, коллык аңкый!

Хибесханәнең тар аралыгыннан сирәк-мирәк узгалаучы тоткыннарга ишектәге бәләкәй тишектән карап-карап торгалады Абдулла. Бак, вакыйган, үзгәрә икән монда бәндә дигәнең. Чырайлары мәетнеке сыман, йөрешләре мескен, атлаулары ләштер-ләштер. Алар үтәдән-үтә кабахәт хибесханә исенә манчылган, шуңа исереп, кешелекләрен дә җуйганнар бугай.

Вә әй хәсрәт, үзе дә шул көнгә калырмы? Әйа, нигә дип сорап торырга, ул бит инде күптән башка кеше. Тетрәнеп куйды Абдулла. Мәгәр аннан соңгы фикере тагын да аянычлырак иде.

Моңа хәтле халаекларның иркен, асабалыгын таптап-изүче явыз Каракошны Петербург, Мәскәү вә Казан якларыннан гына килә дип фикер йөрткән Абдулланың зиһенендә дә бөтенләй бүтән фикер пәйда булды. Мәгърипта яралып, шуннан чыкса да, бу якларга килә-килә ныгый гына бара икән ул Каракош. Ераккарак очкан саен канатлары талып зәгыйфьләнми, яңадан-яңа каурыйлар исәбенә куәтләнә бара икән ләбаса! Әлеге каурыйлар исә урыслар арасында гына түгел, һәр халаекта бар икән бит. Мәртәт морза Тәфтиләү дә, берсеннән-берсе комсыз Яныш кебек старшиналар да, эреле-ваклы башка төрәләр дә явыз Каракошның канатын ныгытучы каурыйлар икән ләбаса. Әнә шул каурыйларны йолыкмый, яндырып юк итми — Каракошны хәлсезләндереп екмый торып, халаекларга ирек тә, җир дә, асабалык та булмаячак! Ә аңа ирешүнең юлы бер генә — көрәш вә көрәш! Үзең соң көрәшеп карадыңмы әле, Батыршаһ?.

Тагын ярты айдан аны төрмә конторасына чакырып алдылар да, аны-моны сөйләми, берни аңлатмыйча, өенә кайтарып җибәрделәр. Бәхете бар икән, Уфаны чыгуга, артынннга атлы юлаучы куып җитте. Абдулла аны уздырып җибәрү нияте белән, юл читенә чыкты. Атлы исә чаптырып үтеп китәргә уйламады да, аның турына җитүгә, атын туктатты һәм куанычлы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Әйа хәзрәт, бән вит сәне эзлим. «Батыршаһны алмый кайтма»,— дип җибәрделәр Карышбашлар. Утырың әле, утырың!

Абдулла гаҗәпсенеп арбага күз салды. Кулына дилбегә тотып олау түренә утырган сәләмә бәндә — авызы колагына җиткән Колчура иде.

Сүзнең калганы инде яңа төшкән язгы юлда дыңгырдап барган арбада дәвам итте. Абдулла кулга алыну белән, Карышбашлар гына түгел, бөтен тирә-яктагы карьяларда бар халык кубып, гадәләтле мулланы коткару өчен тамга җыйганнар икән. Әмма Яныш Уфага барырга, эш йөртергә ашыкмаган. Җыелган тамгаларның тик ятуын белеп алган кешеләр, кулларына чукмарлар вә гөрзиләр тотып, старшинаның өен камап алганнар. Яныш юашланып калган, тавышы да мескен генә икән.

— Тимәгез, җәмәгать, яндырмагыз,— ди икән явыз.— Зинһар, таралыгыз. Хәзер үк Уфага китәм, Батырша мулланы коткармый торып кайтмыйм.

Колчураның көлә-көлә кызык итеп сөйләгән сүзләре Абдулланы әллә нишләтеп җибәрде. Ишеткәннәре үзенең төрмәдә уйлаганнарына төңгәл ләбаса! Явыз Каракошның каурыйларын да, үзен дә көч-куәт белән генә юк итәргә мөмкин икән бит. Димәк, башка юл юк, димәк, алда — көрәш! Әйе, әйе, мәсләк ачык. Бүгеннән Абдулла дигән бәндә юк дөньяда, күкрәге үч тулы Батырша гына бар!

## Беренче бүлек

Кара көзнең гаҗәеп бер мизгеле — беренче күренгән кырпак кар җил тарафыннан чокыр-әрәмәләргә куылып, басулар ала-кола булып калгангамы «Ала бия» дип аталган вакыт җитүгә, чамасыз зур губернаның бихисап юллары арбалар дөбердәгән, атлар пошкырышкан тавышларга күмелеп кала.

Агайларның Оренбур ягына тозга дип кузгалулары. Кырык-илле олау, көзге төн юлда дөбердәп-шатырдап ике авыл арасын үтүгә, аларга тагын шул хәтле үк күршеләре кушыла. Бераздан инде кәрванга күршеләрнең күршеләре, аннан инде аларның күршеләре иярә. Берзаман кәрван шулкадәр зурая ки, аның инде башы Киезледә булса, койрыгы — Биятледә.

Арбаларның саллы дөңгердәвенә һәм атларның киерелеп тартуларына караганда, олаулар буш түгел. Шулай инде, Оренбур хәтле Оренбур ягына кузгалгач, акыллы баш юлга буш чыкмас. Агыйдел һәм Ык, Минзәлә һәм Зәй буйларында яшәүче татарлар — гомерлек игенчеләр торыпшага төреп саллы арыш-арпа, гәрәбәдәй тары төягән булсалар, Урал буе чагылларыннан, урман араларыннан купкан башкортларның олауларында батман-батман бал, кибеп каткан җәнлек тиреләре. Бөтен далага «Яман кала» дип аты чыккан Оренбургка ничек итеп буш кул белән барасың?!

Олауда барын сатып, бераз акча да төшерсәң, тормыш тагы да түгәрәкләнәчәк. Аннан килеп, буш арбада шалтырап янә алтмыш дүрт чактым җир үтәсе, мәшһүр Илек күленә җитәсе, күршең белән бергәләп Тозтүбә тавыннан тоз чыгарасы һәм, аны төяп, туган төягәнә кайтып егыласы гына кала. Гаиләңә дә, мал-туарыңа да ел әйләнәсенә җитәрлек тозың бар дигән сүз. Шунысы куанычлы, аның өчен акча түлисе дә, тире саласы да юк, ходай биргән күлләрдән сосып, яисә таудан ватып кына аласы. Мондыен бушка килгән табышка сөенми ничек чыдыйсың, ди. Шул рәвешле һәркайсының йөрәгендә пытпылдап барган шатлыксөенеч, эчләренә генә сыеша алмый, җыр булып тышка бәреп чыга:

> Сандугач сайрый бакчада,
> Гөл бакчасы сәйран дип.
> Без юллардан җырлап узсак,
> Кызлар чыга бәйрәм дип.

* * *

Офыктан-офыкка җәйрәп яткан киң дала уртасындагы шушы каланың беренче ташын үз куллары белән салган көннән соң узган ун ел гомер эчендә көндәлек хаҗәткә әйләнгән гадәте буенча, Неплюев бүген дә, йөреп кайтырга дип, иртә таңнан кузгалды. Авыл вә җәйләү мокытларын гына түгел, Мәскәү һәм Петербург кебек пайтәхетләрдән килгән кунакларның да игътибарын җәлеп итәрлек чиркәүләр, зиннәтле пулатлар янында үтте дә, туплары крепость дивары буйлап тезелгән, таш түшәлгән мәйданга таба китте. Әле июль аенда гына алтмышын тутырган Иван Ивановичны кальгадагы офицерлар үзе югында «картлач» дип йөртсәләр дә, ул әле гәүдәсендә бернинди авырлык сизми, сызланусыкрану дигәнне белми — хәрәкәтләре җиңел. Чөнки, яшьтән гадәт итеп алуынча, ашау-эчүгә комсыз түгел, олуг түрә булуына карамастан, эш дигәнне тулы куәтенә тарта. Шәһәр эчендә йөргәндә җәяү атлауны

мәгъкуль саный. Әнә шулар аңа сакланырга ярдәм иттеләр дә бугай. Ул, шөкер, урынбасары Тәвкилев кебек тулып ташымады, гәүдәгә һәрчак җыйнак губернатор.

Дөрес, берара — янындагы якыны — кызы Анна кияүгә чыккач, ялгызлыктан сагышланып, күңеле төшеп алган иде алуын. Шөкер, былтырдан бирле котылды шул эзәрлекләүдән. Узган ел Петербургтагы төпчеге Николай күчеп килде. Үзе генә дә түгел, татарларның тутырган тавыгы сыман хатыны Татьяна Федоровна һәм туп кебек улы Коля белән. Әйе, Николай инде теге чакта кадетлар корпусында укып калган шүре төсле малай түгел, мәһабәт гәүдәле полковник. Неплюевның мәшәкать тулы тормышында бик тә ярап куйды Николай: губернаторның кулы җитешмәгән төбәкләргә барды, өлгермәгән эшләрен эшләде.

Крепость диварлары эргәсендәге таш түшәлгән мәйданга килеп кергәч, Иван Иванович адымнарын салмаклатты. Дивар буендагы тупларны барлап чыкты. Әҗәл чәчүче бу машиналар, өнсез булсалар да, һәрвакыттагыча дала түренә дәһшәтле төбәлгәннәр иде. Губернатор белә: алар төзек, әмма әлегә кирәкләре чыкканы юк диярлек аларның. Моннан уникe ел элек Оренбурда чиркәү ачкан көнне һәм теге чакны кыргыз-кайсакларның Кече йөзе ханы Нуралине каршылаганнан бирле атканнары юк. Гөрселдәмәсеннәр дә! Далага тыныч юл белән үтеп керергә, коры кул белән барып җитәргә кирәк. Юк, юк, коры кул белән түгел, товарларының авырлыгыннан сыгылып торган дөя кәрваннары белән узарга кирәк Шәрыкка. Шулай иткәндә генә кире кайтканда да йөк тулы булыр, Россия империясенә игелек китерелер. Шөкер, монысы инде хыял гына түгел хәзер. Оренбурда татарлар оештырган сәүдә кәрваннары Бохарага, Хива һәм Ташкентка, хәтта аннан да ераккларга баралар һәм шәрык ефәкләре, тәм-томнар, тагы әллә нәрсәләр төяп кире кайталар. Әйе, сәүдә дигәнең киңәйгәннән-киңәя бу якларда. Былтыр Оренбурда беренче кат үткәрелгән олы ярминкә шуның тантанасы лабаса.

Бүген инде сәүдә бер Оренбур белән генә дә чикләнми. Хәтерендә, әле 1743 елда ук Неплюев, Себер белән танышып, булачак губерна үзәгенә кайтып килгәндә, Уй елгасының уң як ярында, аңа Әвәлкә суы кушылган урында ял итәргә тукталган иде. Бакса, изге Троица көне икән. Бу вакыйганы билгеләп үтми ничек калдырасың, ди. Иван Иванович үзе һәм яраннары туктап хәл алган җиргә крепость салырга һәм аны Троицк дип атарга боерды. Һәй ул, әйтергә кирәк, соңрак калкып та чыкты. Тагы биш ел үткәч, ям атлары Троицкига кадәр йөри башлады. Татарлар өлгер халык — анда да барып җиттеләр — ерак далада тагын бер сәүдә үзәге барлыкка килде. Шунысы әйбәт, анда аулаграк, рәхәтләнеп адәм балалары сатарга була.

Мәгәр бу хәтлесе хыял-омтылышларның башы гына. Далада эш җитәрлек әле. Казакъ йөзләренең баш биреп бетергәннәре юк. Урта йөзнекеләр, әнә, әледән-әле Иртешне кичеп, бу яктагы көтүлекләргә чыгып йөдәтәләр. Хәл канлы бәрелешләргә барып җитә.

Уй-хыяллар дигәннән, шөкер, алар акрынлап булса да тормышка аша бара. Әнә, Бөгелмә һәм Казан аша салынган Яңа Мәскәү юлы әйбәт кенә булып чыкты. Югыйсә, Самара аркылы йөри торганы, ягъни Иске юл шактый хәвефле һәм куркынычлы иде — калмыклар тынгы бирмәде. Яңа юлда исә, шөкер, иминлек.

Анысы үзенең хаҗәте булмаса, төкерде ди сиңа үзәк. Хаҗәте бар шул, хаҗәте. Нигә дисәң, дала инде элеккечә кыргый түгел. Неплюев Оренбургка наместник булып килгәннән бирле генә дә, губернада унөч тимер кою заводы, унбиш бакыр эретү заводы салынды һәм худка җибәрелде, яңа кала һәм поселоклар барлыкка килде. Җиде домна, унөч домна асты, унбер чиркәү төзелде. Һай, ул гынамы, пыяла, аракы, шпат заводлары эшли башлады, фарфор өчен ак балчык, алебастр, нефть, кварц, күкерт чыгару җайга салынды. Барыннан битәр, халаек-

лары мал караудан башканы белмәгән якларда иген игелә — Оренбурның үз ипие бар хәзер. Башкарылган эшнең кайсын гына алма, алар барысы да аның тырышлыгы, аның кайгыртучанлыгы нәтиҗәсендә тормышка аштылар бит. Алай да Неплюевның күңеле тынычланмый әле. Губернаның казна хәле мактанырлык түгел...

Ул шундый уйларга чумып, дала уртасындагы таш балбал сыман басып торганда, аста — крепостьның таш диварлары артында нидер дөбердәде. Неплюев шикләнеп, сагышлы карашын шунда төбәде һәм кала капкасыннан чыгып, Җаек кичүенә таба төшеп баручы бихисап атлы арбаларны күреп алды. Губернатор ихтыярсыздан капкага таба борылды — аннан бүселеп чыгып килүче олауларның очы-кырые күренми иде. Оренбур базарында бушап калган крестьян арбалары, иләмсез дөбердәп, далага таба агылалар, крестьяннар Илек күленә, тозга китте.

Неплюевның олауларны саныйсы килеп, күңеле кытыкланып куйды. Чыннан да, ничә меңгә җыела икән? Юк, ялгызың гына ерып чыгышлы эш түгел бу — иртә таңнан тотынып, кичке эңгергә кадәр Тозтүбәгә агылачаклар алар. Менә кайда ул акча!

Илек тозы күптән тынгы бирми Неплюевка. Аны тулысы белән казна кулына алып, крестьяннарга сатып биргәндә, әллә ни булыр иде дә бит канә. Әлегә барып чыкмый шул. Тозга хөкүмәт монополиясе керттеңме, яңа бәла буласын көт тә тор. Дөрес, типтәр-бабуллар аны байтактан сатып алалар алуын. Асак та түлиләр. Тик алардан башка башкортлар, ясаклы татарлар, мишәрләр дә күп бит әле. Чирмеш-ар, чуваш-мукшы ише халыклар да байтак җыела. Шулай, күпме генә баш ватма, башка чара юк — халаекларга тозны сатып кына бирергә кирәк!

Тик бу эштә гаять сак булырга, төбенә шайтан үзе дә төшеп җитмәслек хәйлә уйлап табарга кирәк. Тозны казна мөхазинәләреннән сатып алуны халык үзе сорасын. Илеккә илтә торган юлларны үзе япсын! Губернаторның битенә тагын канәгатьлек билгеләре чыкты, ул хәтта елмаеп куйды. Бу исә янә бер планының чынга аша башлавы галәмәте иде. Ул артына борылмый гына кычкырып җибәрде:

— Кублицкий!

Иван Иванович күптән сизеп тора: майор Кублицкий, бер төркем офицерлар белән, байтактан монда, губернаторның уйларын бүлдермәү өчен генә бер читтә таптанып торалар. Шулай булып чыкты да: җәйпәк ташларга шак-шок итеп баскан аяк тавышлары ишетелде, ул да түгел, Неплюев каршында майорның чандыр гәүдәсе пәйда булды:

— Ни боерасыз, галиҗәнап?

— Бүген калада старшиналардан кем дә булса бармы?

— Төгәл генә әйтә алмыйм, галиҗәнап.

— Барыгыз, базарны, өмәтне һәм башка җирләрне айкагыз. Старшиналарның булган кадәрен табып, миңа алып килегез!

Иван Иванович плац кадәр кабинетына узып, мундирын салырга өлгермәде, ишек шакыдылар. Җавап биргәнне дә көтмичә, секретаре Конбяжев килеп керде:

— Майор Кублицкий һәм старшиналар бирәдә, галиҗәнап.

Башта, гадәтенчә тәз басып, ыспай майор килеп керде, аның артыннан курку-өркүләре чырайларына чыккан, шунлыктан мескенләнеп калган дүрт кеше күренде. Бүлмәгә узуга, очлы түбәле, тире читле бүрекләрен салып, култык асларына кыстырдылар да, ишек катына бөялеп, туктап калдылар.

— Түрдән үтегез, әфәнделәр,— диде аларга губернатор.

Олуг түрәнең кунакчыллыгыннан тәмам аптырап калган кунаклар кыяр-кыймас кына ал постау ябылган озын өстәл янына уздылар.

— Ничек, әфәнделәр,— дип дәвам итте губернатор, әлеге садәлеген саклап,— халыкка ясак түләве авырмы?

Старшиналар бөтенләй коелып төштеләр. Монда инде җавапны бик чамалап бирү кирәк. Губернатор кай якка каерадыр бит әле?

— Йә, йә, әйтегез, курыкмагыз, хәлнең дәресен белү кирәк миңа.

Бүлмәдә беравык борыннар гына мышкылдап торды. Араларында батыррагы старшина Әхмәр иде бугай, башлап ул тел тибрәтте:

— Ясак түләүнең... кайчан җиңел... булганы бар, галиҗәнап?!

— Мин дә шулай уйлыйм,— диде губернатор, әлеге җавапка шатлангандай, елмаеп.— Менә нәрсә, салым-алымны бетерүен үтенеп, шәрәфәтле патшабикәбез Елизавета Петровна исеменә үтенеч языгыз. Императрицабызның шәфкате зур — рәхмәтеннән ташламас.

Монысы һич көтелмәгән сүз иде — старшиналар тәмам гаҗиз калдылар. Неплюев исә аларны һич кенә дә ашыктырмый, тыныч кына көтә иде. Ниһаять, әлеге дә баягы Әхмәр старшина телгә килде:

— Э-э-э, ничек була инде ул, галиҗәнап? Без бит ясакны ак падишаһ Иван Васильичтан бирле түләп киләбез. Асабалыгыз өчен, йәгни ошбу җир-суларыбызга хуҗа булган өчен. Ясак салмасак, асабалыгыбыз да бетмәсме соң?

Акыллы старшинаның сүзләренә башкалар да кәч бирде:

— Шылай шыл, түләүсез берни дә юк бу дөньяда.

— Ясагы бетерелсә, башкасын түләргә туры килер барыбер.

Томана старшиналардан мондый ук җавап көтмәгән иде Неплюев.

— Юк, юк, башкача һичнинди салым-алым салынмас халыкка,— дип ышандырырга тотынды.— Инде казна хәленә килсәк, тозны барча халаекларга хөкүмәт мәхазинәләреннән сатып бирәбез.

Губернаторның соңгы сүзе тагы да сагайтты старшиналарны. Сөйләшү сузылды. Тик кемнең инде губернатор хәтле губернаторга: «Юк!» — дип кисеп әйтергә кодрәтеннән килсен?! Ике-өч көн дигәндә гарызнамә язып бирергә вәгъдә иттеләр.

Үзе кебек үк хәйләкәр старшиналар прошение язып китергәнче, тагы бер зур эш майтарып ташлады губернатор — «верныйлар» дип атлары чыккан иң куштан, иң ышанычлы старшиналарның исемлеген үз куллары белән язды һәм аларны һич кичекмәстән губерна үзәгенә чакырырга кушты.

Әхмәр һәм Кыдрачлар үтенеч кәгазен язып китергән көнгә Оренбургка патша хәзрәтләренә җаны-тәне белән бирелгән байтак старшина җыелып өлгергән иде.

Икенче көнне губерна канцеляриясендә крестьяннарның төшенә дә кермәгән «халык җыены» башланып китте. Үзенең инандыру куәсенә ышанса да, җыенны тавышлы булыр дип көткән иде губернатор. Әмма, ни гаҗәп, һич кенә дә каршы сүз әйтергә булмады.

Ничек итсә итте, теләгенә иреште губернатор. Чана юлы төшүгә, кирәкле кәгазьләр тулысынча әзер иде инде. Сыныкны сылтау итеп, пайтәхеткә үзе барырга булды Неплюев. Үз эшеңне үзең күрсәтмәсәң, алар хакында кем җиткерер императрицага? Ә бөек маликәгә сөйләр сүзе күп аның. Алар инде кәгазьгә төшерелгән, дөньяның бөтен хәкимнәре бергәләп язган хикмәтле китаптан да кадерлерәк булып, тимер сандыкта яталар. Неплюев уенча, язган кәгазьләрнең һәр бите олуг бүләккә лаек.

Санкт-Петербургка ул 1753 елның соңгы көннәрендә генә барып җитте. Императрицаның үзен яңа ел бәйрәменнән соң гына кабул итәчәгенә инанган хәлдә, башкаланың иң зиннәтле миһманханәсенә урнашты, иркенләп, туарылып ял итәргә җыенды, ләкин өс-башын тәртипкә китерергә дә өлгермәде, губернаторны сарайга чакырдылар.

Императрица аны, гадәтенчә, кичен һәм инглиз сырасыннан шактый кызган хәлендә, тәхетендә кабул итте, һич көтелмәгән ягымлылык һәм кунакчыллык күрсәтте. Гомер булмаганны, Оренбург губернаторының рапортын игътибар белән тыңлады, аның зиннәтләп төпләнгән һәм адресы алтын хәрефләр белән язылган нөсхәсен үзенең изге куллары белән алды һәм тарих битләренә эре хәрефләр белән кереп калачак «бөек» сүзләрен әйтте:

— Безгә үзебезнең Оренбург краен төзү хакындагы эшләребезне тыңлавы һәм ишетүе, шулай ук, губернатор, бу җәһәттән синең дә тырышлыгыңны билгеләп үтүе гаять тә күңелле. Шуның өчен сиңа рәхмәтебезне белдерәбез. Ә син, губернатор, крайның барлык генераль вә гади чиннарын, безнең исемнән, якынлашып килүче 1754 ел белән котла!..

## Икенче бүлек

Губернаторның патшабикә исеменнән язылган котлау хаты төбәкнең бирлык чиркәү һәм мәчетләрендә түрәләргә вә гавамга укылуына, халаекларга иминлек һәм тынгылык теләп гыйбәдәтләр кылынуына карамастан, 1754 ел хәвефле башланды. Өметтән-өметкә, иләүдән-иләүгә шомлы хәбәрләр йөрде, ат-хат җитешле барлык аймакларда яшәүчеләрнең телендә бер генә сүз — тоз иде.

Тоз хәбәре җәйләүдән-җәйләүгә, авылдан-авылга күчеп йөри торгач, олы юллардан читтәге Карышбашка да килеп иреште. Батыршага аны Оренбург янәшәсендәге Бөрҗән иләүеннән шәкерт улының хәлен белергә килгән бер башкорт сөйләде.

Әлегә имеш-мимеш рәвешендә генә йөргән тоз хафасының кара халыкны борчуга салуын аңларга була иде. Ләкин аның очы түрә-старшиналарга да тиядер дип көтмәгән иде Батырша. Беркөнне, мәдрәсәдә дәресләр беткәнне саклап кына торган диярсең, шәкертләр таралуга, дәресханәгә шыпырт кына Яныш килеп керде, пышылдап диярлек сәлам бирде:

— Әссәламегаләйкем, хәзрәт!

Мулла аның сәламен алды алуын, әмма каршына сикереп төшәргә ашыкмады. Сөерсенүен яшерергә тырышып, намазлыгы өстендә таралып яткан китапларын җыйган булып маташты. Гаҗәбе — Яныш бүген гөнаһсыз сабыйдай аек һәм ялгызы иде. Бу хәлне нәрсәгә дә юрарга белми озак баш ватты Батырша, араларында берни булмагандай, бөкләнеп утырган намазлыгыннан тормый гына сорап куйды:

— Ни хәл вә ни хәбәр, Яныш агай?

— Хәерледән түгел хәбәрләр, мелла.

— Ул-бу ишетелми сыман бит, Яныш агай,— дип, хәйләгә керешә Батырша... Без каян ишетәек ди, мәдрәсәдә мүкләнеп ятып ни...

— Ясакны бетереп, тозны халаекларга сатып бирмәкчеләр икән.

— Анысы яхшырак булыр димсең, Яныш агай? Әллә яманракмы?

— Һай, Батыршаһ, беркатлы булып кыланмасаңчы?! Падишаһның әле кайчан халаекларга өйбәткә указ иңдергәне бар?! Гавам кесәсеннән өче белән чыгачак, поты утыз биш тиен булачак, ди, тозның.

— Шул хәбәр хак булыр дисеңме? Указ-мазар күренми бугай ла...

— Хаклыгында һич шөбһә юктыр, Батыршаһ. Бәнем писыр Кузьмага гөбернаторның тылмачы үзе сүләгән. Халаеклар исеменнән язылган гарзы хәлне пайтәхеткә үзе алып киткән Ниплүй янарал.

— Гарызнамәсе булгач, аның тамгалары да куелырга тиештер бит, Яныш агай?

— Анысын сәнең белән бәннән сорап тормаганнар. Бөтен куштан старшина, җыенга җыелган булып, тамгаларын салганнар.

— Шундыен җыеннан сән дә калырсың икән, Яныш агай.

— Әйа, Батыршаһ! Нәчөн бәнем хакта гел начар уйлыйсың? — Яныш аның каршына килеп, идәнгә чүгәләде.— Кичер, өйдә, килешик. Тәүбә-истигъфар. Ил өстенә каза килергә торганда, үзара низагта яшәү һич ярамас!

Түрәнең болай акылына зәгыйфьлек килгән бәндә сыман сөйләшүен көтмәгән иде мулла, гаҗизләнеп калды, ни дип тә әйтергә белми, урыныннан кузгалды.

— Ярый, Яныш абзый, ярый. Гөнаһыңа хода җәзасын бирсен. Кинә куа торган гадәтем юк. Бигайбә, катын сырхаулап тора.

Сүзенең ярдәме тиде бугай, ул, старшина әсирлегеннән арынып, чөйдәге туны, бүреге янына килде, аларны ашык-пошык киде дә дәрес-ханәдән чыгып ук китте.

Үй өере исә аның үкчәсенә басып килде. Старшинаның бүгенге кыланышы уйланырлык иде шул. Тоз турындагы хәбәр чыннан да хак, хәлләр катлаулы микәнни соң? Мәдрәсә белән мәчеттә бикләнеп ятып, абайламый калды мәллә ул?

Ил-җир арасына чыгарга, имеш-мимешләрнең төбенә төтен салырга туры килмәде, күп тә үтми мәсьәлә үзеннән-үзе ачыкланды. Кояш туры карап, аяк астындагы кар йомшый башлаган көннәр иде. Гомер булмаганны, җомга намазы алдыннан мәсҗеткә Яныш килеп төште, тәһарәтханәгә кереп, таһәрәт алды, намазга җыенды. Вак-төяк сүз арасында муллага әйтеп куйды:

— Намаздан соң таратма мөхәлләңне! Сүзем бар.

Җомга узгач, мөнбәр алдына Яныш үзе чыгып басты:

— Җәмәгать, тыңлаң! — диде ул, тавышын бөереннән чыгарып,— Патша хәзрәтләренең олуг указы бар. Указ Уфада укылачак. Шуны тыңлау өчен һәр карьядан бер йөрекче хаҗәт.

Мондыен хәл авыл халкы өчен яңалык түгел. Яңадан-яңа указ-фәрманнар тыңларгамы, гавам йомышын хәл итәргәме, Уфага йөрекчеләрне чакырып кына торалар анысы. Һәм, әлбәттә, андыен эшләргә Карышбаштан гел Батырша катнаша. Бу юла да күзләр муллага төбәлде, ул арада кайсыдыр барысының уртак фикерен әйтеп салды:

— Хәзрәт барсын, хәзрәт!

— Ие, ие,— дип, калганнары ризалыкларын белдерергә ашыктылар.

Йөрекчеләр җыенының юл өзегенә туры килүе гаме булган кемсәләрне уйландырырлык иде. Батырша да аз баш ватмады, мәгәр Уфада сүзнең нәрсә хакында барачагын чамалый алмады. Җыенның эт чыкмас вакытта җыелуыннан чыгып кына: «Хәерлегә түгел бу,— дип фикер йөртте,— аллаһ тәгалә ахырын имин кылсын».

Үтә кызыксынучан гадәте һаман да тынгы бирмәде Батыршага, җаен туры китереп, юлда Янышның кылларын тарткалап карады. Тегесе исә әллә үзе берни белми, әллә инде серне алдан ук ачмаска дип ант иткән, авызына су капкандай тын иде. Алай да чираттагы зәп-зәңгәр булып су тулган чокырларның берсен атларының күкрәкләре белән ярдырып чыккач, юлаучыларның кайсыдыр сүгенеп, зарланып алды:

— Юньле хуҗа этен дә урамга чыгармый мондыйда.

— Сукранма. Тәфтиләү хәзрәтләре Оренбурдан ук килгән ана,— дип кисте аны старшина.

— Ул карт дуңгыз хәерлегә йөрмәс,— дип карулашты тегесе.

Юраганнары юш килде — хәбәр, чыннан да, күңелледән түгел иде. Монысына Уфага килүләренең икенче көнендә, йөрекчеләр җыенында инандылар.

Көне җылы, кояшлы. Йөрекчеләр күп булганлыктан, җыенны провинция канцеляриясенең ишегалдында үткәрергә булганнар икән. Ишегалды зур, канцеляриянең болдыры биек, иркен — түрәләр менеп басарга урын җитәрлек. Затлыдан-затлы киенгән, күбесе гаскәриләр мундирыннан булган әлеге башлыклар төркемендә кемнәр генә булмагандыр. Мәгәр йөрекчеләрнең күзләре күмер тутырылган чыпта капка охшап калган Тәфтиләү морзада иде. Ул инде нык бирешеп, чарасыз карт хәленә килсә дә, үзенең затлы сөяктән икәнен күрсәтергә тырыша. Өстендә өр-яңа полковник мундиры, башында урысның зур түрәләренеке сыман озын, ак ясалма чәч гөнҗәләсе. Үзен-үзе тотышы эре, тавышы көр Тәвкилевнең:

— Әй, халаек, тыйлаң! — диде ул, кулындагы шүрегә охшаган кәгазь төргәген сүтеп.— Мәрхәмәтле патшабикәбез Елизавета Петровнаның 1754 ел 16 мартта игълан кылынган указын укыем. Мәликәбезнең шәфкатьле кулы куелган, мөһере сугылган.

Морза төргәкне сүтеп бетерде, аны башы өстенә күтәреп, кәгазь битенең иң астындагы ике башлы каракош сурәте төшерелгән кызгылт мөһерне җыелган халыкка күрсәтте, аннан инде олуг падишаһның кайсы вә кайсы мөмләкәт-аймакларга хөкемдар икәнен санап китте. Җөмләдән, борынгы Болгар дәүләте исемен дә ишеткәч, Батырша, тыңлавын онытып, уйланып калганын сизмәде дә. «Әллә кайчангы ханнар заманындагы Болгар иләүенә ничек хөкемдар була алсын икән соң бу патшабикә?» — дип фикер йөртте ул, мыскыллы елмаеп. Тәвкилевнең җикеренүе аны сискәндереп җибәрде:

— Ник алкышламыйсыз?! Шәрәфәтле патшабикәбез сез мөселманнар мөгыйшәтен кайгыртып, ясакны бетергән ләбаса!

Әмма аның сүзләрен алкышка кумәргә атлыгып торучы күренми, бар да карашларын җиргә төбәгәннәр дә, битарафланып калганнар.

— Тыңлаң, укып бетерәм,— дип, морза кәгазенә бакты һәм һич адәм аңламаслык сүзләр лыгырдарга тотынды. Гарәп-фарсы ләгатен су кебек эчкән Батырша булып Батырша төшенеп җитмәде. Укып бетерде дә, кәгазен янә көпшәгә урады, йөрәкчеләр өстеннән әллә кайдагы йортларга карап, сүзен дәвам итте.— Тәфсире болай: моннан соң, ягъни бу елдан башлап, ясак түләмисе. Аның урынына тозны кальга-калалардан, казна мәхазинәләреннән сатып аласыз. Поты нибары утыз биш тиен.

Моңа хәтле шым гына торган бәндәләр кинәт бер тын белән: «Аһ!» — итеп куйдылар, аннан янә беравык сүзсез калдылар. Шулчак арттагы рәтләрдән кайсыдыр чыелдап җибәрде:

— Ходай биргән тозны ничек инде сатып алырга, ди?!

Аңа икенчесе кушылды:

— Ие, Илек күле гавамныкы!

Тәвкилевнең җавабы өзер иде:

— Хак тәгалә биргән барлык мал-мөлкәт — патшабикәбезнеке!

Инде сүзнең ни хакында баруы, тозның бер дигән тозак икәне бөтенесенә дә барып җитте бугай, кисәк ду кубып, шаулашырга, кычкырышырга тотындылар:

— Кир-рәге юк!

— Элек ничек алсак, шулай алырбыз!

— Указыңны башыңа капла!

Болдырдагы шома битле гаскәриләрнең берсе морза алдына килеп басты, билендәге кынысыннан ялангач кылыч тартып чыгарды, аны баш өстендә болгап, нидер кычкырды. Әмма халык төркеме инде берни тыңламый, берсеннән-берсе әшәке сүзләр кычкыра-кычкыра, капкага таба чигенә иде. Бераздан инде киң ишегалды шып-шыр булып калды, мәйдан өстендә ярсулы авазлар гына эленеп торган сыман:

— Карт дуңгыз! Кәсебе — һаман халык алдау.

— Алырбыз без сәңа сатып!

— Атларга менәргә, кулга корал алырга — вәт шул!

Чарасыз калган түрәләр болдырда бераз таптанып тордылар да, явыз эшләре белән дан алган канцеляриягә кереп киттеләр.

Җыен шул рәвешле кайнар һәм бик тиз булып узса да, йөрәкчеләрнең байтагы — ерак аймаклардан килүчеләре Уфада озакка калдылар. Басу-кырларда чокырлар ярып, елгалар ярларыннан чыкты — ташу кузгалды, язгы дуамал су байтак кына күперләрне өзеп ташлады.

Батырша мулла әнә шул бүленеп калучылар арасында иде. Ул вакытын ничек сарыф итәргә белмичә, Уфадагы күргән-белгәннәренең барын йөреп чыкты. Адәм балаларының телендә бер генә сүз — тоз да тоз. Берәү дә аны сатып алу ягында түгел.

Гәйнә яклары, өйләренә дип, аяк асты җиллеп, җәйге юл төшкәч кенә кузгалдылар. Мәгәр тоз мәсьәләсе алардан алда иләүләргә барып ирешкән икән. Уфадан соң шактый юл алып, инде үз төбәкләренә авышканда, мишәр авылларының берсендә мәчет янындагы җыенга тап булдылар. Ике ягына өзмәвердәй ике драгун баскан әфисәр әлеге мәгълүм указны укып тора. Юлчылар, бер читкәрәк туктап, мәйдән ягына колак салдылар — барыбер атларын хәл алдырасылары бар. Әфисәр укып бетермәде, төркемдә калын тавыш яңгырады:

— Тотсын менә капчыгын!

Аларга җавап итеп, әфисәр зур тавыш белән сузып кычкырды:

— Мо-о-ол-чать!

Баш өстеннән сызгырып йодрык хәтле таш очып үтте, гаскәриләрнең аяклары астына ук барып төште. Ул арада кайсыдыр янәшәдәге читән казыган суырып алды. Патша йомышлылары качып киттеләр. Моңа охшашлы хәлләрне бөтен күрмәсәләр дә, ишеттеләр: тоз хакында указны укыганда, һәр авыл-җәйләүдә ызгыш-талаш купкан икән.

Авылына кайткач, берни ишетмәгән-күрмәгән кешедәй, китаплары дөньясына чумды дә мелла, үзе исә, тирә-юньдә ни бар икән дип, колагын сак тотты. Ләкин олы юллардан читтәге Карышбашка дөнья хәбәрләре тиз генә килеп җитми иде. Шуңа гаҗизләнгән Батырша, Яхъяны атка мендереп, Уфа ягына чыгарып җибәрде, кайда ни ишетсә, шуны кайтып әйтергә кушты. Моңа Зөлхәбирәсе үпкәләде үпкәләвен — язгы кыр эшләренең төмам куерган чагы бит. Батырша, гадәтенчә, остазбикәсенә каршы дәшмәде, мәгәр ниятеннән дә кире кайтмады — ул инде хәбәрсез яши алмый иде.

Яхъя икенче көнне үк кайтып та төште, китергән сүзе дә сәер иде. Көзен тозга бара алмый калганнардан бер төркем Тозтүбәгә киткән булган икән. Барып җитә алмаганнар, бахырлар — солдатлар бөтен юлларны япканнар, Илек күленә берәүне дә якын җибәрмиләр, имеш.

Шуннан инде чыгып, сорашып йөрисе дә калмады. Берсеннән-берсе шомлы һәм хәвефле хәбәрләр, җил канатында йөргәндәй, җәйләүдән-җәйләүгә, авылдан-авылга көне-сәгате белән килеп җитәләр иде.

Ниһаять, сәрәтән йолдызлыгы башында Чуртанлыкүл буенда балык тотып йөргән Яхъя нindидер узгынчыдан өр-яңа хәбәр алып кайтты:

— Мулла абзый, Нугай юлыныкылар коралга ябышканнар икән,— диде ул, тынына каплана-каплана.

Ишеткәне күңеленә сары май булып ятса да, куанычын тышка чыгарырга ашыкмады Батырша. Дөресен әйткәндә, ышанып та бетмәде — малай-шалай ни сөйләмәс. Тик чынын каян белергә? Якынтирәдә белсә аны берәү генә белер — Янышның писаре Кузьма. Телен чишү өчен бер җамыяк балың да булсамы?!

Кичке буйда, көн кызуы сүрелгәндә, ул инде Чуртанлыкүл авылында иде. Бер читтәрәк ялгызы моңаеп торган кабык башлы бәләкәй йортның ишегалдына узды һәм утынлыкта челем пыскытып утырган Кузьмага тап булды. Татарчаны үз теле кебек ук белүче тач җирән Кузьма болай да дусты анысы. Мәгәр сүз башлап җибәрү өчен алып килгән балы бик тә ярап куйды. Бер йомрыны әйләндереп каплагач, үзе сүз башлады Кузьма:

— Болыныңда печәннәр ничек, Батырша? Быел иртәрәк чабарга туры килмәгәе.

— Нидән алай дисең?

— Күк ут вакытында яу купмагае. Нугай юлы башкортлары җәякылычларын төзиләр, ди.

— Шуны хак булыр димсең?

— Оренбур ягыннан килгән хәбәрләргә караганда, хак булыр күк. Каргалы татарлары да хәстәрләнәләр, имеш — ук атып, кулларын күнектерәләр, ди. Себер вә Уса юлларыннан да шындыерак шомлыклар ишетелгәли...

Аяз көнне яшен яшьнәсә. Мөслим карьясының халкы шушы кадәр дә шаккатар иде микән? Батырша хәзрәтнең бу якларга миһман булып килүе авылны гына түгел, бөтен иләүне аякка бастырды. Кем күреп калгандыр да, кайсы ишетеп өлгергәндер — әлеге җәйге көндә өйдә торып калган карт-коры, җәйләвенә китеп өлгермәгән яисә бер-бер йомыш белән кайткан ир-ат һәм хатын-кыз мәчет янындагы мәдрәсә ихатасына җыелды. Ашыга-кабалана шәкерте — бәләкәй Апуш та килеп җитте. Дөрес, аңа инде бәләкәй дип әйтергә тел әйләнми. Ул тәмам буй җиткереп, сөлектәй егеткә әйләнгән, тупый борыны астында капкара булып мыек төртеп чыккан. Аның үз авылларында имам-мөдәррис булып калуын белә иде инде кунак. Исәнлек-саулык та сорашып тормастан, Батырша йозаксыз ишеккә ымлады:

— Йә, имам-мөдәррис, күрсәт мәдрәсәңне?!

— Анда хәзер берни дә юк ич, хәзрәт, дәресханәләр буш.

Батырша аны тыңлап бетермәде, ишекне ачып, эчкә үтте, аннан инде дәресханәләрнең әле берсенә, әле икенчесенә кереп, мәдрәсәне күзәтеп-барлап йөрергә тотынды. Соңгы бүлмәдә туктап калды һәм артыннан ияргән шәкертенә сәоаль бирде:

— Атан-анаң исән-иминнәрме?

—Шөкер, хәзрәт, сезнең хәер-фатихада исән-саулар. Җәйләүгә чыккан көннәре. Үзем дә шунда китәргә дип тораем.

Алар әйләнеп чыкканда, мәдрәсә ихатасы халык белән тулы иде инде. Хәзрәтне күрүгә, чалгыга эләккән үләндәй, җиргә сөрлектеләр, чирәмгә тезләнеп, кулларын өскә күтәрделәр:

— Әйа вәлинигъмәт, догаңнан ташлама!

Бу хәлне күрүгә, тәне эсселе-суыклы булып китте Батыршаның.

— Әй, мөселманнар, торың! Бән һәрчак сезгә догада,— диде. Төркем өстендә: «Амин!», «Машалла!» — дигән авазлар яңгырады. Хәзрәтне урап, хәл-әхвәл сорашу, абруйлы миһманны ашка-чәйгә чакыру башланды. Ярый әле, Мөслим углы Абдулла ярдәмгә килде:

— Бу ни эшегез инде, җәмәгать,— диде ул, шактый кырыс итеп.

— Хәзрәт ерак юл килгән, сусынын басарга, тамак ялгарга да өлгермәгән, сез исә борчыйсыз да борчыйсыз. Ярамый болай, таралыгыз. Батырша хәзрәт бүген безгә кайта.

Арулары җиткән иде. Чәй эчеп, ахшам намазы укуга, йөстүне дә көтмичә, йокларга яттылар.

Юлда ватылуы үзенекен иткән күрәсең, иртәгесен ул кояш шактый күтәрелгәч кенә торып чыкты. Капка төбендә мичәүләп пар ат җигелгән затлы арба күреп алды. Олауга мендәр-ястыклар түшәлгән. Алда тагы юл көтелә икән. Җиңелчә генә капкалап, чәй эчеп алдылар да кузгалдылар. Әйтүләренә караганда, сәфәрләре ерак түгел, авылга иң якыны булган мишәр Хабулла җәйләвенә.

Җәйләү башыннан ук инешкә әверелеп киткән күәтле чишмә буенда, бөтен ягын карагай урманы әйләндереп алган, гөлләр-ганҗәләр белән капланган аланда булса да, Батыршаны гаҗәпләндергәне табигать хозурлыгы түгел, бәлки мондагы халыкның күплеге иде. Арырак, күчмә киез тирмәләр янында бала-чага чыркылдаша, хатын-кызлар кайнаша, шунда ук, биш-алты җирдә имән казыкларга асылган казаннарда ит пешә. Кунаклар килеп туктаган тирәдә исә ир-ат мәж килә. Бар да абруйлы миһманны каршыламакчы, аңа арбадан төшәргә булышмакчы. Олаудан төшеп, аякларын язган арада, Батырша җете күзләре белән танышларын, бигрәк тә Мөслим старшинаны эзләде. Белешләре шактый гына күренсә дә, иләү агасы күзгә чалынмады. Хәтта инеш буенда намазлыклар өстенә тезелешеп утырган аксакаллар арасында да юк иде йортавай.

Көннең шактый эссе булуына карамастан, башларына зур-зур чалмалар урап алган әлеге төркемнең мулла-абызлар, галим-голәмә икенен аңышып, Батырша чыраен сытып куйды. Ул бит Урал аръягы тикле Урал аръягына кара халык арасында туарылып бер ял итәргә, аннан да битәр аларның ни сөйләүләрен, уй-ниятләрен тыңларга дип килде.

Намаздан соң яшел чирәм өстенә җәелгән табыннарга дүрт-биш оя булып утырдылар. Батырша, билгеле ки, урынның затлысына, мендәрпаласлар түшәлгәненә туры килде. Бу баш табында, әлбәттә инде, галим-голәмә вә муллалар. Ул, көнләшеп, башка табыннарга урнашып алган гавам кешеләренә карап-карап алды. Чөнки алар ягыннан инде мәзәк, төртмә сүз, ихластан шаркылдап көлүләр ишетелеп куя. Монда исә бар да вәкарьле генә тезелешеп утырганнар да авызларына су капканнар. Сизелә: һәрбарчасының гыйлемле, гакыллы вә тәүфикълы булып күренәселәре килә.

Батырша үзе сүз башларга ашыкмады. Шулай ул, гакыллы кеше, вакытын көтеп, сүзен башламый тора, тома кеше генә берни белән исәпләшми. Табынның иң аргы башында утырган урта яшьләрдәге чандыр гына берәү — кием-салымына караганда, кечерәк бер карьяның имамы, әллә чын, әллә юри дигәндәй, сорап куйды:

— Әй, вәлинигъмәт, берәү өч хатынын берьюлы аерырга уйласа, талакны ничә кат әйтергә тиеш: өчнеме, тугызнымы?

Олуг миһман янындагы аксакаллар, пырхылдап көлеп җибәрмәс өчен булса кирәк, кайсы йөзен читкә борды, кайсы башын аска иде. Батырша исә сөальнең ихластанмы, әллә шаяртыпмы бирелүен аңларга тырышып, теге бәндә утырган тарафка карап алды. Әмма ул ахмак сөальгә җавап бирергә өзер түгел иде. Шуңа да уена беренче килгәнне җаваплады:

— Талакны өч әткәнгә, тугызны кабатлау авырмы булыр?!

Беренче карашка, беркатлы һәм мәзәгрәк булып тоелган сорау мәҗлес халкын кузгатып җибәрергә ярап куйды, сорау арты сорау явып кына торды. Батырша үз гомерендә аларны күп ишеткән иде инде. Кыска һәм аңлаешлы итеп, сөаль бирүченең кытыгына тими генә җаваплар кайтарды.

Вәли үз эшендә, Гали үз эшендә дигәндәй, шул ук вакытта сыйлану да тукталып тормады. Ниһаять, кымыз бирделәр. Сораулар онытылды, шифалы эчемлекне олылау сүзләре әйтелде. Берәр чәркә эчеп куйгач, табынның кәефе янә үзгәрде: сүзләр киселде, чырайларга олпатлык, зурлык галәмәтләре чыкты. Табында саллырак сүзләр ишетелә башлады. Монысы инде түрдә утыручы галим-голәмәнең әңгәмәгә кушылуы иде. Аларның сораулары да четреклерәк, олырак. Башта олуг кунактан бер кеше аша гына утыручы зур чалмалы мулла телгә килде:

— Әйа вәлинигъмәт, аллаһ тәгаләне бик тә кодрәтле вә куәтле дип беләбез. Иблис шундыен илаһи затка буйсынамы? Баш бирмәсә, ни өчен хак тәгалә аңа харам эшләр кылырга ярдәм итә, ни өчен ул явызның җанын җәһәннәмгә җибәрми?

Монысы мәҗлес саен була торган коткылы сорауларның берсе иде. Олуг галим четрекле сөальгә җавап бирә алырмы, янәсе. Батырша хәлне шунда ук төшенде, катлаулы сорауга җавапны да төпле итеп бирергә кирәклеген аңлады:

— Бу хакта изге китапларда болай диелгән...— Батырша тыныч кына башлады.— Бән бәндәләремә баш бирдем, гакыл бирдем. Күрергә күз, ишетергә колак бирдем. Эшне Иблискә ияреп, аның коткысын тыңлап эшләмә, бәндәм. Уйлап, миеңнә кыймылдатып, гакыл белән эш ит берүк!

Ниһаять, Батыршаның сул ягында утыручы кызыл буй-буй җилән кигән кәҗә сакаллысы сорады:

— Хәзрәт, ишетеп торабыз, күреп торабыз: ил-җиребездә теге ләгънәт орган завут-кальгалар, калалар арткannан-арта, кяферләр

ишәйгәннән-ишәя. Мөэмин-мөселманнарга җәбер-золым чиксез-чамасыз. Бу тарлыклар Дәҗҗал мәлгунь кәсафәте түгел микән дим бән?

Батырша сүзнең болайга авышуын күптән көтеп утыра иде. Инде килеп сүтелә икән, җепнең очын чуалтмый гына йомгакка урарга кирәк. Сорауга төгәл вә ачык җавап бирерлеге, анлык һимməтe булса да, әңгәмәне куерту нияте белән, бәхәсне әйләнчегрәк юлдан алып китте:

— Әйа мелла, китаплардан укып беләбез: Дәҗҗәл замана ахыры җиткәч кенә сизеләчәк бит ул...

Хәйләсе барып чыкты, каршында утыручы сары сакаллы берәү, аны бүлдереп, кычкырып әйтеп салды:

— Шәять, кыямәт җиткәндәр, вәлинигъмәт, дөнья шуңа болганадыр...

— Ярый, шулай дип фараз кылыйк,— дип фикерен дәвам итте Батырша, мәртәбәле генә һәм буй-буй җиләнлегә карап алды,— яүмәлкыямәт — хисап көне җитте диик. Мәгәр шунысы да мәгълүм: ахырзаманда Дәҗҗалның хакимлеге кырык көннән дә артмаска. Мәһди килеп ул явызны үтерергә тиеш ләбаса. Ә сәнең Дәҗҗал, мелла инде ничә еллар башбаштаклана?

Батырша сүзен киная белән әйтсә дә, аны бөтенесе дә аңлады. Әлеге сары сакал, барының уен белдергәндәй, утка ялкын өстәп җибәрде:

— Алайса, безне кыерсытучы көчне Дәҗҗалдан да куәтлерәк димсең, хәзрәт?! Кем соң ул?

Шулчак табынның аргы очында утырган Абдулла Мөслим углы кычкырып җибәрде:

— Әй, аксакаллар, шуны да белмәгән булып утырмасагызчы. Кем дә кем, имеш. Кяферләр, әлбәттә! Шул имансызларны кырып-чабып бетерергә кирәк безгә!

Мәҗлес Батырша көткән юнәлеш алса да, монысы әле яшь әтәч тавышы гына иде. Яшь әтәч кычкырудан гына таң атмый. Гомер иткән карт әтәчләрнең авазларын ишетәсе иде. Шул ният белән ул әңгәмәне янә дә бормалы юлдан алып китте:

— Аллаһе тәгалә әйткән: бән җир өстенә күп кавемнәр яраттым. Бәндәләр барысы да бер-береннән яхшылыкка үрәнергә, көннән-көн әйбәтрәк булырга тырышып яшәргә тиешләр, дигән.

Сары сакал шунда ук аңа каршы чыкты, урыныннан кубып, тезләренә калыкты хәтта:

— Әй, вәлинигъмәт, бер якның тырышлыгы белән генә буламы соң ул?! Хак тәгалә үзе шаһит: безнең халаеклар берәүне дә рәнҗетми, берәүдән берни тартып алмый. Аңа карап туктыйлармы соң тегеләр?! Аллаһ тәгалә әйткән яхшылык һәр ике тарафтан булырга тиеш ләбаса!

Мәҗлескә шушы сүз кирәк булган икән. Бердәм кубып, шаулашакычкырыша башладылар:

— Өстенә бастың, мелла: алар халаекларны көчләп чукындыралар, мәчет-мәдрәсәләрне вәйран итәләр!

— Ие, ие, динен ташламаган мөселманнарга өстәмә алым-салымнар йөклиләр, әллә ниткән бурычлар тагалар, очы-кырые күренмәгән тарлык вә хурлыклар китерәләр!

— Соң инде, гомер бакый хода биргән таулардан вә күлләрдән чыккан тозны сатып алырга кушалар.

Сары сакал аягына ук торып басты һәм бөтен аланны ярып кычкырып җибәрде:

— Мөхәммәт пәйгамбәрнең яшел байрагын күтәрер чак җитте, ирләр!

Мондыен коткыдан йөрәге алынган хуҗа — мишәр Хабулла йөгереп килеп җитте:

— Җәмәгать! Әй, җәмәгать! Ташлагыз әле юк-барны. Сүзне чичән-

нәргә бирик булмаса. Яисә курайчыга... Әй, пәһлеваннар, көрәш мәйданына!

Табындагылар, өсләренә салкын су койгандай, шым калдылар. Моңа хәтле ябайлар табыны тирәсендә чуалган чичән белән курайчы килеп җитте, уен-җыр, мәзәк сүз башланды. Алан уртасында көрәшчеләр сөлгеләрен бер-беренең биленә салдылар.

Батырша, хәле китүне сылтау итеп, кунакчыл хуҗаның киез тирмәсенә керде, түр буйга салынган урынга ятты һәм ишеткән-күргәннәрен бер төенгә җыя башлады. Алай, вакыйган, халаекларның сабыры төкәнеп бара булса кирәк. Дөрес, табында мулла-мунтагай, галимголәмә генә гайрәтләнде гайрәтләнүен. Мәгәр алар ил сүзен сөйлиләр булыр. Соңрак башка табындагыларның да кушылып китүе тикмәгә түгел. Җиһад, диләр. Дин өчен изге сугышка чыкмакчылар, димәк. Сүз дә юк, гавамны кыздыру вә иярту өчен алыштыргысыз чара бу. Гавам кутәрелә икән — үзен җәберләүчеләргә каршы да кутәрелә. Араларында инде үзебезнең мөселман агай-эне дә җитәрлек. Димәк ки, ныклап уйланасы бар монда. Мөхәммәт байрагы астында кузгалган халык көрәше дәвамында аптырап калмасмы? Мөмкин, бик тә мөмкин. Нигә дисәң, җиһадка чыккан халык кяферләргә каршы гына сугышып, мөселман түрәсен якларга тиеш була ләбаса. Ә аларның күбесе урысны күргәне дә юк, нужаны «үз» түрәсеннән чигә. Бар үче-нәфрәте шул ук Тәфтиләүләргә, Янышларга. Ул исә аларга чиертмәскә дә тиеш. Димәк ки, җиһадтан гайрәте кайтачак халаекларның. Мондый хәлдә җиде кат үлчәп, бер кат кисү хәерле...

Мәҗлес икенче көнне дә дәвам итте. Әмма, Батыршаны ашка алырга дип, башка җәйләүләрдән дә килеп кенә торалар. Аларын да үпкәләтеп булмый. Өстәвенә, җае чыкканда яңадан-яңа җирләр күрү, башка кешеләр белән очрашу аның ниятенә дә килеп тора. Җәйләүдән-җәйләүгә йөри торгач, ун көн үтеп тә китте. Мәҗлесләр күп булды, тик аларның берсе дә Батырша көткән очрашу түгел әле.

Батырша инде мондагы бертөрле, тук һәм хафасыз тормыштан туя ук башлаган иде. Беркөнне иртән ул кунак булып төшкән җәйләүгә атларга атланган биш башкорт килеп чыкты. Ук-җәяләре җилкәләрендә чукмарлары кулларында. Яшьләр, чибәрләр, гайрәтлеләр. Арада мәртәбәлесе бугай, кысыграк күзләре, кара-тут табак бите белән кыр казагын хәтерләтүче мөлаем егет аның алдына килеп басты:

— Күршедәге Салчыгут иләүе башкортлары сәне миһман итеп чыкаралар, агаем.

Ниһаять, күңелгә тиеп беткән галим-голәмәдән котылу чарасы табылды — хәзрәт Салчыгут иләүенә җыенды. Мондагы мишәрләрнең дә байтагы мәҗлескә чакырылган икән. Ярый әле, араларында, яшь мулла Абдулланы исәпкә алмаганда, дин әһелләре юк иде. Батырша атка менде, алты-җиде дистә мишәр озатуында, юлга чыкты.

Мөслим старшина иләүендәге табыннар табын булмаган икән. Ир-егетләр, хатын-кызлар кайнап торган зур гына урман аланына килеп кергәч, Батырша бер мизгелгә тукталып калды. Мондыен ук күп халыкны ул егет чагында Эрбет ярминкәсендә һәм Уфада гына күргән иде. Алан тирәли учаклар ягылган, казаннар асылган алар тирәсендә аллыгөлле киенгән бичәләр әвәрә килә. Бер тарафта яңа гына тунап алынган өч ат тиресе чирәмгә җәеп куелган.

Шөһрәт белән Урал төбәгенә таралган хәзрәтне күрүгә, картлар да дәррәү телгә килделәр:

— Әйа вәлинигъмәт, хуш килдең,— дип баш ордылар.

Ул бер читкәрәк китеп, комгандагы су белән бит-кулларын юып килгән арада, бөтен аланны тутырып табыннар әзерләнгән, аларга батман-батман елкы ите бирелгән иде инде. Табыннар кырында ук тәгәрәшеп яткан муртайлар һәм имән мичкәләр монда кымыз-балның мулдан булачагын хәбәр итәләр иде.

Батыршаны милəш күлəгəсендəге аксакаллар табынына алып килделəр. Кунак иң түрдəге мендəр өстенə утырырга өлгермəде, табында кымыз һəм бал тулы чəркəлəр, ташаяк савытлар хəрəкəткə килде. Кайсыдыр:

—Җə, хəзрəт, сенең исəнлеккə,— дип кычкырды.

Башкортларның берсе — пəһлеван гəүдəле, җете-кара сакал-мыеклысы, əллə инде мəҗлескə кадəр үк бераз төшереп алган, аеруча гайрəтлəнеп, бөтен аланга ишетелерлек итеп сөйли иде. Менə ул Батыршага таба борылды һəм яшьлеге ташып торган кеше комарлыгы белəн сүзен дəвам итте:

— Менə шулай, хəзрəт, эчə торган тозларымыз вə аулый торган сунарларымыз тыелды. Был падишаһымыз заманында фетнəлəр вə җəфалар чиктəн ашты. Бəс, төкать тотарлыгымыз калмады. Шуннан да яманрак эш булырмы?!

Моңа кадəр ризыкка кагылмый, йокымсырап диярлек утырган, инде шыр сөяккə калып кипкəн диярлек борынгы аксакал аны зəгыйфь тавыш белəн бүлде:

— Хəзрəт, диндəн чыгармак указ илə тыела, дип ишетелəдер.Шул хакмы?

Бурлат чырайлы башкорт, урыныннан калкынып, əйтеп куйды:

— Тыюдан ни файда, хөкем гаделлек белəн башкарылмагач...

Сүзен тартып алуларыннан канəгать Батырша. Эчлəрен бушатсыннар əйдə.

Ул арада теге Хуҗагол дигəне алдындагы чəркəне бушатып куйды, тезлəнеп алды һəм тагы да ярсыбрак сөйлəп китте:

— Үз кулы астындагы халаекларга золымлык кылган йорт уңмас. Халык теленə төшкəн буш булмас, бу усаллыкларның ахыры бардыр!

Тавышка күрше табындагы ирлəр дə, урыннарыннан кубып, монда җыела башладылар. Бераздан инде милəш төбенə байтак халык бөялгəн иде. Араларыннан берəү — сакал-мыегының пөхтə итеп кыркылуына, чиста вə купшы киеменə караганда, абызга охшаганы сүзгə кушылып китте.

— Күрəсез кем, золымлык түрəлəремездə вə янаралларымыздадыр. Ошбу Ниплүй залим янарал, падишаһка прибул итəем, аңа сөекле булаем вə мəртəбə табаем дип, кул астындагы халаекларны болгата. Төрле хəллəргə дүндереп, өслəренə гомер бакый күрмəгəн йөклəрне йөклəтмəккə көчлəп, риза дəгүллəрне ризалыкка язып, тамгаларны салырга көчлəп, төрле хəйлəлəр берлə дин вə дөньяларына тарлыклар китереп, инсаннарга кайгы-хəсрəтлəр бирəдер. Йəгүни халаекларны падишаһ хакында яман уйларга төшереп, йөз дүндереп, аларның качып китүлəренə сəбəпче буладыр. Падишаһны үз халкы арасында вə һəм башка өлкəлəрдə золымлык вə наданлык исеме илə шөһрəтлəндерəдер. Хак тəгалəнең тəкъдиредер: унларны узып, без ни кылаек?

Анысының сүзен урта яшьлəрдəге кара-сары чырайлы берəве күтəреп алды:

— Хагын əйттең, абыз! Падишаһны димəйбез. Падишаһ гаделдер, вə лəкин үз куеныннан китмəгəн, безгə килеп җитмəгəн гаделлектəн ни файда?!

Баядан бирле нидер əйтергə пытпылдап торган Хуҗагол, тегесе тынып калуга ук, элеп алып китте:

— Əүвəл-əүвəлдəн ишетə-күрə килəбез: залим түрəлəрнең мондый чиктəн вə гаятдин ашкан золымлыклары вə халаекларның бу кадəр рəнҗемəк хəбəрлəре падишаһ хозурына мəгълүм улмас. Ул залимнар кылган тик золымлыкларны үзлəренə дə күрсəтергə кирəк. Əйдəгез, без дə анларның диннəрен хурлап, үз динебезгə өндик, малларын талап алыйк — җаһилларга каршы күтəрелик! Шунда хəллəремез падишаһка ирешер, эшлəремез камиллек вə гаделлек берлəн тикшерелер.

Теге коры сөяккə калган аксакал Хуҗаголны янə тезгенлисе итте:

— Артыгын кайнарланасың, Хуҗагол! Нугай юлы халкының хәле безнекеннән мөшкелрәктер. Ниплүй янарал берлә Котлымбәт морза Оренбурга якын тора торган халаекларның җаннарын алырга житешәләр. Алардан җөй буе бүрәнә, дыранча, кабык ташыталар, җирләренә, урманнарына зыян китерәләр. Ул түбә — угын юкка атмаган, аты җиргә ятмаган данлы-чаблы Алдар батыр төягедер. Шундыен пәһлеван аймагы кяфернең бу фетнәләренә чыдармы?!

Бәхәс кызганнан-кызды, ул инде сумалага капкан ялкындай дөрли иде. Батыршаның тамагы кибеп китте, алдындагы балын йотып куйды да уйланып калды. Хуш, килүе бушка китмәде, мәсьәлә ачыкланды. Башкортларның да изү-кысулардан тәкатьләре калмаган. Бүген яу чыкса, бүген кушылырга әзерләр. Алай да башлап атка мәнәселәре килми. Әлеге аксакалның Алдар батыр төяге булган Нугай юлы башкортларына ишарәсе юкка түгел.

— Әйа вәлинигъмәт! Әйдәгез, пәһлеваннарның көч сынашуларын караек!

Башы өстендә яңгыраган тавыштан сискәнеп, Батырша күзләрен ачты. Табындагы халык, аягына калкып, алан уртасындагы мәйданга таба кузгалган иде. Шул мәлдә халык арасыннан килеп чыккан Абдулла аны суытып җибәрде:

— Атаемнан кеше килде, — диде егет, йөзенә олпатлык чыгарырга тырышып. — Кунып калмасыннар, бәнем җәйләвемә кайтсыннар, диген.

Старшинаның Мөслим авылыннан егерме чакрым чамасы мондарак җәйләвенә күз бәйләнгәндә кайтып җиттеләр. Кадерле кунакны зурлап вә ихтирамлап каршылады Мөслим, әлегә хәтле чакыра алмавына гафу үтенде:

— Бигайбә, хәзрәт, кинәттән катын сырхаулап китте, — диде ул, ничектер кыенсынып. — Шөкер, хәзер инде аягында.

Ул кичне зурдан купмый, вак-төяк сөйләшеп, намаз укып үткәрделәр. Аш мәҗлесе иртәгәгә билгеләнгән икән.

Алай да Мөслим старшинаның табыны бик тә үзгә иде. Хуҗа үзе дә, улы вә өч-дүрт могътәбәр ир. Аңлады Батырша: сыйланудан бигрәк сөйләшеп, мөслихәтләшеп утыруга йөз тоткан мәҗлес иде бу. Шуңа да мәсьәләне башта ук кабыргасы белән куйды:

— Әй, Мөслим ага, заманада яхшылык артамы, яманлыкмы?

Старшина чыраен сытты, сөйләп китте:

— Әйа вәлинигъмәт, ни дип сорайсың? Үзеңә мәгълүмдер, кяфернең җәфасы сәбәбеннән җилкә җенемез сынгандыр. Хак тәгалә үзләренең сыртларын җимерсен, өметләрен өзсен. Бәнем камандамнан байтак кешене хәйлә вә куркытулар берлә диннән чыгардылар һәм Салчыгут иләүеннән күп җәмәгатьне диннән яздырып, харап иттеләр. Гомер бакый падишаһның әмерен тоттым, хезмәтен иттем. Падишаһ ризалыгы өчен диндәшләремезнең канын түктем, җанын кыйдым. Әмма ләкин явыз кяфер тарафыннан фетнә кимемидер, киресенчә, көннән-көн артадыр. Бу арада янә фетнә пәйда булып тора. Ие, тоз...

Мөслимнең сүз башы әйбәт килеп чыкты, табындагылар бердәм гәпкә кушылып китте. Батырша исә әңгәмәгә катышмый, вакыты-вакыты белән сүз кыстырып, тегеләрне кыздырып кына җибәрә иде. Байтак кына түрәләрнең, мулла-абызларның гавам ягына авышулары аның күңелен күтәреп җибәрде, кубачак яуның уңышына ышанычын ныгытты.

Старшинаның җәйләве нибары өч-дүрт тирмәдән тора иде. Батырша монда тынычлап ял итте, бер хафасыз бәндәдәй, урман-су буйларында йөрде, хуш исләр иснәп кинәнде. Ниһаять, ул Карышбашка кайтып китәргә җыенды.

Шул көнне кичке буйда җәйләүгә сәеррәк юлчы килеп чыкты. Аның өстендәге ясауыл мундиры Батыршаны шөбһәгә төшерде. Ул ихтыярсыздан җиләне кесәсендәге паспортын капшап алды. Ярый әле, писыр

Кузьма иске паспортына нидер тырмаштырып биргән иде. Югыйсә, кабат зинданга эләгүеңне көт тә тор.

Шөкер, килүче татар казагы булып чыкты. Аты — Мансур икән. Йомышы да хәерледән — Батырша хәзрәтне миһманлыкка алырга килгән. Иртәгәсен Мансур ясауылның җитәктәге атына атланды. Кыйблага йөз тотып юлга чыктылар. Башта, тәннәр язылганчы дип, атлатып кына бардылар. Мансур, юлны кыскарту нияте белән булса кирәк, тәрҗемәи хәлен сөйләп алды һәм аны шактый күңелсез тәмамлады:

— Падишаһ ризалыгы өчен мөселманнарның канын түктем. Җанымны аямый, укка-сөңгегә каршы барып, күп җәрәхәтләр зәхмәте чиктем. Нәтиҗәсе ни? Көмәләребез комга утырды — вәт шул. Вафасыз мөлъгуннарның сүзен-сүз җиткереп булмас. Ялчыларымны чукындырып, малымнан яздырдылар.

Көн кызганчы дип, юрттырып киттеләр. Инде сөйләшүе кыен, мөгәр уй өчен хөрлек иде. Казакларның да хәлләре шәптән түгел икән, дип фикер йөртте Батырша, сәфәренең бушка булмавына кәефе килеп.

Өмете акланды. Мансур ясауыл кальгасында ул күп гаскәриләр белән очрашты. Бер-ике көнгә генә дип барган мулланың миһманлыгы сузылды. Аны йорттан — йортка, кальгадан-кальгага йөртеп, бик тә олыладылар, сыйладылар. Әмма Батырша өчен иң мөһиме шул булды: ул казакларның да, башка халаеклар кебек үк, кимсетелеп, җәберләнеп яшәүләрен күрде. Аннан да битәр, халаеклар кузгала калганда, казакларның да боларга кушылачакларына ышанды.

— Башлансын гына, татар казакларының барын күтәрәм! — дип саубуллашты аның белән Мансур ясауыл.

## Дүртенче бүлек

Сөмбелә йолдызлыгы — җәйнең таҗы. Инде арыш урылып, кибәнгә куелган. Анысын чәчүлек орлыкка җитәрлек итеп сугып аласы бар. Форсаттан файдаланып, берәр олау ашлыкны тарттырып, яңа уңыштан ипи пешергәндә дә ярар иде кана. Юк, анысы качмас, беренче спас җиткәнче, уҗым арышын чәчеп куярга кирәк. Уҗым басуын эшкәртеп, чәчәргә өлгермисең, бодай башаклары пешеп җитә, арпа, солы коела башлый. Шуңа да игенче алны-ялны белми сөмбеләдә, бәйрәмнәрне, гадәт-йолаларны онытып тора.

Әнә шундый кылны кырыкка ярырдай вакыт булуга кармастан, бу җомга намазына халык гадәттәгедән күбрәк җыелган икән. Карышбашныкылардан кала, тирә-як карьялардан мишәр-башкортлар да килгән. Һәркайсының инде ике айлар югалып торган Батырша мулланың үзе имамлык иткән намазда катнашасылары килә, мөгаен. Чит-ят аймакларда аның миһманлык кына кылмавын, башка иләүләрдәге халаекларның ни киңәштә торуларын ишетеп-күреп кайтуын чамалый мәхәллә халкы.

Батырша исә һич кенә дә чишелеп китмәде: сәламнәрен алды, үзе хәл-әхвәл сорашты, тик сәфәре хакында ләм-мим. Моңа берәү дә үпкәләмәде тагы. Һәр нәрсәнең җае, үз вакыты бар дигәндәй, дөнья хәлләренең сөгате — намаз-вәгазьдән соң. Сабырлык кирәк. Ие, сабыр төбе — сары алтын.

Булмады, мәхәллә кешеләренең өмете акланмады. Батырша җомга намазын, гадәтенчә, һич иренми җирено җиткереп укыса да, гыйбадәттән соң җөелеп китмәде. Хәтта вәгазе дә ничектер коры һәм өтек килеп чыкты. Әрсезрәкләр юкка гына аның тирәсендә сырпаландылар, юкка гына берсеннән-берсе тозсыз сораулар биреп йөдәттеләр. Мулла берсенә дә ачылмады, ул гына да түгел, мәчеттә ялгызы калгандай, тәсбих тарта башлады.

Җомгадагыларның күбесен чит-ят аймаклардагы хәлләрне белесе килү корты кимерсә дә, җәй кояшының тәрәзәдән төшкән нурлары кызыксынудан көчлерәк иде, урыннарыннан бердәм кузгалып, үз мәшәкатьләре ягын карадылар.

Мулла аларны тоткарламады. Тугызынчы дистәне ваклый башлаган, инде Хозыр Ильяс кыяфәтенә кергән ике чал картның иң соңгылар булып кузгалуларын көтте дә, алар ишектән чыгуга, намазлыгыннан кузгалды. Ул тавышсыз гына тышка чыкканда, әлеге аксакаллар, кулларындагы таякларын акрын-акрын күчереп, капкага таба баралар һәм, мыңгырдашып, үзара нидер сөйләшәләр иде. Тышкы ишек күләгәсенә ышыкланып, сүзләренә колак салды Батырша.

— Аңыштыңмы, Мөбәракша, хәзрәт бөтенләй үзгәреп кайткан.

— Ие, ие, хәтта кем патша хәзрәтләре, аның вәзирләре вә наибләре исәнлегенә дога да тотмады бүген.

Сизгәннәр, дигән уй үтте Батыршаның башыннан. Хак, бүген ул, аңлы рәвештә, патшабикәне дә, аның яраннарын да телгә алмады, халаекларны алар саулыгына дога кылырга чакырмады, падишаһка һәм аның түрәләренә буйсынырга өндәмәде. Һәм моннан болай өндәмәс тә! Диндарларны залимнәр аманлыгына догага чакырмас!

Ул картларның ераклаша төшүен көтеп, мәчет баскычына утырды. Уйлары да янәшәсенә чүмәштеләр бугай, һаман да тынгы бирмиләр. Әйе, бүгеннән ул дөньяның бар залимнәренә каршы баш күтәрде. Күңеленнән генә булса да. Бәндәләрне шулкадәр дә тарлык вә хурлыклар белән кыерсытуларга һаман түзеп торыргамы?! Юк, булмас!

Алай да... Алай да күңелендә ниндидер юшкын Батыршаның Ә, ие, бүгенге гыйсьянлыгы белән шәрәфәтле патшабикәне дә залимнар белән бер рәткә куйды түгелме соң ул?! Монысы инде һич кенә дә гакыллылык түгел. Падишаһ мәрхәмәтледер. Кашки, бу мөселман бәндәләрнең чарасыз хәлләре падишаһымыз хәзрәтләренең үз хозурына җиткерелсә, алар падишаһлык гадәләте белән тикшерелсә, мазлум инсаннар рәхмәткә вә рәхәткә тиенерләр иде тиенүен. Вәләкин ошбу яманлыкларны падишаһ катына җиткерү, аңа мәгълүм итү өчен зур тырышлык кирәк шул. Халаеклар: «Мөгаен бу падишаһымызның әмере түгел»,— дип ризасызлык күрсәткәч, шул җәфа сәбәпле падишаһ хозурына барыр, мәрхәмәт эстәр өчен йөрәкчеләр әзерли башлагач, шул ук залим старшиналар вә түрәләр аларны, вурлар дип, тотып бирмәделәр мени? Бәс шулай икән, падишаһ катына бару, мондагы халаекларның авыр хәлен ул бөек затка җиткерү һич мөмкин түгелдер. Алайса нишләргә соң, нишләргә?

Батырша авызы кибүен, эчәсе килүен абайлап алды. Өенә кайту нияте белән урыныннан кузгалды һәм җәһәт адымнар белән атлап китте. Ишегалдында, келәт күләгәсендә, аны ике башкорт көтеп утыра иде. Мулла капкадан керүгә, түбәнчелек белән сәлам бирделәр, хәзрәтнең аягына егылдылар.

— Торың,— диде аларга мулла, йомшак кына.— Кайдан вә кемнәр буласыз?

— Күдәй иләүеннән, Шаганай ыстаршина камандасыннанмыз,— дип җавап кайтарды берсе — хатын-кызныкы сыман нәфис чырайлысы.

— Сәфәрегез еракмы? — диде.

— Йомыш берлә Уран иләүенә баруымыз,— сүзне әлеге дә баягы хатын-кыз чырайлысы сөйли, янындагы юлдашы исә ул әйткәннәрне «ие, ие» дип җөпләп кенә тора иде.— Сездән хәзрәт белән күрешеп, кайбер сөальләрне ачыклап китәек, дип килдек.

— Хуш, өйдән узың! — диде Батырша, башлап үзе кереп китте. Юлаучыларның сусаулары җиткән иде бугай, кыстатмый гына өстәл янына утырдылар. Зәлхәбирә яулык чите белән йөзен каплый-каплый чәй ясаган арада, йомышларын йомышларга ашыктылар. Сораулар

әлеге дә баягы мирас малы бүлү хакында һәм гаять тә беркатлылар иде. Сизелә: төп йомышлары бөтенләй башка башкортларның. Шуңа да Батырша сүзнең дилбегәсен үз кулына алды:

— Йөргән-торган җирләрегездә ни хәбәрләр ишетәсез? Вә һәм йортыгыздагы халаеклар ни хәлдә вә ни киңәштә торалар?

Җавапка һаман да шул җитү кызлардай чибәр башкорт алынды,тегесе исә, башын ия-ия, анысына көч биреп торды:

— Әй, хәзрәт, сәнең тик кешеләрдән яшереп, кемгә әйтәсе булырмыз. Хакыйкать вә чын сүз улдыр: безнең күдәйләр вә һәм Әй суы буйлары, Урал аръяклары вә Нугай юллары хәбәрләшеп, хәл белешкәннәрдер. Кяфирләрнең тәкать тоткысыз җәфалары сәбәбендән гаҗиз улмаклары өчен, сугыш кораллары хәзерләп, аларны азындырмаска вә үч алырга, диделәр.

— Кай вакытта?

— Әлхаль, вакыты мәгълүм дәгүл, вәләкин әзер торсын дип, хәбәр тотыштылар.

— Уран иләүенә хәбәрләшер өчен барамсыз?

—Үз йомышыбыз белән, алыш-бирешкә барамыз.

Тамакларын ялгауга, кунаклар: «Юлчының юлда булуы яхшы»,— дип сөйләнә-сөйләнә, барасы җирләренә кузгалдылар. Алар китте, Батырша исә сорау өермәсе эчендә күмелеп калды. Кузгалу вакытын берәү дә төгәл генә белми. Янә дә килеп, яуның башлыгы кем? Кем ул баһадир җан? Хәзергә исемен белдерәсе килмиме, шуңа халык арасында күренмиме Әйе, сораулар күп. Аларның барына да җавапны бер вакыт кына бирә ала. Димәк ки, сабыр итәргә, тагы көтәргә кала.

Ниһаять, беркөнне кич, ул ахшам намазын укып утырганда, өенең ишеге ачылып китте һәм бусагадан таныш булмаган тавыш ишетелде:

— Хуҗалар үдә микән?

Ул, намазын тәмамлап, аминын әйтте дә, оеган урыныннан кузгалмый гына, алдагы якка карап тавыш бирде:

— Кем ул, ни йомыш?

— Сөләйман ыстаршина алуыннан мелла Гәбделсаттармын,— дип җавап кайтарды баягы бераз карлыккан тавыш.— Каргалыда Гәбделсәлам ахун мәдрәсәсендә укып, өемә кайтып баруым. Анамны, карендәшләремне күрү өчен. Сәңа туктарга җөрьәт иттем, хәзрәт. Әманәтем дә бар.

— Хуш, мелла, узың. Җиләнеңне сал. Ана—су, менә—сөлге, юын. Остазбикә, сән кая?! Миһманга табын әзерлә!

Үзенең исә табынга утырганны көтәргә сабырлыгы җитмәде. Чишенеп, бит-кулын юып алган Гәбделсаттарны култыклап диярлек ак якка алып керде, аны урындыкка утыртып, сораштырырга тотынды:

— Әй, мелла Гәбделсаттар, Оренбур кадәр ерак юлдан килдең, ни хәбәр ишеттең вә белдең, сүләгел?!

— Каргалы халаеклары арасында сүләделәр: башкорт җәмәгатьләре киңәшкәннәр, берекәннәр, күтәрелерләрдер, дип.— Гәбделсаттар түгәрәк кара сакалы белән уйный-сыйпый шулай диде.

— Вә дәхи бер-ике кешедән яшеренлек вә яшермәк шарты белән ишеттем ки, Ягкуб первутчик андагы мөселманнарга ярдәм итмәкче икән...

— Кайчан кузгалмакчылар соң?

— Берәү әтте: быел булмас, диде. Киләсе җәй күк ут вакытында, атлар туенгач, диде.

—Ал-ай...

— Әлхаль Оренбурдан килгән чагында Казан юлы мишәрләреннән Сәфәр вә Тирмә авылыныкылардан сорадым: «Сез ни хәлдә торасыз»— дип. «Халаеклар купса, алар тарафында булырмыз»,—диделәр.

Боларын ишеткән иде инде Батырша, сүзне башкага борды:

— Ибраһим вә Гәбделсәлам ахуннар ни хәлдә?

— Әлхәмделилла, бик хуш торадыр, хәзрәт. Сәңа сәлам вә хат юлладылар: тиз көндә үзе килеп чыксае, диделәр.

Ул җиләне кесәсеннән шомарып беткән кәгазь төргәге алып килде һәм муллага бирде. Тегесе исә хатны әйләндергәләп карады, аннан горфиә акча белән басылган мөһеренә текәлеп торды да:

— Каргалыга тизме кайтырсың?—диде.

— Ауылда биш-алты көн торырмын, ахры.

— Хубдыр. Каргалыга бергә барырбыз. Вә дәхи, мелла Гәбделсаттар һәр тарафлардан хәбәрләр җыең! Вәләкин үзең сүзләшмәенчә, гайреләрнең сүзенә колак салып торгыл, вә ни хәбәр аңласаң, шуны безләргә белдергел.

— Иншә алла тәгалә,—диде Гәбделсаттар, авызын ачып исни-исни.

Батырша шәм яндырды. Остазбикә исә, шәүлә булып кына, өстәлгә тары боткасы кертеп куйды. Кунагы ашагана арада, мөһернең балавызын ватып, төргәкне сүтте Батырша һәм таныш кул белән язылган юлларга текәлде:

«Гыйззәтлү вә хөрмәтлү шәкертемез, мелла Баһадиршаһ! Безки Каргалы бистәсендә мәгыйшәт кылгучы дәмулла Гәбдел-сәлам ахун сезнең тарафларга күпдин-күп, чукдин-чук сәламнәребезне күндерәбез. Үзебез, аллага шөкер, исән-аман вә сезләрне дә шулай диеп беләбез.

Вә дәхи улдыр кем, үземезнең шәригатемездә мәхкүм улуб, байныярлыны вә дустны-гайрене вә карендәшләрне-ятны бер күреп, һичбер алым алмаенча китапларымызда боерылган вөҗһенчә тугрылык белән хөкем итеп, бәхәсләрне гайреләргә фаш итмәүең өчен галимләр вә гәүамлар, барча халаеклар сәне Себер юлы өстенә ахунлыкка куймакка теләделәр. Вәләкин ыстаршина Яныш үзенең әмеренчә булмаганы өчен, сәне теләмәенчә, аның үз әмерендә булырдай бер мелләне ихтиар итеп язу язды. Галимләрдән вә гайреләрдән кулларын куйдырып вә тамгаларын салдырып, ул мелләне Оренбурдагы ике ахун хозурына җибәрде. Динемездә ахунлык ни кагыйдәдә бирелә булса, шул кагыйдәчә ахунлык мәртәбәсе бирелер өчен. Вәләкин без, аны ахунлык мәртәбәсенә ләякатсыз күреп, буш кайтардык.

Вә аның соңында без ахунлар киңәштек: бу заманда галимләр арасында мелләә Баһадиршаһтан гайрегә ахунлык мәртәбәсе лаек дәгүл диб. Вәләкин сән Исәт правинчасына миһман булып киткәнсең, имеш.

Оренбур ахуны Ибраһим вәлинигъмәтләремез сәнең хакыңа ахунлык таныклыгы төзеб, мөһеренә басып, ул риваләне бән Гәбделсәлам ахунга бирде. Кул куеп, сәңа тәслим кылыр өчен. Ул рисаләне кабул итеп алгайсыз. Юл төшү берлә, безнең якларга килеб чыкуыңызны көтеб калгайбыз. Әлхасыйл, ошбу хатны алгуга, үзегезне ахун диб белгәйсез».

Хатның соңгы юлларын укып бетермәде, урыныннан торып, каршында кагаеп утырган Гәбделсаттарга урын-җир күрсәтте. Кеше ял иткәндә сураеп утыруны хуп күрмәде, утын сүндереп, үзе дә остазбикәсе янына караватка ятты.

Тик аңа бүген ансат кына йоклап китү насыйп булмаган икән. Ятуына күз алдына остазы Гәбделсәлам хаты килеп басты. Ләкин андагы сүзләргә сөенергә дә, көенергә дә белмәде мулла. Шатланыр иде, кальбе дин-шәригать дөньясыннан сүрелеп, мәгыйшәт казанында кайнаган чагы. Хафаланыр иде, ахунлыкның мәртәбәсе, абруе зур— тулы бер Себер юлындагы галим-голәмә, мулла-мунтагайга башлык булдың дигән сүз. Димәк ки, ахунлык таныклыгын алмый, муеныңа тагы бер камыт кими тору кирәк. Әйе, әйе, ике якның берсе ачыкланганчы, ятсын шунда, Оренбурда.

Шундыен ниятк килеп, күңелен урынына утыртмакчы булса да, йокы дигәнең каядыр китеп олаккан иде. Исенә Яныш старшина килеп

төште. Күр син ул юха еланны! Мулланың алдында ничек кенә юхаланмый да, ничек кенә төчеләнми. Тәүбә итә, имеш. Тфү! Ә артында аның ахун булуына каршы икән, хәсис. Әллә соң шул Янышка вә аның ишләренә үч итеп алыргамы ахунлык грамотасын?! Юк, кайнарланма, Батырша! Бар, күр, олуг ахуннарның үзләре белән киңәш. Расы шул булыр. Фикерен тәртипкә салып бетерүгә, оеп йокыга китте хәзрәт.

Оренбурга Гөбделсаттар белән үк китәргә уйласа да, әлеге сәфәре насыйп булмаган икән. Авылда ялгызы диярлек тынычлап калгач, мәдрәсәсе исенә төште. Сөмбелә үтеп баруга кармастан, кышлык утын әзерләнмәгән. Утын хафасы кара көзгәчә сузылды, дөньяның башка мәшәкать-шөгыльләре бер читтә торып калды. Мәгәр Батырша янына төрле-төрле тарафлардан килеп йөрүчеләр өзелмәде. Килгәне берсе дәртле һәм ашкындыргыч хәбәрләр ташыды. Һәр дүрт юлдан: «Коралларыбыз вә атларыбыз әзер — фәрман көтәбез»,— дигән сүзләр килеп иреште. Алай да Батыршаны куандырганы анысы түгел иде әле. Ниһаять, ул шикләнгән мишәрләрдән дә әйбәт хәбәр килеп җитте: «Тирәдәге башкортлар атларга атлансалар, без һәм атланырмыз!». Монысы инде төбәктәге барлык халаекларның берегүен раслаучы фал иде.

Дөнья мәшәкатьләре белән әвәрә килә торгач, кар төште — Оренбур сәфәре сузылды. Дөрес, барыбер атка менәргә туры килде килүен Батыршага, тик юлы Уфага иде монысында. Анда Котлымбәт морза килгән имеш. Мулланы янә йөрекче итеп сайладылар...

Шул ук кенсә ишек алды, шул ук болдыр. Тәвкилев кенә бөтенләй башка иде бу юлы. Йонтәс ак кашлары күзләре өстенә ишелеп төшкән, чырае яңгырлы көн сыман. Халаекларның тозны кальгалардан вә калалардан сатып алуга каршылыгы җенен чыгарган, йөрекчеләрне үгетләргә килгән, имеш.

— Юкка карышасыз, юкка маташасыз,— дип кычкырды ул, болдырга чыга-чыгышына.— Барыбер күнми булмассыз. Падишаһыбыз әйтсә, тозны гына түгел, суны да сатып алырсыз...

Аңа җавап итеп, алгы рәттәге ап-ак көҗә сакаллы берәү шөрран ярып үкереп җибәрде:

— Теләмәйбез! Алла биргән тозны сатып алмайбыз!

Тәвкилевнең сүзе бүленде. Ул, акрын гына кыймылдап, баскычтан төште дә әлеге карт алдына килеп басты. Янәшәсендә ике драгун күренде. Халык, ни буласын көтеп, тынып калды. Морза кинәт, егетләр җитезлеге белән, теге бәндәнең сакалын учлап алды һәм бер ыргым белән йолкып чыгарды. Аксакалның иягендә, эт талаган сыман, чи ит торып калды. Морза исә, берни булмагандай, янә болдырга менде һәм канлы сакалны баш өстенә күтәрде.

— Ахмаклар! — дип җикерде ул, ярсып.— Падишаһка каршы сүзләрегез вә гамәлләрегез өчен сакалларыгызны аз йолыктылар мәллә?!

Аңа сөйләп бетерергә бирмәделәр. Төркем, саламга капкан ялкындай гөжләп, шаулый башлады. Бар да нәрсәдер кычкыра, нидер әйтә, тик берәү дә берни аңламый иде. Ул да түгел, баш өсләрендә йодрыклар, чукмарлар бутала башлады. Батырша һич ни аңламый, башын иеп, ярсулы авызларны тыңлап торды. Кинәт колагы төбендә үк кемдер, хатын-кызныкыдай яңгыравык тавыш белән, кайнарланып тезергә тотынды:

— Котлымбәт морзаны белдекемез заманыннан бирле һәр елда ничә мәртәбә антын ишетәмез, Оренбур губернасы халаекларына падишаһның күп мәрхәмәтләре вә күп рәхимле указлары бардыр дип. Хәл бу кем, бүгенгәчә өстемезгә мәрхәмәт тамчысы таммыш юкдыр.

Зарны тагы да куәтлерәк авазлар күмеп китте:

— Йорт-җирләрне туздырдылар вә таладылар!

— Кыйнамак, сукмак, үлтермәк берлән җәфалар күрсәттеләр!

— Юк, чыдар әмәл калмады, ирләр!

Ул да түгел, болдыр ягында аллы-артлы мылтык шартлады — драгуннар куркыту өчен баш өстеннән аттылар бугай. Халык төркеме капкага ыргылды, күз-ачып йомганчы мәйдан бушап калды. Җыенның ахыры хәерле бетәр сыман күренми иде. Батырша йөгерә-атлый фатирына кайтты, атына атланды һәм Карышбашка таба чаптырып китте.

Уфага булган күңелсез сәфәреннән соң, ул бераз басылды, күңелен оланнарга сабак бирүгә утыртты һәм үзен дөньяның ыгы-зыгысыннан арынып калгандай тойды. Әмма бу тынгылык озакка сузылмады, көннәрнең берендә Уфадан указ килеп төште. Аңа Ирәктә иләүе старшинасы Шәрәф белән Уран вулысындагы Уртаулга барырга һәм күптән түгел дөнья куйган Султук старшинаның теркә малын китап хөкеме белән мирас ияләренә өләшергә кушылган иде.

Уртаул Карышбаштан нибары өч көнлек юлдыр. Мирасны бүлеп бирү дә алай озакка сузылмады — низаглар чыкмады. Алай да сәфәре сузылды Батыршаның. Мөхтәрәм миһманны һич кенә дә җибәрәселәре килмәде Гәйнә татарларының. Аш арты аш, өйдән-өйгә, авылдан-авылга кунакка йөрү башланды, гыйбрәтле сүзләр дә күп булды. Чынында шулары өчен тоткарланды да инде ул, үзенә кирәкле кешеләр белән күрешүгә форсат көтте. Ниһаять, кунак-төшем ыгы-зыгысы арасында җаен чыгарып, бер аулак өйгә Чурагол белән Исхак муллаларны, гаярь егетләрдән Акбаш белән Мостайны һәм тагы берничә кешене чакыртты. Шактый тәкатьсез, кызу канлы әзмәвер Акбаш, хәл-әхвәл белешүгә үк, бу як халкының уй-ниятләрен чәчеп салды:

— Безнең урман тарафлары гайәт тә пәһлуаннардыр,— дип башлады ул бераз масаеп.— Вә ук атарга осталардыр. Кырыгар-иллешәр тиенлек санай җәяләремез ялан башкортларының унар-егермешәр сумлык әдернә җәяләреннән артыктыр. Әдернә җәя эссе көндә егерме-утыз мәртәбәдән артык атмыйдыр. Безнеке ни кадәрле эссе көн булса да, атышкан җаен куәтләнә генәдер. Вә һәм чаңгы берлә йөрергә шул кадәр осталар — урман эченә качкан киек котылмыйдыр. Алларында аркылы яткан ат биеклеге агачларны аша сикереп чыгалар. Юлдан килгән ат чаңгылы кешеләремезгә җитмидер. Урман халкы пәһлуанлыкта алан халкы булмас имди. Инде бу хәлдә кяфернең җәфалары чиктән ашты. Алла әгъләм, киләсе җәйдә шәйәт дәхи яу кырында булырмыз!

Ошбу нотык күңеленә сары май булып ятты Батыршаның. Бу сүзләрдә ул Гәйнә татарларының басқынчы Каракошка нәфрәтләрен дә, хәлиткеч яуга әзерлеген дә, җиңүгә ышанычын да күрде.

Мәгәр барыбер йөрәгендә тынгылык юк иде гыйсьянчы мулланың. Татар тотып карамыйча ышанмый шул. Әлеге дә баягы теркә малын мирас ияләренә бүлеп бирү сылтавы белән, башта Гәрәй иләүен урап кайтты, аннан Күдәй якларына юл тотты. Йөргән бер җирендә теләктәшләр тапты. Халыкның чиксез нәфрәте боланың уңышына ышаныч уята иде. Тик... төп узаманлыкны кем башкарыр? Яу башы кем булыр?..

## Бишенче бүлек

Батырша шулай авылдан-авылга, иләүдән-иләүгә йорт-җир арасында халыкның уй-ниятен белеп, тын алышын тыңлап, ишеткәннәрен күңеленә салып һәм җае белән сак кына кешеләрне яуга өндәп, шуңа әзерләү белән әвәрә килеп йөргән мәлдә 1754 ел үтеп тә китте. Тиздән — нәүрүз. Хәзергә исә, шөкер, һәр тарафта иминлек, йот-ачлык җәфасы да бәндәләрдән читтәрәк йөри. Иншалла, елның тулысынча кулай булып куюы, халаекларга җиңү китерүе бар.

Ул үзалдына уйланып утырганда ак якка тавышсыз-өнсез генә остазбикәсе килеп керде һәм Батыршаны хыялларыннан аерды:

— Сиңайтәм, тагы бер бәндә килгән анда, сәне сорый... Җыен өтрәк-әләм артыннан пычрак җыюдан бушыйсыларым юк икән...

Зөлхәбирәнең моң-зарын гүя ишетмәде дә. Йокымсырап торган күзләре зур ачылып, җанланып китте, үзе дә сизмәстән аягына басты:

— Әт, керсен!

Бәләкәй гәүдәле берәү килеп керде. Бозланып катуына карамастан, чем-кара булып күренгән сакал-мыегын искә алганда, инде ир уртасы булып җитсә дә, бөтен кыяфәте малай-шалайныкы иде юлаучының.

Батырша мич буендагы утыргычка ишарә ясады:

— Кем сән, ни җирдән сән?

— Нугай юлы Кәлчир иләүенең Исмәгыйль дигән буламын,— диде кунак, гәүдәсенә ятышып торган хатын-кыз тавышы белән.

— Кая барасың?

— Әй буена, үз йомышым белән,— диде бәләкәй бәндә, куенына тыгылып. Маташа торгач, аннан изелеп-тәпәрләнеп беткән букча чыгарды һәм аны муллага сузды.

— Бу язу кемнән?

— Укысаң, мәгълүм булмасмы?

Язуда аңа, мелла Баһидиршаһка, Мөхәммәт пәйгамбәр хәдисләренә тугры булып, халаекларны аллаһ хакына, динебез хакына туплау, аларны кыздыру һәм яуга күтәрү эше йөкләтелгән иде. Сүз дә юк, хатны язучы гыйлемлектә камил кемсәдер, ихтимал, Гәбделсәлам ахундыр. Тик язуы анык тугел, ят кул. Ниткән дә булса этлек, яманлык юкмы монда? Батырша тын гына утырган кунагына борылды:

— Әй, Исмәгул, бу язудан мәгълүм улмайдыр, һич кешесенең исеме юк. Аны сәңа кем бирде?

— Бән язу танымаем шул, хәзрәт. Мелләмез илә писарымыз Оренбур тарафына барып йөрделәр. Бу язуны бәңа бирделәр, сәңа тапшырыр өчен. «Үзе укыгач, тиз үк төшенер»— диделәр.

Батырша аңа карап-карап торды да, кычкырып җибәрде:

— Сән вур икәнсең! Сез явызларны тотып богауларга кирәк!

Юлаучы сабый баладай мүкәләп, мулланың аягына баш орды:

— Әйа вәлинигъмәт, сәнең мөбәрак атыңны, олы абруеңны ишеттем. Хаҗилар кәгъбәне күрергә мохтаҗ булган күк, йөзеңне күрергә зар булып, ерак җирдән шатланып килдем. Ахыр чиктә бу язуны кабул итмәсәң дә, бәңа рәнҗү ирештермә?!

Батырша чапкынның тәкрарлавын тыңлый-тыңлый, аңа кызганып карап торды.

— Тор, әй, сөекле, уйнап кына әтәмен.— Мулла ашыгып кесәсенә тыгылды һәм аннан биш тиен бакыр акча алып, аны аягына торып баскан юлаучыга сузды.— Мә, юлыңа булыр.— Аннан ашыгып урта ишекне ачты.— Остазбикә, миһманның тамагын туйдыр!

Бүлмәдә ялгызы калгач, ул янә тәрәзә буена килде, хатны тагы бер кат укып чыкты. Хатны язучылар, ачыктан-ачык әйтмәсәләр дә, уратып-уратып, аның алда торган яуга әзерлекнең бөтен мәшәкатьләрен үз җилкәсенә алуын, халаекларны кыздырмак вә егетләмәк эшенә керешүен, ниһаять, болага узаман булуын үтенәләр иде.

Батыршаның бу хәтлесен исенә кертеп тә караганы юк иде әле аның. Хак, ул бөтен вөҗүде белән инкыйлаб яклы, туган җиренең — бар Идел-Урал тәягенең хөррә улуын тели. Шуңа өлешем керсен дип, баргган-йөргән җирендә халаекларның уй-ниятләрен белеште, тегә яисә бу аймакта яу башлыгы булырдай гаярь бәндәләрне ачыклады, алар белән киңәште. Баксаң, боланың узаманы юк, имеш. Югыйсә Гәбделсәлам ахун (Батырша хатның нәкъ менә анык булуына һич кенә дә икеләнми) турыдан-туры аңа мөрәҗәгать итмәс иде.

Хуш, ул кулыннан килгән кадәрен эшләр. Әйтик, каурый каләмен алыр, халаекларга егетләмәк вә кыздырмак хатлары язар. Кирәк икән,

җае чыккан саен, теле белән дә мәдәт итәр. Ул гына да түгел, һич сукранмый иләүдән-иләүгә, төбәдән-төбәгә йөрер, бәндәләрне туплар, көрәшкә чакырыр. Әмма кулына сөңге-кылыч, җәя-ук алып, яуның башына баса алырмы? Хагын әйткәндә, анысына үзе дә шикләнә. Шундыен зур төбәктә бетмәгәндер андый гали вә һиммәтле җаннар. Сәет-Килмәкләр, Җангалиләр, Алдар-Күчемнәр, Карачуралар табылыр алар, табылыр! Хәзергә исә ул кулыннан килгәнен эшли тора ала...

Шул көннән Батырша үзенең ак өенә кереп бикләнде. Өстәлендә кәгазь бите белән каурый каләмнән һәм эт шомыртыннан ясаган карадан гайре нәрсә заты юк. Әмма язмый мулла, көннәр буе алдындагы кәгазьгә карап, уйланып утыра. Бу хәлдән тәмам тәшвишкә төшкән Зөлхәбирә урта ишеккә килеп-килеп караса да, аны ачарга җөрьәт итми. Ходаем, әллә соң чирләп-нитеп киткәнме, җәен-кышын юл йөри, өйгә кайткан арада да әллә кемнәр белән әвәрә итә торгач, гакылына җиңеллек килгәнме? Бу хәлдән коты очты Зөлхәбирәнең, икеләнүләрен онытып, ак өйнең ишеген какты:

— Сиңайтәм,— диде ул тыныч кына,— нишләвең инде бу? Комгандагы су суынды, токмачым куерып бетте. Ашап-эчеп, намазыңны укып аласың мәллә?

Халаекларны кыздырмак вә егетләмәк хатын тиз генә язып ташларга ниятләгән иде мулла. Үз гомерендә санап очына чыгышлы булмаган вәгазь укыды, сүзгә кеше кесәсенә кермәде. Алай да мәчеттәге яисә табындагы бер төркем кешегә үгет-нәсихәт укуы бер нәрсә, ә менә Рәсәйнең яртысыннан күбрәгенә диярлек чәчелгән мөселман агай-энегә җитди сүз әйтүе бөтенләй башка нәрсә икән. Арада булыр укымышлысы, булыр хәреф танымаганы. Димәк ки, бәндәләрнең барысы да аңласын өчен сүз-гыйбарәләре бик тә садә булырга тиеш. Шул ук вакытта алар һәркемнең йөрәгенә төшеп, укучыларны гайрәтләндерсен, дәртләндерсен, кыздырсын. Шунысы да бар, аны беренче нәүбәттә галим-голәмә укыячак бит әле. Эчтәлектәге кара сүзләрдән көлмәсләрме алар, садәлекне беркатлылыкка санамаслармы?!

Шөкер, каурый каләмне тәүге тотуы түгел. Моңа хәтле язган хатларын, рисаләләрен вә башка язуларын укыган бәндәләр аларны бик тә камил һәм хиссиятле дип таба торганнар иде. Аны шикләндергәне вә гаҗизләндергәне — башка нәрсә. Халаекларның күпчелеге алда торган яуны ислам дине өчен җиһад дип саный һәм Мөхәммәт пәйгамбәрнең яшел байрагы астына тупланырга ниятләнә. Батырша үзе һәм аның тарафдарлары исә, мөэмин-мөселманнарны төрлечә кысу-изү, мыскыл итүләргә бөтен вөҗүдләре белән каршы булган хәлдә, боланың дин хакына гына кубуы белән чикләнәселәре килми. Аларча, ачулы халаеклар явыз Каракошны юк итәргә тиеш. Димәк ки, халаекларны зәхмәтле Каракошка каршы көрәшкә чакыру ислам дине өйрәтүләренә капма-каршы булып чыга. Бу исә берәүләрне икеләндерәчәк, хәтта өркетәчәк. Шуннан инде мәгълүм буладыр ки, төп максатны шәрәләндермәскә, аны дин пәрдәсенә төрергә шулай итеп, халаекларның хәерхаһлыгына ирешергә кирәк.

Остазбикәсенең ишекне тагы шыгырдатуына сискәнеп, Батырша башын күтәрде, тәрәзәгә бакты. Караса, кичке эңгер-меңгер төшеп килә. Шунда гына башының чатнап-чатнап алуын тойды. «Бүгенгә җитәр» — дип нәтиҗә ясады ул һәм, урыныннан торып, алдагы якка чыкты. Ашыйсы килмәсә дә, ян сәкегә утырып, инде суына башлаган бәлешне капкалады.

Вакыт дигәнең Батыршаны ашыктыра иде. Әнә, кояш тәрәзәгә көннән-көн турырак карый, дранча һәм кабык түбәләрдән тамчылар тама. Беркөнне исә тәрәзә каршындагы читән казыгына килеп кунган кара карганы күреп, тәненнән яшен ташы узгандай булды. Ул кабаланып каләмен карага манды һәм ашыга-ашыга яза башлады: «Мин, Абдулла Мәзгытдин, бар вә бер алланың һәм пәйгамбәребезнең мөр-

хөмәтенә өмет итеп вә аның сәхабәләре юлын дәвам итеп, сезне, Рәсәй мәмләкәтендә яшәүчеләрне вә хыянәтче йомышлы урыслар тарафыннан һәртөрле мәкерлекләр вә фетнәләр күреп кимсетелгән, чиктән тыш алҗыган хак диндәге бәндәләрне болай дип үгетлим...»

Батырша, каурый каләменең очын авызына кабып, уйланып калды.

Ие, саный башласаң, җәлладларның кыргыйлыклары хәттин ашкан. Алай да барын тәфсилләп тору кирәкмәс, явызлардан күргән җәбер-золым, кан-яшь, кайгы-хәсрәтне искә алып үтү дә җитәр. Иң мөһимен — кяферләрнең хак диннән колүләрен, ул гынамы, бәндәләрне көчләп үз диннәренә аударуларын, исламны, мөселманнарны мәсхәрәләп, үз диннәрен көчәйтүләрен әйтергә кирәк. «Китапларда язылганча һәм күрсәтелгәнчә, безнең бабаларыбыз болгарлар бер диндә булып, бердәм иделәр һәм попларга табынучыларны үз җәмгыятьләренә дини өйрәтү юлы белән генә кертә иделәр».

Юньле кеше бүтәннәргә динен-әхлагын түгел, уй-фикерен дә көчләп такмый. Болар исә, Оренбур салынганнан бирле, ни кыланганнарын белмиләр, халаекларны мылтык-кылыч берлә куркытып чукындыралар, чирү көче берлә муеннарына тәре асалар. Хак булгач, нишләп әле аны һәркемгә тигәнәк урынына ябыштыралар?! Вә дәхи,— дип язуында булды мулла,— ул ислам диненнән чыкарылганнарның ясакларыны вә һәм үзгә хезмәтләрне калган мөселманнарның өстенә салдылар. Ул мөселманнарны диннәрендә торган өчен, анларны хур күреп, элек-электән өсләренә тиеш булмаган йөкләрне йөкләделәр, анларның дин вә дөньяларына тарлык вә авырлыклар җитешсен дип...»

Шул урында ул үзен урманның иң чытырманлыгына килеп кергәндәй тойды. Вакыйган, тәзкирнамәнең гаять тә четерекле җиренә җиткән иде. Ясакны патшаның наибләре, урыс түрәләре билгеләсә дә, аны җыеп алучылар һәм салым-алым эше йорткәндә әллә ниткән башбаштаклыклар уйлап чыгаручылар, халаеклардан тиешеннән артыгын талап, баеп ятучылар мөселман старшиналары лабаса! Бәс шулай икән, телисеңме-теләмисеңме, иләү агаларына да тел тидерергә туры килә.

Ул каурый каләмен карага манды һәм ярсып язып китте: «Бәгъзе ыстаршиналар бинипһая залимлекләр илә халаекларның малын җыеп вә исерткечләр эчеп вә адәмнәрне кылыч белән чабып, кулларыны кисеп, моңа охшаш хәтсез җәфалар кылдылар».

Җөмләсен төмамлады да урыныннан торып ук китте, киез катасы белән йомшак басып, ишекле-түрле йөрергә тотынды. Ие, мөртәтләр һәр заманда булган һәм булып кына тора. Ул сатлык җаннар турында хак сүзне бәндәләргә җиткерми ярамый...

Мулла инде көннәрнең санын югалтты, исемнәрен онытты, башын күтәрми язды да язды. Инде, шөкер, хатының иң четерекле, фәлсәфәле өлеше төмам бугай.

Әйа, ял итеп алу насыйп булмаган икән. Төнката миендә кайнаган уй ташкыны, иртәнгә якта гына бер тәртип алып, шулкадәр ачыкланган иде ки, иртәгәсен ятагыннан торуына каләмен кулына алды һәм яңа көндәге беренче җөмләсен сырлады: «Югарыда язылганнардан чыгып, сез хак диндәгеләргә вә бер аллага ианучыларга ни-нәрсәләрдән вә ниткән хилаф эшләрдән тыелырга киңәш итәм соң?»

Калганы инде һич көчәнүсез һәм тыелгысыз акты да акты: хак диннәреннән язган кяферләр белән килешүдә булмаска, үз мөэминмөселманнарыбызның йорт-җирләрен туздырмаска вә аларның канын коймаска, малларын таламаска вә үзләрен кол итеп әсирлеккә алмаска. Янә дә килеп, кяферләрнең үзебезгә кул күтәрүләренә юл куймаска, мөртәт ыстаршиналарның җаннарын җәһәннәмгә олактырырга...

Кисәк каләме төртелеп калгандай булды, кулыннан ук төшеп китте. Туктале, ул бит ничә еллар буе, төрле авылларда имамлык кылып, мәдрәсәләр тотып, угланнар укытып вә яман гамәл-шөгыльләрдән тыеп

торды. Хәзер исә шуларның киресенә, хәтта кем бирәүләрнең канын коярга чакыра түгелме? Адәмнәр ни әйтерләр моңа, Бәһадиршаһ хәзрәт икейөзле димәсләрме? Бәндәләр бит бөтенләй үк томана түгелләр. Көн буе утырса утырды, мәгәр дин дошманнарына каршы кул күтәрүнең һич кенә дә гөнаһ булмавын исбатлады.

Нәүбәттәге көнендә ул эшен янә тыныч күңел белән башлап җибәрде, онытылып һәм бирелеп язуын дәвам итте: «Сез, бер аллага ихластан инанучы чын дусларым минем, тырышыгыз, тырышыгыз, тырышыгыз! Чиру атлары вә корал хәзерләгез, кылыч-сөңге, җәя-ук вә шуңа охшаш кирәк-яракны мөмкинлегегез барынча әзерләгез һәм алла боерыгына буйсыныгыз: хак тәгаләдән мәдәт сорап, яңа өмет вә ышаныч баглап һәм дә аның катына пәйгамбәребез Мөхәммәт рәсүлуллаһны юллап, теге кяферләрне кыйрата башлыйбыз. Ул зөбаниларны җиребездән куып, йорт илебездә мәчет-мәдрәсәләр гыймарәт кылырбыз, хак динебезне ныгытуны кайгыртырбыз...»

Җөмләсен тәмамлады да янә уйланып калды. Халаекларны яуга күтәрелергә чакыра чакыруын, тик моның өчен югарыда язган сәбәпсылтаулар гына аз, дәлилләр җитәрлек түгел сыман тоелды аңа. Боланың хаҗәтлеген раслап тагы ни дә булса әйтәсе килде ... Ә, әйе, кан-кардәшләребезне зөбанилар тырнагыннан коткару хакында. Чыннан да, Казан, Сембер һәм Зөя өязләрендә биш меңләп адәм, бәлки аннан да артыграктыр, кяферләрнең җәбер-золымына түзә алмыйча, алар диненә күчәргә мәҗбүр булды. Ул бахырлар бездән ярдәм көтә, мескеннәрне коткару фарыз эш. «Сез,— дип мөрәҗәгать итте ул диңгездәй губернаның әллә кайдагы аймакларында яшәүче инсаннарга,— динебезнең башлыгы Мөхәммәт пәйгамбәрне дошман күрүче кяферләр безгә дуслык кулы сузарлар дисезме?! Аң булыгыз, алар Болгар калаларын вәйран иттеләр, хак дин юлындагыларны кырып бетерделәр, мәчетләрне җимерделәр, алар урынына чиркәүләрен гыймарәт кылдылар: үзләренең сафсата диннәрен тарату өчен. Ниһаять, безнең авылларыбызны да болай гына калдырмаслар, Болгар иле хәленә төшерерләр.»

Шулар хакында яза торгач, кан-кардәш халыкларның уртак җәфаларына, салым-алымнарга, төрле җыемнарга, ниһаять, инсаннарга ходай үзе биргән тозны да сатып кына алдырачакларына кереп киткән икән: «Исегездә тотыгыз, йомышлы урыслар безне көннән-көн кыса барып, кыргыз-кайсаклар белән дошманлаштырып, үзара кан түктереп, ике арабызда булган татулыкны һәм килешүне бозарга телиләр.»

Әй, Батырша, Батырша! Хатыңның губернатор Неплюев кулына барып ирешәсен, аның казакъларны башкортларга, ә соңгыларын беренчеләренә каршы котыртып, канкардәшләр арасында суеш-кырылыш чыгарачагын, татарлар белән башкортлар арасын бозуда да кулланасын белгән булсаң, әлеге җөмләне язмас та идең, шәт?!.

Исәбенчә, әйтәсе сүзләр әйтелеп бетте бугай. Яуның вакытын гына бәян итәр дә... Ләкин һаман да нидер җитми, нәрсәдер сөйләнми кала сыман. Ә, ие, инсаннарны дәртләндереп, илһамландырып, егетләндереп тә җибәрергә кирәк! «Сез, бер аллага табынучы яшьләр һәм картлар, җайдаклар вә җәяүлеләр,— дип дәвам итте мулла, ашыга-ашыга,— тизрәк туплаunion һәм озын-озакка сузмый кузгалыгыз. Ул кяферләрдән куркып калмагыз, бер аллага өмет баглагыз. Аның кодрәте илә явызларны тар-мар итәрбез. Сез, исламны яклаучылар, без хак диндәгеләр аз, кяферләр күп дип, шикләнеп-шөбһәләнеп калмагыз тагын. Аллаһ тәгалә кимсетелгәннәрне яклар. Аның рәхмәте белән хак динебез юлында күп санлы дошманны да җиңәрбез!...»

Халыкны дәртләндерү өчен тагы ни дә булса әйтергә кирәк иде... Әһә, шуны да белсеннәр: кыргыз-кайсаклар да безнең белән бер сүздә. Мөселманнар яши торган бүтән кала-салалардан да кяферләргә куркыныч яный.

Боларын да җаен-җайга китереп теркәп куйгач, төп сүзгә күчәргә булды. Монысы инде күптән башында йөри иде, һич тоткарлыксыз тезеп китте: «Әссәламегаләйкем вә рәхмәтуллаһ! Хак дин юлындагылар ишетегез һәм белегез: бән, Абдулла Мәзгытдин, һәр дүрт юл халкының уй-ниятен белешеп абызлар вә галим-голәмә белән киңәш тотканнан соң, шушы 1168 елның күк ут вакытында, ягъни чиллә аеның берендә, ураза бәйрәменнән соң кузгалырбыз дип торам. Пәйгамбәребез юлына тугры булып, хак тәгалә боерыгын үтәп, шул көнне кяферләрне кыйрата башлыйк!»

Барыбер нәрсәдер җитми, иң кирәге әйтелми кала сыман. Вакыйган, ахырга нидер кирәк бугай. Якты өмет, җиңүгә зур ышаныч бөркеп торсын! Ниһаять, йөзенә нур бөркелде, атылып өстәле янына килде, кәгазе өстенә иелеп, ашыга-кабалана хыялын язарга тотынды: «Шушы көннәрдә генә Төркиядән солтанның куәтле гаскәре Әчтерханга килеп төште. Кяферләргә каршы тору һәм аларны кыру өчен. Вә һәм аларның яңадан-яңалары килә тора, дигән хәбәрләр ишетелә».

Монысы инде чеп-чи ялган иде. Мәгәр халаекларны кузгату вә егетләндерү өчен анысы да кирәк. Изге максаттан чыгып ялганлауның гөнаһы юк, диләр бит.

* * *

Зөлхәбирәнең кулыннан эш төште. Башка елларда, көннәр язга авышып, кояш туры карый башлауга, бәйгегә өзерләнгән чаптар сыман, кая басканын белми торган иде. Кышкы көннәрен казан тирәсендә һәм иртә-кич мал-туар янында үткәргән булса, хәзер исә йомышы бармыюкмы, амбар тирәсенә чыгар, чәчүгә дигән орлыкларны кат-кат карартикшерер: чиннеккә кереп, хезинәдә бар кадәр дирбияне барлар, аларны рәтләү-төзәтү хәстәрен күрә башлар. Кулына агач көрәк алып, сабан-сука, тырма ише нәрсәләрне кар астыннан чыгарыр, аларны «әнә күзеннән» үткәрер, шуннан инде ишегалдында һәм ындыр тирәсендә аның боерулы авазы яңгырар:

— Яхъя олан, тимерче Ычтапанга барып кайтырга кирәк!

— Колчура дим, анау тияклөрнең тарткыллары черегән...

Монысы әле карлар эреп, басулар ачылганчы шулай. Инде җир кибеп, сукага төшәр чак җиттеме, кырдан кайтып керми. Хак, үзе җир сукаламый, ашлык чәчми Зөлхәбирә. Мәгәр көнозын буразнада кайнашкан Яхъя белән Колчураның өсләреннән төшми. Җир башындагы калкуырак урынга — яшь үлән борынлап килгән җиргә учак ягып җибәрә, егетләрнең ашарларына пешерә. Ашасыннар, эчсеннәр — ашаган малда өмет бар. Һәм, әйтергә кирәк, егетләр остазбикәгә бурычлы булып калмыйлар, сөрү, чәчү һәм тырмалау эшләрен авылда беренчеләрдән тәгәллиләр.

Быел исә аңа әллә ни булды. Инде кояш көннән-көн биегрәк күтәрелеп, кыеклардан тамчы тама, тиздән ташу да кузгалыр. Ә ул исәр кешедәй өй эчендә әйләнеп йөрүдән узмый. Мулласының һич уйламаганда-көтмәгәндә ак якка кереп бикләнүе ушын алды аның. Башта Зөлхәбирә бу хәлне картының чираттагы бер сөерлеге дип кенә уйлады һәм моңа игътибар итмәскә тырышты. Әмма атна үтте, икенчесе узды, өченчесе башланды, ире исә һаман да ябылып ятуда. Ярый әле, бала дигән газиз җаннар бар доньяда. Ябылуыннан чыккан арасында, оланнар өйдә булса, гел үзгәреп китә Батырша, айлар буе күңелен кимереп торган хафаларын оныткандай була. Балалар белән элеккечә уйнапшаярып ала, көлкеле сүзләр әйтеп аларны чыркылдата. Әмма күпкә түгел, сабыйлар белән гөрләшкән җиреннән кисәк кенә сүзсез кала, чырае караңгыланып китә һәм өлеге ялгызлыгы кочагына ташлана, янә сәгатьләр буе өстәле янында уй диңгезенә чумып утыра. Ходаем, әллә

соң бер-бер олы кайгысы, берәүгә дә әйтергә ярамый торган хәсрәте бармы? Шуны төпченим, бергә-бергә сагышларын җыйнәләйтим дип, берничә мәртәбә сыза гына урта ишекне ачты, сүз кузгатып карады Зөлхәбирә:

— Сиңайтәм...

Тегесе исә сүзне әйтеп бетерергә дә бирми, хатынына усал итеп бер карый да кулын селтәп куя. Комачаулама, янәсе.

Шул сәер хәлләрдә ике айлап вакыт үтте, картының сәерлеге һаман сузылгач, бөтенләй коты очты Зөлхәбирәнең. «Ходаем, әллә соң ныклап сырхаулавы шулмы?» — дип өзгәләнде. Алай дисәң дә, зарланмый-ыңгырашмый, тамагына да ярыйсы гына каба. Әллә соң акылга җиңеләюе шулмы?

Алай дип шикләнсәң дә гөнаһка гына батуың бар. Саташкан-диваналанган бәндәгә бер дә охшамаган карты. Ниткән дә булса китап, кыйсса-мазар яза торгандыр. Алайса, нишләп дөньядан тәмам ваз кичәр? Бер ачылмаса, бер ачылыр, киңәшер, сөйләшер иде бит. Әй, баш ваткан була тагы. Бизгән ул Зөлхәбирәдән. Яратмый бугай аны мулла.

Дөрес, Зөлхәбирә үзе яратуның ни икәнен белмәде, сөеп-сөелеп очыну ләззәтен татымады. Хәер, әгәр дә ярату кемне дә булса якын итү икән, андый кешесе бар иде аның туган ягында — атасыз-анасыз, йортсыз-җирсез һәм туган-тумачасыз бабул Габделҗаббар. Егет иләү агасының елкыларын көтә иде. Хак, Габделҗаббарны ул нибары ике күрде. Берсендә, атасына ияреп, ни йомыш беләндер Мөслим старшинаның атлар өеренә баргач, икенче мәртәбә — үзләренең авылларындагы сабан туенда. Зөлхәбирә аны тәүге күрүендә үк үз итте. Мәгәр аларга кавышу түгел, икәүдән-икәү очрашу да насыйп түгел икән. Шул җәйдә егетне, Мөслим старшинага кизәнгән өчен, каядыр еракка катргa олактырдылар.

Батырша муллага ул атасы кушканга гына барды. Үкенмәде тагы. Батырша аны какмады-сукмады, шул ук вакытта иркәләп-назлап та тормады. Башка киленчәкләрнең сөйләүләреннән белә иде югыйсә Зөлхәбирә: кичләрен печәнлектә яткач, яисә кырда-урманда аулакта калгач, аларны ирләре сөеп-назлап туймыйлар, имеш. Битләреннән генә түгел, чәчләреннән, муеннарыннан үбәләр, иреннәренә капланып исерәләр, тонкага йокы бирмиләр, ди. Әлеге сүзләрнең күпмесе дөрес булгандыр, мәгәр үз иренең алай ук кыланганын күргәне юк остазбикәнең. Хак, аларның да бер-бере кочагында эреп, дөньяларын онытkан чаклары булгалый. Тик әлеге киленчәкләр әйткәндәй, җай чыккан саен түгел...

Әй, аның ни, бигрәк тә әллә ниткән бәндә булып чыкты Батыршасы. Һич кенә дә дөнья көтә белми. Мал дими, акча дими, йортка һич күңел куймый. Хәер-сәдакага да исе китми, ярлылардан исә бөтенләй берни алмый, ул гынамы, еш кына үзе өләрны бүләкли. Башкалар тләү агасыннан бер көлимә яхшы сүз ишетергә мохтаҗ булып, аның янында юргалап йөргәндә, бу тилемсә өенә килеп кергән старшинага да якты чырай күрсәтми. Юк, һич кенә дә яши белми мулла. Йа алла, уңмады ул ирәннән, уңмады.

Үзе гаепле, үзе Зөлхәбирә. Шаулап яз килә, ә ул һаман дуадак каз сыман кая барып бәрелергә белми йөри. Ирем бикләнеп ята дип, дөньядан ваз кичеп булмый бит инде. Ходаем, инде сабанга төшәр чак җитеп килә, хуҗалыкта исә корал-дирбияләр, башка кирәк-яраклар каралмаган. Колчурасын тиз генә табып булмас инде, анысы мич башында йоклап ятадыр байгыш. Ә менә Яхъя мәдрәсәдәдер. Зөлхәбирә кызулап өеннән чыкты һәм ишегалдында кар әвәләп маташкан Таҗикка эндәште:

— Улым, бар, мәдрәсәне урап кил. Яхъя абыеңа әйт: килсен!..

Ул арада Таҗик әйләнеп кайтты, аның артыннан ук йөгерә-атлый килүче Яхъя күренде.

— Ни бар, абыстай? — диде ул, килә-килешкә.

— И-и-и, Яхъя, ни йомыш дип, яз җитте ләбаса. Безнең исә сукалар да көйләнмәгән.

— Күздән каралган алар, абыстай, борчылма!

Шыгырдап ишек ачылды, болдырда мулла күренде.

— Әйа,— диде ул, көр тавыш белән,— замана ахырына каршы кемне уйласаң, шул каршыңа чыгар, имеш. Син кирәгиең, олан.

— Үземнең дә сине күрәсем килеп йөри, хәзрәт. Шәкертләр сабактан тәмам туйдылар. Чәчүгә төшәр чак җитте, дип шаулашалар.

— Тукта, кабаланма. Сүзең хак, таралсалар да буладыр. Вәләкин рөшди сыйныфлар калып торсын!

— Әнә шуларны йөдәтәләр дә инде, хәзрәт.

— Чәчүләре качмас. Утыр әле! Тыңлаң, ошбу тәзкирнамәне күп итеп күчереп язарга кирәк. Аңлат үзләренә: унны күчергәнә бере авылына китә торыр.

— Б-бу б-бит б-бик күп, хәзрәт.

— Әйт: тизрәк кайтасылары килсә, төнлә дә язсыннар!

Мулла белән бәхәсләшүнең урынсыз икәнен белә Яхъя. Кулъязманы алды да китәргә ашыкты.

— Тукта, кабаланма,— дип туктатты аны Батырша,— эшнең зурысы алда әле. Казан өязеннән килгән Исмагул урысча яза белмиме?

— Юк, хәзрәт, юк. Андый эшне белүчеләр каян килсен?!

Мулла сүрәнләнеп, уйланып калды. Шәкерте чыгып киткәч кенә аягына калыкты һәм ишекле-түрле йөрергә тотынды. Миендә исә һаман бер уй бөтерелә иде. Димәк ки, бар ышаныч — Кузьмада гына. Батырша кызулап алдагы якка атлады, ишеге белән Зөлхәбирәсен бәреп ега язды.

— Остазбикә, шайтан суы кирәк!

Ике айдан бирле иренең авызыннан юньле сүз ишетмәгән хатын шатлыгыннан кычкырып җибәрә язды. Шөкер, исән-аман! Әмма шунда ук шикләнеп, тыелып калды. Әллә соң тик торганнан хәмер эчәргә җыенамы бу? Шул гына җитмәгән ие тагы. Әй, эчсә эчсен генә, тик исән-сау булсын да, элеккеге хәленә генә кайтсын.

— Сабан туенда Колчурага дип саклаган нәрсәм бар,— дип ычкындырганын сизми дә калды Зөлхәбирә.

Бераздан инде кулына киҗеле ашъяулыкка төрелгән чүлмәк тоткан Батырша эре-эре адымнар белән Чуртанлыкүлгә атлый иде.

Кузьма, знакумын сагынганмы, кунакның кулындагы төенчеген күргәнгәме, бик шат иде:

— Матрена, куас китер! — дип ашаяк ягына кычкырды.

— Миндә катырагы бар,— диде Батырша, төенен өстәлгә куеп.

Кузьманың авызы ерылды, хәтта көеп-саргаеп беткән сакал- мыегына кадәр елмая иде. Җәһәт кенә үрелеп, тәрәзә төбеннән ике йомры алды.

— Егет кеше дә инде үзең, Батыршаһ!

— Әйдә, салып куйгач мактарсың.

Шулай дисә дә, сүзне үзе дәвам итте мулла:

— Сине, знакум, сер сыяр бәндә дип беләм.

— А как же,— диде тегесе, авызында ипи катысы әвәләп.— Татарлар ничек диләр әле? Егет кешенең йөрәгендә җигүле ат ята диләрме? Менә монда,— ул кулы белән күкрәгенә сугып алды,— әллә нинди секретлар ята, Батыршаһ.

— Алайса, тыңлаң: без бит күтәрелергә булдык.

— Ничек күтәрелергә? Кем ул «без»?

— Без дигәнем — төбәктәге халаеклар. Түрәләргә каршы яу чыгарга ниятләдек.

— Ай-хай, Батыршаһ, булыр микән?! Оренбурда гына да меңәрләгән солдат. Хур булырсыз.

— Без дә аз түгел. Янә дә килеп, алар күп булганга, сеңа килдем дә бән, Кузьма. Завутлардагы кара урысларны да кузгатасы иде. Шуларга хат язып бир сән бәңа! Үз телләрендә.

— Андый нәмәләр язган юк шул, Батыршаһ.

— Ни язасын үзем әйтеп торам. Сән урысчага гына аудар!

Кузьма тынып калды, салмак хәрәкәтләр белән чүлмәккә үрелде, йомрыларга эчемлек койды:

— Булмас, Батыршаһ. Төрле халаекларның бердәм кузгалуларын хәтерләмим мин. Дөрес, Разин Степан явында урыслар белән бергә татарлар, чуваш-мукшылар да сугышкан, диләр. Белмәем, безнең заманда андыен хәл булганы юк. Хәтта бер үк дин тоткан мөселманнар да берсе күтәрелгәндә, икенчесе карап тору ягында.

— Бу юлы башкача, Кузьма туган. Башкортлар да, татар-мишәрләр дә, кыргыз-кайсаклар да дәррәү кузгалмакчылар. Урыслар да кушылса, көчебез бермә-бермә артачак.

— Шулаен шулай да. Тик син андый хәтәр эшкә мине бутама инде, Батыршаһ. Мин шулай кеше йомышларын йомышлап йөрүдән узмамдыр инде, мөгаен. Юк, булмый миннән, Батыршаһ. Рәнҗи күрмә!

Батырша авыр сулап куйды:

— Рәнҗемим, Кузьма. Ә без барыбер кузгалабыз!

Хәтәр ярсып, холыксызланып кайтуына карамастан, урынга ятуга йоклап китте. Иртәгесен иртүк аны Зөлхәбирә уятты:

— Сиңайтәм, тор әле, Яхъя килгән анда!

Егет сүзендә торган, төнен йокламаса йокламаган, тәзкирнамәне ике данә күчереп өлгерткән. Башка шәкертләр дә икешәрне яздылар, ди. Батыршаның йокысы ачылып китте:

— Афәрин, мелла Яхъя! Баргыл, егетләргә әйт: кайсы Гәйнә иленә юл чыгарга әзер?

Чирек сәгать тә үтмәгәндер, Яхъя Казан ягыннан килгән чая Исмәгыйль белән янә күренде. Батырша аларны көтеп тора иде.

— Әй, мелла Исмагул,— диде ул, шәкертнең исемен мишәрчә бозып,— баргыл, бу намәне Гәйнә иләүенә илтеп, Чурагол муллага тапшыр вә аңа әйткел: «Ялган тарафлары бу намә эчендә боерылган эшләргә һиммәт иделәр. Сезләргә һәм ошбу намә эчендә әмерләр буенча һиммәт вә гамәл итмәк лаземдыр»,— диң.

*Дәвамы бар*

## ШИГЪРИЯТ

# Лена Шагыйрьжан

## Өченче микрофон

(«ЙӨРӘК АВАЗЫ» ПОЭМАСЫННАН)

Микрофонга баса тәвәккәлләр:
Яхшысы бар сүзнең, яманы.
Сакланып без сүздән күп яшәдек,
Инде — Сүзне саклау заманы.

Гел яшереп күзне, тел яшереп,
Сүз яшереп үткен каләмнән,
Көн яктысын авыштырдык төнгә,
Төн яктысын «яктык» әрәмгә...

Берәү язды «өстәл эченә» дип,
Берәү җыя барды эченә.
Тупасланды тавыш ярылары,
Җырламагач бөтен көченә...

Шартлы рефлекс ул — бикли телне,
Аллы-артлы шартлар туса да,
Дәшми бәндә — йоткан тел ачкычын.
Баш кадерле, телен җуйса да...

Тел бит хикмәт, бүген хаким итсә,
Иртәгесен куяр кол ясап.
Авызы пешкән бәндә өреп каба,
Дөнья бит ул һаман куляса...

Сүз бирсәләр кайчак, кыюланып,
Мөнбәрләргә мин дә менгәләдем.
Белгәнемнән күбесен сөйләмәдем,
Кирәк иде күпне белмәгәнең...
Дошманыма телем әйләнмәсен,
Бәйләнмәсен, диеп органнар,
«Былтыр кыскан» сүзне быел гына
Әйткәнемә үкенеп йөргән бар...

Телләренә төер чыксын дипме,
Ятлар яман теләк тели безгә.

---

Лена ШАГЫЙРЬЖАН — *шагыйрә, «Мөлдерәмә күңел», «Ышанам йөрәгемә», «Иман әлифбасы» китаплары авторы. Казанда яши.*

Каныга ул каныбыздан бигрәк
Җанны тотып торган телебезгә...

Тел тибрәтеп авыз ачмас борын
Бик салынма, әйдә, телеңә, ди.
Бер телеңә хуҗа булалмасаң,
Очрашырбыз соңра «тегендә» ди...
Хуҗа булыр идем бер телемә,
Миңа менә нәкъ шул кирәк тә.
Ничә гасыр инде тик шул теләк
Шул бер хыял дөрли йөрәктә...

* * *

...Студент чак... Кышкы бер кичәдән
Озата кайтты кала егете...
Икебез ике телдә сөйләшкәнгә,
Аңлашудан өзеп өметен,

Китеп барды... Үкенгәндер, бәлки,
Өйрәнмәгәненә үз телен.
Коры калдым мин дә егетемнән,
Белеп бетермәгәч «дус» телен...

Еллар үткәч, беркөн үзе белән
Татар Үзәгендә күрештек.
Ул — безнеңчә, ә мин юри — русча,
Искә алып шуны көлештек...

Егет кенә түгел, «тел белмичә»,
Күп нәрсәдән коры калдык без...
Ике төрле халык булмасак та,
Күптән «ике телле» халык без...

Ике телне гаҗәп матур итеп,
«Чабатадай оста үрәбез»...
Чабатасын түргә элгән түрә
Булып калдык шуңа күрә без...

...Телем матур минем.
Сындырмыйча
Сөйли белсәң, хәйран калырлык.
Сыйдырмыйча шуны үз йортыма
Үч итәләр... Әле дә тамыр нык...

Дәүләт теле итеп «дәүрәк телне»,
Читен, чит-ят телне тактылар.
Татар мескен табар теленнән, ди.
Ә «бөекләр» нәрсә таптылар?

Йортсыз-җирсез калган дүңгәләкләр,
Хатын-ирсез калган байгышлар...
Сабак булыр микән инде безгә
Телгә йозак салган ялгышлар?!

Кемдер хурлый ата-баба телен:
Ярты-йорты имеш, сукбай ул.
Колгалидән килгән телме фәкыйрь? —
Таный белсәң, шөкер, бик бай ул!

Ул — хәзинәм минем, ул — мирасым,
Ул — мөлкәтем, җыйган дәүләтем...
Телем исән икән, ник дип әле
Терелмәсен «үлгән» Дәүләтем?!

«Күз-колак бул милләтеңә», диеп
Күктән миңа Тавыш иреште...
Күз-колагы булсам, Теле дә бит
Булырга мин аның тиештер...

Ачып җибәр тәрәзәләреңне,
Кыйбла яктан җылы җил исә.
Үз илемдә мин дә үз телемә
Хуҗа булыр идем югыйсә...

Кайда тапкыр телле Хуҗаларым
Илгә-телгә хуҗа булырлык?
Корытмаска иде шулар тамырын,
Югалмасын иде шул орлык!..

...Итәгемнән тарта тагын берсе:
«Бер телеңә, имеш, хуҗа бул!»
Үз телеңә хуҗа булалмасаң,
Яшәү түгел, җаным, нужа ул...

Дәүләт кайтса безгә көн бетәр дип,
Кемдер йөри кара көенеп.
«Кем калыр да әле, кем бетәр», дип,
Һәрбер хыянәткә сөенеп...

Хуҗа булсаң икән үз Телеңә,
Үз җиреңдә күкрәк киереп,
Бер чиртәсе иде танавына —
Йөргәннәрнең борын чөереп...

Телен сатып, теләнчегә калган
Хәерче ул үзе, сукбай ул!
Тукайлардан килгән телме ярлы?! —
Аңлый белсәң, дустым, бик бай ул!!

Урам телем минем, базар телем,
Шигырь телем, газиз сау телем.
Дәүләт тарихымны язар телем.
Дәү телем ул, затлы бай телем!..

* * *

Кызып китеп, оныта язганмын ич
Микрофонга чыгып басканым.
Юл табармы сүзем йөрәкләргә,

Әллә күмелеп калыр — астамы?..
Сүз капчыгым авырайган шактый,
Сүс бау белән бәйләп куймагыз...
Булышыгыз бераз бушатырга,—
Инне баса... Зинһар, тыймагыз!..

* * *

...Мин авылда үскән бала. Телем
Җир-туфрактан шытып ачылган.
Авыл телем — авыр заманда да
Алтын орлык итеп чәчелгән.

Басу-кырда үскән туган телем,
Җир тылсымын имеп, сеңдереп.
Ташкалага алып китәләр дә,
Ташлап калдыралар сындырып...

Ташламадым, ташлар атсалар да,
Мин сакладым аны, ул — мине.
Җитәкләшеп йөрдек. Тән-сакчым да,
Җан-сакчым да минем шул иде.

Аермакчы булып почмак саен
Телкисәрләр торды сагалап...
«Телсез» дип тә ябырылды дөнья
Йортсыз-җирсез бер кыз балага.

«Даһиларның» акцентына түзеп,
Минем «акцентымнан» көлделәр...
Еллар узгач күрдем, алар икән
Үз телләрен хәтта белмиләр.

Без өйрәндек. Утырып калмас өчен,
Кирәк иде утырып өйрәнү.
Өйсез калсак калдык. Безнең исәп
Түгел иде
Исәп-хисап белән «өйләнү»...
«Микрофон»га исеме охшап торган
Бер әдәби образ бар иде...
Беләсездер —
«Өйрәнәсем килми, өйләнәсем
Килә», диеп йөргән баринны...
Читкә киттем бераз төп темамнан,
Читтә йөргәч шулай каңгырып.
Укымыйча гына тук яшәде
Телен йоткан һәрбер аңгыра...
Зур белемле милли кардәшем дә
Үз теленә өстән төкерде.
Туган телдән качкан «зыялылар»
Милләтемә
Ай-һай күпме зыян китерде.

...Күрше-күлән минем эшче сыйныф,
Татар бистәсендә үскәннәр,

Тукай урамында Тукай телен
«Өч борынга» сатып эчкәннәр.
Төкерәләр рухи азыгына —
Телләрендә ит тә, колбаса.
Татарларның иң хәтәре шулдыр:
Әзер чимал — тот та кол яса...

Китапларга язып булмый торган
«Фәлән» — ике сүзнең берендә.
Татар хатыннары «мужик» диеп
Йөртә хәзер хәләл ирен дә...

Калабызның, тузып, тузан баскан
«Яңа» бистәсендә торам мин.
Пелотәндә тимер-томыр моңы
Күмеп киткән Сәйдәш урамын.

Татар пролетары «Әй, мороз»ны
Сибеп үтә кайчак төннәрен.
Тимер чүкеч белән таптасаң да,
Үз хәленә кайтмас телләре...

Төнгә каршы берәү җыр башласа,
Телгә каршы җырлап буламы...
«Рамайлар»ны үз телеңдә генә
Өзелеп җырлап була шул аны...

Идел бит ул ага үз телендә,
Идел бит ул көйли безнеңчә.
Ничә гасыр агып кара әле
Үз телеңнән тәмам бизмичә!

«Я по-русски не знаю»дан башлап
Урыс телен ныгытып ятладык.
Канга сеңгән, әмма ятмый җанга
Хәрам гадәтләре ятларның...

Сулар алыйк әле чишмәләрдән,
Бәлки җаннар китәр сафланып.
Туган телнең тәмен белмәгәннәр
Үксер, улакларга капланып...
Чишмә суын тутырып тустаганга,
«Туст» күтәрәм Телем хакына!
Җиргә ябышып телен саклап калган
Җир «сыйныфы» — авыл халкына
Башым иям керсез саф күңелдән,
Толымнарым җиргә тигәнче.
Зурлый белдең Туган телеңне, дип,
Үзе миңа «Рәхмәт!» дигәнче.

*Казан. 1990, июль—ноябрь*

**А й д а р  Х ә л и м**

# ӨЧ АЯКЛЫ АТ

**ПОВЕСТЬ**

Үзең белән ал, Кәбир!..

Кемдер анын чәчләреннән сыйпый, битләреннән үбә иде.

Малай куркып уянды, дөресрәге, уяныр-уянмас хәлдә сәер авазлар чыгарып, «лып» итеп урынына торып утырды.

— Иплэп... Саташасың, Кәпир...

Тукта, кем эндәште аңа? Эндәштеләрме? Кайда ята ул? Бамбук кайда булган? Ай нурларының яктысы, ике алтын көлтә булып ян тәрәзәләрдән бәреп кергән дә, өйдәге тузан бөртекләрен чагылдырып, мич авызына барып кисешкән. Малай исә шул нурлар ясаган өчпочмакның дөм караңгы уртасында иде. Арып-талчыгуның, йөрәк өзлегүенең чигенә чыккан, шул сәбәпле шактый йокласа да, йокысы һич кенә дә туймаган Кәбир әле һаман айнып җитәр-җитмәс хәлдә яңадан урынына аварга дигәндә генә якында, бик якында, колак төбендә назлы пышылдаган тавыш ишетте:

— Саташасың вет...

Ә-ә, Нәстүк бит әле бу! Ул бит аларга куна төште! Аты караулы, өсте-башы ямаулы, карыны тук, күзе ук бит аның! Нәстүк тә, нәкъ Кәбир кебек, нур көлтәләренең караңгы почмагында утыра икән ләбаса. Ул, торып, ялан аяклары белән салкын идәнгә басты, аннан куллары белән идәндә кармана башлады:

— Нәстә югалттың?

— Оеклар.

— Мин аларны юган...

Кәбир, ай нурларын ерып, ишеккә таба атлады:

— Атны карап керәм.

— Мин тә.

Нәстүк сәкедән сикереп төште, чөйдәге фонарьнең куыгын салдырып, аңа ут алды. Алар икесе берьюлы яктырды. Инде кыз булып җитешеп килгән, күкрәк төерләре шактый ук түгәрәкләнгән Нәстүк яшьлек чаялыгы белән иңбашларын сикертеп куйды һәм, фонарьне кулына алып, тышка юнәлде. Кәбир аның артыннан иярде.

Алар икесе дә яланаяк иде. Туфракның суынып бетмәгән, чыкның төшеп өлгермәгән мәле иде.

— Кара, песдә нинди матур! — диде Нәстүк уңга таба күрсәтеп. Ай

Дәвамы. Башы 6 санда.

якында гына шарлап агып яткан Сабыр елгасына төшеп чишенгән дә шап-шарә килеш су керә иде...

Абзар капкасының келәсен ачып, алар эчкә үттеләр. Кетелмәгән борчудан тынычсызланып булса кирәк, Бамбук кушавеннән туктады. Малай түшлекне тикшерде. Ат уң аягына ял бирергә тырышып, аны ярым асылынган хәлдә тота иде. Кәбир ара-тирә коелгалаштырган солы учмаларын яңадан утлыкка салып, тарау солы яшелен рәтләштерде һәм Бамбукның ялларыннан сөеп куйды. Байтал аңа бар нәрсәгә битараф кебек тоелды. Аның ярым ябык күзләрендә дә әллә ни укый алмады. Ат яңадан чемченә башлады.

— Эчереп кара.

Нәстүк аңа тулы чиләк сузды. Бамбук суны яртылаш эчте һәм, борылып, башын яңадан утлыкка тыкты. Эченә җылы йөгерде Кәбирнең. Теләсә, тагын эчәр дип, ул чиләкне янәшәгә куйды.

Алар абзардан чыктылар. Ай яктысына өйрәнгән күзләргә хәзер фонарь кирәкми иде инде. Нәстүк аны сүндереп, өйгә кертеп чыкты. Кәбирне җитәкләп, елгага тарта башлады:

— Әйдә, су керәпес! Песнен монда тирән пуа пар!

— Ю-у-ук,— диде Кәбир бу эшнең төнлә, аннан да бигрәк кыз кеше белән мөмкин түгеллегенә икеләнмичә.— Бездә төнлә су кермиләр.

— Ә пес керәпес! — диде Нәстүк борсаланып.— Йөзә пелмисен мәллә?

Йөзә белә Кәбир. Су керер иде ул, ыжламас та иде. Тәмам уянып житкән, хәтта йокысы да качкан малай чынында исә ояла иде — их, әгәр аның шәһәр малайлары кия торган, китапларда сурәтләнә торган кыска ыштаны булса! Трусик диләр шикелле аны. Кеше генәме, хатын-кыз белән ничек кенәләр итеп шәрә-бака килеш су керәсең, ди? Оят ни тора!

Өйдә аларны шул ук айлы көлтәләр, шул ук куе исләр, тынчу һава каршылады. Алар үз урыннарына менеп кунакладылар. Хәзер йокы да килми иде кебек.

— Кочакла мине, Кәпир... Өшедем...

Нәстүкне Кәбир утырган уңайдан гына уң кулы белән кочаклады. Нәстүк исә аңа таба борылды, ике кулы белән кочаклап, күкрәгенә кысты һәм ике бит алмасыннан чут-чут үбеп тә алды:

— Юрататан сани, чуным! Юрататан!

Нәстүкнең тирәннән килгән тойгысына әле балалыгы белән бәһа бирә алмаган, шуңа күрә әллә ни аптырамаган, әмма мондый хәл белән беренче тапкыр очрашкан Кәбир, сискәнеп, сорап куйды:

— Нәрсә дидең син?

— Яратам сине, җаным, дидем. Хакым пармы — пар! Син дә мина шулай диген. Йәле, әйтеп караган!

— Һы.

Башка бер нәрсә дә эндәшмәде Кәбир. Шулай дип әйтсә ни дә, әйтмәсә ни? «Яратам сине, җаным...» Бәлки әйтергәдер? Бәлки ул сүз Нәстүккә аш тозы кебек кирәк сүздер? Бәлки аның «йөрисе» киләдер? Аларның авылында бит бер-берсенә күзе төшкән егет белән кызны шундук «йөриләр» дип чыгаралар. Кәбирнең дә бар «йөргән» кызы. Ничегрәк онытып торган ул Мәүсиләне? Өченчедә укыганда төште күзе бу класстагы иң мөлаем кызга. Малайлардан бервакытта да рәнжеттермәде ул аны. Бер мәлне Кое Төбе Сабирларга инәсенең яшьлек дусты Сәбилә апа кунакка кайтып төште. Ул Тула дигән шәһәрдә шикәр заводында эшли икән. Дөньяда иң тәмле нәрсәнең шикәр икәнлеген аңлады Кәбир. Сәбилә түтәй аларга йодрык кадәрле өч шакмак шикәр бүләк иткән иде. Инәсе аны вак-вак телемнәргә бүлеп, кайдадыр яшерде, чәй янына исә берәр валчык кына куя торган булып китте. Әмма малай үз өлешен Мәүсиләгә дип саклады. Көннәрдән бер көн өч нәни шакмак шикәрне чәй кәгазенә төрде. «Мәүсилә, бу сиңа миннән посилка, онытма»,— дип хат язды һәм барысын бергә шырпы кабына салып, Харис

дусына тапшырды. Алуын алган Мәүсилә, әмма җавап язмады, чукынган нәстәкәй...

— Әйтмисенмени, Кәпир?—диде Нәстүк монсу гына.

Әйтергә итә дә бит малай, тик нәрсәдер тота, нәрсәдер җитешми. Аңа янында аты, Бамбугы, ат күзендәге нур җитешми иде кебек. Бу сүзләрне кечкенә йөрәктән кысып чыгару өчен Соры Бүре, Бөкебаш Галләмнәр эзәрлекләвеннән котылырга кирәк иде. Абзар иясенең Бамбукны саклаячагына ышанырга, тагын да әллә кемнәр һәм әллә нәрсәләрдән көч алырга кирәк иде шикелле...

Ул тирән итеп сулап куйды. Йөрәге кысылды һәм дөпелдәп тибә башлады. Анда нәрсәдер утлы төен булып төенләнде, менә-менә шартлаячак! Әйтә ул бу сүзләрне, ник әйтмәсен, ди? Нәстүк үзе сорагач! Җир җимерелмәс әле! Ул күзләрен четертәтеп кысты...

— Юратан сана, чуным!

— Чыннапмы, чуным?!

Нәстүк яшен тизлеге һәм дәһшәтле көч белән Кәбирне яңадан күкрәгенә кысты һәм аны сәкегә аударды. Ул шатлыгыннан нишләргә белми, малайның чәчләреннән, битеннән иркәли, сыйпый, ярата, сөя, үбә, аннан тагын иркәли, тагын үбә, сөя һәм үзенең дә шулай сөеләсе килеп, борсалана иде.

— Син пит миннән өч яшькә генә пәләкәй, Кәпир... Песнен атте дә аннедән өч яшькә пәләкәй...

Әле үсмер чорына кереп тә җитмәгән малайдан үзенә карата шундый ук теләктәшлек тапмаган кыз идәнгә сикереп төште, ай нуры көлтәсендә нурланып, бөтерелә башлады:

— Мин сина иртән тәмле ашлар пешергән! Чырлар чырлап, күңеленне күтәргән! Син кайгыгы пер качан да пирешмәгән, Кәпир, хаклы чынным!.. Әйт, кәзер чырлаган, әйт, кәзер пиегән!..

Әйткәнне көтми, ул җырлап бии башлады:

Юрататып тужерне,
Пече-пече хурине,
Юрататан эн савине,
Кучран нехса кулнине.

Ши-ши шехерса,
Керсе кайре вермана.
Ыран кампа килеп төсе,
Улталаре вал мана...*

Кыз идәндә тыпырдап әйләнде. Аның тавышы искиткеч саф һәм моңлы иде. Бер караганда бөтенләй ят моң һәм телдә, икенче бер караганда искиткеч кардәшлек бар иде. Аңлашылмавы белән аңлашыла һәм киресенчә. Биегәндә Сабыр буе таллары сыман сыгылмалы гәүдәсенең килеш-килбәтенә, җырланган җырына, көтелмәгән илаһи көч белән яктырган йөзенә тап килеп, самимилек һәм табигыйлек сыйфатлары аңа сине тагын да якынайта, бу күренешнең гади бер тамаша, кылану түгеллегенә ышандыра иде. Таң калудан авызын ачкан малай, шатлыгыннан нишләргә дә белми, шаркылдап көлеп җибәрде...

Нәстүк тагын да тыпырдап алды.

---

* Яратам мин яулыкның
Вак сары чәчкәлесен.
Яратам мин сөйгәнемнең
Күземә карап көлгәнен.

Әче итеп сызгырды да,
Кереп китте урманга.
Иртәгә кич киләм, диеп,
Алдаларга булганга.

Ниһаять, алар икесе дә аякларын салындырып, сәкегә утырдылар. Кәбиргә кайнар дулкын бәрде. Йокыларын да онытып, төне буе серләштеләр алар. Шушы шапшаклык шартларында, сабый чагыннан ук авылның иң төпкеле саналган ат алачыгында, җылы сүзгә һәм иркәләүгә саран, сүгенү-җикеренүгә искиткеч бай ир-ат арасында яшәп, ана кадереннән дә мәхрүм Нәстүк, күрәсең, аны тыңлый һәм аңлый алырлык адәми затны зерә дә сагынган иде. Кәбир аны бүлдермәде. Аның ун яшьлек тагын бер туганы — сеңелкәше бар икән. Картинәләрендә тәрбияләнә, ди. Атасы сугышларны башыннан азагына кадәр үтеп, хезмәттән былтыр гына кайтып төшкән. Яраларын төзәтеп, кайдадыр госпитальдә яткан. Нәстүкнең әнисенең — баягы хатын була инде — ул сугышта чакта колхоз хисапчысы Инәкәнтәй белән чуалуын ишетеп, авылга кайтмаска да карар итә. Чуалу гынамы, дип тә өстәп куйды кызкай. Ел саен диярлек хатын алыштырган, холкына килмәсә, куып та чыгарган Инәкәнтәй бер карагында инәсе белән үз йортында, бер караганда Нәстүкләрдә, ике йорт арасында яшәп йөрегән. Хәбәрсез-нисез кайтып төшкән Чтапан дәдәй. Кышкы зәмһәрир суыклар икән. Өенә керсә, анда җәелеп, исерек Инәкәнтәй утыра. «Сине үлде дигәннәр иде, бәй, үлмәдеңмени?» — ди аңа оялмыйча Инәкәнтәй. «Мин тиз генә үләргә җыенмыйм әле, — ди Чтапан дәдәй. — Хәзер сезне куып чыгарам, аннан бу йортны көлгә калдырам, урынында яңа йорт бетерәм, аннан соң да бик озак яшәячәкмен әле...»

Һәм шунда ук Инәкәнтәйне инәләре белән бергә куып та чыгара. Ике баласын алып, шул ук кичне ат алачыгы өенә ат караучы булып урнаша. Төнлә кире кайтып, йорт-җирен казыгына кадәр яндыра. Авылдашлары сүндерергә тырышалар, ләкин ул алардан сүндерттерми. Анфиса сеңелен картинәләре тәрбиягә алган икән. Нәстүк белән Чтапан дәдәй менә шушында дөнья көтәләр. «Песнен йорт урынында кәзер көл-күмер генә калган, атте пыел пүрәнәләр волакать иткән, көзен пуратырга тырышкан», — диде кызкай, кайчан да булса бер зур, якты өйгә кайтып керәчәгенә өметләнеп...

Нур көлтәләре атып килгән таң яктысында сыегая барып, өйне тоташтан оетканда гына йомылды аларның күзләре. Бер толыпка бер булып түшәлгән ике гәүдә, ике баш, ике йөрәк шул ук вакытта ике сиземләү, ике тәртип белән яшиләр иде. Өшемәсен дип, Нәстүк Кәбирнең аркасын толып чабуы белән япкан һәм аны муенынннан кочаклаган. Кайчандыр тарих тиргәнлегендә бер халык булып, аннан аерылган, ике телгә, ике моңга, ике дингә инәнгән ике халыкның ике гонаһсыз һәм рыясыз баласы тигез тында йоклый иде.

...Малай чаң суккан тавышка уянып, күзләрен ачса — яп-якты! Нәстүкнең урыны күптән суынган. Караса, ул һаман да шул агач сәнәген тотып, мич тирәсендә кайнаша. Мичнең ялкыны аның бит алмаларын тагын да алсулата төшкән. Чәче өстеннән артка чөеп бәйләгән кызыл яулыгы да шул ялкыннан кабынып китәр төсле. Бар үткәнен оныткан хәтерсез кеше сыман, җылы толыпка төренгән Кәбир урынында иркәләнеп ята бирде. Аруы җитеп, ул хәтта пинжәген дә салырга оныткан. Хәер, әйбәт булган — салган хәлдә, күлмәгенең җиңсез икәнлеген күргән булыр иде Нәстүк.

— Уянтың та мәллә?

Малай елмаеп җибәрде.

Иркәләп кенә эндәшә иде аңа Нәстүк. Кәбирнең үзенә ачуы килеп китте. Кояш Сабыр таллары өстенә үк күтәрелгәндер, мөгаен, болай иркәләнеп ятарга синең ни хокукың бар? Соры Бүре һәм Бөкебашларның нәфсесе Тушкырга җитмәс дип уйлама, энекәем! Малай сикереп торды.

— Оегын шунда...

Ул сәке йөзлегенә куелган оегын алды. Алар юылган һәм таслап бөкләнгән иде.

— Рәхмәт, Нәстүк!..

— Тапкиларын да шунда...

Ул сәке астыннан чегән юлбашчысы бүләк иткән чүәкләрен чыгарып, бер мизгелгә сокланып торды, аннан тагын исенә килеп, тиз генә киенде һәм ишеккә юнәлде...

Ихатага кергәч, уң кулда, фурман үрәчәләренә кунаклап алган ирләргә тап булды. Тәмәке борхыта-борхыта үз хәлләре хакында сөйләшкән мужиклар Кәбиргә артык игътибар итмәделәр кебек. Чтапан дәдәй алар арасында юк иде. Абзарның ачык капкасы аша үтеп, ул шым гына Бамбук аранына якынлашты. Туктап, тыңлый башлады. Байтал бер җай белән генә утлыкта сайлана иде. Эчтә кемдер мыгырдангандай тоелды. Малай аран ишеге аша үрелеп карады. Чтапан дәдәсе, үз телендә нәрсәдер укына-укына, атның имгәнгән аягын киң тасма белән урый иде...

Дәдәй тирә-ягына төкеренде дә ниндидер дарулар һәм май салынган шешәләр тотып, араннан чыкты.

— Ә-ә, кодай пәндәсе, тордынмы?

— Тордым, Чтапан дәдәй. Рәхмәт инде сиңа...

— Сине мужиклар күрдеме?

— Әллә ни игътибар итмәделәр.

— Якшы, кәзер кеше яман. Күргәндән күрмәгәне якшы.— Кинәттән генә сүзне икенчегә күчерде.— Пиян пуаз күренә пит...

Малайның күзләре таралып китте.

— Әйе, әйе! Прокрайнемер, өч-дүрт айлык... Мин пеләм! Пик тә сылу күренә Пампук... Пләмәнни пия, күрәсен. То-то.. Колынны саклаган кирәк, Кәпир. Кәзер син аны кума. Үз хуты пелән генә кайтсын, ярый?

— Ярар, Чтапан дәдәй,— диде Кәбир әле биянең буаз булу хәбәрен сендерергә өлгермәгән хәлдә.— Бамбукның аягына син нинди дару сөрттең?

— Кодайга шөкер, аяк шешмәгән. Мин аның ике аягын палтыр пелязекләрен үлчәп, сравнивать иткән. Елек мае кибә, значит, палтыр корый пашлый. Пампукның елек мае кипмәгән, значит, яшәгән! Карарга, личить итәргә! — Ул яшькелт күзләрен челт-челт йомып, малайның иңенә дусларча сугып куйды.

— Бамбукның аягына син нинди дару сөрттең? — дип кабат сорады Кәбир.

— Әй, кодай пәндәсе, тәки пелергә телисен, ә? Вына алар! — Ул кулындагы шешәчекләргә ымлап.— Кунжут мае, әбләпих мае... Татарлар анысын чырга мае диләрме? Вынысы куросслеп суында кайнатылган зирек каерысы булган. Екстрат! Мин сина поларнын парысын да пиргән! Мә!..

Малай дару һәм «екстрат»ларның барысын да алды.

— Ә син Бамбукны нәрсә дип өшкердең?

— Вынысын да ишеткән, ә! Сина армиядә контрразведкада кезмәт итәргә дә пула, Кәпир... Нәстә дип өшкергән? Пихамбарга молитва укыган. Эткә-кошка, пүрегә тоттырма, дигән. Мал-туарны ишәйт, дигән...

— Ә кем ул Пихамбар? Абзар иясеме?

— Җирдә һәр нәстәнең Пихамбары булган. Сеснен Апзар иясе дә Пихамбар булган. Кеше иясе — Тәнре. Песдә — Тәнре, сесдә — Алла, урыста — Бог... Мин Пихамбарыбыздан сесне исән-сау кайтарсын дип, теләкләр теләгән... Әйдә, пес нишләп вында озак сөйләнеп торган, Нәстүкнең ашы суынган вет!..

Алар өйгә юнәлделәр. Кайсы җигәргә ат җитәкләп, кайсы урында җигеп, ирләр ихатадан таралган иде. Курага керер алдыннан, кәҗәнкә бурычын үтәгән аралык чөйләрендә элүле аркан-бау, шул ук камытыңгырчак, өстәрәк, кул җитмәс төштә, почмактан почмакка асылынып торган самосад яфраклары тапкырына җиткәч, Чтапан дәдәй сер чишкән сыман әйтеп куйды:

— Әллә сон песдә генә каласынмы, Кәпир? Күрәсен, минен малайлар пулмаган. Матур итеп өй петерәбез — и живи! Чыннан әйтәм, каласынмы? Атынны итеп тапшырабыз. Анаң тегеннән кайтканчы тор песдә!

— Ю-у-ук,— диде малай бераз иркәләнеп.— Мине көтәләр. Мин тагын килермен. Без тагын килербез, Чтапан дәдәй. Бамбук белән...— Икенче бер үтенечен дә әйтергә форсат тапты ул, мизгелдән файдаланып.— Нәстүк белән безгә кунакка килеп чыгыгыз, Чтапан дәдәй. Их, безнең авылның матурлыгын күрсәң! Кешеләре дә ифрат әйбәт... Ат караучы Сәми бабай үзе генә ни тора...

— Килерпес, Кәпир, килерпес. Карамал пазары сеснен якта вет? Шул пазарны күрергә тип күптән кыялланган мин...

Малай, ниһаять, күнел төбендә ятканын да уртаклашырга булды:

— Әгәр мине эзләп килүче булса, әйтә күрмәгез инде... Нәстүкне дә кисәт...

— Әйттем вет син контрразведчик дип! — Чтапан дәдәй ишек алларына кадәр яңгыратып көлеп җибәрде.— Молчок-молоток!.. Ә син майларны ташлама. Пына вынысы үлекне суырган. Вынысы кожаны йомшак тоткан. Икенче сорт. Ир-ат вет сортларнын төрлесен яраткан! — ул шаян күз кысып куйды.— Әйдә, кердек.

Нәстүк сәкегә ашъяулык сыман тукыма җәеп, туралган чөгендер һәм кичә Кәбир күчтәнәч итеп биргән бәрәңгене кушып пешергән кайнар шәнге китереп куйды. Ул шул ук кызыл күлмәктә, чәчләрен матур итеп тараган һәм үргән. Күкрәкчәсендәге тәңкәләре бүген тагын да ялтырарак, тагын да зенләрәк иде. Кәбирне саф мөселманча, аякларын бөкләтеп, түргә менгезеп утырттылар. Берәр савыт сөт, кулга алгач та таралырга торган тары тәбикмәге табынны патшалар табыны дәрәҗәсенә күтәрде.

— Пес вында үсепес бер кәҗә тотапыс,— диде Чтапан дәдәй сөткә ишарә ясап.— Пыел тагын перне алырга исәп пар...

— Мин аны сауган! — дип тә өстәде Нәстүк.

Кәбир анын күзләренә карарга ояла иде. Бу оялуда туганлашудан яратылган шатлык та, үзеннән канәгатьсезлек тә, өмет һәм өметсезлек тә чагылгандыр.

— Чәй пармы? — дип сорады дәдәй.— Тавык җим пелән, татар чәй пелән туйган, ди...

Өчесе дә рәхәтләнеп көлделәр. Аларга кушылып, чөйдә асылынып торган аеры бөятле камытлар да көлде шикелле. Нәстүк мичтән икенче бер чүлмәк чыгарды. Төрле үләннәргә мәтрүшкә дә кушып төнәтелгән чәйне балчык көрәгәләргә салгач, өй эчендә хуш исләр таралды. Сөттән соң әллә ни эчәсе килмәсә дә, эчте малай — бик тә тәмле иде Нәстүкнең иртәнге чәе!..

Кәбирнең бу иң шатлыклы минутлары иде. Әмма китәр мизгел дә җитеп килә шул. Авыр, газаплы иде малайга күңеленә якын кешеләр белән аерылышу. Ул дулкынланып һәм теләр-теләмәс хәрәкәтләр ясап, түрдән төште, почмактагы капчыгын өстерәп чыгарды. Чөйдәге камчысын уң кулына алды һәм «Менә мин китәргә дә әзер!» дигәндәй, хуҗаларга карады. Нәстүкнең ай кебек якты һәм түгәрәк йөзендә нинди дер җепселләр тартышып куйды, ул атасы алдында бер нәрсә дә әйтә, юньле-рәтле хушлаша да алмау гарьлегеннән карашын читкә төшерде һәм табын өстен ашъяулыкның чит-читләре белән каплаштырган арада астан гына пышылдады:

— Мин осата чыккан...

Бер нәрсә дә сизенмәгән Чтапан дәдәй ишекне ачып тышка атлауга, Нәстүк кискен хәрәкәт ясап, ишекне кысты һәм Кәбирне кочаклап, ялвара башлады:

— Тагын кил, чәме? Мин көткән, чәме! Онытма, чәме!..

Ул елый иде. Зәңгәр күзле, житен сары чәчле, өтер кебек кенә җыйнак матур борынлы Нәстүк аңа хәзер үзеннән дә ныграк кызганыч иде. Буйга аңардан беразга гына озынрак булган һәм ялан аяклары белән җир идәнне җылыткан бу кызкай аңа бер карында яратылгандай якын һәм үз күренде. Үз гаиләләрендә кыз бала булмаганга, күрәсең, Кәбир кызлы

йортларны илаһилаштырырга өйрәнгән. Кызлар алар ир туганнарын ничек кенә иркәләп үстерәләр! Ә Кәбирнең беркеме дә юк: утын киссә дә, суга барса да, идән юса да — үзе. Шуңа күрә ул Нәстүккә бертуган апасына караган кебек карый.

— Килермен,— диде Кәбир Нәстүктән арынып.— Син дә кил. Чтапан дәдәй белән бергә килегез. Безнең авыл бик матур. Кешеләре дә әйбәт...

Ул чыкты. Нәстүк аның артыннан ияреп килде дә, ихата читәненә җитәрәк туктап калды. Чтапан дәдәй Бамбукны араннан алып чыгып, эчереп маташа иде. Атның тузанын һәм күбектән кипшенеп тозга әйләнгән төкләрен юеш чүпрәк белән сөртә-сөртә, ул тагын бер мәртәбә кисәтте:

— Матри, кума. Үс җае пелән барсын. Кайтып җиткән. Кара, мин ана нинди итек кидергән?

Бамбукның бәкәленә гүя кара итек куныч кидерелгән иде. Малай капшап карады: төшәрлек-нитәрлек түгел. Җөе дә күренми.

Чтапан дәдәй тезгенне атның муенына урап бәйләде, ялларыннан кагып, сөйде һәм йөгән аелыннан тотып, капкага таба борды:

— Йә, кәерле сәгатьтә! Татарлар әйтмешли, бүдәнәдән — май, ябалактан — йон, этка-кошка тоттырма!..

Кадер сәгатенең тәмамлануын аңлаган Бамбук, Чтапан сыман авыр тын алып, капкага таба титаклады.

Ихатадан чыктылар.

— Ишледә туктамый пулмас сина. Туктасан, минен күптәнге пелещем Нәби пеҗчәгә туктаган. Ул да минен кек конюх... Күп итеп сәлам әйтерсен. Хәленне анлар. Анлардай кеше...

Малай алдына-артына карамый аты артыннан китеп тә бара иде инде.

— Тукта, кодай пәндәсе! — дип кычкырды Чтапан дәдәй.— Шулай исәннәшми дә китәсенмени?

Ул йөгереп килгән Кәбирне сөякләрен сындырырдай итеп кукрәгенә кысты. Өлкән ир кадерен күрмәгән малай аңа атасына сарышкан кебек сарышты. Дәдәй җир сыман коргаксыган кулын сузды:

— Мә пишне!

— Ун булсын!..— диде Кәбир аның кулына үз кул яссуын шапылдатып сугып.

— Вына шулай. Вына пу ирләрчә!..

Чтапан күңеле йомшарып булса кирәк, кырт борылды һәм абзарга юнәлде. Кәбир Бамбукны куып җитте, бераз баргач, артына борылып карады. Артта, инде истәлеккә әверелеп барган кечкенә өйнең почмагына сөялгән тал чыбыгыдай Нәстүк аңа яулык болгый иде...

Артта — яшел үлән, Нәстүк һәм Чтапан дәдәй.

Алда — тагын таулар һәм үзәннәр.

Инде ничәнче тапкыр авыл очындагы Сабыр күпере аша үтеп, яңадан таллыкларга күмелделәр. Бамбук хәзер чабарлык хәлдә түгел иде.

— Аягың нык авыртамы, Бамбук?

— Минем авыртмаган җирем юк. Аннан бик сагындым да... Бүген кайда кунабыз?

— Ишледә. Аңа унбиш-уналты чакырым гына калды. Кичкә барып керербез, алла боерса...

— Мине атлар янына алып барырсың, яме? Ат караучылар атның җанын аңлый белә...

— Ярар, Бамбук.

— Чтапан дәдәй дөрес әйтә. Минем карынымда дүрт айлык көмәнем бар. Инде җиленемә сөт төшәргә дә күп калмады. Син мине кыйнама, яме?

— Ярар, Бамбукҗан...

Аларның күптән болай җанга-җан сөйләшкәне юк иде. Бамбук колын турында хәтергә төшергәч, малайның йөрәген яңа хафа көйдереп

алды — нигә соң әйтте Чтапан дәдәй байталның буаз булуы турында? Бәлки, белмәсә яхшырак булыр иде. Үзләре белән беррәттән уйнаклап чапкан сабый Бамбукны күз алдына китереп, малай елмаеп куйды...

— Син мине бүген ешрак туктатып ашат,— диде Бамбук.— Тоз алырга онытмадыңмы?

— Юк, онытмадым. Чтапан дәдәй безгә тоз да бирде.

— Рәхмәт төшкере. Су эчкәннән соң син аны миңа шикәр урынына гына каптырырсың, ярармы?

— Ярар, Бамбукҗан.

Бүген һава җиләс, көн тымызык иде. Кояш исә бал исе белән тулган сары рәшәдә эрегән. Җир дә дымлы иде бу тирәдә. Төнлә яңгыр сибәләп узган, ахрысы. Тын алуы да җиңел. Кичә генә бөркүлектән җәфа чиккән чәчкә һәм үләннәрнең күзләре һәм йөзләре тулаем ачылып китеп, һәр тарафка хуш ис тарата, күңелне җилкендерә. Бамбукның тын алышы исә кипкән курайның көзге җилдәге гыжылдавын хәтерләтә.

Алар сөйләшеп баралар. Кәбирнең туктаусыз сөйләшәсе, кем беләндер киңәшәсе килә иде.

— Мин бер кыз белән таныштым, Бамбук. Исеме — Нәстүк.

— Күрдем. Бик матур, уңган кыз. Сез төнлә минем янга кергән идегез. Кулъяулык бүләк итмәдеме?

— Син нәрсә сөйлисең, Бамбукҗан? Ул бит минем апа, ә мин аның энесе. Кульяулыкны кызлар бары тик йөрегән егетләренә, булачак кияүләренә генә бүләк итәләр.

— Бәй, син дә аның кияве булырсың.

— Ха-ха-ха-ха! — Малай юлдан күзен алмыйча яңгыратып көлеп җибәрде.— Миннән нинди кияү ди?! Мин бит әле армиядә дә хезмәт итмәгән. Аннан, беләсең, Бүләктә күзем төшкән кызым бар бит...

— Беләм. Мәүсилә. Гел генә вак борчаклы күлмәк кия ул. Инәсе Фәриха белән күп тапкырлар йөк тартканым бар... Гаиләдә берсеннән-берсе кечерәк дүрт ятимә — Василәә, Мәүсилә, Әсилә, Гөлсинә...

— Дөрес, Бамбукҗан. Мәүсиләгә былтыр хат та язып җибәргән идем. Әмма Мәүсиләгә дигән хатымны, ялгышып, Сталинабадтагы Гадел абзыйга, Гадел абзыйга дигән хатны Мәүсиләгә салып җибәргәнмен, малай. Абзый да югалып калмаган. Хатында: «Дөрес эшлисең, Кәбир туган. Мәүсилә, инәсенә һәм Василә апасына тартса, уңган кыз булыр. Кулыңнан ычкындырма»,— дип язган. Оятыннан җир тишегенә керердәй булды Кәбир.

— Ха-ха-ха-ха! — Хәзер инде тугайны тутырып, Бамбук көлә иде.

Кояштан күләгә төшмәгәч, вакытның чамасын белү кыенрак иде. Төшке уникеләр бардыр, дип чамалады малай. Юлның Ишлегә кадәр таллыктан баруына куанып та куйды. Бамбукның тамагын туйдырып алганда да зарар итмәс. Кәбирнең исә ашыйсы да килми. Ул бүгенгә тук иде. Арттан ыргып чапкан тояк тавышлары ишетелгәндәй итте. Байталның колагы укка, Кәбирнең колагы сизгер чукка әйләнде. Борылыштан әлегә беркем дә күренми иде. Әмма килә тояк тавышы, көчәя килә! Йөгереп барып, байталның тезгененнән эләктереп алды һәм таллыкка өстери башлады. Тегесе ашыкмады. Малай аның артына чыгып этте һәм камчы белән кизәнеп, лабылыкка яшереп өлгерде. Җайдакның яшендәй атылып үткән гәүдәсе тал куерымы аша кызарып кына чагылды. Тояк тавышлары, ниһаять, офыкка сеңде. Кем булыр ул?

Кәбир байталны тагын да эчкәрәк алып керде. Язгы ташкыннарда Сабыр елгасы ташыган тиресле ләмдә, үлән дугалы атны күмәрлек булып котырып үскән иде.

Чтапан дәдәй Бамбукның күкрәгендәге ярасына да ниндидер кара дару сөрткән булган икән. Аны черки-чебен, кигәвеннәр сырып алалар да, борын эчләрендә тәмсез тәм тоеп, күрәсең, яра тирәсендә бөтерелеп-бөтерелеп, корсак һәм җилен тәңгәлләренә куналар. Кәбир, ат кузгалагы өзеп алып, канэчкеч кигәвеннәрне куа башлады.

Еракта, инде уң яктан, тагын да тояк тавышы шәйләнде. Бер мәлгә ул тынып калгандай һәм кычкырган тавыш ишетелгәндәй итте. «А-а-а!» Тояк тавышы яңадан кабатланды, яңадан туктады һәм яңадан шомлы аваз белән алышынды. Менә җайдак бар көчкә ыргылып килеп, аның тәңгәленә җиткәч, кинәттән генә атын тыйды һәм ап-ачык итеп аваз салды:

— Кә-ә-ә-пи-и-ир!...

Малай нишләргә дә белмәде. Һич тә көтелмәгән бу кунак — Нәстүк иде. Тәмам шомланган Кәбир куе үләнне аралап, юл тарафына ташланды. Бер-бер хәл булганмы әллә? Җиргә түшәлгән коры-сарыны сындыра-сындыра, ул юл буендагы таллыкка чумды һәм ат өстендәге Нәстүкнең рәвешен тәмам танығач, башын тыгып кына эндәште:

— Монда кил, исәр!

Нәстүк атыннан төште. Тынычланган Кәбир аңа каршы чыкты. Атның тезгененнән әләктереп, Бамбук ягына тартты. Кулына төенчек тоткан кызкай шатлыгыннан югалып калган кыяфәттә әлегә эндәшмитындашмый гына Кәбир артыннан иярде.

— Бер-бер хәл булды мәллә, Нәстүк? Чтапан дәдәй җибәрдеме?

— Юк,— диде кыз тыныч кына.— Үсем килгән.— Аннан үпкәләгән тавыш белән өстәде:— Ник килден дә, ник килден... Сине күрергә! Синен мине күрәсен килмимени?

Малай бик җитди мәшгульдә иде. Алар үләнгә утырдылар.

— Сина ашарга пирергә оныткан,— диде Нәстүк төенчеген чишеп.— Ачыктынмы?

— Юк,— диде Кәбир кырыс кына.

Ашъяулыкта таш кебек каты алабута икмәге, бер дистә чамасы тәгәрәтеп пешерелгән бәрәңге ята иде.

— Кайдан алдың?

— Ник алай сорыйсын? — Нәстүкнең йөзендәге елмаю сүнде.— Пес шулай кәерчемени? Пайда күрсен — котты пулсын, кәерчедә күрсен — кайдан алдын?

— Мин болай гына, Нәстүк...

— Яратсан, аша,— диде кызкай яңадан елмаеп.

Ашыйсы килмәсә дә, малай күчтәнәчләрдән авыз итәргә булды. Читеннән генә булса да, икмәкне сындырып капты.

Нәстүк исә, шуны гына көткәндәй, кояшта тагын да алтынлана төшкән чәч толымнарын артка сыдырып ташлап, дулкынлана-дулкынлана сөйләргә тотынды:

— Син киттен, аннан атте үлән апкайтырга урманга китте. Шундый күңелсес пулып калды... Өйгә кергән — син юк, апзарга кергән — син юк. Үсе ач, аты храмуй, мин әтәм. Күршепес Үстинәгә рәкмәт. Пәрәнгесен дә, икмәген дә пиргән...

Ул бераз тынып торды, аннан тезләрендә шуышып килеп, Кәбиргә укталды.

— Синсес мин янгыс, Кәпир... Миңа куркыныч, Кәпир... Ал мине үсен пелән... Кума мине, Кәпир!..

Нәрсә әйтергә белми аптырап калган малай авызын ачарга да өлгермәде, Нәстүк ике кулы белән бит алмаларыннан чормап алып, үзенә тартты:

— Мин әсер... Мин апзарда иң якшы җүгән салган да качкан... Мин синен пелән киткән, Кәпир чуным!..

— Кайда алып барыйм мин сине? — диде Кәбир чыннан да тирән борчылуга төшеп.— Өйдә беркем дә юк бит, Нәстүк...

— Икәү яшәрпес... Ат синеке, мин синеке пулган...

— Һы. Миндә кәләш алу кайгысы әк әле... Миңа ат өчен җавап бирәсе бар.

— Ат өчен минем җавап пирәсе юкмы? Син пит миңа, хаклы чынным, дип әйттен. Алдадынмы?

Кыз җиргә капланды. Кулбашлары тартышып-тартышып ала. Ул елый иде. Әйе, сугыш аларны ифрат иртә өлгерткән, шуңа күрә тормыш үзе генә тудырган шартларда иртәгә әйтеләсе сүзне бүген әйтергә мәҗбүр иде бу гөнаһсыз җаннар. Нәстүк инде мәңге дә чыга алмас мәхәббәт түгәрәгенә кергән иде. Җир буйлап кузгалган язгы ташу сыман, һәркемгә үз вакытында килә һәм аннан котылып булмый торган бу изге, илаһидан илаһи хис — мәхәббәт хисе Нәстүк җанының шагыйрәнәлеге, шәхсәнә сафлыгы, рухи каһарманлыгы белән бергә кушылып, тагын да аянычлырак көчкә ия булуы белән куркыныч иде. Мәхәббәтенең чәчкә ату чорына ат менеп бәреп кергән бу адәм баласы йөрәк алмасын үзе кебек үк шагыйрәнә, үзе кебек үк шәхсән саф икенче адәм баласына бүләк итә алмаганы өчен үзен иртә, бик иртә гаепли түгелме? Әйе, ул белә: бу минутлар Нәстүк тормышында бүтән кабатланмаячак. Бүгеннән алып ул икенче булачак, икенче түгәрәккә керәчәк. Кәбир өчен бу түгәрәкләр алда иде әле.

Кәбир аның янына килде һәм юата башлады. Шулчак колагына Ишле юлында җиңел арба келтердәгәне ишетелеп китте.

— Тукта! Тавышыңны чыгарма, Нәстүк!..

Кәбир, дөньясын онытып, юлга ташланды. Кул сырты белән яшьләрен сөртә-сөртә, Нәстүк тә аның артыннан иярде. Болай да куе таллар арасында алар җиргә сузылып яттылар һәм юлны күзәттеләр.

— Атлар кешнәмәсә генә ярар иде,— дип пышылдады Кәбир.

— Кешнәсә, алар вында пес икәнлеген каян белә?— диде бернәрсә дә аңламаган Нәстүк.

Ниһаять, борылыштан җигүле ат күренде. Кәбир шундук таныды — бу участкауай Сәйфуллин җигеп йөри торган Кара айгыр иде. Арбада кычкырып һәм көлешеп сөйләшеп, үзләрен тотышларына караганда, бераз кызмача булган Сәйфуллин белән Бөкебаш утыра. Бар үзәнлеккә аракы исе таралгандай итте. Арбада, гүя, тумпак башлы Бөкене һәм фуражкалы Сәйфуллинны түгел, юып һәм киендереп, ике арба кендеген утыртканнар. Уртача тизлектә юртып, Кара айгыр Кәбирләр тәңгәленнән үтеп тә китте. Их, туктатып кына сорашырга иде — инәсенең хәлләре ничек икән? Сорарлык кешеләрме соң алар! Малай ачуыннан ике йодрыгы белән җирне төйде.

— Нәстүк... Бу кешеләр минем арттан киттеләр. Миңа хәзер үк кузгалырга кирәк, югыйсә...

— Нәстә пулды, Кәпир? Кемнәр алар?

— Сөйләп торырга вакыт юк, Нәстүк... Аңла! Икенче бер очрашкач, сөйләрмен.— Малай, ашыгып, чәчелеп яткан күчтәнәчләрне капчыгына тутыра башлады. Аннан Нәстүкнең бөтенләй күңелсезләнгәнен күреп, өстәде:— Мин сине быел кыш утырмага килеп алыйммы? Минем инәй утырма кызларын бик тә ярата...

— Ал, Кәпир, ал!— дип сөенде Нәстүк.— Мин киләм! Әле үсемне алмасаң, атымны пулса да ал... Мин аны синен өчен урлаган... Синен өчен!.. Пампукны минә пир. Үзем караган!..

Алар юлга чыктылар.

— Юк, Нәстүк. Син кайт. Алар, мөгаен, ат алачыгына керми калмас. Мөмкин булса, син аларны куып житеп, узып китәргә тиешсең. Әгәр алар керсә, «Күрдек без ул малайны, кичә генә бездә кунып чыкты, совхозга китте, әлегә кайтканы юк»,— диген. Мин сине кышкы айларда утырмага килеп алырмын. Бамбук белән, яме? Хуш!..

Малай юлга төшкән Бамбук артыннан атлады. Нәстүк аны куып житеп, тагын да кысып кочаклады:

— Син мине парыпер оныта алмаган, Кәпир! Парыпер онытмаган... Хаклы чынным!..

Ул атына атланып, Тушкырга таба торып олакты.

Еллар үтәр. Язмыш сукмагы Кәбирне тагын да Нәстүк тупсасына алып килер. Ләкин язмыш аларны бик тиз очраштырмас.

Кояш чыгып, тагын да кыздыра башлады. Җирдән көйгән каурый исе килә. Урман һәм таулар, болын һәм үзәннәр кояш эссесендә кырылып, бар мохиткә нindидер сәбәпсез рәнҗү тойгысы кичергән, барысы бер җепкә теркәлгән тереклек салкын чишмә дымы турында хыялланган сыман. Ә кояшка нәрсә? Ул — бөек битараф. Күкнең җавапсыз гөмбәзенә калыккан да, үзен, гүя, һәртөрле кайгыртучанлыктан азат итеп, аяусызлык белән бар нәрсәне көйдерә, киптерә һәм шундый ук аяусызлык белән яшәтә. Әйе, үз өнендә яткан сукыр тычканга, көндезен йоклаган ябалакка кирәкмәгән кояш менә шушы көеп яткан далаларга яңгыр иҗат итүче буларак кирәк иде. Быел да ачлык булыр микәнни, ходаем?

Ул хәзер артка борылып карамаска булды. Алар инде кайтып җитте-ләр дияргә мөмкин. Бамбук кына чыдасын. Иртәгә кичкә инәсен газаплаучыларга чик куярга тиеш ул.

Туктап, капчыгыннан төргәк чыгарды. Аннан берничә вак кына кисәкле таштоз чыгарып, пинжәк кесәсенә салды. Бамбукны куып җитеп, тоз каптырды.

— Бәлки сусагансыңдыр? Сабырга борылыргадыр?

— Әлегә кирәкми. Тоз сусауны баса. Рәхмәт сиңа. Тоз минем бәбәемә дә кирәк.

Юл агачлык әсирлегеннән котылып, үргәрәк сукты. Һәм арыш басуы читеннән китте. Вакытыннан иртәрәк саргая иде арыш. Сулдан, аста бормаланып-бормаланып аккан Сабыр буйлап офыкка нindидер кызыл тасма сузылган. Авылдан икмәк таларга килүче упалнамучлар кия торган галифе чалбарларның кызыл тамгасына охшатты аны Кәбир. Келәт янында эшләүче хатыннарның оят җирләренә кадәр капшап торалар алар. Әнә, Мәүсиләнең инәсе Фәриха түтәйне култык астында алып чыккан бер кадак бодай өчен чак-чак кына утыртмадылармыни былтыр? Иген булырмы-юкмы, анысы билгесез, ә менә упалнамучларның көткән кунаклар сыман озакламый килеп җитәчәкләре көн кебек ачык. Безнең Буләккә һаман да шул кап-корсак Спирдон килер инде, дип уйлап куйды Кәбир. Керәшен татары диләр аны. Кем була икән ул, керәшен татары? Исемнәре генә урысныкымы? Шул гынамы?

Ниһаять, җиләс җил исеп куйды. Башаклар диңгезе дулкынланып алды. Туган як җиле! Кәбир туган ягына гына хас булган исләрне тойды. Инде өченче тапкыр үз мәгарәсенә төшеп барган кояшның кайнарлыгын саклаган нурларыннан да тотып алды ул бу кадерле, җанга якын исләрне. Юк, Ырынбур даласының куе әреме исе генә түгел, анда шул ук әрем катыш чәчкә, шул ук әрем катыш юкә балы, шул ук әрем катыш кавын исләре бар анда. Туган як җиле! Ничә яшь сиңа? Нигә шулай якын син? Кәбир онытылып кулларын җәйде һәм, карашын Буләк якларына юнәлтеп, иркен сулады. Ул үзен гомергә булмагандай көчле тойды. Нәстүк буләк иттеме бу көч-гайрәтне? Чтапан дәдәйме? Әллә аның атын пычак астыннан йолып калган чегәннәр юлбашчысымы?

Көчле генә түгел, ул бай да иде. Бик бай иде. Дөньяда аңардан бай кеше юк, әгәр булган хәлдә, ул үз байлыгын барыбер алыштырмас иде. Шушы берничә көн эчендә аның белән әллә нindи үзгәреш булды: буе да үсте, гүя аңа аксакал бабайлар акылы да керде шикелле. Шушы хистән сискәнеп, ул арыш басуына карады. Җил тынган. Ә басу һаман дулкынлана. Җилсез дә ничек тирбәлә, дулкынлана ала ул? Кем көч бирә? Ни дип дулкынлана? Кешене җыр да шулай җилсез дулкынландыра бит. Аның җырлыйсы килеп китте. Әмма җырламады. Тынлык кирәк иде аңа. Гүя, үтелгән юллар, очрашылган кешеләр җырламаска кушты үсмергә. Әгәр алар барысы да Бөкебаш кебек игелексез булсалар, бәлки җырлаган да булыр иде. Әйе, ул кешеләр игелексез һәм имансыз булсалар, ул, ач,

ялангач, телләр белмәгән, илләр гизмәгән, чатан атны йөрәге белән диярлек күтәреп килгән малай, үтә алыр идеме бу юлларны, күрә алыр идеме бу кешеләрне? Туган як җиле! Күләгәләр, шәүләләр һәм колактагы сихри зеңләү! Сагыну һәм наз, анаң елмаюы һәм яшел үлән!

Кәбирдә курку дигән нәрсә бетте. Бөкебашларның алда түгел, артта булуы аңа нишләптер тынычлану китерде. Бамбукның үз җае белән генә сикерәнләп баруы аңа һәрнәрсәгә фәлсәфи нәтиҗә ясау мөмкинлеген бирде. Юлга чыксаң, анда таң калырлык тормыш ыгы-зыгысы икән; кырмыска түмгәгендә дә, агач ботагындагы карга оясында да, сарут төбендәге тычкан өнендә дә, күзең кичерә, зиһенең сыйдыра алган һәр төштә, һәр адымда яшәү өчен көрәш бара икән; бөтенләй таныш түгел кешеләр туганыңнан да якын туганга әверелә икән; юл ялгыз итми, ялгыз итсә — кансыз да итә; юл ач итми, ул ашата һәм эчертә, чөнки ул кешеләр һәм язмышлар кайнашкан чиксезлеккә алып бара...

Нәстүк күптән кайтып җиткәндер инде. Аның исәпләвенчә, эзәрлекләүчеләр бүген кайтмаска тиеш. Совхозга баргач, әлбәттә, Бөкебаш бабасын талап эчәчәк. Исерәчәк. Елаячак. Һәм куныч та калачак...

Атлам дисәң атлам, сикереш дисәң сикерешкә охшамаган сәер хәрәкәтләр ясап һәм могҗизалы җанварны хәтерләтеп, Бамбук тагын да Сабыр кичүенә якынлашып килә. Ялгышмаса, бу авылга кайтып җиткәнче соңгы кичү булырга тиеш. Ул үзен өйдә итеп тойды.

Теге ярга аяк басуга, караса, кичү башында таякка таянган әби һәм биш-алты яшьләр чамасындагы малай басып тора.

— Балакаем, кичү кайда монда?

— Кичү шушы була инде, әби.

— Анысын күрәм дә бит, әмма бер генә дә аяк басар әмәл тапмыйм...

— Хәзер...

Кәбир атны сирәк куаклыклар ураткан акланга кертте. Аның үлән учмаларын комсыз рәвештә өерелтә башлавын күреп куанган малай әбигә ярдәмгә ашыкты.

Агымга зур җәйпәк ташлар ыргытып, мосафирларны аргы ярга чыгарды. Теле авызыннан сәленеп төшкән һәм шул сәбәпле селәгәе агып торган сабыйга ымлап, әби:

— Бизгәк чиреннән шулай калды, мескенкәй,— диде.— Ятимнең дә ятиме. Атасы сугыштан кайтмады, инәсе быел яз ташуга акты... Картинәсе булам...

Кайда баралар, кайдан кайталар алар? Сорашмады Кәбир. Барыбер түгелмени? Шулай да шикләнде. Шикләнүе дөрес тә булып чыкты:

— Сорашып йөрибез... Ходай тәгалә үзе кичерсен инде...

Кәбир капчыгын салды, Нәстүк алып килгән алабута икмәгенең яртысын әбигә сузды:

— Суга чылатып ашагыз. Алабута ипие эчне катыручан була...

— Ыгы-ыгы...

Ипигә кул сузган малай телсез иде. Ул сирәк сары тешләрен әби сындырып биргән түтәрәмгә батырды.

— Рәхмәт, балакаем. Үзеңә калдымы соң?

— Монда җитәрлек, әби.

Карчык озын гына дога укып, амин тотты.

— Юл шәрифләреңә бәрәкәт бирсен, балакаем. Ходай сине ипидән һәм илдән аермасын...

Күп тә үтми, сорау билгесенә охшап бөкерәйгән, сул кулы белән таякка таянган, уң кулы белән оныгын җитәкләгән әби соры кояш нурларына кереп эреде.

Тирәнрәк урынны чамалап, Кәбир су кереп чыкты. Колач салып йөзәрлек булмаса да, тәкъдир кушкан төштә үз-үзенә «упкын» табып, йөзде, уйнап, куллары белән дулкыннар чайпалтты, чумып, су астында

озак кына тынсыз торганнан соң, нур сыман тишелеп чыгып, чуерташларны тезләре, корсагы белән ышыра-ышыра, ярга шуышты.

Киенгәч, аңа җиңел булып китте.

Аты янына килеп, ул тагын капчыгын чиште. Ипидән ипи исе дә килми иде. Шулай да Нәстүккә рәхмәт. Ул ипинең бер өлешен Бамбукка каптырды. Учак ягып, бәрәңге тәгәрәтеп алды. Ярый әле чегән туганнар аның шырпысына кагылмаганнар. Шырпы бит хәзер алтын бәрабәренә йөри! Бер колак көпшә җыеп алып килеп, ул ипине сусыл азык һәм бәрәңге белән бергә сыптыра башлады.

Алар тагын юлга төште.

Юл янәшәсендә, сул яклап, каен катыш имән урманы башланды. Малай үзе дә сизмәстән җырлап җибәрде:

> Кара да гыналай урман, караңгы төн,
> Яхшы атлар кирәк үтәргә...

Көтмәгәндә йөрәктән өзелеп чыккан нәзек, яңгыравык тавыш кайдандыр бер төркем чәүкәләр тубалын күтәрде. Ничәмә-ничә көн бергә булып, үз ирке белән бер генә тапкыр да җырламаган малайның әле килеп моңы чишелүен ишетеп, Бамбук та башын кәңкәйтеп куйды.

> Заманалар авыр, еллар ябык,
> Дус-иш кирәк дөнья көтәргә...

Бамбук туктады. Кәбир аңа тагын да тоз каптырды.

— Әйдә, малкай, бераз тын ал.

— Хәлем бетте, Кәбир. Башкача бара алмыйм.

— Күп калмады, Бамбукҗан. Әнә, Ишле дә күренә инде. Анда сиңа тагын да сөтле солы ашатырбыз...

Байтал малай сузган икмәкне теләр-теләмәс кенә чәйнәде. Малкайга көч бирә торган азык эзләде ул тирә-якта. Капчыкта калган биш-алты бәрәңгенең файдасы булмас. Арырак яшелләнеп яткан басуга йөгереп, бер кочак башакланып килгән бодай яшеле алып килде. Анысын да чәйнәштерде байтал.

— Әйдә инде, малкаем!..

Үзәк өзгеч иде бу аһәң. «Аңлыйм да бит, нишлим соң?» дигәндәй үзе дә аптырап торган байтал, ниһаять, көчен туплап, алга ыргыды. Алар кузгалганда чәүкәләр юл читендәге агачларны яңадан сырып өлгергән иде. Кемдер һау-һаулаган, җиңелчә генә чыбыркы шартлаткан тавышлар ишетелгәндәй булды. Күп тә үтми, каенлыкның авылга житеп кенә тукталган тәңгәленнән атлар өере килеп чыкты да, уңга борылып, Сабыр буена төшә башлады. Куе тузан аша ишетелеп кенә калган тавышлардан Кәбир аларның ат кунасына баручы малайлар икәнлегенә ышанды. Ерак китәрме алар? Таба алырмы атлар көтүен Кәбир? Нәрсә булса да булыр, дип, малай Бамбукны шул якка борды.

Кыңгырау тавышларын чамалап, алар тапау болынлыктан барды да барды. Күз тәмам бәйләнде. Атлар һаман да күренмәде. Юрган кебек йомшак, куе, тыгыз кондырак үлән оя-оя итеп оешкан бүтәкәлеккә, эчкә таба бу бүтәкәлек кыска күрәнле сазлыкка әйләнә башлады. Кыңгырау инде якында гына чыңлады. Малайлар сөйләшкән, сызгырышкан тавышлар да ап-ачык ишетелә. Күрәсең, алар агачлар артындагы акландалар. Байтал белән янәшәдән барган Кәбир аяк астының тотырыксыз булуын сизенде.

— Тукта, Бамбук.

Байтал туктады.

Урынсызга шикләнмим микән дип алга ун-унбиш адым ясарга өлгермәде, аяк кинәт йомшарды, ялган яшел юрган ертылып китте һәм ул үзенең мизгел эчендә тездән сазга батуын сизми дә калды. Бер аягын чыгарам дигәндә икенчесе тагын да тирәнрәк батты. Сазлыкның сасы, үзле ләме тездән югары күтәрелеп, бот төбенә дә житә башлады. Суыра

аны сазлык, суыра болай булгач! Бар тирә-як караңгы. Айның да юньлерәтле яктыртмаган, бер игелексез сәгате иде, билләһи!

Бамбук, ыңгырашып, аңа таба елышкандай тоелды.

— Килмә, Бамбук, батабыз!..

— Кот-ка-ры-гыз! — дип кычкырырга тотынды ул.— Кот-кары-гыз!..

Хуҗасының һәлакәткә эләгүен күзе белән үткер күргән һәм аңа берничек тә ярдәм итә алмаган байтал, бу акыллы һәм сизгер хайван, сызлаулардан, михнәтле юлдан, тозлы тирдән һәм кан басымыннан иңрәгән башын югары чөйде һәм кешнәп җибәрде:

Кичке тыныч һәм тымызык һава урталай ярылды. Артта шаулашкан тавышлар ишетелде.

— Монда ки-ле-гез! — дип чакырды малай тавышларны.— Монда-а-а!..

Тавышлар якынайды. Кемдер авыр итекләр белән дөпелдәп килеп, аңа бау ыргытты. Инде күкрәгенә кадәр сазга сеңгән малай бауның очын эләктереп алды. Караңгыда шаулашкан кешеләр, күмәкләп, аны тартып та чыгарды. Малайлар бәлагә тарыган һәм бөтенләй таныш булмаган атны, аннан да бигрәк үзләренә тиң үсмерне күреп, уратып алдылар.

— Син кайдан, әй?

— Моннан киләмени кеше? Бу бит убыр чокыры...

— Туктагыз, малай актыклары! — дип тынычландырды аларны арадан бер өлкәне.— Кешегә тын алырга ирек бирегез ичмасам! Барыгыз атларыгыз янына, учак тергезә торыгыз. Көш-көш-шу-у!..

Үзен коткаручының йөзен юньләп күрә алмады Кәбир. Шунысын гына абайлады — озын буйлы, көр, кискен тавышлы иде ул. Сизенүенчә, ул нәкъ Чтапан дәдәй әйткән ат караучы Нәби булырга тиеш.

— Бу — безнең убыр чокыры, знат. Белмәгән кешегә турыдан чыгам дип алдануы җиңел... Кайбер елларда шулай җәй буе быкырдап ята...

Теге ярда калган Бамбукны, уратып, бирге ярга чыгарырга кирәк иде. Алар түмгәләктән түмгәләккә сикереп, байтал янына ашыктылар. Нәби булырга тиешле кеше алдан юл саба.

— Кайсы авылдан буласың? Кайдан киләсең?

Малай, форсаттан файдаланып, кыскача гына барысы хакында да сөйләде.

Бер сәгать чамасы вакыт үтүгә, алар урау-урау сукмаклар белән Бамбукны атлар табырына алып килделәр. Учак янына житәрәк, тугарылып куелган һәм яшел печән тутырылган фурман янына туктадылар. Барысын да аңлап алган Нәби Бамбукны ике каен арасына кертте һәм нәкъ Чтапан дәдәй кебек, тасма дилбегәне ике катлап, бер очын бер каенга бәйләп, икенче очын атның күкрәге астыннан үткәреп, икенче каенга бәйләргә азапланды. Ат кадәр атны күтәрү, аны бигрәк тә күтәрткән килеш агачка бәйләү бик тә уңайсыз иде.

— Мәкәрим, Рәхмәтулла, Рәхимҗан! — дип кычкырды ул учак янында кайнашкан малайларга.— Килегез әле монда, туң колаклар!

Ук кебек атылып килгән малайлар Нәби абзыйларына честь бирделәр.

— Ярдәм итешер идегез...

Озак та үтми, ал саны җирдән бераз күтәртелеп куелган Бамбук авызына ук тартып китерелгән фурманнан хуш исле үлән кымтый башлады.

— Кунак бар, егетләр... Син, Мәкәрим, атыңны ал да авылга... Ә син, Рәхимҗан... Абзый малайларның колагына пышылдап, нидер әйтте.

— Есть, иптәш командир!..

Малайлар юк булды. Беренче карашка гына кырыс, каты куллы, кискен кеше күренгән ирнең балалар белән балаларча кыйлана белүе тетрәтте Кәбирне. Тояк тавышлары ишетелеп кенә калды. Учак яны да тынды. Нәби байталның сыртыннан сыйпаштырып, куллары «күн итек» таңгәленә җиткәч, малкай тынычсызланды.

— Газаплана,— диде Нәби абзый.— Сөйләргә теле генә юк бит, бахыркайның... Ир белән ат икесе дә бер ак сөттән яралган газиз җаннар алар. Бер сабырлык, бер канат ир-атка...— Исенә килгәндәй, ашыктырды.— Әйдә, учакта җылы җитәр. Ачыккансыңдыр да, знат... Исемең ничек була?

Ачыгудан бигрәк ләм көпесе белән капланган киемдә ул үзен бик сансыз тоя иде.

— Ничауа... Алмаш киеме дә табылыр. Үзебезнең кулда, знат...

«Үзебезнең кулда». Кәбир бу сүзләрнең мәгънәсен аңламады. Нәрсә үзебезнең кулда? Атмы? Киемме?

— Сез ат караучы Нәби абзый түгелме?—дип сорарга җөрьәт итте малай учак каршына килеп чүгәләгәч.

— Нәкъ үзе булабыз. Ә син аны кайдан белдең?

— Мин бүген Тушкырда Чтапан дәдәйдә кунып чыктым. Ул сезгә күптин-күп, чуктин-чук сәламнәр тапшырырга кушты.

— Ә-ә, шулаймыни?—Нәби абзый җанланып китте.— Нигә аны баштук әйтми торасың, туңколак? Чтапан-петчәне күрдең, знат? Нихәлдә яши?

Үзенең дә «туңколак» булуына куанган Кәбир артык эчкә кермичә генә сөйләп бирде. Елга буеннан малайларның шат шаулаган тавышлары ишетелде.

— Балык сөзәләр,— диде Нәби абзый.— Мин аларны эшләтеп ашатам...

Үз даирәсен сагынган Кәбиргә малайлар белән бергә буласы килеп китте. Әмма һичничек тә мөмкин түгел иде бу. Беравыкка тын калдылар. Тынлыктан файдаланып, Кәбир әйтеп куйды:

— Сездә ат кунасына фурман белән йөриләр икән...

— Нигә алай дисең? Сездә йөрмиләрмени?

— Безнең Сәми бабай кунага ат өстендә генә бара.

— Беләм мин Сәми абзыйны...

Ул сүзен тәмамлый алмады. Тегеләр авылдан урап та килделәр.

— Әйдә өс киемнәреңне югалаштырыйк, булмаса,— диде Нәби абзый аттан сикереп төшкән Мәкәримнең кулыннан төенчек алып.— Корысын киярсең, знат.

Алар елга ярына килделәр. Малай чишенергә дә, кеше киемен кияргә дә уңайсызлангандай итте.

— Кайдан килгән көйсез кияү?—Нәби абзыйсы аны дусларча гына кыздырып алды.— Чишен дигәч, чишен. Бер дә читнеке түгел, мин сугышта чакта вафат булган улымныкы...

Малай чишенеп ташлап, елгага төште. Аның белән янәшәдә айның алтын ыргагы да йөзде. Күлмәк-ыштан бик таман булып чыкты. Сирәк-сарак сөйләштергәләшеп, алар Кәбирнең пычрак киемнәрен юдылар. Нәби абзый ата-анасы, туганнары хакында сорашты.

— Җиңеп кайтуын кайттык,— диде ул Кәбир хикәятеннән соң авыр сулап.— Әмма бер дә рәте-чираты юк дөньясының... Син әйткән Бөкебаш Галләметдиннәр баш безгә. Ә без, Чтапаннар һәм Нәбиләр, җиңүчеләр, знат, Бөкебашлар җигеп йөри торган айгырларны карыйбыз... Чтапан белән күптән таныш без. Фронтка да бергә киттек... Әмма юллар аерылды. Шәп кеше ул, Чтапан!..

Юылган киемнәрне күтәреп, алар учакка таба юнәлделәр. Балык шулпасының исе бар тарафка таралып та өлгергән. Учак тирәсенә түптүгәрәк итеп сырланган малайлар катына җиткәч, Нәби абзыйлары көтелгән сорауны бирде:

— Ну, балык мул эләктеме, туңколаклар?

— Теге җәен тагын ычкынды, Нәби абзый, ул нәкъ безнең Салих кебек, хәйләкәр икән...

— Син аның зурлыгын күрсәң! Монавы фурман кадәр бардыр!..

— Элэгәсе эләкте шунда,— диде казан янында кайнашкан малай.

Салих дигәннәре шул икән.— Биш-алты ташбаш, кызыл канат...

— Шомарта, Нәби абзый, шомарта,— диде балык сөзүне оештырган Рәхимҗан.— Үзем санадым. Йөз дә утыз ике ташбаш, өч йөз алтмыш биш шыртлака, алты йөз унбиш кызыл канат...

— Салих киметсә, син арттырырга оста инде, знат,— диде Нәби абзый тыныч кына.— Балык пешүгә, Салих энем, иң зурысын кунакка, аннан бәләкәйрәген көрәштә җиңүчегә бүлеп куй...

Нәби белән Кәбир учакның җылы тыны житәр аралыкта ике чатлы казык кагып, аркылы агач суздылар да, юылган киемнәрне кипшенергә элеп куйдылар. Озынча бакыр йөзле, кечкенә буйлы, җиң ертыгыннан терсәкләре чыгып торган Рәхимҗан, камыт аяклы, гел көлеп кенә сөйләшә торган Мәкәрим атларны табырлау өчен сүзсез генә караңгылыкка чумдылар. Яраталар Нәби абзыйларын малайлар. Кәбир ышануынча, ул аларны ат кунасына бик теләп йөртә, көрәштерә, йөгертә, мөмкин булганда, тамакларын да туйдыра икән. Әнә ул фурман тапкырындагы каенга эленгән ике чалгыны алды да, үләнлерәк җир эзләп, китеп барды. Малайлар белән бергә Кәбир дә аның артыннан иярде. Күп тә үтми, төнге болынны парлы чалгының выжт-выжт итеп үлән кырыккан тавышлары басты. Икенче чалгы белән Кәбир төшкән иде. Нәби абзый пакусын катлап чыкты, чабылган печәнне чалгысы белән күбәләде:

— Учак тирәсенәрәк түшәгез...

Алар кире учак янына килгәндә Рәхимҗан фурманнан иске паласлар, бишмәтләр алып, үлән өстенә җәеп маташа иде.

— Көрәшчеләргә бүләк әзер! — дип каршылады аларны Мәкәрим казан янына түшәлгән какы яфракларына пешкән балык бушатып.

— Йәгез, туңколаклар, тотыныгыз.— Нәби абзый казанны бер читкәрәк алып куеп, учакка коры-сыры өстәде. Үрчеп киткән озын телле ялкыннар яктысы малайларны гына түгел, бөтен болынны яктыртты.— Алдан ук кисәтеп куям: хәрәмләшмичә, аяк чалмыйча көрәшергә, знат. Хөкемдар — үзем!..

Малайлар, Кәбирне санамаганда, сигезәү иде. Алар тәүдә ике төркемгә бүленеп көрәштеләр. Аннан җиңүчегә җиңүче чыкты. Рәхимҗан тыңкыш Имаметдинне чырк итеп кенә җиргә чәпәде. Рәхимҗанны чегәнгә охшаган кара малай Зикаф баш аша очырды. Соңгылар булып Зикаф белән Мәкәрим очрашты. Кәбир бөтен күңеленнән Мәкәримнең җиңүен теләде. Сәер исемле, үскәч, сакал җибәргән хәлдә, нәкъ теге сакалбайлар кебек булачак Зикаф аңа нәрсәсе беләндер ят сөяк тоелды. Әгәр ул җинсә, кем белә, каршы чыгарга Кәбир үзе дә күп сорамас иде. Билләреннән эләктерешеп алган малайлар, җирне сөреп, бер-берсенең көчен һәм ныклыгын сыный башлады.

— Ә-тә-тә-тә-ң,— дип көрәшчеләрне тирәләп әйләнде Имаметдин.— Бирешмә-ң Мәкәрим, кабыргасын сана-ң, Зикаф!..

— Җирдән күтәр, Мәкәрим! Әнә шулай!..

Мәкәрим Зикафны чынлап та җирдән аерган иде. Күп тә үтмәде, ул тегене күтәргән килеш өерелдерде дә, янтаеп, әйләндереп тә салды. Болын гөр килде. Нәби абзый какы яфрагында парланып яткан кызыл канатны алды да:

— Туңколакларның бердәм карары буенча иң зур балык җиңүче Мәкәримгә тапшырыла,— дип тантаналы рәвештә игълан итте.

— Кул чабыгыз, туңколаклар!

Бердәм кул чаптылар.

— Монысы кунагыбыз Кәбиргә!..

Туңколаклар тагын да болынны яңгыраттылар.

— Ә хәзер, ипи шүрлекләрегезне казанга якынайтыгыз!

Ипи шүрлекләре даими буш булган малайлар, кашыклар белән коралланып, казанны сырып алдылар.

Шулпасы да, балыгы да ифрат тәмле булды. Корсаклары тулган туңколаклар, болын буйлап йөгерешә, куыша башлады.

— Сез, төн убырлары, знат, көчләп яткырмасаң, ята белмәссез,— дип оран салды Нәби абзый.— Ну-ка, по ранжиру, ложись!

— Есть, тауариш командир!..

Кәбирнең карашы бушап калган чуен казанның төбенә төште. Артып калган балык шулпасының өресендә ат күзе булып ай ялтырый иде. Кәбир Бамбугы янына хәл белергә барды. Байтал яшәү өчен тырышып ята иде. Ул аның ялларыннан яратты.

— Мин дә ятам, Бамбукҗан. Икебез дә иртәгәсе соңгы сикерешкә көч туплыйк...

Малайлар үзләре белән алып килгән палас-бишмәтләрен ябынып, хуш исле үләнгә түшәлделәр. Иң читтән озын буйлы Салих, аннан кыскарак Зикаф, аннан такырбаш Имаметдин, аннан Мәкәрим, аннан Рәхимҗан һәм башкалар тезелде. Нәби абзый әйтүенчә, солдатларның буй чамасыннан чыгып тезелүе ранжир дип атала икән. Ул үзе белән янәшәгә Кәбирне яткырды. Алар чүпрәк палас, аның өстеннән тун да ябындылар.

Сүрәнәя төшкән учак уты калтырана-калтырана янәшәдәге агачларны яктырта. Байталны татлы борчыган кыңгырау тавышлары ишетелеп куя. Пошкырып һәм тояклары белән дөпелдәп, тышаулы атлар үлән кетердәтә. Алар арасында авыр тын алып, Бамбукның да үлән чүпләштергәне шәйләнә. Карын тук. Җылы. Өс бөтен. Күктә йолдызлар... Газаплы да, күңелле дә икән бу тормыш! Малайлар тагын пышылдаша, көлешә башлады.

— Табышмак әйтәм, табыгыз! — диде Рәхимҗан.— «Ике чите салынган, аңа ирләр ялынган». Нәрсә була?

— Бишмәт!

— Ха-ха-ха!

— Чабата!

— Хи-хи-хи!

Бу сәер табышмак малайларның һушын алды.

— Таптым-ң,— диде палас астыннан чыелдап тыңкыш Имаметдин.— Әйтмим генә-ң...

— Сиңа ышансаң,— диде кемдер.— Менә мин таптым. Колаклар!

— Юләр! Колаклар ул хатын-кызларда юкмыни?

Тагын да дәррәү көлештеләр.

Рәхимҗанга үзенә әйтергә туры килде. Баксаң, ул һәркемгә таныш нәрсә икән:

— Бүрек!..

— Вәт, әй, үзебез шуны киеп йөрибез, ә үзебез...

— Кармавычлар әйтешик, кармавычлар!

— Үзең башла!

— Сезнең кызлар безнең кызларга кер тукмаклаштырмакчылар иде, тукмаклаштырсалар, тукмакларын алып килсеннәр, тукмаклаштыргаламасалар, тукмакларын биреп җибәрсеннәр...

Шактый каты төш булып чыкты бу тел кармавычы. Күпләр телләрен сындырды:

— Тукмаклаштырмасаларасан... ман... мак... сак...

— Малайлар, йоклагыз, дим! Иртәгә бәйрәм түгел...

Әмма алар тыелып кына көлүләрен дәвам иттеләр.

— Нәби абзый, Буләк кунагы гына әйтсен дә! Нинди рәк кармавычлар әйтәләр икән аларда? Отып калыйк!..

— Тыңлагыз,— диде Кәбир.— Карамалыдан кара малайга чана карамалатырга биргән идем, карамалады микән кара малай, карамаласа да, карамаламаса да, карамалаганына да, карамаламаганына да карамыйча, карап кайт. Ул карамаламаса, үзем карамалармын. Амин!..

— У-у!..

— Бу Бүләкләрнең очына чыгарлык түгел...

— Кәбир, иртәгә иртән син безгә моны язып бирерсең. Без теге оч малайларының һушын алачакбыз!

Нәби абзыйларының ачуын кабартудан шөлләгән малайлар ябынган хөлләләре астында гына сөйләшә башладылар.

— Малайлар, житте, знат!..

Ниһаять, барысы да тынычланды. Озакламый алар берәм-берәм мыш-мыш килеп йокыга талды. Төн суыгы жиргә төшә башлады. Кәбир колак салды: Бамбукның йөгән тимерләре фурман үрәчәсенә бәрелеп-сугылып ала. Ул күкнең асылташлар белән ачылган гөмбәзенә бакты. Әнә, Алтын Казык. Әнә Җидегән йолдыз. Урыны-урыны белән йолдызлар тыгыз кишәрлек булып сибелгән. Бу йолдызлар барысы да күккә ашып, йолдызга әйләнгән ир-ат йөрәкләре генә түгел, ир-ат күзләре булып та тоела башлады малайга. Кайда икән хәзер Бамбукның күзе? Кайсы йолдызда? Атасы-анасы, Чтапан дәдәйнең, Нәстүкнең, Нәби абзыйның күзләре һәм йөрәкләре кайсы тирәдә яктырта?

Иңен иңгә терәп, аның белән янәшәдә генә Нәби абзыйсы гырлап йоклый. Димәк, аның хәзер гәүдәсе генә жирдә. Ә күзе йолдыз булып, күктән яктырта... Чәчкә тажы кебек, малайның да күзләре йомыла башлады. Менә ул саташып һәм төшләр күреп, йокыга талды...

... Бамбук белән Кәбир Ишледән Бүләккә очып баралар, имеш. Аста Сабыр елгасы, таулар һәм үзәннәр күзгә чалынып кына кала. «Синең канатларың ял итсен, минем канатлар житеп торыр»,— дип эндәшә, имеш, аңа байталы. Менә алар Сабыр буасындагы су тегерменe битләвенә, нәкъ авыл кырыендагы каберлек янына очып килеп төшәләр. Карасалар, Соры Бүре тешләрен ыржайтып, кабер казый. «Мин ач, мин әрвахләрне ашыйм!» — ди, имеш.

... Саф салкынлык тоеп, Кәбир күзләрен ачты. Таң атып, жир өсте яктырып килә. Нәби абзыйсының урыны буш. Ул үз паласын кунак малае өстенә катлап япкан да, каядыр китеп югалган. Таңда төшкән чыктан авыраеп китеп, гәүдәне баса башлаган жылы палас эченнән кулын чыгарып, капшап карады — салкын юештән шундук качты — әйе, чык мул гына төшкән икән шул. Кичә кичергән вакыйгалар һәм теге ат кунасы күренешләре телсез кино булып күз алдында жанланды. Кайтасы араның нибары сигез-тугыз чакрым икәнлеген искә төшергәч, жинел сулап куйды. Саташу катыш күргән төшләре дә хәтеренә килде аның. Соңгы вакытта бер-берсен дәвам иткән бер үк төшләргә аптырамый иде инде ул хәзер.

«Туңколаклар» изелеп йоклый. «Минем кебек ятимнәрдер инде»,— дип уйлап алды малай. Ул кичә кичен генә танышкан дусларының өсләреннән шуышып бишмәт-паласларын рәтләде дә Бамбукка таба атлады.

Таң алсулыгында йөзгән каеннар уемына килеп житкәч, ул көтелмәгән күренешкә аптырап, туктап калды: фурманның теге ягында аңа арты белән баскан да, Нәби абзыйсы байталның муеныннан кочкан һәм башы белән аның ялларын сөрә-сөрә, нәрсәдер мыгырдана иде. Елаган төсле дә тоелды ул Кәбиргә. Ат исә ашавыннан туктап, башын Нәбигә борган, борыны белән аның аркасын, жилкәсен, муены житә алган һәр төшен фыр да фыр килеп, «ынхыһы-һыынхыһы-һы» кебек авазлар чыгарып исни... Аларга комачауламаска тырышып, Кәбир арба астына чүкте, аны хәзер Нәби абзыйсыннан һәм Бамбуктан арбадагы калдык печән каплый иде.

Кинәт Нәби ялдан аерылды, байталның башын үзенә каратып, куллары белән аның йолдыз кашкасыннан сыпырып төште, күзләренә уктал-ды, аңкауларын күтәртеп, тешләренә кадәр тикшерде, аннан тагын югары үрләп, колакларыннан сыйпады һәм тагын мыгырданды. Бу юлы кайбер сүзләре ап-ачык ишетелде:

— Булмас... Булмас... И малкай!..

Куллары белән сыйпый-сыйпый ул байталның арт санына таба китте, янбашка җиткәч, анда өтергә охшап төзәлгән яраны тикшергәндәй итте.

Ул Кәбиргә исерек кебек күренде. Әмма Нәби якты пыяла кебек аек иде.

— Бамбук... Бамбук...— дип пышылдады ул.— Димәк, син дә исән?!

Соңгы бер атна эчендә нәрсәләр генә күрмәгән-кичермәгән малайның бу кадәре аптыраганы юк иде әле. Кайдан белә Нәби абзыйсы Бамбукның исемен? Ул сорамады, Кәбир әйтмәде ләбаса!..

Менә ул аттан аерылды, чайкала-чайкала каеннар арасындагы алсулыкка керде һәм кесәсеннән ниндидер ак тукыма чыгарып, нәкъ Бамбук каршына җәйде; авыз эченнән сөйләнә-сөйләнә, чабаталарын чишеп ташлады һәм сөттәй ак тукымга басып, Кәбир бөтенләй аңламаган телдә кычкырып, тәкбир әйтә башлады... Нәби абзыйсының мәкаме искиткеч матур иде. Ул аның өчен ниндидер бер чабаталы «знат» түгел, ә илаһи бер зат булып яктырды. Иртәнге саф һавада әйтелгән тәкбир җанга кереп яңгырады. Әле генә тын торган, әле генә мыгырданган, әле генә елаган кеше хәзер җырлый диген син, ә?

Бер аякларына басып, бер яңадан сәҗдәгә китеп, Нәби абзыйсы намаз укыды. Менә ул кул яссыларын кушырып, намазын багушлауга да барып җитте:

— Хәтәр сугышларда башлары югалган ватандашларым, барлык тере һәм тере булмаган рухлар ихтыярына кабул ит, илаһым. Үз табигатең һәм чит табигатьләр иминлеге хакына! Балаларым, балаларымның балалары хакына ошбу Кәбир атлы ятим сабый, рыясыз ат җаны — Бамбук кардәшемне, сугышларда исән-аман саклап калдырган канатым итеп, барлык сырхаулардан азат ит, күктән очырт, җирдән йөгерт, илаһым! Ошбу ир-ат җанын кош-корт күзеннән, кешебашлы козгыннар кулыннан сакла, илаһым! Кан-Күрәзә кошы, ялваруларымны ишет... Бу газиз җаннарны ат каракларыннан, дошманнан ерак йөрет! Куам төн карасын, ходай ярлыкасын, үлегә — иман, терегә — бәрәкәт!.. Амин!..

Урыныннан күтәрелеп, намазлыгын җыештырган арада аның алдында Кәбир калкып чыкты.

— Иртәләгәнсең,— диде Нәби кулындагы таслап төрелгән намазлыгын кесәсенә салып. Аның күзләре кызарган һәм дымлы иде.— Нигә йокламыйсың?

— Йокым туйды.

— Туйды, знат? — Ул башы белән Бамбукка ымлады.— Ярыйсы гына тырыштырган... Алдында салганны әйтәм. Мин аны эчердем дә. Бик акыллы, нәселле мал күренә. Җигәләр идеме?

— Җигәләр генәме! — дип кычкырып җибәрде Кәбир.— Иманын савалар, Нәби абзый!

— И-и, мондый бияне шулай алҗыталармыни... Буаз да күренә, знат. Исемен ничек дидең?

— Бамбук.

Нәби абзыйның болай да аксыл йөзе тагын да агарынып китте.

— Бамбук, знат... Авылда шулай кушканнармы аны?

— Военкоматта кушканнар, диләр. Ул сугышта да булган, имеш. Безнең колхозда бердәнбер пашпортлы ат...

— Алай икән. Колакка ничек соң?

— Элегрәк колакка каты булган. Хәзер әлләни сизелми.

— Бамбук... Исеме дә мәрәкә, знат. Ул нәрсә була икән инде?

Нәби абзыйсы әллә белеп, әллә белмичә биргән булды бу сорауны.

— Бик тә җылы якларда үсә торган агач диме шунда...

— Бамбук, знат... Шулай дип уйлаган идем шул...

Ул атның башын кочаклап, аның томанлы күзләрен үз күзенә терәде.

— Менә без тагын очраштык, Бамбук. Туган илебездә. Шөкер! Исәннәр бер килеп очраша икән...

Ул хәзер чынлап та елый иде. Күрәсен күргән, кем әйтмешли, яшисен яшәгән, ашыйсын ашаган ир үзенең күз яшьләреннән оялмады да, сөртергә дә ашыкмады. Ул тагын да йөзне йөзгә, күзне күзгә текәп, Бамбукка эндәште:

— Таныйсыңмы син мине, Бамбук? Воронежны хәтерлисеңме, картлач?

Кәбир өчен күргәне-ишеткәне серле төш булып тоелды. Ул да, үзенә-үзе ышанмыйча, байталның күзләренә капланды. Әле генә томанлы бәбәкләр зәңгәрсу энҗе булып яктырган иде. Ак каеннар чагылгандай була аларда.

— Таныйм,— диде Бамбук.— Таныйм, Нәби.

Әмма моны Кәбир генә ишетте.

— Таныйсың шул... Танымасаң, син дә еламас идең...— Нәби кесәсендә кульяулык-фәлән эзләп, тапмагач, намазлык тукымасы белән атның күзендәге яшьләрне сөртте дә, аннан үзенекен сыпырып алды.— Таныйсың, знат...

Бу могҗизага әле һаман да ышанып җитмәгән малай, бер караганда, бөтенләй мәгънәсен югалткан сорау бирде:

— Син Бамбукны кайдан беләсең, Нәби абзый?

Нәбинең йөзеннән дәһшәтле шәүлә үтте. Ул күңеленнән малайга рәнҗегәндер дә, мөгаен.

— Мин аның белән... сугышта... бергә булдым,— диде ул, гүя, һәр сүзне авырлык белән сыгып чыгарып.— Аңлыйсыңмы син, сабыем?.. Бамбук — минем фронтташым, җиккән атым. Ул мине үлемнән коткарып калды.

— Фронтта атларны... җигәләр дә мени?

— Җигәләр дә шул, энекәем. Кил әле монда!..

Ул малайны үзенә тартып алып, Бамбук янына китерде һәм алгы ботына төртеп күрсәтте:

— Шәйлисеңме сан эзләрен? «191» дигәнне сиземлисеңме? — Ул баш бармагын йон белән капланган эздән үткәрде.— Кызган тимер белән баскан тамга ул, знат. Бөтәшкән, кәнешне, йон баскан.— Ул Кәбирне җилтерәтеп диярлек байталның арткы уң боты тәңгәленә алып килде. Тагын да бармагы белән эзләр сызды.— Күрәсеңме, «РККА» дип язылган булган? Рабоче-крестьянская Красная Армия, знат. Әлбәттә, күңел күзе күрмәсә, аны тоймаска да мөмкин... Алты ел үткән бит бу тамгаларга, алты ел!

Кәбир куанычыннан тәмам түземлеген җуйды.

— Бамбукны сугышта булган дип сөйлиләр иде, дөрес икән! — дип өзгәләнде ул.— Нәби абзый, сөйлә әле, сез аның белән ничегрәк табыштыгыз? Ул ничек сине коткарып калды?

— Озын тарих ул, Кәбир энем... Бер килеп чыгарсың әле, иркенләп сөйләрмен, ямме?

— Ә син кыскача гына сөйлә.

— Сугыш хатирәләрен һич кенә дә искә төшерәсе килми бит әле. Монандый матур иртәдә, знат...

— Сөйлә инде!.. Син аны сөйләргә, мин аны белергә тиеш.

Нәби атның янбашындагы яра эзенә төртеп күрсәтте:

— Мина дип очкан снәрәт кыйпылчыгы эзе ул.

— Нинди снәрәт иде соң ул, Нәби абзый? Зурмы, бәләкәйме?

Нәби абзыйсы көлемсерәми түзмәде. Алар бераз читкәрәк китеп, үләнгә утырдылар.

— Син түлке моны малайларга сөйләмә. Күпертергә ярата ул тунколаклар. Аннан... бер дә мактанырлык нәрсә юк монда. Без фронтка Бамбук белән Кыргыздан ук бергә киттек. Ул безнең як аты, тик белә генә алмадым — кайсы хуҗалыктан? Ә ул, знат, болай килеп чыкты. Безне бер рәткә, атларны каршыдагы рәткә тезделәр. Муеннарында язу — исеме, ничә яшьтә... Аның исеме дә, җисеме дә миңа ифрат ошады.

Акчунга үз хутыбыз белән бардык, аннан шалуннарга төялеп, алгы сызыкка... 1942 елның башы иде, знат. Без Бамбук белән комендантский взводка билгеләндек. Корал-снәрәт ташырга. Ошады миңа куе бурлы. Сизгер. Йөккә дисәң йөккә, меңгегә дисәң, меңгегә әзер. Әллә кайлардан танып ала, сызгыруым була, килеп тә җитә, малкай. Тамакка да талымсыз. Шунысы әкәмәт, мин аның бия икәнен алгы сызыкта гына белдем. Бүген килеп аптырыйм, Кәбир энем, ничек эләккән ул сугышка? Комиссиядән ничек үткән? Бияләрне алмыйлар ие дә бит... Бары тик айгырларны, алашаларны гына алдылар. Айгыр малын шундук печтерәләр иде. Ә бу — бия! Атлары җитмәгәч, берәр колхоз военкоматка күз буяп, алаша урынына байтал тыкканмы? Әллә башка берәр сәбеп булганмы — хәзер аны кем белә инде. Әгәр мин аны Кыргызда, йә Акчунда белгән булсам, мөгаен, баш тарткан булыр идем... Ярый әле белмәгәнмен...

Аһ, атлар күп кырылды, атлар исә кешедән ким кырылмагандыр. Безнең белән килгәннәр сугышның тәүге айларында ук кырылып беттедиярлек. Кавалеристларга атларны Кубаньнан китерделәр. Безгә алар эләкмәде. Сөлек кебекләр. Өйрәтелгәннәр, мин сиңа әйтим. Әкчә белән кабыргасына төртәсең — алып олага, аяк очы белән төртсәң — шып туктый, тезләнә, өстендәге җайдагы белән бергә җиргә сылашып ята, ышанасыңмы? Күпме гомерләрне саклап калды ул бахырлар...

Нәби абзый күзләрен челт-челт йомып, беразга сүзсез калды. Ул зиһенен җыя алмый азапланды шикелле.

— Мин кайда туктаган идем әле?

— Күпме гомерләрне саклап калды ул бахырлар!.. — дип ярдәмгә ашыкты Кәбир.

— Әй, шулай бит әле. Воронеж күп тапкырлар кулдан кулга күчте. Бер тапкыр без камалышта калдык. Вәт, энем, кайда булды кырылыш һәм туралыш! Әле исләремә төшсә, атлар кешнәве колак пәрдәләремне тетрәтә, мин сиңа әйтим... Шулай, егермеләп җигүле ат, снәрәтләр төяп, обозда барабыз. Хәтердә, юл сирәк-сарак агачлыктан килә. Язгы-көзге быжык вакыт, кар-яңгыр. Кинәттән, сулдан, кара тәрелер ташкыны килеп чыкмасынмы! Дошман танкылары, знат. Фашистларның, Кәбир энем, күкрәкләрендә дә тәре, танкыларында да тәре... Безнекеләр, пушкаларны кирегә борып, танкыларга ут ачмасынмы! Без ике ут арасында калдык... Без мондый чакларда, камыт бауларын бушатып, атларны җиргә яткырырга өйрәткән идек. «Ложись!» дип кычкырам. Юк, Бамбук бушатылган камыты белән каерып, тимер юл астындагы күпергә алып кереп китә һәм туктый, знат. Мин йөктән сикереп төшеп, камыт бавын бәйләп торганда, арттан көчле шартлау яңгырый, ә Бамбук күкрәк тавышы белән әче кешнәп җибәрә... Уң беләгемә нәрсәдер каты итеп сукты, шинель җиңеннән кан да ага башлады... (Нәби абзый күлмәк җиңен сыдырып, тирән яра эзен күрсәтте). Менә ул... Бамбук, мескен, каты яраланган булып чыкты. Снәрәт ярчыгы аның янбашын чөерел алган. Безнең обоздан ике-өч кенә йөкче исән калды. Әгәр Бамбук күпер астына алып кермәгән һәм миңа дип килгән снәрәтне үзенә кабул итмәсә... без икебез дә кара җирдә черегән идек инде, энем...

Кадер-хөрмәт белән күмелгән солдатлар һәм атлар сирәк булды сугышта. Бигрәк тә атлар... Тереләре — кадерсез, үлгәннәре — каберсез, знат. Җирдә ятып калды алар, кош-кортка азык, сабынга чимал. Авыр яралы атлар атып үтерелде, форсаты булганда, суеп, солдат казанына озатылды...

Без Бамбук белән госпитальгә эләктек. Мин — кешеләр, ул — атлар госпиталенә, знат. Аерылышыр алдыннан мин аңа паек шикәремне каптырдым да, йөгәнен салдырып алдым. Истәлеккә, знат. Ул йөгән минем биштәремдә сугыш юлларын үтеп, өемә кадәр исән кайтты, энем...

Бу хәбәрне ишеткәч, Кәбирнең йөрәге ярсып тибеп куйды. Алар тагын тынып калдылар.

— Туган җиреннән киткән солдат белән атның яңадан туган җирен-

дә очрашуы — бу бит эскерттә табылган энә, Кәбир энем,— дип тынлыкны бозды Нәби абзый.— Күпме гомердән соң... Мин сиңа ярдәм итә алам. Әйтик, Бамбукны син миндә тәрбиягә калдырасың. Телисең икән, атка алыштырабыз. Җитәкчеләргә минем сүзем үтә...

— Юк,— диде малай кырыс кына кисеп.— Авылга мин аны үзем алып кайтырга тиеш.

— Киреләнмә. Әйдә, болай итик. Безнең «Динамо» колхозы хәлле генә исәпләнә, беләсең. Аның машинасы да бар. Без Бамбукны машинага салып илтәбез, ә?

— Юк,— диде малай.— Мин аны үз аягы белән алып кайтам. Хәзер күп калмады.

— Син дә бер тунколак икәнсең,— диде Нәби ачуланып китеп.— Ул чакта мин сиңа нәрсә эшли алам соң? Бу бит, энекәем, ни дисәң дә уртак ат бит — икебезнең ат!..

— Бамбукның йөгәнен бүләк ит миңа,— диде Кәбир сабыр гына.

— Шул гынамы? — Нәбине капма-каршы уйлар биләп алды, күрәсең. Ул мәсьәләнең шулай гади хәл ителүеннән еларга да, көләргә дә белмичә, офыкка күз салды. Сүзләрендә ниндидер рәнҗү дә чагылып куйгандай итте.— Синең белән сөйләнеп утырып... Әнә, кояш та күтәрелеп килә, соңламыйк, тагын!.. Әй, тунколаклар, йокы симертүчеләр, торыгыз!..

Алар икәүләп сүнгән учак янына китте. Малайлар, уянып, урынжирләрен җыештыра башлады.

— Рәхимҗан, Имаметдин, Зикаф, Зәкәрия, атларны табырлый башлагыз. Ә син, Мәкәрим, монда кил әле! — Йокысы күз керфекләрендә эленеп торган малайның иңнәренә кулын салып, ягымлы гына эндәште: — Син хәзер тиз генә битеңне чылатып ал да, авылга сыпырт. Сабира апаңнан кәҗәнкәдәге сандыкта яткан йөгәнне алып кил, яме?

— Кан-Күрәзә кошы нинди кош була ул, Нәби абзый? — дип сорады Кәбир тегенең кәефе урынына утырганнан файдаланып.

— Ә син кайдан ишеттең аны? Тыңлап тордыңмы?

— Әйе.

— Кан-Күрәзә кошы дисең, знат. Фәрештә ул. Ат каракларының кан дошманы. Ат урларга чыгар алдыннан алар, Кан-Күрәзә кошы күрмәсен, дип мул гына хәер өләшәләр. Бу фәрештә кошы урланган атларны яңадан урлап, хуҗаларына кайтарып бирә...

— Кы-зы-ык!..

— Кызганыч була күрмәсен, дим. Безгә Бамбукның нәселен ничек кенә булса да саклап калырга кирәк, энем... Әгәр байталга Бүләктә ниндидер куркыныч яныса, шундук миңа хәбәр итәсең, ярыймы? Ә мин — аткан ук, знат. Килештекме?

— Килештек.

Күк гөмбәзе сары томанда иде.

— Бал ява,— диде Нәби күккә ишарәләп.— Игеннәрне белмим, ә менә бал, кара кыраулар төшмәсә, быел булачак...

Каен чаукалыгы артында гына тояклар дөпелдәгәне ишетелде. Малайлар хәзер атларны куып, кайтып та китәчәк. Менә аерылалар да. Кәбирнең күңелен яхшы кешеләр белән саубуллашканда гына була торган моңсулык, ниндидер якты сагыш биләде.

— Исән бул, Кәбир! — дип кычкырышты малайлар.— Тагын кил!..

— Үзегез дә килегез!

Атлар табыры, бал сарысында саргаеп, авыл тарафына йотылды.

Кәбирнең кинәттән генә үләнгә ятып үксисе килеп китте.

Ярый диме? Малай ташландык учакка иелде. Юк, анда очкын әсәртәсе күренмәде. Ул аңа үзләренең хуҗасыз калган өен хәтерләтте. Ниһаять, карашы аркылы агачта эленеп торган киемнәренә төште. Пәрәмәч, кеше киемендә ләбаса! Ул ашыгып-ашыгып күлмәген салып ыргытты.

— Тукта!

Нәби абзыйсы аңа таба килә иде.

— Салма! Алар миннән сиңа бүләк. Олы малаемның төсе итеп киярсең...— Кәбирнең тартынганын чамалап, өстәде:— Кеше киеме димә. Таман бит? Таман, знат!

Ул арада булмады, җан-фәрман чабып, Мәкәрим дә килеп җитте. Кулындагы капчыкны җиргә ыргытты. Төбендә ниндидер авыр нәрсә бар иде, күрәсең, капчык дөпелдәп куйды.

— Кәбир турында сөйләгәч, Сабира түтәй бер бидрә чамасы бәрәңге һәм кыурган киндер орлыгы салды...

— Әй, рәхмәт төшкере хатын,— дип куәтләде Мәкәримне Нәби абзый.— Ә минем шул хакта әйтергә һушыма да килмәгән... Йөгәнне онытмадыңмы соң?

Мәкәрим капчыктан йөгән китереп чыгарды. Калын каештан катлап тегелгән һәм чит-читләре җиз атламалар белән каелган бу армия йөгәне Кәбиргә бүген иң зур бүләк иде. Ярыйсы гына саллы йөгәнне кулына алып, ул Бамбук янына барды һәм йөгәнен алыштырып кидерде. Аның ышануынча, бу йөгән Бамбукны үзе үк күтәреп кайтырга тиеш иде...

Алар Кәбирнең дәүләтен бергәләп тутырдылар. Тетелеп, сәләмәгә әйләнгән бер җиңсез киндер күлмәген, юганнан соң да балаклары гармун күреген хәтерләтеп бөгәрләнгән соргылт чалбар аламасын, йөгәнне тыктылар. Чират Сабира түтәй бәрәңгеләренә җиткәч, малай авыр була, дип карышты.

— Булмас. Булса, үзең күтәрә алганчы ал. Иң өзек чак, знат. Искесе беткән, яңасы өлгермәгән...

Үзе бер генә нәрсә дә бүләк итә алмавына үкенде ул. Әмма хәлдән чыкты. Капчыгыннан өзек дилбегә алып, Нәби абзыйсына сузды:

— Бамбукның дилбегәсе. Истәлеккә булыр...

— Рәхмәт.

Бәрәңгенең яртысын да алмады ул. Алар атны «бишек»тән төшерделәр.

— Сөягә чатнаган булырга кирәк,— диде Нәби, атның бәкәленнән кулын шудырып.— Андыз төнәтмәсендә тотарга кирәк, знат.

Нәби, күзләрен йомып, Бамбукны тагын бер мәртәбә муенынннан кочаклады, ялыннан сөйде һәм колагына нидер пышылдады. «Бирешмә, фронтовик»,— диде шикелле.

Бераз баргач, малай борылып карады. Аклан уртасына аякларын аерып баскан Нәби абзыйсы һәм җете сипкелле Мәкәрим аңа кул болгыйлар иде...

## Иманлек таулары биек...

Бамбук атламы хәзер инде бала атламы иде. Һәр сикереш туктап диярлек хәл алу белән аралашканга күрә, ул чынлап та бала атламына тиң иде. Алар авылга кереп тормадылар. Әллә кайлардан караеп яткан юл тасмасы буйлап Ишленең аргы очына суктырдылар. Юл хәзер калкулыкка күтәрелә, аннан сөзәк битләүдәге бодай басуы аша бара да, авылга кайтып җиткәнче иң озын үрләрнең берсе — Иманлек урманы үренә килеп төртелә.

Өч чакрым чамасы бардыр бу үрнең озынлыгы. Аннан калын урман башлана. Тагын үр. Соңгы, хәлиткеч үр. Түбәгә менеп җиткәч, аста, Сабыр үзәне буйлап ике рәт булып кына утырган Бүләк уч төбендә сыман күренә. Кайтып та җитәбез бит, Бамбук!

Ялгызы булса да, Кәбир ялгызлык тойгысы кичермәде. Малайлардан аерылганнан соң ул ниндидер бергәлек өмете белән яктырды.

Инде кайтып җитәр алдыннан гына очрашырга теләми иде ул Бөкебашлар белән. Борынга хуш исле тау бөтнеге исе бәрелде. Туган як

бөтнеге, саумы! Кәбир, юлдан чыга язып, камыл төбенә капланды һәм җирне кабат-кабат иснәде — көннәр буе кояш табасында кыздырылган туфрак Бамбук аягына ябылган дарулар, күкерт исе белән аңкыгандай тоелды...

Җирдән күтәрелгәндә ул капчыгының шактый авыр булуын искәрде. Күпме мөлкәт аның капчыгында! Теләсә, хәзер туктап, учак яга, бәрәңге тәгәрәтә, байталны ипекәй һәм ярмалы бәрәңге белән сыйлый ала. Өч көн эчендә ничә тапкыр бушап, ничә тапкыр тулыланып калды аның капчыгы!

Көч-хәл белән өстерәлеп барган, янбашларына инде тагын көмеш тир төрткеләре сытылып чыккан Бамбуктан сорап куйды:

— Нигә шулай?

Байтал аңламады.

— Мин әйтәм, нигә сорашкан хәерчегә кешеләр бирергә ашкынып тормыйлар, ә сорашмаган хәерчегә үзләре бирәләр?

— Сорашкан хәерчедә сер юк, Кәбирҗан. Ә менә сорашмаганда — бар. Кешеләрдә сер кызганудан өстен...

— Һы...

Бамбукҗан әйткәч, бәлки, шулайдыр да. Кәбир, мәсәлән, кызгануда да сер булуы мөмкин, дип исәпли. Менә ул байталны кызгана, әмма аңа кигезелгән йөгән шушы кызгануны үзенчә серле итә. Кәбир, гомумән, һәр нәрсәдә сер эзли, тик таба гына алмый, чөнки аның тирәсендә серләрнең серен белгән кешеләр житешми кебек. Әйтик, малайның кайдадыр чыгып олагуы авыл өчен генә түгел, дәүләт баганалары булып исәпләнгән адәмнәр өчен дә серме? Сер. Бөкебашларның совхозга имгәнгән ат артыннан китүе серме? Түгел. Ә нигә түгел? Чөнки алар бу хәбәрне яшермәделәр, киресенчә, мөмкин кадәр халык белүен теләделәр. Аларга моннан төшем бар. Азмы җир йөзендә сер? Нигә, ни өчен, нәрсә исәбенә яна бу кояш тәүлек, ай, ел, гомерләр әйләнәсенә? Нәрсә исәбенә тибә аның йөрәге? Бармы аңарда йөрәк? Тереклекне бар иткән кояшта йөрәк булмагач, нигә ул кояш баласы — кешедә бар? Кешедә дә, хайваннарда да йөрәк булгач, нигә соңгылары сөйләшә алмый? Нигә яшь тә, тир дә тозлы? Кан нигә кызыл?

Бамбук бодай басуын чыгып җитте дә, туктады.

— Тоз.

Ул байталны кылган катыш бүтәкә үләнгә тартты. Капчыгыннан ипи алып, икегә бүлде. Пинҗәк кесәсендәге тозы чамалы калган икән. Бармак башы кадәр тоз кисәген Бамбукка каптырып, калганын кәгазенә төреп, кесәсенә тыкты. Ул иртән ашамаган иде. Малай белән байтал алмаш-тилмәш ипи ашый башлады.

— Үз йөгәнеңне таныйсыңмы, Бамбукҗан?

— Танымыйммы соң! Воронеж янында, госпитальгә китәр алдыннан салдырып алды бит аны миннән Нәби. Елады ул минем белән аерылышканда. Мин дә еладым...

— Син чынлап та Муса бабай аты нәселеннәнме?

— Әйе.

— Сугышка кайсы авылдан, кайсы колхоздан киткән идең?

— Ярлекәүдән. Ишеткәнең бармы шундый урыс авылын? Чапаев колхозы диләр аны...

— Син анда ничек барып юлыктың?

— Муса табырында без барлыгы унике ат җаны булганбыз. Бер айгыр. Аны Тәңкә дип атаганнар. Җиде алаша. Бер бия. Бурлы бия. Минем картинәй. Бер тай. Бер кырыкмыш. Бер колын. Минем инәй була инде. Утыз өченче елгы ачлыкта безнең Өченче Интернационал колхозы аларның берничәсен күрше хуҗалыкларга сатарга карар итә. Безнең нәселне бик теләп алалар алар. Бигрәк тә бия һәм саулык кырыкмыш, колыннарны. Минем инәй, дүрт яшьлек бия, иң кыйммәт хакка Ярлекәүләргә сатыла...

— Сиңа хәзер ничә яшь?

— Мин бик карт инде...— диде Бамбук уфырып.— Унынчы яшем белән барам. 1939 ел колыны мин...

— Мин бу йөгәнне бары тик сиңа гына кигезәчәкмен, Бамбук! — дип кычкырып җибәрде малай яланны яңгыратып.— Мин бүтән атларны җикмәячәкмен дә! Ун яшь карт диме? Менә мин уникедә!..

— Мин иртәгә үләчәкмен, Кәбирҗан...— диде байтал чәйнәмен йотып җибәреп.

— Син нәрсә сөйлисең, Бамбукҗан?! — Хискә бирелеп китеп, акыл бәеннән ычкынган малай йодрыгы белән байталның маңгаен төя башлады.— Син нәрсә сөйлисең?!.. Без яшәячәкбез, Бамбукҗан... Менә күр дә тор, яшәячәкбез!..

Соңгы кабым ипие белән ул үләнгә сыгылып төште. Бамбук исә, бер нәрсә булмагандай, бүтәкә кырка башлады. Күпме ятканын ул хәтерләми. Авыр уйлардан арынырга теләп, ул Нәбине исенә төшерде. Кара син аны, Кәбирләр авылының култык куенында гына яшәгән икән Бамбукның сугыштагы хуҗасы! Кем уйлаган? «Ерактагын якыннан эзлә»,— дип халык юкка гына әйтмәгән икән шул. «Ерак куйсаң, якыннан алырсың»,— дип тә өстәгән... Менә бит Бамбукны да язмыш бик ерак куйган, әмма якыннан алдырган. Колак төбендә генә каты үлән өзгәләштергән Бамбукның күзләренә инде ничәнче тапкырлар бакты... Күзнең күгәрчен йомыркасын хәтерләткән, зәңгәрсу, төпсез тирән мөлдерәмәсендә үз йөзенең чалыш чагылышын күреп, таң калды. Атның күзе дә аның күзендә чагыла микән?

Ниһаять, алар Имәнлек үрләрен яулау өчен кузгалдылар.

Үрнең беренчесе, урманнарның ике як кысымыннан котыла алмыйча, сөзәк кенә күтәрелә-күтәрелә дә, талчыккан юлчыга бераз гына булса да хәл алырга мөмкинлек биргәч, уйсулыктан тагын да текә — хәлиткеч үргә әйләнә. Урман исә юлны тәгәрмәч эзенә кадәр кысрыклый, урыны-урыны белән муенына элмәк салып, бөтенләй бумакчы иткәндәй күренә...

Байталның көрчеккә терәлгәне инде көн кебек ачык. Гүя, яңа гына тоякланган колын, буыннары тота алмагач, инәсенең җилененә борынын төртеп, имчәген каба да, үзенә тотыныр тотка, басып торырлык хәл таба. Гүя аның күзләре яңа гына ачылган, көнбагыш мәмәе кебек вак сөт тешләре әлегә ана сөтеннән башка бер азыкны да үткәрә алмый. Кайда ди ул өченче көнге фырылдап ыргу һәм ухылдап сикерүләр! Атлам белән сикерү арасындагы аерма тәмам сүнгән. Ул бары тик ике арткы аяк көче белән генә үзен алга этәрә. Бу гарьлекне авыр кичергән байтал ниндидер сәер тавыш чыгарды. «Их!» — дигән кебек ишетелде Кәбиргә. Малай атны узып, ун-унбиш атлам атлады да, йөзе белән аңа таба борылды. Борын тишекләре чамасыз киңәйгән Бамбук, гыжлап һәм пошкыра-пошкыра тын юлларын чистартып, аның кочагына егылырга дип кереп килә. Кайчандыр совхозга барганда беренче тапкыр күргән һәм хәзер күзенә каен шырпысы булып кадалып елаган кояш Имәнлекнең текә үреннән Бамбукны этәреп алып менеп килә. Менә ул Кәбиргә килеп үк терәлде... Малай читкә тайпылды. Байталның ике күзе дә йомык иде. Нәрсә, туган иленә сукыр килеш тә юл сабамы малкай? Әллә ул, шулай күзләрен йомып, сызлануларын басарга тырышамы? Әллә уйланып-моңланып, туган туфракка басу шатлыгын кичерәме? Колын салырга җыенмыйдыр бит югыйсә?!

Уйсуга аяк баскач, тагын да туктап ял иттеләр. Соңгы түтәрәм ипи дә Бамбук карынына юл алды.

Кояш төшлектән авышканда кузгалдылар. Имәнлек үренең иң текә өлеше башланды. Кинәттән Бамбук, тау текәсенә менә алмый, артка шугандай тоелды. Ул аяклары белән тырыша-тырмаша җирне ыргакларга итә. Ат туктады. Малай аның янына йөгереп килде һәм ябык күзләренә текәлеп кычкырып җибәрде:

— Бамбук!

Байтал җавап бирмәде.

— Ярамый! Хакың юк... Ишетәсеңме?! — Малай нишләргә белми, үрсәләнеп, йодрыклары белән тезбашларын кыйный башлады. — Нигә эндәшмисең?!

— Ярдәм итәр идең, ичмасам...— дидениндидер өн.— Янбаштан...

Әллә җирнең үзеннән килгән бу тавыштан канатланып киткән Кәбир атны янбашыннан этә башлады. Кузгалгандай итте тегә. Аркасындагы капчыгын агач төбенә ыргытып, икеләтә көч белән этә башлады.

— Кан-Күрәзә кошы!...Ярдәм ит!..

Ат кадәр атның унике-унөч яшьлек малай ярдәменә мохтаҗлыгы да булмагандыр, бәлки. Әмма бөтенләй ярдәмсез калган, таза йөрәк исәбенә генә өстерәлеп булса да алга елышкан ат, үзен белеп алган ташландыклык, ятимлек тойгысыннан котылырга теләп, янындагы икенче бер шундый ук таза ир бала йөрәгеннән өстәлгән дәрт һәм дәһшәт белән генә тере калачагын аңлый, күрәсең. Бу минутта шушы хакта бөтенләй уйламаган ир белән ат мәңгелектән килгән ир-ат бердәмлегенең коръән сүрәсе иде. Кечкенә ир җаннан күчкән кечкенә очкын зур куәт өсти иде аңа. Бер адым алга — ял. Адым алга — ял. Атны җан ачуы белән алга этәргән Кәбирнең алдыннан кызыл күлмәкле кыз йөгереп үткәндәй булды...

Агачлар өстеннән киеренке җил исеп куйды. Нәселле каусәләр, ыңгырашып, чайкалыштылар. Алга, бары тик алга!

Мәңгегә атасыз, әлегә хәтта анасыз, күкрәкләрендә үр җилләре кураен уйнатып, кеше биргән күлмәк-ыштанда, кеше биргән кәвешләрдә, сугышларны үтеп исән калган, явызлар пычагы астыннан очраклы гына котылган атны этәреп, черегән ботак-сатак, мурыган үлән, тамырлар исе белән пошлыгып яткан урман төпкелләреннән йөрәге сыман күтәреп алып чыгып килгән малай — кемең булыр ул синең, туган ил? Кем өчендер бик тә кадерле, кем өчендер бик тә кадерсез, туфрактан яралган, кояшта карайган, җилдә җилләнгән, кырда көрәйгән, илдә иләнгән, төптән, бик тирәннән күтәрелгән бу тере тамыр, тормышның зирәк һәм хисле бер күзәнәге — кемең булыр ул синең, туган ил? Кешелек басуының тук бөртекләр белән тулышырга ният тоткан бер башагы, болыннар чәчкәсенең күзләве, иртәсен дә, кичен дә, төнен дә, көндезен дә дөньяга инәлеп, мәңгелек сагыну авазлары салган, явызлык белән очрашканда сыкраган-сыктаган, янартау булып күкрәп чыккан бу сабыең — кемең булыр ул синең, туган ил?

Хәлдән тайган ике җан иясе, ир һәм ат, тозлы тир тамчылары белән җирне ашлап, ниһаять, Имәнлек үренең иң югары ноктасына менеп җиттеләр. Монда дөнья якты, һава кискен һәм кояшлы иде. Урман авызына җитеп килгән малай, әллә түбәнгә, авыл тарафына карарга тартынып, әллә бу кадерле минут ләззәтен тагын да сузарга тырышып, карашын күтәрмичә, тирләрен сөртте. Яшь яфракларны шыбырдатып, кайнар күкрәкне, ут булып янган бит алмаларын, колакларны рәхәт салкынлык белән изрәтеп, җил исте. Якында гына күккүкнең сакау тавышы ишетелде. «Иртә сакаулангансың». Бамбук исә сөйрәлүен дәвам итте. Туктасын иде ул. Бераз ял итәрләр иде. Инде кая ашыгырга? Әмма байтал туктамады. Һаман да ябык күзләренең кара керфеге белән капшый иде ул юлны. Чтапан дәдәй кидергән «итек» шактый чыдамлы булып чыкты: таушалмады да, урыныннан да кубарылмады. Башын түбән иеп алган байтал «Миңа хәзер барыбер» дигәндәй, һәр нәрсәгә битараф күренде. Ыргып чабу, юрту түгел, аны хәзер атлап бара дип тә булмый. Аякларын гына алмаш-тилмәшли. Капшанып кына җирне җентекли. Ярасы аягыннан таяныч эзләгәндә ыңгырашмый да кебек. «Билгесездә тәвәккәл коткара». Малайның хәтеренә инәсенең яратып кабатлый торган мәкале төште. Кешене генә түгел, җанварны да тәвәккәл коткара, күрәсең. Беренче көнне гел ыргып кына чапкан ат авылына җитәрәк менә шулай капшанып кына барачагын башына китердеме икән?

Менә соңгы борылыш. Менә алар хәзер урман авызына килеп чыгачак. Аннан тирәкләр һәм карт өянкеләр арасында куе үлән эчендә юан аркан сыман ишелеп яткан авылы күренәчәк... Аннан юл ук булып түбәнгә атылачак һәм... Нәрсә инде сөйләп торырга!..

Соңгы адымнар. Бер... Ике... Унбиш... Егерме...

Агачлардан төшкән шәүлә һәм күләгәләрнең үзенчәлекле үзгәрүен, тирә-якның кычкырып яктыра төшүен чамалап, ул күзләрен җирдән күтәрде һәм тау түбән карады — анда исә, җир йөзендәге иң тирән тынычлык, матурлык һәм килешкәнлек белән рәшәдә җәйрәп, туган авылы Бүләк ята иде...

Малай йөгерә-атлый байталның алдына чыкты, күзләре йомык башны күкрәгенә кысты һәм кулын авылга таба сузып, кычкырып җибәрде:

— Мбамбо-бимбо! Сама-рана-сама, Бамбукҗан!..

— Болай да күрәм мин, тиле...

Атның сары тоз сарган керфекләре ачык иде. Ул Бамбукны сулга, урман кырыена тартты. Тегесе бер сүзсез буйсынып, яралы солдат сыман алга шуышты.

— Капкалый тор, — диде малай байталның башын үләнгә төртеп.— Мин хәзер!..

Агачлар арасындагы мүк үләнгә ләпәшеп төшкән капчыкны табып, аркасына артмаклап маташканда, үзеннән астарак, борылыш артында тәгәрмәч келтердәгән, кешеләр сөйләшкән тавышлар ишетте. Малайның төсе качты, тыны буылды. Үрдән, һичшиксез, атлы арба менеп килә. Ул йөгерә башлады. Малайның аяк чәлтерләре иң җитез тәгәрмәч тырнакларыннан да җитезрәк хәрәкәт итә иде. Ниһаять, тавышлар ерагаеп калгандай булды. Атны яшереп өлгерергә кирәк! Бөкебашлар булып чыкса, нишләрсең? Кинәттән аның күз аллары караңгыланып китеп, йөрәген нәрсәдер тотты. Ут капкандай, үнәче яна, теленең кипкән аңкауны капшарлык та хәле юк. Егылып китмәс өчен ул юл читендәге имәнгә сарылды... Өлгерергә кирәк! Секундлар ел сыман озын тоелды Кәбиргә. Һушына килгәндәй, кесәсеннән тоз валчыгы чыгарып капты һәм тел өстендә әйләндерә башлады. Тоз тәмен тойган аңкау селәгәй белән тулды. Арба тәгәрмәчләре, купшы теркелдәп, якынлашып килә. Эчен борып алган катудан котылып, яңадан байталына ташланды.

— Тизрәк, малкай!..

Ул атын урман куерымына этәрде. Өлгерергә! Инде тәмам исәңгерәгән, шуның аркасында берни дә аңышмаган Бамбукны кочка-кочка генә чикләвек куакларына алып кереп өлгерде. Менә агачлар арасыннан, агымсу аша чуерташ сыман караеп, кара айгыр күренде. Шулар, билләһи газыйм!.. Әнә Сәйфуллин фуражкасының кызыл каюы агачларны телеп килә. Әлегә Бөкебаш күренми.

— Мә.— Кәбир соңгы тоз кисәген Бамбукка каптырды һәм колагына пышылдады.— Бүтән сорыйсы, тавышыңны чыгарасы булма!..

Нәзек чикләвек чыбыклары арасында үзе дә бер шундый чыбыкка әверелгән малай җиргә сеңеп, бар игътибарын арбага юнәлтте.

Урман авызына чыгу белән кара айгыр Кәбирләр ягына борылды да туктады. Малай тәмам тынсыз иде. Фуражка, гер сыман дөпелдәп җиргә сикерде. Үрәчә эченнән мыгырдана-мыгырдана Бөкебаш калыкты. Ул җылак хәлендә иде, күрәсең. Төшә алмый азапланганнан соң, ниһаять, җиргә ләпәште. Кәбир аркасындагы капчык та капчык, Галләметдин дә капчык иде. Юлчыларның мондый хәлдә булуы малайга көч өстәгәндәй итте. Сәйфуллин һәм аягында чак басып торган Бөкебаш башта кече йомышларын үтәделәр, аларга кушылып, айгыр да бушанды. Участкауай билен язды да, арба кузласы астыннан нииндидер төенчек тартып чыгарды. «Баш төзәтергә табын кораштыралар», — дип уйлап алды малай. Тегеләрнең үзара сөйләшкән сүзләре бигүк ишетелеп җитми иде. Аркасындагы капчыгын салып ташлап, ул урман авызына таба шуышты. Яшеренеп тыңлау өчен янәшәләрендәге куе зелпе куагы бик ятеш булып

чыкты. Сәйфуллин фуражкасын һәм наганлы каешын салып ыргыткан. Бөкебаш исә Кәбир тарафына карап, кырын яткан. Ул гадәттәгечә бик йомшарган һәм йончыган иде. Бите, күз кабаклары, танавы — барысы берьюлы шешенеп, йөзе күзсез, башы танаусыз бер ит түмгәләгенә әйләнеп калган. Бу түмгәләкнең бердәнбер исән әгъзасы — ул зур гына ярык, ягъни иреннәре бүртенеп күпергән авыз иде. Менә түмгәләк дерелдәде, ярык ачылгандай итте:

— Балы ичкергән ие, чабакының... Әйдә, чал әле, иптәш лейтнат!..

— Сәфәр! Әйтер идем инде...— Сәйфуллин ямьсез итеп сүгенде, стаканнарга аракы койды.— Бер маңка малай әзмәвердәй ике ирнең ике көн вакытын ашасын әле! Суга төшкән балта!..

— Кайткандыр ул, нибуч. Авылдадыр...

Алар эчеп җибәрделәр. Бөкебашның теле ачылып киткәндәй булды.

— Чугыш заманнары булчамы? Бу ат өченме? Мме!... Чажт!

Авыз ярыгы тагын да ниндидер ымлыклар, аһылдаулар һәм уфылдаулар хасыйл итте.

— Мучаны әйтер идем... Бер нәчтә дә белми, имеш. Мин чминәдә идем, имеш. Калхуз атын харап иткәне өчен бер ун ел чәпәчән, белер ие, нибуч... Балы ичкергән дип тормадык, без аны барыбер йөгерттек! — Бөкебаш, кәефе килеп, «Җомга» көенә җыр сузды:

Әби бәлеч печергән
Чамарчкий кичердән.
Әбекәем ачуланма,
Без әдерәк төчергән...

— Син бик азынма, кеше-кара күрүе-ишетүе бар. Заманаларны беләсең...— Сәйфуллин аңа тавык боты сузды.— Мә, кимер.

— Курыкмыйм! Монда мин влачть, чин влачть, иптәш лейтнат!..— диде дә Бөкебаш, көчек кебек мырылдап, тавык боты кимерә башлады. Кәбиргә бу манзараны күзәтүдән дә авыр эш юк иде. Шул ук аклан, шул ук үләннәр, гөжләп очкан шул ук кигәвеннәр һәм энә караклары... Монда Бөкебашлар һәм Кара айгыр гына яңа икән. Хуҗалар аның аркалыгын төшереп тә тормаганнар. Милиция аты текә күтәрелгән камыт аша буылып, үлән сирәкләргә тырыша. «Озак утырмаячаклар»,— дип уйлап алды малай.

— Кайткан дисең, ызначит? — диде йөзенә алсулык йөгергән Сәйфуллин тагын да аракы коеп.— Ә ничек кайткан ул? Атын җилкәсенә салыпмы? Ышанмыйм мин моңа. Нигә аны башка авылларда күрмәгәннәр? Беркемнән дә ярдәм сорамаган? Ат дворларына да кермәгән? Нәрсә диде безгә теге чатан чуваш? Күбәләкнең канатсыз очуы мөмкин, ә менә ат малының өч аяклап кайтуы мөмкин түгел, диеме? — Сүзнең Чтапан дәдәй хакында баруын абайлаган малайның йөрәге кысылып куйды.— Муса картның балыннан зеңкегән башыңны айнытып, әйт син миңа: нигә авылларга кермәгәннәр дә, нигә аларны күрмәгәннәр? Ул малай актыгы Хозыр Ильяс түгелдер бит?!

Кәбир үз юлының дөрескә чыгуына ышанды. Авылларда төнгелеккә туктамаулары акланды, димәк. Куна ятып, Муса бабаларын шактый яфалаган, шактый талаган икән болар!

— Атны Казагыстан далаларына алып чыгып таймагандыр бит? Шулай түгел дип раслый аласыңмы? — Сәйфуллин Бөкебашка ни өчендер ачулы иде.— Исерткеч ләззәтендә изрәгән Бөкебаш сүзгә юмартланып китте. Синең сүзеңә ышанып йөрегән мин дүрәк...

Бөкебаш күз кабакларын ачарга маташты.

— Булыр ул бандиттан, булыр!.. Иначе, пучкай, чтатья буенча китчен, ә малайга вчесоюзный розыска бирәбез — и бачта! — Сеңер җепселләренә кадәр кимереп чәйнәлгән сөяген үзе аша артка чөйде. Сөяк Кәбирнең аркасына килеп төште.— Анычы да монычы, ике көн ял иттек, иптәш лейтнат!.. Колхоз эче бетми ул...

— Нинди статья? — Мәсьәләләренең торышын төптән белгән кешеләргә хас вәкарь белән дәвам итте Сәйфуллин.— Нинди статья ди тагын? Кичә совхоздан сөйләшкәндә прокурор ярдәмчесе ачыктан-ачык әйтте бит: гражданка Садрыеваны яклап, авылдашлары мөрәҗәгать итте, кайбер нәрсәләрне ачыклыйбыз да, тикшерүне туктатабыз... Ат хакын түләтәчәкләр, ә гражданка Садрыева иртәгә туп итеп Бүләккә кайтып төшәчәк...

Бөкебашны яшен суккандай итте. Күз кабаклары шар ачылды. Ул хәтта торып утырды. Авыз ярыгына кайдандыр папирос килеп кунды. Алар тәмәке кабыздылар; аклан өстендә яшь җитен сүсе сыман күгелҗем төтен таралды. Әле генә ишеткән хәбәрләр Кәбирне чиксез куандырды да, борчыды да. Димәк, инәсен әле булса йозактан чыгармаганнар. Димәк, ул өйдә түгел. Кемнәр мөрәҗәгать иткән аны яклап? Үзе кебек солдаткалардыр инде. Ревкомиссия Рәис абыйлары оештыргандыр. Нәрсәләрне ачыклый пркарул? Атның хакын тулаем чәпәп куйсалар, Бамбук аларның үзләрендә калырга тиеш буламы? Шәп булыр иде дә бит, ул кадәр акчаларны кайдан алмак кирәк?

— Чулай җиңел генә котылачакмы ул, иптәш лейтнат? Чучы контра нәчеле безне җиңәчәкме? Чтрам!..

— Алда күз күрер. Монда Мусаның кысылышы юк микән. Ат кайтса, безнең хәл хөрти. Кайтмаса...— Сәйфуллин тастымал кадәр төтен чыгарды.— Кайтмаса, Санияның балдак-йөзекләрен даулап йөрергә форсаты калмаячак. Үзенә балдак кидерәчәкбез...

— Бу бүләкне күрчә, Чаҗидә чинең алга үзе ятачак, менә күр дә тор! — диде кеткелдәп Бөкебаш.— Чаҗидә чинең кулдагы кош балачы инде... Ә менә Чанияны чин генә чындыра алачың... Чин чындырчаң, кулыма үзе керәчәк!

— Сандыкны юньләп яптыңмы, әйберләрне пыран-заран китермәдеңме?

— Анда пыран-заран китерерлек бер нәчтә дә юк. Барычы да чин кушканча, иптәч лейтнат! — Бөкебаш уфыргандай итте.— Тик менә чунычы гына, балдаклар төрелгән похарунка кәгазен дә алып чыкканмын...

— Шуннан?! Нишләттең инде аны?

— Ертып ыргыттым.

— Ишкәнсең икән ишәк чумарын!..

Малай бик ачык аңлады — Сәйфуллин кушуы буенча Бөкебаш аларның өйләренә басып кергән һәм депутат Саҗидәгә бүләк итү өчен инәсенең балдак-йөзекләрен урлаган. Башка сыймаслык хәбәр иде бу. Юкка гына кызышмаган булган теге чакта Саҗидә ул алтын-көмешкә! Димәк, болар оятсыз рәвештә яр бүлешәләр.

— Чыгар әле Мучаның икенче чечәчен! — диде ачуы кузгалган Бөкебаш.— Утырган тек утырган, иптәш лейтнат!..

Сәйфуллин төенчектән икенче акбашны чыгарып, кырлы стаканнарга голт-голт аракы салды.

— Әгәр ат кайтмаса, аның белән бер-бер хәл килеп чыкса, шахмат тактасында безнең йөреш әзер: гражданка Садрыева җиккән социалистик дәүләт малы һич кенә дә бүредән түгел, ә кешегә тамак ялына ялланып, бүрәнә ташыганда җәрәхәтләнгән. Һәм башкалар, һәм башкалар. Аңладыңмы? Менә ул документ.— Сәйфуллин кесәсеннән кәгазь алып күрсәтте.— Син нәрсә, мине илле чакрымда яткан совхозга юкка барып йөргән дип уйладыңмы? Безне аңлаган кешеләр анда да бар!

Ул каһкаһәләп көлеп җибәрде.

Бамбук тарафыннан, урман эченнән, ботак шартлап сынган тавыш ишетелде. Табындашлар шул якка борылдылар. Бамбук аягын алыштырганда булдымы бу саксызлык?

Шатлыкка барысы да тынычланды.

— Син аны... соң?

Сәйфуллинның соравы үтә дә оятсыз иде.

— Әлбәттә! — диде Бөкебаш.— Ычпрашиваешь тагы...

Тагын да оятсызрак җавап яңгырады.

Алар үләндә тәгәри-тәгәри көлештеләр. Кәбирнең карашы якында гына сары елан булып яткан каешка һәм алтатарга төште. Әллә атылып чыгарга да, наганны кулга төшереп, атып үтерергәме үзләрен? Эһ тә итми чәнчелдерер иде, билләһи! Әгәр алар аны тотсалар, сыптырып алырга камчысы да янда юк, ичмасам...

— Чин кушкан нәрчәләрне мин иртәгә рәтләрмен. Барычы да булыр...

— Күп кирәкми,— диде Сәйфуллин.— Берәр капчык он, берәр сарык түшкәсе, атка бер-ике центнер солы шунда... Минем зонада синнән дә ышанычлырак кешем юк, Галләметдин абзый...

— Эр-рәх-мәт, Чәйфуллин иптәч, яме! — дип чыйнап җибәрде Бөкебаш.— Мине чулай дөреч аңлаган кечеләрнең табанын үбәргә әзер мин! — Ул Сәйфуллинга таба шуыша башлады.— Табаныңнан гына үптер, иптәч лейтнат!..

Сәйфуллин, җирәнеп булса кирәк, аны итек табаны белән этәреп җибәрде.

— Зерә, мин чиңа әйтмим... Мин, Чәйфуллин иптәч, бик тә йомчак күңелле кече. Берәрче җылы чүз әйтчә дә җылыйм мин...— Исерүнең арьягына чыккан Бөкебаш чын-чыннан елый иде.— Чин мине убажать итәчеңме? Мин ч-чине н-нык уб-бажать итәм, Ч-чәйфуллин! — Ул тагын да шуышып барып, участкавайны үбәргә маташканда, тегесе кырыс кына читкә этәрде.— Мин ч-чинең өч-чен яраткан хатынымның ч-чандыгына кереп, б-беләзекләрен урладым, аңлыйчыңмы чин шуны?..

— Әгәр бу турыда тагын да бер тапкыр искә төшерсәң... Берәр кешегә чыгарсаң, мин сиңа да статья табармын. Смотри аны, гражданин Зыятдинов!..

— Куркытма чин мине, к-куркытма,— диде Бөкебаш күз яшьләрендә йөзеп.— Мин болай да курка торганнардан... курка торганнардан түгел!.. Онытма, Чәйфуллин, бер-бер хәл булча, хафачын икәү бүлешәбез, булдымы? Чал тагын берне... Чын дучлык өчен, Чәйфуллин!..

Участкавай шешәне бушатты. Чәкештермичә генә эчеп җибәрде. Аракысын авыз тирәсенә дә китерә алмас хәлгә җиткән Галләметдин аны бүлена-бүлена чөмерде, стаканның төбе изүенә түгелде. Аек фикерләү чамасын югалтып, ул теленә нәрсә килсә, шуны мыгырдана башлады:

— Мин чоциаличтик ярыч алдынгычы... Мин районда бер бригадир!.. Ә чин кем? Чания тәнеңдәге бет чин... Минем тәндәге бет!.. Мин бәхетчез... Кайтмыйм, хатын янына кайтмыйм!..

— Дөрес эшлисең,— диде түземе беткән Сәйфуллин, урыныннан сикереп торып.— Айныгач кайтырсың. Яланда йокы тәмле була ул! Синең белән бергә авылга керергә оят!...

Участкавай атына утырып, авылга йомылды.

— Тук-та-а-а! — Сәйфуллин белән бер дә юктан, һич кенә дә көтмәгәндә килеп чыккан низагның үз файдасына тәмамланмаячагын исерек баш белән булса да чамалап алган Бөкебаш, дүрт аякланып басты һәм лап-лоп килеп, сөрлегә-сөрлегә йөгерде.— Тук-та-а-а, Чәйфул-ли-и-ин!..

Пар күгәрчен кебек гөрләшеп табынга утырган юлдашларның сәфәре менә шулай әкәмәт кенә тәмамланды. Ишеткән-белгәне һәм үз күзләре белән кичергәне өчен чиксез шат иде малай. Ул зелпе куагы артыннан чыгып, табын янына килде. Табындашлар ташлап киткән ашъяулык Зөлхиҗә әбиләрендә күргән ашъяулык иде. Ярыйсы гына зур ипи түтәрәмен култык астына кыстырып, ул ашъяулыктагы буш шешәләр һәм сөяк, калдык-постыкны зелпе төбенә җилгерде дә, яраткан әбисенең ашъяулыгын бөкли-бөкли, байтал янына үтте. Ипи исен сизгән ат аның ягына сузылып, һаваны иснәде.

— Мә, Бамбукҗан. Безне сатмаган өчен Чтапан дәдәйгә рәхмәт.

— Настүккә дә рәхмәт.

— Дөрес, Бамбукҗан. Чегән юлбашчысына да.

— Нәбигә дә...
— Кайтып җиттек бит, Кәбирҗан.
— Әйе, Бамбукҗан. Рәхмәт инде сиңа...
— Сиңа да. Әле без синең белән күп тапкырлар ат кунасындагы ярышларда чабырбыз, алла боерса... Аягым гына төзәлсен. Кралов яланнарыннан сиңа утын һәм печән ташырбыз. Сәми карт урынына ат караучы булып та килсәң, ә, Кәбирҗан? Минем шундый яшисем килә... Авылны күргәч, миндә өмет уянды. Күр дә тор, аягым тиз төзәләчәк!..
Алар урман эченнән акланга чыктылар. Кәбир авылга кадәр ялтырап яткан юлга карады. Бөкебаш күренми иде.
Кояш инде дүртенче тапкыр офыкка кереп чумарга әзерләнә. Кәбир ашыкмады. Авылга кичләтеп, атлар кунага китмәс борын кайтып керү аның теләгенә хуш килә. Бамбук хәзер атламын тышау салынган сыман бик вактан ишә. Аның артыннан, җиңүче кебек күкрәк киереп, Кәбир атлаштыра. Бер мизгелгә ул үзен чынлап та сугыштан кайткан җиңүче-солдат итеп күз алдына китерә. Күкрәге тулы орден-медальләр... Аркасында исә түккән каны өчен түләнгән бер капчык акча. Шыгырдап торган йөзлекләр. Менә аны малайлар, карт-коры сырып ала... Ул бала-чагага жиз медальләр, йөзләрендә адәм чырае калмаган ач авылдашларына төргәк-төргәк акча тарата...
Ул авылын йотлыгып күздән кичерде. Матур дисәң дә матур шул аның Бүләккәе! Исеме генә ни тора — Бүләк! Кемгә бүләк?
Ул инде авылын икенче хис, икенче көч белән, җитлеккән ир-ат булып ярата иде. Яратуыңны сынау өчен еракка китеп карарга кирәк икән. Менә Кәбир дә еракка китеп карады.
Салкын кышларда әгәр таудан тауга түбәне япсаң, бер авыл халкы бер өйдә яшәп, бер самавыр чәйдән җылына алыр кебек. Әмма нигә алай түгел? Нигә бертугандай яшәргә тиешле кешеләр бер-берсенең бугазыннан ала? Юклык шулай иттерәме? Гомеренең башында туган шушы бик гади сорау Кәбирне шулай ук гомере буе җәфалар: нигә? Җир шары әйләнүдән туктагач кына туктармы мондый аһ-зар һәм рәнҗеш?
Куражиләк чишмәсе чокырына төшкәч, шәфәкъ күзгә күренеп куерды. Берничә атлам җирне сазламыкка әйләндереп яткан чишмә алкымына җиткәч, Бамбук кисәк кенә туктады.
— Эчәргә булдыңмы?
— Юк.
— Алайса мин эчәм...
Малай кушучы белән үзагымда җылына төшкән чишмә суын уртлады.
— Әйдә, малкай. Соңгы омтылыш. Күп калса, бер чакрым калгандыр...
— Мин колхоз дворына кайтмыйм. Анау казыкны суырып ал да, маңгаемның кап уртасына тондыр, Кәбирҗан. Үтер, ас, кис, суй — анда кайтмыйм...
Кәбир аны ничек кенә иркәләмәсен һәм юхаламасын, байтал кымшанмады да. Гүя ул аягүрә җан биргән иде. Моңарчы Бамбукҗанны мондый халәттә күргәне булмады малайның. Аның йөрәген нәрсәдер телеп, яндырып үтте.
— Колхоз дворында бит синең дусларың! Ирекле атлар!..
— Үтенәм, Кәбирҗаң, калдыр!.. Анда — коллар гына!.. Коткар!..
— Син мине коткар! Күтәреп булса да алып кайтам мин сине...
Якында гына гырлаган тавыш ишетелде. Малай шул тарафка ташланды. Ни күзләре белән күрсен — сазламыкка буй салып, Бөкебаш йоклап ята. Песи сыман тавышсыз-тынсыз якынаеп, өстенә иелде: менә бу, ичмасам суйсаң да уянмас иде. Галләметдиннең сасыган авыз тирәсен, сары керфекләренә кадәр шешенгән йөзен кичке эре чебеннәр сырып алган. Менә ул коллар хуҗасы. Дөресрәге, ирне аттан аерып кол итүче кол. Кәбирнең башыннан әллә нинди хәтәр уйлар үтте... Пәкесе чегәннәр

табырында калды шул. Малай бу фикердән тиз арынды. Исәнә килеп, капчыгыннан камчысын алды. Уң кул беләзегенә киде һәм камчы очын һавада чажлатып, Бөкебашның йөзе өстендә кизәнде... Йөрәккә жыелып килгән гарьдән сабырлык, Бөкебашлардан килгән, алар сеңдергән коллык өстен булып чыкты, күрәсең. Сукмады. Галләметдин дә кеше бит. Бәлки, ятимнәрне юкка рәнжеткәнен бер килеп аңлар. Аңламаса, үсә төшкәч Кәбир үзе аңлатыр. Аңласа, үзе килеп гафу сорар Бөкебаш. Малай читкә төкереп куйды. Әшәке гырылдау баскан бу тынчу аралыктан тизрәк котыласы килде аның. Бәлки байталны да шушы гырылдау өметсез иткән һәм туктаткандыр?

Башка бер генә дә чарасы калмаган Кәбир, таш сыман атылып, ат янына ыргылды һәм үзенең нәрсә эшләгәнен дә белмичә, сөттәнә башлады:

— Менә сиңа! Менә миңа! Менә сиңа! Менә миңа!..

Байтал белән алмашлап, ул үзен дә каезлады. Әмма тугры юлдаш бу очракта җавапсыз иде.

— Менә сиңа! Менә миңа! Менә сиңа! Менә миңа!..

Атны һәм үзен кыйнап, ул хәлдән тайды. Ахырда, җиргә бөгелеп төшеп, аякларыннан кочты һәм инәлә башлады:

— Йомры тоягым... Тырнак колагым... Ялбыр ялым... Нечкә бөерем, үлмә... Үлмә, җаныкаем...

Ул байталның артына чыкты да, янбашына капланып, елый башлады. Үрсәләнеп үксү һәм гырылдау бергә кушылды.

— Әйдә, малкай... Әз генә калды бит!

Ул байталны бар көченә этәргә тотынды.

Фәрештәләрнең «Амин!» дигән мизгеленә туры килде, күрәсең, ыңгырашып һәм как сөякләре белән иске арбадай шыгырдап, ат кузгала бирде. Кузгалды шикелле. Әйе, кузгалган икән шул, рәхмәтләр төшкере!

Малай яшь аралаш елмайды.

Карыш арты карыш юлны җентекләп, алар авылга килеп керде. Күз бәйләнеп өлгермәгән, менә хәзер таудан тузанга батып, көтү төшәр мәл иде. Сабыр күпере төбендә каз бәпкәләре белән чыр-чу килеп маташкан Сәрбиямал карчык очрады. Әле теге як ярдан ук сәер хәрәкәтләр ясап, күпергә кереп килгән җан ияләрен шәйләгән әби, үз күзләренә үзе ышанмагандай, уң кулын каш өстенә куеп текәлде дә, аннан, инде күпер аша чыгып өлгергән Кәбирне танып алып, кычкырып җибәрде:

— И-и балакаем!..

Сул кулындагы каз каурыйлары яңадан җиргә төшеп капланды.

— Кайтып киләсезмени? — Ул Кәбирне кочаклады, барлык әгъзаларын тикшергәндәй капшап карады да дога кылды. — Ходай тәгаләгә рәхмәт, барлык тән шәрифләрең исән, атың да исән ләбаса! Авылда бит сезне югалттылар... Әллә нинди сүзләр йөри, балакаем. — Карчык тагын да укынып алды. — Инәңне кайчан чыгаралар, хәбәр-хәтәр юкмы?

— Иртәгә, — диде Кәбир һичбер икеләнүсез. — Иртәгә, Сәрбиямал әби.

— Шулай гына була күрсен инде, балакаем.

Һаман да догаларын укынып, карчык артта калды. Менә, ниһаять, кайчандыр, әле Кәбир дөньяга килмәгән елларда киселеп төшерелгән манарасының сөлдәсе һаман да җиргә сеңешеп яткан иске мәчет — клуб бинасы, олпат тирәкләрнең ябалдашы астында сукыр тавык кебек үтсыз чекерәеп утырган картатасы йорты — кәнсәләр тирәсеннән дә исән-аман үтеп киттеләр. Аннан Сәйфуллин килеп чыгар да, инәсеннән түгел, инде малайдан һәм аттан сорау алып, икесен бергә шунда ябып куяр төсле тоелды. Әмма кәнсәләрдә ир-ат кайгысы түгел, үлем тынлыгы хөкем сөрә иде.

Кайдандыр Бөкебашның сәлбер колаклы малае Сәмих калкып чыкты. Ул Кәбирдән ике класс түбән укый.

— Атаңа сәлам әйт, без кайттык!

— Өйдә юк әле ул,— диде малай сабыйларча беркатлылык белән.— Инәкәй, аны, кайтса да, өйгә ээ бастырмыйм, ди...

— Кайда соң ул? — дип сораган булды Кәбир.

— Кайда булсын. Йөридер әле шунда берәр җирдә дуңгыз сидеге чүмереп,— диде сабый инәсенең сүзләрен кабатлап. Аннан, йөгереп килеп, сорап куйды:— Атыңа нигә итек кидердең, әй?

— Кызык итеп.

Кәбирдә Бөкебашлар гаиләсенә, аның балаларына карата бернинди дә дошманлык тойгысы сакланмый. Үзеннән ике генә яшь бәләкәй Сәмихның сабыйлыгы гына сәерсендерде аны. Ул аңа әллә кайларда торып калган балачагы булып күренде. Аннан, аталы балалардан шактый ятсына, читләшә, хәтта аларны ничектер кызгана да иде Кәбир. Ата кешеләр балаларын гел генә тиргәп, гел генә сыртларын каезлап торган кебек тоелалар иде.

Кибет турыннан үткәндә болдырга әллә кайдан кызарып күренгән кибетче Казак Әгъләм, аның артыннан шулай ук кызмача Аккүз Сафа, Шытыр Гыйләҗләр чыкты.

— Нигә аны җәфалап алып кайтып маташтың? — дип кычкырды исәнлек-саулык сорашудан алда Аккүз Сафа.— Иткә тапшырырга иде...

Ул тешләрен ыржайтып, авызын һавага әлде. Бу Шытыр Гыйләҗгә ошап бетеңкерәмәде, ахрысы. Нәрсәдер эндәште. Аккүз шундук көлүеннән туктады.

— Маладис, энекәш! Егет икәнсең...— дип кычкырды болдырдан Шытыр.

Алда салам түбәсе кичке шәфәкъ ялкынында янган ат абзары күренде. Үзләре килеп егылачак хәлиткеч ноктага җиткәч, Кәбиргә моңсу булып китте. Гүя яшәүнең мәгънәсе, кызыгы беткәндәй тоелды. Ул бүген кич, бүген төнлә бер ялгызы караңгы өйдә нишләр? Аның бу мизгелне озайтасы килде. Бер мәшәкатьсез калу кайгысын кичерде ул. Адымнарын ат җентекләгән адымнарга җайлап, янәшәдән бара башлады. Бамбукның «сүнәм, менә сүнәм» дип барган күзләрендә өмет очкыннары күрәсе килде аның. Әмма күзләрдәге баз караңгылыгы тагын да тирәнәйгән сыман иде. Малай сул як бите белән ялга сыенып, тын гына пышылдады:

— Бмамбо-бимбо... Сама-рана-сама... Без әле яшәячәкбез, Бамбук...

Байтал җавап бирмәде.

Кәбир кулын пинжәк кесәсенә тыкты. Тозның кыйпылчыгы да калмаган шул. Шул шифалы тозны каптырса, ат җанланыр сыман тоелган иде югыйсә.

Ачык капка аша алар ат абзары ихатасына үттеләр. Һәркайдагыча әрле-бирле сугылып, уйнаган һәм тешләшкән тай-тулаклар, эш камытын салганнан соң кое тирәсендә өнсез калган алашалар барысы аларга борылып карады шикелле. Сабыр буендагы әрәмәлектән шомырт әчесе бәрде. Малай керфекләренә менә-менә саркырга торган күңел чыкларын басарга тырышты. Байтал коега юнәлеш алды. Чит-читләрен яшел мүк сарган улакның өстәге тишегеннән су саркый. Улакта озак ятудан кургашын төсенә кереп оеган һәм авырайган суны Бамбук берничә тапкыр уртлады. Авызлык тимеренең хәлсез генә зеңләве тирә-якны уята алмады. Байтал башын күтәрде һәм, һавадан нинди исләр, авазлар тотарга тырышып, колакларын шомрайтты. Таза, чит ирен-борыннар тыгылудан болганмаган су тели, ахрысы, бу, дип, Кәбир сиртмәле чиләкне кое авызына төшерә башлады. Кое бурасы эчендәге төпсез караңгылык Бамбук күзләрендәге баз караңгылыгы белән бер күренде малайга. Улакка, шамбырдатып, таза су салды. Әмма ат селкенмәде дә. Ул кинәттән башын тагын да югарырак чөйде һәм, хәлсез өзлеккән тавышлар чыгарып, кешнәп җибәрде:

— И-һа-һа-һай!..

Кәбир үзенең йөзенә җәелгән нурлы елмаюны җыеп өлгерә алмады, хуҗалык кирәк-яраклары саклана торган кара келәттән Сәми карт килеп

чыкты һәм... урынында катып калды. Аннан, һушына килеп, көтелмәгән мосафирлар янына таш булып атылды. Дулкынланудан булса кирәк, аның сүзләре бәйләнешсез иде:

— Ә-әй, Кәбир майкаем!.. Белдем мин... Сизендем мин шулайдыр диеп... Исән-саулар, димәк?! — Ул малайны хуш исле печән исләре аңкыган кочагына алды. — Исәнме, Бамбук ахирәткәем!.. Котылдык, болай булгач...— Карт байталның ялларыннан какты, яралы аякларыннан, күкрәк тапкырларыннан сыйпады. Хуҗасын таныган ат, ыңгырашкан, инәлгән авазлар чыгарып, аны иснәштерде. — Котылдык, болай булгач... Пәйгамбәр син, Кәбир майкаем! Әйе, пркарулга хат язып, җәмәгатьтән бардык... Галләм тәре!.. Сабирҗаңга рәхмәт... Иртәгә сөйләрмен, ямен?

Сәми картны туктатыр әмәл юк иде.

— Сиңа Нәби абзый күп итеп сәлам әйтте. Бамбук аның...

— Ишледәнме? Нәбиме? — Карт аны тагын бүлдерде. — Ифрат кыналар да һәйбәт кеше ул Нәби...

— Атны үземә тәрбиягә алыр идем, ди. Бамбук аның фронттагы...

— Атны Нәбигә тәрбиягә?! — Сәми картның уемтык сакалы кашына менде. — Син нәрсә? Нәрсә, Сәминең үзенең кулы юкмы? Йөрәге юкмы? Көпшәсендә дарысы чыланганмы? Үз атымны мин үзем тәрбияли алмыйммы? Димәк, синеңчә, майкаем, мин дастуен түгел?! — Ул күзләрен челт-челт йомып алды. Малай бу сүзләрне ник әйткәненә үкенде. — Үзем аякка бастырам мин аны... Хәзер үк! Ат — залатуй фонд Красной Армии! Кем әйткән? Даһи Сталин әйткән! Бу хакта бүтән ишетмим, колагына киртеп куең!..

Хәзер үк кулыннан ычкындырудан курыккандай, ул атны абзарга әйдәде. Бамбук аның ихтыярына буйсынып, абзарга таба шуышты. Тирдән һәм бер урында торудан суынып, аркасында таш булып каткан капчыгының авырлыгын тойган Кәбир дә, үзендә сәер бер ятимлек тойгысы кичереп, алар артыннан иярде. Мең җәфа аша атны аранга керттеләр.

— Бар, Кәбир майкаем, сәндерәдән яшел печән төшер. Мин келәттән солы алып киләм. Галләметдин тәре айгыры солысыз да торып торыр...

Бабасы ямшәеп беткән бидрәдә солы алып килгәндә Бамбук утлыктан теләр-теләмәс кенә итеп печән берәмтекли башлаган иде.

— Күрдеңме? Ашаган малда — өмет бар, дигән борынгылар. Димәк, өметсез түгел, — дип сөйләнә-сөйләнә, Сәми карт ат алдындагы печәнне бераз читкәрәк этештереп, утлыкка тас куйды һәм солы салды. — Ашап беткәч, тагын өстәрбез... Шуннан аякка да басып китәр, ходай кушса... Бар, син монау бидрәләр белән су алып кереп куең...

Кәбир кире кергәндә бабасы байталның корсак астыннан каеш үткәреп маташа иде.

— Әйдә, ярдәм итең. — Ул каешны ат корсагы астыннан сузды. — Бүгенгә без аны бүтән борчымыйбыз. Калганына иртәгә тотынабыз, Кәбир майкаем... — Аннан малайның иңеннән сөеп куйды. — Ә син олыгаеп киткәнсең, димме? Бөркет инде, бөркет — Кан-Күрәзә кошы, мин сиңа әйтим!..

Сәми бабасы күпме белсә дә, аның авызыннан беренче тапкыр ишетелгән бу сүз Кәбиргә, чыннан да, канат куйды.

— Анысы нәрсә тагын? — дип сораган булды ул белмәмешкә салышып. Бабасы ишетмәде, ахрысы, җавап бирмәде. Каешны баганага бәйләгән арада ул соравын тагын кабатлады: — Ниткән Кан-Күрәзә кошы була ул, Сәми бабай?

— Бәй, ишеткәнең юкмыни? Кан-Күрәзә кошын белмәгән булсаң, менә бел: ат каракларының аяусыз дошманы. Бамбукны безнең үзебездән урларга маташкан үзебезнең ат караклары дошманы... Кан-Күрәзә йә кичләтеп, йә төнлә урланган атларны кире хуҗаларына кайтара. Менә син аны кайтардың, майкаем. Караклар ул коштан — синнән нык кур-

калар. Ат урларга барыр алдыннан караклар, Кан-Күрәзә күрмәсен, дип, аңа корбан бирәләр. Алар синең инәңне корбан итәргә тырышты. Булдыра алмадылар, иншалла, булдыра да алмаслар!..

Алар эшне тәмамлады. Буш абзар эчен җанландырып, Бамбук үзенчә яшәргә тырышып кыштырдый иде. Араннан чыктылар. Ихатада атлар ишәйгән иде.

— Бар, майкаем, кайт, ял итең. Мин бүген кунача бармыйм. Монда кунам,— диде Сәми карт.— Күңелең тыныч булсын. Иртән күрешербез.

— Тукта! — диде малай нәрсәнедер кинәт исенә төшереп.— Мин хәзер!..

Ул атылып абзар эченә, аннан аранга үтте һәм, байталдан гафу үтенгән сыман сылаштырып-сыйпаштырып, башыннан йөгәнне салдырды.

— Миндә торсын, Бамбукҗан.. Кем белә, югалып куюы бар... Ни дисәң дә, колхоз, күмәк хуҗалык бит...— дип пышылдады ул, байталның колагына кайнар тыны белән өреп.— Үзем белән алганга рәнҗемисеңдер лә?

— Юк,— диде Бамбук.— Синдә торсын. Сакла, ярыймы?

— Саклармын, Бамбукҗан. Иртәгә кадәр исән бул.

— Хуш, Кәбирҗан. Рәхмәт сиңа. Сын-сөякләремне туган җиргә кайтарганың өчен рәхмәт.

Бугазга килеп тыгылган төердән буылып, ул абзардан чыкты.

— Нигә салдырдың? — диде Сәми карт малайның кулындагы йөгәнгә аптырап.

— Кирәк,— диде Кәбир кырыс кына.— Бу бик истәлекле йөгән, Сәми бабай. Иртәгә сөйләрмен әле...

Сәми бабасы белән хушлашып, Кәбир теләр-теләмәс кенә адымнар белән атлар алачыгыннан урамга чыкты. Аркасындагы йөк хәзер һич кенә дә йөк түгел иде. Иң зур йөк иңнән төште. Ләкин ул шатлык кичермәде. Киресенчә, шомы арта барды. Моңа кадәр, әйтик, берничә көн буе булса да, Бамбук «аныкы» иде. Хәзер аныкы түгел. Күмәк хуҗалыкныкы. Аның язмышын күмәк хуҗалык хәл итәчәк. Мир белән. Күмәкләр, барлык мир кыерсыттырмас әле, дип уйлады малай, киңәшеп эш итәрләр.

Алар ат абзарына якында гына яшиләр. Менә Кәбир беркайчан да бикләнми, келәсе салынмый торган имән ишекне ачып, өенә керде. Анда да гүр тынлыгы хөкем сөрә иде. Капчыгын салып, идәнгә куйганда Нәби абзыйсы биргән бәрәңгеләр доңгылдаган тавыш чыгарып, аңа нәрсә эшләргә кирәклеген төшендерде. Бик нык ачыккан иде шул. Әмма тамак туйдырудан да җитдирәк эшләр бар икән үз өеңә кайткач. Ул көзге каршына килде. Урыны-урыны белән көмеше кубып, акшарланып беткән көзгедән үзен таный да алмады: кечке карангылык аша аңа күзләре эчкә баткан, йөзе аска сузылып төшкән һәм олыгаеп калган адәми зат — бөтенләй икенче, аңа охшаган, ниндидер алмаш Кәбир карап тора...

Ул сандыкны ачты да, чүпрәк-чапракларда бутанганнан соң, кирәкле кәгазьләр, атасының сугыштан язган хатлары, заем облигацияләре саклана торган савытны тартып чыгарды. Барысы да урынында, әмма инәсенең атасы похоронкасына төрелгән көмеш алка-беләзекләре генә юк иде. Димәк, Имәнлек урманы акланында Сәйфуллин белән Бөкебаш юкка гына сатулашмаганнар...

Малай ихатага чыкты. Чит-читләрен әрекмән һәм кычыткан баскан читән абзар эченә керде. Анда да шул ук гүр тынлыгы иде. Авыл очыннан кәҗә-сарык бәэлдәгән, сыер малы бакырышкан тавышлар ишетелде. Көтү төшә, күрәсең...

Аңа дөнья да, үзе дә икенче иде хәзер.

Бер кочак утын алып кереп, ул учагын тергезеп җибәрде...

— Кәбир... Кәбир...

Күзен ачса — сәкедә, аның белән янәшәдә Харис дусты утыра. Үткән борчылу һәм кайгыларны төн йокысында тәмам оныткан Кәбир яткан җирендә иркәләнеп кенә сузылды һәм, йокысыннан айнып, елмаеп җибәрде:

— Килмисең дә... күренмисең дә...

Моңа кадәр бер-берсеннән аерылып, бер сәгать, бер көн дә тора алмаган ике ахирәт күрешеп тормый гына кочаклаштылар.

— Үзең миңа әйтмичә дә киткәнсең әле...— диде Харис үпкә катыш.— Дус, имеш. Кайтканыңны әле генә белдем...

Кәбир аның күзләрендә ниндидер шом, ул әлегә әйтергә ашыкмаган үтә житди хәбәр барлыгын тойды.

— Нәрсә, бер-бер хәл булдымы? Әйт!..

— Мине сиңа Сәми бабай җибәрде...— Харис, беркем дә ишетмәсен дигәндәй, аның колагына пышылдады:— Эшләр хөрт, малай...

— Нәрсә булды? Әйт тизрәк!

— Бамбукны суялар!.. Киттек, малай!..

— Булмас!..— Бу кадәр озак йоклап ятканы өчен оялуының чиге юк иде Кәбирнең.— Кемнең кулы күтәрелер?!

— Булмас сиңа... Сәми карт җибәрде, дим бит.

Алар урамга чыгып, ат абзарына таба җилдерделәр.

— Мал суючы картлар чүпрәккә төрелгән үткен пычакларын култык астына кыстырып китеп баралар иде. Үзем тап булдым, малай. Бәлки суйганнардыр да инде.

Кәбир шып туктады, дустын үзенә таба тартты:

— Син нәрсә сөйлисең? Син нәрсә сөйләгәнеңне беләсеңме?!

Алар авыл урамы буйлап мичәүле ат сыман алга томырылдылар.

Ат абзары ихатасының Сабырга барып текәлгән тәңгәлендә кайнашкан кешеләрне күреп, Кәбир шыбыр тир булды. Капкадан урап та тормыйча, алар ихата эченә читән аша гына сикерделәр. Җирдә гырылдап яткан Бамбукны күреп, әллә үзе күзләрен йомды, әллә көн караңгыланды... Бер сүз белән әйткәндә, ул таш булып катты. Әмма үзен шундук кулга алып, тирә-юньне күздән кичерде: аяклары аркан белән бәйләнгән килеш, кыйблага каратып, яны белән җиргә герсеелдәтелгән Бамбук; башы күренми, теге якта; бастырыкларының очын дүрт аякны бер итеп бәйләгән юан аркан астыннан тыккан, аны карын өстеннән байтал кымшана да алмаслык итеп үткәргән һәм үзләре шушы бастырыкка атланып алган Аккүз Сафа белән Ярар Ярыяхмәт; атның баш тәңгәлендә, теге яклап, үзләренең бурычына төшкән иң гадәти эшләрен уңышлы башкарып чыгу өчен урын-җир, бау-тияк, чүпрәкчапрак хәстәрләп маташкан Актык Тәминдар һәм Шытыр Гыйләҗ; читән буендагы эре ташларда кояш нурында кайралып яткан болай да үткен пычаклар...

«Нәрсә көтәсең?! Әле соң түгел!». Бамбук шулай эндәшкәндәй тоелды Кәбиргә. Тегеләр малайларны абайламый иде әле. Кәбир дусына күз кысты. Харис исә, һәрвакыттагыча, аның өчен утка керергә әзер иде. Алар пычакларга таба атылдылар.

— Туктагыз!..

Пычаклар белән коралланып алган ике үсмер дүрт ир-узаманга ташланды. Бастырыкка түшәлеп хәл җыйган Аккүз Сафа белән Ярар Ярыяхмәт, көтелмәгән һөҗүмчеләрдән куркып, читкә янтайды. Нәрсә булганлыгын аңышып өлгермәгән Аккүз Сафа һәм Шытыр Гыйләҗ аптырап калдылар.

— Бамбук! — дип кычкырып җибәрде Кәбир үзәк өзгеч тавыш белән.— Бамбукҗан!..

Өлкәннәрнең мондый кыюсызлыгыннан файдаланып калырга тырышкан малайлар байталның аякларын чорнаган арканнарны кисә, тураклый башлады. Авыр тын алып гырылдаган Бамбук тыпырчынырга тотынды һәм, Кәбирне тавышыннан танып булса кирәк, җирдән башын калкытты һәм җан ачуы белән кешнәде:

— И-һа-һа-һай!.. һа-һай!..

Эшнең асылын иң тәүдә Аккүз Сафа аңлап алды. Ул арттан килеп, тимер тырма сыман куллары белән Кәбирне каерып алырга дигәндә генә, пычактан сакланып, җикеренде:

— Ташла пычагыңны, маңка малай!..

Актык Тәминдар исә Харисны җилләп очырды. Әле һаман бернәрсә төшенмәгән Шытыр, ана каз кебек, Кәрим тирәләй йөренә башлады:

— Э-э-э... Малайлар, дим, малайлар...

— Бу атны суярга ярамый! Сез шуны беләсезме? — Кәбир белән Харис пычакларын айкап, яңадан байталга ярдәмгә ташландылар.— Ул сугышлардан исән кайткан фронтовик ат! Китегез, барыгызны пычактан үткәрәм!..

— Нәрчә, карап каттыгыз! — Артта Бөкебашның буш мичкәдәй дөбердәгән тавышы ишетелде.— Тотыгыз, бәйләгез үзләрен!..

Кәбир, юлбарыс сыман ажгырып, шешенгән Бөкебашка таба килә башлады. Ул бүген Ябалак иде.

— Кара әле, кара... Чин кемгә кул күтәргәнеңне беләчеңме, чабакы? — Фронтовикка күтәрәчеңме? — Артка чигенгән Ябалак мал суючыларга уратып алырга ишарә ясады да, малайларны үзенә якын китермәс өчен шарт-шорт чыбыркы шартлата башлады.— Мин — влач! Башыгызны төрмәдә черетәм, чабакылар!..

Вакыйга ике түгәрәк эчендә бара иде. Беренче түгәрәк уртасында туктаусыз чыбыркы шартлаткан Ябалак, аны кысырыклап барган малайлар, икенчесендә аларны эләктерергә чамалаган дүрт ир ураткан. Чыбыркы, ниһаять, Харисның күз төбендә генә яшьнәде.

— Әлү-әлү!..

Дусты, үрсәләнеп, күзен каплауга аны эләктерә салдылар һәм, кулларын каерып, пычагын алдылар.

— Бәйләгез үзен!..

Кәбир, пычагын күкрәк тапкырында тотып, Ябалакка якынлашты.

— Арттан! Арттан! — дип бакырды ул һәм көтмәгәндә генә Кәбирнең нәкъ йөзе өстендә чыбыркысын шартлатты. Күзләрдә утлары гына ялтлады.

— Ин-нәй!..

— Әле инәңне хәтергә төшерденме, чабакы? — Ябалак котырган кыяфәт белән Кәбирне чыбыркы белән яра башлады.

— Чин күмәк хуҗалык атын үтерү өчен юлга алып чыктыңмы?! Менә чиңа! Менә чиңа!.. Атың-иең белән нәчеленне!..

Кәбирне тотып алдылар һәм кулыннан пычагын бәреп төшерделәр. Тегеләрдән ычкынып китә алган Харис, арттан килеп, Ябалакка таш белән томырды. Аңа шунда ук бау ыргыттылар.

— Нәрчә карап каттыгыз? Бәйләгез үзләрен!

Кайдандыр йөгереп килеп, тыны буылган Сәми карт, тезләнеп, Ябалакка ялвара башлады:

— Галләметдин туган... Суйдырмаң!.. Мәҗүси бабаларыбыз да үзе җиккән атны суеп ашамаган...Тамагыңа торыр! Суйдырмаң!..

— Минем тамакка эләкмәячәк ул,— дип җикерде Ябалак.— Чинең тамак, колхозчылар тамагына керәчәк! Печәнгә төшәбез. Халык ач!..

— Аякка бастырам мин аны. Үтенеп сорыйм, Галләметдин энекәш, харап итмә Бамбук нәселен!..

— Нәселе әйбәт инде, анысына сүз юк,— дип куйды Шытыр Гыйләҗ.

— Нинди нәчел? — Битләре тимгелләнеп кызарган Ябалакны үзе уйлаган эштән кире көндерү мөмкин түгел иде.— Казалы нәчел, контра нәчел! Җилдә какланган гәүдәче генә калган инде анын... Чалыгыз, дим бит!

— Ярар, син әйткәч,— дип Ярар Ярыяхмәт Бамбукка таба атлады.

Янәшәдә арба үрәчәсенә бәйләнгән Кәбир тыпырчына башлады:

— Абзыйлар!.. Буаз ул.. Эчендә алтыны бар!.. Колынласын!..

— Кайдан килгән мал духтыры,— дип шаркылдап көлде Ябалак.— Җәһәтрәк кыйланыгыз дим бит! Чуяргамы-чуймачкамы икәнлеген малай-шалай түгел, күмәк хуҗалык, халык хәл иткән. Казага тарыган атны күрә торып үтертергәме әллә? Үлчә, Чанияга җиңелрәк булыр дип уйлыйчызмы? Чания җәлке, Чания!..

Үз максатына ирешү өчен Ябалактан Җылак Галләметдин рәвешенә кереп алудан да тартынмады ул.

— Ярарыгыз инде,— диде бастырыкка барып асылынган Ярар Ярыяхмәт.— Башлыйк булмаса...

Аркан белән бәйләүдән тулысынча котылырга өлгерми тыпырчынып яткан яралы атны алар янадан чорнадылар. Сары Зариф Ярыяхмәткә ярдәм итеп, бастырык очына барды. Актык Тәминдар байталның башына ике аягы белән тезләнде. Катык сыман ак, эчкә баткан күзләрен тагын да эчкәрәк яшергәндәй, карашын очлап, Аккүз Сафа чалгыдан ясалган кыя пычагын кояшта ялтлата-ялтлата ат башы янына килде, сул тезе белән ял яклатып муенына тезләнде...

— Бисмиллаһ иррахман иррахим!..

— Буаз ул, абзыкайларым.. Колынласын!..— Үзе бәйләнеп куелган арбаны ду китереп, Кәбир тагын да бер тапкыр тыпырчынып алды.

Күзем күрмәсен, дип булса кирәк, Сәми карт абзар эченә кереп китте.

— Ябалак тәре! Ябалак тәре! Ябалак тәре!..— Харис, бөен өзәргә тырышып, арбаның икенче башында бәргәләнде.

— Нәрчә мыштырдыймыз инде?! — Ябалак каушап калган сугымчыларга тагын бер тапкыр җикерде.

— Бисмиллаһ иррахман иррахим...

Аккүз Сафаның куллары сизелерлек дәрәҗәдә калтырый иде. Шулай да ул үзен кулга алды. Менә ул сул кулы белән атның үнәченнән тотты, уң кулындагы пычакны житез хәрәкәт, өйрәнелгән алымнар белән байталның ефәктәй елкылдап торган бугазына ышкуы булды — Бамбук «хшша-ша-ша» сыман авазлар чыгарды — бугаздан чишмә булып ал кан чәптерде. Бар тирә-якны байталның ямьсез гырылдавы басты...

Кәбир үз күзләренә үзе ышанмый иде. Гүя, бу — бер куркыныч, кыргый төш иде. Бамбук һәр буыны белән тартыша, тыпырчына башлады. Бамбукның күзләрендә үз гәүдәсенең шәүләсен күреп, Кәбир торараш булып калды. Бу күзләрдә зәңгәр төпсезлеге белән күк гөмбәзе айкалды, аннан бу зәңгәрлек кечерәйгәннән кечерәя барды, ниһаять, ул күз карасыдай ноктага әверелде дигәндә, анда ниндидер аяклана алмаган кош баласы талпынды-талпынды да, әле генә энҗе булып ялтыраган күз төссез койка сыман оеды, сүнде. Керфекләрдән соңгы яшь тамчысы зәңгәр энҗе булып үләнгә тәгәрәде... Гәүдә һаман тартышты, аның һәр тамыры соңгы тапкыр киерелеп бушанды, ниһаять, соңгы тапкыр дертләде дә тынып калды.

Малайлар елаудан туктады. Мәгънәсе беткән иде. Кәбир өши башлады. Гүя, кояш кара янды, җәйге чилләдә кар яуды.

Урамнан, ат абзарын дер селкетеп, ХТЗ тракторы үтте. Тракторчы Биктимер абзыкайларының Бамбукка кысылышы юк иде.

Кәбир Бамбукҗанның соңгы авазын хәтерләде. Хш-ша-ша-ша... Нәрсә диде ул Кәбиргә? Нигә алып кайттың, диде мe? Кичәге хушлашуының раска чыгуын тагын бер мәртәбә, инде үлеме белән дөресләдеме? Нинди кош кагынды аның күзендә? Кан-Күрәзә кошы мәллә?

Сугымчылар атны арканнардан арындырган арада ул тагын бер мәртәбә Бамбукҗанының күзенә карады. Ул аны бүтән беркайчан да күрмәячәк. Хәзер анда күктәге ак болыт кисәге тонган иде. Бу күзне, бу карашны Кәбир беркайчан да онытмас: нәрсәдер мәңгелеккә өзелде, ир белән ат арасындагы нисбәт җимерелде. Тормыш озак, бик озак мантымас. Җыр тынар, әкият яңгырамас. Табигатьтән мул бирелгән һәм иртә өлгергән зирәк ир акылы белән Кәбир шуны аңлады: ир белән ат арасындагы бүгеннән башланган өзеклек тиз генә ялганмас, һәрхәлдә, егерменче гасырда ялгана алмас. Бу өзеклек кешеләрне бик күп бәлаләргә китерер. Һәм Кәбир дә тормышының иң кискен мәлләрендә шушы мәсьәләнең уңай чишелешенә, аның никадәр зарур булуына кабат-кабат әйләнеп кайтыр...

Бугазына пычак салынгач кына үз күзләре белән күреп ышанды бит ул Бамбук күзләренең үз күзләре сыман сөрмәле булуына. Бу күзләрдә инде беркайчан чегәннәр дә, Нәби, Чтапаннар да, кызыл күлмәкле Нәстүк тә, Соры Бүреләр дә чалынмас. Яктыны якты, караны кара итеп тоеп китеп барды ул җир йөзеннән. Үзе эчкән чишмәләрдән, хәтта үзе үстергән бәрәңге чәчкәләреннән оялды Кәбир. Аның яшисе килми иде.

— Ычкындырыгыз мине! — дип кычкырды, яңадан ян-якка сугылып.— Чишегез! Югыйсә...

— Нәрчә югыйчә? — Ябалак аның каршына җикеренеп килде. Авызыннан кичә эчелгән аракының көйгән арыш исләре аңкыды.— Нишләмәк булачың? Сафа, Тәминдар, алыгыз тегечен! Ә мин — монычын!.. Эшләргә бирми, чабатажниклар...

— Ярар! — диде һәрчак алдан юл ярган Ярар Ярыяхмәт һәм, килеп, Харисны чишә дә башлады. Ябалак исә Аккүз белән икәүләп Кәбирне бәйдән ычкындырдылар һәм каравыл йортына өстери башладылар. Җирдән сөйрәлгән малай Ябалакның кулына тешләрен батырды.

— А-а-а, бандит!..

Ябалак улап җибәрде. Малайларны кертеп яптылар һәм өсләреннән бикләп куйдылар.

— Син әтәй белән инәй үчен миннән аласың! — дип кычкырды Кәбир ишекне бикләтмәскә тырышып.— Бамбук та безнең нәсел! Безне генә түгел, малыбыз нәселен дә корытырга итәсең... Сәйфуллиннан яклатыр өчен син аның сөяркәсенә инәйнең алка-беләзекләрен сандыгыбыздан урладың! Әтәйнең үлемтек кәгазен ертып ташладың! Мин барысын да беләм!..

Ишек ярыгы аша күренгән Ябалакның күзләре аларып китте. Ул беравыкка телсез калды. Нәрсәдер мыгырданды ул танавы астыннан. «Күп беләчең... Чин әлегә уйланып келәттә утыр, яме... Аннан төрмәгә күчерербез!»

Һәм келәт ачкычын кесәсенә салып, китеп барды.

Якында гына сугымчыларга биргән боерыгы яңгырады:

— Җәһәт кыланыгыз! Бачы-тоягы, эчәге-фәләне үзегезгә!..

Харис пәрәвез оясы сарган кечкенә тәрәзәгә капланып, елаудан кызарган күзләре белән сугымчыларны күзәтә башлады. Өлгене, бәлки, алып ташлап та булыр иде, әмма уем алар сыярлык түгел иде шул. Тәмам күңеле төшкән Кәбир почмактагы камыт өсләренә барып утырды да, учлары белән битен каплап, тын калды. Ул картатасының ак келәтеннән кара каравыл өенә әйләндерелгән каралтыда биктә утыра иде.

Сугымчылар сөйләшкән сүзләр бирегә сыек мыгырдану булып кына саркыла. Харис ара-тирә аңлатма биреп бара:

— Атны туный башладылар...

— Эндәшмә, Харис!..

— Бөкебаш хатын-кызларны куып китерде... Эчәге юарга, ахрысы...

— Үзе абзарга кереп китте. Хәзер сәндерәгә менеп, әзерләп куйган шешәсе белән махмырын төзәтәчәк һәм сәндерәдән Җылакка әйләнеп төшәчәк...

— Сөйләнмә дим бит мин сиңа!..
Кәбир ишеккә атылды һәм бар көченә дәбердәтә башлады. Аңа Харис та кушылды. Юк, беркемдә дә алар кайгысы юк иде.
Ул яңадан урынына килде. Аның якты көнгә карарлык батырлыгы житми иде. Харис, тәрәзәсеннән аерылып, дусты янына килеп чүгәләде. Ул Кәбирне ничек кенәләр итеп тә юатырга белмәде.
Кәбир янә урыныннан торды. Аның бу зинданнан чыгасы килә иде. Тәрәзә кырына килде һәм Хариска текәлде:
— Нишлибез, ахи?
— Чыгабыз,— диде тегесе икеләнмичә.— Чыгабыз да, авылдан качабыз.
Бу бик кызык иде. Бигрәк тә авылдан качу турындагы фикер.
— Кая качабыз соң, Харис?
— Шәһәргә. Илдә чыпчык та үлми, диләр түгелме соң? Без дә үлмәбез әле. Икәүбез бит...
— Ә ничек чыгабыз?
Харис мич торбасына күрсәтте:
— Түшәмне куптарыйк. Аннан — дүрт як кыйбла.
Кәбир дустының тапкырлыгына куанып, аның иненә сугып куйды. Малайлар мич башына менеп, иңнәре белән берьюлы ике тактаны күтәрә башлауга, кемнеңдер ишектә кыштырдаган тавышы шәйләнде.
Алар песи саклыгы белән ишек катына килде. Кемдер йозак элгече астына тимер казык тыгарга азаплана иде. Икесе ике ярыктан тышка карасалар, һушлары-акыллары китте: ул Харисның гарип абыйсы Заһир иде!
— Аскарак, абый, аскарак,— диде Харис абыйсына ярым пышылдап.— Иненә куеп күтәрт!..
Заһир исә шактый уңышлы алымнар белән элгечне суыра башлады. Көчәнеп, соңгы омтылыш ясады, һәм йозаклы элгеч, тәмам суырылып чыгып, ишек тактасында зеңгелдәде.
Ирекккә чыккан тоткыннар коткаручыларын кочаклап алдылар. Житкән чәчле, кабыгыннан арындырылган бәрәңге сыман ап-ак йөзле, зәңгәр күзле Заһир үзенең зур эшкә яраганлыгына чиксез куанып, елмая иде.
Чәпченеп торырга вакытлары да, кәефләре дә булмаган малайлар сугымчылар янына ялтандылар.
Ябалакның жикеренүеннән болай да алжыган, шуңа күрә вакытыннан алдарак килеп, юарга эчәк-карта әзер булмагач, бер читтәрәк сөйләшеп торган хатыннар да, мөкиббән китеп, Бамбукның карынын актара башлаган сугымчылар да абайламый калды — малайлар янәшәдәге чана табанлыклары өеме артына постылар. Аккүз Сафа белән Актык Тәминдар карыннан нәрсәнедер аера алмый азапланды һәм, ниһаять, аерып, бу капчыкка охшаган күкшел коңгырт нәмәстәкәйне читән буендагы кычыткан арасына илтеп томырдылар.
— Малай әтнәке дөрес чамалаган,— диде Сары Зариф.— Дүрт-биш айлык булыр... Ходаем, үзең ярлыка, Бамбук нәселенә кул салдым бит...
— Әллә туачак, әллә үләчәк иде әле ул.— Ярар Ярыяхмәт канлы пычагын байталның бурлы тиресенә сөртте.— Без кушылганны гына үтибез, рас!
— Шулай да кумәргә кирәк булыр, кордаш. Жан иясе бит...
— Йөрәк дигәч тә йөрәк булган икән байталда! — Актык Тәминдар атның йөрәген суырып чыгарды.— Ун кила булыр, әй! — Ул тиякккә асылган йөрәкне читән казыгына элеп куйды.— Сиңа, Сафа. Чалган кешегә. Көнбагыш маеңда кыздырсаң, үтергән була ул.
— Закускага! — дип шаркылдап көлде Аккүз.— Бергә авыз итәргә язсын!
— Анысы инде синнән тора...
Болай да алсу йөрәк түбәгә менеп килгән кояшта тагын да алсурак булып күренә иде.

Бу манзараның нәрсә белән тәмамланачагын алдан әйтү мөмкин түгел иде. Аны абзар эченнән ишетелгән тавышлар бүлде.

— Әйдә, малай!

Иң алдан Харис торып олакты. Аның артыннан — Кәбир. Аннан — хатыннар. Аннары гына сугымчылар килеп җитте.

Абзарга килеп керсәләр, ни күзләре белән күрсеннәр — ревкомиссия Сабирҗан абзыйлары, Ябалакның, ике кулын артка каерып алып, җиргә тезләндергән:

— Моннан соң ятимә хатыннар, ятим сабыйлар өстеннән көлмим диген!

Харис дөрес сиземләгән булып чыкты. Сәндерәдә баш төзәтеп өлгергән һәм шактый җылынып алган Ябалак хәзер, чыннан да, Җылак Галләметдингә әверелгән иде.

— Көлмим, Чабирҗан туганкаем, көлмим!

— Өч тапкыр ант ит! Өч тапкыр ант итәм, дип әйт!

— Ант итәм! Ант итәм! Ант итәм!..

— Җир ашап ант ит!

— Җәфалама, Чабирҗан туганкаем... Ничек ашыйм ди инде мин аны?!

— Ашарсың. Башкаларга ашатасың бит. Йә, кемгә әйтәләр?

Җылак чын-чынлап елый башлады.

— Кызган, Чабирҗан туганкаем... Көлдермә... Мин бит Чанияны җәлләп кенә... Үләкчә безгә нәрчәгә? Халык өчен!..

Сабирҗан абзый, тегенең кулларын тагын да каера биреп, башы белән җир сөрдерә башлады.

— Чамалап, Сабирҗан! — Аккүз Сафа алгарак чыкты. — Үз өстеңә күбрәк аласың түгелме, энекәем?

— Сез үз эшегездә булыгыз, — диде Сабирҗан тыныч кына. — Башланган эш — беткән эш. — Җылак исә, уңга каерыла, иреннәрен җирдән читләштерергә тырыша иде. — Аша, диләр сиңа!

Кәбир йөгереп килде һәм Җылакның җилкәсеннән шакарып, башын турыга борды, аракы исе бөркелеп торган авызын җиргә ордырды:

— Аша!

Сугымчылар урында таптандылар.

— Көлмәгез юк өчен кеше өстеннән! — диде Гөлсем түтәй арага кысылып. — Чынлап та, Сания өчен атның суелуы файдалырак түгелмени? Аранда үлгән ат белән акланып буламыни?

— Аша да куй инде, Галләметдин, — диде эчкерсез беркатлылык белән Рәйхан җиңги. — Бер тапкыр бук ашаганнан бер нәрсә дә булмас...

Беркем көлмәде. Эш көлүдән күпкә ары киткән иде.

Җылак, мыгырданып, иреннәре, тешләре белән кармады һәм башын күтәрде — аның авызы, йөзе, шешенгән күз кабаклары яшькелт ат тизәгендә иде.

— Хәш-шәрәт!

Сабирҗан абзыйлары Җылакны этәреп җибәрде һәм, читкә төкереп, абзардан чыкты.

Анда кояш түбәгә күтәрелеп җиткән иде.

— Инәң бүген кайтачак, Кәбир, — диде Сабирҗан абзыйсы. — Кайгырма, туган, мәсхәрәгә бирмәбез...

Кәбирнең Сабирҗан абзыкаен кочаклап аласы килде, әмма ул инде сугымчыларга күрсәтмә бирә иде:

— Кәтрәсенә кадәр келәткә тапшырасыз, Сафа абзый. Бу итне үз халкыбызга ашатырга хакыбыз юк. Тамагыннан үтмәс. Гәрчә ул ач булса да. Итне райүзәк ашханәсенә тапшырачакбыз...

Аккүз Сафа өчен ни өчендер Ярар Ярыяхмәт җавап тотты:

— Ярар, Сәлимҗан энекәш. Безгә ни, ни кушсалар, шул булыр, Сәлимҗан энекәш...

Сабирҗан абзый ашыгыч адымнар белән ихатадан чыгып китте.

Кѳтмәгәндә Кәбирнең күз алдына атка атланган кызыл күлмәкле кыз пәйда булды. Зиһенендә ниндидер кояш кабынды, түгәрәк сызып, сүнде. Ният ѳлгергән иде. Ул сугымчыларга таба атлады.

— Юк инде, Сафа абзыкаем, Бамбукның йѳрәге сезгә закускага ярамас. Эчегез авыртып куюы бар,— диде ул — Бамбукның йѳрәге безгә кала...

Ышанычлы адымнар белән барып, кансырап торган йѳрәкне казыктан тѳшерде.

— Күтәреш, Харис!

Тиякне ничек җитте шулай учмарлап, алар капкага юнәлделәр.

Аккүз Сафа, арба тәртәсен алып, артларыннан ташланды. Әмма малайлар авыл очына таба җилдерәләр иде инде. Бамбукның Кәбир белән Харис уртасындагы әле суынып та бетмәгән йѳрәге тѳшлектәге кояш кызуында Муса бабай абзарындагы фонарь сыман кызарып һәм ѳч ягыннан алтын очкыннар коела иде.

Авылдан бер чакрым чамасында, нәкъ Кыргыз юлы ѳстендә яткан Изге Имәнгә юнәлделәр алар. Бик тә борынгы, бик тә тарихи имән диләр аны. Япа-ялгыз бер ялгызы кѳн итә. Аңа ничә яшь икәнлеген аксакаллар да белми. Янына басып карасаң, аннан Сабыр-Усылы буйлары күренгәндәй итә. Аталарының сугыш юллары шушыннан башланган, ләкин чит-ят яланнарда тәмамланган...

Менә алар Изге Имән янына килеп тә җиттеләр. Аның чатыр сыман киң ябалдашы астындагы күләгәгә кереп, очлы ташлар ярдәмендә һәм тырнак итләрен ерта-ерта, тыгыз туфракны чокый башладылар. Йѳрәк ѳчен кабер иде бу. Бамбук йѳрәге ѳчен.

Адашкан җил имән яфракларын шыбырдатып алды. Ниһаять, кабер дә әзер булды. Ике ятим, ике дус дүрт куллап Бамбукның ут булып янган йѳрәген кабергә тѳшерде. Аларның куллары да ялкында иде. Эндәшмитынмый гына туфрак коя башладылар. Йѳрәк күмелә барган саен Кәбирнең Соры Бүрене, Кан-Күрәзә кошын, Нәстүкне, Чтапан дәдәйне, Нәби абзыйсын, инәсен, тагын да әллә кемнәрне, әллә кемнәрне күрәсе, аларның барысын да ат җиназасына чакырасы килде. Бу тойгы кѳчәйгәннәнкѳчәя барды.

Кабер алдында бер мизгел тын торганнан соң, алар ябалдаш күләгәсеннән кояшка чыктылар.

Арыш басуы дулкынлана, һавада сусыл арыш җимшәне исе аңкый иде. Кеше-мазар күренмиме, дип Кәбир артына борылып карады. Кыргыз юлыннан кулына тѳенчек тоткан бер шәүлә тирбәлә иде.

Үз сѳяген рәшә аша тѳсмерләп, малай каршы йѳгерде.

Ул, әлбәттә, аның әнисе иде.

*1985—1990*

*Пицунда — Куктүбә — Канбәк — Уфа.*

## Фәнис Яруллин

### ҺАМАН ДА БЕР ҮК КЫЙБЛАМ

* * *

Син дә хәлсезләндең, йөрәк,
Арыдыңмы әллә?
Хәлсезлегең кичереп булыр,
Ләкин дәртсезләнмә.

Күпме кортлар кимерә сине,
Син бит йомшак алма.
Кортлар кимерсә кимерсен,
Ләкин катыланма.

Син яшисең каный-каный
Гел яралы хәлдә.
Яраларыңнан үлсәң үл...
Ләкин гамьсезләнмә.

* * *

Балачак хыялы — очар кош:
Тартыла биеккә-биеккә.
Туктауны белми ул очыштан —
Канаты кояшка тиеп тә.

Яшьлекнең хыялы — агымсу:
Ашкына еракка-еракка.
Бара ул барачак җиренә
Туры да, тауларны урап та.

Картлыкның хыялы — авыр таш:
Өстери тирәнгә-тирәнгә.
— Биеклек, ераклык, тирәнлек —
Яшисең шуларны сөйгәнгә.

* * *

Хыялларым пыяла —
Шәфкатьсезлеккә бәрелеп
Челпәрәмә уала.

Өметләрем нечкә кыл —
Хаксызлыкны күтәралмый
Өзелә дә төшә гел.

Шигырьләрем тынмас чаң —
Өзгәләнә, бәргәләнә,
Чаңның теле — минем җан.

Мәхәббәтем якты нур —
Өметләрне өметләргә
Ялгап тора бары шул.

---

Фәнис ЯРУЛЛИН (1938) — танылган шагыйрь, прозаик, драматург, егермегә якын китап авторы, М. Җәлил исемендәге премия лауреаты. Казан яши.

## Умырзая

Һәр яз саен куңлем урманында
Умырзая шытып чыга да,
Зәңгәр күккә зәңгәр күзен текәп,
Гаҗәпләнеп карый дөньяга.

Өзүчесен көтә сабыр гына
Кар астыннан чыккан тыйнак гөл.
Сискәнә ул агач ботагына
Кагылып куйганда да уйнак җил.

Аяк очларына баса-баса
Күзәтә ул: юкмы бирәрсе?
Шушы матурлыгын бирәрсенә
Бик бирәсе килә, бирәсе.

Көтә-көтә шаулы язлар үтә,
Зәңгәр күзнең бетә нурлары.
Тын аланда үкси умырзая:
Күрүчеләр мине булмады шул,
Өзүчеләр мине булмады.

Язлар саен бу хәл кабатлана —
Тамыры һаман исән бу гөлнең...
Җилләр генә бер шаулатып ала
Урманнарын минем күңелнең.

## Аңладым

Алларыңа килеп
Былбыл булып
Күпме сайрадым.

Ә син
Тик юри дә колак салмадың.

Бер яшь егет килеп
Карга булып
Каркылдаган иде —
Иярдең дә киттең,
Кызык иттең.

Менә шунда
Яшьлек белән картлыкның мин
Аермасын яхшы аңладым.

* * *

Яз күзендә — яшь бөртеге,
Тамып төшәргә тора.
Язның яше тамган җирдә
Гөлләр үсәргә тора.

Яз күзендә — яшь бөртеге,
Тамсын әле иренемә.
Бәлки язлар ашкынуы
Тулыр минем күңелемә.

## Янды, янды

Тормышларны бөтенәйтмәк булып
Яшәсәк тә гел-гел өй сипләп —
Янды ләкин, күпме шатлык янды
Йөрәк мичләрендә төтенләп

Янды, янды, шартлап-шартлап янды
Киләчәккә булган өметләр.
Замананың тишек казанына
Кайнап акты безнең җелекләр.

Янды, янды, гомеркәйләр янды,
Төтеннәре очты һавага.
Дөрләп янган якты хыялларның
Көлен сипте җилләр далага.

Янулардан һаман туктаган юк,
Яна эчтә ачу, яна үч.
Бөтенесен үзенә йотып бара
Зур авызы белән дөнья — мич.

## Картлыгымны телим алдарга

Чыклы үләннәрне таптый-таптый
Йөгерәм икән якты таңнарга —
Елларымны юлда адаштырып
Картлыгымны телим алдарга.

Кышларыма кереп җитмәс борын
Гел ашкынам икән язларга —
Гөрләвекләр җыры белән шулай
Картлыгымны телим алдарга.

Кул-аякны таштан канаттырып
Үрмәлимен икән тауларга —
Зуррак булып күренер өчен түгел,
Картлыгымны телим алдарга.

Йөрәгемнең очкыннарын җыеп
Учак ягам икән айларга —
Яшьлегемнең якты уты белән
Картлыгымны телим алдарга.

* * *

Матур төшләр сирәк керә хәзер.
Ә бүген мин шундый төш күрдем:
Иреннәрең аша мәхәббәтнең
Татлы суын миңа эчерден,
Һәм мин — исердем.

Айный алмыйм шушы төшемнән мин
Һәм теләмим бер дә айнырга.
Мин ризамын мәңге синең белән
Матур төшләремдә калырга,
Юк, теләмим айнырга.

## Мәхәббәткә ялвару

Китмә әле, китмә, мәхәббәт,
Бик аз кунак булдың бит әле.
Хыял тулы минем йөрәккә
Тагын бер яз бүләк ит әле.

Ә аннары китсәң китәрсең,
Өметләрне киссәң кисәрсең
Озатырмын үзем кул болгап,
Йөгерерләр гөлләр юл буйлап.

Китмә әле, китмә, мәхәббәт,
Тагын бер җәй бүләк ит әле.
Җылынырга кайнар учакта
Тагын бер җай бүләк ит әле.

Китмә әле, китмә, мәхәббәт,
Тагын бер көз бүләк ит әле
Бакчамдагы гүзәл гөлләрне
Өзәселәр бардыр бит әле.
Китмә әле, китмә, мәхәббәт.

## Әни, синең хәер-фатихаң

Ашкынабыз ерак юлларга без
Яулар өчен күбрәк җиңү-дан:
Юлда безне бәлаләрдән саклый,
Әни, синең хәер-фатихаң.

Баш очында кайчак кояш сүнә,
Атмас кебек була якты таң:
Караңгыда безгә юл күрсәтә,
Әни, синең хәер-фатихаң.

Киңәшергә янда дус югында,
Бәргәләнгән чакта ялгыз җан,
Иң акыллы бер киңәшче була,
Әни, синең хәер-фатихаң.

Шунсыз җирдә яшәү мөмкин түгел,
Шунсыз булмас иде безгә сан —
Туган көннән үлгәнчегә кадәр
Кирәк, әни, хәер-фатихаң.

* * *

Үзгәрсә дөнья үзгәрсен,
Яңарсын әйдә заман.
Мин яшим әле искечә —
Күңелдә иске Иман.

Кемнәрдер исем яңарта,
Яраклаша заманга:
Яңа күлмәк кигерәләр
Шулай иске ялганга.

Кирәкми мәхәббәтнең дә
Яңарган, буялганы.
Кадерле миңа Сөюнең
Искесе, сыналганы.

Ахрысы, искелек минем
Уйга тирән уелган:
Һаман бер үк юлдан барам,
Һаман да бер үк Кыйблам.

* * *

Кинәт кенә китеп барсам әгәр
Шаулап торган синең дөньяңнан
Син уйлама,
Берни калмас диеп моңардан.

Калыр, калыр!
Йөзеңдә сыр калыр,
Күзеңдә моң калыр тулышып.
Ул моң зәңгәр сөрмә булып ятар
Керфек төпләреңә елышып.

Күңелеңдә яңа бер җыр калыр,—
Җырлап кына бетмәс озын җыр.
Ычкындырмас ул үзеннән сине,
Урап тотар — гүя бер чылбыр.

Мәңгелеккә өмет итмим, ләкин
Син барында яшәрмен әле.
Күзләреңдә шул моңнарны саклап
Тик син генә яши күр, яме.

## Илдус Гыйлаҗев

# ЙОЛДЫЗЛАРДАН ЭЗЛИМ ҮЗЕМНЕ

## Татар язмышы

Ашатып та карадың,
Эчертеп тә карадың.
Ул симерде... ә үзеңнең
Ачлы-туклы тамагың.
Кыз да бирдең кияүгә,
Ул да бирдең... киленгә:
Сөйләшүче бетеп бара
Инде туган телеңдә.
Ил-җиреңне теттердең,
Артыңа да типтердең.
Үзең һәрчак аны яклап
Утка-суга сикердең.
Динеңне дә югалттың,
Денеңне дә югалттың.
Орлыгы да калмас әле
Синдәй тиле... юмартның.
Корытса да тияген,
Аны мактап сөйләдең.
Барыбер бит яратмады —
Бар сөйкемсез сөяген.
Шуңа көн-төн каргалдың,
Яшәрлегең калмады...
Кемлегеңне әйтеп бирдем,
Үзең уйла калганын...

## Өмет ае

Башкалам дип киләм сиңа, Казан,
Бабаларым сиңа табынган.
Рәхәтләнеп мәгәр йөри алмыйм:
Хөр түгел син... яулап алынган.
Ят исемнәр сеңгән урамнарда
Адашмыйча йөреп буламы?
Ай яктысы эзлим... түбәләрдә
Катлы-катлы тәре урманы.
Бәйсезлеген җуйган милләтләрне
Халык диеп әйтү ярасамы —
Татарга да кеше кагылмаган
Берәр почмак тиеш ләбаса!
Җанга җылы булсын анда баргач,
Өмет ае торсын күгендә!
Ә хәзергә андый пайтәхетне
Йөртәм бары күңел түрендә...

---

Илдус ГЫЙЛАҖЕВ (1946) — *шагыйрь. «Җир китабы», «Җилкенү» һ. б. китаплар авторы. Азнакай районында яши.*

* * *

Атсын әйдә, юыйк юшкыннарны,
Каерып ал бөке-чакмасын.
Хәмер көче житмәс хәсрәтләр бар,
Шуларыннан алла сакласын.

## Чаллы

Яулап алу тиз була ул,
Буйсындыру бара озак.
Мәкерле бер аучы кебек,
һәрбер чатка тезгән тозак.
Син дә кереп каптың, Чаллы,
Күңел әрни шуны сизеп.
Татарлыгың шикле инде —
Үзләштерде... КамАЗ төзеп.

## Сугым вакыты

Китеп торыйм мәллә моннан бүген?
Авыл өсте тоташ кан исе.
Кыерлыйлар гына малкайларны,
Югалтканнар кызгану хисен.
Яшәү мөмкинлеген бүтән төрле
Була алмагач, кешем, ни кылыйм.
Аңласам да, күңел риза түгел,
Күреп йөрүләре әй кыен.
Яшим диеп шулай кылан икән,
Симерт тә суй, имеш, гел малны.
...Үзебез дә, хәер, кем өчендер
Яшәп өлгертәбез лә жанны.
Ул да шулай өзгәләнә микән,
Кызганамы киткәндә алып?
Үз язмышын уйлап куя микән,
Моңсу башын мендәргә салып...

## Җир токтыны

Аңлый алмый гомер үтеп бара:
Нигә күңел шулай ярсына?
Йодрык кадәр йөрәк тынгы бирми,
Бәргәләнә, җирне тарсына.
Яралгысы шунда калганмы соң?
Югарыга таба тартыла.
Талпын дисәң, очып китәрсең күк...
...Такканнар шул — Җирне артына:
Җилтерәтеп кире сөйрәп ала...
Җаның гына китә ахырдан.
Яшәп интегергә хөкем алган
Мәхбүс төсле кеше — бахырҗан...

* * *

Күңел сынып китә кайчакта,
Булсам да бик чыдам, түземле.
Җирдәгеләр кага башласа,
Йолдызлардан эзлим үземне...

* * *

Бер микъдарда шәраб чөмерсәң дә,
Бөтен кеше тигез исермәс.
Җебедем дип телең чишелмәсен,
Айнык утырганнар кичермәс.
Мәхәббәт тә тигез тилертми шул,
Артык каударланма тиктомал.
Син ярсыган чакта бүтән якның
Хисе кузгалмавы ихтимал...

## Үз йолдызым

Минем хуҗам — Кәҗәмөгез!
Язмышымны шул үзгәртә.
Гамәлемне гел күзәтә.
Ялгыштыра, я төзәтә.
Сөенгәнме, көенгәнме,
Аваз салып мин туганда?
Әйтә алмыйм. Үзем бик шат
Өлешемә ул тигәнгә.
Килеп аласын да беләм,
Кадерләп каршы аласын.
Йолдызлар бит кеше түгел,
Ятим итми үз баласын...

## Мөмкин булса

Узган безнең матур кичләр
Йөрер-йөрмәс.
Күңелдәге тойгыларны
Белер-белмәс
Йомшак килеш кулларыңны
Кысар-кысмас.
Сылу чакта билләреңне
Кочар-кочмас.
Теләк барда яннарыңа
Килер-килмәс...
Нигә йөрдек икән шулай
Иләс-миләс?
Инде белдем, без булганбыз
Тиле-миле.
Кайтарып куй шул елларга
Кире мине...

ПУБЛИЦИСТИКА

**Мәдинә Рәхимкулова,**

**Лирон Хәмидуллин**

# УНИВЕРСИТЕТЛАР ҮРНӘГЕНДӘ

Татар мәдрәсәләре тарихы, белгәнебезчә, бик ерактан, Болгар дәүләте чорыннан ук башлана. Россиягә караган дәвердә оешкан иң мәшһүр уку йортларын гына санасаң да зур бер исемлек барлыкка килер иде. Оренбург губернасында унсигезенче гасырдан ук халкыбыз мәдәнияттән һәм мәгърифәтен үстерүгә сизелерлек өлеш керткән Каргалы авылы (Сәет бистәсе) һәм Эстәрлебаш авылы мәдрәсәләрен генә искә алыйк. Каргалыда, мәсәлән, татар, башкорт халыклары тарихында тирән эз калдырган хәрби җитәкче һәм шагыйрь Салават Юлаев (1752—1800), күренекле имам һәм шагыйрьләр Габдерәхим Утыз-Имәни (1754—1834), Әбелмәних Каргалый (1782—1826), һибатулла Сәлиховлар (1794—1867) белем алып чыкканнар. Эстәрлебаш мәдрәсәсендә шулай ук танылган шагыйрьләр һәм җәмәгать хәдимнәре Шәмсетдин Зәки (1825—1865), Гали Чокрый (1826—1889), Мифтахетдин Акмулла (1831—1895) укыган.

Гомумән алганда, татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә генә түгел, Россия империясенең төрле почмакларында да татар зыялылары тарафыннан байтак уку йортлары булдырылган, алар үз милләтебез вәкилләреннән тыш тугандаш төрки халыкларга да хезмәт иткәннәр. Каргалы, Эстәрлебаш яисә Казан ягындагы атаклы Кышкар мәдрәсәсендә тәрбия алып чыккан хәлфә-мөгаллимнәр, илебезнең төрле якларына таралып, яңадан-яңа мәктәп-мәдрәсәләр ачканнар. Анда укучылар соңыннан татар, башкорт, казакъ халыкларының йөзек кашы булырдай шәхесләр — әдип һәм шагыйрьләр, галимнәр, матбугат хезмәткәрләре, инженерлар булып өлгергән. Шунда ук халкыбызның киләчәген кайгыртучы алдынгы карашлы руханилар да гыйлем эстәгәннәр.

Татарның мәгърифәтчел рухлы дин әһелләренең эшчәнлеген бәяләү өчен бу очракта бер генә мисалга тукталасы килә: бүгенге казакъ әдәбиятына һәм язма казакъ теленә нигез салучы акын Абай (Ибраһим) Конанбаев башлангыч белемне Семипалатта яшәгән татар Әхмәт Риза хәзрәт мәдрәсәсендә алган. Узган гасырларда башка тугандаш милләт вәкилләреннән дә байтак кына мәгълүм шәхесләрнең зыялыларыбыз тарафыннан укытылып, татар мәдрәсәләре шәкертләре төркеменнән чыкканлыкларын беләбез. Унтугызынчы гасырның икенче яртысын Казан, Оренбург, Уфа мәдрәсәләренең элек дан тоткан Бохара, Сәмәрканд кебек мәгариф үзәкләре белән ярышка чыккан һәм, заманча тәрбия бирүгә юнәлеш тотулары нәтиҗәсендә, бик абруйлы саналган шушы кадими белем үзәкләрен артка калдыра башлаган дәвер дип карарга кирәктер.

Менә шушындый алдынгы уку йортларының берсе сыйфатында унтугызынчы гасыр азакларында Оренбург шәһәрендә «Хөсәения» мәдрәсәсе калкып чыккан һәм, әйтергә кирәк, тиз арада шөһрәт тә казанып өлгергән.

Җәдитчә белем бирүче мәдрәсәләрнең һәрберсендә диярлек, дин белеменнән тыш, ислах таләп иткәнчә, дөньяви фән-гыйлем бирүгә дә юнәлеш тотыла, география, гомуми тарих, хисап, алгебра, физика, химия һ. б. дәресләр кертеләләр. Бу җәһәттән бигрәк тә бай сәүдәгәрләр — Оренбургтагы Хөсәеновларның «Хөсәения», Троицкидагы Яушевларның «Мөхәммәдия» мәдрәсәләре уңай

якка аерылып торганнар, аларда аерым-аерым фәннәр буенча бай җиһазланган кабинетлар да оештырылган.

Мәҗит Гафури 1898 елның көзендә Троицк шәһәрендә Яушевларның «Мөхәммәдия»се белән танышуын болай тасвирлый: «Мәктәпкә барып керү белән миндә бертөрле гаҗәпсенү туды, аның моңарчы үзем күргән мәктәп-мәдрәсәләргә караганда башка икәнен күрдем. Ишектән керү белән бераү мине туктатып ни өчен килгәнемне сорады... чабатамны чишенергә кушты. «Шәкертләр теге бүлмәдә сабак алалар»,— дигәч, коридор буйлап шунда киттем. Уңга карасам — андагы бүлмә карават белән тулган. Һәммәсенең дә өсте ап-ак нәрсә белән ябылган. Бүлмә бик таза һәм матур. Сул яктагы бүлмәдә — озын өстәл, аның тирәсенә урындыклар тезелгән. Өстенә тәрилкә, кашыклар куелган. Хәлфә дәрес биргән бүлмәне акрын гына ачып кердем дә арттагы буш партаның бер як читенә утырдым... Шәкертләр һәммәсе дә бер төсле киенгәннәр. Стенага ашъяулык зурлыгындагы төсле буяулы кәгазь (географик карта) эленгән. Кыскасы, бу мәктәптә моңарчы мин күрмәгән яңалык һәм башка төрле тәртип күренеп тора. Мин монда укучы шәкертләрнең бәхетенә кызыктым... Үземнең өстемә кигән җиләнемне, башымдагы мескен бүрекне, билемә бәйләгән кызыл башлы тастымалны боларның киемнәренә чагыштырып, уңайсызланып калдым...»

Күренә ки, байтак татар мәктәп-мәдрәсәләреннән аермалы буларак, монда шәкертләр таза тормыш шартларында яши һәм укыйлар: мәдрәсә җитәкчеләре аларны уку кирәк-яраклары белән дә, кием-салым һәм яшәү шартлары белән дә тулаем тәэмин иткәннәр. Монда заманча җиһазлы уку классларыннан тыш йокы, ашау-эчү бүлмәләре дә булдырылган. Әлбәттә, мондый уку йортларының чыгымы зур, шунлыктан андыйларның саны да чагыштырмача аз. Ул вакытта татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен патша хөкүмәте бер тиен дә тотмыйча, киресенчә, аларны өзлексез эзәрлекләп торуы гына мәгълүм.

Оренбург шәһәрендә мәшһүр миллионер-сәүдәгәрләр, абыйлы-энеле Хөсәеновлар тарафыннан 1889 елда ачылган «Хөсәения» мәдрәсәсе дә уку-укыту тәртипләре буенча М. Гафури истәлекләрендә китерелгән шартларга туры килә. «Хөсәения»дә дә укулар, башлыча, түләүсез оештырылган була: уку кирәк-яраклары, ашау-эчү, кием-салым — бөтенесе дә өлеге байлар хисабыннан.

«Хөсәения» мәдрәсәсенең чагыштырмача кыска вакытта татар, башкортлардан тыш Казагыстан, Урта Азия һәм Кавказ халыклары арасында да абруй казануының төп сәбәбе шушылар һәм, әлбәттә, заман таләпләренә җавап бирердәй рәвештә укыту булган. Чөнки беренче көннән үк «Хөсәения» мәдрәсәсе төп максат итеп алдынгы карашлы мөгаллим һәм галим-белгечләр әзерләү юнәлешен ала. Башка мәдрәсәләрдән аермалы буларак, мулла-мәзиннәр биредән бик аз чыгалар. Мондый фактны иске караштагы зыялыларыбызның бер ише, зур гонаһка исәпләп, патша җәнабларына, Синод әһелләренә һәм Диния нәзарәтенә кат-кат язып, әләкләп торалар: имештер, «Хөсәения» мәдрәсәсе, чынлыкта мөселман кануннарын алга сөрүче уку йорты түгел, аның йөз шәкертеннән нибары сигез-уны гына мулла-мәзин булып китәргә әзерләнә.

Бу «гаепләүләр»дә, әлбәттә, дөреслек бар: «Хөсәения» үз заманында иң алдынгы карашлы, Европача фикер йөртүче шәхесләр тәрбияләүгә йөз тота. Мәсәлән, тарихчы Зәки Вәлиди, Сәгыйть Рәмиев, Ильясбәк Кудашев-Ашкадарский, Мирхәйдәр Фәйзи, Афзал Таһиров, Шамил Усманов, Шәехзадә Бабич, Кәрим Хәкимов һәм башка бик күп язучылар, җәмәгать эшлеклеләре, илчеләр — шушы мәдрәсә шәкертләре.

Һәр елны мәдрәсәне уңышлы тәмамлаган берничә шәкерт миллионер Хөсәеновлар билгеләгән стипендия исәбенә чит илләргә китеп укуларын дәвам иттергәннәр. Алар арасында Истанбул, Каһирә, Дәмәшкъ, Бәйрут кебек мөселман дөньясында мәгълүм уку үзәкләреннән тыш Россия, Франция, Бельгия университетлары һәм институтларында укып, Европача белем үстерүчеләр дә булган. Шунлыктан бу мәдрәсәне тәгәлләүчеләр арасында физика, математика, химия кебек төгәл фәннәрне тирәнтен үзләштерүчеләр дә, медицина белгечләре сайлаучылар да байтак.

Оренбург шәһәре үзе дә унтугызынчы, егерменче гасырларда татар дөньясында үзенә күрә бер мәгърифәт һәм мәдәният үзәге буларак танылган. Бу җәһәттән ул фәкать Казаннан гына калыша. Хәер, Оренбург каласының барлыкка килүе дә Казанга бәйле. Россиянең көнчыгышка үтеп керүе һәм элекке Казан губернасы чикләренең Уралның көнчыгыш тарафларына җәелүе нәтиҗәсендә Казан губернасын икегә бүлү хаҗәте туа. Һәм Анна Иоанновна патшалык

иткән унсигезенче гасырның утызынчы елларында Оренбург шәһәренә нигез салу һәм яңа губерна булдыру хакында указ чыга. Губернаны оештыру һәм яңа башкала урынын сайлау вазифасы сенатның обер-секретаре И. К. Кириллов җитәкчелегендәге вәкаләтле комиссиягә тапшырыла. Бу комиссиягә тарих һәм география белгечләре галимнәр В. Н. Татищев белән П. И. Рычков та керә. Ә хәрбиләрдән милләттәшебез полковник (берничә елдан соң генерал) Котлымөхәммәт Тәфкилев (1675—1766) тә була. Чөнки бу комиссиягә туплар белән көчәйтелгән ике укчы полк, төрки-татар солдатларыннан торган тулы булмаган бер полк һәм өч йөз илле атлы казактан гыйбарәт гаскәр дә беркетелә. Бу гаскәр җир бүлү эшләреннән башлап, булачак шәһәргә нигез ташын салырга да, моңа комачау итәргә ниятләгән җирле халыкка карата «чапкын чабарга» да тиеш булган. Тәфкилевнең Оренбург губернасын оештыруда катнашуы моның белән генә дә чикләнми, билгеле. Патша хөкүмәте аны биләмәләре Урал суының көнчыгыш ярыннан башланган казакъ хан-солтаннары белән элемтә урнаштыруда һәм аларны Россиягә кушылырга үгетләүдә дә оста куллана.

Оренбург шәһәренә нигез ташы 1743 елның апрель урталарында салына. Бу вакытта инде экспедиция белән элек берничә ел Төркиядә илче булып торган, җирле халыкларның телен һәм гореф-гадәтләрен яхшы ук белгән бик усал сәясәтче И. И. Неплюев җитәкчелек итә. Яңа каланы төзү өчен солдатлардан тыш меңәрләгән татар, башкорт крестьяннары да куып китерелә. Бер үк вакытта экспедициянең хисапчы хезмәтен дә башкарган П. И. Рычков: «Бу кешеләрнең ашатылуы солдатча иде, көненә икешәр тиеннән эш хакы түләнде».— дип белдерә. Шул ук галимнең тасвирлавынча, Оренбург крепосте элекке нугай ханнары биләмәсенең бер почмагында, нугайларның Актүбә каласы урынына салына. Актүбә каласы исә Явыз Иван яулап алганчы, Басман хан биләмәсе булган. Хан сугыш кырында һәлак булганнан соң бу каланың каберлегенә кайтарып җирләнгән. Оренбургка нигез салганда бу каберлек бар иде әле, дип яза галим.

«Хөсәения» мәдрәсәсенә нигез салучы бертуган Хөсәеновлар тумышлары белән — Оренбургның Каргалы бистәсеннән. Гади авыллардан зур булганлыктан һәм кайчандыр «Сеет бистәсе» дип нигезләнгәнлектән, аны шулай «бистә» дип тә, «шәһәр» дип тә атау гамәлгә кергән. Бу авыл үзәгендәге бай йортутарлар, шәһәр җирендәгечә, икешәр катлы итеп салынганнар, мәчет һәм кибетләр, өйләрнең аскы өлешләре зур-зур итеп тау ташыннан күтәрелгәннәр һәм каладагы биналардан аларның һич кенә ким урыннары юк. Күккә ашкан мәчет манаралары да шәһәр күренешен хәтерләтә. Егерменче гасыр башларында Каргалыда ун мең чамасы кеше яшәгән. Авылда унбер мәхәллә булган. Шагыйрь Ишнияз бине Ширниязның атаклы мәдрәсәсеннән тыш монда берничә мәктәп-мәдрәсә, шул исәптән хатын-кыз мөгаллимәләр әзерләүче мәктәп тә эшләп килгән.

Губерна эшен җайга салу өчен башлыча Казан каласы чиновниклары күчерелгән булса, җирле халыклар арасындагы алыш-бирешне һәм Урта Азия сәүдәгәрләре белән элемтәне җайга салу өчен исә Каргалы авылына ике йөзләп татар гаиләсенең күчереп утыртылуы мәгълүм. Алар, нигездә, Чистай, Мамадыш өязләренә караган авыл сәүдәгәрләре булганнар. Атаклы миллионер Хөсәеновларның Каргалыга барып төпләнүче бабалары Иманкол Мамадыш өязе Кибәхуҗа авылыннан була. Иманкол варисларының шәҗәрә тезмәсе болай килә — Габдрахман — Гобәйдулла — Хөсәен — Гали...

Бөлгенлеккә төшкән сәүдәгәр Гали Хөсәеновның өч улы — беренче хатыныннан туган Әхмәт (1837—1906) белән Мәхмүт (1839—1910), икенче хатыныннан туган Гани (1839—1902) ятимлектә үсәләр. Аталары үлгәндә, аларның иң өлкәнә Әхмәт тә малайлыкка ялланып көн күрерлек яшьтә генә була. Беләкләре бераз ныгый төшкәч, ул мәстәкыйльлеккә чыга — яз айларында күпләп йомран тота да шуларның тиреләрен сата, җәй көннәрендә балчык базында, сатуга дип, кирпеч суга. Кыр, дала буйлап йомран аулап тамак туйдырган көннәрен онытмасын дигәндәй, авылдашлары аңа «йомран» кушаматы тагалар. Әхмәт исә, шул рәвешчә тырышып, үз сәүдәсен башлап җибәрердәй мая туплый. Бертуган Хөсәеновларның тиенне тиенгә куша барып, мал-мөлкәтләрен уңга-сулга исраф итмичә эш йөртүләре мәгълүм. Әмма иң гаҗәбе шунда, болар үзләре баер өчен генә түгел, башкалар да шундый ук мөмкинлекләргә ирешсен, дип тырышалар, миллионнарының байтак өлешен халык ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен тоталар. Хөсәеновлар төп максатларын мәктәп-мәдрәсәләр ачуда һәм аларда мөгаллим һәм хәлфәләр булдыруда күрәләр. Шулай ук үзләре

яшәгән төбәктә Казан якларында дан тоткан «Иж-Буби», «Мөхәммәдия»ләр ише зур бер мәдрәсә ачуны, анда заманча итеп укыту мөмкинлекләре тудыруны үз бурычлары саныйлар. Моннан да изге максатның булуы мөмкинме?! Беренче гильдия сәүдәгәрләр Хөсәеновларның шушы изге максат өчен нәрсәләр кылганлыгына күз салыйк. Әхмәт һәм Мәхмүт байлар унтугызынчы гасырның соңгы чирегендә Казан төбәгендә генә дә егерме мәчет һәм мәдрәсә, мәктәп ачалар. Шәһәр, авыл мәчет-мәдрәсәләренә алдынгы карашлы мулла һәм мөгаллимнәрне туплап, аларга еллык хезмәт хакын түләп баралар.

Оренбург өлкәсенең дәүләт архивында Казанның 5 мәхәлләсе каршындагы мәктәп укытучысының Хөсәеновлардан эш хакы алуына распискасы саклана. Хөсәеновлар җәмгысе кырыклап мөгаллимгә эш хакы түләп торганнар, ике йөзләп мәктәп һәм мәдрәсәне уку-укыту әсбаплары белән тәэмин иткәннәр, аларның биналарын төзекләндерү максатында да ярдәм булдырганнар.

Алар шулай ук Эрбет, Мәкәрҗә ярминкәләрендә, Урта Азиянең Сәмәрканд, Коканд шәһәрләрендә һәм хәтта ислам дине үзәге Мәккәдә дә мәчет һәм мәдрәсәләр ачканнар. Үз хисапларына Россиянең һәм Европаның мәшһүр уку йортларында белем алучы студентларны укытуны да үзләре өчен бик саваплы бурыч санаганнар. Һәр елны берничә сәләтле егет алар билгеләнгән стипендия хисабына Петербург, Мәскәү, Саратов, Томск, Каһирә, Бәйрүт, Истанбул югары уку йортларына укырга җибәрелгән.

Әхмәт һәм Мәхмүт байлар төзелеш эшләренә генә дә йөз меңнән артык акча тотканнар. Дала ягы авылларына нарат бүрәнәләре бик ерактан китерелгән. Мәчет, мәдрәсә биналарын исә алар башлыча нарат бүрәнәләрдән генә салдырганнар, табигый таш булган урыннарда гына төзелеш шул таштан башкарылган.

Габделгани бай Хөсәенов мал-мөлкәтен ике туганыннан аерып эш йөртә. Мондый мәгариф-мәдәният учакларын ачуга Габделгани бай утыз мең сум күләмендә башлангыч чыгым билгели. Ул 1898 елда Каргалы авылында, Истанбул университетын тәмамлап кайткан галим һәм язучы Фатих Кәрими ярдәмендә, авыл мөгаллимнәренең белемен күтәрүгә ният тоткан берьеллык мәктәп-курслар ача. Бу мәктәп Каргалының Әюбхан Ибраһим хәзрәт мәхәлләсендә ачыла. Анда һәр елны җәдитчә укыту ысулларын йөзгә якын мөгаллим үзләштерә. Бу мәктәптә укырга дип шәкертләр Россиянең төрле почмакларыннан, шул исәптән, хәзерге Казагыстан һәм Төньяк Кавказ, Әстерхан төбәкләреннән дә киләләр. Соңыннан милли әдәбият һәм сәнгатебез дөньясында зур галим булып танылган профессор Габдрахман Сәгъдинең шушы мәктәптә белем эстәп чыгуын да әйтеп үтү урынлы булыр.

Моннан тыш шул ук Каргалы авылында авыл мөгаллимнәре әзерләүче кызлар мәктәбе дә эшли башлый. Гани бай бу мәктәпне оештыручы җитәкче итеп шушы төбәкнең иң алдынгы карашлы кешеләреннән саналган шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Дәрдемәнднең хатыны Мәһүбә ханым Рәмиеваны билгели.

Гани бай 1901 елда Оренбург шәһәрендә Мәһүбә ханым һәм башкалар ярдәмендә сигез сыйныфлы үрнәк кызлар мәктәбе оештыра. Бу мәктәпнең уку программасы рус кызлар гимназиясе тәртип-программаларына якын була. Шунлыктан аны Октябрь революциясеннән соң да ябмыйлар. Җитәкчесе мөгаллимә Фатыйма Әдһәмова исемендә, «Адамова мәктәбе» буларак, ул 1925 елга кадәр эшли. Бу мәктәпне байтак кына күренекле хатын-кызларыбыз тәмамлап чыгалар. Алар арасында мәктәп мөдире Фатыйма абыстайның ике кызы да була. Соңыннан алар үзләре дә бу мәктәпнең абруйлы укытучылары булып җитешәләр: Хәдичә — географиядән, ә Зәйнәп рус теленнән укыта. Монда белем алган Багбостан Моэминова исә, соңыннан «Багбостания» кызлар мәктәбен оештырып, милли мәгърифәтчелек өлкәсендә абруй казана.

Шулай итеп, бертуган Хөсәеновлар узган гасырның җитмешенче-сиксәненче елларыннан башлап революциягә кадәр Казан, Оренбург, Уфа, Самара губерналарында һәм башка шәһәрләрдә алтмышлап мәктәп һәм мәдрәсә булдырганнар. Алар тарафыннан уку-укыту әсбаплары белән тәэмин ителгән мондый уку йортларының саны исә ике йөзгә якынлаша. Кайбер белем учаклары, шул исәптән «Хөсәения» мәдрәсәсе дә ярлырак шәкертләр өчен бушлай укуга көйләнгән. Алар, ашау һәм интернатта түләүсез яшәүдән тыш, хәтта ос киемнәре белән дә тәэмин ителгәннәр. Бу льготалар ярлылар өчен генә түгел, ерактан килеп укучылар өчен дә, фәннәрне яхшы үзләштерүчеләр өчен дә каралган була. Шәкертләрнең ос киемнәре — кара тостәгә затлы постаудан

тегелгән утыртма якалы күзәки һәм чалбар, ак күлмәк — реаль училищеларда укучылар киеменә тартымрак була. Башларында — татар кәләпүше.

Элекке еллар матбугатында Хөсәеновлар «бакчасы»на байтак кына кара ташлар ыргытылды. Янәсе, мәктәп-мәдрәсәләрне алар байлыкларын киләчәктә ишәйтү ниятеннән чыгып кына төзегәннәр. Имеш, алар мәчет салу белән күбрәк мавыкканнар, мәктәп-мәдрәсәләр оештыру белән түгел. «Хөсәения» мәдрәсәсе утарына да иң әүвәл таш мәчет утыртып куйганнар...

Безнең карашыбызча, Хөсәеновлар, әлбәттә, диндарлыкның югары дәрәҗәсендә үк тормаслар да, динне һәм дини йолаларны хөрмәт иткәннәр. Билгеле, Мәкәрҗәдә, яисә үзләренең сәүдә багланышлары булган Бохара, Коканд, Сәмәрканд төбәкләрендә мәчет торгызганда алар, ислам дине кануннарына буйсыну белән беррәттән, сәүдә эшләренең барышын күпмедер дәрәҗәдә яхшыртуны да истә тотканнардыр. Эшлекле кешегә андый сыйфатлар һәм күрәзәчелек тә хас, моны инкяр итеп булмый. Ләкин «халыкны талап җыйган миллионнарын кая куярга белмәгәнлектән генә мәчетләр торгызуга тотканнар», дигән фикер белән килешәсе килми. Алар байлыкны башлыча «халыкны эксплуатацияләп» түгел, ерак Азия белән Европа базар мөнәсәбәтләренең үзенчәлекләреннән чыгып таба белгәннәр.

Хөсәеновларның дини кануннарга гына таянып эш итмәгәнлекләренә дәлилләр җитәрлек китереп булыр иде. Ә ник соң алайса алар авыл саен үз мәчетләрен булдырырга тырышканнар? Аллаһы тәгалә каршында, дин әһелләре алдында аклану өченме? Юк. Заман таләбе, әхлакый нормалар шундый булган. Патша законнары, Изге Синод дип исемләнгән югары дини оешма таләбе һәм карарлары Рәсәйдә яшәүче барлык халыклар өчен, шул исәптән, мөселман динендәгеләр өчен дә берсүзсез үтәлергә тиешле саналган. Бу кануннарда нигезендә дини һәм дөньяви эшләр бер-берсеннән аерылгысыз булганнар. Кешенең рухи халәтенә йогынты ясаучы ике мөстәкыйль юнәлеш — белем бирү өлкәсе белән дин шушы кануннар нигезендә бер-берсенә беркетелеп куелган, барлык башлангыч уку йортлары (мәктәп, мәдрәсәләр) фәкать чиркәү һәм мәчетләр карамагында гына яшәргә хокуклы саналган.

Менә нигә Хөсәеновлар, берәр авылда кечерәк кенә мәктәп ачарга уйласалар да, анда иң әүвәл мәчеткә нигез салырга тиеш булганнар. Нәкъ менә шушы сәбәпләр аркасында гына да безгә кардәш казакъ авылларында даими эшләүче мәктәп-мәдрәсәләр булмаган диярлек. Авылның мәчете юк икән — мәктәбе дә була алмый. Мәчетне исә, күчеп йөргәнлектән, салмаганнар алар.

Үзләре исән вакытта бертуган Хөсәеновлар да, аларның варислары да берничә мәртәбә патша хөкүмәтенә һәм Синодка мөрәҗәгать иткәннәр: әгәр безгә, мәчет салмыйча гына, мәктәп һәм мәдрәсәләр ачарга рөхсәт бирсәгез, шул ук чыгымнар белән, халкыбызны аң-белемле итү эшенә, бермә-бер күбрәк өлеш кертә алыр идек, дигәннәр. Ләкин патша хөкүмәте аларның бу изге максатын хупламаган, һәрвакыт тискәре җавап килгән.

Мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеккә хиреслек Хөсәеновларга ничек йоккан соң? Бердән, ул «начар» заманнарда халыктан чыккан байларга һәм зыялыларга үзләрен тудырган миллләт файдасына берәр савaплы эш башкару гомумән хас булган. Халык өчен китапханә, театр, музей тотучылар яисә Җәмгыяте хәйрияләргә акча күчерүчеләр русларда гына түгел, бездә дә күп булган. Татарда, әйтик, фабрикант Акчуриннар төрки-татар телендә беренче булып басыла башлаган һәм халык арасында киң рәвештә таралган «Тәрҗеман» газетасына байтак кына матди ярдәм итеп килгәннәр. Моны алар, билгеле инде, газетаның оештыручысы һәм мөхәррире Кырым морзасы Исмәгыйль Гаспралының соңыннан үзләренә кияү булганлыгы өчен генә түгел, беренче нәүбәттә милләтне агарту, аң-белемле итү ниятеннән чыгып эшләгәннәр. Алтын приискасы хуҗалары бертуган Рәмиевләрнең дә татар телендә матбугат булдыруга, туган телебездә бастырылып таратылган китапларга тоткан һәм шулай ук уку-укыту эшләренә керткән өлешләре — өнә шул изге нияттән чыккан.

Бу җәһәттән Әхмәт бай Хөсәеновка бәйле истәлек-хатирәләр бик гыйбрәтле. Ул юкка-барга акча исраф итүне бер дә өнәмәгән. Тормышта үзе бик тыйнак яшәгән. Юл йөргәндә дә еш кына икенче класс вагоннарына билет ала икән һәм моңа гаҗәпләнүчеләргә, «Голәмәдән аерым булуны яратмыйм»,— дип әйтә торган булган.

Аның җәдитчә укытуга йөз тоткан мәктәп һәм мәдрәсәләр ачуга булган хиреслеген замандашлары Әхмәт байның үз язмышына бәйләп аңлаталар. Әхмәт бай үзе, алда тасвир ителгән сәбәпләр аркасында, тотрыклы белем ала алмаган: иске гореф-гадәтләргә нигезләнгән авыл мәдрәсәсенең нибары дүрт

сыйныфын тәмамлаган. Әмма белемнең сай булуын бик тиз аңлаган һәм: «Яшьләребез аңлы, белемле булып җитешсен өчен безгә яңача укыту ысулларына тизрәк күчү зарур...» — дигән төпле бер карарга килгән. Әхмәт бай Хөсәенов әйтә торган булган: «Сәүдә мирасымны биш сумнан башлап дүрт миллионга җиткерә алганмын икән, димәк, барып чыккан бер ахмак түгелмен. Ә инде дүрт кыш укып та язарга өйрәнә алмавым — иске мәдрәсә кимчелегеннән килә, шунлыктан без җәдитчә укытуны алга сөрәбез!»

Сәүдәгәр Хөсәеновлар васыятьләрендә дә, шушы изге максатка тоту өчен, бик зур мирас калдыралар. Шул акчага алар варисларына яңадан-яңа мәктәпләр ачарга кушып калдыралар, үзләре өчен саваплы дип саналган бу юлдан тайпылмауларын үтенәләр. Әхмәт бай Хөсәенов белән туганы Мөхмүт бай шушы максатка тоту өчен ярты миллион чамасы мирас билгелиләр. Шуңардан Казандагы «Мөхәммәдия» һәм Уфадагы «Госмания» мәдрәсәләренә өчәр мең сум, Оренбургтагы Җәмгыяте хәйриянең «Белек» бүлекчәсенә егерме биш мең сум күчерелә. Әхмәт бай вафат булгач 1906 елда ук «Белек» җәмгыяте, башка байлардан җыелган акчаны да кушып, Оренбург шәһәрендә йорт алып, зур гына китапханә ача. Аңа күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм мәгърифәтче Исмәгыйль Гаспралы исеме бирелә. Революция көннәрендә Хөсәен Ямашев исеме белән аталган бу бай китапханә бүген дә өлкә шәһәрендә яшәүче татар-башкорт укучыларына хезмәт итеп килә.

Моннан тыш Әхмәт һәм Мөхмүт бай варислары алда телгә алынган кызлар мәктәбе «Багбостания»не ачуга да өлеш кертәләр. Мәктәп ябылганчы (революциядән соң), аның мөгаллимнәренә эш хакын түләп торалар, барлык сыйныфларда укучы кыз балаларга ел саен ос киемнәре тектерелә. Бу мәктәп каршында ел саен авыл мөгаллимнәренең белемен күтәрү курслары эшли, шушы максат өчен генә дә Хөсәеновлар тарафыннан ун мең сум бүлеп бирелгән була.

Әхмәт һәм Мөхмүт Хөсәеновларның варислары 1910 елда Каргалыда да заманча белем бирүче «Мөхәррәмия» дигән үрнәк кызлар мәктәбе ачалар. Әлеге уку йортында кызларга гомуми белем бирүдән тыш тегү, чигү, бәйләүгә өйрәтү дә яхшы оештырылган була.

Шунысы да әһәмиятле, «Багбостания» белән «Мөхәррәмия» мәктәпләренә тотылган байтак чыгымнар өлкән Хөсәеновлар васыятьнамәсендә каралмаган була, боларын аларның балалары, аталары тоткан юлга тугры булуларын исбатлап, үзләре бирә. Бу җәһәттән сәүдәгәр Хөсәеновларның васыятьләрен үтәүдә аеруча тугрылыклы булып калган Шәрәфетдин Мөхмүт улы Хөсәеновны телгә алу кирәктер. Атасы Мөхмүт бай вафатыннан соң «Хөсәения» белән җитәкчелек итү дә аңа йөкләтелә.

Габделгани байның да балалары аталары билгеләгән юлдан тайпылмыйлар диярлек. Мәктәп һәм мәдрәсәләргә даими рәвештә матди ярдәм итү өстенә, алар да мәгърифәтчелек һәм мәдәният өлкәсенә үз өлешләрен кертәләр. Оренбург шәһәрендә «Хөсәения» мәдрәсәсеннән тыш даны икенче урында булган «Вәлия»не оештыручы һәм тотучы — Гани байның олы улы Мөхәммәтвәли мулла. Татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимов некъ менә шушы «Вәли мулла мәдрәсәсе»ндә җиде-сигез ел белем ала. Соңыннан мәдрәсәнең эчке тәртипләренә карата беркадәр тәнкыйди караштә торса да, алган белеменнән һич зарланмый.

Әйтергә кирәк, көндәлек татар матбугатында иске гореф-гадәтләргә мөкиббәнрәк булганлыгы өчен ярыйсы ук тәнкыйтьләнгән «Дин вә мәгыйшәт» (1906—1918 елларда Оренбургта нәшер ителә) журналының башында торучы да — Мөхәммәтвәли мулла Хөсәенов. Бу журнал аның тарафыннан оештырыла һәм 1918 елга чаклы аның акчасына нәшер ителә.

Гани байның икенче улы Газиз Хөсәенов байтак еллар Оренбург губернасында мөселманнар Җәмгыяте хәйриясенә җитәкчелек итә, шул исәптән атасыннан калган мирасның да бер өлешен шушы җәмгыять ихтыяҗларына даими күчереп тора.

Байның өченче улы Хәмит Хөсәенов «Хөсәения» мәдрәсәсенең идарәче байлары белән берлектә байтак эш башкара, атасы мирасына ачылган авыл мәктәп-мәдрәсәләре тормышында якыннан торып катнаша.

Көндәлек сөйләмдә «Идарәче байлар һәм зыялылар» дип, документларда «Попечительләр Советы» дип теркәлгән идарә, «Хөсәения» мәдрәсәсе эшләреннән тыш, шәһәрдән читтәге мәктәп-мәдрәсәләр белән дә элемтәдә тора һәм күпмедер дәрәҗәдә аларга булышлык күрсәтә. Әхмәт бай васыятьнамәсендә шушы идарәгә караган чыгымнарны каплау кирәклеге дә истә тотыла. Моннан

тыш бу документта дәреслекләр һәм кулланмалар бастырып чыгару өчен һәр елны биш йөз сум акча бүлеп бирү карала.

Татар яшьләренә Россиядәге һәм чит илләрдәге югары уку йортларында белем алу өчен дә Хөсәеновлар шартлар булдырганнар иде. Әхмәт бай васыятьнамәсендә табиб һәм инженер һөнәрләрен үзләштерергә омтылучы яшьләр өчен дә чит-ят дөньяда яшәп укырдай күләмдә стипендия түләү планлаштырылган була. Россия гимназияләренә, реаль училищеларына, коммерция мәктәпләренә кереп укучылар өчен дә өстәмә кызыксындыру чаралары каралган була. Әлбәттә, мондый стипендияләр беренче чиратта «Хөсәения» мәдрәсәсен уңышлы тәмамлаучыларга һәм Хөсәеновлар ярдәмендә ачылган мәктәп-мәдрәсәләрнең чыгарылыш сыйныфлары укучыларына бирелә. Аларны билгеләү һәм бүлү исә күмәк рәвештә, алда телгә алынган Идарә утырышларында уздырылган.

Әхмәт Хөсәенов васыятен үтәү аның үлеменнән соңгы беренче елларда энесе Мөхмүт бай өстендә була. Мөхмүт Хөсәенов үзе вафат булганчы — 1910 елга кадәр — абыйсы йөкләп калдырган бурычларны тулысынча үтәп килә. Ә үзенең үлеменнән соң бу эшне уларына — Шәрәфетдин белән Хөсәенгә тапшыра.

Мәгълүм булганча, бертуган Хөсәеновлар мәгърифәтчелек өлкәсендә башкарган олы эшләрнең иң мөһиме, әлбәттә, «Хөсәения» мәдрәсәсе белән бәйле. Милләтебезгә утыз елдан артык армый-талмый хезмәт иткән бу уку йорты иң зур ихтирамга лаек. Татар дөньясы бу мәдрәсәдә белем алган шәкертләре хисабына гына да күпсанлы олуг шәхесләргә баеды. Үз халкына фидаиларча хезмәт иткән бу шәхесләрнең исемнәрен санап чыгу өчен генә дә аерым бер китап язу кирәк булыр иде. Өстәвенә, «Хөсәения»дә татар һәм башкорт яшьләре генә түгел, казакъ, үзбәк, кыргыз, каракалпак, карачай, нугай һәм башка тугандаш төрки халыкларның вәкилләре дә белем алганнар.

«Хөсәения» мәдрәсәсенең мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеге совет власте елларында да әзелмәде: шул нигездә яңа төр институтлар оешты, аның хәлфә-мөгаллимнәре халкыбызны аң-белемгә өндәү эшләрен яңа дәвердә дә дәвам иттеләр. Дөрес, соңыннан мәдрәсә тарихына кырын караучылар яисә аның әһәмиятен кечерәйтеп күрсәтергә омтылучылар булды. Әмма СССР Министрлар Советы тарафыннан чыгарылып килгән рәсми документларда бу уку йортының әһәмияте инкяр ителмәде, «Хөсәения» мәдрәсәсен тәгәлләүчеләр, белем дәрәҗәсе буенча, совет чорының Укытучылар әзерләүче институтларын тәмамлаучылар белән тиң белемле дип расланды. Бу карарда «Хөсәения» белән берләттән Казандагы «Мөхәммәдия» һәм Уфадагы «Галия» мәдрәсәләре дә күрсәтелгән иде.

* * *

Оренбург каласында «Хөсәения»гә кадәр дә рәсми һәм рәсми булмаган мәктәп-мәдрәсәләр, татар-башкорт яшьләренә белем бирердәй уку йортлары булган. Бу бәхәссез, чөнки Уфага күчерелгәнче үк Идел-Урал буе һәм Себер төбәге мөселманнарының Диния нәзарәте нәкъ менә Оренбургта оеша башлый, шул хәл монда яңадан-яңа мәчетләр ачылуга этәргеч була. Ә беркадәр соңрак биредә, патша хөкүмәте рөхсәте белән, Оренбург генерал-губернаторы Перовскийның башкорт-татар гаскәрләре каһарманлыгын «исәпкә алуы» нәтиҗәсендә Кәрвансарай мәчете төзелә башлый. Бүген дә шәһәр архитектурасының горурлыгы саналган шушы мәчет каршында мәдрәсә дә оеша. Тиздән ул хәтта Каргалы авылындагы атаклы мәдрәсә белән «ярышу» дәрәҗәсенә күтәрелә. Татар мәдәнияте күгендә якты эз калдырган, әмма иҗаты бүгенге көн укучысына аз мәгълүм булган шәхесләрдән әдәбиятчы һәм тарихчы Габделбарый Батталовның әнә шушы Кәрвансарай мәдрәсәсе шәкерте саналганлыгын да искәртик.

«Хөсәения»нең тууына һәм аның киләчәктә тотачак юнәлеш-программасына күпмедер дәрәҗәдә Оренбургтагы башка уку йортлары да йогынты ясаганнар. Бигрәк тә ул уку йортларының җирле халыктан хәрби хезмәткәрләр һәм патша идарәчелеге өчен чиновниклар тәрбияләүгә юнәлеш тотканнары һәм аларда эшләгән татар укытучылары бу җәһәттән булачак мәдрәсәнең «өлгесен» төзүдә зур эш башкарганнар. Мәсәлән, И. И. Неплюев исемендәге хәрби училищеда («кадетлар мәктәбе» дип тә йөртелгән) «туземец»лардан гаскәри кадрлар әзерләп чыгарыла. Шуңа күрә биредә татар һәм башка көнчыгыш телләрен

укытуга да җитди әһәмият бирелә. Нәкъ менә шушы уку йортында Иванов һәм Кукляшевларның татар теле дәреслекләре һәм сүзлекләре төзелә.

Бу чорда Оренбургта шулай ук рус-татар, рус-казакъ казна мәктәпләре дә ачылалар. Җирле халыкларны руслаштыру сәясәтеннән чыгып, патша хөкүмәте империянең көнчыгыш губерналарында һәм Себер, Урта Азия шәһәрләрендә өч һәм бишьеллык мондый мәктәпләрне күпләп ачарга тырыша. Алда әйтелгәнчә, унтугызынчы гасыр урталарында Оренбургта шундый ике мәктәп эшли башлый. Аңа да милли тел һәм гореф-гадәтләрне азмы-күпме белгән укытучылар тупланалар.

1759 елда Казанда ачылган Беренче гимназиянең дә Оренбург төбәгендә яшәүче татарлар тормышына йогынтысы зур була. Билгеле, казна мәктәпләренә дә, бу гимназиягә дә, башлыча, элек-электән патшага тугры хезмәт иткән морза, бәк, төрле гаскәри чин балалары тупланалар. Аларның уку чыгымнары халыктан өстәмә түләтелгән салымнар хисабына каплана, ә бу укучылар «губерна стипендиатлары» булып исәпләнә.

Унтугызынчы гасырның икенче яртысында исә татар-башкорт казна һәм гаскәри мәктәпләре өчен укытучылар тәрбияләү максатында Оренбург укытучылар мәктәбе («учительская школа») ачыла. Бу мәктәпкә керү өчен әүвәл аның каршындагы бер еллык әзерлек курсларына кабул ителүчеләр татар теленнән һәм арифметикадан имтихан тотканнар. Аңа татар мәдрәсәләрендә башлангыч белем алган, унбиш яшьтән дә яшь булмаган үсмерләр алынган. Бу мәктәптә ислам диненә бәйләнешле дәресләрдән кала барлык фәннәр русча укытылсалар да, шәһәр төбәгендәге милли мәктәп һәм мәдрәсәләр өчен аның ачылуы, әлбәттә, бик әһәмиятле була.

Шушы уку йортын бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаганнан соң шунда ук укытырга дип калдырылган Гайса морза Еникеев «Хөсәения» мәдрәсәсенең укыту программаларын төзешүдә катнаша. Укытучылар мәктәбенең әзерлек курслары мөдире, Казан университетын тәмамлаган Ш. Шәһиәхмәтов та бу эштән читтә калмый. Оренбург Укытучылар мәктәбе директор-инспекторы титуляр советник Усман Юзәй улы морза Саинов та, башта Казанның Беренче гимназиясен, аннары шунда ук университет курсын тәмамлаган зыялы буларак, мәдрәсәнең киләчәк язмышына зур йогынты ясый.

Шушы җәһәттән Казан университеты белән Беренче гимназия эшчәнлегенә дә игътибарны юнәлтеп алыйк. Россия дәүләте мәнфәгатьләрен яклау өчен ачылган бу уку йортларына әкренләп татар зыялылары балалары да аяк басалар. Патша хөкүмәте бу омтылышка кирәкле юнәлеш бирү өчен мөфтигә хат белән мөрәҗәгать итә. Казан, Уфа, Оренбург губерналарындагы тугрылыклы мөселман балаларын Казан гимназиясенә укырга бирергә өндәгез, диелә ул хатта. 1831 елда мөфти Сөләйманов урындагы җәмәгатьчелеккә өндәүләр язып тарата, «Балаларыгызны губерна идарәләре хисабына гимназиягә укырга җибәрергә чакырам»,— дип белдерә. Элегрәк мөфти бу юнәлештә чирканыч алган була: дин башлыгының улы Мирзаҗан дигән берәү гимназия бусагасын 1809 елда ук атлап керә, әмма аннан үрнәк тәртип белән кайтмый.

Бу юлы исә мөфтинең мөрәҗәгате эзсез калмый — утызынчы елларда Казан гимназиясендә утызлап, ә кырыгынчы елларда илледән татар һәм башкорт балалары белем алалар. Укучыларның күпчелеге Оренбург төбәгеннән чыккан татар балалары тәшкил итәләр. Гимназия бетереп кайткан яшьләр, әлбәттә, Оренбургтагы мәдәни тормышка йогынты ясамый калмаганнар. Ә «Хөсәения»нең киләчәк язмышы хәл ителгәндә, күргәнебезчә, аларның кайберләре турыдан-туры катнашканнар яисә аның юнәлеш-программасын билгеләүгә этәргеч булганнар. Белгәнебезчә, Казан гимназиясендә татар телен һәм халык авыз иҗатын өйрәнүгә дә әһәмият бирелгән, беренче әлифбабыз да шушы уку йортының көнчыгыш телләре укытучысы Ибраһим Хәлфин тарафыннан төзелгән. Аннары монда аның улы хәлфәлек иткән.

Гимназияне уңышлы тәгәлләгәннән соң югары белем алуга омтылучы якташларыбыз да байтак булган. Мәсәлән, 1813 елда Оренбургта офицер гаиләсендә туган Гайса Мөхәммәт улы Бикмиев, Оренбург губернасы стипендиясенә укып гимназияне тәмамлагач, 1832 елда Казан университетының филология факультетына кабул ителә. Диплом алып чыккач исә Омскидагы хәрби училищега укытырга җибәрелә. Әмма туган шәһәре белән дә элемтәсен өзми.

Татар теле һәм әдәбияты дәреслеге белән сүзлеге «Диван хикәят татар»ны (1859) язган Оренбурглы Салихҗан Бикташ улы Кукляшев та — Казанның Беренче гимназиясендә белем алучыларның беренчеләреннән. Соңыннан, 1836 елда ул да Казан университетын тәмамлый, аннары, фән кандидаты сыйфатында,




*«Хөсәения» мәдрәсәсе һәм мәчете.*

Оренбургның Неплюев исемендәге хәрби училищесына, көнчыгыш телләрен укытырга җибәрелә. Гыйльми хезмәтен Казанда бастырган дәвердә ул инде училищеның өлкән укытучысы һәм подполковник дәрәҗәләрендә була. Гайса да, Салихҗан да әлеге хәрби училищеларның «азиатский» дип йөртелгән махсус курс-факультетларында укыталар. Болар — татарлардан беренчеләр булып Казан университеты дипломын алган шәхесләр. Дөрес, алардан берничә елга элгәрерәк ирекле тыңлаучы сыйфатында университетта Ибраһим Хәлфинның улы Шәңгәрәй дә укыган, ләкин укуын тәмамламаган.

Алтмышынчы елларда университетның физика-математика факультетын морза улы Мөхәммәдьяр Биглов та уңышлы тәмамлый һәм туган ягына, Оренбург гимназиясенә укытырга җибәрелә. Аңардан берничә елга соңрак шул ук уку йортының юридик факультетын Ш. Шаһиәхмәтов, З. Сыртланов һәм Ә. Мөхәммәдьяровлар тәгәллләп кайталар да Оренбург казна мәктәпләрендә укытырга керешәләр. Билгеле, Казанның гимназия һәм университетларында укып кайткач башка төр хезмәтне сайлаучылар да байтак. Әйтик, табиб дипломы алучылар да, офицер хезмәтен сайлаучылар да булган.

* * *

Менә шушы шартларда унтугызынчы гасырның сиксәненче елларында абыйлы-энеле Хөсәеновлар һәм аларның фикердәшләре Россиянең югары уку йортлары дәрәҗәсенә якын торган мәдрәсә ачу хыялы белән яшиләр. Баштарак мәдрәсәне Каргалы авылында ачарга ниятләп йөриләр. Ләкин соңыннан бу фикердән кире кайталар һәм «Хөсәения» Оренбургта арендага алынган берничә бинада 1889 елның көзендә, ниһаять, ишекләрен ачып җибәрә.

Үзара килешү буенча аңа нигез итеп моңа чаклы эшләп килгән өч мәдрәсә алына: «Хәйретдин хәлфә мәдрәсәсе», «Дамелла Шаһимәрдән хәзрәт мәдрәсәсе» һәм «Сөнгатулла әфәнденең төрек мәдрәсәсе». Бу мәдрәсә һәм мәктәп җитәкчеләре Вәлиев Хәйретдин, Утәгәнов Шаһимәрдән белән Галиев Сөнгатулла «Хөсәения»нең төрле сыйныфларында хәлфә-мөгаллимнәр булып калалар. Бу мәдрәсәләрдән фәкать Шаһимәрдән хәзрәт уку йортында гына югары сыйныфлар була. Казан губернасы, Малмыж өязе, Түнтәр авылында туып-үскән Шаһимәрдән хәзрәт «Хөсәения» мәдрәсәсе тарихында да якты эз калдырган шәхес санала, башлыча гарәп телен һәм гарәп илләре тарихын укыта.

Бүгенге көндә Оренбургның дәүләт архивында мәдрәсә тарихына кагылышлы алтмыш өч берәмлек документ саклана. Мондый эчтәлекле материаллар

шулай ук Уфа шәһәре архивларында да булырга тиешләр. Әйтик, Диния нәзарәте архивында...

Узган гасырның туксанынчы елларында шәһәр үзәгеннән читтәрәк, татар бистәсе белән ике арада, мәдрәсәнең үз утарын төзү өчен заманына күрә бик кыйммәт хакка җир мәйданы алына. Озакламый шунда «Хөсәения»нең өч катлы төп уку корпусы, таш мәчете, имам өе һәм мәдрәсәнең хезмәткәрләренә исәпләнгән ике катлы торак биналары өчен нигез салына. Барысы да — нык таштан һәм кирпечтән. Мәдрәсәнең төп бинасы 1905 елда төзелеп бетә һәм шәһәр буйлап таралышкан шәкертләр шушында тупланалар. Бу өч катлы иркен йортта заманча җиһазландырылган уку классларыннан тыш бай гына китапханә һәм ашау-эчү, йокы бүлмәләре дә була. Мәдрәсә утары бүген дә исән. (Монда егерменче елларда Халык мәгарифе институтлары һәм Татар педогогия техникумы эшләде, хәзер исә Оренбург авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультеты урнашкан.) Мәдрәсә утарын төзүдә өлкәнең хәзерге Шарлык районы, Мостафа авылы кешеләре дә саваплы эш башкаралар: балта осталарын өйдәүче — күренекле артист Хәлил Әбҗәлиловның атасы Галиулла оста була, десятник вазифасын Муса Җәлил атасына баҗа тиешле Хаммат Сәйфетдинов үти.

«Хөсәения»дә уку дәвере ундүрт еллык була: өч баскычлы башлангыч ибтидаи сыйныфлар, дүрт сыйныфлы урта белем бирүче рөшдия бүлеге, дүрт сыйныфлы тулы булмаган югары белем бирүче игъдадия бүлеге һәм өч еллык югары белем бирүче галия бүлеге. Телəгән шәкерт игътидадияне тәмамлагач та гомуми, ягъни башлыча авыл җирләрендәге мәктәп һәм мәдрәсәләрдә укыту мөмкинлеге биргән таныклык алып чыгып китә алган. Рөшдия бүлегеннән соң да төрле һөнәр училищеларына күчеп укучылар ишле генә булган. Мәсәлән, Риза Фәхретдин, Закир һәм Шакир Рәмиевләрнең уллары шулай иткәннәр һәм, Оренбург реаль училищесын тәгәлләгәннән соң, Россия һәм чит ил институтларында укып, инженерлык дипломнары алганнар. «Хөсәения»нең танылган хәлфәсенең улы Шамил Усманов та рөшдиядән соң һөнәр училищесында белем ала.

Мәдрәсәдә шәкертләр саны биш йөздән артмаска тиеш булса да, кайбер елларда анда укучылар күбәеп киткән. Мөгаллим-хәлфәләр саны утыз-утыз бишкә җиткән. Аларның хезмәт хакы бүтән мәдрәсәләрдәгедән шактый артыграк, шунлыктан иң тәҗрибәле һәм белемле укытучыларны сайлап алу мөмкинлеге булган. «Хөсәения»нең педагоглары арасында төрле-төрле губерналардан



*«Хөсәения» мәдрәсәсенең бер төркем мөгаллимнәре. 1915 ел.*

чакырылган мөхтәрәм шәхесләр байтак. Патша хөкүмәте тарафыннан «Иж-Буби» мәдрәсәсе таркатылгач та кайбер абруйлы хәлфәләр эшне Оренбургта дәвам иттерәләр.

«Хөсәения» мәдрәсәсендә шәкертләр русча укырга һәм язарга да өйрәнгәннәр. Элегрәк бу хәл башлангыч сыйныфларда гына булган. 1895 уку елыннан рус классы җитәкчесе итеп тәҗрибәле педагог, мәдрәсәнең Попечительләр советы әгъзасы Гайса Еникеев эшли башлый. Рус классы укытучысына хезмәт хакын земство түли. Патша хөкүмәте тарафыннан 1874—1875 елларда кабул ителгән тәртип буенча, мәдрәсәләрдә Россиядә басылган дәреслекләр генә кулланыла алган. Шушы тәртипкә һәм заман таләпләренә нигезләнеп, «Хөсәения» мәдрәсәсе хәлфәләренең күпчелеге үз белгечлекләре буенча русча чыккан дәреслекләрне татарчага күчерү белән дә, ана телебездә дәреслекләр язу белән дә шөгыльләнгәннәр.

Укыту, тәрбия мәсьәләләренә багышланган китаплар, кулланма-дәреслекләр бу елларда күпләп басылып чыгалар. Аларның кайберләренең авторлары — шулай ук «Хөсәения»гә мөнәсәбәтле шәхесләр. Мисалга Казанда Учительская школаны тәмамлаганнан соң 1902 елда «Хөсәения»гә хәлфә итеп чакырылган Гаяз Исхакыйның тәрбия мәсьәләләренә караган иҗатын алырга була.

Башка хәлфәләрдән Шаһидулла Вахитов — «Гыйлем хисап» (1901, 1911); Нургали Надиев — «Ибтидаи мәктәптә хисап укыту ысуллары» (1917); Хәнәфи Бакиров — «Гыйльме табигыя дәреслеге», ике кисәк (1918); Габдулла Ибраһимов-Шөнаси — «Мохтәсар химия», ике басма (1910, 1912); «Хикмәт табигыя дәреслеге», (1916); Шакирҗан Ибраһимов — «Рәсемле фәнни кыйраәт» (1910); Зәки Вәлиди — «Кыскача төрек-татар тарихы» (1912); «Ходаяр ханның соңгы көннәре» (1915); Фатих Кәрими — «Мохтәсар җәгърәфия» (1899 елдан башлап алты басма); «Кыскача җәгърәфия» (1914, 1915); Харис Фәйзи-Чистопули — «Ысул җәгърәфия» (1900—1905 елларда биш басма); Ризаэтдин Фәхретдинов — «Исмәгыйль сәяхәте» (1903); «Ибн Фазланның Болгарга килүе» (1915); Борһан Шәрәф — «Иран мәктүпләре» (1909) һ. б. хезмәтләре бар.

«Хөсәения» мәдрәсәсенә, нигездә, югары галия сыйныфларда белем бирүгә хокукы булган хәлфәләр генә алынганнар, аларның укыту сәләте идарәче байлар тарафыннан тикшерелгән. Мәдрәсәдә беренче нәүбәттә, ул замандагы барлык мәдрәсәләрдәге кебек, дин дәресләре һәм дин тарихы, дини кануннар укытыла, гарәп, фарсы телләре тирәнтен үзләштерелә. Башкалардан аермалы буларак, татар телен һәм әдәбиятын өйрәнүгә дә зур урын бирелә. Өч класслы рус теле һәм әдәбияты бүлеге булуы «Хөсәения»не башка шундый дәрәҗәдәге уку йортларыннан аерып тора. Ләкин бу җәһәттән Хөсәеновларга да, «Хөсәения»нең идарәчеләренә дә байтак кына тәнкыйть сүзләре ишетергә туры килә. Искелеккә ябышып ятучы зыялылар һәм дин әһелләре Диния нәзарәтенә дә, югары хөкүмәт оешмаларына да «Хөсәения» мәдрәсәсендә рус телен укытуны тыюны таләп итеп шикаятьләр язалар: «Шушындый абруйлы мәдрәсәгә мөселман динен һәм кануннарын гасырлар буена эзәрлекләп килгән бер тел буларак, рус телен укыту харам»,— дип баралар. Мәдрәсә эшчәнлеге күп мәртәбәләр Диния нәзарәте вәкилләре һәм Оренбург уку округы инспекторы тарафыннан тикшерелә һәм даими күзәтү астына алына. Ләкин шуңа да карамастан, яшьләрне заманча белемле итү максатын алга сөргән «Хөсәения» мәдрәсәсендә башка милләтләр һәм мәдәниятләр белән аралашу чарасы булып барган рус телен өйрәнүдән читләшмиләр. Киресенчә, шәкертләр таләбе буенча бу тел тиздән югары сыйныфларда да укытыла башлый. Аннары озакламый шуңа өстәп немец һәм француз телләрен өйрәнү дәресләрен дә гамәлгә кертәләр.

Дөньяви фәннәрдән «Хөсәения» мәдрәсәсендә Россия тарихы һәм мөселман дөньясы тарихы, әхлак һәм фәлсәфә, логика һәм үз-үзеңне ничек тоту кагыйдәләре, педагогика һәм башка дәресләр керә. Башлангыч сыйныфларда матур язу, сызым, рәсем ясау һәм соңрак музыка дәресләре дә булдырыла. 1905 елдан соң шәкертләр оркестры оешкан. Ә 1917 елның көзендә, «Хөсәения» мөгаллимнәре һәм шәкертләре көче белән мәдрәсә каршында «Музыка-драма» дигән җәмгыять оеша. Шушы җәмгыять үз хисабына «Музыка-әдәбият» исемле кызыклы гына җыентык бастырып чыгара. 1918 елда исә монда музыка мәктәбе дә ачыла, анда мәдрәсә укытучыларыннан тыш рус музыкантлары да катнашалар. Тиздән аның директоры итеп булачак мәшһүр композитор Салих Сәйдәшев сайлана. Шушы музыка мәктәбе тыңлаучылары арасында элекке «Хөсәения» шәкерте, композитор буларак танылачак Җәүдәт Фәйзи дә була.

Мәдрәсә шәкертләре төгәл фәннәрдән гадәти хисап (арифметика), алгебра, геометрия һәм тригонометрия кануннарын өйрәнгәннәр. Аларга шулай ук физика, химия, астрономия, табигать белеме һәм география фәннәреннән дә ныклы белем бирелгән. Унтугызынчы гасырда бу җәһәттән «Хөсәения» белән «Иж-Буби» мәдрәсәләре генә бер-берсенә якын торганнар дип әйтергә була.

Фәннәрне өйрәнүгә күпме вакыт бүленгән соң? Менә 1906—1907 уку елына караган атналык расписание. Ибтидаи сыйныфлар өчен: ана теле — 17 сәгать, интикад (дини эчтәлекле әсәрләр белән танышу) — 3 с., әхлак мәсьәләләре — 3 с., Коръән сүрәләре — 11 с., мөнәҗәт уку — 3 с., гыйбадәт кылу — 4 с., тарих, географиягә кагылышлы хикәятләр — 3 с., гомуми тарих — 2 с., география — 1 с., хөсне хат (матур язу) — 2 с., физика һәм сызым дәресләре — 5 с., хисап — 9 с.

Рөшдия сыйныфлары өчен: Коръән тәдриҗ — 8 с., дин тарихы — 8 с., әхлак мәсьәләләре — 4 с., гомуми тарих — 8 с., география — 4 с., хисап — 4 с., һәндәсә (геометрия) — 4 с., физика — 4 с., татар теле — 12 с., гарәп теле — 8 с., рус теле — 18 с.

Игъдадия сыйныфлары өчен: дини хокук мәсьәләләре — 4 с., гомуми тарих — 6., география — 3 с., физика — 3 с., химия — 3 с., табигать тарихы — 3 с., алгебра — 3 с., геометрия һәм тригонометрия — 3 с., астрономия — 1 с., психология, логика, фәлсәфә тарихы — 5 с., хокук — 2 с., гигиена, медицина — 1 с., политэкономия, сәүдә эше — 6 с., ысул дәфтәре (бухгалтерия) — 1 с., гарәп теле һәм әдәбияты — 7 с., татар теле һәм әдәбияты — 7 с., рус теле һәм әдәбияты — 10 с., немец теле — 11 с.

Игъдадиянең дүрт еллык дини юнәлешле сыйныфлары өчен (шәкертләр таләбе белән бу бүлек 1907—1908 уку елыннан бетерелә): әхлак — 4 с., дини хокук — 12 с., гакаид (теология) — 6 с., гомуми тарих — 4 с., география — 3 с., дин тарихы — 3 с., физика — 2 с., химия — 2 с., табигать тарихы — 3 с., алгебра — 2 с., геометрия — 2 с., астрономия — 1 с., психология — 2 с., логика — 2 с., фәлсәфә тарихы — 2 с., хокук — 1 с., гигиена, медицина — 1 с., бала тәрбиясе — 2 с., гарәп теле һәм әдәбияты — 5 с., татар теле, әдәбияты — 5 с., рус теле һәм әдәбияты — 6 с., фарсы теле — 3 с., Коръән тәфсире — 6 с., Мөхәммәт пәйгамбәр нотыклары — 3 с., дини хокук — 2 с., дини фәлсәфә — 1 с.

Гомум белем бирү бүлегендә унынчы елларда француз телен өйрәнү дәресләре дә өстәлгән. Атналык уку сәгатьләре, әлбәттә, кырык сигез сәгатьтән дә артмаган. Көндезге ашау-эчүдән һәм ял иткәннән соң шәкертләр, кизү торучы хәлфәләр җитәкчелегендә, киләсе көн дәресләренә кичке әзерлек сәгатьләренә җыелганнар.

Менә мәдрәсә шәкерте, язучы Сәгыйть Агишның ул елларга караган истәлекләреннән бер өзек: «Хөсәения»дә дин дәресләре белән бергә физика, математика, география, туган тел, рус теле дә укытыла, рәсем һәм физкультура да бар иде. Мәдрәсәдә гомуми ятак һәм биш вакыт намаз үтәү өчен идәнгә яшел постаудан намазлык җәелгән бер бүлмә дә бар иде. Мәдрәсәдә төп дәфтәргә теркәлгән синең исемең алдында бер номер була. Әйтик, ул номер 32 нче. Бөтен җиргә — ашханә өстәленә, сөлге куя торган әрҗәнә, сандык бүлмәсендәге киштәнә, кроватенә һәм партаңа шушы номер язылган була...

Шуны да әйтергә кирәк, кемнәрнең тәэсире беләндер, бу мәдрәсәдә әдәби хәрәкәт шактый көчле иде... Шагыйрь һади Такташ та әллә шушында укый, әллә килеп кенә йөри иде, әмма аны без бик еш күрә идек. Исхак Башмаков дигән бер шагыйрь дә бар иде. Мәдрәсәдә кульъязма рәвешендә чыга торган журналда Кәрим Фәйзи һәм башкаларның да шигырьләре еш күренә иде»...

Хөсәеновларның варислары берничә мәртәбә Россиянең Дәүләт Думасыннан һәм Россия мәгариф министрлыгыннан «Хөсәения» мәдрәсәсен Диния нәзарәте карамагыннан алуны һәм хосусый бер уку йорты итеп кенә калдыруны үтенәләр. Әмма уңай җавап ала алмыйлар.

Төгәл фәннәр укыту өчен бу мәдрәсәдә баштан ук аерым билгеләнгән класслар булдырыла, физика һәм химия кабинетлары махсус җиһазландырыла. 1914 елда, мәсәлән, шушы ике кабинеттагы лаборатория җиһазларын алыштыру һәм укыту барышында кирәк булачак әсбап һәм химикатлар алу өчен генә дә мең алты йөз туксан сум тотылган. Еллык гомуми чыгым исә унбиш-егерме мәртәбәгә күбрәк булган. Мәсәлән, 1915 елда мәдрәсәнә тәртиптә тоту, ут, су кертү, шәкертләрне киендерү, тукландыру, хәлфәләргә хезмәт хакы түләү һәм торак белән тәэмин итүгә барлыгы егерме дүрт мең сум сарыф ителгән. Заманына күрә бу — бик тә зур чыгым.

Мәдрәсә китапханәсендә татар һәм рус телләрендәге дәреслекләрдән тыш гарәп, төрек, фарсы, инглиз, немец, француз телләрендә басылган төрле китап-

лар, белешмәләр һәм энциклопедияләр дә тупланган. Китапханәгә Россия, Төркия, Мысыр һәм Европа илләре вакытлы матбугаты белән беррәттән күпсанлы матур әдәбият китаплары да алдырылган. Шәкертләр 1906 елда мөселман Җәмгыяте хәйрия ачкан «Белек» китапханәсеннән дә файдалана алганнар. Чөнки бу китапханә башта мәдрәсә утарында урнаша.

Мөгаллим һәм үзешчән рәссам Сәләх Камал җитәкчелегендә «Хөсәения»дә шулай ук борынгы шәрык сәнгатен өйрәнү дәресләре дә оештырыла, соңыннан бу мөгаллим үз классын «Шәрык музее»на әверелдерә.

«Хөсәения» мәдрәсәсе 1918—1919 уку елы тәмамланганчы яши. Аннары ул «Хөсәеновлар укытучылар институты» итеп үзгәртелә. Утыз ике ел яшәү дәверендә мәдрәсәдә җәмгысы йөз иллеләп мөгаллим һәм хәлфә дәрес бирәләр. Ә көндәлек тормыш белән Идарәче байлар (Попечительләр советы) тарафыннан сайлап куелган баш мөдәррис җитәкчелек итә. Андый урынга, билгеле инде, укымышлы гына түгел, дини даирәләр тарафыннан да танылган имам хатиблар сайланган. «Хөсәения» җитәкчеләре арасында дин галиме, казый Габделгалим Дәүләтшин, Габдерәхим Дәминов, галим, язучы һәм әдәбият белгече казый Ризаэтдин Фәхретдинов, Таһир Ильясов бар. Мәдрәсәнең соңгы баш мөдәррисе галим Хәнәфи Бакиров була.

Әйтергә кирәк, «Хөсәения» мәдрәсәсендә кадими Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәләрендә белем алган хәлфә һәм мөгаллимнәр бик аз. Мәдрәсәне оештыручылар да, аның Идарә әгъзалары да Урта Азия белем үзәкләренең укыту һәм тәрбия тәртипләрен өнәп бетермәгәннәр, үзләренә кыйбла итеп, нигездә, мәдәниятле Европа һәм Якын Көнчыгыш югары уку йортларын сайлаганнар. «Хөсәения»гә башлыча Истанбул, Бәйрут, Каһирә институт һәм университетларында, Көнбатыш Европа илләрендә белем алган шәхесләр чакырылган. Мәсәлән, мәдрәсәнең уку-укыту буенча баш мөдәррис ярдәмчесе Хәнәфи Бакиров белән тәрбия һәм укыту эшләренең башлангыч дәвердәге илһамчысы саналырдай зыялы хәлфә Фатих Кәрими, хәлфә һәм мөдир Габдулла Ибраһимов-Шонаси — Истанбул университетында белем алганнар. Хәлфәләр Муса Бигиев, Сөнгатулла Бикбулатов, Салихҗан Насыйров, Гобәйдулла Рафиков, Вәли Батталов, Шаһидулла Вахитов — Каһирә университетын, Хәлил Гайнуллин, Сәләх Камалетдинов, бертуган Фәйрушиннар Бәйрут университетын бетергәннәр, Камил Кәрими исә Казан университетын тәмамлаган.

«Хөсәения» ачылган дәвердә Идарә әгъзалары башында әүвәл Әхмәт бай Хөсәенов үзе тора, аның вафатыннан соң бу вазифаны энесе Мәхмүт бай үти. 1910 елдан башлап Идарә башында «Хөсәения» тәрбиясен алган Шәрәфетдин Хөсәенов тора. Мәдрәсәнең төрле елларда теркәлгән Идарә әгъзаларының исемлеге мондый: Ихсан Биказаков, Нургали Габдуллин, Мәхмүт Госманов, Габделгалим Дәүләтшин, Мәһди Дивишев, Гайса Еникеев, Әбүбәкер Капкаев, Насрулла Кәримов, Фатих Кәрими, Камил Кәрими, Шакир Рәмиев, Закир Рәмиев-Дәрдемәнд, Нигъмәтулла Тимошев, Харис Фәйзуллин-Чистопули, Габдрахман Хәбибуллин, Закир Хәеров һәм Насрулла Ядкәрев. Болардан тыш Габделгани Хөсәенов уллары Газиз белән Хәмит һәм Мәхмүт бай Хөсәеновның икенче улы Хөсәен дә Идарә составында булалар. Боларның һәрберсе мәдрәсә чыгымнарының бер өлешен үз өсләренә дә алганнар. Әйтик, бертуган Рәмиевләр акчалата матди ярдәмнән тыш узган гасырда ук физика һәм химия кабинетларын җиһазландыруны үз бурычлары итеп саныйлар һәм аларны, нигездә, Алманиядән кайтарталар.

Мәдрәсәнең утыз елдан артык яшәү дәверендә табиб вазифасын Исхак Гали улы Медведев башкарган. Әлегә аның кайда укып табиб дипломы алганлыгы ачыкланмаган, мөгаен, башкалар кебек үк, ул да Казан университетының медицина факультетында укыгандыр. Фельдшер булып монда озак еллар Ә. Акимов хезмәт итә.

«Хөсәения» шәкертләре, шактый кырыс тәртип-кагыйдәләргә буйсынып яшәгәнлектән, шәһәрдә йөргәндә дә итагатьлелек, тәрбиялелек белән аерылып торганнар. Бу җәһәттән абыйсы Шакирҗан һәм кардәше Мохтар Ибраһимовлар укыган «Хөсәения»гә барган вакытта Галимҗан Ибраһимовның андагы тәртипне «Вәлия» мәдрәсәсе тәртип-тәрбияләре белән чагыштыруы бик тә гыйбрәтле, безнеңчә. «Көндәш» шәкертләрен ул бик өстен куя.

1905 елгы вакыйгалардан соң мәдрәсә кагыйдәләрен үтәү һәм уку-укыту барышына йогынты ясау өчен Шәкертләр бердәмлеге оештырыла. Бу бердәмлек вәкилләре соңрак мәдрәсәнең Педагогия советы утырышларында катнашу хокукын да яулап алалар. Бу бердәмлек эшендә шәкертләрдән Р. Рәкыйби, Г.

Максудов, Б. Шәфиев, Г. Туктаров, З. Габдеев, И. Сәүбәнов, булачак шагыйрь Шамун Фидаи-Шакирҗанов, Габдулла һәм Гобәйдулла Мохтаровлар аеруча активлык күрсәтәләр. «Хөсәения» мәдрәсәсендә оештырылган берничә ябык забастовка да башлыча шушы шәкертләр җитәкчелегендә узды-рыла. Шәһәр халкын җәлеп итәрдәй шаулы забастовкалар исә монда булмый.

Мәдрәсәдәге хәлфә һәм мөгаллимнәренең күпчелеге — шул чор татар дөньясында киң җәмәгатьчелеккә бик таныш кешеләр, энциклопедик белемле шәхесләр: күренекле җәмәгать эшлеклесе Фатих Кәрими (башлангыч чорда даими, соңрак факультатив рәвештә укыта), галим, язучы һәм дин әһеле Ризаэтдин Фәхретдинов, аның улы, Казан һәм Пермь рус югары уку йортларында белем алган Габдрәшит Фәхретдинов, күренекле язучы Шәриф Камал, күпсанлы дәреслекләр авторы чистайлы Харис Фәйзуллин, ислам дине галиме һәм гарәп теле белгече Муса Бигиев, тарихчы Зәки Вәлиди, шагыйрь, драматург һәм ялкынлы журналист Сәгыйть Рәмиев (үзе дә «Хөсәения» тәрбиясен алган зыялы), танылган әдәбият галимнәре Габдрахман Сәгъди һәм Җамал Вәлиди, әдип-тәрҗемәче — Нигъмәт Еникеев, нәшир һәм әдәбиятчы Шәрәф Борһан һәм башкалар.

Элегрәк мәдрәсәдә башлангыч сыйныфларда рус теле һәм әдәбияты да өйрәнелгән, анда тәҗрибәле педагог һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе, Оренбург шәһәреннән Икенче, Өченче һәм Дүртенче Думаларга депутат булар сайланган морза Гайса Хәмидулла улы Еникеев белем биргән дип әйткән идек. Егерменче гасыр башыннан, югары сыйныф укучыларына да рус теле кертә башлагач, бу фәннән укытучылар санын арттыру хаҗәте туган. «Хөсәения» мәдрәсәсенең игъдадия бүлеген уңышлы тәмамлаган берничә шәкерт мәдрәсә хисабына Казандагы Учительская школага укырга җибәрелә. Тиздән шунда белем алып кайткан бер төркем яшьләр — Мирсәйфетдин Әхмәтсафин, Зәки Ишаев, Габдрахман Киникеев, Шакирҗан Кылычбәков, Ильяс Кудашев-Ашкадарский, Мирсәяф Туктамышев, Хөсәен Хакбирдиннар мәдрәсәнең хәлфәләре сафына килеп кушылалар.

Югары сыйныфларда шулай ук тарих һәм гомуми белем бирү дәресләрен Вәли Батталов, Нигъмәт Еникеев, Камил Кәрими, Шәрәф Борһан, М. Фәйзуллин, Г. Йосыповлар алып барганнар.

Төрки-татарлар тарихын картограф-рәссам Сәләх Камалетдинов һәм Ибраһим Бикчәнтәев, милли тел һәм әдәбиятны Сәгыйть Рәмиев, Шәриф Камал, Җамал Вәлиди, Нәҗип Гасрый-Мәвләнбирдиев, Габдрахман Сәгъди, Сәгыйть Сүнчәләй, Тохфәт Ченәкәев-Сәмәви һ. б. укытканнар.

Математика, физика, химия кебек төгәл фәннәрдән дә дәреслекләре мәктәп-мәдрәсәләр киштәсеннән төшмәгән зур белгечләр укыта: М. М. Алиев, Х. К. Бакиров, Н. М. Вәлишев, Ш. В. Вахитов, Х. Г. Галикеев, Гибад әл Сабур, Г. С. Ибраһимов-Шонаси, З. Г. Ишмаев, В. А. Мөхәммәдиев, К. С. Мөхәммәдиев, Н. Надиев, Х. Рәмиев, Г. Рафиков, Ф. Гобәйдулла. Мөхәммәт Вәлишев (1886—1935) соңгы дәвердә «Хөсәения» мәдрәсәсе Гыйльми советының сәркатибе вазифасын да үти, ә 1915 елда Оренбург милли мәктәп-мәдрәсәләре инспекторы итеп билгеләнә. Утызынчы елларда ул Сәмәрканд педагогия институтының математика кафедрасы мөдире була.

Хәнәфи Кәрим улы Бакиров (1884—1935) «Хөсәения»нең соңгы директоры, физика һәм химия дәреслекләре авторы буларак та билгеле. 1920—21 елда мәдрәсә нигезендә Халык мәгарифе институтларын оештыруда актив катнаша. Татар, башкорт, казакъ һәм гомумшәрык халыклары институтлары дип дүрт өлешкә бүленгән бу уку йортлары 1925 елда ябылгач та Хәнәфи Бакиров, Казанга күчеп, югары уку йортларында укытырга керешә. Утызынчы елларда Казан химия-технология институтының химия кафедрасы доценты була. Химия һәм физика фәннәре буенча дәреслекләре совет чорында да берничә мәртәбә басылалар.

Нургали Надиевның (1882—1941) да хезмәт юлы шуңа охшаш. Нургали Иделнең түбән агымында урнашкан Сүләев авылында туа, төпле белемне Казан мәдрәсәләрендә укыганда ала. Казанда чакта алдынгы карашлы яшьләр, шул исәптән Гафур Колахметов белән якыннан аралаша. Берничә ел Минзәлә һәм Бозаулык төбәкләрендә укыта. 1913 елда, мөгаллим буларак даны таралгач, «Хөсәения»гә чакырыла. Бу мәдрәсәдә дә аның абруе тиз күтәрелә. Мәсәлән, аның олкән хезмәттәше Фатих Кәрими, Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең беренче сайланма әсәрләренә кереш мәкаләсендә, Нургали Надиевны мәдрәсәнең иң алдынгы карашлы хәлфәләре исемлегендә атый. Нургали Надиев 1919 ел

көзендә «Хөсәения» мәдрәсәсен яңа тәр югары уку йорты итеп үзгәртү комиссиясенең рәисе итеп билгеләнә. Аннары, ябылганчы, бу үзенчәлекле уку йортының эшлекле директоры була. 1925 елда Казанга күчеп китә һәм берара, Г. Ибраһимов сырхаулый башлагач, Татарстан мәгариф халык комиссариаты каршындагы академик үзәкне җитәкли. Аннары Казан дәүләт педагогия институтында укыта. Егермеләп дәреслекнең һәм гыйльми китапның авторы, Көнбатыш Европа һәм Якын Көнчыгыш илләренең күренекле педагоглары хезмәтләрен татарчага тәрҗемә итеп бастыручы буларак абруй казана. Нургали Надиевның шагыйрь Муса Җәлил өчен сөекле укытучы гына түгел, олы киңәшче һәм остаз булганлыгын да искә төшерик. Шагыйрь сугышка киткәндә остазына бер чемодан кульъязма һәм документларын ышанып калдыра. Чемодан, белүебезчә, илленче елларда Муса Җәлил исеме кабат телгә керер көннәргәчә Надиевлар фатирында хәтәр күздән посып ята.

Гарәп телен һәм әдәбиятын, мөселман хәлифәтләре тарихын Каһирә һәм Бәйрут университетларында белем алган белгечләр укытканнар. Яисә язучы һәм журналист Закир Хәлим улы Кадыйри кебек Мысырда гарәпчә газета чыгаруда катнашкан тел белгечләре булалар алар. Аның «Гарәп сарфы» (1912), «Гарәп нәхүе» (1912) дәреслекләре була. Гарәп мәдәниятенә һәм теленә, гомумән, шәрык дөньясына кагылышлы дәресләрне шулай ук К. А. Айдаров, Г. Г. Бакыев, С. Н. Бикбулатов, Г. Салихов, М. Бигиев, Х. Гайнуллин, Хәйрулла Усманов (язучы Шамил Усмановның атасы) кебек мөгаллимнәр укыта.

Мәдрәсәдә немец һәм француз телләреннән дә дәресләр биргәннәр, дидек. Хәлфәләрдән бу телләрне яхшы ук белүчеләр дә булган. Мәсәлән, Ф. Кәрими белән Г. Ибраһимов-Шонаси французча иркен сөйләшкәннәр. Ә махсус укытучылардан, унынчы елларда немец теле буенча Алексей Сергеевич Лазов, француз теленнән Людмила Васильевна Лазова мәдрәсә журналына теркәлгән.

Соңгы дәвердә «Хөсәения»дәге хәлфә һәм мөгаллимнәрнең ишле бер өлешен шушы мәдрәсәдә белем алган шәкертләр тәшкил иткән. Аларның күпчелеге мәдрәсәне тәмамлагач та Идарәче шура тарафыннан сайланып төрле-төрле югары уку йортларына Хөсәеновлар байларның мирасы хисабына җибәреп укытылган. Мәдрәсә стипендиатлары булып танылган ул студентлар, нинди генә уку йортларында укысалар да, «Хөсәения»гә кайтып, дүрт ел хәлфәлек итәргә тиешле саналганнар. Мәсәлән, игъдадия бүлеген тәмамлаган шәкертләрнең кайберләре мәдрәсә хисабына даими рәвештә Казанның учительская школасына җибәрелгән. Аннан инде алар үз уку йортларына «урыс хәлфәләре» булып кайтканнар.

«Хөсәения»гә кайтып кимендә дүрт ел укыту тәртибе чит ил институтларында укучыларга да кагылган. Әйтик, Каһирә университетына җибәрелүчеләр — Закир Аюханов (революция алдыннан укып кайта, егерменче, утызынчы елларда Башкортстанда педагогия институтында укыта, беренче башкорт әлифбасын төзүчеләрдән); Сөнгатулла Бикбулатов (1885—1956), хәлфә, мәктәп-мәдрәсәләр өчен гарәпчә уку китаплары авторы, соңгы дәвердә Казан дәүләт университетында гарәп теле укытучысы була; Гобәйдулла Рафиков, мәдрәсәдә мөгаллим, дәреслекләр авторы; Әмирхан Сәйфетдинов, Вәли Батталов, Сәлихҗан Насыйров-Ногманов, Латыйф Заһитов, Шаһидулла Вахитов та университет дипломы белән мәдрәсәгә укытырга кайталар.

Бәйрут университетында укытылган шәкертләр: Сәләх Камалетдинов, Хәлил Гайнуллин, Шакирҗан белән Галимҗан Файрушиннар.

Камил Кәрими, Искәндәр Мостакыймов һәм Хәсән Мөхәммәтъяровлар мәдрәсә стипендиясенә Казан университетында белем алганнар. Укып кайткач Камил Кәрими әзлекле рәвештә «Хөсәения»дә тарих һәм юридик фәннәрдән укыта. Габделхәй Йосыпов белән Камал Мөхәммәдиев Томск технология институтында белем алалар. Укып кайткач, мәсәлән, К. Мөхәммәдиев мәдрәсәдә алгебра һәм геометрия дәресләре мөгаллиме була. Кавказ якларыннан килеп укыган шәкерт Габдулла Хаҗи-Бәкер углы Мостафаев соңыннан Саратов университетын тәмамлый. Ә Якуб Сөләйман улы Шинкевич «Хөсәения»не бик яхшы билгеләренә тәгәлләгәннән соң Петербург университетының Көнчыгыш факультетында зур белем ала. Бертуган Рәмиевлар токымыннан Бельгиянең Льеж шәһәре институтында Тау эшләре белгечлеге буенча инженерлык дипломына Закир улы Гариф белән Шакир улы Әхмәт Рәмиевләр укыйлар. (1914 елда шагыйрь Закир Рәмиев-Дәрдемәнд, кызы Зәйнәп белән, аларның хәлен белергә бара, бергәләп төшкән фоторәсемнәре сакланган). Искәндәр Рәмиев исә Алман илендә инженер дипломы ала.

Икенче буын Рәмиевләр барысы да башлангыч белемне шулай ук «Хөсәения»дә үзләштергәннәр. Париж, Прага университетларына барып кергән шушы мәдрәсә шәкертләре турында да хәбәрләр бар, ләкин бу хактагы архив материалларын табуы читен.

Яшәү дәверендә «Хөсәения» мәдрәсәсен ике мең дә илледән шәкерт тәмамлап чыга. Шуларның күпчелеге соңыннан, төрле җәмгыять эшләрендә һәм фән, гыйлем дөньясында катнашкан кешеләр булараk, мәдәниятебез тарихында теркәлеп калган олы шәхесләр: Җ. Абзгилдин, И. Г. Әбләзин, Л. Х. Әбүбәкер, Галим Айдаров, Гыйбад Алпаров, З. Л. Әминов, Сәләх Атнагулов, Фатих Бакиров, С. Н. Бикбулатов, С. Г. Габделганиев, М. В. Галиев, Ш. Ф. Гыйсмәтуллин, Г. Г. Гобәйдуллин, Г. С. Дәүләтшин, З. С. Дусаев, Шакирҗан Ибраһимов, Г. В. Игдисанов, Камил Кәрими, Х. Х. Корбангалиев, Г. Максудов, Х. М. Мостафин, Г. Х. Усманов, М. Х. Фәйзуллин, Г. Р. Фәхретдинов, А. Т. Хәсәнов, Ш. С. Чураев, З. Шакиров һ. б. бар.

Шушы низамлы мәдрәсә ишегеннән чыккан талантлы шәхесләр исемлеге дә зур: Сәгыйть Рәмиев, Мирхәйдәр Фәйзи, Тәхфәт Ченәкәй-Сәмәви, Мөхәммәт Гали, Муса Җәлил, Шамил Усманов, Афзал Таһиров, балалар шагыйре Гобәйдулла Мөэминов-Рәдүди, Заһид Йосыпов-Шәркый, Нигъмәт Еникеев, Галим Айдаров, Ярлы Кәрим, Шамун Фидаи, Габдулла Биги-Мостакаев, Амантай (Г. С. Табулдин) — татар әдәбиятында эз калдырган шәхесләрнең бер өлеше генә. Башкорт әдәбиятында җиң сызганып эшләгән шәхесләрдән Сәгыйть Агиш, драматург М. Бурангулов, Гариф Гомәр — шулай ук «Хөсәения» шәкертләре. Казакъ әдипләре һәм шагыйрьләре Б. Ж. Жумагалиев белән Җ. Теләпбиргәнов, беренче казакъ профессоры галим Ходайбиргән Җубанов та шушы мәдрәсәдә белем алып чыкканнар.

Россиядә беренче мәртәбә зур сәхнәдә татарча театр уйнарга ниятләгән, 1905 елның көзендә зурлап репетицияләр уздырып, Оренбург рус драма театры бинасында беренче спектакль куярга йөргән эшлеклеләрнең дә күпчелеге «Хөсәения» шәкертләре. Шул ук елның декабрендә, спектакль буласы дип афишалар эленгәч, тамаша рәсми рәвештә уйналмый кала — тыела. Бу эштә башлап йөрүчеләр һәм театрга ихлас гашыйклар Ильяс Кудашев-Ашкадарскийдан тыш И. М. Әлмөшев, Г. Әхмәров (Варлам), Ш. С. Вахидов, Л. И. Зөбәеров, И. Кугушев, Х. Г. Мамин (Мираватский), Ш. А. Мәүлүтов, Н. Н. Сакаев, В. Г. Фатыйхов — шулай ук «Хөсәения»дә укыйлар.

Оренбург, Казан, Уфа, Ташкент, Алма-Ата, Ашгабад, Бишкек тарафларында эшләүче мөхәррир һәм журналистлардан да «Хөсәения» шәкертләре байтак була. Мәсәлән, Рәкыйп Рәкыйби Каракалпакстанда, Гобәйдулла Хөсәенов Төркмәнстанда, Сәхи Рәхмәти белән Габдулла Биги Үзбәкстанда, Шәрәф Борһан Казагыстанда Совет матбугатына нигез салучылар булып саналалар. Илленче елларга кадәр төрле республика күләмендә басылып килгән газета-журналларда мөхәррир булып эшләүчеләр арасында без Фатих Мөсәгыйть, Лотфи Гаделев, С. Алиев, М. Гобәйдуллин, Г. Усманов, Г. Кәримов, Н. Сәйфелмөлеков һ. б. очратабыз.

Мәдрәсә стипендиатлары арасында табиб дипломы алган шәхесләр дә бар. Т. Ш. Сабитов, Г. К. Сәйфелмөлеков, Б. К. Сәйфелмөлеков, Б. В. Сөләйманов — халыкка медицина ярдәмен күрсәтү һөнәрен сайлаган шәкертләрнең бер өлеше генә.

Халык хуҗалыгының төрле тармакларында хезмәт итеп абруй казанган кешеләр арасында М. А. Атнашев, И. З. Рәмиев, А. Х. Сүнәев, И. Сүнәев, Г. С. Хисамов, А. Г. Йосыпов, Х. Г. Янбулатовлар мәгълүм.

Әлбәттә, шәкертләрнең күпчелеге халык мәгарифе өлкәсендә җигелеп эшләүче хәлфә-мөгаллимнәр, мәктәп һәм мәдрәсә җитәкчеләре, совет чоры мәгариф оешмалары җитәкчеләре арасында байтак. Алар шулай ук илебезнең төрле төбәкләренә таралганнар, татарлар күпләп яшәгән Идел-Урал регионыннан тыш Урта Азиядә мәгариф эшен җайга салучы байтак кадрлар, шул исәптән Х. Әбүбәкеров, И. Акчурин, А. Мангушев, Х. Таналин, Г. Усмановлар «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкертләре булганнар. Әйтик, гражданнар сугышы чоры комиссары Шамил Усмановның энесе Гали Усманов Төрекмәнстанда уку-укытуны заманчалаштырып оештыруда актив катнаша, соңрак ул Төрекмән дәүләт университеты доценты булып озак еллар эшли. Аларның туганы Габделәхәт Усманов исә Хәрәзм һәм Сәмәрканд өлкәләрендә җаваплы эшләр башкара. Мохтар Ибраһимов шулай ук байтак еллар Үзбәкстан башкаласы Ташкентта җаваплы эшләр башкара, тугандаш халык телендә басылып чыккан дәреслекләрне төзү

һәм язуда катнаша. Ә Кәраметдин Айдаров Сәмәрканд педагогия институтын әйдәп баручы укытучыларыннан исәпләнә. Һиндстан империясен оештыручы хан һәм галим, үзбәк шагыйре Заһретдин Бабурның «Бабурнамә» әсәренә багышланган гыйльми хезмәтен яза. Галим Айдаров исә күренекле тел галиме булып җитешә, егерменче елларда Мәскәүдә Халык мәгарифе комиссариаты бүлек мөдире вазифасын үти, республика күләмендә милли мәктәпләр эшчәнлеге белән җитәкчелек итә. Соңрак Оренбург педагогия институтында укыта.

* * *

«Хөсәения» мәдрәсәсенең мөгаллим һәм хәлфәләренең халыкны агарту буенча башкарган эшләре дә зур. Моны алар «Белек» җәмгыяте аша да, шул заманның вакытлы матбугаты битләрендә дөнья күргән күпсанлы мәкалә-язмалары аша да башкарганнар. Җәй айларында исә «Хөсәения»дә башка мәктәп-мәдрәсә мөгаллимнәре өчен белемне күтәрү курслары эшләп килгән. Аларда мөгаллим-хәлфәләрдән тыш галия сыйныфы шәкертләре дә катнашканнар: лекцияләр укыганнар, физика, химия кебек төгәл фәннәрдән практик дәресләр үткәргәннәр.

Мәсәлән, 1915 елда алдынгы карашлы яшь хәлфәләр тырышлыгы белән шундый өч еллык даими курс-мәктәп оештырыла. Ә 1917 елда исә кызлар мәктәп-мәдрәсәләре җитәкчеләре өчен дә белем күтәрү җәйге курслары ачыла. Анда уку өчен барлык губерналардан ике йөз илле биш мөгаллимә-абыстай җыела. Шушы курсларда дәрес бирү өчен «Хөсәения»нең тәҗрибәле мөгаллимхәлфәләреннән тыш Касыйм шәһәреннән абруйлы мөгаллимәләр Сара Шакулова, Гөлнур Галиева һәм Мәрьям Аимбәтовалар чакырыла. Соңгысы бу курсларның директоры итеп билгеләнә. Сара Шакулованың моңа чаклы Парижда, Сорбонна университетында белем алган беренче татар кызы булганлыгы барыбызга да мәгълүмдер.

* * *

Шунысы игътибарга лаек, «Хөсәения»дә укып дин әһеле булып китүчеләр чагыштырмача аз. Үз вакытында, «бу мәдрәсәнең йөз шәкертеннән ун мулла да чыкмый», кебек үпкә сүзләрен мәдрәсәнең җитәкчеләренә күп ишеттерәләр. «Дин вә мәгыйшәт» журналы хәтта: «Хөсәения» мәдрәсәсеннән елына бер түгел, ун елга да бер мулла чыкмый. Дини бәйрәм көннәрендә анда театр уйный шәкертләр»,— дип яза. 1917 елның маенда уздырылган Россия мөселманнары корылтаенда катнашучы дин әһелләре арасында да «Хөсәения» шәкертләре азчылык тәшкил иткәннәр. «Съезд хатирәләре» дигән китапта анда катнашучыларның исемлеге китерелә, шулардан өч кеше, алары да төрле мәдрәсәләрнең мөдәррисләре «Хөсәения»дән булып, ун имам Уфадагы «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаучылар икән. «Хөсәения»дән булган ул өч имам-мөдәрриснең икесе тиздән югары уку йортларына укытучылык хезмәтенә күчә: Заһир Дусаев 1917 елдан ук укытучылык эшен сайлый һәм озак еллар дәвамында Казан дәүләт педагогия институтының доценты була. К. Айдаров та, алда әйтелгәнчә, Сәмәрканд педагогия институтына эшкә урнаша.

Революцион рухлы яшьләр исә бу низамлы мәдрәсәдән бик күп чыга. Билгеле, шәкертләрнең рухи яктан шушындый юнәлеш алуына шәһәр тормышы, андагы революцион вакыйгалар да, хәлфәләре Сәгыйть Рәмиев, Сәгыйть Сүнчәләй кебекләрнең йогынтысы да булгандыр. Большевистик фикерле «Урал» газетасының берара Оренбург төбәгенә үз нурын чәчеп алуы да эзсез югалмагандыр. Алдынгы яшьләргә революцион юнәлеш бирүче булып балкыган «Таң йолдызы» газетасы да, гәрчә Казанда нәшер ителсә дә, рухи һә матди яктан Оренбургта ныгып, киң дөньяга шуннан борын төрткән. Чөнки аны оештыручы яшь зыялылар — «Хөсәения»гә бик якын мөнәсәбәтле кешеләр. Газетаның булачак мөхәррире Сәгыйть Рәмиевтән тыш биредә күренекле әдип һәм актив җәмәгать эшлеклесе ислахчы Гаяз Исхакый да 1902—1903 уку елында шушы мәдрәсә мөгаллиме — шәкертләрнең остазы булган иң. «Таң йолдызы» газетасының чыгымнарының байтагын үз өстенә алучы Беренче Дума депутаты, яшь сәүдәгәр Габдрахман Дәүләтшин да шушы мәдрәсә даирәсенә бик якын кеше — үз баласы булмаган Әхмәт Хөсәенов аны улы дип таныган.

Мәдрәсә хәлфәләреннән Н. Еникеевның 1913 елда ук М. Горькийның «Ана» романын, Сәгыйть Сүнчәләйнең «Марсельеза» һәм Сәгыйть Рәмиевнең «Интернационал» җырларын татарчага тәрҗемә иткәнлекләрен искә төшерү дә урынлы булыр.

Әлбәттә, башка хәлфә-мөдәррисләрнең дә татар халкын икеләтә изүдән арындырып, иреккә, яктылыкка алып чыгарга омтылуын ассызыклап үтәргә кирәк. Хәтта баштарак «Таң»чылар тарафыннан шактый ук тәнкыйтьләнгән Фатих Кәрими кебек «тормышыннан канәгать» олуг шәхесне дә яшьләр күңелендә борын тәрткән революцион омтылышка каршы бер кеше булгандыр дип раслый алмыйбыз. Чөнки аның иҗаты, карашлары, чынлыкта, шул ук Гаяз Исхакый, Сәгыйть Рәмиевләрнең мәсләгеннән читләшми.

Менә шушы җирлек, шул шартлар «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкертләренең күбесенең яңа тормыш өчен көрәшчеләр сафына килеп кушылуына сәбәпче була. Яшь хәлфәләр һәм шәкертләрнең күпчелеге унҗиденче ел вакыйгаларын өметләнеп каршы ала һәм илебезнең бөтен төбәкләрендә искелеккә каршы барган кискен көрәштә: «Һәр кеше һәм һәр милләт ирекле яшәргә, тигез хокуклы булырга тиеш!» — дигән лозунгны яклап иҗтимагый-сәяси хәрәкәткә кушыла. Соңгы ун ел эшләү дәверендә мәдрәсәдән нибары ун гына мулла чыккан булса, яңа тормыш һәм яңа власть өчен көрәш мәйданына исә йөзләгән хәлфә һәм шәкерт аяк баса. Элеккеге шәкертләр һәм хәлфәләр Кәрим Хәкимов, Шамил Усманов, Габдулла Дәүләтшин, Афзал Таһиров, Әхмәтсолтан Хәбиби, Шәһит Ходайбирдин, Гали Шәмигулов, Бәхетгәрәй Шәфиев, Сәхиулла Рәхмәтуллин, Гобәйдулла Хөсәенов, Нигъмәт Еникеев һ. б. Совет властен урнаштыруда актив катнаштылар, күренекле җәмәгать эшлеклеләре булдылар. Кәрим Хәкимов Оренбург губерна башкарма комитетында Мөселман бюросы башлыгы буларак көрәш мәйданына килсә, 1919—1920 елларда инде Төркестан һәм соңрак Бохара республикаларында большевиклар партиясе җитәкчесе буларак таныла, М. Фрунзе белән кулга-кул тотынышып эшли. Ә егерменче елларда ул Иранда, аннары Гарәбстанда илче була. Ул үзбәк, казакъ, төрекмән телләреннән тыш фарсы һәм гарәп телләрен, ул халыкларның тарихын һәм гореф-гадәтләрен яхшы үзләштергән була.

Оренбург губернасының революциядән соң тормышын «Хөсәения» хәлфәләреннән һәм шәкертләреннән башка күз алдына да китерергә мөмкин түгел: һәрбер оешма башында диярлек шулар торган. Революциядән соң барлыкка килгән күпсанлы газета редакцияләрен дә шулар җитәкләгән. Мәсәлән, «Мөхбир», «Юксыллар сүзе», «Юл», «Очкын» һәм башка газеталарның мөхәррире Заһид Йосыпов-Шәркый булган; «Хаксызлар сүзе» газетасын Афзал Таһиров оештырган; Эстәрлетамакта 1919 елда чыккан «Башкортстан» газетасын әүвәл Заһид Йосыпов-Шәркый, аннары Габдулла Дәүләтшин җитәкләгән. Элекке «Хөсәения» шәкерте һәм хәлфәсе Габдулла Дәүләтшин шулай ук тарихта Беренче Совет Башкортстанын оештыручы һәм аның беренче җитәкчесе буларак та мәгълүм бер шәхес.

Казагыстанда, Үзбәкстанда, Төрекмәнстанда, Каракалпакстанда беренче совет оешмаларын төзүче һәм оештыручылар исемлегендә дә элек «Хөсәения» мәдрәсәсендә тәрбия алган кешеләр байтак. Фатих Бакиров, Сәхиулла Рәхмәтуллин, Габдулла Мостакаев, Габделәхәт Усманов шундыйлардан. Фатих Бакиров соңыннан Ташкентта газетада мөхәррир була, аннары университет профессоры дәрәҗәсенә ирешә. Гражданнар сугышыннан соң Шәкүр Вахидов та озак еллар Урта Азия университетында укыта, профессор була. Рәкыйп Рәкыйби исә Каракалпакстанда беренче газеталар чыгаруны оештыра, озак еллар китап нәшриятын җитәкли. Гобәйдулла Сираҗи Бохара Халык республикасын төзүдә катнаша, җитәкче оешмаларда эшли. Ваис Рәхимов-Мөхәммәдниязов Бохарада партия өлкә комитетының беренче секретаре булып эшли. Саный китсәң, Урта Азия республикаларының һәрберсендә егерменче-утызынчы елларда «Хөсәения» шәкертләренең төрле-төрле тармакларда җигелеп эшләгәнлекләрен ачыклыйсың.

Күршеләребез булган Башкортстан республикасын оештыруда шулай ук мәдрәсәнең байтак кына элекке шәкерт һәм хәлфәләре катнашканын күрәбез. Аерым автономияле Башкортстан республикасын игълан итүчеләрнең башында Зәки Вәлиди, Гали Шәмигулов, Шаһит Ходайбирдин, Сәләх Атнагулов, Бәхетгәрәй Шәфиев, Шәехзадә Бабичлар торды. Егерменче, утызынчы елларда Башкортстан Автономияле Совет республикасын Афзал Таһиров җитәкләдә.

Партияле һәм партиясез барлык бу иптәшләр бар булган белемнәрен, көчкуәтләрен үзләре башкарган эш уң булсын дип тырышканнар, үзләре хезмәт

күрсәткән тәбәкләрдә тормыш алга китсен, мәдәният, мәгърифәт чәчәк атсынга вакытларын да, көчләрен дә кызганмыйча эшләгәннәр. Ләкин... бу каһарманнарның күпчелеге утызынчы еллар афәтен дә үз җилкәләрендә кичергән, байтагысының шул заманнарда гомерләре вакытсыз өзелгән. Революция еллары комиссарлары Шамил Усманов, Кәрим Хәкимов, Афзал Таһиров һәм башка бик күпләр 1937—1938 еллар корбаны булдылар. Әмма бүгенге тормыш аларның дөрес юлдан барганын раслады. Шулай итеп, җәмгыять фаҗигасе шәхесләр фаҗигасенә барып тоташа...

* * *

Әхмәт, Мөхмүт һәм Габделгани Хөсәеновлар, әлбәттә, бик тә саваплы һәм изге эшкә тотынганда — «Хөсәения» мәдрәсәсенә нигез салганда — бу мәгърифәт учагын тәмамлаган шәкертләрнең киләчәктә иске дөньяны — бу сәүдәгәрләр табынган дөньяны тәмам җимереп атачакларын башларына да китермәгәннәрдер. Алар, нинди генә алдынгы карашлы кешеләр булмасыннар, барыбер иске гореф-гадәтләргә һәм иске тәртипләргә таянган һәм табынган кешеләр. Ә шулай да бу сәүдәгәрләрнең мөсләкләре изге — халыкка хезмәт итү булган!

«Хөсәения» мәдрәсәсе 1919 елның җәенә исән-имин килеп җитә. Бу вакытта мәдрәсәне Совет власте таләп иткәнчә үзгәртү, «халыклаштару» бурычы килеп баса. 1918 елда шәһәр мәгариф бүлегенең милли мәктәп-мәдрәсәләре буенча мөдир итеп билгеләнгән Нургали Надиев җитәкчелегендә аны башта «Хөсәеновлар укытучылар институты» рәвешендә үзгәртәләр, ул шушы байлар мирасы хисабына яшәвен дәвам иттерә. Ә инде 1921 елдан соң мәдрәсә татар, башкорт, казакъ һәм башка шәрык халыклары институтлары рәвешен, бер бинада урнашкан аерым-аерым дүрт уку йорты рәвешен ала һәм 1925 елгача эшли.

Сәгыйть Хафизов

# ЯҢАЧА КАРАШ КИРӘК

«Татар әдәбияты тарихы»ның дүртенче томында совет чоры, атап әйткәндә, аның 1917—1940 еллардагы үсеше яктыртыла. Һәм бу этап түбәндәге чорларга бүленгән: Гражданнар сугышы чоры әдәбияты (1917—1920), Егерменче еллар әдәбияты (1920—1931), Утызынчы еллар әдәбияты (1932—1941). Мәгълүм бүленешкә ярашлы рәвештә китапта әдәби чорларга характеристика ясалган, жанрлар торышына анализ бирелгән һәм классикларның әдәби портретлары тасвирланган. Мондый бүленеш, мондый композиция, әйтергә кирәк, 1960 елда чыккан «Татар совет әдәбияты тарихы»нда да урын алган иде. Һәм бу урыс, тугандаш халыкларның «Әдәбият тарихлары» өчен шулай ук күптәнгә өлге булып килә. Бер караганда, тамырланган бу күренешкә каршы чыгу урынсыз дәгъва кебек. Чынлап та, әдәбият тарихын ничек бүлгәләсәң дә барыбер түгелмени? Иң мөһиме — «тарих»үзе фәнни нигезле, жанлы, кызыклы итеп язылсын! Әмма, юк шул, әдәбият тарихын чорларга бүлү формаль, техник мәсьәлә генә булып кала алмый. Ул чын мәгънәсендә методологик, фәнни-теоретик проблема рәвешен алып, безнең аңыбызда «тарих»ның гамәли рәвешен барлыкка китерүче мөһим факторларның берсенә әверелә. Шуның өстенә, академик басмаларга нигезләнеп, бездә әдәбият тарихы буенча урта мәктәп һәм югары уку йортлары өчен программалар төзү һәм дәреслекләр язу гадәте бар. Димәк, бу очракта әдәбиятның чорларга бүленеше турыдан-туры укыту эшенең нәтиҗәлелегенә йогынты ясый, методик проблема төсен ала. Шул фикерләүләрдән чыгып караганда, алга куйган мәсьәләнең, һичшиксез, гаять җитди, актуаль булуы аңлашыла. Һәм ул, безнең карашыбызча, принципиаль сөйләшүгә мохтаҗ.

Без дигәндә мин Башкорт дәүләт университетының татар теле, әдәбияты кафедрасын күздә тотам. Без анда үзара киңәшеп, совет әдәбиятының традицион бүленешеннән баш тартырга, яңа периодизация нигезендә укытырга булдык. Татар совет әдәбияты тарихын укытуның оригиналь нигездәге программасын да төзедек. Һәм мәгълүм программа яктылыгында шәхсән минем үземә «Татар әдәбияты тарихы»нда чагылыш тапкан бүленешнең «кытыршылык»лары аеруча күзгә нык бәрелеп тора.

Беренчедән, әдәбият тарихын дистә һәм аннан да азрак елларга бүлгәләү, вак чорлар белән чуарлау вакыт, заман каршында инде үзен акламый. Бу хәл әдәби күренешләрнең хаотиклыгына, кабатлануына китерә һәм эре, масштаблы үсеш тенденцияләре билгеләнә алмый. Икенчедән, әдәбиятны чорларга аеруда элеккеге зур хата — иҗат процессының үз закончалыкларына нигезләнүдән бигрәк җәмгыятьнең тарихи үсеш баскычларын күздә тотып эш итү кабатлана. Нәтиҗәдә, татар совет әдәбиятының теге яки бу чордагы әдәби хәрәкәтен характерлау башлыча аерым замандагы социаль, культура, әдәбият өлкәсеннән фактлар тезмәсе коруга кайтып калган. Татар совет әдәбиятының тасвирланган өлешендә, кызганычка каршы, фәнни проблемалылык әле бик зәгыйфь сиземләнә. Мәсәлән, утызынчы елларның әдәби хәрәкәтен яктыртканда илнең социаль-экономик хәлен, мәдәни торышына, язучыларның өешу мәсьәләләренә чиктән тыш зур игътибар бирелсә дә, татар әдәбиятының эчке үсеш закончалыкларын, язучыларның актуаль идея-эстетик эзләнүләрен, уртак иҗат принципларын барлау, билгеләү кебек әһәмиятле эш ботенләй читтә калган. Хәер,

әдәбият үсешендәге координаль күренешләрне тотып алу, андагы үзәк проблемаларга чыгу тарихи чорларны дөрес, фәнни нигездә билгеләгәндә генә мөмкин.

Әдәбиятны чорларга бүлүнең фәнни нигезе кайда? Иҗат процессында төрле-төрле баскычларны,юнәлешләрне калкыткан, ә икенчеләрен әдәбият мәйданыннан төшерткән иң мөһим фактор ничек дип атала? Әлбәттә, бу — идеология. Ләкин идеология сәнгать түгел әле ул. Монда иҗтимагый фикер һәм сәнгатьне кисештергән, тоташтырган иң мөһим ноктаны табарга кирәк. Ул, һичшиксез, кеше концепциясе!

Әдәби этаплар, чорлар алмашыну механизмын күзәткәндә нәкъ менә кешегә карата булган карашлар эволюциясенең анда көчле генератор булып торуын күрәбез. Кеше концепциясендәге һәртөрле яңарыш-үзгәрешләр образлы фикерләү өлкәсендә иске стереотипларны ватып ташлый, шәхеснең рухына, холык-фигыленә, характер сыйфатларына һәм тормыш күренешләренә карата яңа бәяләрне китереп чыгара. Шулай ук иҗат принципларында, стиль, сурәтләр системасында принципиаль яңалыклар формалаштыра башлый. Немец шагыйре һәм галим Иоһанс Бехернең мәгълүм сүзләрен хәтерләми һич мөмкин түгел: «Яңа әдәбият яңа стильдән дә, яңа формадан да түгел, ә иң элек яңа геройдан башлана».

Шул фикерләүләрдән чыгып эш иткәндә совет әдәбиятын чорларга аеру, димәк, тарихи планда кеше концепциясе эволюциясен җентекләп күзәтеп чыгу, андагы үзгәреш-яңалыкларны билгеләү ул. Әмма «Татар әдәбияты тарихы»ның без сүз алып барган китабындагы чорлар бүленешендә әлегә үзгәреш-яңалыкларның төп критерий булып торуын тану мөмкин түгел. Әйтелгәнчә, анда бүленеш социалистик җәмгыять төзелешенең этапларына карап корылган. Әмма бу — мәгълүм хезмәт авторларының гаебе генә түгел. Совет әдәбият белеме, чынлап та, әлеге этапларны совет кешесенең формалашуындагы баскычлар итеп санап килде. Иллюзияләрдән арыну өчен үзгәреш чорына килеп керергә, хәбәрдарлык дәвере нәтиҗәләрен тоярга кирәк иде. Хәзер безгә инде яхшы ачык: Октябрьдән башланган дәвер, берьяктан, безнең прогрессив әдипләрнең кешегә карата тирәннән, тарих төпкеленнән килгән иң яшерен өметләрен, тарихи оптимистик, кайнар пафослы гуманистик карашларын гәүдәләндерергә мөмкинлек бирсә, икенче яктан, социализм төзү барышында һәртөрле субъектив омтылышлар, акланган һәм акланмаган социаль экспериментлар, командачылык һәм суллык шапырынулары, шәхес ирекен чикләү, кеше рухындагы табигый, изге кыйммәтләр белән каршылыкка керделәр. Аннары совет кешесенең чын асылын бөтен тулылыгы белән ачып салган Бөек Ватан сугышы башлану, демократик нормаларны тергезергә теләп совет кешесе яшәешенә яңа рух өргән партиянең XX съезды булып узу...

Кыскасы, менә болар совет кешесенең аңына, өхлагына тирән эз салган тарихи этаплар. Татар әдәбиятында аның конкрет чикләрен ничегрәк билгеләргә мөмкин?

Октябрь социалистик революциясеннән соңгы беренче унъеллыкны без татар совет әдәбиятының тәүге дәвере итеп саныйбыз. Бу милли иҗатның гаҗәп бай, субъектив көчләр белән тоткарланмаган, буылмаган, объектив үсешле, төрле стильле, төрле юнәлешле, кызыклы, эзләнүчән, омтылышлы чоры. Революция, коммунизмның ашкындыргыч идеяләре һәм аеруча Ленин шәхесе белән сихерләнгән бу чорның һәрбер әдибе кабатланмас индивидуальлек белән аерылып тора, үзенең анык билгеләнгән шәхси стилен раслый. Әйтик, Һ. Такташ — бунтарь гыйсъянчы, соңыннан лирик реалист. Г. Ибраһимов — кырыс романтик. М. Гафури, Ш. Камал, А. Шамов кебекләре исә җиргә береккән реалистлар. Г. Камал, К. Тинчурин — сатириклар. Ф. Бурнаш, Ш. Усманов, М. Максуд әсәрләрендә революцион аскетизм идеяләре ярылып ята. К. Нәҗми, ике дә уйламый, үзен имаженист итеп белдерә, ә Г. Кутуй — футурист итеп таныта. Үзләренең кыю экспериментлары белән Х. Туфан, Сирин, М. Крымов шигырь мәйданына атыла...

Бу чорның әдәби хәрәкәтендә кискен бәхәсләр, дискуссияләр, каты сыйнфый һәм идеяви көрәш бара. Шул катлаулы процесста эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли татар совет әдәбияты формалашып, туып килә. Социалистик реализмның төп принциплары билгеләнә. Бу чын мәгънәсендә яңа әдәбиятның эзләнү һәм билгеләнү чоры.

Татар совет әдәбиятының «утызынчы еллар» дип аталган дәвере хакында безгә җитди һәм принципиаль сөйләшү кирәк. Әдәбият тарихының дүртенче

томы үзгәртеп коруның дүртенче елында доньяга чыкты. Ләкин хезмәт хәбардарлык рухына тулы җавап бирә алмый. Аның байтак өлешләре, кызганычка каршы, торгынлык чорының иллюзияле, догматик карашларыннан чыгып язылган. Утызынчы елларның иҗатына шәхес культы китергән аерым зыяннар санап үтелсә дә, ул халыкчанлык, партиялелек, ихласлылык принципларына тирән зарар ясаган фаҗига итеп тамгаланмый. Китаптагы шәхес культы турында сөйләнгән урыннар киемгә ак җеп белән типчелгән ямаулыкны гына хәтерләтә — контекстка һич тә ябышмый.

Ә гомумән алганда, китап авторлары утызынчы елларны «чын мәгънәсендә романтик, сихерле заман» итеп күрәләр һәм анда күбрәк милли иҗатның триумфаль җиңүләрен билгелиләр. Әйтик, торгынлык заманында бәйрәм докладларында яңгыраган купшы фразаларның даими кабатлануы моңа дәлил түгелмени? «Утызынчы елларда татар совет поэзиясе халык тормышын үсештә, хәрәкәттә күрсәтү, хезмәт кешесенең рухи доньясын, характерын һәм әхлагын сурәтләү юлында җитди уңышларга ирешә» (362 б.). «Поэма һәм баллада жанрлары утызынчы елларда зур уңышка ирешә»... (377 б.) «Утызынчы елларда җыр жанры да зур уңышларга ирешә»... (378 б.) «Проза һәм драматургиядә дә яңа үрләр яуланды...» (533 б.).

Кыскасы, уңышлар, уңышлар һәм, әйтелгәнчә, романтика... Тик чын романтика булды микән ул? Закон һәм команда белән куркытылган хезмәт кешесендә булганмы романтика? Көчләп колхозларга кертелеп, ачлык елларда гаиләләре белән чебен урынына кырылган крестьян массаларында булганмы бу югары күңел халәте? Яисә юк-бар гаепләр тагып репрессияләнгән, төрмәләрдә газап чиккән, үтерелгән интеллигенция вәкилләрендә, яисә репрессияләнүдән куркып үз уен, үз сүзен әйтергә җөрьәт итмәгән чиновниклар рупорына әверелгән идеология хезмәткәрләрендә булганмы романтика? Бәлки бу бөтенләй ялгандыр. Сталин заманына җайлашкан куштаннарның безнең заманга килеп ирешкән ялган бер өне генәдер?..

Мин художникның тойгыларына һәрчак тирән ышанам. Менә бит Фатих Хөсни утызынчы елларны үзе кичергән кеше. Әмма аның «Утызынчы ел» романы күптән безнең алда шул дәвернең тирән драматик, фаҗигале язмышларын ачып салган иде... Танылган тәнкыйтьче Г. Нигъмәти «Кызыл Татарстан» (1928, 13 июль) газетасында басылган бер чыгышында татар поэзиясендә төшенкелек мотивлары көчле булу турында яза. Ул яшь шагыйрь Ш. Маннурның «Безнең еллар җыры җиңел түгел, без җырлаган җырлар сагышлы»... кебек шигырь юлларын китерә дә, «Мондый кара пессимизм ноталары яңгыравын ни дип аңлатырга?»— дип гаҗизләнеп сорау куя. Ул гына түгел, утызынчы елларның байтак рәсми, купшы каләмле тәнкыйтьчеләре дә татар шагыйрьләре арасында кулак, мещан, буржуа мистикасына төшүчеләр күп булу турында һаман-һаман язып киләләр.

Утызынчы еллар тәнкыйтендәге тагын бер «зар»га игътибар итмәү мөмкин түгел. С. Борһан «Кызыл Татарстан» (1928, 26 август) газетасында басылган бер мәкаләсен «Матур әдәбиятта кризис» дип исемли: «Соңгы вакыттагы татар әдәбиятын җентеклебрәк тикшерә башласак, шаблон, маузугсызлык, төшенкелек, плакатчылык, язарга вакыт таба алмау кебек нәрсәләрне бик күп очратып була».

Татар әдәбиятындагы кризис турында «Кызыл Татарстан» газетасы алга таба да гел искәртеп килә. «Безнең юл», «Кызыл яшьләр» кебек газета-журналлар да шул турыда чаң сугалар. Милли иҗаттагы кризис күренешен Г. Нигъмәти дә таный: «Безнең язучылар арасында авыр җитди һәм зур маузугларга тотынудан качып кечкенә, вак һәм күбесенчә шәхси кичерешләргә кайтып калган маузуглар переживаниесе яхшы ук көчле күренә». Бу юллар «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 ел, 13 июль санынан алынды. Әмма бер дистә ел узгач, нәкъ шундый төшенке фикерне М. Җәлил дә кабатлый: «Безнең язучылар әле һаман хәзерге тормышның төп проблемаларыннан читтәрәк торалар, ә күбрәк шәхси тормыштагы артык типик булмаган, артык зур әһәмияте күренмәгән вак, очраклы күренешләр белән мавыгалар...» (Совет әдәбияты. 1941, 1-2 саннар, 110 бит).

Мондый фактларны искә алганда мәгълүм чор иҗатының «уңышлары» турында кычкыру килешерме? Сталинизм дәверендәге татар әдәбияты, һичшиксез, гаять катлаулы, әчке каршылыклар белән тулы, тоткарлыклы үсеш чоры ул. Тик аның чикләре кайда? Кайчан башлана бу драматик дәвер?

Әйтелгәнчә, Сталин исеме белән бәйле шәхес культы күренешләре турында фикерләүдә китап авторларына киңлек, тирәнлек җитми. Шәхес культының

зыяны турында язганда алар бер төркем язучыларның «әдәби процесстан һәм укучылардан көчләп читләштерү»не, «язучылар арасындагы дуслык мөнәсәбәтләренең нигезенә шактый зур комачаулык ясау»ны һәм иҗатта ясалма конфликтларны, «тормышны бизәп, шомартып күрсәтү омтылышының урын алуына китерү»не генә санап үтәләр. Ә бит совет иҗтимагый фикерендә күптән «сталинизм» дигән төшенчә йөри. Сталинизм — Сталин гына түгел, һәм шәхес культы гына түгел, бәлки еллар дәвамында әскорма күренешләрендә социалистик демократия принципларыннан кискен тайпылып, законсызлыклар һәм әхлакыйэтик гаделсезлекләр нигезендә формалашкан зур иҗтимагый тарихи дәвер ул.

Сталинизм дәвере әдәби хәрәкәтендә иҗади бәхәс, эстетик фикер алышулар кими, тегә яки бу иҗат юнәлеше, стиль, форма эзләнүләре йомыла, иҗат эшендә командачылык, административ йогынты ясау көчәя һәм шуларны санга сукмаган хөр рухлы язучыларга карата вульгар социологизм һөҗүме җәелә.

Үтә конкретлыкка омтылганда әлеге чорның башын РАПП эшчәнлеге җәелгән 1928 елга килеп тоташуын искәртми мөмкин түгел. 1929 елда РАППның киңәйтелгән пленумында татар әдәбияты турында доклад тыңлана һәм субъектив резолюция кабул ителә: «Революциягә чаклы татар әдәбиятының төп йөзе буржуа әдәбияты булмыйча мөмкин түгел иде... ТАПП һәм башка татар секцияләре үзләренең составларын тазартырга тиешләр».

Әлеге резолюция уңае белән татар язучылары алдында торган бурычларны билгеләп, ТАПП җитәкчесе Гомәр Гали болай дип яза: «Бөтен маскаларны ачып ташлап: «Син кем, синең сәяси йөзең ничек, нәрсәләр эшләдең һәм нәрсәләр эшләргә җыенасың?»— дигән соальне куярга». («Безнең юл», 1929, 8—10 саннар, 16 бит.) ТАПП җитәкчеләге озак көттерми, язучыларны дуска һәм дошманга аерып, сыйнфый чистарту эшен башлый.

1930 елның җәендә татар, башкорт язучыларын сискәндергән «Җидегән» уйдырмасын да сталинизмның мәкерле бер чагылышы итеп исәпләргә кирәк.

Төхфәт Ченәкәй 13 августта «Башкортостан» газетасында «Идарәгә ачык хат» бастыра, ә 19 августта бу хатны «Кызыл Татарстан» күчереп баса һәм зур шәрехнамә бирә. Газеталар татар, башкорт язучылары арасында «партия сызыгын бозып пролетариат әдәбияты һәм аның куйган принципларына каршы көрәш алып бару»чы яшерен оешма ачылды дип белдерәләр. Милли язучыларны җинаятьләрдә гаепләүләр, тормәгә утыртулар башлана. Профессор И. Таһировның «Кем ул Солтангалиев?» (Казан утлары, 1989, 4 сан) дигән мәкаләсендә билгеләп үтелгәнчә, ОГПУ органнары «Җидегән» оешмасының эшчәнлеген солтангалиевчылык белән бәйлиләр. «Җидегәнчеләр солтангалиевчылык идеяләрен таратканнар, имеш». Ләкин бүгенге көндә әлеге хәлләрнең халыкка карата геноцид политикасын үткәрү өчен корылган интригалар икәне безгә яхшы ачык.

Бу елларның вакытлы матбугатын күзәткәндә, чиновникларның матур әдәбиятка административ һөҗүмен бик ачык тоясың. Мәсәлән, Сафа Борһан яза: «Партияле язучының пролетариат идеологиясенә илтә торган бөек хезмәте әле файдалы хезмәт рәтенә саналмый. Әйтик, бер партияле язучыга сигезенче март көне уңае белән доклад ясар өчен повестка килә. Бу язучы партия комитетына барып: «Мин хикәя язамын, мине доклад ясарга җибәрмәгез»,— дисә дә, моның сүзенә колак салмау гына түгел, бик нык пешереп җибәрәчәкләр. Хәтта партиядән оторваться иткән, дигән бер караш туса да, гаҗәпләнерлек түгел...» («Кызыл Татарстан», 1928, 26 август).

Һәм бу чорда партиянең совет әдәбиятына җитәкчелек итүе аның турыдантуры язучыларга боерык бирүе дип кабул ителә. Газетадан бары бер җөмлә китерик: «Европаның 50—100 ел буена төзегән техникасын 10 ел эчендә узып китүне бурыч итеп куйган Советлар Союзының поэзиясе дә менә шул бурычны тормышка ашырганда партиянең төп юлыннан барырга һәм аның лозунгыларын ударникларча үтәргә тиеш...» («Кызыл Татарстан», 1931, 30 август.)

Мондый командачылык басымы астында нечкә иҗат дөньясы нинди югалтуларга очрый, ни дәрәҗәдә зәгыйфьлек кичерә — бу исә безне тагын да ныграк уйландыра төшәргә тиеш.

Совет әдәбиятының формалашу һәм үсү процессын өйрәнгән галим дә, әдәбият тарихын укыткан укытучы да, мөгаен, килешерләр: әдәбиятны ялангачландырган пролеткультчылык идеяләре яшь татар язучыларына да тискәре йогынты ясый, ышанычлы традицияләрдән, реализмнан читләштерә. Ләкин, күзәтүемчә, бу гарип идея-эстетик концепцияләр системасы үзенең йогынтысын үз вакытында, егерменче елларда түгел, бәлки шактый соңлап, сталинизм дәверендә көчәйтә төшә. Сәбәбен аңлау кыен түгел: егерменче елларның

сәламәт, демократик атмосферасы һәм аеруча әйдәп баручы халыкчан, партияле әдипләр Г. Ибраһимов, М. Гафури, һ. Такташ, Ш. Камал, Ф. Бурнаш черек, сектант идеяләргә тиешле отпор бирә барсалар, сталинизм дәвере татар әдәбияты мәгълүм сәбәпләр аркасында саклану, каршы тору көчен сизелерлек югалта, аны пролеткультчылыкның, вульгар социологизмның зарарлы микроблары басып ала.

Нәтиҗәдә, бу чор әдәбиятында кешене схематик, ялангачландырып гәүдәләндергән принциплар, тормыш һәм иҗат законнары белән каршылыкка кергән алымнар формалаша, тамыр җәя. Догматик эстетика, әйтик, лириканы шәхеснең субъектив хисләренә, индивидуализмга гына корылган форма итеп карый, аның объектив чынбарлыкны гәүдәләндерү мөмкинлекләрен искә алмый һәм ахыр чиктә ул совет халкына чит-ят настроениеләрне чагылдыручы жанр итеп бәяләнә. Бу чор эстетикасы романтизм сәнгатен дә реакцион итеп саный, юмор, сатираны совет әдәбияты өчен чит, ят алымнар төркеме итеп исәпли. Нәтиҗәдә, бу чор әдипләре чынбарлыкны чагылдыруның күп кенә сыналган формаларыннан мәхрүм ителәләр. һәм кайсы гына жанрны алсаң да, катлаулы заман тормышыннан, халык кичерешләреннән, тойгыларыннан читләшү тенденциясе күренә. Ике төрле дөреслек яки ярым-йорты дөреслекләр калка. Бер якта Сталин, партия чиновниклары күрергә теләгән иллюзияле дөреслек, икенче якта — халык кичергән кырыс, фаҗигале дөреслек. Язучыларның күбесе исә шуларны бер итәргә, кушарга омтыла, хакыйкатькә, намусына хыянәт итә...

Мин бу очеркта барлык язучыларны да аклап, аларны «тарих тарафыннан ихтыярсыз тагылган бәла» каршында тәмам гаепсез, «үз чорының намуслы уллары» (535 б.) итеп күрсәтүче китап авторлары белән һич тә килешә алмыйм. Чынлыкта бик күп язучыларның ялгышы да, гаебе дә зур. Менә Сталинга дан җырлау мотивын гына алыйк. Кайсы гына язучыбыз мәдхияләр укымады аңа?! Әйе, килешәм, бар, яши ул әдәбиятта идеал кешеләр шәүләсе. Әйтик, Х. Ямашев, М. Вахитов кебек ялкынлы революционерлар, Газинур, Җәлил кебек батырлар шәхси тормышыбызга ничаклы рухи ямь, мәгънә өсти. һәм җәмгыять үзенә рухи үрнәк биргән идеал шәхес, остазлардан һич тә туймый, киресенчә, ул һәрчак аларга кытлык кичерә. Әмма Сталин шәхесе тормышта ничек үз асылына туры килмәсә, әдәбиятта да аның культы хакыйкать белән каршылыкка кергән күренеш булды.

Ихтыярсыздан Пушкин әкиятендәге көзге искә төшә:

— Әйт, көзге, доньяда иң матур, иң гүзәл зат кем ул?

— Син, син, шаһзадә!— ди көзге.

Безнең аерым язучыларыбыз да шул көзге хәлендә калмаганнармы соң?

Г. Галиевның «Даһига тавыш биргәндә» исемле очеркында • шәхес культы галәмәтләрен ачкан бер гыйбрәтле эпизод бар. Сайлау участогында бер төркем хатын-кызлар төн буенча Сталин портретын чәчәкләр, тасмалар, чуклар белән бизәп чыкканнар. Инде сурәт тә, зал да купшы итеп бизәлгән. Ләкин үз теләкләре белән «кешеләр һаман бизиләр, һаман матурлыйлар...» ,

Мәгълүм чорның каләм ияләре дә әнә шул хатын-кызлар кебек кыланалар, чамасыз панегерик булып китәләр. Алар халык иҗатындагы, әдәбият арсеналындагы һәртөрле сәнгать чараларын, тропларны Сталин образын бизәүгә хезмәт иттерәләр.

Сталинизм дәвере татар әдәбиятында «үзебез хуҗа илгә бүген без» мотивы еш яңгыраса да, асылда аның каһарманнары «бөек ата» кулындагы уенчык, курчак булдылар. Әсәрләрдә ул аларның язмышларын хәл итте. Аларга «бәхет, шатлык» өләште. Аларның иң интим, яшертен уй-ниятләрен дә белеп торды, киләчәккә шәхси планнарын да корды. Әйе, әйе, байтак шигырь некъ шуны раслый: «Ә ул илнең һәрбер кешесен сынап, танып белә, һәр кайсының өметен, хыялын ул бик анык белә». Г. Кашшафның «Ана шатлыгы» (1940) хикәясендә колхозчы Нәзирә Мәскәүгә Сталин янына бөтенсоюз киңәшмәсенә чакырыла. Ул күп еллар элек югалткан улын эзли һәм менә, ниһаять, аны әлеге киңәшмәдә, Кремль залында таба.

«— Иптәш Сталин,— ди Нәзирә апа үзенең Кремль трибунасыннан ясаган речендә ифрат дулкынланып.— сөеклебез син безнең! Син безгә яхшы тормыш бирдең... Син минем ахыргы теләгемне дә үтәдең. Син улымны һәм мине чакырып китердең дә, шушы шаулаган Мәскәвдә очраштырдың».

Хикәядән күренгәнчә, «бөек ата» ана белән улның фаҗигасен белеп торган һәм менә, ниһаять, ул аларны очраштырып бәхетле иткән. «Шулай итеп, кеше

тормышларының буен һәм аркылысын Сталин дип исемләнгән яңа «алла» кисеп үтте. Хәтта Ә. Ерикәй кебекләр: «Шул исемне әйтеп йоклап китә, шул исемне әйтеп уяна»,— дип бу «алла»ны сабый җаннарына да кертеп утыртудан тайчынмадылар. Бу инде рухи бушлык һәм җайлашу иде.

Җайлашу... Кем үз намусы һәм халкы каршында иман сатып дан-дәрәҗә ала? Кем каргалган юлдан югары үрмәләгән саен кеше буларак һаман түбән тәгәри? Болар, һичшиксез, каләм көче зур булса да, карьерачы, вак җанлы, умырткасыз, зәгыйфь адәмнәр. Һәм шуңа күрә мондыйлар үз заманында ничаклы гына бу исем белән кәперәеп йөрмәсеннәр, вакыт, хакыйкать алардан изге титулны тартып ала. Ә халык үз хәтереннән җуеп ташлый.

Күпме алар, менә шундый фаҗигале әдәби язмышлар, үкенечле биографияләр, культ корбаннары! Юк, шәхес культы һич кенә дә зыянсыз була алмый. Чөнки культ буш урында тумый, туа алмый. Аның мөкерле психологиясе, талымсыз шартлары бар. Культ ул имгәнгән, кол җаннардан төзелгән пирамида башына менеп кунаклый. Димәк, шәхес культы белән янәшәдә шәхесләр трагедиясе, халык фаҗигасе ята.

Кешене чын шәхес, гражданин итүгә түгел, ә кол ясауга булышучы культ күренеше, сталинизм безнең әдәбиятыбыз өчен чиксез зарарлы иде, ул реалистик кеше концепциясе белән тирән каршылыкка керде. Аны фаш итү — репрессиясәнгән каләмдәшләребез, шул ук «минем халык каршында гаебем юк, тарих үз сүзен әйтер...» дип тулы хакыйкатьне көтеп җан биргән Галимҗан Ибраһимовлар каршында кешелек бурычын үтәү. Аны фаш итү — чын мәгънәсендә әдәбиятыбызның сафлыгы, югары идеялелеге, сугышчанлыгы өчен көрәш. Һәм шәхес культының иҗатка китергән зыяннарын ачып салу ул һич тә татар әдәбиятының казанышларын инкарь итү түгел, бәлки аның ачылмаган мөмкинлекләргә, идея-эстетик ачышларга сәләтле зур әдәбият булуын раслау.

Инде төп темага якынлашыйк. Сталинизм дәвере безнең әдәбиятта кайчан тәгәлләнә, иҗат кешесе турында рәсми-ялангач, бюрократларча фикерләүләрдән, әдәби-эстетик догмалардан ничек арына? Бу мөһим мәсьәлә турында уйланганда безгә, һичшиксез, партиянең XX съездын игътибар үзәгендә тотарга кирәк.

Ләкин Бөек Ватан сугышы чоры дип аталып, аерым өйрәнелгән дәвер белән ни эшләргә? Без Бөек Ватан сугышы елларын аерым чор итеп түгел, ә 1928—1955 елларга, ягъни социализм дәверенә нисбәтле рәвештә өйрәнергә тәкъдим итәбез. Һәм безнең кафедра мондый бүленешкә ышаныч белән карый. Чөнки сугыш еллары әдәбияты экстремаль шартлар тәэсирендә эчтән тирән үзгәрешләр, атап әйткәндә, иҗат шартлары кискенләшү, әдәби сүзнең роле үсү, вак жанрларның активлыгы көчәю һәм реализм, халыкчанлык принципларының камилләшүен кичерсә дә, формаль яктан әдәби хәрәкәт принципиаль яңалыкларга ия була алмады. Сталинизмның авыр, кара болытлары үзләрен гел сиздереп тордылар. 1944 елда кабул ителгән «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшләренең торышы һәм аларны яхшырту чаралары турында» моңа ачык мисал. Һәм сугыштан соңгы унъеллыкта да сталинизм сөреме тарала алмады. Кеше турында шул ук ялангач фикерле догматик концепцияләр, вульгар-социологизм һөҗүмнәре. Бары тик яңа дулкыннар өстәлә: сугышта ут һәм кан эчендә туган чын хисләрне танымау, төрле уйланма, сатлык теорияләргә нигезләнеп, тормышны ал да гөл итеп күрсәтүне таләп итү...

Ләкин без татар әдәбияты тарихында Бөек Ватан сугышы еллары иҗатын, мондагы казанышларны кечерәйтергә җыенмыйбыз. Ул шәхес культы чорының догматик әдәби-эстетик принципларын какшатуда беренче зур, җитди удар ролен башкарды. Шул эволюция яктылыгыннан чыгып караганда, сугыш чоры әдипләре формалаштырган ике принципиаль яңалык игътибар үзәгендә торырга тиеш.

Беренчедән, кеше турында рәсми, абстракт, схематик уй йөртү урынына конкрет-реаль фикерләү башлангычы көчәйде. «Күбрәк җанлы кешеләр, җанлы геройлар бирергә, аларның индивидуаль сыйфатларын күрсәтергә кирәк»,— дип яза М. Җәлил фронттан җибәргән бер хатында.

Икенчедән, тойгылар палитрасы киңәйде һәм хисләр тирәнлеге, ихласлылык гаҗәп көчле үсеш алды. Бу күренешнең сәбәбен Ф. Кәримнең фронттан язган хаты бик ачык аңлата: «Стройда шунысы кыйммәт, бөтен нәрсәне йөрәгең аша үткәрәсең. Минем язган әйберләрем уңышлы икән, моның төп сәбәбе шушы: канымны коеп сугышам, шуның турында хис белән язам».

Кырыс сугыш хакыйкате сталинизм формалаштырган ясалма эстетик модельне аяусыз рәвештә җимерде, яраксызга чыгарды һәм яңасына нигез салды. Сугыштан соңгы елларда фронтовик шагыйрьләр Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, С. Хәким, Ш. Маннур, Г. Хуҗиев, Ш. Мөдәррис, З. Мансур иҗатлары тирәсендә кылыч кисештерүләр милли әдәби җирлектә эстетик карашнең көчле булуы турында сөйли. Ә. Фәйзи үзенең көндәлегендә (12.1.1955.) нәфрәтләнеп бер төркем вульгар тәнкыйтьчеләр турында яза һәм: «Без аларга карап иң-иң кыйммәт тойгыларны бүген яшерикме?»— дип риторик сорау куя. Ныклы һәм ышанычлы җавап — «юк!»

Ф. Кәрим кебек фронтовик шагыйрьләрнең халык каршында абруе үсү, М. Җәлилнең фашист тоткынлыгында иҗат иткән дәфтәрләре басылып чыгу һәм дөнья җәмәгатьчелеге каршында киң танылуы да сталинизмның әдәби принципларына каршы килү иде.

Шулай итеп, татар совет әдәбияты илнең рухи өлкәсендә кискен үзгәрешләр ясаган XX съездга ныклы эчке әзерлек белән килде. Аннан соң инде татар әдәбиятында 1956—1984 елларны эченә алган, ягъни үзгәртеп кору заманына кадәр булган, бик тә кызыклы, үзенең идея-эстетик эзләнүләре һәм каршылыклары булган колачлы яңа чор башлана...

Йомгак итеп әйткәндә, укучы безнең, «Татар әдәбияты тарихы» авторларыннан аермалы буларак, татар совет әдәбияты тарихын чорларга аеруда принципиаль яңа бүленеш тәкъдим итүебезне аңлагандыр. Без аны 1917—1927, 1928—1955, 1956-1984 еллар белән билгелибез һәм бу бүлүнең фәнни нигезле, заман таләбенә яраклы булуына тирән ышанабыз. Хөрмәтле укучы, әгәр син әдәбиятыбызны өйрәнүче галим йә укытучы, яисә милли иҗатның үсеш мәсьәләләре белән тирән кызыксынучы сәнгатькяр икәнсең, рәхим итеп, бу турыда үзеңнең карашларыңны уртаклашсаң иде.

# ЯҢАРЫШ ҺӘМ САТИРА

Яңарыш рухы көчәю, тормышта тәнкыйть һәм үзара тәнкыйтькә юл ачылу соңгы елларның көлке шигъриятендә дә үзенең шифалы йогынтысын сиздерә. Элегрәк һәр әйткән сүзенә каршы күсәк көтеп гадәтләнгән шигъри сатира бүген авыз тутырып сөйләрдәй темаларга, проблемаларга үтеп керде. Илленче елларда ук баш калкытып, тора-бара тагын да тирәнрәк үсешкә ирешкән бюрократлык темасы да соңгы ун елда чор таләп иткән үзәк мәсьәләләр белән бәйләнештә үзенең яңа аспектларын ачып җибәрде. Ягъни, бер яктан бу тема «түрәкратларны», куштаннарны, ришвәтчеләрне, әшнәләрне, формальлекне күздә тотса, икенче яклап, үзгәртеп кору, яңарту проблемаларына, милләт, тел, азатлык мәсьәләләренә юл ачты.

Мондый көн кадагына суккан темалар хакында сөйләгәндә иң элек Г. Афзалның яңа шигырьләрен телгә алу кирәктер. Бюрократның көлкеле сурәтен торгызу ягыннан шагыйрьнең «Көзге алдында уйлану» әсәре кызыклы. Үзендә түрәләргә кирәкле барлык сыйфатларны туплаган типның килбәтен сурәтләгәндә автор сатирик буяуларны кызганмаган. Г. Афзал, гомумән, сиксәненче елларда бюрократлык темасына байтак әсәрләр иҗат итте. Аксөяк түрәләрдән мыскыллы көлгән «Балыкчы һәм балык турында» шигыре, эшлексез карьеристларны камчылаган парчалары шагыйрьнең фикри кыюлыгын, иҗади җитлеккәнлеген күрсәтеп торалар. Безнең бүгенге көндәге иң көчле бу сатирик шагыйребез турында соңгы елларда «Казан утлары» журналында байтак кына мәкаләләр басылды. /Кара: «Казан утлары» № 5, 1991 ел; № 12, 1991 ел; № 5, 1990 ел/.

Мондый консерватив түрәнең сатирик образын гәүдәләндерүче әсәрләр М. Саттаров, А. Буланов, Ф. Яруллин һәм башка күп шагыйрьләребез тарафыннан да иҗат ителде. М. Саттаровның халыкчан стиль белән язылган «Уйна, дустым, гармуныңны», «Эштән чыгарылган түрә бәете», «Бюрократ әби», «Чыдам Вильдан» кебек шигъри әсәрләрендә сатира угы халык белән исәпләшмәгән, калын тиреле карьеристка юнәлтелә. Түрәләрдәге «кемнең кулында — шуның авызында» дигән яшәү принцибы Ф. Яруллинның «Рәис сайлау» шигырендә дә көн яктысына чыгарыла.

А. Буланов — кыска шигырьләр остасы. Тәнкыйтьнең кан дошманы булган үзсүзле, мин-минлеге чиктән ашкан бюрократка ул «Минем урынга», «Шәптән түгел», «Искә алдылар», «Соңару» шикелле дүрт кенә юлдан торган үткен сатираларын юнәлтә. Ике генә җөмләдән торган диалогта да ул ачы рәвештә фаш итә, комик эффектка ирешә:

*— Күп акчалы, эшсез эшкә*<br>*Йөрисем килә, әти!*<br>*— Ыштыр бит! Минем урынга*<br>*Утырыр иде тәки.*

Н. Арслановның бюрократлар эшлексезлеген, әрәмтамаклыгын ассызыклаган «Бюрократлар оясында» шигырендә атап үтәргә кирәк, «Эт — эткә, эт — койрыкка» принцибы буенча яшәгән түрәләрнең эше боерыкка, формальлеккә генә кайтып калуын күрсәтә автор.

Сатира угын нәкъ бюрократның үзенә төбәгән сатира әсәрләре соңгы унъеллыкта шактый күп иҗат ителде. Аларның байтагы «Чаян» журналында дөнья күрде. И. Юзеев, Ә. Рәшитов, Р. Зәкиев, М. Хәсәен, Х. Хөснуллинның түрәләрне көлке угына алган шигырьләрен талантлы әсәрләр рәтендә атарга була. Җәмгыятьтә бюрократлыкның конкрет чагылышы булган әшнәлек, ришвәтчелек, формализм күренешләрен тәнкыйтьләүне һәрбер сатирик үзенең бурычы санады дисәк, ялгыш булмас.

Р. Зәкиев «Йөри кәгазь» шигырендә:

*Ун багана, ун ишек,*<br>*Контор саен ун мөдир.*<br>*Кәгазьләр шома йөргәндә*<br>*Кәгазь чыдар, ил бөлер,*

— ди, гыйбрәтле итеп.

Бюрократлыкка яшәү мөмкинлекләре тудыручы куштаннар галереясе инде 60—70 еллар сатирасында ук формалашкан иде. 80 нче елларда исә алар янына

«яңа вәкилләр» өстәлде. Җыелышта тәнкыйть дигәч, үзен-үзе кыйнаучы куркакжан /Ә. Фәтхетдинов «Үз-үземне»/, тәлинкә тота-тота бөкрәйгән ялагай /К. Гыйльмуллин «Лакей»/, түрәләр авызына табынган мөртәт /Н. Акмалов «Боерык котәбез»/, түрә бөкре булса, бөкрәя, сакау булса, сакаулана торган хамелеоннар /Ш. Галиев «Куштанлык»/ — әлеге типларның яңа сыйфатлары әнә шундый. Әсәрләрдән күренүенчә, мондый көлке типлар берни белән дә кызыксынмаган, киләчәк турында кайгыртмаган, аңсыз, соры, кечкенә кешеләр түгел. Аларның күпчелеге үзләренең карьерасы, байлыгы хакына дәшми, «сынык өмет итеп» түрәләргә койрык болгый, җәмгыять тормышы хакында түгел, үз кесәсен кайгыртып хәсрәтләнә.

Мондыйларның икенче бер кәсебе — каян булса да урлап-йолкып мал җыя. Мәсәлән, Г. Рәхимнең «Ләтчә» сендәге Гафый, «Койрыклы балыклар»дагы сатучы, Р. Абдулның «Ничек телең бара?» шигырендәге «үз көче белән» колхоз печәненә ия булучы Шәмсемөхәммәт, Ә. Рәшитовның «Тә-әк» шигырендәге төзелештәге барлык әйберне Плюшкин сымак өенә ташып гадәтләнгән Мәрдәгалләм, И. Хөснетдиновның «Син уйлама...» шигырендәге колхозның өч танасына акт төзеп, туй ясаучы мөдир — боларның барысы да үзләрен бик булган кешеләр дип саный. Аларның тормыш фәлсәфәсе: хөкүмәтнекен алу — караклык түгел, ә булдыклылык кына. Мондый типлар Г. Латыйпның «Үзеннән зур кашык», Ф. Яруллинның «Габдулла белән Мөнип», Н. Арслановның «Тотыла» әсәрләрендә дә кыю чагылдырыла.

Көлке типлар арасында иң куркынычлары яңарышны, үзгәрешне аңламыйча эш итүчеләр түгел, ә төсләрен тиз алмаштырырга сәләтле хамелеоннар, бүгенге көндә дә властька омтылган торгынлык варислары. Соңгы чорда мондый типларны фашлаган әсәрләрдән сатирик яктан куәте, зәһәрлеге, реальлеге белән аерылып торганы — Ә. Баяновның «И, шамакай» шигыре. Сатирик шагыйрь бүген халыкның әйдәүчесе кыяфәтенә керергә омтылган шамакайның үткәндәге кылган эшләрен фаш итә. Үз вакытында ялган отчетлар белән мавыккан, илне бөлдереп, геройлык исеме казанган типка ул:

*Үзең дә бит бирмәдең мах:*
*Хәреф җыйнап, китап язгач,*
*Алмаштырдың тышлыкларын,*
*Исемнәрен бутап тагын,*
*Нинә тапкыр булак алдың,*

— ди. Баксаң, Шамакай үзгәртеп коруда да алга омтыла. Үзендә булмаганны «намус, вөҗдан», дип сөрән сала. Автор бюрократлыкның яңа кыяфәткә керүенә игътибар итә, киләчәкне андыйлардан арындырырга чакыра.

1989 елда «Чаян» журналында дөнья күргән тагын бер гыйбрәтле эчтәлекле әсәргә тукталып китик. М. Саттаров Тукай традицияләрен дәвам итеп язылган «Күзләре ачылмаган Сталин шәкертләре ни диләр» шигырендә торгынлык чорында алданып, рухи яктан зәгыйфьләнгән халык язмышын күздән кичерә.

*Кул чаптык без күп мәртәбә,*
*Аңламыйча бер нәрсә дә.*
*Селкенмәдек таш төсле без,*
*Җилбер-җилбер җил бәрсә дә.*

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

*Юрган ябып йоклап яттык,*
*Акыл саттык, борчак аттык.*
*«Бу — ялган речь!» «Буржуаз», — дип,*
*Чын гыйлемне читкә кактык.*

— ди сатирик күз яше аркылы көлеп. Әсәрнең нәзирә жанрында язылуының өстенлеге шунда: торгынлык тарафыннан алданган халык турында сөйләгәндә автор Тукайның мәдрәсәдә томаланып яткан надан шәкертләренә ишарә ясый. Мондый ассоциатив фикерләү комизмны көчәйтә төшә, көлүне куәтли.

Җәмгыятебездә барган яңарыш рухы сатирик шигърияткә торган саен иңә бара. Тел, милләт язмышы хакында борчылу, милли азатлык мәсьәләләре дә төп проблемаларның берсе булып китте. Сатирада яңага омтылу, искене инкяр итү белән бергә, үткәндәге хаксызлыкны хөкем итү, югалтулар белән бәйле трагик мотивлар килеп керә. Г. Рәхимнең «Идел» журналында дөнья күргән «Оран» шигырендә күз яше аркылы көлү, ачы сатираның лирик уйланулар белән үрелтеп бирелгән. Шагыйрь әхлак бетүгә кайгырып, түрәләргә әле дә җил-яңгыр тимәүгә пошына:

*Алар туган илдә туган телне*
*Яклаудан да гаеп табалар.*
*«Туган телем — дәүләт теле»,— дисәм,*
*Милләтче дип ярлык тагалар.*

Икенче бер «Кыю шигырь»ендә /үземә сарказм белән/ автор эпиграф итеп газеталардагы мондый җөмләне ала: «Үзгәртеп кору елларында илдә цензура тыюлары туктатылды.» Г. Рәхим мондый күрсәтмәнең чынбарлыкта тулысынча инкяр ителүен ачып сала. Кыю шигырь язучы, «җилкәсе артында заман сулышын тоеп», әсәрне үзгәртергә мәҗбүр була.

Сиксәненче еллар көлке шигъриятендә үзенең пародияләре, эпиграммалары белән танылган талантлы сатирик Л. Леронның «Мәскәүгә хат» шигыре — үзгәртеп кору сатирасына булган таләпләргә иң тулы җавап бирердәй әсәрләрнең берсе. Эпиграф итеп шагыйрь Тукайның «Ни кылырсың... Тотса Мәскәүләр якаң?» дигән сүзләрен сайлый. Милләт горурлыгын таптап, милли дәүләт интересларын санга сукмыйча, үзәккә табынуны автор ачы сарказм белән фашлый. Сатирик шигърияттә мондый, хакыйкатьне беренчеләрдән булып кыю рәвештә ачып салган шагыйрь «безне һәрчак эткәләп һәм типкәләп» торган Мәскәү абзыйларына нәфрәтләнеп болай ди:

*Әгәр тел бик озынайса,*
*Йолкы да ташла телне.*
*Хәер, йолкып ташларлык тел*
*Калмады бугай инде.*

Ил язмышын, кешелек язмышын бәяләгән гыйбрәтле фикерләр — соңгы чор сатирик шигърияте өчен хас үзенчәлек. Өметләрдә алдануны, хыялларда адашуны бүгенге күзлектән чыгып бәяләү көлкене лирик-фәлсәфи һәм трагик мотивларга баета. М. Галиевнең «Алдану» шигыреннән мондый юлларны китерик:

*Уйный дөнья, чөеп-чөеп китерә дә,*
*Килә бер көн: шундый итеп салып таптый.*
*Корыч ирдән — аударылган һәйкәленнән*
*Сабый бөгеп сындырырлык кашык ясый.*

Күренүенчә, бу юлларда алданулар, югалтулардан күз яше аша көлү дә, чынбарлыкка гомумфәлсәфи караш та, киләчәк турындагы икеләнүле уйлар да берләшә.

Чор сатирасында урын алган киләчәк турында уйлану мотивлары, бер яктан, кешелекнең рухи мохите мәсьәләсенә бәйләнсә, икенче яктан, җирнең киләчәге, табигать язмышы проблемасына барып тоташа.

Экология, табигатьне саклау темасы 50 еллар сатирасы өчен ят булса да, 60—70 елларда ярыйсы гына эшкәртелде. Ә соңгы унъеллыкта шагыйрьләр бу проблема буенча тагын да житдирәк уйлана башлады. «Чаян» журналы битләрендә дә шактый гына әсәрләр дөнья күрде. Болар арасында күтәрелгән проблемасы, фикри колачы һәм күләме, сатирик чаралары белән аерылып торган әсәр Зөлфәт иҗатына карый. «Җирдән кайтышлый» исемле зур күләмле шигъри әсәрне автор «Жалу тикшерер өчен Кояш системасына килеп киткән «Дезинфекция» исемле Очар Тәлинкә командиры гаризасы рәвешендә тәкъдим итә. Имеш, Җир җиһан башлыкларына шикаять яза. Үзәктә — экология проблемасы, кешелек кулындагы Җирнең киләчәге мәсьәләсе.

Кешенең Җиргә мөнәсәбәте, аның язмышын кайгыртырга тиешлеген автор тикмәгә генә фантастик сюжетка төрмәгән. Образга фантастик характер бирүче интенсив комик күпертү һәм үткенләү сатира теориясендә гротеск дип атала. Ю. Борев сүзләре белән әйтсәк: «Гротеск әйберләрнең яшерен элемтәсен сурәтли, аларның эчке микъдарын күрсәтә, ә чынбарлыкта алар турыдан-туры күзәтелүчән, конкрет тоем белән торган килбәттән мәхрүм». Шагыйрь биредә гротеск алымын кулланып сурәтләрнең җанлыгына, фикер тирәнлегенә дә ирешә.

Җирнең киләчәге проблемасын кешелек киләчәге, яшь буын проблемасы белән янәшә карау Г. Рәхим иҗатында да чагылыш тапты. Табигать тапталу белән бергә яшь буынның да күңеле тузанлануга пошынып шагыйрь болай яза:

*Сары балчык...*
*Тузанлы юл...*
*Көтү таптаган ярлар...*
*Нахал оныклар үстерә*
*Без сөйгән асыльярлар.*

60—70 елларда куәтләнеп киткән эчкечелеккә каршы көрәш 80 елларда да үзенең актуальлеген югалтмады. Бу тема буенча иң актив эшләүче сатирик М. Саттаров булды. Шулай ук Ш. Маннапов, Ф. Яруллин, А. Буланов эчкечелекне фашлаган уңышлы әсәрләр иҗат итте.

М. Саттаров үз иҗатында фольклор традицияләрен, Тукай мирасын иҗади дәвам итә. Эчкечелеккә каршы язылган «Әлкәш Ибрай бәете», «Унбиш гәүлеккә утырган Бәдри бәете», «Самогончы Хафиз бәете» әсәрләре дә халыкның бәет стиленә нигезләнеп иҗат ителгән. Автор сатирик типларын фашлауны монолог алымын кулланып башкара. Аларның кылган эшләрен, җәмгыятькә һәм гаиләләренә китергән зыяннарын халыкчан гади тел белән үзләре тарафыннан сөйләтә.

Ш. Маннаповның «Үз каланчасыннан», «Сәлам белән Аракын», «Дару гына» әсәрләре дә эчкечелек кебек куркыныч социаль чирнең асылын ачып сала. Аракы кешене рухи яктан гына зәгыйфьләндерми, ә аның яшәү энергиясен, сәламәтлеген ала, аны даруга илтеп тери, дигән фикер үткәрә автор.

Ф. Яруллинның «Эше бетми», «Колхоз гаражында» әсәрләрендә эчкечеләрдән көлү, фашлау алымы фикернең кисәк борылышына нигезләнгән. Беренче әсәрдә сатирик бөтен әйберен төзәтеп кенә торган Миңхәтне эшчән кеше дип мактагандай итә. Баксаң, ул «Айнык чакта төзәтә, исерек чакта вата» икән...

Соңгы ун ел дәвамында көлке шигъриятенә нинди дә дәрәҗәдә өлеш кертмәгән һәр шагыйрь гаилә-мәхәббәт темасына әсәр иҗат итми калмады, дисәк, хата булмас. Шулар арасында үзенең көлү талантын шушы темада ачкан шагыйрьләрне аерым атарга да була. Болар Г. Рәхим һәм Ф. Яруллин.

Г. Рәхимнең көлке шигырьләренең бер өлеше юмор өлкәсенә караса («Кыз яулау», «Сөю китсә», «Һади кызы», «Көйләндем»), икенчеләре — кешенең әхлакый кимчелекләрен камчылаучы «Эт белән Мәче кебек», «Рас әйтте», «Үтә кайгыртучанлык», «Гел яңача» кебек әсәрләр сатирик фашлау көченә ия. Ир белән хатын, кыз белән егет мөнәсәбәтендәге төрле каршылыкларны чәнечкән мондый шигырьләрендә автор сатирик чаралар, комик эффектка ирешү ысуллары белән гаҗәеп оста эш итә. Фикерен матур төсләргә, җанлы сурәтләргә төреп бирергә яраткан шагыйрь җор чагыштырулар, күпертеп сөйләү алымын эшкә җигә. Сатирик үткенәйтү һәм аңлы рәвештә зурайту сурәтләнә торган социаль күренешнең аеруча мөһим индивидуаль һәм гомуми сыйфатларын калку итеп күрсәтә, аны күз белән күреп, конкрет тоярга мөмкинлек бирә. «Эт белән мәче кебек» дигән шигырьдә ир белән хатын арасындагы каршылыкны иң киеренке ноктага илтеп терәгән «бозау кадәр бер мәче» һәм хатынның мәчесен өзгәләргә ир тарафыннан сатып алынган «ат кадәр эт» арасындагы мөнәсәбәт бөтенләй котелмәгәнчә корыла. Эт белән мәченең дуслашуын күреп:

*Карап тордым да аптырап,*
*Кычкырдым аяк тибеп:*
*— Хатын, яшик әле шушы*
*Эт белән мәче кебек!..—*

ди ир кеше түземлеген җуеп. Халыктагы «эт белән мәче кебек» фразеологик тезмәсенең күчерелмә мәгънәсе белән реаль хәл арасындагы капма-каршылык бирәдә көчле комик эффект тудыра.

«Гел яңача» шигыре дә шушы ук алымнар нигезендә иҗат ителгән. Шәһәрдән кайткан Гөлмәрфуганың загссыз яшәргә теләвен шатланып кабул иткән ир-ат, бала ташлап чыгып качкан хатыныннан алимент юллап судьяга баргач болай була:

*Судья минем паспортымны сорап ала,*
*Бер актара, өч актара, биш актара.*
*— Синең бит,— ди, загсың юк, Сәпәр туган,*
*Загссыз,— ди,— бала синдә каян булган?!*
*Бәлки балаң ул хатыннан булмагандыр,*
*Җилдән-фәләннән тумагандыр?!*
*Ярдәм итү авыр,— ди ул,— син кәмиткә,*
*Загс кирәк, Сәпәр туган, алиментка...*

Г. Рәхимнең сатирик шигырьләре дә күңелле сурәтләргә, юморга бай. Халыкчан стиль, гади сөйләм образларны җанландыра, сурәтләрне реаль итә. Ир-хатын мөнәсәбәтеме ул, сөю, мәхәббәт хәлләреме — шагыйрь тормыштагы мөһим күренешләрне тотып ала, аның сурәтләнгән вакыйгалары, әйткән фикере һәрчак тормышчан яңгырый. Алар афоризмга тиң.

*Өйләнгәнче:*
*Мин бала булсам иде дә,*
*Син курчак булсаң иде.*
*Өйләнгәч:*
*Син карбыз булсаң иде дә,*
*Мин пычак булсам иде.*

Үткен каршы кую нәтиҗәсендә дүрт кенә юлга шагыйрь олы бер тормышны сыйдыра алган.

Кечкенә күләмле «Гаилә рифмалары»нда да «ата» һәм «хата», «бала» һәм «бәла», «хатын» һәм «сатыйм», «малай» һәм «давай» сүзләре аша гаиләдәге катлаулы мөнәсәбәтләргә, каршылыкларга ишарә ясый автор. Күренүенчә, ул комик эффектка ирешкәндә авазлар гармониясе, сүз яңгырашы, аның күчерелмә һәм туры мәгънәсе белән оста эш итә. Сүз уйнатуны бик тә урынлы куллана:

*Төшендем мин синең асылыңа:*
*Кеше менә шулай асылына*
*Ефәк тасмаларның асылына.*

Гаилә-мәхәббәт темасы Ф. Яруллин иҗатында яңа аспектлары белән ачылып китә. Ир-хатын мөнәсәбәтеннән тыш, аталар һәм балалар, киленнәр һәм каенаналар арасындагы каршылыкларны үзәккә ала аның әсәрләре. Сатира угы өч хатынга алимент түләүче «мәхәббәт корбанын» да /«Мәхәббәт газабы»/, уңган иргә чыгарга хыяллаган эшлексез кызларны да /«Үпкәләттем кызларны»/, власть өчен гауғалашкан ир белән хатынны да /«Белми алар»/, кушылган эшләрне әбиләренә аударып гадәтләнгән оныкларны да /«Кечкенә кеше»/, балаларын анасына ташлаган Әлфинурны да /«Гомер-гомеркәйләр»/, үзендә булмаган сыйфатларны булачак кияүләрдән таләп итүче Гөлзәбирәне дә /«Таләбе бик югары»/ өлешсез калдырмый.

Шунысы игътибарга лаек: Ф. Яруллин тапталган сюжетлар, кабатланган вакыйгаларны читтә калдыра. Аның фикер юнәлеше дә, фашлау объекты да үзенә кадәрге сатирада очрамый диярлек. Мәсәлән, «Алмашыну» шигырендә автор Сания белән Даниянең татулыгын, бөтен нәрсәләрен, хәтта ирләрен дә алмашып яшәүләре турында сөйли.

*Үтте айлар, үтте еллар,*
*Бетте әйбер алмашырга,*
*Калды бары йодрык кына*
*«Алмашырга», «аңлашырга».*

Әйтергә кирәк, Ф. Яруллинның көлке шигырьләре кимчелекләрдән дә мәхрүм түгел. Автор кайчак фикерне озынга суза, күпсүзлелектән котыла алмый. Бу исә сатираның көчен киметә төшә, тәэссезләндерә. «Сатирик әсәрләр өчен төп таләпләрдән берсе — кыскалык. Кирәгеннән артык озынга сузу, күпсүзлелек шигъри сүзнең эмоциональ көчен киметә»— , дип бик дөрес язган иде сатира белгече Ү. Гыймадиев.

80 еллар шигъри сатирасындагы гаилә-мәхәббәт темасы хакында сөйләгәндә Ш. Маннаповның соңгы елларда дөньяга чыккан «Дәште кызый», «Жигули», «Импорт», «Элек һәм хәзер» кебек тормыш ыгы-зыгысын, яшь гаиләләр проблемасын эченә алучы әсәрләрне атамый үтеп булмый. Автор бүгенге яшьләр, киләчәк гаиләләр турында борчыла, әхлакый бозыклыкны кешенең тышкы матурлыгына, саф мәхәббәтне рухи бушлыкка каршы куя. «Дәште кызый» шигырендәге лирик герой, мәсәлән, үтеп баручы кызның сынына, гүзәллегенә соклана. Яхшы егеткә тап булсын иде, дип кенә изге теләктә торганда, кызның аңа: «Эй, ты козел, дай-ка закурить!»— дигән сүзләре әсәрнең үзәк ноктасын тәшкил итә. Мондый гүзәллек белән тәрбиясезлекнең килешмәс капма-каршылыгы, тышкы ялтырау һәм эчке бушлык арасындагы контраст үткен сатира тудыра. Мондый каршылыкка корылган шигырьләр рәтендә соңгы елларда «Чаян» журналында дөнья күргән И. Мулллануров әсәрләрен дә атарга була. Автор нечкә билле сылу кызларның ялкаулыгын ачып сала, андыйларны сорыкортка тиңли.

Гаилә-мәхәббәт проблемаларын эченә алган шигырьләр «Чаян» журналында шактый күп басыла. Хәзерге вакытта махсус таныштыру бюролары эшләве мәгълүм. Газета-журнал битләренә күз төшерсәк тә, «төскә матур, һәртөрле кимчелекләрдән азат» кешеләрнең үзләренә тиң яр эзләвен күрәсең. С. Гәрәеваның «Кәләш эзли Ханнан» шигыре дә шушы уңай белән язылган. Булган кәләш эзләүче Ханнан үзен гел яхшы яктан гына характерлый:

*Язмады нича ел эшләргә теләмәгәнен,*
*Үзенең өч баласына алимент түләмәгәнен,*
*Көн саен сыра залында типтерен гүләгәнен.*

Шушы рәвешле үзен яхшы итеп танытырга уйлаган типның чын йөзе ачып салына. Сатира буенча белгеч С. Бочаров сүзләре белән әйтсәк, көнкүрештә һәрвакыт очрап торган күренешләрнең эчке нигезсезлеген сатирада күпкә калку итеп тоярга мөмкинлек бирелә.

Кызганыч, соңгы чорда шигъри сатирада бала тәрбияләү мәсьәләләрен, яшьләр проблемасын үзәккә алган әсәрләр бик сирәк очрый. Ә бүгенге көн өчен болар бик тә актуаль бит. Яшьләр тормышында кимчелекләр күп. Наркоманлык, эчү, тарту дисеңме, һәртөрле хулиганлык, җинаять — болар барысы да тәрбиясезлек нәтиҗәсе. Сатира объектын менә шуларга да юнәлтәсе иде. Бүгенге сатираның бу өлкәдә пассив булуы — зур җитешсезлек, билгеле.

Сиксәненче еллар көлке шигъриятенең тематик киңлеге кыска шигырь, эпиграмма, пародия жанры аша да раслана. «Пычак кебек үткен шигырь белән мин суярмын сине, халтура!» — дип чыккан Г. Рәхим иҗаттагы һәртөрле күз буяучылыкка, «акчачылыкка», сәләтсезлеккә, исем-дан артыннан кууга сатира уты ача.

Г. Рәхим белдекле тәнкыйтьчеләр, «пешмәгән» шагыйрьләр белән кырыс телдә сөйләшә. Мондый әсәрләргә көчле сатирик эффект, фикер үткенлеге хас. Поэзиядәге күпсүзлелеккә, фикер чуарлыгына, чиктән тыш абстрактлылыкка каршы һөҗүм итүче мондый әсәрләр автордан стильләштерү осталыгын да, уй үткенлеген дә таләп итә.

Л. Лерон пародияләре исә бүгенге шигърияттәге һәртөрле негатив күренешләрне, бер үк фикернең күп авторларда кабатлануын, әсәрләрнең реаль җирлектән ерак китүләрен, уй-фикернең эзлексезлеген, иҗатта ихлас булмауны тәнкыйть итә. Шагыйрь үзе ЭВМ сыман; ул йөзләрчә-меңнәрчә шигырьләрнең юлларын исендә тота, иҗади урлашу, хәрамләшүне шундук эләктереп ала.

Л. Леронның эпиграммаларына портретлар җанлылыгы, уй үткенлеге хас. Боларында да автор каләмдәшләренең күзенә карап, кимчелекләрне ярып сала.

Күреп үтүебезчә, бүгенге көлке шигъриятенең тематикасы шактый киң. Шулай да, көлке шигъриятенең көчләрен милли азатлык һәм тел, мәдәният, яшьләр әхлагы, табигатьне саклау кебек көнүзәк булган мәсьәләләргә ныграк җәлеп итәсе иде. Милли сатирабызның киләчәге тагын да ышанычлырак булсын!

**Ләйсән КӘШФИЕВА,**
**филология фәннәре кандидаты.**

**Мәсгут Гайнетдинов**

# XVIII ЙӨЗДӘ ТАТАР ЯҢАРЫШ ХӘРӘКӘТЕ

## Чукындыру: гамәл һәм нәтиҗәләр

Татар яңарыш хәрәкәте турында кемнәр генә нинди фикер әйтмәгән! Берберсенә каршы килүчеләр дә, бер-берсен инкяр итүчеләр дә бар. Ул хәрәкәтнең чикләрен билгеләүдә генә дә фикер аерымлыклары кимендә ике гасырга сузыла. «Мостафадел әхбар»да һәм «Асар»да Ш. Мәрҗани белән Р. Фәхретдинов Болгар, Алтын Урда заманыннан XVII йөз азагына кадәр араны «сикереп» үтәләр, ул аралыктагы вакыттан материаллар сакланып калмаган диярлек. Иванай, Җансарый, Юныс Орувилар кебек XVII йөз азагы кешеләре, Мортаза Симети, Мансур Борындыкыйлар кебек XVIII йөз башы укымышлылары бу хезмәтләргә, татар тормышында кабат җанлануның беренче хәбәрчеләре буларак килеп керәләр. Шул яңару вәкилләре төсендә тәкъдим ителәләр. Ягъни, Мәрҗаниләр карашынча, татар тормышында яңару билгеләре XVII йөз азагы — XVIII йөз башларында күренә башлый. Казанда гарәп хәрефләре белән татарча беренче басма китаплар чыгаручы (XIX йөз башы), Г. Бурашов, И. Хәлфиннәр даирәсе дә, чыгарган китапларына караганда, шундый ук фикердә торганнар. Әмма XIX йөз башларында төрле төбәкләргә сибелеп яшәгән Г. Утыз Имәни, Г. Курсави, Әбелмәних Каргалый, Кандалый кебек укымышлыларның инде XVIII йөздә яшәгән элгәрләре белән бәйләнешләрен «оныта» башлаганлыкларын күрәбез. XIX гасырның соңгы ун-унбиш елында боларның үзләрен дә «онытталар». «Татар тормышында яңару хәрәкәте Ш. Мәрҗани эшчәнлегеннән башлана»,— дигән яңа караш мәйданга чыга. Мәрҗани шәкертләре һәм мәктәпләргә яңа аваз методын кертү өчен көрәшүче беренче буын җәдитчеләр шул карашта торалар.

1905 ел революциясеннән соң туган телебездә вакытлы матбугат барлыкка килә. Гәзит-журнал битләрендә инде яңару хәрәкәте күпчелек очракларда 1905 елдан башланды, дип күрсәтелә башлый. Бу караш әдәбиятка да килеп керә.

Октябрь революциясеннән соң, татарларда яңару (Г. Ибраһимов аны «интибаһ» — «уяну», «күз ачу» чоры дип атый) башлап Ш. Мәрҗани, К. Насыйриләр эшчәнлегендә күренде, дигән бердәм караш урнаша. Әмма конкрет фактларга мөнәсәбәттә бу чик бик җиңел генә теге яки бу якка күчерелә. Мәсәлән, XX йөз башы әдәбияты турында сөйләгәндә, Г. Тукай, Ф. Әмирхан h. б. татар тормышында яңаруны башлап җибәрделәр, дип күрсәтелә. Г. Курсави турында сүз чыкса, яңаруның чиге шундый ук җиңеллек белән XIX йөз башына да күчерелә.

Яңаруның мәгънә эчтәлегенә карашта да шундый ук күптөрлелек хөкем сөрә. Бер урында аны схоластиканы җимерә башлау дип, икенче очракта культура нигезе булган укыту системасын үзгәртү яки тормышка эстетик мөнәсәбәтнең искергән традицион формаларын төптән үзгәртү, дип билгелиләр.

Мәсьәләгә караштагы бу күптөрлелек өлешчә татарлар арасындагы иҗтимагый хәрәкәтләрнең тарихи үзенчәлеге белән аңлатыла. Абсолютизм шартларында татар халкы җәмгыятьнең иң түбән катламнарында калдырылган була. Колониаль халыклар арасында җанлану, хәрәкәт омтылышы дәһшәтле эзәрлекләүләргә дучар ителә. Менә шул сәбәп тәэсирендә, татарлар арасындагы прогресс көрәшчеләре үзләре үк, халыкны законсыз эзәрлекләүдән саклау өчен, бу хәрәкәтләрнең

---

Мәсгут ГАЙНЕТДИНОВ (1929) — *галим, филология фәннәре кандидаты, «Давылларда, җилләрдә» китабы һәм күп кенә гыйльми хезмәтләр авторы. Казанда яши.*

билгеләрен, эзләрен яшерергә, дөньяга чыгармаска тырышканнар. Бу хәл үткән гасырның икенче яртысында матбугат эшләре активлашканга кадәр, ә өлешчә исә вакытлы матбугат мәйданга чыккан көннәргә чаклы шулай дәвам иткән. Шул рәвешчә, хәрәкәт турындагы мәгълүматның азлыгы аңа башы, дәвамы, азагы күз алдында булган тулы бер процесс итеп карарга комачаулый. Яңалык өчен көрәшнең кискенлеге дә яңарыш чикләрен һәрчак шул соңгы дәвер кинлегендә генә алырга мәҗбүр иткән. Аңарчы булган бик күп фактларның бу дәвер белән бәйләнеш җепләре, кызганыч ки, игътибардан читтә калдырылган. Нәтиҗәдә Ш. Мәрҗани шәкертләре, җәдитчеләр, XX йөз башы эшлеклеләре — һәммәсе үзләре яңаруны башлаучылар рәвешендә мәйдан тотканнар.

Югарыда бәян ителгән мәсьәләгә караштa тәгәлсезлекләрдән котылу өчен, иң башта «яңару»ның үзен төгәл билгеләмә белән чикләргә кирәк. Яңару дигәндә, схоластика, мәктәп, әдәби-эстетик формалар үзгәрү һ. б. түгел, бәлки, барлык халыклар тарихындагыдай, урта гасырчылыктан (феодализмнан) арыну, капиталистик үсү юлына чыгу, шул хәрәкәтнең тарихи юлы күз алдында тотылырга тиеш. Ә бу «урта гасырчылыктан арыну» хәрәкәтенең башы, баскычлары исә татар халкы тарихында, аеруча аның мәдәни үсешендә шактый ачык күренерлек уелып калган.

Казан ханлыгын җимерү белән бер үк вакытта Мәскәү дәүләте татар феодал сыйныфын юкка чыгару сәясәтен дә актив үткәрә башлый.[1] Төп терәк булган сыйныфның җимерелүе татар урта гасырчылыгын җитди тетрәтә. Иҗтимагый тормышта игенчеләрнең әһәмияте күтәрелә. XVI гасырның икенче яртысыннан башлап туктаусыз дәвам иткән халык хәрәкәтләре мөһим тарихи эчтәлек белән байый. Шул үзенчәлекләрнең чагылышы буларак, рухи тормышта демократик башлангычлар өстенлек итә башлый. («Чура батыр», «Сәйфелмөлек», «Чыңгызнамә» һ. б.).

Беренче Петр чоры — татар феодал сыйныфын юкка чыгаруда яңа сәхифә, бер үк вакытта, татарлар арасында ачыктан-ачык көчле яңару хәрәкәте башланып китүгә дә җирлек булды. Әмма бу хәрәкәт, царизм эзәрлекләве нәтиҗәсендә, гадәттән тыш озакка сузылып, төгәлләнмәгән хәлдәге 4—5 баскычка бүленә:

1. Петиция хәрәкәте һәм яңару омтылышының царизм тарафыннан тар-мар ителүе (1713—1753).
2. Халык күтәрелешләре чоры (1755—1790).
3. «Абыз агайлар» — крестьян укымышлылары хәрәкәте (1790—1840).
4. Ш. Мәрҗани, К. Насыйрилар чоры, тамырланып тотрыклы кысалар пәйда булу (1840—1890).
5. Җәдитчелек хәрәкәтенең башлануы (1890—1905).

Хәрәкәтнең беренче дәверендә яңа төр «йомышлы татарлар» катлавы һәм «ясаклылар»ның «йомышлы» өлеше зур активлык күрсәтә.

Әйткәнебезчә, Беренче Петр заманы татар җәмгыятендә дә көчле яңару хәрәкәтен башлап җибәрә. Бу хәрәкәтнең элгәреге дәвере шундый зур тетрәнеш чыгара ки, самодержавие кимендә ун ел чамасы (1742—1753) турыдан-туры аңа каршы чаралар күрергә мәҗбүр була.

Петр чоры яңалыкларын күтәреп алырлык социаль көч татар җәмгыятендә дә була. Ул социаль көч — шул чорда формалашкан яңа төр йомышлы татарлар төркеме иде.

Русиядә, социаль төркем буларак, йомышлы татарлар XIV—XV йөзләрдә үк формалаша башлый. Аерым татар феодаллары хан яки бәрәр көчле морза белән конфликтка керә дә, эзәрлекләнүләрдән качып, күрше урыс кенәзләренә хезмәткә үтә. Урыс кенәзләре, аеруча, Мәскәү дәүләте андый феодалларны бик хуплап каршы алганнар. Эре феодаллар мөстәкыйльлегенә, таркаулыкка каршы көрәштә Мәскәү кенәзләре шул «йомышлы» («служивый») татар феодалларына да таяна.

Русиядә шуннан соңгы гасырларда йомышлы татарлар күбәюне архивтагы «Кырым йорты» эшләре»нә карап та билгеләп була. Анда Мәскәү дәүләте белән Кырым арасындагы атчабарларның, тылмачларның байтагы татар икәнлеге күренә. Кырымга барып кайткач, башкарган эшләре өчен хезмәт хакы итеп аларга кайчак утарлар да бирелгән. Шул рәвешчә, Дала чиге буенда — Тамбов, Воронеж губерналарында билгеле байтак йомышлы татарлар төркеме барлыкка килә.

---

[1] Газиз Г. Татарларда сыйныфлар тарихы. М. 1925. 6—7 б.

Бу татарлар арасында атчабарлык, тылмачлык вазифасы атадан балага, аңардан оныкка күчкән, күрәсең. Мәсәлән, 1499—1505 еллар арасында Тәвәккәл дигән татар Иван III тапшырган йомыш белән ике мәртәбә Кырымга барып кайта.[1] Ә 130 елдан соң шул ук эштә Мостафа Тәвкилев дигән кешене очратабыз.[2] Петрның Бессарабия походында (1711) катнашкан тылмач Алексей (Котлымөхәммәт) (1675—1764) Тәвкилев тә шул ук нәселнең дәвамы булырга тиеш.

Төркия, Иран, Урта Азия, Казагыстан, Кавказ ханлыклары белән бәйләнештә һәм ерак Себерне үзләштерүдә дә татарлар төрле йомышка (атчабар, тылмачлык) тартылганнар. Аларның бу ерак илләргә сәяхәттә мөһим роль уйнаганын, мәсәлән, Англия сәяхәтчесе Җенкинсонның 1557—1559 елларда Хива һәм Бохара ханлыкларына сәяхәте мисалында күрергә була. Урал елгасы тамагында тылмач татар бу экспедицияне һөҗүмнән, һәлакәттән саклап кала.

Әмма XVII йөздә үк инде царизм татар феодалларының бу төркеменә каршы да хәлиткеч һөҗүмгә күчә. Беренче чиратта, төп татар җирләреннән читтәрәк яшәгән татар алпавытлары юкка чыгарыла. Касыйм ханнары әледәнәле чукынырга мәҗбүр ителәләр. «Шура» хәбәренә караганда, 1629 елдан Ярослав губернасы Романов өязендәге татарларны чукындыру башлана.[3] Бу татарларның чукындырудан саклауны сорап 1647 елда патшага язган зарлары сакланып калган. Һәм, ниһаять, 1681 елда Низовой (Югары Волга) шәһәрләре районында яшәгән татарларны чукындыру турында хәлиткеч указ чыгарыла. Көньяк чик районнары да (Воронеж, Тамбов) бу указ тәэсиренә тартылалар.[4] Фаҗигале бу процессның барышын, мәсәлән, «Исторические акты, относящиеся до обращения в христианство при царе Федоре Алексеевиче князей, мурз татарских...» (1681) дигән китаптагы материалларга карап, өлешчә күз алдына китереп була.

Реакцион руханилар бу чараларны, гомумән, татарларга каршы һөҗүмгә сигнал дип кабул итәләр, читрәк өлкәләрдә татарларга каршы погром башлап җибәрмәкче булалар. Мәсәлән, Тобольск митрополиты Павел 1685 елда, татарларны бу шәһәрдән читкә куу турында рөхсәт сорап, хөкүмәткә мөрәҗәгать итә.[5] Мондый эзәрлекләүләрнең җиле Идел буе татарларына да сизелә башлаган, күрәсең, патшадан яклау сорап Ишбулат абыз, Надирша Шигаев дигән иптәше белән Мәскәүгә барып, 1682 елда бистә Казан татарларын «служилый» итеп санау турында грамота алып кайта. Ул грамотада, патшага хезмәтләре өчен, бистә татарларына акчалата һәм икмәк белән хак бирелмәстән, стрелецлар кебек, хезмәттән азат вакытларында һәртөрле һөнәр һәм сәүдә эше белән шөгыльләнү һәм сәүдә пошлинасы түләү тиешлеге күрсәтелгән була. Шул грамота буенча, бистә татарларының гаризасы нигезендә, Ишбулат абыз бистә мәчетенә мулла итеп билгеләнә.[6] 1749—1750 еллар ызгышларында үз хокукларын исбатлауда Ишбулат абыз грамотасы бистә татарлары кулында аз санлы юридик документларның иң мөһимнәреннән берсе була. К. Насыйрилар телендәге «Ишбулат мулла заманы» дигән гыйбарә дә шул вакытларда мәйданга чыккан, ахры.

Татар йомышлыларының тагын бер төркемен элеккеге Казан ханлыгы морзаларының сакланып калган токымнары тәшкил итә. Билгеле булганча, Казан алынган көннән башлап рус хөкүмәте халыкны сәяси берләштерүгә сәләтле татар феодал сыйныфын — морзаларны бөтенләй бетерергә йөз тота. 1553—1557 ел чуалышларында гына да 1560 бәк һәм морза юк ителә.[7] Мәскәү яклы булган татар феодалларының күренеклерәкләре исә, хезмәткә чакыру сылтавы белән, дәүләтнең көнбатыш районнарына күчереп урнаштырылалар. Үз халкы белән бәйләнешләре өзелгән мондый феодаллар икенче-өченче буында ук инде фамилияләре буенча гына татар булып калалар.[8] Ә татар җирлегендә калган эре һәм вак феодаллар, дәүләт тарафыннан оста оештырылган әхлакый-сәяси һәм икътисадый кысрыклаулар, эзәрлекләүләр тәэсирендә, шундый ук тизлек белән юкка чыга баралар. Әмма бер үк вакытта урыс хөкүмәте аерым татар феодалларына хезмәтләре өчен җир һәм төрле льготалар биргәләп торырга да мәҗбүр

[1] ЦГАДА, 123 ф. II-төпләм, 798, 1105 б. б.
[2] Шунда ук, 123 ф. I-төпләм, 18 эш, 1629 б.
[3] «Шура», 1908, № 22, 682 бит.
[4] П. С. З. (Полное собрание законов), II т. 315 бит. № 867.
[5] Малов Е. О татарских мечетях в России. Казань, 1868, 25 бит.
[6] ЦГАДА: 248 ф. 14 оп., 803 эш, 958—960 бб.
[7] Г. Газиз. Татарларда сыйныфлар тарихы. 6—7 бит.
[8] Никольский Н. В. Конспект по истории народностей Поволжья. Казань, 1919. 24 б.

була. Мәсәлән, чирек гасыр буе диярлек зур восстаниегә житәкчелек иткән жинелмәс Жангалигә каршы сугышта катнашкан һәм аны тотып, хөкүмәт кулына тапшырганы өчен, йомышлы морза Уразгилде һәм Чүрүчәй Хужашка Казан өязендә утарлар бүләк ителә.[1] Хөкүмәт сәдакасын эләктерә алган башка морзаларның «хезмәте» дә, ул шартларда нәкъ шул характерда, үз халкына зыян китерүгә генә юнәлтелгән була алган. Шул «хезмәт»ләр үк инде бу морзаларны сыйныф яки милләт вәкиле буларак түгел, күбесенчә сыйнфый, милли йөзен югалткан арзанлы ялчы итеп таныталар.

«Йомышлылар»ның санап үтелгән төркемнәре аларның морза өлешен тәшкил итә. Әмма XVII йөздә үк инде йомышлыларның башкарак характердагы һөнәрче һәм игенче төркемнәре дә формалаша башлый. Югарыда дәүләтнең төрле (йомышларына) тартылып та, вак һөнәрчеләр — податныйлар саналып килгән Казан бистәсе татарларының, Ишбулат мулла алып кайткан указ нигезендә, 1682 елдан рәсми рәвештә йомышлылар катламына күчерелгәнен күрдек.[2] Йомышлыларның үзенчәлекле зур бер төркеме көнчыгыш төбәкләрдә, Казан өязендә, Кама аръягында, Оренбург далаларында, Урал буе төбәкләрендә барлыкка килә. Воронеж ягы йомышлыларыннан аермалы буларак, боларга хезмәтләре өчен жир һәм крепостнойлар бирелми. Алар игенче катламының үзенчәлекле бер төркеме булып калалар. XVII йөз урталарыннан башлап ук инде бу төркем йомышлылар татар ижтимагый хәрәкәте[3] үзәгендә тора башлый, дип уйларга нигез бар. Көнчыгыш йомышлыларының бу активлыгын хөкүмәт вәкилләре дә үз вакытында билгеләп үткән.

Бу төркем арасында, XVII йөздә үк яңа типтагы (морза булмаган) йомышлыларның ижтимагый һәм фикри традицияләре формалаша башлый.

Беренче Петр дәвере реформаларын кабул итә һәм куәтле алырлык социаль көч татарда нәкъ менә шул йомышлылар булдылар. Бу дәвердә феодаль-патриархаль экономика, тормыштагы йомыклык татар феодал сыйныфы өстенә ябырылган какшаткыч һөжүмгә юлыга. Идел буе игенче хужалыклары ирексездән шактый көчле сәүдә мөнәсәбәтләренә тартыла. Гаскәрне драгун һәм йөк атлары белән тәэмин итү, армиягә һәм яңа башкала Петербургка кирәкле азык-төлекне житкереп бирү, беренче чиратта, зур су юлы буендагы уңдырышлы жирләрдә яшәгән Идел буе крестьян хужалыкларына йөкләнә, алардан икмәк сатып алу эше дә оештырыла. Чирек гасыр буе туктаусыз дәвам иткән сугышлар крестьяннардан алына торган түләү-салымнарны күп мәртәбәләр үстереп жибәрә. Ул салымнарны түли алыр өчен крестьян яңа керем чыганакларын табарга, авызыннан өзеп, соңгы сыныгын булса да базарга чыгарырга, сатарга мәжбүр була. Шул рәвешчә, крестьян хужалыклары сәүдә мөнәсәбәтләренә тартыла.

Халыкның чит дөнья, тирәлек белән мөнәсәбәте, географик хәбәрдарлыгы да киңәя. Авыл агайлары, рекрутлыкка эләгеп, патша мәнфәгате өчен ерак жирләрдә сугышып йөри; күпләр дәүләт күләмендәге төрле авыр эшләргә тартыла.

Халык кузгатылып, шулай масса күләмендә хәрәкәткә, эшчәнлеккә жәлеп ителгән көннәрдә, татар феодализмының нигезенә дә балта чабыла: 1713 елда Беренче Петр, биләмә-утарларын алу белән янап, ярты ел эчендә, христиан динендәге крепостнойлары булган татарлар — «бусурман» феодаллары чукынырга тиеш, дигән указ чыгара. Татар феодалларының төп массасы чукынмый. Указ нигезендә, хөкүмәт аларның биләмәләрен һәм крепостнойларын тартып ала. «Чабаталы морза» булып калган мондый «феодал»ларны ясаклы крестьяннар һәм «йомышлы» крестьяннар белән тиңләүдә, 1719—1721 елларда үткәрелгән беренче ревизия (халык санын исәпкә алу) соңгы хәлиткеч адым булды. Бу жан исәбе алу буенча, чабаталы морзалар хокук ягыннан крестьяннар дәрәжәсенә төшерелә һәм кораб эшләренә — лашманнар исемлегенә языла. Аларның шулай тулысынча вак милекче крестьян хәленә калдырылуы буржуалашуга йөз тотылган шартларда капитализм үсүе өчен иң кулай жирлек тудыра. Нәтижәдә, XVIII йөз башы татар жәмгыятендә дә капиталистик үсү билгеләрен ачык төсмерләргә була. Бистә татарлары (мәсәлән, түбәндә телгә алыначак С. Уркин һәм аның улы) Әстерхан, Кавказ, Хива, Бохара, Иран, ерак Кяхтага кадәрле киң Себер базарлары белән сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштыралар. Авылларга да сәүдә капиталы тамыр жәйгәнен күрәбез. Мәсәлән, яңа үзләштерелә башлаган Оренбур

---

[1] Древние грамоты и разные документы, собр. Е. Маловым, К., 1902, 7—11 бб.
[2] ЦГАДА, 248 ф. 14 оп. 803 эш., 958—960 бб.
[3] АКТЫ исторические, 5 т. № 87, 139 б.

төбәгендә сәүдә эшләрен юлга салу өчен, 1744 елда Казан ягыннан 200 татар гаиләсен Оренбурга (Каргалыга) күчерү турында указ чыга. Татарларда социаль катламлану шул дәрәҗәгә җиткән, күрәсең, 1740 елларда бөлгенлекнең соңгы чигенә баскан татар авылларында хәлле 200 гаилә шунда ук бик җиңел табыла. XVIII йөз башларында татарлар арасында капиталистик үсеш өчен кирәкле булган иң кулай иҗтимагый җирлек шул рәвешчә барлыкка килә. Әмма ул, колония коллыгы шартларында яшәгән халыкта тагын да куәтлерәк үсеп-киңәеп китә алмый. Царизм татарлар арасындагы һәртөрле яңаруга, җанлануга шикләнеп карый; яңалыкны бөреләнгән көннәрендә үк туңдырып, үтереп торучы иң консерватив, реакцион феодаль көч буларак кына мәйдан тота. Шул рәвешчә яңару чикләнә. Әмма аның сулышы шактый көчле булганын күрәбез. Феодаллар (морзалар) сыйныфы белән бергә «йомышлы татарлар» катламы да юкка чыгарылмый. Киресенчә, хөкүмәтнең бу чарасы татар йомышлыларын тотрыклы социаль бердәмлеккә китерү, аларның оешуын җиңеләйтү юнәлешендә мөһим адым була. Социаль бердәмлек йомышлыларны көчәйтә, аларның активлыгын арттыра. Шул ук вакытта йомышлылар сан ягыннан да бик нык үсә. Чөнки дәүләт буйсындырылган халыкларны идарә итүдә, алардан салымнар җыюда, рекрутлар алуда, югарыда саналган кебек төрле эшләрне оештыруда җирле халык арасыннан чыккан күп санлы старосталар, йөзбашлар, старшиналар, тылмачлар кебек кешеләр ярдәменә мохтаҗ. Мондый «йомышлы»ларны, гадәттә, крестьяннарның үзләре эченнән — укымышлырак, хәллерәк, активрак кешеләр арасыннан алалар. Шул рәвешчә, XVIII йөзнең беренче чирегендә татар җәмгыяте «йомышлылар» һәм «ясаклы татарлар» дип аталган, милек, хокук һәм җәмгыятьтәге урыны буенча, бер-берсенә шактый якын булган, нигездә, ике крестьян сословиесенә генә калдырыла. Феодаль җирбиләүчеләр катлавы юк ителгәч, «йомышлы» татарлар шул заман тормышының югары баскычындарак торган «җитәкче» сословие булып кала. Әмма бу сословие Петргача чордагы феодал йомышлылардан инде бик нык аерылып тора. Иң мөһиме — аларның җир биләмәләре һәм крепостнойлары булмый. Дәүләтнең төрле эшләрен, йомышларын башкарган өчен, аларга сәүдә итүдә кайбер мөмкинлекләр бирелгән. «Йомышлылар» иң чикләнгән мөмкинлекләрне дә максималь файдаланырга тырышканнар. Кыскасы, аларның бөтен эшчәнлекләрендә буржуаз яралгылар өстенлек итә, алар капиталистик үсү юлына омтылышлы, шул үсүгә сәләтле булалар. Бу катламның актив вәкилләрендә күренгән авантюр, маҗаралы тормыш белән яшәү кебек сыйфатлар да «йомышлы»ларның капиталистик үсү юлына йөз тоткан социаль төркем икәненә тагын бер дәлил. Мәсәлән, XVII йөз азакларында, Урта Азиядән укып кайтышлый, Юныс бине Иванай Оруви казакъ ханы Чыңгызның Мөһелбикә исемле кызына өйләнеп, аны иленә алып кайта.[1] Мортаза Симети, белем эзләп, Дагыстан якларына барып чыга, XVIII йөз башларында ике мәртәбә хаҗда була.[2] Иштирәк Ишмәтов иптәшләре белән Петербургка армия өчен атлар куып илтә, (1716). Тәфкилев (1675—1764) урыс разведчигы булып, ярым тоткын хәлендә, ике ел казакъ урдасында яши һәм Әбелхәер ханны Русия кул астына күчү ягына аудара (1730 еллар). Гайса Кашаев татарлар өчен төрле телләргә өйрәтә торган мәктәп ачуны үтенеп, Сөбханкол Иманколов тимер рудасы табып, шуны эшкәртергә рөхсәт алыр өчен, 1730 елда Мәскәүгә килгән.[3] Мондый тынгысыз хәрәкәтчәнлек бу социаль катламда типик бер күренешкә әйләнеп калган. Урал буеннан Төньяк Кавказга килеп, царизмга каршы сугыш ачкан, Казанга күтәреп асып үтерелгән Солтан Морад,[4] Урал буеннан Кашгаргача араны кылыч уйнатып гизгән, рыцарьлыгы, галимлеге белән хәтта дошманнарын таң калдырган, күп санлы мәкерле дошман тозагына төшмәстән, тарих сукмакларында эзсез югалган милли-азатлык көрәше батыры Карасакал[5] да шул «бакча»ның җимеше икәнен тынгысыз маҗаралы тормышы күрсәтеп тора. Яшь кәсептәшләрен дә ияртеп Кяхтага (Монгол-Кытай чигенә) кадәр булган исәпсез Себер базарларын гизгән бистә сәүдәгәре Сөләйман Уркин, Оренбург чигендә Урта Азия белән сәүдә эшләрен эзгә салган Арсланов, Мансуров, Казан якларыннан күчеп китеп Оренбург янында Сәгыйть бистәсенә нигез салган 200 татар сәүдәгәре — болар һәммәсе шул социаль катлаудан.

---

[1] Р. Фәхретдинов, Асар, II жез, 38 б.
[2] Р. Фәхретдинов, Асар, II жез, 33—36 бб.
[3] ЦГАДА, N 248 ф. 5 тасв., 238 эш. 10—16 бб.
[4] Материалы по истории Баш. АССР, II кисәк, 1936, 232, 238—295 бит.
[5] Шунда ук, 377—494 битләр.

Китерелгән мисаллар ук бу социаль катламның төрле төркемнәрдән торганын күрсәтә. Юныс Оруви, Мортаза Симети кебекләр аның укымышлылар төркемен тәшкил иткән. Бу төркем, урыс халкы арасында мәгариф эше янару белән бер үк вакытта, татарда да ислам мәгарифен янарту кәсебенә жиң сызганып керешкән. Авыр тарихи шартларга да карамастан, мәктәп-мәдрәсәләр челтәрен барлыкка китергән. 1726 елда Казанның Татар бистәсендә ике катлы мәчет салынган. Аның аскы катында мәктәп-мәдрәсә булган. 1769 елда экспедициядә йөргән Н. П. Рычков та татар авылларының хәтта иң кечкенәләрендә дә мәчет булып, шул мәчет мулласы авыл балаларын укытуы турында яза һәм укытуны «хаклы рәвештә мактауга лаек»,— дип, югары бәяли.[1] 1742 елгы мәчет жимерүләр шаукымы заманында Казан өязенең үзендә генә дә ким дигәндә 536 мәчет, димәк, шуңа якын санда мәктәп булган. Ягъни, беренче Петр дәүләт көче белән урысларда «Цифер мәктәпләре» оештырган кеннәрдә, татар жәмәгатьчелеге, дәүләттән бер тиен ярдәм алмыйча (киресенчә, кыерсытулы эзәрлекләнү шартларында), һәр авылда дип әйтерлек, мәктәп-мәдрәсәләр челтәрен барлыкка китерә. Бу мәгариф системасы XIX йөз азакларынача яшәп килә. XX йөз башларына кадәр кулланылышта булган «Әлифба» китабы язылуы да шул чорга бәйләнә: аны XVIII йөз башында яшәгән Мортаза Симети әсәре дип күрсәтәләр.[2] Юныс Оруви ның математика буенча хезмәте — «Фәраиз әс-Сиражия»гә шәрехе безнең көнгәчә килеп житкән. Бу мәгариф челтәрен тудыручылар арасында, тиздән замандашлары «Остазы көлли» (һәммәнең остазы) дигән шәрәфле исемгә лаеклы дип тапкан шагыйрь Габдессәлам бине Уразмөхәммәт[3] кебек күренекле мөдәррисләр, 1740 елларның фажигале кысымнарына жавап буларак оештырылган халык хәрәкәтенә житәкчелек иткән. Батыршадай шәхесләр житешә. Батырша кебек белемле һәм сәләтле эшлекләләр тәрбияләп үстергән Габдрахман бине Туймөхәммәтнең[4] Тайсуган мәдрәсәсе кебек гыйлем учаклары бу төркем эшчәнлеген күзаллауга жирлек була ала.

Икенче төркемне игътибарларын икътисадый эшчәнлеккә бирүчеләр дип билгеләргә мөмкин. Аларның эшчәнлеген һәм үзенчәлекләрен Ташкент сәүдә юлын ачкан Ш. Арслановлар, әйткәнебезчә, Сәгыйть бистәсен салучы татарлар мисалында күрергә була. Алар Оренбур якларына килеп, ярты Европага тиң Казагыстан һәм Урта Азия белән сәүдә эшләрен күрелмәгән дәрәжәдә жанландырып жибәрәләр. Шул заманда Оренбург генерал-губернаторы булган И. И. Неплюев тә болар хезмәтен һәм аның нәтижәсен: «...шундый тырышлык күрсәтәләр ки, 1745 елдан Оренбурның мәшһүр сәүдәсе башланып китә алды»,— дип югары бәяли.

Өченче төркем — административ эштә катнашучылар: старосталар, сотниклар, старшиналар — социаль катламның иң күп санлы, иң өлгерлек күрсәтүче, иң шау-шулы, халык эченә сеңгән төркеме. Шуна да күрә бу яңа социаль катламның сыйфат үзенчәлекләрен дә күбесенчә шул төркемгә карап билгеләргә мөмкин. Бу төркем дәүләт органнары белән бәйләнештә үзен татар халкының рәсми вәкиле итеп сизә, кәсебен рәсми яктан, дәүләт тарафыннан да раслатырга, үзләренә урыс дворяннары файдаланган микъдардагы хокуклар алырга тырыша. Шул максатына ирешү юлында аның бердәнбер таянычы, терәге — үз халкы арасындагы абруе, тәэсире. Әле генә татар феодал сыйныфын юкка чыгарган самодержавие, бу катлам йөзендә тагын да эшчәнрәк, активрак сословиене аякка бастыруга бара алмый. Самодержавиене үзләренә кирәк юнәлештә күпмедер ташлама ясарга мәжбүр итәр өчен, бу катлам прогресс өчен армый-талмый көрәшергә, халыкны оештырырга, аның кирәкләрен даулап йөрүче «выборныйлар», «ходок»лар буларак мәйдан тотарга мәжбүр. Әмма йомышлылар самодержавие белән килешергә, аның теләсә нинди хезмәтен һәр минутта чын күңелдән үтәргә дә әзер торалар. Моны, мәсәлән, А. П. Волынский эше буенча Мәскәүгә «выборный» булып барган (1730) Габдүш Госманов хаты буенча ачык төсмерләп була. Ул тикшерүләр барган бер вакытта: «Казан, Зөя, Сембер өязеннән качкан татарлар һәм үзгә халыклар Уфа өязендә торалар. Ул кешеләрнең кайсы подушнайдан, кайсы корабельный эштән качканнар. Вә янә шул югарыда язылган барча өязләрдән, кайсының — атасы, кайсының — бабасы килгән. Рәхимле падишаһыбыз ул кешеләрне кайтарырга боергай ирде. Уфа өязеннән авыл саен йөреп сорарга. Ул йортта язылган татарларга Уфа өязенең башкортлары кайсысы —

[1] Рычков Н. П., Журнал или дневные записки путешествия... Пб, 1770, 5 бит.
[2] Ибраһимов Ф., Белем әлифбадан башлана. Казан, 1973, 40, 319 бб.
[3] Р. Фәхретдинов, «Асар», II жезе, 42 бит.
[4] Шунда ук, 44—50 битләр.

кыз биргән, кайсысы — кыз алган, кайсысы — дус булган. Ул башкортлар югарыда язылган татарлар өчен рәхимле олуг падишаһның указына бәхәс итмәгәйләр ирде. Рәхимле падишаһ боергай ирде, ул югарыдагы кешеләрне мән мескенгә кайтартырга кушкай ирде. Шул югарыда язылган Уфа өязеннән мең душ кеше табар ирдем», — мәгънәсендә хат язып бирә.[1] Хат аңларга кыен рәвештә надан язылган. Шуңа күрә икенче көнне бу хосуста хат авторыннан сорау алалар. Анда ул үзен бер отряд составында шул качкыннарны эзләргә җибәрүләрен сорый.

Кама аръягында Көнчыгыш төбәкләрдәге татарлар арасында да шул ук халәт булганын күрәбез. Шул ук 1730 елларда Әлмәт тирәсендәге авылларның берсендә яшәгән мәшһүр Нәдер старшина, тирә-яктагы барлык старшиналардан имза җыеп илнең Көнчыгыш төбәкләрен казакъ, каракалпак, калмык кебек күчмә халыклар һөҗүменнән саклар өчен, үзенә «барабан, кылыч-мылтык һәм байрак» бирүләрен сорап, Сенатка гариза бирә. Читтән гаскәр кирәкми, мин Казан, Уфа өязе татарларыннан гаскәр оештырып, авылларны (һәм дәүләт чикләрен) дошманнардан саклармын, ди. Үзен атаман итеп билгеләсәләр, фетнәләрне бастырып, башка һичнинди чуалышларга юл куймаска да вәгъдә бирә. Сенат бу мәсьәлә буенча тикшеренүләр, чокчынулар башлап җибәрә. Билгеле, аны Нәдер старшина ярдәмендә көнчыгыш чикләрен саклау мәсьәләсе түгел, бәлки Нәдернең нинди кешеләрдән, кайсы вакытта күпме гаскәр җыя алуы мәсьәләсе кызыксындыра. Ул тикшеренүләр җыелмасы «Татар Нәдер Уразмәтовнe үзен «выборной» дип игълан итүе өчен җәзалау хакында эш» дип атала. Кызганыч ки, Нәдер турындагы материаллар саклана торган без күргән «эш»ләрдә[2] бу старшинаның татарлар арасындагы нинди көчләргә ишарәләве һәм башкорт старшиналарының ул тәкъдимгә мөнәсәбәтен күрсәткән кайбер кәгазьләр генә сакланган...

Беренче Петр заманы йомышлы татарлар катламының гадәттән тыш ныгып, көчәеп китүенә уңышлы җирлек булды. Империя төзелү чорында йомышлылар дөрестән дә үзләрен мөһим, мәгънәле дәүләт эшен башкаручы тарихи көч итеп сизә башлыйлар.

Әмма колониаль коллык шартларында «йомышлы»ларның социаль урыны шактый тотрыксыз иде. Бер яктан, алар дәүләт өчен мөһим эшләрне башкаралар. Дәүләт эшендә алар арасыннан тылмачтан Оренбур комиссиясе командиры урынбасары дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән генерал-майор Котлымбәт Тәфкилев (1675—1764) кебек кеше үсеп чыккан. Әмма XVIII йөзнең беренче яртысында аңардан башка тагын берәр татарның Петрның «Дәрәҗәләр турында» указы тәэсиренә эләгә алганы мәгълүм түгел. Йөзбашларына, старшиналарга хезмәтләре өчен җир биләмәләре бүләк ителүе дә билгеле түгел: хезмәт хакы да бирелмәгән. Алар халыктан бераз йолыккаласалар да, нигездә үз хуҗалыклары хисабына көн кичергәннәр. Татар тормышындагы «дәрәҗәләр табелендә» исә алар өчен укып мулла булу һәм, бюрократия киртәләрен ерып үтеп чыга алса, сәүдәгәрләр сословиесенә күчү мөмкинлеге генә булган. Язмышларының шул үзенчәлеге аларны хәлле крестьян белән бер үлчәмдәгерәк катлам итеп калдыра, ягъни шул заман крестьян сыйныфына якынайта.

Татарлар арасында бу әрсез, эшчән социаль катламның формалашуы беренче Петр вакытында ук инде хөкүмәтнең игътибарын үзенә җәлеп итә: дәүләт алар арасына ничек тә таркаулык кертергә, матди яктан көчсезләндереп, әхлакый, сәяси, хәрби кысулар белән аларда курку хисе уятырга — аларны активлыктан тыярга тырыша. Дини-рухи яктан морзаларны халык массасыннан аерыр өчен, 1713 елның 3 ноябрь указы чыгарыла (П. С. З. № 4273). Бу указ нигезендә чабаталы морзаларның утарларын алу да шул «йомышлылар»ны матди яктан көчсезләндерү иңкәнлеге бәхәссез.

1713 ел указы XVIII йөздә инородецларны чукындыру хәрәкәтенең башлангыч ноктасы булды. Шул указдан рухланып, 1714 елда Алексей Раифский дигән монах Казан губернасында миссионерлык эшен җәелдереп җибәрә.[3] Бу эшчәнлек дәүләт тарафыннан да кайнар хуплана. Чукындыру чыгымнарына тотарга дип, дәүләт 1720 елда Казан епископы Тихонга 1000 сум акча билгели. «Мөселманлыкка каршы миссия» чыгымнарына Казан әрхәрәе конторыннан һәр ел 666 сум акча бирелсен, дигән указ (I. IX. 1722) чыгарыла.

Шул ук вакытта татарларны аерымлау чаралары да күрелә башлый. Урал буйларына качып китүләрне туктатыр өчен дигән сылтау белән, Казан һәм Уфа

[1] ЦГАДА, 248 ф., 5 тасвирл., 238 төпләм, 490—491 б. б.
[2] ЦГАДА, 248 ф. 4 тасвирл., 169 төпләм; 7 тасвирл, 387 төпләм.
[3] Архив чыганакларыннан дип күрсәтелмәгән христианлаштыру тарихы материаллары Е. Маловның «О Новокрещенской конторе» (1878) дигән китабы буенча алына.

губерналарында хәрби заставалар төзү башлана. 1729—1730 еллардан Кама аръягы саклану сызыгын кабат янарту эшләре башланып китә. Кама-Чирмешән аралыгындагы төбәкләргә отставкадагы һәм запастагы драгуннар күчереп утыртыла. Алар хәрәкәтчән ландмилиция отрядларына берләштереләләр. Кичуй, Яңа Чишмә кебек ныгытмалар төзелә. Кече жөз казакълары Русиягә кушылып, дәүләт чикләре Арал дингезенә якынлашкан көннәрдә Кама буенда хәрби ныгытмалар төзүне чик сызыгын ныгыту дип карарга мөмкин түгел. Чик сызыгы Урал аръягына күчкән XVII йөздә үк Камада ныгытмалар төзү (1652—1656), нигездә, татар-башкорт халыкларын аеруга каратылганын революциягә кадәр үк Мөнир Һади билгеләп үткән иде: «Казан вә башкорт йирләре забт ителгәч, анлар арасындагы мөнәсәбәтне бетерер өчен, Кама аръягы сызыгы бина ителмеш...»[1] Казан Кремлен төзәтү эшләре башлап җибәрү[2] кебек чаралар да нигездә шул максатка, шул социаль катлау активлыгына басым ясауга каратылган иде.

Әмма Анна Ивановна, Елизавета Петровналар заманындагы дәһшәтле хәлләр белән чагыштырганда, Беренче Петрның бу чаралары мәсьәләне нигездә сәяси юл белән хәл итүгә юнәлтелүе аңлашыла. Объектив тарихи процессны сылтау итеп, ул әле, стихияле афәт сыман, гаепсез халык өстенә ябырылмый, бәлки шул процесс нәтиҗәсендә тууы ихтимал хәлләргә алдан ук әзер торырга гына тырыша. Икенчедән, аның бу хәрәкәте үзеннән соңгы патшалардагы милли чикләнгәнлек төсмерен дә ул кадәр кискен рәвештә сиздерми әле. Мәсәлән, шул ук елларда ул, элеккеге боярлар кебек үк, илне законсыз җәберләү-талау юлына баскан урыс дворяннарының бозыклыкларын тикшерү эшен дә башлап җибәрә. Тарихчыларның әйтүенә караганда, андый дворяннарны да ул, тәхеткә утырган елларында стрелецларны туздырганы кебек, шәфкатьсез тар-мар итәргә җыена. Иран белән башланган сугыш бу җәза көнен кичектерә һәм Беренче Петр кабат бу мәсьәләгә әйләнеп кайта алмый үлеп китә.[3]

Йомышлы татарларның дәүләт хезмәтенә атлыгып торулары да Петрда аларга карата берникадәр ихтирам уяткан, ахры. 1749—1750 еллар вакыйгаларында татарларның үз хокукларына дәлил итеп китергән Петрның Әстерхан указын (19.VI.1722) шул ихтирамның чагылышы дип бәяләп була. Анда указны үтәмәүчеләрне каты җәза белән куркытып, христиан динендә булмаганнарны көчләп чукындырмаска, мөселманнарның каберлекләрен һәм мәчетләрен туздырмаска, дип күрсәтелгән була.[4] Йомышлы татарлар карашында дәүләтне һәм закон нигезендә оештырылган тәртипләрне идеаллаштыру кебек гамәлләр Петрның шул типтагы чаралары тәэсирендә мәйданга чыккан булырга тиеш. Патшаның шундый сәясәтенә җавап буларак, Беренче Петр дәверендә йомышлы татарлар эшчәнлегендә, үз халкы хокукларын даулап йөрүгә караганда, дәүләт хезмәтенә омтылу теләге өстенлек итә.

Беренче Петр үлгәннән соң дәүләтнең йомышлы татарларны эзәрлекләве, сугыштагы кебек, ачыктан-ачык хәрби көч белән тар-мар итүгә йөз тота. Җирле хакимнәрнең шундый сәясәт үткәрүенә җавап рәвешендә, татарларның югары катлам бюрократиягә каршы көрәше дә һаман киңрәк колач ала. Бу хәрәкәтнең башында йомышлы татарлар тора. Шул процесс тәэсирендә, татарлар үзләрен бердәм, бер халык итеп сизә башлыйлар. Бу чорда татарлар арасында башланган һәртөрле хәрәкәт (мәгариф) челтәрен төзү, мөрәҗәгатьләр язу (һ. б.) халыкның менә шул милләт булып оешуының тышкы чагылышына әйләнә. Ул хәрәкәтләрдә катнашучылар «бөтен халык исеменнән» сөйлиләр. Монарчы сизелмәгән бу яңалык хөкүмәтне сискәндерә һәм бик тә ярсыта. Аңа чик куям, дип хөкүмәт татарларга карата кискенрәк, аяусызрак чаралар күрә башлый.

Эзәрлекләүнең көчәюе А. П. Волынский Казан генерал-губернаторы булган 1725—1730 елларда күзгә ташлана. Губернаторлыгының соңгы елында ул халыктан үз файдасына «салым» җыйдыра. Вакыйга болай була: 1727 елда Сенат Иранга тәрҗемәче итеп җибәрер өчен[5] Казан өязендәге татар муллаларын җыю турында әмер бирә. Бер елдан бу указ юкка чыгарыла. А. П. Волынский әмернең үзгәртелгәнен яшереп, сезне Иранга барудан азат итәм, дип муллалардан үз файдасына акча җыясы итә. Муллалар үзләре дә бу кармакка эләгергә әзерләнгән

[1] «Шура», 1909, № 14, 433 б.
[2] ЦГАДА, 248 ф. 3 тасвир., 102, 107 төпләм,
[3] Никольский Н. В. Конспект по истории народностей Поволжья, Казан, 1919, 58—59 б. б.
[4] ЦГАДА, 248 ф., 14 тасвир, 803 төпләм, 968 б. Бу указның оригиналы Сенатта табылмавына ишарәләп, Е. Малов кебек кайбер тикшеренүчеләр аны татарлар уйлап чыгарган нәрсә кебек бәялиләр. Е. Малов. О новокрещенской конторе, 1878. 243 б.
[5] Г. Газиз. Татарларда сыйныфлар тарихы. Казан, 1925.

була. Зөя өязеннән Персиягә җибәрелергә билгеләнгәннәре «Калыр өчен берәр чара юк микән?» — дип, Коллар авылы йомышлы татары Габдулла Атманов аша губернаторның ышанычлы хезмәтчесе керәшен Василий Кубанецка мөрәҗәгать итәләр. Икенче көнне үк В. Кубанец: «Губернатор белән сөйләштем. Авыллардан акча җыеп, Мәскәүгә гариза бирүчеләр җибәрергә киңәш итә»,— дип җавап кайтара. Иранга җибәрер өчен Казанга җыелган муллаларны да авылларга, халыктан акча җыярга кайтарып җибәрәләр. Сайланган челобитчиклар акча җыеп, Казанга килгәч, В. Кубанец: «Мәскәүгә барып җәфаланып йөрүнең кирәге юк, Татарларны Персиягә озатмау турындагы указны губернатор үзе чыгартырга вәгъдә бирде»,— дип акчаларны алып кала.[1]

1730 елның җәендә Сабаның Йосыф мулла Мөхәммәтев h. б. Персиягә тылмачлыкка җибәрелергә билгеләнәләр. Алар Казан сәүдәгәре Яков Каменев аша губернатордан үзләрен бу сәфәрдән азат итүне сорар өчен Казанга Саба сәүдәгәре Рәим Аитовны җибәрәләр (125 б.). А. П. Волынский Я. Каменев аша бу муллаларга: «500 сум акча бирсәләр, аларны Персиягә китүдән азат итәм»,— дигән хәбәр ишеттерә. Муллалар: «Бездә ул кадәр акча юк шул»,— диләр. Я. Каменев, губернатор сүзләре нигезендә булса кирәк: «Өч денщик алып чыгыгыз да өязләрдән җыегыз. Карышучылар булса, Казанга (губерния канцеляриясенә) алдырыгыз»,— дип киңәш итә (125 б.). Шул рәвешчә, Арча юлы авылларыннан — 402 сум, Алат юлы авылларыннан 115 сум җыеп губернаторга китереп бирәләр. Губернаторның «эшләре» көйләнә. Ул арада Мәскәүдән яңа указ килә. I нче ревизия буенча, Воронеж губернасында яшәүче йомышлы татарлардан 12087 кеше Казан адмиралтействосына лашманлыкка язылган була. 1729 елның 24 апрель указы еракта яшәүче лашманнардан ясак кына алып Воронеж губернасы өчен лашманлыкны Казан, Зөя өязендәге ясаклы татарларга йөкләргә күрсәтмә бирә.[2] Әмма 1730 елның 17 июль указы Казан, Зөя өязе татарларын лашманлыктан азат итеп, бу эшне кабат воронежлыларның үз җилкәләрендә калдыра (105—106 бб). Инде А. П. Волынскийга «лашманлыктан азат итү» указы өчен татар авылларыннан акча җыйдыру мөмкинлеге туа. Авыллар гөж килә. Старшиналар, сотниклар халыктан акча җыеп, Иранга китүдән, лашманлыктан котылган кебек үк, бөтен авыр салымнардан котылу фикерен илгә тараталар. Акча җыю хәрәкәте Казан, Зөя өязе чикләреннән чыгып, Идел буенда татарлар яши торган бөтен өлкәләрне иңләп ала. Бу хәрәкәтне оештыруда старосталар, сотниклар актив роль уйный. Авыл җәмәгатьләре шул эш артыннан йөрер өчен махсус кешеләр сайлап, аларга үз исемнәреннән эш йөртергә тулы хокук бирә.

Шул хәрәкәт кызган бер вакытта, А. П. Волынский Казан генерал-губернаторы эшеннән азат ителә. Ул Мәскәүгә кайтып китә. Татарлар, «выборный»лар сайлап, шунда ук аның артыннан Мәскәүгә вәкилләр җибәрәләр. Сенатның бу мәсьәлә буенча тикшерү материалларында ул вәкилләрдән Җөри юлы Дусайкичү авылы татары Юзәй Атнагулов, Башавы авылыннан Мәмәт Ермаков (Ярмәк улы), Зөя өязе Әмин авылы татары Биктимер Әхмәтовлар исеме бар. Зөя өязе Шәмәк авылы татары Гайса Кашаев Мәскәүгә ясаклы татарлар балаларына төрле телләр өйрәтер өчен мәктәп ачарга рөхсәт сорап килгән була (10 б). Соңыннан килүчеләр артыннан аңа «Волынский эше» буенча йөрергә җыен карарын җиткерәләр. Юшады авылыннан Габдуш Госманов та Мәскәүгә элгрәк килгән. Аңа мир җыены таныклыгын Мәскәүгә «сәүдә эше белән килгән» Саба сәүдәгәре Рәим Аитов тапшыра (16 б). Арча юлы Байкы авылы татары Сөбханкол Иманколовның да Мәскәүгә килгәненә инде өч айдан артык үткән була. Ул Берг Коллегиясенә, тимер рудасы табуы турында хәбәр итәргә теләгән. Югарыда күрсәтелгән «вәкилләр» белән бер өйдә яшәгән. Тегеләр моңардан «мир эшләре» буенча йөрүен үтенгәннәр. «Вәкилләр» А. П. Волынскийдан 2500 сум акчаны кире кайтарып бирүен сорыйлар. Бу вакыт инде кайбер хәбәрләр Сенатка да килеп җиткән була. Казанның яңа губернаторы Михаил Владимирович Долгорукий декабрь, январь, февраль айларында Казан һәм Зөя өязләре татарларыннан Волынскийның үз файдасына акча җыйдыруы турында тугыз шикаять хаты алуы турында Сенатка хәбәр итә. Губерна канцеляриясе Казан өязеннән 79 сотникны, Зөя өязеннән ике сотникны чакырып сорау алган һәм шул күрсәтелгән хәлләрнең дөрестән дә булганын ачыклаган. Сенат һәм Казан губерна канцеляриясе да-

---

[1] ЦГАДА, 248 ф. 5 тасвир., 238 төпләм, 118—119 б. б. Алда бу делодан алынган материалнын битләре текст эчендә генә күрсәteләчәк.

[2] Лашманнар саны 1817 ел указы чорына 120000, 1836 елларда 160500 кешегә җиткәне билгеле.

ирәләренә якын торган А. П. Волынскийның бу хәлләрдән хәбәрдар булмавы мөмкин түгел. Шуңа күрә ул татарлар белән араны тизрәк өзәргә ашыга. Волынский вәкиле Андрей Борисов: «Алпавыт бүген-иртәгә Мәскәүдән походка китә. Ул походка китсә, бер тиен дә ала алмыйсыз. Хәзер ул сезгә 800 сумнар кайтарып бирергә риза. Коры кул белән калмыйк, дисәгез, шуны алыгыз да, 2500 сумны тулысынча алдык, дип язу бирегез»,— дип киңәш итә. Выборныйлар уйлашалар, уйлашалар да, 16 мартларда тылмач Алексей Тәфкилев өендә 2500 сумга расписка биреп, шул 800 сум акчаны алалар.

1731 елның 18 мартында Казан губернаторы хәбәрләмәсе Сенат утырышында тикшерелә башлый. Сенат А. П. Волынскийны чакыртып, аңардан шул мәсьәлә буенча сорау алырга карар бирә. Әмма йә «өйдә юк» дип, яки «авырый, һичкемне кабул итә алмый» дип, ике баруында да Сенат секретарен Волынский өенә кертмиләр. Сенат бу зур түрәдән ничек тә җавап алыр өчен дүрт пункттан торган «сораулык» төзи һәм аны гаепләнүченең өенә җибәрә. 1731 елның 24 мартында Волынский бу сорауларга җавап кайтара.

26—27 мартта «ходок» булып килгән татарлардан сорау алына. Бу «вәкилләр»нең җаваплары буенча татарлар арасындагы хәрәкәтнең программасын якынча билгеләргә була.

1. Ясак җыюны откупщикларга бирмәскә. (Күренә ки, ясак турында да сүз кузгатыла, ягъни хәрәкәт йомышлыларның гына түгел, гомумән, барлык татарларның, шул җөмләдән, ясаклылар мәнфәгатен яклауны да максат итеп куйган).

2. Авыл арасында сатылган ат өчен пошлина алмаска, ярминкәләрдә саткандa гына пошлина түләтергә.

3. Бакуга һәм Гилянга (Төньяк Иран) татар укымышлыларын тылмачлыкка җибәрмәскә.

4. Качып киткән ясаклы татарлар салымнарын авылдашларыннан түләтмәскә.

5. Поташ эшләренә, поташ заводларына татар авылларыннан целовальниклар алмаска.

6. Авылларга урманнардагы кораб эшләренә яраксыз агачлардан һәм чыбык-чабыктан файдалану хокукын бирергә.

7. Татарларны башкалар өчен лашман эшләренә җибәрмәскә.

Бу таләпләрнең барысы да татар халкының дәүләт белән үзара мөнәсәбәтләрен закон белән билгеләнгән ныклы бер тәртипкә кую өчен көрәшкә кузгалганын күрсәтә.

Казан, Зөя өязләрендәге татарлардан губернатор файдасына өстәмә салым җыелганын бу ходоклар да раслый. Авыллардан акча җыюга ярдәмләшер өчен, Волынский хәтта губерна идарәсеннән солдатлар да җибәртә. Выборныйлар җавабында ачыкланган фактларны искә алып Волынский өчен яңа сораулык төзелә. Бу түрә файдасына күпме акча җыелганын ачыклар өчен, акча җыелган авыллар сотникларын кабат җавапка тартырга, акча җыюда катнашкан деньщикларны табып, алардан сорау алырга Казан губерна идарәсенә күрсәтмә бирелә. Сенат боерыгы буенча, ахры, акча җыю эшендә зур активлык күрсәткән унбишләп старшина кулга алына.

Хәрәкәтнең колачы ачыграк билгеләнгән саен Сенат тикшерүендә дә А. П. Волынский фигурасы артка чигенә бара һәм, ниһаять, бөтенләй күздән югала. «Эш» татарлар арасындагы хәрәкәтне җентекләп тикшерүгә генә кайтып кала. Дөрестән дә, Волынский кыланышларын болай тәфсилләп сөйләр өчен әллә ни зур сәбәп юк. Колониаль коллыкта яшәгән халыкның зур түрәләр, хисапсыз күп бюрократия тарафыннан алдап талануы искитәрлек нәрсә түгел. Әмма, милләт булып оешу чорына борылганда, татар халкы арасында булып үткән шул шактый көчле иҗтимагый хәрәкәт гадәти хәл түгел иде. Бу хәрәкәтнең рухын — дәүләт белән халык арасындагы мөнәсәбәтләрне кануный ныклы бер кагыйдәгә нигезләү теләген Беренче Петр реформалары тәэсирендә татар җирлегендә ярлаган алдынгы бер карашның чагылышы дип бәяләп була. Аның яшәвенә юл кую татарларда гына түгел, гомумән, Русиядә прогрессив көчләр язмышы өчен шактый нәтиҗәле булыр иде. Әмма Беренче Петр тәрбияләп үстергән дәүләт эшлеклеләре, сәяси яңаруны яклаучы көчләр, үзләренең социаль табигатьләре буенча моны аңлаудан әле шактый ерак торганнар. Урыс җәмгатьчелеге эчендәге алдынгы демократик көчләр дә әле тиешле дәрәҗәдә формалашып җитмәгән иде. Нәтиҗәдә, татарлар арасындагы яңару хәрәкәте дә үтә фаҗигале язмышка тап була.

Хазар каганлыгы вакытыннан ук көнчыгыш славяннар Дала халыклары тарихы даирәсенә тартылалар. Киң Кыпчак даласы халыклары белән көнчыгыш славян кенәзлекләре арасындагы сәяси бәйләнешләрне тагын да ныгытуда мөн-

гол явы (1236—1240) соңгы хәлиткеч вакыйга була. Урыс кенәзлекләре дә Алтын Урда белән тыгыз бәйләнештәге урдалар — олыслар статусын алалар. Дала берлегендә урыс кенәзлекләренә, өлкәнең этник-географик үзенчәлекләренә бәйле рәвештә, хәтта берникадәр уңайлырак мөмкинлекләр дә булган. Дала халкы (күчмәннәр) тарихында һәрчак зур активлык күрсәткән аерымлану омтылышы бу этник-географик чик буе төбәкләрен үзенең табигый әшнәсе дип санаган. Аерымлану омтылышын — далада яңа сәяси берләшү үзәге булу дәгъвасын күтәргән төрки олысларга каршы көрәштә үзәк хөкүмәт тә мондый дәгъвага этник яктан хокукы юк дип саналган урыс кенәзлекләрендә үзенең иң ышанычлы таянычын гына күрә. Берләшү юлына баскан Мәскәү кенәзлеге бу ике кара-каршы көчне үз файдасына бик оста файдалана. Дүртенче Иван заманындагы Мәскәү сәясәте моңа ачык мисал. «Казан Сарай миссиясен үзенә алырга тели»,— дигән шомны куертып, урыс дипломатиясе Җаек буе, Әстерхан-Кавказ төркиләренең Казанга каршы берлеген, Кырым ханлыгының бу берлеккә эчтән теләктәшлеген тудырырга ирешә. Шул көчләрнең һәр яктан тоташ кысрыклавы нәтиҗәсендә, Казан үз теләге белән Мәскәү ихтыярына тапшырылырлык халәткә житкерелә. Казанны басып алуын Иван Грозный бабаларының биләмәсен үз кулына кайтару дип атый. Бу — урыс дәүләтенең яңа хәрби-сәяси программасы иде. Ягъни Мәскәү инде Даланы берләштерүне максат итеп алган яңа үзәк, Алтын Урданың, соңрак исә, гомумән, Чыңгыз империясенең варисы, бердәнбер мирасхуры буларак мәйдан тота башлый. Бу дәгъвага берникадәр законлы төс бирер өчен, күз буяр өчен генә булса да, Мәскәү патшалары үз сарайларында татар ханзадәләрен асрый башлыйлар. Алар дәрәҗә ягыннан урыс кенәзләреннән өстен куелалар, һәрчак патша янында буталалар, патша янында утыралар. Иван Грозныйның Опричнина елларында Касыйм ханы Симеон Бикбулатовичны Земщина «патшасы» итеп «күтәрү» шамакайлыгы, Алексей Михайловичны хәтта төнлә уянып чиркәүгә гыйбадәткә барганда да татар ханзадәләре озата баруы тарихта билгеле. Бер үк вакытта мондый йолалар, күрер күзгә генә булса да, татарлар урыс халкының «тиң хокуклы» союздашы икәнен дә искәрткәннәр.

Беренче Петр бу шамакайлыкларга кискен чик куя. Малай чагыннан ук булачак патша күнелендә Мәскәүнең Нимес бистәсенә мәхәббәт уяна, ягъни Петр малай чакта ук инде Русиягә Көнбатышка якынаю кирәклеген сиземли башлый. Патша инде үз тирәсенә татар шаһзадәләрен түгел, Көнбатыш белгечләрен җыя башлый. Бу — әһәмиятсез, очраклы бер хәл генә түгел. Бу — урыс дәүләте тарихи үсешенең яңа баскычка үтүе билгесе — урыс дәүләтенең татарларга һәм, гомумән, Дала халыкларына мөнәсәбәтенең төптән үзгәрүе иде. Инде Русия мондый буйсындырылган халыкларга, Көнбатыш Европа колонизаторлары кебек үк, колониаль коллар итеп кенә карый башлый. Урыс патшалары тирәсендә татар ханзадәләре урынын Лефортлар, Минихлар, Бироннар биләп ала.

Татарларның дәүләт хезмәтенә ашкынулы гражданлык активлыгы уянуы дәүләт аларның элеккеге юк-бар сәяси ролен дә тулысынча юкка чыгаруны максат иткән һәм шул юнәлештә эзлекле чаралар күргән көннәргә туры килә. Татарларның уяну хәрәкәте башлангыч чорында ук, шул рәвешчә, Русиядәге гаять көчле реакцион урта гасырчылык белән генә түгел, көчле империягә әйләнгән урыс дәүләте белән дә иң кискен конфликтка юлыга. Беренче Петр үлгәннән соң ул керткән яңалыклар язмышы зур куркыныч астында кала. Яңалыкка каршы ажгырып торган реакцион көчләрнең ярсуын бераз булса да тынычландыру өчен, аларга нindидер ташламалар ясау кирәк иде. Хакимнәр бу вәхши көч «авызына» Идел буе халыкларын ташлау белән котылырга уйлый. Бу адым яңа империя хөкүмәтенең реакцион руханиларга, урта гасырчылыкның иң күп тармаклы һәм актив катламына, үзенең традицион (көчләп чукындыру!) сәясәтенә турылыклы калуын искәртүгә, шул рәвешчә, алар каршылыгын берникадәр нейтральләштерүгә дә төбәлгән сәясәт иде. Идел буе халыкларын чукындыру сәясәте әнә шулай тагын да дәһшәтлерәк күләмдә кабат җанландырыла. Реакцион православие тарафдарларын күпмедер канәгатьләндергән шушы чара дәүләтнең татарларга карата ниятләренә дә җавап бирә иде: бу халыкка колониаль коллык камытын кидерер өчен, алардагы яңаруны, җанлануны үтерергә кирәк. Моңа исә халык арасына таркаулык кертү аша гына ирешергә мөмкин иде. Чукындырудан нәкъ шул таркаулык кертү максаты күзләнгәнен шул заманның материаллары да ачыктан-ачык исбатлап тора. Көчләү, җәберләүләр белән халыкның бер өлешен генә чукындырса да, самодержавие керәшен татарларын ислам динендә калган кардәшләренә каршы куюга ирешә: ислам динендә калган татарларның чукынган кардәшләренә карата ачуын кыздыра. Боларның үзара бәрелешүләрен тыю сылтавы астында, халыкны ачыктан-ачык хәрби көч яр-

дәмендә кысу, җәберләү, талау-көчсезләндерү процессы башлана. ЦГАДАда Зөя провинциясе канцеляриясенең шул чордан сакланып калган «эш»ләре бар (441 ф.) Бу «эш»ләрнең күбесендә керәшеннәр белән иске диндә калган татарлар арасында бер-берсенең атын, малын урлап сую, игенен таптату, йортын ут төртеп яндыру, кызын, хатынын көчләү; күсәкләр белән сугышу, үтерешү кебек эшләре, мөгънәсез ызгышларны тикшерү материаллары тутырылган. Аларга карап: «Әйе, царизм халыкны үзара ызгыштыруда шактый зур нәтиҗәләргә ирешкән!» — диярга генә кала.

Кыскасы, XVIII йөзнең икенче чирегендәге чукындыру тарихы — татарларда башланган милләт булып берләшү, яңару, җанлану хәрәкәтенең буылу тарихы ул.

XVIII йөзнең утызынчы елларыннан чукындыру хәрәкәтендә яңа этап башлана. Җирле хакимнәрнең, поплар, миссионерларның халыкларны чукындыру кебек эшләрен оештыру һәм координацияләү өчен, 1731 елда Зөядә «Новокрещенская комиссия» дигән оешма төзелә. 1740 елның 17 сентябрь указы белән ул оешма «Новокрещенская контора»га әйләндерелә. Бу оешманың үзәге итеп Зөядәге Богородица монастыре, оешманың җитәкчесе итеп исә архимандрит дәрәҗәсенә күтәрелгән миссионер Алексей Раифский билгеләнә. 1732 елда А. Раифский чукындыру эшләрен җәелдерү турында үзенең проектын Синодка тәкъдим итә. Әмма аңа үзенең планнарын гамәлгә ашыру насыйп булмый кала: 1732 елда Казан епархиясенә башлык итеп билгеләнгән Илларион (Рогалевский) белән А. Раифский «Новокрещенская комиссия»гә бирелгән акчаны бүлешкәндә ызгышалар, бер-берсе өстеннән Петербургка әләк яза башлыйлар. Дәүләт акчасын үзләштерүләре фаш ителгәч, А. Раифскийны Петербургка чакырып алалар һәм ул инде шуннан кабат әйләнеп кайтмый: аны «Новокрещенская комиссия» эшеннән читләштерәләр. 1735 елда Илларионны да Казаннан Черниговка күчерәләр. Шуннан соң да әле ике-өч ел буе бу комиссия эше эзгә төшә алмый. 1738 елда архиепископ Гаврил да Казаннан Устюгка күчерелеп, Казанга әрхәрәй итеп Устюгтан Лука Конашевич китерелә. «Крещенская контора»ның дәһшәтле эшчәнлек еллары менә шул Лука Конашевич әрхәрәй булган елларга туры килә. Бу чорда инде хөкүмәт тә чукындыру эшен янабаштан оештырырга керешкән була. 1740 елда җирле халыклар телен белгән утызлап грамотлы поп табып, миссионерлык эшенә әзерләү өчен Петербургка җибәрү турында указ чыгарыла. Синод аларны, Петербургка җибәрмичә, миссионерлык эшенә Казанда гына әзерләргә күрсәтмә бирә. (ПС. З., XI № 8090). 1740 елның 11 сентябрендә Казан, Әстерхан, Сембер, Нижегород, Воронеж губерналарындагы мөселман һәм мәҗүси инородецларны чукындыру турында указ чыгарыла. Е. Малов бу указны «чукындыруның тулы инструкциясе һәм программасы» дип атый. Указ «Новокрещенская контора»ны материал һәм кадрлар белән тәэмин итү эшен яңа баскычка күтәрә. Дәүләт чукындыру эшенә һәр елны ун мең сум акча, биш мең чирек икмәк бирүне планлаштыра. Саратов белән Царицын арасында яңа керәшеннәр өчен мең кешелек авыл салып, анда ике поп, бер дьякон, өч церковник билгеләргә, чукынмаганнардан җыеп, елына попларга алтмыш сум акча, алтмыш чирек арыш һәм бодай оны, дьяконнарга кырык сум, кырык чирек он, церковникларга утыз сум һәм утыз чирек он бирү планлаштырыла. Указ буенча, «Новокрещенская контора»ның штаты яңартыла һәм киңәйтелә. Бу контора җитәкчесе итеп Мәскәү Духовная Академия укытучысы Дмитрий Сеченев билгеләнә. Аңа биш ярдәмче һәм кирәк кадәр солдатлар бирү тиешлеге күрсәтелә. Бер ел да үтми, Д. Сеченев тагын дүрт ярдәмче сорап Синодка мөрәҗәгать итә. Синод аның үтенечләренә һәрчак уңай мөнәсәбәт күрсәтә. Мәсәлән, 1740 ел указында яңа чукынган кешеләрне иске диндә калган кавемдәшләре арасыннан күчерү (аеру) тиешлеге күрсәтелгән була. Бу күчерү эшләренә җитәкче итеп Андрей Жуков дигән кеше билгеләнә. Әмма бу кеше тырышлыгы Д. Сеченевны канәгатьләндерми. 1742 елда ук инде Д. Сеченев аның урынына Зөя шәһәренең элеккеге воеводасы Борис Ярцевны тәкъдим итә. 1742 елда бу эшкә Б. Ярцев билгеләнә. 1742 елның сентябрь башында Д. Сеченев Нижегород епискобы итеп билгеләнгәч, Синод: «Новокрещенская контораны Зөядә калдырыргамы? Конторага җитәкчелеккә кемне билгеләргә?» — дип аңардан ук киңәш сорый.

1740 ел указында, яңа чукындырылганнар арасында христианлык кагыйдәләрен җәю максатында һәм һәр халыкның үз эченнән шул телне яхшы белгән руханилар әзерләү өчен, Казан епархиясендә һәркайсы утызар укучы укытырлык дүрт яңа керәшен мәктәбе ачу тиешлеге дә күрсәтелгән. Аларны оештыру эшен царизм, А. Раифский проекты нигезендә, 1735 елларда ук башлап җибәргән була. Ул эш 1749 елда гына гамәлгә аша. Шундый дәвамлы газаплар белән оештырылган бу дүрт бәләкәй мәктәп гомерсез булалар: 1753 елда Казанның Татар бистәсендә, Кабан күле буенда «Үзәк яңа керәшен мәктәбе» төзелә, Зөя, Алабуга,

Царевокакшайск (Йошкар-ола) мәктәпләре исә ябыла. Аларның укучылары Казан яңа керәшен мәктәбенә күчерелә. Бу мәктәпләрдәге укучыларны ата-аналарыннан көчләп тартып алып җыялар. Ул балалар котычкыч язмышка дучар була. М. М. Щербаков «Статистика в рассуждении России» дигән язмасында ул мәктәпләр турында: «Яңа керәшен мәктәпләре укучыларының күбесе ачлыктан үлеп бетте»,— дип күрсәтә. Мәктәп бинасы таушалып шул дәрәҗәгә җитә ки, 1792 елда ремонт ясау мәсьәләсе күтәрелгәч, аңа ремонт ясау мөмкин түгеллеге ачыклана һәм яңа бина салырга мәҗбүр булалар. Әмма яңа бина да ул мәктәпне юкка чыгарудан коткарып кала алмаган. Күренә ки, халыклар язмышында бу мәктәпләр дә, «Новокрещенская контора» кебек үк, дәһшәтле роль уйныйлар[1].

Миссионерларны саклар өчен дигән сылтау белән махсус командалар оештырыла, һәр губерниядә бу командаларга җитәкче итеп чины майор дәрәҗәсеннән дә түбән булмаган «комиссарлар» билгеләнә. Мәсәлән, Нижний Новгород губерниясендәге отрядка башлык итеп майор Гаврило Ларионов, Казан губерниясендә майор Лазарев, Воронеж губерниясендә майор Борис Ярцев, һәммә командаларга җитәкче итеп исә коллежский советник Федор Вячеслов билгеләнә.

Самодержавие бу көчләүләргә халык каршылыгын булдырмау чараларын да алдан кайгырта. Мәсәлән, 1728 елда патша губернатор һәм воеводаларга: «Халыкларны чукыну юлыннан аздыручыларны эзләп табарга, аларны һич кызганусыз үлем җәзасына тартырга, мәчетләрен яндырырга»,— дип наказ биргән була. 1740, 1742, 1744 елларда бу «наказ» ны кабат-кабат искә төшереп торалар. Җирле хакимнәр, патша шулай төртеп күрсәтеп, рухландырып тормаса да, халыкларны эзәрлекләүдә чикне-чаманы белмәгәннәр. Мондый «наказ»ларның чыгуы эзәрлекләнүче халык үзенә һичбер кайда ярдәм, таяныч, закон таба алмасын, яклауны эзләп йөрмәсен, дип күрсәтүгә генә хезмәт иткән.

Җәмәгатьчелекне куркытыр өчен һәм фаҗигале хәлләрнең сәбәбен эзәрлекләнүче, җәберләнүче бичараларның үз өстенә ябып калдырыр өчен, царизм нәкъ шул чорда шау-шулы тикшерүләр һәм хөкемнәр башлап җибәрә. Аларның нидән гыйбарәт икәнен, мәсәлән, Зөя өязе, Әстерхан, Оренбур процессларына карап билгеләп була. 1742 елда хөкүмәт губернаторларга мөселманнар Мөхәммәт диненә мәҗүсиләрне үгетләмиләрме? Мөмкин булган барлык чаралар белән шуны тикшерергә һәм гаепләләрне каты җәзаларга»,— дип күрсәтмә бирә. Зөя өязендә, сөннәтләнмәгәннәрме, дип барлык чувашларны комиссиядән үткәрәләр. 33 сөннәтле чуваш ислам динендә булганы, 260 мәҗүси чуваш сөннәтле икәне, 26 чуваш кызының татарга кияүгә чыкканлыгы ачыклана. Тикшеренүләр һәм суд эшләре 1749 ел урталарына кадәр дәвам итә. Чувашларны исламга күчәргә үгетләгән, дип 16 татарны кулга алалар һәм мәңгегә Себергә сөрергә, дип хөкем итәләр. Сөннәтле чувашларны христиан диненә күчәргә үгетләргә, риза булмасалар, камчы белән суктырырга, татарга кияүгә чыккан хатыннарны ирләреннән, балаларыннан аерып, үз халкы арасына кайтарырга һәм чукынырга «үгетләргә» дигән карар чыгаралар. «Крещенская контора» шикаяте буенча, Синод аларның балаларын татарлар кулында (әтиләрендә) калдырмаска, чукынган чувашларга өләшергә тәкъдим итә һәм Сенат шул хакта карар чыгара. (П. С. ЗХIII №, 963).

Әстерхан губернасында калмыклар арасында да шундый ук тикшеренүләр үткәреп, татарлар күпмедер калмыкны мөселман итү турында шаулы тикшерү башланып китә[2]. Оренбур губернасында да (Җаек шәһәрендә) утыз татарның калмык хатыннарына өйләнгән булуы ачыклана. Татарлар: «Ата-бабаларыбыз Җаекка күчкәннән бирле бездә калмык кызларына өйләнү гадәт булып калган. Кайсыбызның әнисе, кайсыбызның әбисе калмык»,— дип күрсәтәләр. Сенат Әстерхан һәм Җаектагы калмык хатыннарын татар ирләреннән аерып алып, Ставрополь өязенә, чукынган калмыклар арасына күчерергә һәм чукындырырга дип карар чыгара. Әмма монда аларны — «мөселманлыкка аздыручыларны» Оренбурга һәм Әстерханга җыеп, каты җәза белән янап, киләчәктә бу халык белән һәртөрле бәйләнешне туктатырга кушу карары гына чыгарыла.

Шул рәвешчә, һәр яклап әзерлек чаралары күрелгәннән соң, ясалма шау-шу тавышлары астында 1740 елда Идел буе халыкларына каршы һөҗүмгә сигнал бирелә. Ләкин, Анна Ивановна үлгәч, тәхет тирәсендәге шау-шулар бу эшне берникадәр кичектереп торырга мәҗбүр итә. Елизавета Петровна тәхеткә утыргач һәм берникадәр сәяси тотрыклылык төсмерләре сизелгәч үк, миссионерлар бу мәсьәләгә кабат әйләнеп кайталар. Руханиларны үз ягына аударудан файда күрергә комарланган Елизавета Петровна аларның тәкъдимен ике куллап күтә-

[1] Е. Малов. Новокрещенские школы в XVIII в. Казань, 1868. 97—116 бб.
[2] П. С. З. XIII т. № 9722.

реп алырга әзер тора. Әмма татарларга каршы һөҗүмгә ниндидер законлылык төсмере бирер өчен, берәр сылтау, боерыкка нигез булырлык юридик билгеләмә табарга кирәк була. Бу билгеләмәгә сылтауны «Новокрещенская контора» житәкчесе Дмитрий Сеченев табып бирә. 1742 елда ул Синодка татарлар өстеннән шикаять яза. Христиан диненгәге кешеләр (керәшеннәр) яшәгән жирдә мәчетләр эшләү килешми. Алар христиан күңеленә коткы сала, янәсе. Патшаларның «моннан соң яңа мәчетләр салмаска», дигән указы булуга да карамастан, татарлар яңадан-яңа мәчетләр коруны дәвам иттерәләр, дип зарлана Д. Сеченев[1]. Синод шул хакта Сенатка рапорт яза һәм патша указыннан соң салынган татар мәчетләрен җимерергә, яңадан мәчет салуны тыярга, христиан динендәге кешеләр керәшеннәр булган жирдән татарларны күчереп җибәрергә дигән тәкъдим кертелә. Сенат бу тәкъдимнәрне хуплый. Шуннан инде, Сенат карары нигезендә, мәчетләрне җимерү хәрәкәте башланып китә.

Фактлар бу хәрәкәтнең дә төрле мәкер-хәйләләргә нигезләнеп, җентекләп әзерләнгән булуын күрсәтә. Д. Сеченевның «тыю указыннан соң мәчетләр салу» фикере 1736 ел указын күз алдында тотып языла. 1736 елның 11 февралендә Казан губернасына, шул ук елның 15 мартында Уфа провинциясенә мәчет һәм мәктәпләр салу эшен тыеп указ җибәрелгән була. Сенатның «патша указларыннан соң салынган мәчетләрне җимерергә», дигән указы алынганнан соң, Казан губерния канцеляриясендә 1593 елда патша Федор Иванович «Казан воеводаларына җибәргән указны «табалар». Яңа «табылган» бу документ нигезендә, 1736 елдан соң түгел, 1593 елдан соң салынган барлык мәчетләрне махсус командалар белән һәр авыл саен җимереп йөрүгә әйләнә. Авылларының мәчете 1593 елга кадәр, ягъни шуннан 150 ел элек салынганын исбат итә торган документ, билгеле, бер авылда да булмый. Федор Ивановичның 1593 елгы «указы»нда да, нәкъ Д. Сеченев хатында һәм Синодның Сенатка тәкъдимендәгечә, христиан динендәге кешеләр яшәгән җирләрдә мәчетләр булуына борчылу, «соңгы елларда» татарларның һәр җирдә мәчетләр сала башлавы, христиан динендәге кешеләр яши торган җирләргә якын урнашкан мәчетләрне җимерү, татарларны аннан күчереп җибәрү тиешлеге турында «язылган»[2].

Кыскасы, татарларда яңару хәрәкәтен тар-мар итү эшен самодержавие рухи дөнья өлкәсенә һөҗүмнән башлап җибәрә. Ул заманда мәчетләр бер үк вакытта балаларны укыту урыны да булган. Мәчетләрдә китаплар, язма документлар сакланган, ягъни мәчет китапханә һәм архив вазифасын да башкарган. Самодержавиенең мәчетләрне гыйбадәт урыны итеп кенә түгел, беренче чиратта, халыкның мәдәни һәм белем-тәрбия мәркәзләре буларак эзәрлекләвен 1736 ел указында ук инде күреп була.

Сенатның карар чыгару хәбәре Казанга килеп житү белән ук, прапорщик Иван Посысальщиков башчылыгында гарнизон солдатларын җибәреп, шәһәрнең татар бистәсендәге дүрт мәчетне дә җимереп ташлыйлар (53 б.). Авылларда халык каршылык күрсәтмәсен өчен, һәр авылның сотникларын Казанга җыеп, Сенат карарын аларга ишеттерәләр (53 б.). Бик тә кулай сылтау һәм «законлы билгеләмә» табып биргән өчен, Д. Сеченевның шунда ук дәрәҗәсен күтәрәләр: ул Нижний Новгород губернасы епископы итеп билгеләнә. Вятка, Пермь, Воронеж, Пенза, Сембер, Әстерхан, Себер якларындагы мәчетләрне җимерү буенча да губерна идарәләре белән хәбәрләшүләр башланып китә (13, 55, 179 битләр).

60—123 битләрдә Казан өязендәге авыллар, алардагы йортлар һәм мәчетләр саны, кайда күпме мәчет җимерелү турында белешмәләр китерелә. Казан өязендә, бистәнекеләрне дә кертеп, 536 мәчет булган, 1743 елга шуларның 418 е җимерелә (154 б.). Галич юлындагы 17, Алат юлындагы 91 мәчетнең һәммәсе җимерелә. Җүрәй юлында 97 мәчеттән берсе, Нугай юлында 135 тән илле икесе, Арча юлында 192 мәчеттән алтмыш бише калдырыла.

«Эш»тә Тубыл губернасы һәм Әстерхан авылларында мәчетләр җимерелүгә карашлы кайбер материаллар, статистик белешмәләр дә бар.

Казан татар бистәсендәге мәчетләр җимерелгәч, бистәнең йомышлы татар вәкилләре (Сәфәр Умәров һ. б.) үтенеч бирергә Сенатка килеп житәләр. Аннары бүтән өязләрдән дә вәкилләр кузгала. Түбән авыл сотнигы Бакый Исмаилов, Сембер өязе Мәчәләй авылы йомышлы татары Мәмәдәли Мөхәммәдев, Пенза өязе Түбән Илҗә авылы йомышлысы Давыт Кудашев иптәшләре белән шул

[1]ЦГАДА, 248 ф. 14 тасвир, 803 төпләм, 52 б. Алда бу «эш»тән алынган материалның битләре текст эчендә генә күрсәтелә.

[2]Менә шул үзенчәлекләре һәм Казанда гына табылуы тарих китапларына XVI йөз документы итеп кертелгән бу грамотаның XVIII йөз урталарында шул чор хәлләренә каратып Зоя миссионерлары әзерләгән ялган грамота булу ихтималын искәртә.

өязләрнең бөтен татарлары исеменнән мәчетләрне ваттырмау турында бергә үтенеч бирәләр (21 б.). Бу үтенечләр шул заманда татарлар арасында зур оешканлык, бердәмлек, тапкырлык-тәвәккәллек булганын ачык сиздереп торалар. 1730 еллардагы А. П. Волынский мәсьәләсе тирәсендә үзләрен тотышы белән чагыштырып караганда, бу чорда татар халкы арасында рухи үсеш, янарыш нинди зур тизлектә барганы әйбәт күренә. Әмма, эчтәлекләре буенча, бу беренче үтенечләр әле кызгандыру, җәлләтүгә генә корылган. Аларга җавап итеп, Сенат Синодның мәчетләрне җимерү турындагы боерыгын куәтләве турында кабат карар чыгара да вәкил Бакый Исмәгыйль улына кул куйдырып, шуның күчермәсен тоттырып җибәрә (34—36 бб.) Күрәсең, Синод, мәчетләр җимерергә боерык биргәндә, Сенат указын да көтеп тормаган.

Юридик дәлилле билгеләмә табып кына бу карарларны үзгәртү мөмкин икәнен тиздән татарлар да төшенә башлый. Һәм андый билгеләмә табыла да. 1744 елда Казан бистәсе, Зөя һәм Сембер өязләре татарлары исеменнән Ибрай Сивушев, Әбляз Акбирдин, Морсәлим Майков һ. б. биргән үтенечтә мәчетләрне җимерү хәлләрен сөйлиләр дә янадан мәчетләр салырга рөхсәт сорыйлар. Чөнки мәчетләр халыкны ант иттерү һәм патшага ил исеменнән сәламәтлек теләп дога кылдырыр өчен кирәк, диләр (157 б.). Ягъни мәчетләрнең җимерелүе татарларны анттан — дәүләт каршысында үз өсләренә алган һәртөрле йөкләмәдән азат итә. Һәм, гомумән, ул заман төшенчәләре буенча, халыкны динсез калдыру аларга үзе теләгәнчә кыланырга хокук бирә, дип каралган. Шуңа күрә дәүләт үзенең бу «хатасын» тиздән төзәтергә мәҗбүр була. 1744 елда ук инде Сенат Казан, Әстерхан, Себер, Воронеж губерналарында җимерелми калган мәчетләрне яңа указ белән күрсәтмә биргәнгә кадәр җимермичә торырга, дип боерык чыгара (167 б.). Озакламый исә Казан татар бистәсендә 2 мәчет, авылларга 200—300 кешегә бер мәчет хисабыннан кабат мәчетләр салырга рөхсәт указы чыгарыла (202 б.).

Шуның белән мәчет гаугалары берникадәр тына. Әмма нәкъ шул көннәрдә татар халкының матди тормышын чыгырыннан чыгаруны күзләп, төрле башбаштаклыклар, мыскыллаулар башлап җибәрелә. Бу яңа эзәрлекләүләрне дәртләндерүче дә Дм. Сеченев булган. 1740 ел указында яңа чукынган христианнарны (керәшеннәрне) үз кавеме арасыннан күчереп җибәрү планлаштырыла. Бу яңа керәшеннәр арасында ризасызлык уята. Дм. Сеченев Синодка хатында: «Күченүләр — керәшеннәргә чукынган өчен җәза бирү сыман күренә, аларны матди яктан көчсезләндерә. Христиан диненә күчкәннәр булган җирдән мөселманнар куылырга тиеш»,— дип белдерә. Сенат аның бу тәкъдимен дә хуплый һәм 1743 елда христиан динен кабул иткән кешеләр булган урыннан мөселманнарны күчереп җибәрү тиешлеге турында күрсәтмә бирә (209, 362 бб.). 1744 елның яз башыннан татарларны авылларыннан күчереп җибәрү хәрәкәте башланып китә. Миссионерлар «күчерү» гаугасын чәчү башланганда кузгатып җибәрәләр. Аның ничек үткәрелүен Воронеж губернасы Шацк һәм Тамбов провинцияләре, Касыйм, Кадом, Инсар өязләре татарлары исеменнән Бикбай мирза Терегулов иптәшләре белән биргән үтенечкә карап күзалларга була. Авылларыннан татарларны күчереп җибәрер өчен, 1744 ел язында Воронеж губернасына командасы белән Б. Ярцев килә. Татарлар, хуҗалыкларын таркатып, ата-бабалары яшәгән җирләрдән күчәргә теләмиләр. Ярцев нәкъ чәчү өсте якынлашып килгәндә, барлык ирләрне кулга ала. Аларны салкында тоталар, кыйныйлар, ачлык белән җәзалыйлар (385 б.). Ир-атсыз калган авылларга, һичкемне чәчүгә чыгармаска, дигән боерык белән солдатлар куялар. Татарларның җирләре игелмәстән кала. Икмәксез калган татарлар, ачтан үлмәс өчен, берәр кәсепкә керешү нияте белән, күченергә ризалык бирәләр, күрәсең, аларны азат итәләр.

Яңа җиргә килеп урнашкач кына, күчерүче түрәләрнең исләренә җир мәсьәләсе килеп төшә. Алар: «Менә татарларны күчердек. Әмма бу авылларда аларга бирергә буш җирләр юк икән. Җир каян алырга?» — дип Сенатка мөрәҗәгать итәләр. Б. Ярцевка Сенат 1745 елда: «Җир белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл иткәнче татарларны авылларыннан кузгатмаска (382, 399 бб.), аларны кайда нинди җирләргә күчерү мөмкинлеген тикшерергә кушып указ җибәрә (382 б.).

Күчерүләр төрле губерналарда булган. Шул ук 1744 елда Әстерхан губернасындагы «Солтанавыл» татарларын (1119 кеше) Казан губернасына күчерү турында указлар чыгарылган. Указда шул татарлар арасыннан 73 сабый баланы, Беренче Петрның 1722 ел указы нигезендә рекрутлыкка алып, Архангел һәм Рига гарнизоннарына җибәрү турында күрсәтмә бар.

Керәшеннәр күчерелгәндә дә мөселманнар «өлешсез» калмаган. Мәсәлән, Е. Малов «О новокрещенской конторе» китабында Котыш (Рождественское) авылы керәшеннәрен Кыязлы һәм Кади авылы татарлары җәберләве турында яза.

Кадилар Котыштан 100 чирек басу һәм 1000 кибәнлек печәнлек жирләрне, Кыязлылар — 60 чирек басу һәм 600 кибәнлек печәнлекләрен тартып алганнар, имеш (131 бит). Бактың исә, бу Котыш авылына Сембер, Пенза өязеннән керәшеннәр күчереп утыртылган икән (139 бит). Яна күченүчеләргә жирне Кыязлы авылы татарларыннан тартып алалар. XVIII йөз урталарындагы чукындыру хәрәкәте тоташ менә шушындый ялган, яла, көчләү, мыскыллаулардан гыйбарәт.

«Новокрещенская контора» тәхетендә Д. Сеченевны алыштырган Стефан (монах булгач, Сильвестр) Головацкий да үз элгәресеннән калышмый. 1749 елның июлендә ул Тубыл митрополиты итеп күтәрелә һәм яна урында Казан губернасындагы һөнәрләрен дәвам иттерә: Себер татарларының балаларын көчләп тартып алып, чукындырып, христианнарга өләшә, кешеләрне, богаулатып, консистория подвалына ташлата һәм азатлык шарты итеп чукынуны куя. Шундый ук явызлыкларны ул Урал буе башкортлары арасында да алып бара. Аның халыкны көчләүләре җәмгыять өчен шулкадәр хәтәр төс ала ки, Сенат, жирле халыклар аның котырынуларыннан берникадәр яклау таба алсын өчен, башкортлар өчен Оренбурда, Себер татарлары өчен Тубылда ике рухани, ике зур чиновниктан торган махсус комиссияләр төзергә мәжбүр була (ПС. З., XIII т. № 9904).

Б. Ярцев кебек эшлекләләр дә «тырышлыкта» болардан калышмаган.

Нижегород губернасында мордвалар баш күтәреп үзләрен яклый алганнар, Урал, Себер мөселманнары — махсус комиссия төзетүгә ирешкәннәр. Чукындырулар вакытында, чынлыкта, хәрби хәлгә куелган Казан губернасында бу мөмкинлекләрнең берсе дә булмаган. Яклаучысыз калган татар халкына карата бу котырган түрәләр һәртөрле явызлыкны чикләнмәгән дәрәҗәдә эшли алган.

Менә шул таланган, үртәлгән халыктан христиан диненә күчкән кешеләр өлешендәге салымнарны да түләткәннәр. Нәкъ шул өстәмә түләүләр татар янару хәрәкәтенең матди нигезенә — халкыбыз хуҗалыгы тамырына балта чабу булган. Беренче Петр 1720—1721 ел указларында «Христиан диненә яңа күчкән кешеләр өч елга һәртөрле салымнардан азат кылынсын», — дип боерган була. Анна Ивановна заманында (1730 ел) бу указга: «Болардан алынырга тиешле салымнар христиан динен кабул итмәгән нәселдәшләренә йөкләтелсен», — дигән төзәтмә кертелә. 1740 елларга кадәр бу указларның халык хуҗалыгына тәэсире әле ул кадәр сизелми. Чөнки бу дәвердә христиан диненә күчүчеләр саны әле бик аз була. Мәсәлән, 1721—1740 елларда Казан губернасында 254660 имана җаныннан 12782 кеше генә чукынган (387 б.). Әмма 1740 елдан соң хәл кискен үзгәрә. 1740 елда — 338; 1741 дә — 8348; 1742 дә — 12358; 1743 тә — 10025, дүрт елда барлыгы 31069 кеше чукындырыла. 1746 елдан инде мордва, чуваш, мари, удмурт халыкларын тоташ чукындыру башлана. 1744 елда — 4895, 1745 тә — 10993, 1746 да — 73955, 1747 дә — 113392, 1748 дә — 38140, 1749 елның беренче яртысында — 23413, шул дәвердә барлыгы 264 788 кеше христиан диненә үтә (592 б.). Шулар арасында керәшен татарлары 3451 кешене генә тәшкил иткән (596 б.). Әмма ислам динендә калган татарлар христиан диненә күчкән үз кавемдәшләренең генә түгел, Идел буендагы чукындырылган йөз меңләгән мордва, чуваш, мари халыкларының салым һәм йөкләмәләрен (рекрут, ямчы һ. б.) түләргә һәм үтәргә мәжбүр ителәләр. Нижний Новгород, Пенза, Воронеж губерналарында христиан диненә күчкәннәр өчен салымнарны түләү 1744 елда ук инде Казан губернасындагы татарлар өстенә йөкләнәләр. Кыскасы, татарлар Идел буендагы яңа чукынган барлык халыкларның салымнарын түләргә мәжбүр ителәләр. Үз өлешләренә төшкән салымнарны да зур киеренкелек белән генә түләп бара алган хуҗалыклар бу көчләүләр нәтиҗәсендә бик тиз аяктан егыла. 1745 елдан башлап татарлар шул мәсьәлә буенча инде Сенатка үтенеч компаниясен башлап җибәрәләр. Бу чорны үтенечләр агымының иң көчәйгән вакыты дип билгеләргә мөмкин: вәкилләр җибәргән төбәкләрнең чикләре чагыштыргысыз киңәя. Казан, Нижний Новгород, Воронеж, Пенза, Сембер, Вятка вәкилләре үз губерналарындагы татарлар исеменнән бер үк вакытта, бер үк эчтәлекле үтенечләр белән Сенатка керәләр. Сенатта бөтен татар халкы исеменнән сүз йөртәләр: Сембер губернасы Идел аръягы Карамалы авылы йомышлысы Абушаһман Сәфәрев, Тау ягы Югары Чапкас авылы йомышлысы Биметов, Пенза губернасы Үзән станы Гали авылы сотнигы Ибрай, Саранск өязе Ләмбер авылыннан Йосыф Баймитов — төрле төбәк кешеләре 1747 елда бер булып бер үтенеч бирәләр (322 б.).

Христиан диненә яңа күчкәннәр өчен рекрут бирү халыкны аеруча интектергән. Бу мәсьәлә буенча зарланулар башка якны хәтта тоныкландыра да. Моның дәлилле сәбәпләре дә бар. Беренче Петр заманында рекрутлык хәтта урыслар өчен дә төрмәгә, каторгага китүдән дә куркынычрак булган[1]. Тел белмәгән, чит

диндәге кеше буларак кимсетелгән татар өчен ул кыенлык, билгеле, бермә-бер арткан. Әмма төп сәбәп бу да түгел, халыкның башкалар өчен рекрут биреп, иң таза эшче көчтән мәхрүм калуы да түгел. Рекрутлыкта, хәрби хезмәттә, татар халкының хокуксызлыгы аеруча күзгә ташланган. Рекрутлык мәсьәләсендә Беренче Петрның татарларга мөнәсәбәтен күрсәтүче документ сакланып калган. Бүтән диндәгеләрдән рекрутлар алу турындагы 1722 ел указы кәгазе читенә Падишаһ үз кулы белән: «Мордва, чирмешләрдән, урыстан алган кебек рекрут алырга, ә татарларны яшьли, хосусан, гарнизоннарга 10—12 яшьлекләрне алырга һәм аларны генералларга, штабчыларга деньщик кылып файдаланырга...»— дип язып куйган. 1722 елда Сенат бу язуны аерым указ итеп чыгарган[2].

Оренбур экспедициясе командиры Иван Кирилловның хөкүмәткә җибәргән язуында (1734 ел) шундый юллар бар: «Мишәрләр һәм ясаклылар аз булса да Оренбур шәһәрендә хезмәт итәргә билгеләнәчәк, әмма алар анда булганда, хатыннары кысыр калачак, каза тапкан солдатлар исә бөтенләй әйләнеп кайтмаячак... Мондый сәясәт бөтен мәмләкәттә борын-борыннан дәвам итә: швед, поляк, төрек сугышларында татарлар һәр җирдә алгы сафка бастырылды. Хезмәт иттерү дип саналса да, чынлыкта алар, ил-йортка кирәкмәгәнлектән, һәлакәткә дучар кылынды»[3]. Күренә ки, хөкүмәт татарларга карата хәрби хезмәтне беренче чиратта шул ук чукындыру, эзәрлекләү, юкка чыгару, геноцид сәясәтен үткәрүгә зур мөмкинлек биргән үзенчәлекле бер чара итеп караган. Билгеле ки, татарлар да бу сәясәтнең асыл мәгънәсен, җаны белән булмаса, тәне белән һәрчак сизеп торганнар. Шуңа күрә алар рекрутлыкка дәүләткә хезмәт идеалын гамәлгә ашыруның бер чарасы итеп карый алмаганнар, эзәрлекләүләргә каршы торган кебек үк, рекрутлык битлеге астына яшерелгән законсызлыкларга каршы да көрәш алып барганнар.

Чукынмаган өчен дип, татарлар башка эзәрлекләүләргә дә дучар ителәләр. Христиан диненә күчмәгән һәр дүрт кешенең берсе ат-арбасы белән Эльтон күленнән Идел башындагы шәһәрләргә тоз ташырга җибәрелә h. б. (522 б.).

Казан губерна кәнсәсе салымнар җыяр өчен ят диндәге авылларга унтер офицерлар башчылыгында командалар җибәрә. Бу солдатлар авылларда яши, чиксез җәберләүләр белән салым җыя. Түли алмаган кешеләрне кулга ала, шәфкатьсез кыйный. Халык, йорт-җирен ташлап, балаларын тотык итеп калдырып, туган якларыннан качып китәргә мәҗбүр була (523 б.).

Халыкның гадәттән тыш авыр хәлгә калуы турында тиздән Казан губерна кәнсәсе үзе дә сүз кузгата. 1748 ел башында Сенаттан, гадәттәгечә, салымнар суммасы һәм аның түләнү вакыты күрсәтелгән хат килә. Губерна кәнсәсе, ул салымнарны җыя алмаслыгын белдереп, 1748 елда Сенатка хат язарга мәҗбүр була. «Эш»тә, башка бер урында, бу таланулар күләмен бераз күз алдына китерерлек статистик мәгълүматлар да бар:

Казан губернасында 1750 ел башына татарлардан 19 389 җан юкка чыккан. 64 700 җан салым түләрлек хәлдә түгел. Калган 44998 җанны, ягъни бар халыкның өчтән берен каты кысрыклау юлы белән салым түләттерергә мөмкин. Әмма бу аларны да югарыдагы төркем сафына китереп кушачак,— диелгән хатта.

Күренә ки, хуҗалыкларын күчерү һәм яңа чукынганнар өчен төрле салымнар түләтү сәясәте берничә ел эчендә татар хуҗалыкларының 66 процентын таркатып бөтенләй юкка чыгара. Тарихта: «Казан наместниклыгы Петрга кадәрге чорда — Алексей Михайлович заманында, Русия бюджеты керем өлешенең өчтән берен биреп барган»[4] — дигән сүз бар. Беренче Петр заманында, аңардан соңгы еллар бюджетында да Казан губернасы өлеше яхшы ук сизелерлек булган. Шул керем чыганагының зур бер өлеше мәгънәсез башбаштаклыклар нәтиҗәсендә юкка чыгуы хөкүмәтне инде зур тәшвишкә сала. Өстәмә түләүләрне түли алмаган өчен кулга алынган татарларны азат итәргә, түләнмәгән бурычларны түләтүне дүртбиш елга кичектерергә, соңынан аны егерме елга бүлеп түләтергә, 1752 елга кадәр яңа чукынганнар салымын татарларга салырга, әмма аны түләүләрне биш елга кичектерергә күрсәтмә бирелә. Инде хөкүмәт каяндыр, нинди дә булса өстәмә керем чыганаклары эзләү белән баш ватырга мәҗбүр була.

*Дәвамы киләсе санда.*

---

[1]Н. И. Костомаров. «Русская история», 3 т.
[2]ЦГАДА, 248 ф., 8 тасвир, 450 төпләм, 921 б. ПСЗ, № 3884.
[3]Материалы по истории Башкирской АССР, 3 т., М.-Л., 1949, 494 б.
[4]Никольский Н. В. Конспект по истории народностей Поволжья, Казан, 1919. 23 б.

# АНАЛАР БӘХЕТЕ ӨЧЕН КӨРӘШҮЧЕ

ЯЗУЧЫ РӘИСӘ ИШМОРАТОВАГА 75 ЯШЬ



Әдәбият дөньясында кайбер әдипләр кулларына каләм алу белән танылып өлгерәләр, икенчеләре урта яшьләрдә танылалар, ә менә өченчеләренә танылу бәхете өлкән яшькә җиткәч кенә насыйп була. Бу хәл әдипнең язу алымына да, язмыш аңа бүләк иткән тормыш биографиясенә бәйле рәвештә дә бара.

Рәисә Ишморатова, башка әдипләр кебек, унҗиде яки егерме яшендә кулына каләм алмый. Җир йөзендә утыз ел яшәгәч кенә каләмгә тотына. Моның кайбер сәбәпләре бар. Әдибәнең тормыш юлы белән танышканнан соң аның ник шулай килеп чыгуына төшенәсең.

1986 елны дөнья күргән «Татар совет язучылары» китабында әдибә хакында мондый сүзләр әйтелгән:

«Рәисә Гыйниятулла кызы Ишморатова (Чебдарова) 1917 елның 20 июлендә Чистай шәһәрендә хезмәткәр-тегерменче гаиләсендә туган. Җидееллык мәктәпне һәм Чистай шәһәрендәге рабфакны тәмамлагач, бераз вакыт Арча (хәзерге Биектау) районы Коркачык авылы тегермәнендә әтисе янында эшли, аннары Азык-төлек институты каршындагы югары курсларда бер ел укып кайткач, Казан тегерманнәр трестында лаборант була.

Бөек Ватан сугышы башлангач, әти-әниләре янына кайта һәм Арчада ачылган эвакогоспитальдә сестра-хозяйка булып урнаша. 1942 елда аны Эчке эшләр халык комиссариаты (НКВД) системасына эшкә алып, 1943 елны фронт якларына җибәрәләр. Ул 1945 елга кадәр Украинаның Виница шәһәрендә Дәүләт куркынычсызлыгы комитетында оператив эшләрдә эшли. Казанга кайткач та, 1946 елның сентябреннән 1949 елга хәтле, шушы системадагы эшен дәвам иттерә. Ә 1952 елдан бирле Р. Ишморатова әдәби иҗат белән генә шөгыльләнә».

Менә бу — Рәисә ханымның кулына каләм алганчы булган тормыш юлы. Шактый ук зур һәм катлаулы язмыш! Ә бу зур тормыш алга таба аның иҗаты өчен бик тә кирәкле бай материал булып әверелә.

Рәисә Ишморатованың илленче елларда язган хикәяләреннән күңелгә ятышлысы, минем уемча, «Килен кайткач» хикәясе. Мин аны беренче тапкыр китаптан укымадым, артистлар укуында радиодан ишеттем. Ире сугышта үлеп калган тол хатын Фатыйма улы Илдарны бик зур авырлык белән карап-багып үстерә. Илдар Ленинград хәрби Академиясен тәмамлаган офицер булып җитешә. Өйләнә — башлы-күзле була. Менә шуннан соң инде хикмәтләр башлана. Килен дигән көйсез яшь хатын ирен гел әнисенә каршы котыртып, агулы еландай ыжгырып тора. Ике бозауга кибәк аера белмәгән кайбер булдыксыз ирләр мондый чакта хатын коткысына биреләә торган булалар, шуның белән газиз аналарына мәңгелек яра ясыйлар. Илдар исә хатын ягына аумый. Әнисенә рәхмәте зур булганга күрә, аңардан җан җылысын, уллык-балалык кайгыртуын кызганмый. Бик авыр шартларда, дөньяның ачысын төчесен күреп үскән Илдар хатынын үз ягына аудара — әнисен хөрмәтләргә мәҗбүр итә.

Хикәяне мин алтмышынчы елларда тыңлаган идем. Шуннан соң егерме еллап вакыт узгач, «Аналар» исемле хикәя һәм очерклар китабында ул хикәяне кабат очраттым. «Бәлки, мине артистлар тавышы, модуляция алдагандыр», — дигән уй белән әсәрне кабат укыдым — тәэсирем кимемәде. Хатын-кыз кулы белән, кайнана һәм килен, ана һәм бала мөнәсәбәтләрен, ул мөнәсәбәтләрнең тышкы чагылышын, психологиясен яхшы белеп язылган хикәя икән бу. Бу хәл мине соңгарак. Җыентыкка тупланган алты хикәянең алтысында да ясамыйча

чәчәкләми-чукламыйча язылган тормышчан әсәрләр булуы күңелгә ятты. Бераздан мин Рәисә ханымның иҗаты белән ныклабрак кызыксына башладым. Бер нәрсәгә төшендем: «Аналар» китабындагы хикәяләрнең тормышчанлыгы очраклы хәл түгел икән, аларның авторы еллар буе республикабыз районнарында йөреп, дистәләгән очерк бастырган, ә бу җыентык — шул хезмәтнең сөземтәсе икән. Моннан егерме биш еллар элек басылып чыккан кече күләмдәге әсәрләр бүген дә искермәгән. Сәбәбе гади: болар — гаиләгә кагылышлы әсәрләр. Гыйбрәтле хәл - - әле күптән түгел генә гаилә язмышы, ана — улы — килене һәм ана — кызы — кияве мөнәсәбәтләре әсәрләрнең үзәгенә куелмый иде. Ә менә заманнарның үзгәрүе, көнкүрешебездәге кискен үзгәрешләр яшь буынны тәрбияләү мәсьәләләрен алгы планга китереп чыгарды. Шулай булгач, табигыйдер ки, җәмгыятьнең күзәнәге булган гаилә үзенә игътибарны ныграк сорый башлады. Гомерендә байтак бала тәрбияләп үстергән, алардан күңел җылысын кызганмаган Рәисә ханым гаилә проблемаларын беркайчан да исеннән чыгармаган икән. Моннан үзебез өчен кирәкле бер нәтиҗә ясыйк алабыз: әдәбиятта, тормыш материалын сайлаган чакта, үзең яратып алган һәм шуны барлык аспектларында белә торган өлкәң булу — язучыны уңышка алып килә икән.

Соңгы елларда Р. Ишморатованың «Рәйхана» исемле повесте бәхетле язмышка очрады. Аның хакында авторга хатлар килеп тора, укучылар конференцияләре уза. Повесть 1985 елны «Казан утлары» журналында дөнья күргәч, шул ук елны аерым китап та булып басылып чыккач, күп санлы укучылар да, язучылар җәмәгатьчелеге дә әсәрнең тормышчан икәнен әйттеләр. Мин бу фикергә кушылам. Эвакогоспитальдә эшләгән шәфкать туташы Рәйхананың татар хатын-кызларына хас мөлаемлыгы, борын-борыннан килгән шәфкатьлелек сыйфатыбыз, авыруларны сабыр гына бага белү — аны җанга ятышлы образ итә. Госпиталь тулы тормыш белән яшәгәнне төгәл детальләрдә, ул тормышның мәшәкать-газапларын, авыр сыкрануларны, теш кысып түзүләрне сурәтли белеп сурәтләгәнгә күрә, әсәр безне ышандыра. Хәтеребезне яңарта. Боларның һәммәсе өстенә, дөресрәге шул киеренке шартларда Рәйхананың әти-әнисе белән булган мөнәсәбәте дә әсәрнең тукымасына бик төгәл кереп урнашкан. Түземле-сабыр булуы белән генә абруй казанмый Рәйхана. Тормыштагы ныклыгы, гүзәллеге, шул гүзәллекне гүзәл килеш саклый белүе, икейөзле бәндәләргә отпор бирүе белән дә, характер буларак, зурая, камилләшә бара.

Югарыда телгә алынган тормыш биографиясе менә кайчан үз дигәнен итә. Әгәр повестьның авторы сугыш елларында Арча эвакогоспиталендә эшләмәгән булса, сугыш мәхшәрләрен Украинаның Виница каласында күрмәсә, «Рәйхана» повестенда шул авыр заманның төгәл детальләрен укучыга ирештерә алыр идемени?!

«Рәйхана» повестена уңыш алып килгән тагын бер шартны әйтмәсәк, бигүк дөрес булмастыр. Әлеге повесть басылып чыкканчы ук Рәисә ханым инде берничә повестьның авторы иде. «Милиция лейтенанты» — моның бер мисалы. Бу — шулай ук яшь буынны тәрбияләүгә багышланган әсәр. Милиция органнарын якыннан белеп иҗат ителгән повесть. Ул җитмешенче еллар башында «Казан утлары» журналында басылып, СССР Эчке эшләр министрлыгы үткәргән конкурста бүләк алуга ирешә. Югарыда телгә алынган бер хакыйкатьне искә төшерик: Рәисә ханым каләмне кулына утыз яшьләрдә генә ала, дидек. Эзлекле әдәби белеме булмаганлыктан, аңа үзлегеннән күп өйрәнергә, юлында очраган кыенлыкларны җиңеп чыгарга, шул исәптән кайбер каләмдәшләренең аны язучы итеп танымаска тырышуларына да еллар буена җанында күтәреп барырга туры килә. Холкындагы ныклык һәм ихласлык булмаса, ихтимал, гайрәте чигеп, каләмне ташлаган да булыр иде. Ләкин ул үҗәт бер ныклык белән алга бара. Хәтерлим, «Милиция лейтенанты»н мавыгып укыдылар. Бу — «Аналар» җыентыгыннан соң бер адым алга китү иде. Кыскарак, тыгызрак итеп яза белү, сюжет-композицияне оештыра алу чагылды әлеге әсәрдә. Шулай да әле бу повестьта персонажларның тышкы физик портреты белән эчке психологик портреты кушылып җитми иде. 1980 елны басылып чыккан хикәяләр китабында геройларның тышкы портреты белән күңел дөньясын бер бөтен итеп куша алган хикәя күрдем мин. «Чәчәкләр» хикәясе. Автор бу хикәяне Чистай каласында Ярлылар комитеты председателе булып эшләгән әтисе Гыйниятулла Чебдаровка һәм әнисе Гыйшкыйҗамалга багышлый. Җир йөзендәге иң кадерле кешеләргә — әтиең белән әниеңә багышлана торган хикәянең һәр яктан өлгергән, камил булуы сорала бит инде. Үзеңнең бу эшеңә-гамәлеңә чамадан тыш җаваплы каравың кирәк. Фронтовиклар сүзе белән әйткәндә, бу — үз өстеңә ут алу белән бер. «Чәчәкләр» хикәясен укып чыккач, авторның әлеге әсәрне

эти-энисенә багышларга хакы барлыгына ышанасың. Бәләкәй генә хикәядә ниндидер сабыр моң, әчке моңаемлык, олы язмышлар бар. Әсәр беренче юлларыннан ук безнең көндәлек тормышыбызга карата җылы-лирик мөнәсәбәт белән ачылып китә: «Ничә еллар инде менә дүрт катлы йортның икенче каттагы тәрәзәләренә карап узам. Кышкы суык, ул тәрәзәләргә оста рәссамнар көнләшердәй бизәкләр төшереп, ак пәрдә яба. Яз җитеп, кояш карау белән, тәрәзә төбендә яран, кына, роза гөлләре шау чәчәккә күмелә. Чүлмәккә утыртылган өй гөлләре янында, бәләкәй генә пыяла вазада, беренче чәчәкләр умырзая, аннары энҗе чәчәк, шомырт төлгәшләре, бераздан канәфер чәчәге күренә. Күзгә кадәр шулай. Бер-берсен алмаштырып, төрле төстәге чәчәкләр тәрәзәне балкытып торалар. Алар беркайчан да шиңми...»

Төгәл язылган күренеш. Сүзләр гади, үтемле. Мин дип сөйләүче лирик герой көннәрдән бер көнне күрә — тәрәзә төбендә чәчәкләр юк. Ни булган? Шомланып өйгә керә. Өй буш, салкын. Чәчәк яратучы абзый вафат. Ап-ак чәчле, төенчек кадерле генә бер әби урын өстендә авырып ята...

Иплән кенә сөйләшеп китәләр. Зөләйха әби Вәли исемле егеткә булган мәхәббәтен сөйли. Гражданнар сугышын, Бөек Ватан сугышын узган, үзен кайчандыр үлемнән саклап алып калган Зөләйха-сылуга чәчәкләр алып кайтып торган Вәли Сәфәровның — инде дөнья куйган батырның тормыш юлы ачыла. Гыйбрәтле дә, чиксез авыр да гомер, әмма соклангыч гомер! Гүзәл Зөләйха белән батыр Вәлинең тышкы портретлары белән күңел матурлыклары бер бөтен булып кушыла бу хикәядә.

Болар — Рәисә Ишморатованың проза жанрында өкренләп, адымлап, карышлап үсә баруын дәлилләүче мисаллар. Ләкин бит ул әдәбиятка тәүге адымнарында прозаик булып килгән кеше түгел. Әдәбиятка ул бер пәрдәле пьесалар авторы булып килде. «Директор хатыны», «Бай кияү», «Куркыныч авыру», «Фирая», «Омтылыш» кебек әсәрләр моның мисалы. Шунысы күңелле, безнең әдәбиятта яшь каләмнәрне танучы, аларга ярдәм кулын сузучы өлкән әдипләр һәрвакыт булып торды. Рәисә ханымның «Бай кияү» әсәрен беренче булып Таҗи ага Гыйззәт укый. Әсәрне ул кат-кат эшләтеп театр сәхнәсенә кадәр китереп җиткерә. Безнең арадан бик иртә киткән фронтовик язучы Гамир Насрый, яшь драматургның беренче пьесаларына уңай бәя биреп, «Яшь сталинчы» газетасында (1954 ел, 12 декабрь саны) «Осталар сафына омтылу» дигән мәкалә бастыра. Мондый мөнәсәбәт яшь авторның күңелен канатландырмый.

Миңа калса, Р. Ишморатовага драматургия жанрында уңыш алып килгән беренче зур әсәре «Тормыш юлында» исемле драмасы булды. Илленче елларда Язучылар берлегенең иҗат секцияләре бик яхшы эшли иде. Бу әсәрне тикшергән секциядә мин дә катнаштым. Хәтеремдә — әсәр бертавыштан уңай бәя алды, өлкәннәр аның тормышчанлыгын әйттеләр. Ул сүз расланды: «Тормыш юлында» драмасы Башкорт дәүләт академия театрында, Башкортстанның Салават, Баймак, Ауыргазы колхоз-совхоз театрларында, Республика күчмә театрында уйналды. (Хәзерге К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры.) Озак уйналды бу әсәр. Аңа әдәбиятның күренекле вәкилләреннән Мостай Кәрим, Әмирхан Еники, Ибраһим Гази уңай бәя бирделәр. Ә бит болар — юк-бар әсәрне мактый торган әдипләрдән түгел.

Барлык фикерне бергә туплап әйткәндә, әсәрнең кыйммәтен болай билгеләп булыр иде: автор бу драмада мораль таркалуның, эшкә җавапсыз карауның, укып алган профессияңнән читләшүнең гомуми эшкә дә, гаилә мөнәсәбәтләренә дә никадәрле зарар китерүен сәнгать чаралары белән ачып бирә. Димәк, беренче зур күләмле пьесада ук инде «гаилә мөнәсәбәтләре» дигән төшенчә килеп керә. Без моны исебездән чыгармыйк. Чөнки без авторның прозасында инде бу төшенчә белән бер мәртәбә очрашкан идек. Төрле елларда Рәисә ханым иҗат иткән очерк һәм хикәяләрдә акчага табынучы, байлык артыннан куып, намусларын югалткан комсызлар, түбән зәвыклы бисгә мещаннары фаш ителә. Ә бүгенге заман ул кешеләрне күпләп мәйданга чыгарды. Безнең алардан күз яше түгәсе көннәребез алда әле! Спекулянтлык, алыпсатарлык, комсызлык күкрәп тора хәзер. Кибетләр, базарлар, караңгы подваллар алар белән тулы. Шулай булгач, Рәисә ханым драмасының тормышчанлыгын әсәр язылганга кырык еллап вакыт узганнан соң да сизеп торабыз. Шунысын да әйтергә кирәктер, Р. Ишморатова кире типларны сурәтләү белән генә чикләнмәде ул чакта, аларның антиподлары булган фидакарь җанлы укытучылар, мәгариф хезмәткәрләре, терлек караучылар, савымчы кызлар, булдыклы һәм намуслы колхоз рәисләре, һәвәскәр сәнгатьчеләр, сәхнәгә нур өстәүче данлы артистлар (Гөлсем Болгарская, Галия Булатова һ. б.) образ-

ларын укучыга алып чыкты. Нинди генә һөнәр ияләре, нинди генә проблемалар юк өлеге очеркларда!

Ахырга таба болар һәммәсе бер темага төйнәлә. Ул да булса яшь буынны тәрбияләү. Бу — аналарча кайгырту, бу — аналар бәхете өчен көрәш. «Тормыш юлында» драмасыннан башлап, «Яшьлек канат җәйгәндә» пьесасы аша, «Милиция лейтенанты» һәм «Рәйхана» повестьлары аша, үзе белгән, яраткан, эзлиэзли тапкан үз юлына — тәрбия мәсьәләләрен зур итеп күтәрү юлына килеп чыга язучы. Бу өлкәдә ул сизелерлек уңышларга ирешә. Шушы өлкә аша укучының һәм тамашачының ихтирамын яулый. Ихтимал, аны бу өлкәгә тормышта башкарган җәмәгать эшләре дә алып килгәндер. 1951—1963 елларны ул халык суды утырышчысы, аннары — Актаныш районы «Коммунизмга» колхозының почетлы колхозчысы (бу исемне юкка гына бирмиләр!), Татарстан Язучылар оешмасында местком рәисе, инде менә күпме еллар — Татарстан Язучылар берлеге каршындагы көнкүреш комиссиясе рәисе, әдипләр тормышын кайгыртучы. Әлеге дә баягы — ул башкарган эшләр гел гаилә мөнәсәбәтләренә, тәрбия мәсьәләләренә бәйле. Шулар янына өстәргә онытмыйк, ул безнең хөрмәтле өлкән язучыбыз Риза агай Ишморатның гомер юлдашы, берничә оя баланы карап-багып үстергән ана. Гаиләләр һәм үсмерләр язмышы белән турыдан-туры бәйле булган өлкәләрдә өзлексез эшләү, сугыш елларының авырлыгын үз җилкәсендә татып белү, ятимнәр һәм толларның күз яшенә битараф кала алмау аның иҗатының профилен билгеләдә, аны әдәбиятның зур һәм җитди юлына алып чыкты.

Рәисә ханымның бер автобиографик язмасында мондый юллар бар: «Гомер юлындагы чакрымнарның җитмешенче баганасы күренә башлагач, гәрчә ул бик шартлы билге булса да, артта калган еллар хакында моңарчы булганга караганда бөтәнчәрәк уй йөртә башлыйсың икән. Үткәндәге хәлләрне, вакыйгаларны, кешеләр белән үзара мөнәсәбәтләрне, кылган гамәлләрне, ирешкән казанышларны эрерәк иләктән илигәндәй буласың. Кәнендә-сәгатендә бик мөһим булып күренгән уңыш та, үз вакытында күңелне нык кына тырнап киткән тискәре күренеш тә, бу иләктән коелып кала, төссезләнә, әһәмиятен югалта. Хәтер исемлегенә теркәлердәйләре исә коелмый да, төсен дә җуймый. Алары йөрәккә якын, алары дөньядан кешенең үзе белән генә китәләрдер».

Акыллы фәлсәфә. Катлаулы тормыш юлы узып, «гомер чакрымнарының җитмеш бишенчесенә килеп җиткән әдибә, драматург, прозаик, җәмәгать эшләре фидакаре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, тәҗрибә туплаган кеше генә әйтә ала мондый фикерне.

Әдәбият — аның тормышы, авыр сынауларны җиңеп чыккан язмышы.

**Гариф АХУНОВ.**

## МИЛЛӘТНЕҢ ИҢ ЗУР ҖЫЕНЫ

19 июньдә башланып 22 июньгә кадәр барган Бөтендөнья Татар Конгрессы милләтебез тарихындагы иң мөһим вакыйгаларның берсе булып калачак. Конгресска татарның төрле кыйтгаларга чәчелеп яшәүче меңнән артык вәкиле килгән иде. Иң күп санлы делегацияләр АКШ, Төркия һәм Финляндиядән булды. Моннан тыш Австралия, Канада, Румыния, Польша, Франция, Япония, Кытай, Германия һәм башка илләрдән дә вәкилләр бар иде. Ә БДБ илләре арасында иң зур делегация Россиядән килде.

Бөтендөнья татарлары җыенында республика Президенты Минтимер Шәймиев зур чыгыш ясады. Ул татар халкының бай тарихы, бәйсезлек өчен көрәш баскычлары турында сөйләде. Татарстанның икътисади, сәяси хәленә, суверенлыкны ныгыту юнәлешендә башкарылган эшләргә, алдагы бурычларга тукталды.

Бу конгресс халыкларга, дәүләтләргә, Берләшкән Милләтләр Оешмасына Татарстанның бәйсезлеген танырга чакырган Мөрәҗәгать кабул итте. Даими эшләүче орган буларак, Бөтендөнья Татарлары Конгрессының башкарма комитеты оештырылды. Ул Татарстан Җөмһүриятенең башка дәүләтләр белән күпкырлы элемтәләрен ныгыту, татар милләтен берләштерү, мәдәни-этник мөнәсәбәтләрне үстерү өчен җавап бирәчәк.

Йомгаклау сүзе белән Президент М. Шәймиев чыгыш ясады.

Икенче көнне конгресс эше секцияләрдә дәвам итте. Кунаклар шулай ук Казан Сабан туйларында катнаштылар. 22 июнь көнне Бөтендөнья Татар Конгрессында катнашучылар шәһри Болгарга сәяхәт кылдылар.

## КОНГРЕСС ИСЕМЕНӘ КОТЛАУЛАР

Бөтендөнья Татар Конгрессы барган көннәрдә аның исеменә күп санлы котлаулар алынды. Россия Федерациясе Президенты Борис Ельцин җибәргән котлауда мондый сүзләр бар:

«Конгрессның эше гомумтатар проблемаларын хәл итүгә, Татарстан республикасында һәм Россия Федерациясендә милләтара татулыкка, халыкларыбыз арасында гасырлар буена килгән дуслык җепләрен ныгытуга булышлык итәр, дигән ышаныч белдерәм».

Шулай ук АКШның элеккеге дәүләт секретаре, күренекле политик Генри Киссинджердан да телеграмма килде. Өлешчә ул болай дип яза:

«Ике континент — Европа һәм Азия тоташкан җирдә урнашкан Татарстан, зур көч-кодрәткә ия булган хәлдә, үз төбәгендә икътисад өлкәсендә һәм интеллектуаль сферада мөһим роль уйный алыр».

Шулай ук Берләшкән Милләтләр Оешмасында үз вәкиллекләре булмаган милләтләр һәм халыклар оешмасы исеменнән генераль секретарь Микаэль ван Праг әфәнделәрдән, һ. б. лардан да котлау телеграммалары алынды.

## КАЗАНДА КОРБАН ГАЕТЕ

Мөселманнарның иң зур бәйрәме булган Корбан гаете быел 11 июньдә беренче мәртәбә рәсми төстә зурлап үткәрелде. Татарстан Югары Советы карары белән бу көн алдан ук ял дип игълан ителгән иде. Шуңа күрә милли мәркәзебезнең үзәгендә — Сөембикә манарасы янында — бу юлы халык аеруча күп җыелды.

Татарстанның баш мөхтәсибе Габделхак хәзрәт Саматов вәгазь укыды. Аннары Корбан гаете намазы башланды. Бәйрәм намазын татарлар белән бергә Төркия, АКШ, Германия, Япония, Әзәрбайҗан, Казагыстан һәм башка бик күп дәүләтләрдән килгән мөселманнар укыды.

Сөембикә манарасы янындагы гает намазы беренче мәртәбә телевидение аша күрсәтелде. Ә Мәскәү мәчетендәге гает намазын Останкино каналы аша карау мөмкин булды.

## ХАЛЫКАРА ТЮРКОЛОГИК КОНФЕРЕНЦИЯ

Бөтен дөньяның төрки телле халыкларын өйрәнүче галимнәре үзләренең чираттагы конференциясен уздыру өчен Казанга җыелды. Бу фәнни форумга чит илләрдән 200 ләп (шуларның 150гә якыны БДБ дәүләтләреннән) галим килгән иде. Татарстанның үзеннән катнашучылар исә 160 кеше булды.

Конференцияне Татарстан Югары Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин ачты. Үзенең кереш сүзендә ул Татарстанның икътисади-сәяси яктан БДБга кергән байтак дәүләтләрдән өстен торуын басым ясап әйтте.

Аннары АКШ профессоры Кәмал Карпат, Мәрмәрә университеты профессоры Надир Дәүләт һ. б. галимнәр чыгыш ясады.

Конференциядә катнашучы галимнәр секцияләргә бүленеп эшләделәр.

## МИРСӘЕТ СОЛТАНГАЛИЕВНЕҢ 100 ЕЛЛЫГЫ

Сталинның милли политикасына принципиаль рәвештә каршы торган, ил халыкларын сортларга аеру белән килешергә теләмәгән көчле рухлы революционер һәм дәүләт эшлеклесе Мирсәет Солтангалиев исемен дөнья халыклары яхшы белә. Ул шәрык дөньясын-

да бара торган милли азатлык хәрәкәтенең атасы дип санала.

Июнь аенда менә шушы олы шәхеснең юбилеена багышланган тантаналар булып узды. 12 июнь көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Мирсәет Солтангалиев кичәсе үтте. Аны кереш сүз белән Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев ачты. М. Солтангалиевнең тормыш юлы һәм күпкырлы эшчәнлеге турында докладны Татарстан Җөмһүрияте Премьер-министрының беренче урынбасары, Татарстан Фәннәр Академиясе президенты Мансур Хәсәнов ясады.

Казан мәдәни үзәгендә М. Солтангалиевкә багышланган фәнни конференция булды. Шунда ук бу олы шәхеснең тормыш юлын яктырткан күргәзмә ачылды.

М. Солтангалиев исемендәге мәйданда торгызылачак һәйкәл нигезенә таш кую тантанасы да булды.

## М. ШӘЙМИЕВНЕҢ АКШ ҺӘМ КАНАДАГА, ЕВРОПА ИЛЛӘРЕНӘ ВИЗИТЫ

Бәйсез Татарстан дәүләте дөнья илләре белән үзенең бәйләнешләрен үстерү буенча бер-бер артлы ныклы адымнар ясый. Республика Президенты М. Шәймиевнең АКШ һәм Канадага, Европа илләренә булган эш визиты әнә шуңа мисал булып тора.

Президент һәм делегация әгъзалары үзләре булган илләрнең күп санлы эшлекле вәкилләре белән очраштылар. Казан аэропортын реконструкцияләү һәм Алабуга автомобиль заводында яңа җиңел машиналар җитештерү, нефть эшкәртү заводы төзү һ. б. төрле хезмәттәшлек турында килешүләргә ирештеләр.

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 70 ЯШЬ

Журналыбызның 70 еллыгы бу олуг бәйрәмнәр белән бер вакытка туры килү дә аерым бер мәгънәгә ия иде. 18 июнь көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында булган зур тантанада бу бигрәк тә ачык чагылды. Залда җир шарының төрле кыйтгаларыннан җыйналган хөрмәтле кунаклар бик күп иде.

Тантананы Республика Җөмһүрияте Премьер-министрының беренче урынбасары Мансур Хәсәнов ачып җибәрде. Кереш сүзендә ул журналның милләт тормышында тоткан бик тә мөһим урынын билгеләп үтте, «милләт өчен мәркәз булган калабызда «Казан утлары» балкымаса, дөнья буйлап чәчелгән милләттәшләребездә туган җирне сагыну хисе болай ук дөрләмәс иде» диде.

Аннан соң журналның баш мөхәррире шагыйрь Равил Фәйзуллин сүз алды. Ул бүгенге сәяси һәм мәдәни вакыйгалар яктылыгында «Казан утлары» тоткан төп юнәлешләрне бәян итте, алда торган бурычларга тукталды.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев, «Ватаным Татарстан» газетасы баш мөхәррире Мөнир Әһлиуллин, «Сөембикә» журналы баш мөхәррире Роза Туфитулова, «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире Ренат Харис, «Салават күпере» журналының баш мөхәррире Зиннур Хөснияр, Казан дәүләт университеты профессоры Миркасыйм Госманов, Балык Бистәсе районы администрация башлыгы Хатыйп Газизов, Татарстан Югары Советы депутаты Фәндәс Сафиуллин, Уфадан килгән күренекле шагыйрь Нажар Нәҗми, язучы Аяз Гыйләҗев һ. б. чыгыш ясаучылар да журналга югары бәя бирделәр.

Чит илләрдән «Азатлык» радиосы вәкиле Фәрит Иделле, Австралиядән Сәгыйть Садри әфәнделәрнең чыгышы аеруча зур игътибар белән тыңланды.

Тантаналы кичәдә Татарстан Югары Советы Рәисе урынбасары Зилә Вәлиева «Казан утлары» журналына Татарстан Президентының Мактау грамотасын тапшырды.

Тантаналы кичәнең икенче өлешендә Татарстан җыр һәм бию ансамбле зур концерт куйды.

## ЖУРНАЛГА ҺӘМ АНДА ЭШЛӘҮЧЕЛӘРГӘ БҮЛӘКЛӘР

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Указы белән татар әдәбиятын үстерүдәге зур хезмәтләре өчен һәм чыга башлавына 70 ел тулу уңае белән «Казан утлары» журналы Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Әдәбият һәм сәнгатьне үстерүдәге казанышлары өчен журналның баш мөхәррире урынбасары Рашат Мияссәр улы Низамиевка һәм проза бүлеге мөхәррире Шамил Мәгыйзь улы Маннаповка «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр бирелде.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Беренче биттә:** «Батырша». Уфа шәһәре рәссамы Мэлс Вафин эше.

Ю. ФИЛИМОНОВ фоторепродукциясе.

**Дүртенче биттә:** танылган шагыйрь, драматург Рөстәм Мингалим.

М. КОЗЛОВСКИЙ фотосурәте.

Tatarstan تاتارستان

# ТАТАРСТАН

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!

Әгәр дә синең заман югарылыгында торган мәгълүматлы, белемле, киң карашлы зат буласың килсә, моңа ирешүнең бердәнбер юлы — «Татарстан» журналына язылу.

«Татарстан» — милли хәятебезне иң тулы чагылдыручы, аңа дөрес бәя бирүче төп журнал. Шуңа күрә дә аны хөкүмәтебез үз канаты астына алды.

«Татарстан» — бүгенге иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади тормышыбызга төпле анализ, үзең өчен милли тарихның төрле дәверләрен ачу, халкыбызның бай мәдәнияте, әдәбияты-сәнгате, бетү куркынычы алдына килеп баскан теле хакында уйланулар, яңарыш кичергән дине, гаилә-тәрбия мәсьәләләре, гореф-гадәтләре, йолалары турында кызыклы язмалар дигән сүз.

«Татарстан» — бер үк вакытта теоретик-нәзари журнал да. Ул җөмһүриятебез, милләтебезнең барлык рухи казанышларын укучыга җиткерүне үзенә максат итеп куя. Журнал битләрендә фән дөньясына да зур урын бирелә. Күренекле шәхесләр, галимнәр, чит илләге милләттәшләребез — журналның авторлары.

Журналның бәһасе — ярты елга 96 сум. Татарчасының индексы — 73377, русчаныкы — 73947.

Һәр нәрсәдән хәбәрдар булырга омтылган белемле, киң карашлы кешегә «Татарстан»сыз яшәү мөмкин түгел!

**«Татарстан» журналы редакциясе**



Бәясе 1 сум 80 тиен

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен во Всесоюзный каталог